
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

4. 1991



## Нияз АКМАЛ

### Тукай

Кешеләрне шул сорау борчый:
Тереклеккә тере су кайда?
Йөз яшәгән картка килгән кебек,
Килә кеше япь-яшь Тукайга.

Мең тарафка таралганы Җирнең
Бер тарафка куйган төйнәлеп.
Тукай кебек карый белү кирәк,
Һәр төенгә шулай төбәлеп.

Төбәлгән ул... Халык язмышларын
Йөрәгенә аннан төйнәгән.
Чынбарлыгын әкият итеп әйткән,
Әкиятендә чынын сөйләгән.

Пәйгамбәр дә түгел, бары — шагыйрь!
Юраганы әмма юш чыга.
Шүрәлене бер очрату кирәк
Өнсез, телсез калган юлчыга.

Ә юлчыны шул сорау борчый:
Тереклеккә тере су кайда?
Мең яшәгән картка килгән кебек
Киләчәкләр әле Тукайга...

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
БЕРЛЕГЕ
ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1991

4


## *Бу санда*


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Р. ӘХМӘТҖАН. Күлгә төшкән идем. *Шигырьләр* . . . 3
И. ГЫЙЛӘҖЕВ. Кешелегем калды елап... *Шигырьләр* . . . 8
З. ЗӘЙНУЛЛИН. Сугыш алды малайлары. *Повесть* . . . 10
Н. АРСЛАНОВ. Төшмим. *Шигырьләр* . . . 72
Н. ИЗМАЙЛОВА. Улларыма исем куштым. *Шигырьләр* . . . 77
З. САДЫЙКОВ. Ясалма чәчәкләр. *Повесть* . . . 80
Г. ТАВЛИН. Буран. *Хикәя* . . . 115
Р. ГАЗИЗОВ. Күккә ябышкан болыт. *Хикәя* . . . 120

ЮНЫС ӘМРӘНЕҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Н. К. ЗӘЙБӘК. Миллионнар күңелендә . . . 125
Ю. ӘМРӘ. Шигырьләр . . . 127

ПУБЛИЦИСТИКА

Ә. ЕНИКИ. Кем җаваплы? . . . 131
Р. ЯГЪФӘРОВ. Хәлләрең ничек, мәктәп? . . . 143

ӘДӘБИ МИРАС

М. ГАЙНЕТДИНОВ. Тукайның «адашкан» шигырьләре . . . 146

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тукайлар рухы (*А. Хәлим белән әңгәмә*) . . . 149

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

А. СӘГАДЕЕВ. Солтангалиев һәм Советлар Россиясенең милли сәясәте . . . 158
И. ЗАҺИДУЛЛИН. Җыеннар тарихыннан . . . 174

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Сәрвәр Әдһәмованың тууына — 90 ел . . . 176

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. ШӘРИПОВ. Хикәяне күңел сагынган . . . 178



ТАТАРСТАН
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркәтип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-36-12.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

СӘНГАТЬ

Ә. ЯҺУДИН. Шигъри сүз куәте. (*Истәлекләрдән өзек*) . . . . . . . . . . . . . . 180

ЮМОР-САТИРА

Р. ЗАРИПОВ. Мин кемнән ким? . . . . . . 185
А. ШАКИРҖАНОВ. «Су анасы» гаепле, иптәшләр! . . . . . . . . . . . . . . . 186

Котлыйбыз! . . . . . . . . . . . . . . . 177
Каләмдәшләребез — СССР Язучылар берлегенең яңа әгъзалары . . . . . . . . . . . . 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . 189

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повести З. **ЗАЙНУЛЛИНА** «Мальчики предвоенных лет», З. **САДЫКОВА** «Искусственные цветы», рассказы Г. **ТАВЛИНА** «Метель» и Р. **ГАЗИЗОВА** «Застывшие на небе облака», новые стихи **РАШИТА АХМЕТЗЯНОВА**, **Н. АРСЛАНОВА**, **И. ГИЛЯЗОВА**, **Н. ИЗМАЙЛОВОЙ**.
«Праздник творчества турецкого поэта Ю. Амры»: статья **Н. К. ЗЕЙБЕКА** «В сердцах миллионов»; стихи **Ю. АМРЫ**.
«Публицистика»: статья **А. ЕНИКИ** «Кто ответит?», **Р. ЯГЪФАРОВА** «Как живется, татарская школа?»
«Литературное наследие»: **М. ГАЙНУТДИНОВ**. «Забытые стихи» Г. Тукая».
«Литературная критика»: беседа критика М. Валеева с поэтом, публицистом А. Халимом.
«К истории культуры»: статья **А. САГАДЕЕВА** «Султангалиев и национальная политика Советской России».
«Книжное обозрение»: **Р. ШАРИПОВ** рецензирует сборник рассказов С. Шамси.
«Искусство»: отрывок из воспоминаний **А. ЯГУДИНА** «Сила поэтического слова».
«Юмор-сатира»: рассказ **Р. ЗАРИПОВА** и рецензия-шутка **А. ШАКИРЗЯНОВА**.
Новые члены Союза писателей СССР.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: юбилейный сборник классика турецкой литературы Юнуса Амры, изданный в Турции; писатель и ученый, лауреат госпремии ТССР им. Г. Тукая Ибрагим Нуруллин.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Г. Хөснетдинова.

Производствога бирелде 15.02.1991 ел. Басарга кул куелды 16.04.1991 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70\times108\,^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 42504. Заказ И-69. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1991 ел.

# Рәшит Әхмәтҗан

## Күлгә төшкән идем

Киләә дә җил, бозлы кулы белән
Тәрәзәгә бәрә:
— Сез генә
Булдырасыз. Төшеп карагыз бер
Серләр тулы Кабан төбенә...

Сабыр ит, җил! Безнең җаныбызны
Дауламыйсың ласа... Әле мин
Өйдә түгел. Күлгә төшкән идем,
Кайгыларым авыр — менәлмим.

Көтеп торам әле тегеләрне —
Алтын-көмеш эзләүчеләрне,
Төшләренә кергән хәзинәдән
Һаман өмет өзмәүчеләрне.

Күрсәтәсем килә Колшәрифнең[1]
Шәкертләре баткан көймәне.
(Ауса ауды биек манаралар,
Ятка беркем башын имәде.)

Табасым бар әле тагын монда
Сөембикә гүзәл балдагын.
Җыр язылган булыр: «...әй, алдадың,
Абайламый калдым алдагын.»

(Илдән китеп бара. Иреннәрен
Бер чылатыр иде — су канлы.
**«Алла суксын! Шаһгалиләр[2] мине**
**Урысларга сатып куанды».**

**Китә... Сөембикә!**
**Дүрт йөз елга**
**Үлә-үлә халык чигенә.**
**Мәет өсләреннән атлый-атлый,**
**Коллык килә татар иленә.)**

---

[1] Колшәриф — шагыйрь, мәдрәсә тоткан дин галиме, илче. 1552 нче елның 2 октябрендә Явыз Иван Казанны яулап алган көнне үзенең шәкертләре белән бергә кулына кылыч тоткан килеш батырларча һәлак була.

[2] Шаһгали — урыс патшалары кулы белән Казан тәхетенә өч мәртәбә куелган Касыйм ханы. Үз халкына каршы коточкыч явызлыклар эшләгән бәндә.

Көтеп торам әле тегеләрне.
Актарсалар тагын әз генә,
Тау-тау кеше сөякләре ята —
Күл төбендә шундый хәзинә.

Сандык-сандык алтын эзләп йөргән
Комсызларның җаны әрнесен:
Ул алтыннар күптән балкыта бит
Меңәрләгән чиркәү тәресен.

Төптә кылычлар бар. Хәзинәгә
Алар белән булмый юл ачып.
Кешеләргә акыл кирәк чакта,
Кала алсаң, алтын, кал качып!

Кабан күле — көзге. Һәркем үзен
Бер карасын иде көзгедән.
Сезгә алтын кирәк. Ә милләтнең
Тәсбих төймәләре өзелгән...

Ничә гасыр узды.
Менә бүген
Ирек алган халык, иң элек
Аумый калган соңгы манараның
Алтын Аен куйды меңгереп.

Кояш чыгышына шаһит булып,
Бу бәйрәмгә ярты ил килде.
...Кол Галине күреп... Шаһгалинең
Йөрәге ярлып үлде шикелле...

## Булмый ул!

*Рәшит Ягъфәровка*

Таныдым. Теге давыл бу.
Нигезгә бәрә! Димәк,
Ул тынсын өчен упкынга
Корбан бирергә кирәк...

Төн җитте. Чират — **минеке**.
Суырып алыр агым...
Һәм булыр упкыннан чыгып
Башны калкыткан чагым.

«Ай-һай, дөнья, туйдым синнән»,—
Дип әйтер өчен түгел.
Ымлаган иде йолдызлар:
«Ни булса — безгә үрел!»

Соңгы күренү булыр ул,
Соңгы үрелүләрем,—
Батармын туганнарымның
Озайтып гомерләрен.

Кешедән туйган дөньяга —
Шул булыр минем бүләк.
(Салган бөтен ясакларын
Бетергән идем түләп.)

Мине кызганамы әллә,
Офыклар кызыл төстә.
Су астында да әйтермен:
Бу дөнья безнең өстә бит,
Бу дөнья безнең өстә.

Ә син, дус, кызганма мине,
Без — үлми торган халык!
Булмагач булмый икән ул,
Халыкның җанын алып!

Мин яшәгән давыл-дәвер аша
Рухым, жаным киләчәккә шакый:
— Фанилыгың, дөнья, гомер түгел,
Кешелекнең хакыйкате бакый!

## Язгы ташу

Офыкларга бага-бага
Чыгам яшел сукмакларга.
Юк юлдашым дияр идем —
Сулар ага, силләр ага.

Гомеремнең кайсы чоры,
Кайсы жыры — язгы ташу?
Илдән китеп югалганчы,
Хәерлерәк күккә ашу.

Яшел булгач — яшен сукмас,
Карыйм яшел таулар ягын.
Әллә жиргә килгән чагым,
Әллә жирдән киткән чагым?

Кая китәр, кая житәр —
Сулар ага, силләр ага...

Китүчеләр китә инде,
Кемнәр кайта бу дөньяга?

Таудан күрәм су төбенә
Батып барган талларыңны —
Сулыш алмый көтеп торам,
Көтәм тартып алганыңны.

Дөнья, дөнья, кайда жаның,
Ник тамчы да кымшанмыйсың?!

Күз алдымда алды ташкын
Таллардагы кош оясын,—
Ул көймәгә кем сыяр соң —
Синме?
Минме?

*

Ялгызбаш идем. Исәнме?
Син монда икән, миләш!
Еракта елаган чагым,
Якыным булып сөйләш.

И-и-и, тәлгәшләрең кып-кызыл,
Синең дә көннәр канлы.
Минем дә йөрәгем канлы,
Мине дә кемдер алды.

Иллэрдән каерып алып
Китте бит, китте кемдер...

Хәзер аларча яшәргә
Бу жанны ничек күндер!
Бер генә минут калган ич,
Ул «яшәү» башланырга.
Синдә — ут. Мөмкин икән бит
Утларга ташланырга.

Бар икән әле безнең дә
Балкыйсы көннәребез!
Жилләрдә... илләргә житәр
Кушылган кулләребез.

## Синме?

Өстә калганмы дөньяның вак-төяге,—
Тамырларның кочагында кем сөяге —
Беләсеңме?

Агачларның нигә соң ул асты икән,
Әллә үзе кискән агач басты микән —
Белмисеңме?

Бар кешегә бәхет даулап яшәгәнме,
Һәм бар кеше — бер кешегә таш бәргәнме, —
Белмәдеңме?

Безнең дә бит чак-чак исән калды башлар,—
Таш бәрүдә мәргән булды замандашлар —
Беләсеңме?

Кочар икән безне кайда, кайсы тамыр,
Безне яшел яфраклардан кемнәр таныр —
Улым, синме?

Кешеләрне яклаганда кыйнадылар,
Кыядан ук ыргытырга кыймадылар.

Уйладылар: — Кыйнаганда безне ятлар —
Бәлки әле шушы адәм килеп яклар...

Мин дә уйлыйм йөздән канны сөртә-сөртә:
Болар белән мине алда ниләр көтә?

Һәр терене яклап җирдә яшәдем мин,
Балкып тордым, юк-бар өчен дәшмәдем мин.

Хәзер инде әйтергә дә кыенсынам:
Гомер үткән даладагы кое сыман.

Сусаганга су биргәнмен... Үткән көннәр...
Көннәремне гомер иткән әнә кемнәр!

Затсызларны үз урнына кую кирәк,—
Уйларына хәнҗәр булып уел, йөрәк!

Каршы сук та — батмасыннар билдән генә,
Басарлык ит җәһәннәмнең иданенә!

## Кояш төшкән кайтыр юлларга

Ил капкасын кагам...
Өр-яңадан
Өлгердем мин җиргә туарга!
Кичерерсез, туры килә хәзер
Үз урнымнан сезне куарга.

Сез талаган бөтен хәзинәне
Кайтарыгыз димим берьюлы.
Канун китабына теркәгез, мин —
Кай җирләрдә туган, кем улы?!

Икенчесе — минем туган телне
Кире кайтарырга сез тиеш:
Тик карагыз,
«Әнкәй» дигән сүзнең
Моңы торган булсын шул килеш!

Бу ике шарт үтәлергә тиеш,
Үтәлергә тиеш бүгеннән.
Тереләчәк телем. Үз уллары
Коткарачак аны үлемнән,

Тереләчәк иман! Ул әлегә
Далаларда йөргән бер качак...

Ул адашкан барлык балаларын
Үз өенә алып кайтачак.

Без куылган идек.
Өр-яңадан
Өлгердек бит җиргә туарга!
Кояш төшкән... халык йөрәгенә
Алып кайта торган юлларга.

❁

Кайтып җиттем бу дөньяның
Бер яфраксыз ягыннан.
Таптым, кактым — сезнең өйнең
Капкалары ябылган.

Шакыйм, шакыйм — юк, ачылмый,
Ник ачылмый капкагыз?
Иксез-чиксез бу дөньяга
Ялгызымны япмагыз!

Дуслар, сезгә ниләр булды? —
Капка кагам. Бикләнгән.

Мин кайттым, мин! Кайталмас дип,
Кайсыгыздыр шикләнгән.

Йөрде мине яклый-яклый,
Саклый-саклый Сөюем...
Кертмәсәгез, китәм инде,
Сөюем бар — үз Өем!

Минем Өем бу дөньяның
Бер яфраксыз ягында.
Сугылыгыз — сулышыгыз
Бик кысылган чагында.

## Каргышлары безнең өстәдер

Оныттыңмы әллә? Хыянәтең
Яралады — йөрәк канады.
Чәч агарды. Калган караларын
Таң яктысы табып санады.

Үз иясен ташлап,
кыялардан
Упкыннарга чумды яшь акыл...
Ул чак миңа сабырлыклар биргән
Сагышыма табын, дога кыл.
Әгәр кулга богау салмый торса
Бик аз гына шунда сагышым,—

Кабатларга тиеш булганмын бит
Отеллоның соңгы ялгышын.

Шушы сагыш — үлем элмәкләрен
Синнән, миннән салдырган икән,—
Сөюнең дә шунда яшеренеп
Берәр нуры калмады микән?

Калгандыр ла, бардыр, яшидер ул —
Инде күптән сары төстәдер...
Сары төсләр тагын өстәлер лә —
Каргышлары безнең өстәдер.

❁

Күңелемдә барны барлап яшим,
Саклап яшим — үлмәм!
Күңелемдә юкны мин барыбер
Беркайчан да күрмәм.

Күңелемдә юкны беркайда да
Мин барыбер тапмам.

Күңелдәге дөньям, китмә миннән —
Үлемнәрдән саклан!

Үлемнәрдән саклан, халкым, телем —
Сакла, туган илем!
Сау булсагыз, үзем... күзегезгә
Күренмәс тә идем.

# Илдус Гыйләҗев

## Кешелегем калды елап...

Килде дә ул кәгазь сузды,
Чират тормый эчкә узды:
Әйтерсең лә бер вәхши зат
Пычак белән җанга сызды...

Нишләде соң бу мәмләкәт,
Ничек мондый хәлгә төште?
Кеше кадәр кешедән дә
Мөһәр суккан кәгазь көчле...

Дәүләте дә кәгазь өеп
Корылганмы әллә моның?
...Затлы кәгазь йөрткән түрә
Аңлый диме халык моңын?

Әнә ничек кереп бара,
Алла диеп үзен уйлап.
Тапталган бер чәчәк кебек,
Кешелегем калды елап...

## Мин идем ул

Ләббәйкә, дип, биеп торган,
«Кызыл күзлек» киеп йөргән —
Мин идем ул, гөнаһ шомлыгы.
Ахмакларга күзе баккан,
Дәртләндереп кулын чапкан —
Мин идем ул, шайтан алгыры.

Телен, денен санламаган,
Милләт зарын аңламаган —
Мин идем ул, ләгънәт оргыры...
Соң булса да акыл кергән,
Кәгъбәсенә йөзен борган —
Монсы да мин... рәхмәт яугыры!

## Рәсәй

Рәсәй бу...
Туймас тужлык калыбы:
Чуртан йоткан маймыч төсле
Илнең күпме халыгы.

Рәсәй бу —
Гаделсезлек үрнәге.
Тиргә батып эшләгәннәр
Анда рәхәт күрмәде.

Рәсәй бу...
Каршы әйтсәң — таптарлар.
Нәселеңне корытырлар,
Еллар үткәч... акларлар.

---

*Илдус* ГЫЙЛӘҖЕВ *(1946) — шагыйрь, «Җир китабы», «Җилкенү» исемле китаплар авторы. Азнакайда яши.*

## Туры сүз

*(Рус шовинистына)*

Дөрес түгел, дөрес сөйләмисең,—
Алдашырга ярамый...
Китапларда, киноларда
Без һаман да «поганый».
Җылы караш, йомшак мөнәсәбәт,
Юкса дуслык таләбе...
Безнең исем белән йөри
Сездә шайтан таягы.
Беркемнән дә ким-хур булмасак та
Шөһрәт, сыйфат ягыннан;
Анадан тумас борын ук
Нигә тамга салынган?
Үзеңә тиң безне санамыйсың,
Йөрәкне шул яралый.
Авыр алма, сүзем туры:
Татар бит мин, «поганый».

## Авылдан мин

Авылдан мин, буразнадан,
Басу-кырлар арасыннан;
Җан суы итеп эчәрлек
Саф чишмәләр тарафыннан.
Юып-юып бетмәсә дә
Кара төсе кулларымның —
Тәмле исен саклый алар
Уңдырышлы кырларымның.
Яшәвемнең мәгънәсе дә
Гади генә ике шәйдер:
Олпатларым-кешеләргә
Иминлек һәм ипекәйдер!

❁

Ятим бу дип уйламагыз,
Үстерделәр баштан сыйпап.
Бар бит әле кешеләрдә
Миһербанлык дигән сыйфат.

Мескен бу дип уйламагыз,
Күз яшемне качып сөртәм.
Котыпларны эретерлек
Җан җылысы саклап йөртәм

Бетә бу дип уйламагыз,
Тамырым нык, үсәм әле.
Күләгәдә көн күрсә дә,
Халкым яши, исән әле....

Татар бетә дигәннәрнең
Өметләрен кисәм әле,
Болытларны тишәм әле...

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

### Зәки Зәйнуллин

# СУГЫШ АЛДЫ МАЛАЙЛАРЫ

ПОВЕСТЬ

## Юкә бурлары



Авылның Базар урамыннан Югары очка күтәрелгән чакта, Бәләкәй Базар, аннан таш коймалы Хәким Бабач йортын үткәч, сулга борылып, Нигъмәт Япун тыкрыгына керсәң, тәүге өй картечке төшерә торган урын була. Тик анда эшләгән пеләш башлы, алтын күзлекле яһүд, картечкәгә төшерү мәшәкате аз булганлыктан, күпчелек вакытын үзенең бакчасында үткәрә.

Татарлар гына яшәгән бу авылда аның бакчасы аерым бер игътибарга лаек. Ул авылга килгән көннән башлап, өч-дүрт ел буена бик ныклап эшләсә дә, уңыш җыеп ала алганы юк. Авыл малайлары аның бакчасының кайсы төшендә, нәрсә үскәнен һәм күпме үскәнен үзеннән дә әйбәтрәк белеп, шуларны вакыты җитәр-җитмәстә үк юк итә торалар.

Мөселман булмаса да, күрше бит. Яһүднең җәй буена эшләп тә көз көне буш кул белән калганын күреп йөргән Габдулла бабай аңа бер көчек кертеп биргән. Шул кечкенә нәрсәдән җәренгә бер яшьлек бозау зурлыгындагы эт үсеп, яһүднең яшелчә уңышын арттыруда төп көчкә әйләнгән. Берничә әрсезрәк малай шул эт авызында төрле зурлыктагы, төрле төстәге чалбар, күлмәк итәкләрен калдырганнан соң, яшелчә тәмен онытып, яһүд бакчасы янынан сызгыргалап, яисә бакчаны зур тырышлык белән саклаган эткә таш бәргәләп уза торган булалар.

Кояш белән торып, көне буена «эт сугарып», әллә кайларда чабып, кичкелеккә ашарлык та хәлләре калмыйча өйләренә кайтып тәгәрәгән малайлар өчен, картечкә төшерә торган урын һәрчак серле булып калды. Серлелеге әллә кая китмәс иде лә ул тик менә акча юклыгы. Акчасы да юк, аннан соң кигән күлмәкнең нинди төстә икәнен әйтерлек түгел. Изүләре сәдәфсез, җиң очлары каешланып каткан. Өстәвенә, «чебиле» аяклар...

---

*Зәки ЗӘЙНУЛЛИН (1933) — техник фәннәр докторы, «Үрләр аша» китабы һәм вакытлы матбугатта чыккан повесть, хикәяләр авторы. Казанда яши.*

Яз житеп, кар сулары китә башлаган вакыттан яланаяк йөрүче малайларның аяклары, көн саен юсаң да, агармаслык булып «чебили». Ә язгы сулар белән бергә чыккан шул «чебиләр»нең әрнүенә төне буена елап чыккан малайларны, әнкәләре әллә ничә тапкырлар эссе мунчада чабып, акырта-акырта, аякларын кайнар сулы таска тыгып, мунчала белән ышкып юалар. Тик «чебиләр» барыбер, җәй уртасы житмичә бетми. Бетсәләр дә, аяклар кара оекбаш кигән кебек кап-кара булып кала бирәләр. Ул кара төсне җиңәргә хәтта кибет сабынының да көче житми.

Кәртечкегә төшәлмәүнең тагын бер сәбәбе — кайбер малайга, өч-дүрт яшькә житмичә, ыштан дигән нәрсәнең әләксә дә, төпсезе генә...

Авыл урамнары буйлап, парлашып чапкан малайлар «атлы» уйный. Бик матурлап, чуклап асып ишелгән дилбегәләр, йөгәннәр кигән житез «атлар» чаба, ай-һайлап, юкә дилбегәне кулларыннан ычкындырмаска тырышып, чыбыркылары «күчерләр» куа, ә алар артыннан нечкә генә тавыш миһаһайлап, артта калмаска тырышып, «колыннар» ияргән. «Колыннар» — уенга кереп китәргә тулы хокукы булмаган, өч-дүрт яшьлек әнә шул ыштансыз малайлар инде.

1936 елның июль башлары иде.

Алты-жиде яшьләрдәге малайлар Пожарный урамында «атлы» уйный. «Сбруй» яклары шәп малайларның. Чөнки алар, дүрт көн элек, колхоз атларын карауичы Ибрай бабайның, бүреген кырын салып, көпә-көндез бөтен урамны яңгыратып, «Француз яулык» көенә жырлап узганын каршы алдылар. Ходайның бирмеш ул көннән малайлар, язгы сабан туен көткәндәй, атнадан артык сагалап йөрделәр. Бик еракка китмәскә тырышып кына уйный иделәр. Менә хәзер жырлап килгән — Банжур Ибрай — алар өчен, иң кадерле һәм кирәк кеше. Лап-лоп атлап, колхозның нәсел айгырларын һәм бишенче бригаданың эш атларын карауичы ул кешене, авыл халкы Банжур Ибрай дип йөри. Ул, хәмер дигән нәрсәне әз генә авызына алса да, авыл урамнарында каршы очраган хатын-кыз янынннан дәшмичә үтә алмый. Яңа гына буй житкереп килгән кызмы ул, әллә инде картаеп, таякка иярәп йөргән карчыкмы, Ибрай, туктап, чабаталы аякларының үкчәсен үкчәсенә бәреп, жәен-кышын башыннан салмыйча кигән бүреген баш өстенә күтәрә биреп сәламли:

— Банжур, мадам!

1915—1918 елларда Россиянең Франциягә жибәргән хәрби экспедиция корпусында, Германиягә каршы сугышып йөргәндә, шул ике сүзне, французларга булган мәхәббәте итеп алып кайткан Ибрай. Кайтуының тәүге көннәрендә, ул, урамда очратып, кендек әбисе Тайфә карчыкны куркыткан. Аның хәлен белергә дип, таякка таянып, урам буенча килгән әбигә ул әнә шулай сәлам биргән.

Әлеге сүзләрне ишеткәч, әби, куркуыннан кая барганын онытып, алты елдан артык капкасын ачмаган, яратмаган мөртәт киявенең өенә кабалана-кабалана кереп киткән дип сөйлиләр.

Шуннан бирле Ибрай — Банжур Ибрай!

Үзенә генә хас тагын бер гадәте бар Ибрайның. Анысы да хәмер кергән чакларда була. Шундый чакта ул үзе чыгарган «Француз яулык» көенә әйттерә. Үзе жырлый, үзе бер адым да читкә чыкмыйча, урам уртасыннан килә. Каршы килгән атлыга да, мир үгезенә дә — беркемгә дә юл бирми. Урам уртасы — Банжур Ибрайныкы. Жырны ишетеп калган авыл кешеләре, көлемсерәп, «Бүген Банжур Ибрае француз булган»,— диләр.

«Француз яулыгы»н малайлар арасыннан беренче булып, Папай Нигъмәте ишетеп алды:

— Әлләгенәм! Ибрай бабай әйттерә бит теге көйне!

Читән буендагы чирәмдә пәкеле уйнап утырган малайлар сис-

кәнеп киттеләр. Чыннан да, Пожарный урамы ягыннан азрак карлыккан тавыш белән җыр ишетелә иде. Җыры ишетелә, ләкин җырчы үзе күренми әле.

Менә, ташчы Фәттах йорты яныннан бүреген кырын салган Ибрай бабайлары күренде. Тула оек-өсте кигән чабаталы аяклары юл тузанын туздырып, туры атларга тырышалар. Ике кулы, оча алмыйча җирдә генә йөри торган әллә нинди кошның канатларын хәтерләтеп талпына. Бармаклары, аягын баскан саен, шарт-шарт килә. Банжур Ибрайның дөнья нужалары тәгалләнгән. Ул «Француз яулык»ны әйттерә:

Фра-анцуз я-аулык са-атып алды-ым,
Юук акча-а-ларымны ба-ар итеп.
Ке-емгә ка-ар-ы-ыйм, ке-емгә ярыйм,
Ке-е-емне алды-ыйм ярар-рр итеп?

Ул, җыры бетәр-бетмәстә, капка аша авызын ерып карап торган Фәттах хатыны Васфикамалны шәйләп алды. Туктады да, бүреген күтәрә төшеп, чабаталы аякларын бер-берсенә бәрде:

— Ба-анжур, мадам!

— Әллә француз булгансың инде, Ибраһим!

— Сәләви, француз әйтмешли. Булдым шул, әллә синең эчең көяме моңарга?— Җавап-фәлән көтмичә, үз юлы белән атлап, җырын дәвам итә:

Француз яулык матурлата, Пәрүләрнең Бануын.
Үзем генә беләм инде йөрәгемнең януын.

Бу — малайлар көтеп алган шатлыклы хәл, ел да бер тапкыр җәй уртасында була. Җыр бетүгә, туры гына атлаган аяклар, чалыш-чолыш килеп, аны Төрек күле кырыендагы өенә таба алып китә. Малайларга иң кызыгы шунда: әллә урам, урынында тормыйча, Банжур Ибрайдан читкә тайпыла, әллә ул үзе урамнан бара белми — аңламассың. Алпан-тилпән килеп, урамның әле бер ягына, әле икенче ягына чыга. Урамдагы ике яклап сузылган читәннәрнең, ташкоймаларның, җил капкаларның барысына да тотынып карамыйча үтә алмый.

Малайлар исә, тыннарын да алмыйча, аның Төрек күленә таба борылганын көтеп торалар. Шунда борылуы була — малайлар «эшкә» керешә...

Банжур Ибрай бакчасы артындагы кечкенә Каенлы елгасын, язгы сулар китеп, котыруы басыла төшеп, ярларына кайтып тынгач, тал чыбыгы, тирес, туфрак ташып буа. Шул буага ике-өч курыс бастыра. Ни хикмәт, «Француз яулык»ны әйттереп кайткан чагы һәр елны менә шушы курыс өлгереп, юкәгә әйләнгән чакка туры килә. «Атлы» уйнарга дип, дилбегә ишүче малайлар бу хәлне бик тә яхшы белә. Менә шуңа күрә дә бүген аларга бәйрәм.

Ибрай бабалары хәзер өенә кайтып җитә дә йокларга ята. Ул «француз» булган көнне аның усал Алабае да урамга чыкмый, ояла. Чөнки хуҗасының таләбе шундый: чыкма, өрмә! Ә «Француз» булмаган көннәрдә Ибрай бабай үзе дә, аның усал Алабае да шул буадан ерак булмаган колхозның ат сарае янында атлар карап гомерләрен үткәрә. Юкә кәсепләгән малайлар буа янына килергә өлгерми, Алабай, кая керергә белмичә, тузан бураны күтәреп, аларга өрергә, чәбәләнергә тотына. Бер буа ягына чаба, бер кире килә. Аның шулай, бик зур эш бетергән кебек, йөгергәләп өрүенең сәбәбе Банжур Ибрае өчен ачык. Теге яңарак кына ыштан кигән имансыз малайлар, мөгаен, юкә урларга килгәннәр. Шуннан ул, бик кабаланган булып, атлар сараеннан килеп чыга. Малайлар, тилгән төшкәндәге тавык чебиләре кебек, кайсы кая чәчелеп юк булалар. Аларның ялтыраган

аяк табаннарына карап, Банжур Ибрай түзәлмичә, кычкырып җибәрә:

— Һайт, машинник малайлар!

Ә бүген минә бәйрәм. Чөнки аларның Банжур бабалары «француз» булган. Бүген аның усал Алабае урамга чыкмаячак. Бүген — малайларның кәсеп көне...

Банжур бабай күздән югалгач, малайлар икегә бүленде. Хәйбүш белән Нигъмәт буага төшәргә, Көрпә Гарифы, Писер Илсуры, Фазулла бабай Тәлгате, Мәчтәк Файзыры һәм алардан калмый тагылып йөргән ике ыштансыз «колын», буадан ыргыткан юкәле курысларны эләктереп, таллыкка җилдерергә тиешләр. Буа яныннан үтеп барган зурлар: «**Нишлисез сез анда, малай актыклары?**» — дип кычкыргалаганчы, курыслы булып өлгерергә кирәк. Ә инде курыс булгач, юкә була. Юкә булгач, аннан ишә инде малайлар дилбегә-йөгәннәрне!

Читән буенда яткан ташка ышкып, пәкене тиз генә үткерделәр дә, арада иң елгыр Нигъмәткә тоттырдылар. Суга батырылган курыслар өстенә аркылы бәйләнгән өч колга чишеп, уннан артык курысларны аерып алдылар. Җирдаларны кире урынына куеп бәйләделәр һәм тизрәк таю ягын карадылар. Шуннан соң авыл очындагы таллыкка кереп чумдылар, юкә төшерделәр. Көтү кайтыр вакыт килеп җиткәндә, Банжур бабай буасыннан урланган юкәләр Нигъмәтләр абзарында асылынып тора иде инде.

Икенче көнне иртән Нигъмәтләр ишек алдында җыйналган малайлар үзләре өчен дилбегә, йөгән, чыбыркы ишеп, чуклар ясап, ду киләләр иде. Араларында Хәйбүш кенә юк. Ул, өйлә җиткәнче, зират артындагы тауда йөргән атлар койрыгыннан кыл алу белән мәшгуль булды. Чөнки чыбыркы очын кылдан ишеп куймасаң, нинди шартлау инде ул. Ә Хәйбүш иң усал дигән атлардан да кылны ала белә.

Өйлә үтүгә «атлы»лар, авыл урамнарының берсен дә калдырмыйча, урап чыктылар. Күрсеннәр бүтән урам малайлары Түбән очларның ничек итеп «атлы» уйнаганнарын, аларның сбруйларын!

Уйнап туеп, берничә көн үткәч, бүген урамнар буйлап чабаргамы, әллә башка берәр уен табаргамы, дип сөйләшеп торган чакларында, хәле-тыны бетеп, Мәчтәк Файзыры килеп җитте. Файзыр «колын»лыктан чыккан да, чыкмаган да кебек. Ул алты яшен тутырып килә, тик шәп итеп йөгерә алмый. Шуңа күрә, азрак уйнагач, башкалардан аерылып кайтып китә. Күп йөгерсә, никтер, һава җитми аңа. Менә әле дә ул тынын еш-еш алып, малайлар арасында һәрчак берәр яңа уен оештыручы Нигъмәткә эндәште:

— Ними! Сине абый чакыра! Тиз генә чабып килеп җитсеннәр әле, ди. Бик зур йомыш бар, шул йомышны үтәсәләр, барысын да кәртечкәгә төшерәм, ди.

Малайлар Файзырны сырып алды.

— Нинди кәртечкә?

— Нәрсә белән төшерә?

— Ничек итеп төшерә?

Файзыр аларга җавап бирмәде. Һаман үзенекен сөйләде:

— Әйдә инде, Ними! Килмәсәләр, бүтән урам малайларын чакырам, ди.

— Ы-ы-ы! Чакырттылар, ди...

Файзырны тыңлап та бетермичә, малайлар аның өе ягына йөгерделәр.

Файзырның абыйсы Габдерахман аларны үзләренең капка төбендә көтеп тора иде. Сүзне ул кыска тотты:

— Менә нәрсә, малайлар! Әгәр бүген безнең бәрәңге чүбен уташсагыз, шуның өчен мин сезне картечкәгә төшерәм. Һәм һәрберегезгә берәрне ясап бирәм.

— Ничек итеп төшерәсең аны?

— Нәрсә белән төшерәсең?

— Миңа да бирәсеңме?

Габдерахман, күпне белгән кеше кебек, эре генә аңлатты:

— Миңа укытучы Каюмов абый фотоаппарат биреп торды. Картечке төшерергә өйрәтте. Әгәр чүп утарга риза булмасагыз, выжгыз моннан. Мин хәзер үк Югары Оч малайларын чакырам.

Барысы өчен дә Нигъмәт карар кылды:

— Утыйбыз, малайлар!

«Атлар», «кучерләр», «колыннар» бертавыштан күтәреп алдылар:

— Утыйбыз!

Габдерахман, кабаланмый гына, күз йөртеп чыкты да:

— Менә бу ике ыштансыз малай кирәкми,— дип «колын» булып йөргән ике бәләкәйгә күрсәтте.

— Ния кирәкми?

— Алар әле бәрәңге белән алабутаны аера белмиләр һәм утауның нәрсә икәнен аңламыйлар да.

Киң күңелле Нигъмәт ике бәләкәй малайны якларга тырышты:

— Беләләр алар, Габдерахман абзый, беләләр...

— Беләсезме?

Бәләкәй Габдерахман белән Зиннурҗан эндәшмичә тик кенә басып тордылар. Өстәвенә, икесенең дә елыйсы килә башлаган иде инде.

«Картечкече» үзенекен әйтте:

— Аннан соң ыштаныгыз да юк икән әле сезнең. Ыштансыз малайларны картечкәгә төшерергә рөхсәт юк. Бар, кайтыгыз да, әниләрегездән ыштан таптырып, киеп килегез. Шуннан төшерермен.

Икесе ике якка йөгерешкән малайлар артыннан, авызын ерып, аз гына карап торды да калганнарны бакча эченә чакырды:

— Әйдә, керегез!

Кызыллар белән аклар сугышы башланган 1918 елда туган бала иде Габдерахман. Матур гына үсеп килгән чагында, аяк астыннан килеп чыккан бәла гомере буена гарип калдырды аны.

Унөч яше тулып үткән көннәр була. Мич башыннан төшеп килгәндә, аягына уралган песигә абынып, уң аягы белән кайнап торган казанга баса. Пешкән аягының тиресе генә түгел, сөягенә кадәр ите дә кубып төшә. Шуннан соң яшәгән гомере эчендә зәгыйфь аягын чүпрәккә генә урап йөртә торган булып кала Габдерахман. Йөрәгенең дә сугуы ялгышып китеп, барган җиреннән хәле бетеп туктый торган була.

Ата-анасы нинди генә им-том иттермәделәр инде аны?! Атап Коръән чыгарттылар. Ибракай авылының мулласын кышкылыкка китереп, көненә дүрт тапкыр өшкерттеләр. Җәй көннәрендә улакка тутырган үләнгә керттеләр. Берсенең дә файдасы тимәде. Бары тик 1934 елда авылга килгән иң тәүге врач Кульсицкий гына азрак аягын төзәтә алды Габдерахманның. Үзе ясаган дарулар белән дәвалап, малайның таягын ташлатты. Улларының, таягын ташлап, тыйтаклый-тыйтаклый йөри башлаганын күрү — ата-анага иң зур шатлыкларның берсе булды. Габдерахманның әнисе Хәсби түти куаны-

чыннан бер бөтен каклаган каз алып барган Кульсицкийга. Тик тегесе алмаган. Күңеле кителгән Хәсби түти урамда туктый-туктый зарлана икән:

— Йә инде, илаһым. Нит, бабушка, ни нады»,— ди.— Малай пуч кушает»,— ди. Мин бит аңа, улымны төзәткәнгә, куанычымнан илткән идем. Алмады...

Кайнаган казанга батканда, Габдерахман алтынчы сыйныфта укый иде. Сыйныфларында ул иң шәп укучы булды. Укуыннан тыш, үзенә генә хас сәләте дә бар, гаҗәп дәрәҗәдә кулы оста. Энесе Файзырга ясаган уенчыкларын урамнан үтеп барган дәрәҗәле картларга кадәр туктап, телләрен шартлатып, сокланып карыйлар иде. Аягы имгәнгәч, ул төрле-төрле уенчыклар ясап, авыл базарында сата башлады. «Ай-һай» Ибрай малаеның осталыгын»,— дип сөйли башладылар аның турында.

Тик ул башкача мәктәпкә йөрмәде инде. Аягын бәйләгән чүпрәкләрен көненә биш-алты тапкыр алыштырырга кирәк иде. Аннан соң, мәктәптә, бөтенесенә ияреп, тузаннар туздырып, шаярып та йөрмәгәч, нинди уку ди инде ул? Үзеннән бер генә яшькә кече булган күрше малае Гарифулла белән өендә азрак укыштыргалап, төрле уенчыклар ясап, тишелгән комган, тазлар ямап, гомерен үткәрде. Бервакыт, кайчандыр үзе укыган мәктәпнең ватылып эштән чыккан патефонын алып кайтып, төзәтеп илтеп биргән. Шушы эшеннән соң ул, укымаса да, мәктәптә үз кеше булып киткән.

Габдерахман белән Фәйзерахманның, җәйге эссе көндә, җан тирләрен чыгара-чыгара, бәрәңге утыйсылары бар иде. Шул көннәрнең берсендә, теге «атлы» уйнап чапкан малай-шалайны күреп, Габдерахманның башына бик шәп бер уй килде.

Малайлар, бәреп-сугып, тиз генә утап чыкмакчылар иде дә, алай җиңелдән түгел икән шул! Ничек утарга кирәген Габдерахман үзе күрсәтте:

— Чүпнең башыннан тотып тартмагыз! Төбеннән эләктерегез! Очыннан тотсаң, сабагы өзелеп, тамыры җирдә кала, аннан тагын чүп үсеп чыга. Хәзер дүртегез чүбен утар, икегез алар артыннан кәтмән белән җирне йомшартып барыр. Кәтмәнләгәндә җирне бәрәңгенең төбенәрәк салыгыз, бәрәңгенең төбе ачык калмасын!

Шулай итеп, өмә кебегрәк эш булды инде бу малайларга. Өйлә турысында аларга талкан болгатып ашаттылар, күп итеп катык куйдылар. Саранрак булса да, Хәсби түти бүген ризыкны кызганмады, чөнки малайлар шәп эшли иде.

Бәрәңге уталып беткәндә, кояш баерга байтак вакыт бар иде әле. Эш ахырына якынлашкан бер мәлдә, теге ике «колын»ның парлашып елаган тавышы ишетелде. Алар — әнкәләреннән ыштан таптырып та теләкләренә ирешә алмаган бәләкәй Габдерахман белән Зиннурҗан иде:

— А-а-а-а-оа. Аптырам-а-ан абзый, а-а-а-а-оа!..

Елап, үзләрен кызгандырып, кәртечкегә төшәселәре килә иде аларның. Тик Габдерахман аларга игътибар итмәде. Бераз вакыт үткәч, елаган тавыш басыла башлады. Малайлар арыды, күрәсең — тамаклары да кипте булса кирәк. Аннан соң елаганыңны тыңлаучы булмаса, кызык түгел бит ул. Тагын күпмедер вакыт үткәч, малайларның берсе янә шыңшый башлады. Тора-бара, тавыш акырынайганнан-акырыная барып, инде басылды, тәмам бетте дигәндә, икенче малайның көр тавышы елауны эләктереп алды:

— А-а-а-оа! Аптырама-а-ан абзы-ыйй, а-а-ааа!

Габдерахман түзмәде, көлеп куйды:

— Бу ыштансыз нәмәстәкәйләр, берсе елаганда, икенчесе ял итеп, мине җиңәргә булдылар, ахрысы.

Ул, титаклый биреп, капка төбенәрәк китте:

— Йә, кая ыштаннарыгыз, ә?!

Икесе өчен дүрт яшьлек бәләкәй Габдерахман җавап бирде:

— Ни әйтә, әни әйтә, ни ди, әни әйтә... Мәчтәк үзен белсен, үзенең ыштан кигәненә кайчан, дип әйтә, кәчтеркегә төшерсен, дип әйтә...

— Ә-ә-ә, шулаймыни әле? Мәчтәкмени әле мин, ыштансызмыни әле. Каяле, минем менә монда, читән буенда гына үскән кычытканнарым?!

Ул, көлүдән күзләренә килгән яшьләрен күлмәк җиңе белән сөртеп, урамның икенче очына таба йөгергән малайларны карап калды...

Эшне бетерүгә бит-кулларны юарга дип, Габдерахман йорт эчендәге коедан улакка салкын су тутырып куйды. Аннан, юынып, су сибешеп туйган малайларны ишегалдында үскән каз үләненә утырта башлады:

— Менә шушында дүртегез аякларыгызны бөкләп утырыгыз, икегез артка басыгыз!

Малайлар, һәркайсысы алгарак эләгергә тырышып, тарткалашатөрткәләшә башладылар.

Габдерахман аларны бик тиз тәртипкә индерде:

— Йә, төртешмәгез, төшермим алайса...

Аның сүзләрен бүлеп, урам яктан зәһәр тавыш ишетелде:

— Син, Мәчтәк, нишлисең ул маңкалар белән?!

## Кытыйка

Барысы да борылып, капка ягына карадылар.

Урам якта, читән казыкларына ике куллап тотынып, башын кып-кызыл чәч баскан, унбиш-уналты яшьләр чамасындагы, күрше малае Сабур басып тора иде. Җавап булмаганга аптырап калмады, кече капканы ачты да ишегалдына керде.

— Нишлисез сез монда, ә?

Бүредән курыккан сарыклар кебек, малайлар Габдерахман артына җыелдылар.

— Әйдәгез тизрәк, кирәгегезне бирмәс борын!

Габдерахман теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

— Мин аларны картечкегә төшерәм.

— Картечке-е-е?!

— Әйе...

Кытыйка Сабур — Түбән очта иң явыз малай. Аның яныннан беркем дә еламыйча үтә алмый. Улларын кыйнаган өчен, бәләкәй малайларның аталары берничә тапкыр Сабурны тотып та ярдылар, тик файдасы тимәде. Сабур, үзенә тигән ирләрнең баласына, урамга чыгармаслык иткәнче каныгып, аларга көн күрсәтмәс булды. Аның белән генә калмыйча, үзен җәберләгән ирләргә такмак чыгарып, үзе салган көйгә җырлап, аларны авыл халкы алдында көлкегә калдырып йөри башлады. Тора-бара ул, такмак әйтүен кәсепкә әйләндереп, һәр атнаның шимбә көн кичендә, Пожарный янында чыгышлар оештырды. Баштагы концертларында ул такмаклый гына иде, аннары үз кәмитеннән үзе дә тәм таба башлап, инде биеп җырлый башлады. Малайлары Сабур кулыннан кыен алып, аталары Сабур теленнән көлкегә калгач, авыл халкы аңардан курка һәм шикләнә төште.

Шул шимбә көнне ясаган чыгышлары өчен Сабур йә бишәр тиен акча түләтә, яисә икешәр конфет ала. Аның җырлап-биегәнен карап буй ягыннан авылда иң бәләкәй булган Алтын бабай, эченә кату

төшкәнче, хәле беткәнче көлә. Һәр концертка кешедән алда килергә тырыша. Тик кайбер вакытта халык инде җыйналып өлгергән була. Алтын бабай йөгерә-атлый Пожарный янына килеп тә җитә, халыкны аралап, алга үтәргә тырыша:

— Җәмәгать, дим, җәмәгать! Кая, мине алга үткәрегез әле, юкса күренми бит миңа. Мин бит кәмфитне ике урынына дүртне салам, үткәрегез!

Алтын бабай, алга ук чыгып, бишмәтен астына салып, җиргә аякларын бөкләп утыра да Сабурга үзенең теләгән белдерә:

— Син, Сабирҗан улым, теге Гыйльметдинле җирен онытa күрмә берүк, биегән чагында, дим.

Сабур Алтын бабайны күрми дә, ишетми дә кебек. Башындагы түбәтәен иплэп төзәтеп кия дә уртага чыга.

Алтын бабай, азрак чиңгаанрак тавыш чыгарып, көлә дә башлый.

— Ай, чукынган да гына малай икән, чын ясау әртист бит, чын ясау!

Алтын бабайның бөеренә кырыендагы икенче бабай сиздермәскә тырышыбрак төртеп ала: шаулама, янәсе. Шул вакытта Сабур, иренгән кыяфәт белән, уртада йөреп, түгәрәк ясый. Кыяфәт-атлауларын үзгәртеп, үч алырга теләгән кешесенең йөрешен килештереп күрсәтә. Халык, тын алырга онытып, Сабурның йөрешен күзәтә. Кемне үртәгәнен танырга тырыша, белеп калсалар, ду күтәрелеп, көлә. Ә аңламый, белми чара юк — Сабур үз эшенең остасы.

Менә ул уң кулының биш бармагы белән, кызыл чәчле башын каплап тота, сул кулының ялангач сыртын тырнап-тырнап кашый, йөзендә бетмәс-төкәнмәс шатлык балкый, үзе уңга-сулга төкеренә. Халык, күргән кызыгына чыдый алмыйча, үкерә:

— За-һи-ит т-а-ааз!

Сабурның йөзе яктыра. Ул, ике кулбашын күтәрә биреп, ике куллап борынын тотып, аны тазарткан авазлар чыгара...

— Танау Шәри-и-иф!

Сабур, терсәкләреннән ике кулын азрак кәкрәйтә дә аяк очларын читкәрәк каратып, алгарак киергән корсагын адымнары уңаена селкетә-селкетә, түгәрәкне әйләнеп, тиз-тиз адымнар белән атлап китә. Ә түбәтәе кырын киелгән, бер күзен каплый язып, эленеп кенә тора. Ә халык көлә, халык гөж килә:

— Гә-ә-әби-ии Төксә-әә, ха-ха-ха-а-а-а!!!

Кешеләрнең йөрешен, кыланмышын күрсәтеп, Сабур түгәрәктә озак йөрми. Шушы аз гына вакыт эчендә тамашачыларны әзерләп ала да, ишек алдындагы тавыкларын барлаган җирән әтәчкә охшатып, кызыл чәчле башын югарыга чөеп-чөеп җибәрә. Шулчак аның тамагының әллә кайсы җирләреннән иң кызыклысы килеп чыга:

— Кыттый-кыттый-кыттыйка-а-а-а!

Андый чакта Алтын бабай, сакалының ап-ак икәнен дә онытып әнисен имәргә хәзерләнгән сабый бала кебек шатлана:

— Әйттер шуны, Сабурҗан улы-ы-ым!

Сабурҗан әйттерә, әлбәттә:

Кыттый-кыттый кытыйка. Кытый белән Сыбыйка.
Имакайга — Чумакай. Миңнисага — Җомакай.

Кыттыйка-кыттыйка,
Кыттый-кыттый, кытыйка.

Алтын бабайның түземлеге бетә башлый:

— Гыйльметдинне, улым, Гыйльметдинне!

Сабур көттерми:

Калаларда батис яулык, илле тинул, илле тин,
Арада ин котсыз кеше — Гыйльметдин ул, Гыйльметдин.

Сабур уртада бөтерелә, ә аны шартларга җитешкән кып-кызыл битләр, күлүдән яшьләре чыккан күзләр, тынычлыгын югалткан авыл картлары, ир урталары һәм бала-чага уратып алган. Сабур бии, Сабур җырлый, Сабур үч ала, Сабур кәнфит җыя, Сабур акча таба...

Алтын бабай түзә алмый, тагын килеп кысыла:

— Әйттер, улым, шуларны...

Кысыла да... үзенә тиеш өлешне дә эләктерә. Сабур, аның яныннан үткән чакта, көлүдән күзләре бөтенләй кысылып беткән Алтын бабай «уклар»ын җибәрә.

> Алтын бабай, кәмфит түләп, Гыйльметдинне җырлата,
> Бүе бәләкәй булса да, әче балны гөжләтә...

Сабурның «кыттыйка» дигән сүзләре, халыкның көлүенә күмелеп ишетелми башлый. Торып баскан Алтын бабайның Сабурга йодрык янавы әлеге көлүләрне тагын да көчәйтеп җибәрә.

...Кәртечкегә төшәргә җыенган малайлар янына менә шул Сабур килеп керде. Керде дә:

— Инәңнең... күлмәге, Мәчтек! Миннән башка кәртечке төшү буламени, ә? Булмый ул! Кая миңа урын?

Габдерахман артына поскан малайларның берсе тавыш бирде:

— Монда бәрәңге утаганнар гына төшә!

— Шауламагыз! Әйдә, бәрәңгеләрегезне йолкымаганга рәхмәт әйтә-әйтә төшерегез. Юкса алырсыз кирәгегезне!

Ул, Габдерахманның әйткәнен дә көтмичә, фотоаппарат алдына атлады. Габдерахман малайларны тигезләп утыртты. Сабур арткы рәтнең уртасына кереп басты.

Төшерүче өчаякны кабаланмый гына тигезләде, шуның өстенә бәләкәй генә гармунга охшаган фотоаппаратны нығытып куйды. Аннан соң, әнисенең калын кара шәлен фотоаппаратка каплады, үзенә дә бөркәнде, шундагы караңгыда бик озак нәрсәдер эшләде. Малайлар тын калды. Аларның мондыйны әле гомердә дә күргәннәре юк иде. Үзләре белән бер урамда яшәгән Габдерахман абзалары кәртечкегә төшерә бит! Бу әле авылда булган хәл түгел.

— Төшерәм, тын да алмагыз!

Малайлар тын алудан туктадылар.

Шәл астыннан нәрсәләрдер чалт-чолт итеп тавыш бирде. Аннары шәл астыннан чыккан Габдерахман үзе күренде. Ә малайлар селкенмичә дә һаман утыра бирделәр. Шуннан Сабур пышылдап сорады:

— Булдымы?

— Булды, инде кузгалсагыз да ярый.

Малайлар фотоаппаратны уратып алдылар. Габдерахман кисәтү ясады:

— Карагыз гына, иллә мәгәр кул белән тиясе булмагыз!

Сабур исә аларны урамга ук куа башлады.

— Барыгыз, бар, эшегез беткән, уйнавыгызны белегез!

Ишегалдындагы шау-шуны басып, Хәсби түтинең ачуланган кебегрәк тавышы ишетелде:

— Әй, илаһем! Габдерахман, күрмисеңмени, әнә теге оятсызларны?

— Кемне тагын?

— Әнә бит, читән башында утыралар.

Өйдән чыгып килгән Хәсбиҗамал түти, урам ягындагы читәнгә карап, кулы белән янады:

— Төшегез тизрәк, Ибраһим бабагыз күрсә, орышыр үзегезне!

Читән башына унбер-унике яшьләр чамасындагы ике малай менеп кунаклаган икән. Ишегалдына керергә кыюлыклары җитмәгәнме, якын килмичә генә, картечкегә төшүче малайларны шуннан гына тынсыз күзәтеп утыралар иде.

Сабур йортта үзе хуҗамыни, читән башындагы малайларны куа ук башлады:

— Югалыгыз күздән, выжт хәзер үк!

Ул читән ягына бик көдерәеп бара башласа да, малайлар аңардан курыкмадылар. Чандыр буйлы Җәүдәт аңа җавап бирүне кирәк дип тә санамады, ахрысы. Аның күзе һаман теге фотоаппарат ягында иде. Малайларның икенчесе, төптән юан чыккан, курку белми торган Габдерәхим иде. Читән башында утырган җиреннән, кабаланмый гына, үзенең нәрсә сөйләгәнен белеп, Сабурга җавап кайтарды:

— Килеп тә маташма, Кытыйка, алдым, салдым таш белән.

Сабур, читәнгә дүрт-биш адым кала тукталып, аларны сүгәргә тотынды:

— Төшегез, төш! Син, Җомай, телеңә күп салынсаң, тешләреңне учлап кайтып китәрсең.

— Китте ди, бар, китмичә. Үзең учлый күрмә тешләреңне!

Габдерәхим — Җомай Мәҗит малае.

Сабур, бар урамны куркытып, барлык малайларны кыйнап, үз кулында тотса да, Габдерәхимне үзенә буйсындыра алмады. Төптән юан чыккан, казакъка охшаганрак бу малай да Сабур кулыннан күп җәбер күрде. Күрүен күрде, тик барыбер бирешмәде. Алар арасында елдан артыкка барган чәкәләшү быел май аенда чын дошманлыкка әйләнде. Ул болай булды. Сабур аны кыйный башлагач, Габдерәхим, алдан әзерләп, кесәсенә салып куйган таш белән, Сабурның танавына тондырды. Яңа кулмәген борыныннан аккан канга буяп, Сабур озак азапланды. Тик канны тиз генә туктата алмады.

Икенче көнне, Габдерәхимнән үч алу уе белән аңа каршы чаба башлагач, Габдерәхим аның якынлашып килгәнен, уң кулын кесәсенә тыккан килеш, кузгалмый гына көтеп торган. Бүре баласыдай карап торган Габдерәхим каршында Сабур, аны сүгә-сүгә таптанып тора, ләкин якын бара алмый икән...

Шуннан соң үзе кыйнаган малайларның Габдерәхим янына җыйнала төшүен күрә Сабур. Уйга кала. Үсеп килгән малайларның аңа каршы көч җыя, туплана башлаганын аңлый.

Бүген дә Сабур Габдерәхимгә тияргә кыймады. Әрләп-әрләп сүкте аны, ә үзенең күзләре кесә тирәсендә иде. Габдерәхимнең кесәсе шактый гына бүлтәеп тора. Аннары янында Батрай малае Җәүдәт тә бар. Анысына да тиеп булмый, чөнки ул быелгы сабан туе ярышында, ат чабыштырып, беренче килде. Икесен бергә җиңеп кара син аларның!

— Төшегез, малайлар, читәнне ватасыз бит,— диде Габдерахман аларга. Тегеләр, икесе бергә диярлек, ишек алдына сикереп төштеләр дә, Сабурны ике яклап урап үтеп, фотоаппарат янына килделәр.

— Безгә дә әйткән булсаң бит инде, Габдерахман абый. Бу малайлар ише генә утар идекмени бәрәңгегезне,— диде Габдерәхим азрак үкенечле тавыш белән.

— Каян белдегез аларның бәрәңге утаганын?— дип сорады Габдерахман.

— Соң белмичә! Син бит минем энекәшне, ыштаның юк, дип әйтеп, картечкегә төшермичә кайтаргансың.

— Габдерахман абый, син безне бәрәңгегезне күмергә чакыр. Шунда картечкегә дә төшерерсең, ярыймы?

— Ярар, ярар!..

...Инде ул еллар бик еракларда торып калды. Белеп кенә сөйләүче кеше дә юк хәзер. Күмдеме алар бәрәңгене, әллә Габдерахман энесе Файзыр белән үзләре генә эшләдеме — билгесез. Тик башкача кәртечкегә төшү булмады. Ә теге сурәт Габдерахман абзыйларда бүгенге көндә дә саклана. Малайларның күбесе, авызын йомарга онытып, шаккатып, ушлары китеп, туп-туры карап утыралар. Араларында артка баскан, эшләмичә генә әрсезләнеп кәртечкегә төшкән Кытыйка Сабур да бар...

Шул җәйге матур көннәрдән соң биш ел үтүгә, ил өстенә, кара афәт булып, сугыш башланды. Төрлесе-төрле яшьтәге, әле уйнап та туймаган малайларның балачагын тартып алып, аларның гамьсез көннәрен ачлык-ялангачлык, нужа-михнәт белән алыштырды. Тук-матур, шат-бәхетле тормышны таптап үтеп, малайлар язмышын сугыш үзенчә борды. Дәһшәтле-авыр, ач-каһәрле юл белән алып китте.

## Соры шинель, кирза итек

Рязань шәһәреннән кырык чакрымнар чамасында, Ука елгасы буена урнашкан хәрби лагерьда Габдерәхим Йосыпов белән Җәүдәт Галиевка хәрби кием кидерделәр. Үз гомерендә яланаяк йөргән яисә чабатадан башка аяк киеме күрмәгән Җомай Габдерәхиме, җылы чолгау урап, кырык дүртенче размерлы кара кирза итекләрне аякларына кигәч, ансыз да зур авызын җыеп ала алмады:

— Карале, Җәүдәт, минем аякларны! Итекләре шыгыр-шыгыр итеп кенә тора, әй. Булды болай булгач. Күрсәләр, шаккатырлар иде...

Җәүдәттә дә аякның кәттәсе икән — кырык бишенче размер. Ул да, кулына эләккән байлыкның табаннарына чиртколәп карады да, кара гуталин исе килеп торган итекләрне кияргә тотынды.

— Кызык та инде бу армия дигән нәрсә, Гаптери дус. Тик торганнан буп-бушка бирәләр бит инде боларның барысын да...

Соры шинель, ике колакчынлы җылы бүрек, кулларында өч бармаклы бияләйләр — март суыклары алырлык түгел егетләрне!

Кулына озын, штыгы дүрт кырлы трехлинейка дигән мылтык та килеп кергәч, Габдерәхим әтәчләнергә тотынды:

— Тизрәк кул сугышына өйрәник тә, киттек фрунтка, кешеләр кебек орден-медальләр алырга... Мылтыгы ярыйсы озын да икән, кадарга гына өйрәнәсе бар...

Лагерьга килүләренә ике ай вакыт сизелмичә дә үтеп китте. Шул арада нәрсәләргә генә өйрәтмәделәр аларны. Мылтыктан, ППШ дигән автоматтан атарга да өйрәттеләр, саламнан ясалган фашист гәүдәсенә штык белән дә кададылар. Окоп эчендә сапер көрәге белән кул сугышы оештыру, тревога белән чыгып йөгерү, төн үткәнче кырык-илле чакрым араны марш-бросок белән үтү... Көндез азрак эреп, төнгә ярмаланган карга күмелеп ятарга, йөгереп барган уңайга йорт тәрәзәсенә граната ыргытып тидерергә, часовойларны тавышсыз гына юк итәргә, этләрдән качып котыла белергә...

Ике ай чамасы үтүгә 1943 елның май урталарында, кояш кичкелеккә карап борыла башлаган бер вакытта, лагерьнең зур тимер капкасы аша тигез сафларга тезелеп, ике ротага якын солдат-сержантлар килеп керде. Алар сафта яшь солдатлар кебек бер-берәнә берегеп тезелмәгәннәр. Килгәндә үк тигез бер ритм чыгарып атлыйлар иде. Бөтен саф зур итекле бер генә солдат баскан тавыш чыгарып атлый һәм күпне күргән, чын солдатлар килгәне әллә кайдан ук сизелеп тора иде. Лагерь эчендәге яшь малайлар, солдатлар сафы үткән юлның ике ягына тезелеп, тавыш-тынсыз катып калдылар.

Тимер юл станциясеннән ике ротаны җәяүләтеп алып килгән капитан, аларны штаб янында туктатты. Яңгыравык көчле тавыш белән әмер бирелде:

— Сул-га!

Тирә-яктагы яшь солдатларның да үзәгенә үтәрлек итеп, тагын ике команда яңгырады:

— Тигезләне-гез! Үрә-кат!

Капитан, тынын да алмыйча басып торган сафны күздән кичердә дә җитез адымнар белән штабка кереп китте.

Лагерьда яшәгән солдатлар, килгән сафны тавыш-тынсыз уратып алган хәлдә, басып тора бирделәр. Сафтагы солдатларның чиста итеп юылган, уңган гимнастеркаларында орден-медальләр ялтырый. Аларның гимнастеркалары түшендә җәрәхәтләнгәннәре өчен алган сары-кызыл төстәге тамгалары да күп иде. Азрак кырын салып киелгән бүрек, пилотка, сирәк-мирәк кенә күренгән фуражкалары аларга егетлек төсе кертеп тора. Күп сугышлар күргән, авыр юллар үткән итекләре юл тузанына буялган. Аларның үзләрен тота белүләре дә сокландыргыч. Бирелгән әмергә буйсынып, ләкин үз дәрәҗәләрен белеп, тып-тын басып торалар.

Солдат киеме кигән көннән алып, үзләрен фашистларны юк итүчеләр дип санаган унҗиде-унсигез яшьлек үсмерләр — әлеге солдат сафына карап, коерыкларын бот арасына кыстырган көчекләрне хәтерләтәләр иде. Алар төркеме буйлап, дулкын булып, барыбер сүз үтте: фронтовиклар!

Бу халык, чыннан да, Сталинград, Кавказ, Украина сугышларын үтеп, Урал тавының теге ягындагы эреле-ваклы шәһәр госпитальләрендә дәваланып чыккан кешеләр иде.

Фронтовиклар килгәннән соң, лагерьда көндәлек тормыш нык үзгәрде. Алар мылтык тотып штык сугышына өйрәнүне, окоп казуны, танк астында калып окопта утыруны, сугыш кырларында үлем белән күзгә-күз очрашып инде өйрәнгән халык — солдат һөнәрен яхшы беләләр. Алар күбрәк лагерьдагы төрле хуҗалык эшләренә катнашалар һәм менә шуларны зур теләк белән башкаралар. Ә инде, азрак буш вакытлары булса, озын җәтмә белән (каян тапканнар диген!) Ука елгасыннан балык сөзәләр, яр буенда кояшта кызыналар, сорап тормастан, дүрт чакрым җирдә урнашкан ике чиркәүле рус авылына киткәлиләр. Болардан үрнәк ала башлаган яшь солдатларның берничәсе алар кебек кыланмакчылар иде, барып чыкмады. Лагерьда командалык иткән старшина-сержантлар, төрле эшкә нарядлар биреп, тегеләрне тиз бастылар.

— Өлгерерсез! Язмыш кушып, исән калсагыз, госпитальдән соң сез дә шулар кебек кыланырсыз. Ә хәзер, менә сезгә эшкә өч наряд, шагом марш ефрейтор Наумов карамагына.

Аларны төнге тревога белән уяттылар. Атлый-йөгертә тимер юл станциясенә алып барып, вагоннарга төяделәр һәм көньякка каратып алып та киттеләр. Ике тәүлек дигәндә, Курск каласына җитеп, шуның ярым җимерек вокзалында, таң белән вагоннардан төшерделәр. Төшкән көенә барлап, тикшереп чыктылар да, шәһәрдән утыз чакрым читтәге урман эчендә палаткаларга урнаштырдылар.

Килгәннәренә өч көн дигәндә, Габдерәхим белән Җәүдәт мәңгелеккә аерылды...

Кояш белән уянган солдатлар йөгереп, физзарядка ясап, юынып сафларга тезелеп, иртәнге ашка китеп барганда, ат менгән, аркаларына автоматлар аскан биш солдат аларга каршы очрады. Армиягә килгәннән бирле юньле ат күрмәгән Җәүдәт, аларга карап, сафтагы атлавын ялгышты. Аның артыннан килүче, Җәүдәтнең үкчәсенә басып, зарланып куйды:

— Атла әйдә, нәрсә син, атлар күргәнең юкмы әллә?!

Иртәнге аштан кайткач, солдатларның дүрт ротасын палаткалар янындагы зур аланга тезделәр. Сафлар уртасына батальон командиры капитан Логинов белән әле генә ат менеп килгәннәрнең берсе чыкты. Күкрәгендә бернинди орден-медальләр юк. Шулай булса да, аның җыйнак гәүдәсенә карап, бу кешенең күпне кичергән фронтовик икәне күренеп тора. Капитан, сафларны тынычланырга чакырып, уң кулын азрак күтәрә төште.

— Иптәш кызылармеецлар! Старшина Завьялов безнең янга фронттан килгән. Аның исәбе — сезнең арадан разведкага кешеләр сайлап алу...

Сафта торганнар гөрләп куйдылар. Разведкага-а-а? Фронтны күреп, җәрәхәтләнеп, госпиталь аша үткән солдатлар гына торышларын үзгәртмәделәр. Алар разведканың нәрсә икәнен яхшы беләләр: йә баш, йә орден...

Батальон командиры, кулын күтәреп, тагын тынычлык сорады. Тик фронтка әләгеп, тизрәк герой булырга хыялланган малайлар, разведка дигән сүзне ишеткәч, йөрәкләренә һәм телләренә баш була алмадылар.

— Үрә-кат!

Сафлар, электр тогы үткән кебек, тынып калды. Капитан Логиновның тавышы корычтай яңгырады:

— Кем разведкага тели, дүрт адым алга, марш!

Малайлар юкка тавышланганнар: разведчик булу бик гади һәм тиз икән ич. Менә бит, теләгән кешегә дүрт адым алга атларга гына кирәк. Балалыктан да чыгып бетмәгән малайлар, дәррәү күтәрелеп, разведкага язылу исәбе белән, саф алдына чыгып бастылар.

Аптыравын яшерә алмаган капитан Логинов, янында торган разведчик-старшинага нәрсәдер әйтергә теләп борылган иде, старшина, аңа карап, тәмәкедән саргайган мыегы астыннан елмайды:

— Үземә сайларга рөхсәт итегез, иптәш капитан? Хәзер бар да көйләнер.

Ул, төптән юан чыккан гәүдәсен песи атлагандай тавышсыз адымнар белән кузгатып, разведчик булырга ашкынган солдатлар алдына килеп басты.

— Минем әмерне тыңларга! Бер сафка тезелегез! Үрә-кат!

Тынып калган сафка карап, дәвам итте:

— Разведкага әләгү өчен, бер шартны үтәргә кирәк.

Ул, артына борылып карамыйча гына, кемгәдер боерык бирде:

— Дроздов, китер монда!

Шул мизгелдә кара атка атланган, иярләнмәгән ак айгыр җитәкләгән, пилоткасын салып, аның сул читеннән ут кебек җирән чәчләрен чыгарып куйган солдат палаткалар артыннан җилдереп килеп чыкты. Килеп җитеп туктамас борын ук, үз атыннан сикереп төшеп, ак айгырның тезгенен старшина кулына тоттырды. Старшина уң кулы белән тезгенне алды да атның ял-муеннарыннан сөеп сыйпады, аннан соң тып-тын басып торган солдатларга карап сөйли башлады:

— Разведкага әләгергә теләгән кеше менә шушы ак атка атланып, әнә лагерьга кергән җирдәге шлагбаумны урап, кире килергә тиеш. Бердәнбер шарт менә шул!

Өздереп кенә әйтелгән әлеге сүзләреннән соң, старшина сафның уң як башында, күкрәген тәгәрмәч кебек түгәрәкләндереп басып торган, буеның озынлыгы ике метрга якын булган таза солдатка атның тезгенен сузды.

— Тот! Син беренче булып басып торасың, гәүдәң дә бик шәп күренә, әйдә, күрсәт егетлегеңне!

Зур гәүдәле солдат бик аз гына уйланып торды да, сул кулы белән атның тезгенен алып, уң кулы белән аның сыртына үрелде.

Шуны гына көтеп торган кебек, ак айгыр бөтен гәүдәсе белән читкә янтайды. Солдат, тезгенне кулыннан ычкындырмастан, уң кулы белән тагын атның сыртына үрелде. Аның кулы атның аркасына тиеп өлгермәде, ак айгыр, кискен хәрәкәт ясап, арт аякларына басып, тезгенен солдат кулыннан ычкындыртты һәм, егылган солдатны урап, старшина янына килеп басты. Разведкага дип чыкмыйча урыннарында басып калган солдатлар исә гөрләп көлеп җибәрде. Разведкага ашкынучы солдатларның тавыш-тыннары чыкмады. Егылган солдат, җирдән торып, куллары белән өс-башын каккалады да, уңайсызлануын яшерә алмыйча, старшина-разведчикка карады. Старшина, ике кулын ике якка җәя биреп, авызын ерды да, янына килеп баскан атка күрсәтеп, чираттан икенче кешене чакырды. Тик анысы да әллә ни кыра алмады. Ак айгыр аңа тезгенен тотарга да ирек бирмәде. Бер-бер артлы чыккан унлап кеше, шундый ук уңышсызлыкка очрап, үзләренең тәүге урынына кире басарга мәҗбүр булды. Чиратын көтеп торган кайбер солдатлар да, эшләренең болайга киткәнен күргәч, элек чыккан сафларына кире атладылар.

Саф уртасында, бер-берсенә тотынып дигәндәй, басып торган Габдерәхим белән Җәүдәткә дә чират килеп җитте. Җәүдәттән алдарак торган Габдерәхим, лап-лоп атлап, сафтан чыкты да атка якынлаша башлады. Ак айгыр баскан җирендә кузгалмый көтә иде. Шулчак старшина акрын гына тавыш белән атка боерык бирде:

— Күрсәт!

Янына килеп җитәргә биш-алты адым кала, ак айгыр ике колагын шомартып яткырды да, пошкырып, Габдерәхимгә ташланды. Моны көтмәгән Габдерәхим, үзе дә сизмәстән, кире борылып, иптәшләре янына элдертте. Бу тамашаны карап торучылар айнып та өлгермәде, җан-фәрманга чапкан Габдерәхим яныннан, бил каешын урталай бөкләп, авызына капкан Җәүдәт җитез гәүдәсе белән атка каршы ыргылды. Ыргылды да шул ук мизгелдә ике куллап айгырның озын ялына асылынды. Ак айгыр, арт аякларына басып, һавага сикерде.

Старшина янында басып торган кара ат хуҗасын, Җәүдәткә ярдәмгә барырга дип кузгала башлагач, тегесе аның җиңеннән тотты:

— Тыныч кына, тик тор!

Аягына басканнан алып авылның бик күп атларын, атаклы айгырларын сырт менеп йөрергә өйрәткән Җәүдәт монда да югалып калмады. Ул ак айгырга талпан булып ябышты. Акрын-акрын гына сул кулын айгырның ялыннан ычкындырды да аның борын тишекләреннән өстәрәк сузылып торган тын юлыннан эләктереп алды. Эләктерде һәм нык итеп кысты.

Әле генә борын тишекләреннән ут көлтәсе чәчеп кая басарга белмәгән айгыр, Җәүдәткә буйсынып, башын җиргә ия башлады. Җәүдәт, бармакларын аз гына бушатып, айгырны тын алдырды да тагын кысты. Берничә тапкыр шулай эшләгәч, азрак аның муенын сыйпаштырды да ат ялындагы тезгенне эләктереп алды. Күз ачып өлгермәслек вакыт эчендә, сул аягы белән тезген каешына басып, атның борынын ычкындырды. Ачуы ташып чыккан айгыр, арт аякларына басып, яңадан башын һавага чөйде. Җәүдәт тә, аягын тезгеннән ычкындырмыйча, ат башы белән һавага очты.

Тын да алмый басып торган солдатлар ушларына килгәндә, ул ике куллап тезгененә ябышкан хәлдә, ат өстендә утыра иде.

Ак айгыр, кырын-кырын атлап, әле артын сикертеп, әле арт аякларына гына басып йөреп, Җәүдәтне өстеннән мәтәлтеп төшерергә тырышты. Җәүдәт-җайдак исә айгырга узынырга ирек бирми, башын күтәреп һавага сикергән вакытында, сул кулына урталай бөкләп тоткан солдат каешы белән аның маңгаена тондыра, артын

сикертсә, артына суга. Аптыраган ат, башын әле сулдан, әле уңнан борып үрелеп, өстендәге егетне тешләре белән эләктерергә азаплана. Җәүдәтнең тимер куллары, авызындагы корыч авызлык аша, аның ул теләгән юкка чыгара бара.

Шуннан айгыр түзмәде, баскан урынында зур тизлек белән берничә тапкыр тыпырдап әйләнде дә, тынып калган «разведчиклар» сафын урталай ярып, лагерь капкасы ягына ташланды...

Уктай атылып, лагерь капкасыннан чыгып чапкан ат артыннан соклануын яшерә алмыйча карап калган старшина-разведчик, кесәсеннән алюмин портсигар чыгарып, шатлыгын яшерә алмыйча, янында басып торган иптәшенә сузды.

— Егет тә соң бу!

Тегесе дә аңа кушылып, җавап бирде:

— Чын абрек бу егет, чын абрек!

Айгыр белән Җәүдәт ярты сәгатькә якын юк булып тордылар.

Кире әйләнеп кайтканда, ак айгырның корсак астыннан бүрекбүрек булып кара күбек коела иде. Янына ук килеп туктаган Җәүдәтне старшина ат өстеннән сабан туе ярышларында җиңеп килгән малайларны алган кебек күтәреп алды. Аягына бастыргач, соклануын яшерә алмыйча карап торды да, кочаклап, өч мәртәбә битеннән үпте.

— Рәхмәт, улым, рәхмәт! Чын егет икәнсең!

Җәүдәттән соң, старшина башкаларны ат мендереп сынап тормады. Фронтовиклар арасыннан тагын дүрт кешене сайлап алды да эшен төгәлләде. Җәүдәттән калмаска тырышкан, күзеннән яшьләрен агызып янында басып торган Габдерәхимне старшина кызгану хисе белән аркасыннан сөйде, ләкин алмады. Җәүдәтнең ялынуы да файда итмәде. Күпне күргән разведчикның сүзе кыска булды:

— Юк, туганкай, кирәкмисең.

Әле генә сайлап алган биш кешене үзе белән машинага утыртып, шул кичне үк каядыр алып та китте.

Дусларның аерылуы һәрчак авыр була. Чит-ят җирләрдә, бөтенләй диярлек таныш булмаган кешеләр янында аерылышулар икеләтә моңсу һәм йөрәк өзгеч тоела. Җәүдәт белән Габдерәхимнең аерылуы мәңгелеккә иде. Төнге куе томан артында, күренер-күренмәс кенә черпек ут булып җемелдәгән өметләренә ышанып, сугыш беткәч, авылга исән-сау кайткач очрашырбыз әле, дигән уй белән бу дөньяда башкача күрешмәскә аерылдылар...

Җәүдәт утырып киткән машина артыннан карап, Габдерәхим лагерь уртасында япа-ялгыз торып калды. Бетмәс эшләре белән каядыр үтеп баручы өлкән яшьләрдәге рота старшинасы, Габдерәхимне, иңеннән кочаклап, үзе белән алып китте:

— Әйдәле, миңа ярдәм ит, Йосыпов. Кайгырма! Разведкада орденнарны күп бирәләр, әлбәттә, тик башны саклау бик авыр анда. Ә монда, пехотада, тере калуың би-ик ихтимал. Шанс монда күбрәк...

Шанс дигән сүзнең окоп казый торган бәләкәй сапер көрәге икәнен Габдерәхим белә иде инде. Шуңа күрә рота старшинасы кырыннан атлап барганда, аңлар-аңламас уйлап куйды: ул бәләкәй сапер көрәгенең монда ни катнашы бар инде...

## Җиңү бәйрәме

Саз тугаенда, Зирекле борын дигән җирдә, язгы чәчүнең соңгы көннәрен үткәреп йөргән бишенче бригада колхозчыларының станы урнашкан. Ул урын яр астыннан чылтырап агып яткан көмеш чишмә янында. Чәчүдә эшләүчеләр — күбесе ундүрт-унҗиде яшьлек яңа

буй үстереп килгән малайлар. Шулар арасында заманында Мәчтәк Габдерахманына бәрәңге утап, кәртечкегә төшеп йөргән балалар да бар. Алар — Папай Нигъмәте, Көрпә Гарифы, Дульдин Хәбире, Писер Инсуры. Араларында тик Фазулла бабай Тәлгате генә юк. Аның гәүдәсен авыл очындагы таш койма белән уратылып алынган зиратка илтеп күмгәнгә инде ике ел тулып, өченчегә киткән. Тәлгатьне кырык өченче елның март бураннары котырган чакта, колхоз малларына ялан эскертләреннән печән ташыганда, ат тибеп үтерде. Ничек типкәнен күргән кеше булмады. Чана төбенә җәйгән кабыкка ятып йокыга талгач, юл түбән төшкәндә, гәүдәсе шуып чана алдына килгән дә, атның дагалаган арт аягы чигәсенә китереп бәргән.

Эскерт ягына керә башлагач, Тәлгатьнең кулыннан ычкынган дилбегә чана табанына эләгеп, аты туктагач кына, бергә печәнгә килгән малайлар аны килеп уята башлаганнар.

— Тор, Талгый, ач күзеңне, әнә дилбегәң кая кергән, тор!

Тик Тәлгать, тона башлаган ачык күзләрен каядыр текәп, аларга җавап бирмәгән. Сугыш алдыннан читкә киткән кызының улын бердәнбер терәк итеп үстерергә тырышкан Фазулла бабай карчыгы белән бәләкәй генә юкәгач өйләрендә икәүдән икәү генә торып калдылар.

Бригада атларын караучы Гапкадыйр, биясен җигеп, авылга кайтырга әзерләнә. Шихан исемле шул бия кечкенә гәүдәле бабай артыннан аксый-аксый, боздан барган кебек, зур саклык белән атлый. Бабайның үз аяклары да ныклык ягыннан әлеге биянекеннән артык түгелләр. Чөнки ул бишенче елгы Япун сугышында дошман снарядыннан күп яралар алган һәм гомерлек гарип булып калган. Шуңа күрә дә, читтән караганда, бу ике җан иясенең кайсы ныграк аксаганын ачык кына итеп әйтерлек тә түгел.

Ат җигәргә әзерләнеп йөрсә дә, Гапкадыйр бабайның кайтасы килми. Авылда аның бер почмагы җиргә сеңгән, түбә саламы череп яртылаш коелган өе, сыңар мөгезле кәҗәләренең сөтен эчеп җан асраучы карчыгы белән инде менә өченче ел күкәй салмый торган бүрекле чуар тавыгы гына бар. Улы Мансур кырык өченче елның февралендә сугышка чыгып китте. Аны берничә ай укытып, җәен фронтка озаттылар. Уллары шунда — тәүге сугышта ук, Курск дугасында һәлак булды. Төпчек кызы Маһирәне каладагы зур кызы алып китте. Гапкадыйр бабай берничә тапкыр, чуар тавыкны суярга исәпләп, ташка пычак кайрап караган иде дә, тик карчыгы:

— Тия күрмә берүк! Мансурымның төсе итеп тотам мин аны, йөресен. Аны ашап, сиңа теш чыкмас, сузма нәфесеңне! — дип ирек бирмәде.

Төп сәбәбе нәрсә булгандыр, әби белән бабай аны белмәделәр: чуар тавык соңгы елларда күкәй салуын туктатты. Әби моны азык җитмәгәннән, йончыганыннан күрә, ә бабай ул тавыкны үҗәт ди. Күрше йортта яшәүче адашы Пуликәр Гапкадыйр картның кара әтәче, сугышка кадәр булган тук вакытын исенә төшереп, бабай йортына әле дә кергәли. Андагы бодай саламын, үзенең көндәше — кызыл әтәчне, аның җиңел холыклы, купшы, күп санлы чибәр тавыкларын сагына.

Дөньяда булмаган хәл: күрше әтәче, кыткылдый биреп, читәннән бу якка төшкән уңайга ук, чуар тавык аңарга каршы сугышка ташлана. Сугышуы да әтәчләр сугышуы кебек түгел, ә тач ирләрен тырнап сугышкан хатыннар кебек, канатларын җәеп, тавыш-тынсыз тегенең өстенә ыргыла. Мондый хәлне күрмәгән әтәч, зур, көчле гәүдәсен җиргә елыштыра биреп, урам якка сыпырта. Ул, ни өчендер, килгән юлы белән читән аша чыкмый, чуар тавыктан качып, читән аша чыгып өлгерүенә икеләнә-шикләнә күрәсең.

Мәрфуга әби тавыгының әтәчкә булган нәфрәтен үзенчә аңлата:

— Шулай итми. Теге хәшәрәт Гитлерны дөмектерми торып, этәч кайгысы була димени? Ул да бит җан иясе.

Бабай тавыкның күкәй салуын тели. Тик, улының үле хәбәре килгәннән бирле, карчыгына каршы эндәшкәне юк. Ярар инде, анығча булсын. Ишегалдында үскән үләнне ашап кына нинди күкәй дә, этәчкә нинди күңел төшү ди ул? Салмаса салмасын, тик карчыгы гына ирен бер ялгызын калдырып китеп бармасын.

Бүген аның кайтасы килми. Командир итеп куелган Папай Гобәйдулла малае Нигъмәтулла монда эшләп йөргән һәр малайның өенә кереп, ашарга алып килергә кушты. Кушкач, кайтуын кайтыр инде, тик үзенең өеннән алып килерлек бер нәрсәсе дә юк. Чәчү вакытында колхоз биргән бер кадак онның яртысын бабай карчыгына кайтарды. Ә авылдан бабайга бернәрсә дә килми...

Кырда эшләүчеләргә ашарга алып килүче бригадир Габидулла бүген нигәдер юк. Иртән тугызлар-уннар тирәсендә килергә тиеш иде, инде өйлә җитеп килә, һаман күренми. Бабай тынычсызланып, авыл ягына еш-еш карап, Шиханга камыт кидерә, үзе уйлана: мөгаен, килгәндә атның чөелдереге чишелгәндер. Ә Габидулланың чөелдерек кысарга көче җитми. Юл кырында берәрсенең үткәнен көтеп утыра булыр, бахыр.

Чыннан да, Габидулла бригадирның, авыл халкы әйтмешли, Габи Төксәнең, бүреген сул кашына китеребрәк «егетләрчә» итеп киеп йөрергә яратса да, бил бавының очларын купшы итеп, салындырып буа белсә дә, чөелдерек кысарлык көче юк. Аның ике аягы да тумыштан гарип: нечкә һәм көчсезләр. Гәүдәсе дә урта буй малайлар гәүдәсе кебек кенә. Шулай булса да, ул үзен тота белә һәм халык та аны кешелеклелеге, ярдәмчеллеге өчен үз итә, ярата. Шуның өстенә бик оста итеп пима ямый, җыйнак итеп эшли, хакын да намус белән ала.

Арысландай ирләр сугышка китеп беткәч, элекке елларда иген эше ягыннан исәпкә бар, санга юк саналган Габи Төксәне, бишенче бригадага бригадир итеп куйдылар. Юньле исәнлеге булмауга карамастан, инде өч елдан артык тәмле теле, тынгысызлыгы белән яңа үсеп килгән малай-шалай, йөгенгән картлар, күп балалы хатынкызлардан торган бишенче бригада белән җитәкчелек итә. Язын — чәчтерә, җәен печәнне чаптырып, эреле-ваклы кибәннәргә өйдерә, кар төшкәнче игенне, бәрәңгене җыйдыра. «Фронт икмәк көтә, фронт бәрәңге көтә, фронт җылы кием көтә»,— дип, еллар буена бер сүзне сөйли. Ничек итсә дә итә, көйләп-чөйләп бар халыкны эшләтә.

Көн дә иртәнге якта, төрле зурлыктагы катык чүлмәкләре, төенчекләр салынган тарантасына утырып, таң этәчедәй бөтен җан иясеннән алда торып, Габидулла бригадир килеп җитә. Әче телләр аның бөтен кешедән дә алда торып, атын җигеп чыгуына төрттереп, болай диләр: «Габи Төксә иртән атын җигешергә хатыны Газимәне иялтеп бара икән. Камыт чөелдереген Газимәсе кысып бирә икән».

Ә менә бүген ул юк. Бу гаҗәп хәлгә аптыраган малайлар бабайны авылга озаттылар.

— Йә, Гапкадыйр бабай, син тизрәк кыймылда инде. Ашарга юк бит. Без чәчүне ташлап китә алмыйбыз — фронтка икмәк кирәк. Монда агуланган тарыны да ашап булмый. Исеңдәдер, шундый тарыны ашап, өченче ел Сәвәләй Фәритнең үлгәне. Менә-менә Гитлерны дөмектереп, әтиләр-абыйлар кайтыр чак җиткән, түзик инде. Габи абзыйга кереп чык, әллә авырып китте микән. Кичә бик җәфаланып йөргән иде.

Бабай аларга җавап биреп тә, ризасызлыгын белдереп тә тормады. Каршы әйтергә дә кыймады. Чөнки бу малайлар зурлар гына

башкарып чыга торган авыр кыр эшләрен инде менә берничә ел буена зарланмыйча эшлиләр иде. Кара яздан алып, кар төшкәнче Яланда куна ятып эшләү, кыш буена җигүле ат белән печән-салам, утын ташу, тирес түгү, кар тоту — барысы да алар җилкәсендә. Араларындагы менә шушы Нигъмәтуллага мөнәсәбәте бигрәк тә җылы. Чөнки ул малай беркайчан да сүгенми, кычкырмый, эшкә уңган.

Гапкадыйр бабай, Нигъмәтнең сүзен тыңлап, җигәр өчен Шихан биясен эзләргә китте. Ә аны табуы җиңел түгел. Ул, бахыр, ятса, тиз генә тора алмый. Шуңа күрә, ялandaгы бүреләрдән сакланыптыр инде, ял итәргә ятканда арты белән берәр куакка терәлеп ята. Торырга вакыты җиткәч, ике ал аягына басып, үзен күрсәтергә тырыша. Озаграк яткан вакытларында, буе җиткән кадәр тирә-ягындагы үләнне ашап бетергәч, теше белән казып, тамырларын ашый башлый. Үзен эзләп тапкач, авыз эченнән генә мекердәп, кешнәп, куанганын белдерә. Гапкадыйр бабай да, малайлар да моны бик яхшы белә. Койрыгыннан тотып, азрак өскә күтәрсәң, ул зур авырлык белән булса да, калтыранган аякларына баса. Аннан инде, су эчеп, коры печәннән дә авыз иткәч, үзе үк эзләнеп, камыт-дугалар янына бара. Бу аның, аяклары гариплектән, тора алмыйча озак кына ятса да, колхоз эшендә җаннарын аямыйча, көне-төне эшләгән кешеләргә үзенең кирәклеген күрсәтергә тырышуы була. Шуның өстенә, янбашларына бишмәт элерлек булып ябыкса да, яз җитүгә ел да колынлый. Ә аңардан туган колыннар, берничә ел үтүгә йөгерек һәм көчле атларга әйләнеп, Шихан биясенең тамырлары дигән исем белән, колхозда эшләгән малайлар арасында дан тота башлыйлар.

Гапкадыйр бабай бияне җиккән арада, авыл ягыннан килгән юлдан һаман да күзен ала алмый. Инде җигеп бетереп, арба төбенә азрак печән салып торганда, еракта, авыл юлында бер олау күренде.

— Йә, ходай, Габидулла гына булсын иде. Инде кайтмаска гына булса ярар иде.

Күп тә үтмәде, Туры тай җигелгән җиңел тарантаска утырган Габи бригадир килеп җитте. Атын туктатыр-туктатмас, аңарда гомер булмаган тизлек белән, җиргә сикереп төште. «Ул юк-бар аяклары ни күрә инде хәзер, нәрсә булган моңа?»— дип уйлап куйды бабай.

— Исәнлек-саулыкмы, Гапкадыйр абзый!

Үзе җавап көтеп тормады, нәрсәгәдер азрак шашына төшкән күзләрен малайлар тары чәчеп йөргән якка төбәп, дәвам итте:

— Чаң как, абзый, бик нык итеп чаң как! Шабаш булган эшкә, чаң давай!

Аптыраудан каушый башлаган бабайга игътибар итмичә, титаклый биреп, кабалана-кабалана, җиргә казып утырткан баганага аскан сабан төрәне янына ашыкты. Тирләп чыккан Туры тайны тугара башлаган бабайның күңеленә шом керде. Әллә берәр зур үлемҗитем бар микән? Чаң-чоң китереп арба кендеге белән сабан төрәненә суккан Габидуллага карап, эченнән дога укый башлаган иде, түземлелеге җитмәде, Габигә эндәште:

— Йә, Габидулла җитәр инде, йөрәкне кузгата башлады бу чаңың да, тукта! Чаң кагарлык нәрсә булды тагын шул хәтле?

— Сугыш беткән, Гапкадыйр абзый, сугыш! Шул сиңа яңалык!— Ул, кулындагы кендекне җиргә ташлады да, аксый биреп, тарантасы янына атлады. Бабай аңа аптыраган кыяфәт белән азрак карап торды да буыла төшебрәк тагын сорады:

— Суг-гыш... беткән?

— Әйе, сугыш дөмеккән, Гапкадыйр абзый, радиодан әйттеләр.

Әлеге сүзләрне ишеткәч, Гапкадыйр бабай, егетләр җитезлеге

белән, чаң янына ташланды. Иелеп, җирдә яткан кендекне алды да, шашып-шашып чаң кагарга тотынды.

Берникадәр вакыт үтүгә, атларын җир өстендә калдырып, Дулдин Хәйбүшнең тешле тәгәрмәчле тракторына төялгән малайлар килеп җиттеләр. Габи бригадир янында капылт туктаган трактордан коелып, чаң сугучы бабайны уратып алдылар. Бабай, аларга әһәмият бирмичә, тирә-яктагы бер кешене дә күрмичә, тимер кендек әле һаман сабан төрәнен кыйный иде. Нигъмәтулла, аның кулыннан кендекне алып, Габигә борылды.

— Нәрсәгә икәүләшеп шашасыз сез, нәрсә булды?

— Сугыш беткән, егетләр, сугыш!!

Кырда тирән тынлык урнашты.

Беренче булып Хәйбүш телгә килде:

— Ничек инде ул, сугыш беткән?

— Шулай инде менә, беткән киткән и вчу шуның белән! Герман полный капитулятсе иткән. Радиодан сөйләделәр бүген иртән.

Радио дигән сүз чыккач кына, малайлар башына барып җитте.

— Ура-а-а!!— дип, Хәйбүш трактор өстенә басып кычкырып җибәрде.— Габи абзыйны һавага чөяргә!

Малайлар өерләре белән Габигә барып ябыштылар.

— Китегез, кит, мәхлуклар, туктагыз, билемне кузгатасыз. Кайтып егылсам, Газимә җиңгәгезгә җавап бирерсез, туктагыз дим!

Нигъмәтулланың боерыгы яңгырады:

— Тыңламагыз сез аны, чөегез һавага!

Ике куллап тарантас үрәчәсенә ябышкан Габине йолкып алып, һавага очырдылар. Малайларга кушылырга үзендә көч тә, гайрәт тә тапмаган Гапкадыйр бабай яңадан сабан төрәнен тукмарга тотынды.

— Дөрес эшлисез, машинник малайлар, әйдә, селкетегез Габине.

Малайлар, кызарып бүртенгән Габидулланы җиргә утырттылар да. Нигъмәтнең пышылдап биргән боерыгына буйсынып, бабайга ташландылар. Ул аларга каршы әйтеп өлгергәнче, аны иплә кенә тотып, бик биек ыргытмыйча, һавага чөйделәр. Бабайны җиргә бастырганда, аның күзләре тулы яшь иде.

— Әй, балалар, балалар! Мансур улы-ым...

Каушый төшкән малайларга бригадир ярдәмгә килде:

— Ярар, Гапкадыйр абзый, елама! Бүген безнең бәйрәм. Җиңү бәйрәме. Шул җиңү өчен һәлак булды малаең, абзый. Андый егетләрне яшь түгеп искә алмыйк инде без бүген.

Үзе, сөйләгән арада, тарантасыннан алып малайларга зур гына чүпрәк палас сузды.

— Бик шәпләп җиргә җәегез шушы паласны. Берничәгез барып атларны тугарып алып килеп, ашарга бирегез. Ул хайваннарга да аз эләкмәде нужа михнәте...

Кораман юрганга төрелгән зур балчык чүлмәктә туп-тулы итле аш иде. Икенче чүлмәктә — әрчеп пешерелгән бәрәңге. Тагын бер чиләктә өсле катык белән дүрт бөтен икмәк алып килгән иде бригадирлары. Табын тирәли тезелешеп утырган малайларны Габи авыз эченнән генә санап чыкты да, тарантасыннан балчык стакан кебек савытлар чыгарып, Нигъмәтуллага тоттырды.

— Тарат.

Үзе коры печән эченнән бер чирекле пыяла шешә алды.

— Монысы, егетләр, сезгә Газимә җиңгәгездән күчтәнәч. Җиңү бәйрәме белән котлый сезне җиңгәгез. Күп түгел түгелен, ну шәп инде, малай!

Малайлар дәшми генә вак печән кисәкләре ябышкан шешәгә текәлделәр. Сугыш еллары буена тамаклары азыкка туймаган малайларның әче бал эчкәннәре юк иде, билгеле. Гапкадыйр бабай, кабалана биреп, Габинең кулына үрелде.

— Ай, рәхмәт төшкере бәндәсең дә инде, Габидулла энем! Мәнә зурладың тек зурладың син безне, асубы мине, карт солдатны.

Балчык стаканнарны бал белән тутыргач, Габи үзенә тигәнне күтәрде.

— Кубегезнең бу хәмерне тәүге эчүедер. Габидулла абзый эчәргә өйрәтте, диеш булмасын. Иң авыр елларда илебезнең тамагын туйдырып, фронтны ипекәй, ит, май, сөт белән тәэмин иттегез сез, егетләр. Арысландай ирләр эшли торган авыр эшләрне эшләдегез. Ил алдында күрсәткән батырлыгыгыз өчен, мең рәхмәт сезгә. Җиңү белән котлыйм сезне, туганнар!

Ул, тавыш-тынсыз гына эчә башлаган малайларга бераз карап торды да, аларның эчеп бетергәнен көтеп торып, бабайга эндәште:

— Сиңа да, Гапкадыйр абзый, җиңү белән котлап, карчыгың бүләк җибәрде.

— Нәрсә генә җибәрә алды икән инде ул? Кая карап карыйк!

Габидулла фуфайка кесәсеннән бер чүпрәк алды да, аны саклык белән генә сүтеп, эченнән бер тавык йомыркасы китереп чыгарды.

— Тот, Гапкадыйр абзый. Чуар тавыгыгыз бүген иртән күкәй салган! Әби әйтте, җиңү бәйрәме белән котлады безне бүген тавыккаебыз, ди. Син кайгырма, әбигә мин яртыны ипи калдырдым. Күршегезнең әтәче дә сезнең тавык янында. Инде бер-берсеннән калмый йөриләр, ди. Әтәч түгел, бөркет диярсең, инде дә кодырая тавык янында, инде дә кодырая...

Көлешкән малайларның тавышын басып, өстәп куйды:

— Гитлерның дөмеккәнен әллә тавык та беләме икән?!

## Сугыш беткән көздә

Кала юлыннан, тузан туздырып, авыл ягына «пылтаратунка» дигән йөк машинасы килә, артыннан пырхылдап чыккан кара төтене ул машинаның эчке торышларының бигүк шәп булмаганын күрсәтеп тора. Йөреше дә әллә ни кызу түгел. Күрәсең, юктан бар булган нәрсәдер инде. Машина кузовы идәнендә, аркасын кабинага терәп, өстенә иске, погонсыз шинель, башына йолдызсыз пилотка кигән солдат кебегрәк бер бәндә утырган. Янында яткан капчыгының арыклыгы, үзенең таушалган саргылт йөзе, өметен югалта язган тоныкк күзләре — бу кешенең шатлыклы көннәре аз булып, нужа-михнәт белән бик яхшы таныш икәнен белдерә.

Авылга җитәргә ярты чакрым тирәсе калгач, ул кеше, аякларына басып, кабина башына берничә тапкыр сукты. Машина әллә нинди сызгырган-ыжгырган тавышлар чыгарып туктады. Шинельле бәндә, авыру кеше кебек җайлап кына, машина тәгәрмәчен аяклары белән сәрмәп баса-баса җиргә төште. Кабина эчендә, рульдә утырган чибәр генә кызга ул унлык акча сузды. Тик кыз акчаны алырга ашыкмады.

— Әллә пленнән кайтып килүеңме?

— Әйе...

— Ярар инде, абый! Акчаңның үзеңә дә кирәк җире күп булыр, синең нәрсәңне аласың инде?

Кыз аңа башка сүз әйтмәде, кузгалып китте. Төшкән кеше машина тәгәрмәчләреннән күтәрелгән тузанлы юлда ялгызы басып калды. Аннан соң, олы юлдан уңгарак алып, тау буеннан сузылган сукмак белән авылга юнәлде.

Авыл очына җиткәч, таш коймa белән уратып алынган борынгы зират янына туктап, башын иеп, бераз уйланып торды да, таш моешеннән үрмәләп менеп, зират эченә төште. Ул каберлекне яхшы белә иде, ахрысы, туктамастан, зират уртасына, үзенә кирәк урынга

юнәлде. Төрле зурлыктагы, төрлечә ясалып утыртылган кабер ташлары аның күңеленә авыр һәм күңелсез тойгылар китерә иде. Ул, ниндидер дога укый-укый бара торгач, үзенә кирәк каберне тапты. Оста итеп язылган зур ташлы, өстен кылган каплаган иске кабер янына җиткәч, туктап, капчыгын җиргә куйды. Калтыранган бармаклары белән кабернең көзге кояш нурларында азрак җылынган ташын, аның чокып язылган хәрефләрен сыйпады. Бу — этисенең кабере иде. Ул, кабер янына тезләнеп, үзе белгән барлык догаларын да укып бетерде дә тавышсыз гына, туйганчы елады.

Дөнья мәшәкатьләрендә эше булмаган зират эчендә үзенә генә хас булган бер тынычлык. Елаган саен йөрәгендәге ничәмә еллар җыйналган авырлык җиңеләйгән кебек була, күргән михнәтләренең эзләре дә җуела башлар кебек тоела иде.

Кич булып, ут алыр вакытта, ул Банжур Ибрай өендә сәке кырыенда, үзен азрак гаепле кеше сыманрак тотып, чәй эчеп утыра иде инде. Банжур, Ибрайның хатыны Миңлекамал — аның бертуган апасы. Тик чәй эчүләренең яме генә юк. Кәз булганлыктан, ашау ягы, бик бай булмаса да, ярыйсы гына күренә. Әрчеп пешерелгән ярмалы бәрәңге, азрак каймак, сөтле чәй. Әмма озак еллар берберсен күрми торып очрашкан туганнар арасында була торган шатлык кына юк.

— ...Кырык өчнең май башында, хатының белән кызың бер көнне үлделәр. Беребез дә сизми калдык. Кызың кар астында кышлаган башакны җыеп алып кайткан. Шуны Мәгүзә килен кул тегермәненнән үткәреп, ярма иткән дә, боткасын пешергән. Икәүләшеп шуны ашаганнар. Ул агулы була икән. Икенче көнне күрше малайлары йөгереп килгән: «Мәгүзә апа белән Оркыя әллә нәрсә эшлиләр»,— дип. Барса-а-а-ам!..

Миңлекамал, яулык очы белән күзләрен сөртеп алды да, дәвам итте:

— ...кызын кочаклап яткан, йөрәккәем. Икесенең дә борыннарыннан, колакларыннан кан ага. Мин баргач, кызың, озак тормады китте. Сабый бит, ач булгач, күбрәк ашаган, күрәсең. Хатының кичкә таба үлде. Барган көйгә, су җылытып, икесенең дә баш-күзләрен юдым... Синең туй бүләге итеп биргән әйбердән теккән үз күлмәген, аннан син туйда кигән, якаларын үзе чиккән ак күлмәгеңне сандыгыгыздан алдыртты. Икесен ике урындык артына элдерткән иде...

Миңлекамал, сүзләрен сөйли алмыйча, ашъяулык почмагын бөтереп, озак кына утырды. Энесе солдат Латыйф эндәшмәде. Тик эчендә уты бетергә җитешкән сары җиз самавыр гына, әле үзенең эссесе барын белгертергә тырышып, нечкә итеп тавыш бирә иде.

— Сандык эче буп-буш, бөтен нәрсәсен ризыкка алыштырып бетергән. Калганы шул ике күлмәк тә, шулар төрелгән иске чаршау кисәге. Кәфен эченә шул син бүләк иткән күлмәген кидертеп куярга кушты. Кидердем инде, гөнаһысы үземә булыр. Үләренә күп калмаган иде. Иелергә кушты. Шуннан соңгы сүзләрен әйтте: «Кем белә, бәлки Латыйфым исәндер. Плиндер, мөгаен. Исән-сау кайтса, соңгы сәламемне әйт, мин бәхил. Бик рәхмәт, әйбәт итеп торган идек. Исән булса, кайтыр. Кайткач, ялгыз тормас, өйләнер. Әйт, башкача безнең нәселдән алмасын. Туганым белән торуын теләмим»,— диде. Шул менә сиңа Мәгүзә киленнең сүзләре. ..Икесен дә бер кабергә куйдылар. Әтидән ерак түгел, диделәр... Өеңне күргәнсеңдер инде. Тәрәзәләре такта белән кадакланган көенә тора. Әни Майкамалларда. Иртәгә барырсың, үзе килә алмас. Югары очтан байтак ара бит.

— Кияүнең хәбәре бармы?

— Юк шул! Кырык икенче елның уртасында килгән иде, биз-

висте дип, шул юктан юк инде. Үзең йөргән җирләрдә очрамадымы соң сиңа...

— Юк.

— Әй, илаһым! Минә синең кебек плин булса, исән-сау калып, кайтып та килгән булыр иде әллә?

— Әй, апа! Плин булганчы, үлгәнең мең артык! Анда күргәнне дустыңа түгел, дошманыңа да күрсәтмәсен. Очрашкан көнне үк шул турыда сөйләшмик әле, йөрәк болай да бозылган... Очратмадыңмы дигәннән, мин бит теге Җомай Габдерәхимен очраттым, уйламаган җирдә...

Латыйфның йөзе ачыла төште һәм ул апасына беренче тапкыр күтәрелеп карады. Сулыккан, картайган иде апасы.

— Ничек итеп тагын? Кайсы Габдерәхим ул? Җомай Мәҗите малаемы?

— Әйе, мин аның сугышка алынганлыгын белмәгән идем.

— Соң, белергә ни! Аларны бит кырык өченче елны гына алдылар. Кыш киттеләр алар. Ул бахырларны өчесен бер көнне озаттылар. Өч Габдерәхимне. Әмин бабай Хәбиренең Габдерәхиме, Сукыр Хәйринеке, аннан шушы Җомай Мәҗитенеке. Кайда күрдең аны? Аның бит кыш көне үк үле хәбәре килде. Тапшырырга кешесе булмагач, силсәвиттә калды, әле дә шундадыр.

— Нишләп алай?

— Соң, шулай булмый ни... Әнисе кырык бернең кышы башланган вакытта үлде. Әтиләрен теге трудәрмиягә алып киттеләр кырык өчтә. Анысын шунда нәрсәдер басып үтергән. Исеңдәдер, азрак төшерсә, урам тотырып кайта торган иде, мәрхүм. Кырык беренче елны, Хәфизә түти үлгәч, Ибрай авылыннан зур бер шадра хатын алган иде, анысы үзе трудәрмиядә чакта, кире кайтып китте. Мәҗит абзыйның ике баласы өйләрендә ялгыз торып калды. Хәбибә белән Габдерахманы. Шуннан силсәвит икесен дә детдомга бирде. Өйләрен саттылар. Бүрекче бабай алды. Ел бардыр инде. Куйбышев дигән калага озаттылар — зурраклар җыйналган детдомга диделәр. Кайберәүләр, Хәбибәсен Ташкентка озатканнар икән, дип тә әйтә. Ничектер инде, хөкүмәт кулында алар. Габдерахманын җәллим дә инде шуларның. Ә-әй дөнья, кырыкка әйләнә икән... Карале, әллә кая кереп киткәнмен, кайда күрдең ул Габдерәхимне?

— Норвегиядә.

— Бәй, анысы нәрсә тагын?

— Таш-кыядан гына торган бер ил бар төньякта. Немецлар безне норвегларның Керкенес дигән каласы янында концлагерьда тоттылар. Җир астыннан руда казыттылар. Шул концлагерьны кырык бишенче елның гыйнварендә совет гаскәрләре азат итте. Төнлә диңгездән десант төшергәннәр. Бик тиз булды бу. Ике сәгать тә үтмәгәндер, кичә генә әллә кем булып йөргән фашист сакчыларының берсе дә юк. Әллә плин да алып тормадылар инде үзләрен. Иртән безне, егермеләп кешене, шул фашистларның мәетләрен бер җиргә җыеп, күмәргә куштылар. Бер иптәш белән киркалар күтәреп китеп бара идек, арттан берәү татарчалап дәште бит миңа: «Латыйф абзый, әллә син инде?»,— ди. Барган җирдән егылып китә яздым. Тиз генә әйләнеп карасам, барак ишеге төбендә өч кызыларәмеец басып тора. Шинель, бүрек кигәннәр, аркаларында автомат, бил каешында теге финка дигән пычак, гранаталар. Ну, дастуеннар инде. Карап-карап карыйм, танымыйм бит. Шул авызы ерыгы якынрак килде дә тагын дәште. Авылыбызның исемен әйтә. Бик җентекләп карагач, таныган кебек булдым бит моны. «Мәҗит абзыйның Габдерәхиме дип әйтсәм инде»,— дим моңарга, кыяр-кыймас кына. Шуннан түзмәде, кочаклап алды бу мине. Сөякләрне сындыра язды, көч моңарда үгез-

неке кебек. Ул Җомайлар нәселен үзең беләсең, элек-электән таза нәсел бит. «Сез кырган фашистларны күмәргә кирәк, шуңа китеп барыш»,— мин әйтәм. «Әйдә, керик әле»,— ди бу миңа. Кердек теге барак эченә. Иптәшенә карап кына алды, тегесе чыгып китеп юк та булды, әйләнеп тә керде. Миңа рөхсәт алырга чыккан икән. Барактан ике солдат капчыгы алдылар да, яңадан чыгып киттек. Теге фашист сакчылары яшәгән кирпеч йортның икенче катына менеп, зур бер бүлмәдә кич буена сөйләшеп утырдык. Күкрәк тулы орден, медаль моңарда, капчык тулы ашамлык, спирт. Эчәргә бик көчләп караганнар иде, кая ул эчү. Күз ризыкта гына.

Десантчы икән болар. Бик озак утыргач, авыл хәлләрен сөйләшеп бетергәч, дигәндәй, бик тә теләмичә генә аерылыштык без Габдерәхим белән. «Энем Габдерахманны үлеп сагынам, исән-сау кайтсам, инженерлыкка укытыр идем мин аны»,— диде бахыр. Балалар йортында икәнлеген белә иде. Үзебезнең торган баракка озатып куйды бу мине. Ике кирпич ипи, өч американски тушонка бирде. Өчесе дә зур банкалар. Аннан бер пар җылы күлмәк-ыштан, бер свитер бирде. Ул свитере әле дә бар. Кайткач, энесенә бирермен дип, кимичә йөрттем. Аерылышканда әйтте: «Иртәгә без Керкенес шәһәрен алырга китәбез,— диде.— Шуны башкаргач, мин сине эзләп табармын. Азрак акчам бар, шуны алып кайтып, энем белән сеңелемә тапшырырсың»,— диде.

Атнадан артык вакыт үтте — юк бу. Безне тезеп, санап барладылар. Карап, тикшереп торырга утыз кешегә бер солдат куйдылар. Аннан соң Рәчәйгә озата башладылар. Корабльгә утыра башлаганда бер солдат җиңнән тотты бит: «Синме Рахимның землягы?» — ди бу. Карасам, апака-ем, ике иптәшенең берсе. Танып алган бит. «Сине чичәнче көн эзлим бит инде. ...Погиб Рахим Юсупов, Керкенесне алганда»,— ди. Еладым, апа.

Миңлекамал апа, күз яшьләрен сөртә-сөртә, өстәп куйды:

— Ә-ә-әй, энем! Еламаслыкмы соң? Сугыштагысы — сугышта бәхетсез, мондагысы — монда бәхетсез. Йә инде, сугыш башланганда гына биш кеше үзләренчә гөрләшеп яшиләр иде, бичаралар. Хәзер менә берсе дә юк. Кит инде, ичмасам, ходай азрак искәртмәгән дә икән, бик алдан ук йөгермәскә иде шул сугышкан җирендә. Йә инде, язмыш диген, илаһым. Болай булгач, чит илдә, чит җирдә күмелеп калган бит инде?

— Шулай инде...

— Әй, ходаем! Бу каһәр суккан Гитлерны тере көенә тота алмадылар бит. Агуланып җиңел генә котылды, мур кыргыры. Тимер читлеккә утыртып, иң алама үгезне җигеп, авылдан авылга күрсәтеп йөрергә иде хәшәрәтне.

— Белмим шул, апа, үгез тартыр идеме икән аны?

— Шулай шул, туганым, тартмасые...

Сүнә башлаган самавыр сузып-сузып кына тавыш бирә, мич артында чикерткә чырылдый, тышта төнге караңгылык.

— Җизнәңне «кайда» дип сорамыйсың да.

— Һәй, апа, сорарга да куркам инде.

— Исән-сау, аллага шөкер. Чиләбе каласында, танклар ясый торган забутта трудармис булып эшли. Үткән атнада гына Вәрис абзый кайткан. Шуның артыннан бер пар рабучи батинкалар җибәргән, миңа бер яулык. Һаман шул Банжур инде. Атларымны да, Миңнекамалымны да бик сагындым, дигән. Үктәбер бәйрәменә кайтарырлар, ахры, көтеп торсын. Банжур Ибрай җиңүсез кайта торган кеше түгел ул, дигән. Озакламый кайтыр инде үзенең атлары янына...

Сәйти бабай капкасы төбенә килеп туктаган «американский вилис»не Таракан Барыйлары янында «чебенле» уйнап йөргән малайлар сизми калдылар. Тик «көтүче» булып йөгергән, ике тез башы да тишек чалбар кигән сипкелле малай алҗыган күзләре белән машинаны шәйләп алды. «Көтүче»лектән котылу өчен сәбәп табуына куанып, кулындагы «чебен»не яшел чирәмгә ыргытты да Сәйти бабайларга таба йөгерде.

— Американский вилис, малайлар, ура-а!

Бар да сискәнеп китеп, шул якка борылып карады һәм теге малай артыннан йөгерешә башлады. Алар машина алдына барып җиткәндә, зур таза гәүдәле, хәрби киемдәге, күкрәген тутырып орден-медальләр таккан берәү, кул биреп, машина шоферы белән хушлаша башлады.

— Хуш, туганкай! Бик нык ярдәм иттең син миңа, күп рәхмәт!

— Без бит фронтовиклар, ничек ярдәм итмисең. Шулай гына булырга тиеш.

Кузгалып китеп барган машинага малайлар әллә ни әһәмият итмәделәр, алларында басып торган хәрбидән күзләрен ала алмыйча, өнсез калдылар. Аның күкрәгенең уң ягында ике Дан, бер Кызыл Байрак ордены, ә сул ягында Ватан Сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары ялтырый иде. Ул, елмайган күзләрен малайлар өстеннән йөртеп чыкты да, моңлы күкрәк тавышы белән аларга эндәште:

— Ну, безнең урамның егетләре, исәннәрмесез! Минем энекәш нигә күренми?

Малайлар эндәшмәделәр. Алар аптырау һәм соклануда телсез калганнар иде.

— Нигә дәшмисез? Әллә танымыйсызмы?

Малайлар төркеменең иң алдында басып торган Халит, чаялыгы белән Чапай кушаматы алган малай, телгә килде:

— Таныйбыз, Җәүдәт абый, таныйбыз!— Ул, кулындагы таягын читкә ташлап, чуендай каралган ике кулын кулмәгенә ышкыштырып, Җәүдәткә суздьі:— Исән-сау кайттыңмы, Җәүдәт абый?

Төрле зурлыктагы малайлар, ут күзләрен Җәүдәтнең күкрәген каплаган орденнардан ала алмыйча, бик җитди кыяфәт белән бербер артлы кулларын биреп, шул ук сүзләрне кабатладылар. Җәүдәт, күрешеп бетәр-бетмәстә:

— Нигә арагызда минем энекәш юк, кая ул?— диде.

Җавапны Халит бирде:

— Әлфәт, Җәүдәт абый, Ваһиба әби белән Юкәле Күл яланына башак җыярга китте. Сәйти бабай колхоз келәтләре янында көндезге каравылда тора. Йөгеримме?

— Йөгер, энем, чап! Җәүдәт абый кайтты диген, сөенче ал! Сөенче миннән булыр!

Үзе белән алып кайткан ике зур чемоданны һәм бер солдат капчыгын күтәргән малайларны ияртеп, Җәүдәт каз үләне каплаган ишегалдына үтте. Аның чибәр йөзендә әчке бер җылылык балкый иде.

Авыл шау-гөр килде. Уйлап карасаң, шәп бит! Картәнисе һәм картәтисе янында үскән Блюхер Батыргәрәй улы Җәүдәт, кырык өченче елны сугышка киткәндә, малайлыктан да чыгып бетмәгән иде. Менә хәзер күкрәге тулы орденнар белән исән-сау кайтып керсен әле! Әйтергә генә ансат: биш ордены, алты медале бар!

Кайтуына атна-ун көн үтүгә, Җәүдәт җиң сызганып колхоз эшенә чыгып китте. Картайган, сугыш елларында йончыган Сәет-

гәрәй бабай белән Ваһибә әбине карарга, ундүртен тутырып килгән энесе Өлфәтне укытырга кирәк иде. Сугыш турында ул сөйләргә яратмады. Тик күпне төпченергә яратучы Түбән оч малайлары иген урганда, сабанда йөргәндә, колхозның ындыр табакларында куна ятып печән чапкан вакытларда Җәүдәтне сөйләтеп, бер нәрсәне белделәр: ул фронтта зур командирларга гына буйсынган һәм махсус бурычлар үти торган, фашистлар тылына җибәрелгән развед-диверсантлар төркемендә сугышып йөргән икән. Сөйләгән чакларында, эчке бер өзгәләнү белән, үзе дә сизмәстән эчен бушатып куя:

— Фашистлар тылында аеруча мөһим бурычны үтәп йөрү, разведкага чыгып, «тел» алып кайту гына түгел. «Тел»не эләктергәч, бар белгәнең үзебезнең якка таю була. Ә безнең бурыч — икенче. Менә син биш-алты минут эчендә немецларның берәр штабын юк итеп кара. Шул арада кирәкле документларын да эләктереп өлгер. Артыңнан куа чыккан эт өереннән котылып, тере дә кал. Көтелмәгән әллә нәрсәләре килеп чыга әле аның. Безгә тиз һәм туры итеп ата белү, пычак сугышы, кул сугышы, тәүлекләр буена кузгалмастан яшеренеп качып яту — барысы мөһим иде. Үләсе килми адәм баласының — түзәсең, иркәләрем, барысына да түзәсең. Күп күрдем мин анда ир-егетләрнең солтаннары-ын! Кирәк булгач, аждаһа авызына кергән кебек, немец өеренең иң уртасына кереп китәләр. Алтыҗиде кеше чыгып китә торган идек, кире ике-өчебез генә әйләнеп кайта. Тәүдә араларында иң яше мин идем. Немец тылына чыккач, үзләренең уллары итеп карап, саклап йөрттеләр. Бер Завьялов дигән старшина бар иде. Атамнан күрмәгән кадерне күрсәтте. Бик ярата иде мине, мәрхүм...

— Киттемени, Җәүдәт абый?

— Китте шул. Варшава каласын алганда, безнең чигенгән төркемне каплап торып калды. Шунда үзен граната белән шартлаткан.

— Аны ничек итеп белдегез?

— Шартлаганнан соң Польша крестьяннары җыйнаштырып күмгәннәр. Шулар сөйләде.

1943 елның башында сугышка чыгып киткән малайлардан Җәүдәт белән Габдерәхим генә исән-сау кайтып, илен, туганнарын күрү бәхетенә ирештеләр...

## Күзгә ачы җилләрдә...

Октябрь урталары җитеп килгән чак иде. Туктамастан көнетөне яуган көзге салкын яңгырлар авыл урамнарын үтә алмаслык пычракка әйләндерде. Сугыштан кайтмаган хуҗаларын көтеп җиргә сеңгән, салам түбәләре күптән туза башлаган авыл өйләрендә өметсезлек хөкем сөрә. Сугыш елларын зур михнәт, югалтулар белән үткәргән, йончыган авылда күңелсез караңгылык. Хәшәрәт Гитлер белән сугышып, мәхшәри яуда башларын салган ирләрен, бәлки исәндер, менә кайтыр әле, диеп көткән күп балалы яшь хатыннар йөрәгендә өмет, шомлы шиккә әйләнеп, йөрәккә кан саудыра. Сугыш беткәнгә инде ел тулып, икенчегә китеп бара. Ә киң күкрәкле, зур куллы, кочакласа, сөякләрне шытырдатырдай ирләре кайтмый. Колхозлар арык, бала-чага ач-ялангач, хатыннарның күзләрендә сагыну, юксыну, сагыш. Үсеп буйга җиткән кызлар, авыр булачагын алдан белсәләр дә, кайсылары торф чыгара торган якларга, кайсылары Сталинград шәһәрен төзешергә диеп, авылдан китә торалар...

Шундый салкын кичләрнең берсе. Аякланмаслык булып пычракка баткан авыл урамы буйлап солдатча киенгән, юешләнгән, күшегеп өшегән берәү атлый. Юлда җыелып торган яңгыр суларын

да, арба тәгәрмәчләре, мал аяклары изгән пычракны да карап тормый. Чөнки аның инде моңардан да артык юешләнәсе, пычранасы калмаган. Әмма юлчы урамның читеннән, койма-читән кырыйларыннан, ансыз да караңгы урамның караңгырак җирләреннән барырга тырыша. Күрәсең, исәбе — кеше күзенә чалынмау. Җәбрәй Хәсәннең калай белән япкан йортын үткәч, урамның икенче ягына чыгып, тәрәзәләреннән беленер-беленмәс кенә ут яктысы сирпелгән берничә өйне үтеп, тар тыкрыкка борылды. Пожар урамына чыга башлады. Ул, күрәсең, авыл урамнарын яхшы белә иде.

Хәбир Чатан иңенә салган тунын, төшеп китмәсен өчен сул кулы белән тоткан хәлдә, ишегалды уртасында туктап калды. Чөнки ул әле генә тар тыкрыкка борылган кешене шәйләгән иде. Аяк астындагы пычрак юлга чыкылдатып баса-баса, кабаланмыйча гына атлаучы юлчы, ниндидер таныш булмаган телдә, әкрен генә җырлый:

«...Ах, майн либер Аугустин,
Аугустин...»

Кем булыр икән бу?

Шушы сорау, өенә кереп, катыклы арыш умачы ашарга утыргач та Хәбир Чатанга тынгылык бирмәде. Кырые кителгән агач кашык, балчык савыт белән зур авыз арасын берничә тапкыр урады да туктап калды.

— Карале, Мөкәррәмә, әле генә безнең тыкрыктан берәү Пожар урамына таба үтеп китте. Үзе бик арыган да кебек, үзе нәрсәдер җырлый да. Тик танып булмады.

— И-и, ир кешеме?

— Соң ир булмыйча! Хатын-кыз төнлә белән урамда җырлап йөримени? Баш диген!..

— Әй шушыны! Алай минем баш ярамагач, сүзләреңне эчеңдә генә тот. Әнә, умачыңны аша, суытма. Чуртым йөрсенме эт чыкмаслык төндә.

Хәбир кашыгын тоткан көенә азрак уйланып торды да әйтеп салды:

— Тануын танымадым, тик шигем бар. Ул кешене Сабур дип уйлыйм мин.

— Кайсы Сабур ул тагын?

— Кытыйка Сабур!

Мөкәррәмә, кашыгындагы умачын шопырдата-шопырдата авызына озатып, кабаланмыйча чәйнәп йоткач кына телгә килде:

— Ки-и-ит! Сабур Кытыйка кырыгынчы елны әрмиягә киткәннән бирле юк бит ул. Сугыш башлангач та бер хаты да булмады. Әнисе Шәрифә түти инде елавыннан да туктады шикелле.

Мөкәррәмә, сөйләнгән арада, кызыксынып, иренең күзләренә карый. Ул да үтеп киткән кешенең Сабур булуын тели иде кебек.

— Нигә Сабурга охшаттың соң әле син аны?

— Охшатмадым охшатуын, тик, мин әйтәм, шушындый әшәке, көзге төндә Сабурдан башка кемнең җырлавы мөмкин, ә?

Ул зур тантана белән хатынына карап алды да, аның эндәшмәвен күргәч, җиңгән кыяфәт белән өстәп куйды:

— Туты менә! Мөгаен, Сабур!

Хатын да ире кебек үзсүзле иде, ахрысы:

— Сугыш беткәнгә ел ярым үтеп бара. Каян килеп Сабур Кытыйка булсын? Әллә кайчан сөякләре череп беткәндер инде. Уйлап чыгарырга булса, сиңа куш!

Ире җавап биреп тормады, уена чумды.

* * *

Юешләнеп, күшегеп өшегән кеше, Пожар урамына чыккач, арба күчәрләре читәнгә бәрелмәсен өчен куелган зур ташны, караңгыда күрмәсә дә, әллә кайчан белгән кебек, әйләнеп үтте. Аннан, туктალып, шинеленең якасын ике куллап төшерде дә, кулбашын сикертеп, аркасындагы тыгызлап тутырылган солдат капчыгын җайлап куйды. Кире борылып ике адым атлады да, уң аягы белән тыкрык почмагындагы ташка җиңелчә генә тибеп алды. Таш, чыннан да, урынында иде.

— Һе, бетергән ди Гитлер Сабурны! Бетерерсең! Менә ул мин! Үз урамымда басып торам! Үз йортыма кайтып җиттем!

Сабур баскан җирендә азрак дәшми торды да, сүгенгән кебек, зур нәфрәт белән пышылдап өстәп куйды:

— Фаш-ш-ши-ст!..

Хәбир Чатан дөрес исәпләп чыгарган икән. Кара төннәрдә, күзгә ачы җилләрдә җылы эзләп йөрүче бу бәндә, чыннан да, пленнан кайтып килүче Кытыйка Сабур иде. Ул, куеныннан бер пар күн перчаткалар чыгарып, күшеккән кулларына киде. Итекләрен берберсенә бәреп, балчыктан арындырды. Туктамыйча гына, башындагы фуражкасын салып селкеде. Зур канәгатьлек белән көлеп куйды. Шуннан соң гына, кырт борылып, күршедәге өйгә керде.

Икенче көнне авыл урамнары яңа хәбәр сөйләп гөж килде:

— Кытыйка Сабур кайткан. Кытыйка кайткан!

«Чатан күп йөрер»,— дигәндәй, таң атар-атмаста, Шәрифә карчыкның ишегалдына, бата-чума, чатан Хәбир килеп керде. Керер алдыннан, читән аша үрелеп, өй тәрәзәсенә карады — анда кечкенә генә ут яктысы бар иде. Төне буена йокламыйча чыккан Хәбирнең йөрәге күкрәгеннән чыгардай булып тибә. Ул, эчкә караган уңайга тәрәзәгә күз салып алды, тик анда бернәрсә дә күренмәде, өй тәрәзәсе эчтән парланган иде. Хәбир, кечкенә чоланны үткәч, сәрмәнәсәрмәнә өй ишеген тапты. Аны ачып, тавыш бирде:

— Керергә рөхсәтме?

Өй эченнән, Чатан Хәбирнең сугыш елларында нужа-михнәт, эш белән көрәшеп арган йөрәгенә сары май кебек ягымлы кагылып, Кытыйка Сабур тавышы яңгырады:

— Әйдүк, әйдүк. Гутен морген! Үтегез, үт, кем ул анда?

— Әссәламегаләйкү-ум!

— Әйдүк, Хәбир абзый, әйдүк! Түрдән уз. Исән-сау йөрүме?

Сәке янына түмәр куеп утырган Сабур Чатан Хәбирне якты йөз белән каршы алды. Утырган җиреннән тиз генә торып, Хәбир белән ике куллап күреште дә аны сәке янына, табынга чакырды.

Бу өйдә төне буена йокламаганнар. Зур җиз самавыр янында утырган Сабурның әнисе, Шәрифә әби, күзләрен улыннан ала алмый. Аның өчен, алты ел читтә югалып йөреп, әллә нинди илләрдә, әллә нинди тоткынлыкларда булып та исән кайткан җирән улыннан да матур кеше юк. Сабур исә, тирләп-пешеп, кызарган битен, муеннарын киҗеле сөлге белән сөртә-сөртә, Хәбирне кыстый башлады:

— Утыр, Хәбир, абзый, утыр. Әйдә, менә күчтәнәчләрдән авыз ит.

Сабурның «күчтәнәч» дигәннәре эре-эре итеп телгәләп ташланган юан колбаса, берничә балык консервасы, тозлы балык; ашъяулык читендә, харәм булсак та, безгә дә урын табылды бит әле дигәндәй, гәзит кәгазенә туралып салынган чучка мае. Болардан тыш Шәрифә әби янына өелгән чәй-шикәр, прәнник-печенье, берничә кирпеч ак һәм кара ипи. Аларына Шәрифә әби хуҗа. Сабур янында бушап бетә язган бер «акбаш» тора. Сәкедә, аякларын бөкләп, азрак кызмача, чәчләре энесенеке кебек үк кызыл булмаса да, шактый ук җирән,

Сабурдан җиде яшькә зур абзасы Тимергали утыра. Әнисе белән абыйсы Сабур сөйләгәннәрне төне буена тыңлаганнар, тагын әллә ни гомер тыңларга әзерләр.

— Шуннан, Хәбир абзый, тормышлар ничек?

— Тормыш дип, бик кәпераеп сөйләп булмый әле, Сабур энем. Эшләр бик шәптән түгел. Колхоз трудка иген бирми диярлек, башкача килер җир юк. Яшибез инде шунда, исәпкә бар, санга юк... Безнеке ярар, энем, син үзең сөйләп җибәр Җаврупа хәлләрен. Кайларда йөрдең ни гомер хәбәр дә бирмичә? Инде кайтуын да соңлабрак...

— Тот әле менә шушыны. Башка юк, бетте.

Хәбир берничә тапкыр күз төшереп алган шешәдән кырлы стаканга салган аракыны беткәнче салды да аңарга сузды Сабур.

— Тот!

— Ярап торыр иде инде эчмәсәк тә. Сыйлаганда су эч дигәндәй, ярар алайса, синең исәнлеккә булсын.

Хәбир, эчеп бетергәч, ихылдап тамак кыра-кыра тирән итеп тын алды да тозлы балыкка үрелде. Сабур гәҗит өстендәге чучка маен аңа якынрак тартты:

— Кабып җибәр, теге тырышып йөгерә торганныкын да дим.

— Юк, юк, энем, мәшәкатьләнмә! Мин ул нәрсәне авыз иткән кеше түгел. Сугыш башланганнан бирле тозлы балык күргәнем юк минә.

Ул, койрыгыннан эләктереп, бер балык кисәген алды да зур ихласлык белән шуны кимерә башлады.

Сәкедә аякларын бөкләп утырган Тимеркәй телгә килде:

— Шуннан, энем?

— Һе, шуннан? Шуннан шул. Кырык өчнең сентябрендә теге «телячий вагон»нарга тутырдылар да алып киттеләр. Дүрт көн бардык. Бөтен вагонга көненә ике чиләк су бирәләр дә — вәссәлам. Доңгыр-доңгыр алып киттеләр үзләренең Германнарына...

Атна буена Шәрифә карчыкның өй ишеге ябылмады. Чатан Хәбирнең аягы җиңел булды. Сабурны күрергә авылның карты-яше агылды. Ирләре сугыштан кайтмаган хатыннар, сүнеп бетеп бара торган өметләренә азык булып, Сабурдан берәр җылы сүз чыкмасмы икән, диеп, аны күрергә ашыктылар. Килгән бер хатын, ике куллап Сабур белән күрешә дә, шул ук мизгелдә үзенекен суза башлый:

— И-и иркәм, Сабу-у-ур! Әнкәңә зур шатлык инде исән-сау кайтуың. Менә бит, насыйп булгач. Йөргән җирләреңдә минем Зөбәйдуллам очрамадымы? Аның да кырык икенче елның языннан бирле хәбәре юк бит.

Өй эчендә тавыш-тын юк. Барысы да Сабурны тыңлыйлар. Килгән халыкның соравына җавап биреп, башыннан үткәннәрен атнаун көн эчендә әллә ничә тапкырлар сөйләп чыкты ул:

— Кырыгынчы елның август азагында авылдан без икәү генә чыгып киттек. Мин дә, Чишмә башындагы Камун Галәү энесе Габделхәй. Ул калада ук аерылып калды — авиациягә алдылар аны. Ә мине Забайкальега, Магоча дигән станциягә озаттылар. Шунда аерым саперно-пантонный батальон төзеделәр. Батальон командиры Ломакин дигән капитан иде. Март башына кадәр шунда булдык. Ул суык, мин сезгә әйтим! Ул теге Монголия ягыннан, кар катыш ком бураны куптарып, җил исә. Ни юньле агач юк, ни юньле урман юк. Ташлы сопка да сопка.

— Сопка дигәне нәрсә тагы?

— Ул якта тауларны шулай атыйлар. Сопка аралары — үлән үсеп утырган тип-тигез дала. Шул даладагы җирле халыкны Забайкалье казаклары дип йөртәләр. Элекке заманда иген дә чәчкән,

печән чапкан, патшага да хезмәт иткән алар. Без анда вакытта барысы да колхозда иделәр. Ә риза булмаганнары граждannар сугышы чорында ук Кытайга качып киткәннәр.

Шуннан соң, кырык бернең март башында, төнлә белән тревога ясап җибәрмәсеннәрме! Ну безнең кот ботка төште. Сугыш икән, диеп торабыз. Алты сәгать эчендә бөтен коралны, пантоннарны, кухняларны эшалонга төяттеләр дә, үзебезне бер-бер вагонга кырыгар кеше кертеп, гүләтеп алып та киттеләр. Смоленск дигән калага хәтле унбер тәүлек бардык. Хат язарга кушмыйлар. Станцияләрдә ишек ачарга рөхсәт юк. Чыгып вагон янында басып торырга да форсат бирмиләр. Төнлә белән генә берәр җирдә туктаталар да, ул бик кечкенә берәр тимер юл станциясе була инде, тавышсыз-тынсыз гына алып чыгып тезәләр. Әйдә, безне йөгертергә! Үзебез ясаган вагон сәндәрәсендә көне буена ятып ялыккан халык — ничә километр булса да йөгерә инде, малай. Шуннан Смоленскида ун көн чамасы тордык. Аннан походным порядком, анысы җәяүләп дигән сүз була инде, Брест крепостена алып киттеләр. Тик эченә кереп, дүрт кенә көн тордык. Брест каласыннан утыз биш чакрым җирдәге лагерьга алып киттеләр. Анда ике артиллерия полкы икән. Безне шуларга беркеттеләр. Яңа гына кар эреп беткән чак иде. Китте тренировка, китте пантон күперләр салырга өйрәнү. И-и, нәрсә генә эшләмәдек, малай. Артиллеристларныкы кебек бик шәп карабиннар бирделәр. Ашау шәп, өс бөтен...

Күрше артполкта Казан артыннан бер бик әйбәт егет бар иде. Арсланов Рәхим. Шимбә җитсә, саратски гармунын күтәрә дә килә бу. Ул уйный, мин сиңа әйти-им! Рәхимгә кадәр андый уйнаган кешене күргәнем булмады. «Сине биетергә килдем, Сабур дус, әйдә, бас»,— дип, сузып җибәрер иде...

— Сугыш башланасын белдегезме, Сабур, юкмы?

— Белдегезме дип, сизелә инде ул. Күршең төнлә утын кисса дә ишетелә бит. Монда да шул инде. Аннан, чикнең теге ягында яшәүче поляклар, белоруслар үзләренең бу яктагы туганнарына хәбәр иткәләделәр. Сугыш башланырга бер ун-унбиш көн кала, күршедәге белорус авылыннан биш гаилә, атлар җигеп, сыерларын арба артына тагып, әйберләрен төяп, Смоленск ягына чыгып киткән булганнар. Тик аларны арест ясап, паника кузгатып йөрисез дип, хөкем иткәннәр икән, диделәр.

Сабур, сөйләүдән туктап, уйланып торды. Аның күз алдыннан моннан биш ел элек булган вакыйгалар үтә иде...

— Сугыш башланган иртәне артиллериядән аткан тавышка уянып киттек. Тиз-тиз киенеп, казармалардан йөгерешеп чыктык. Без яшәгән казарма белән артиллеристларның пушкалары торган парк арасы бер чакрым тирәсе булыр. Шунда бара торган җирдә кара болыт булып немец снарядлары шартлый. Чыккан шәпкә каушатты. Андыйны күргән юк бит. Шулчак янымнан гына берәү йөгереп үтеп китте. Үзе кычкыра бу: «Әйдә, шәбрәк йөгер, Сабур, нәрсәгә иелеп, куркып торасың?» — ди. Карасам, теге Казан арты Рәхим. Аркасында гармуны, бер кулында карабины, икенчесендә — бер ящик патрон. И-их, йөгерә бу! Мин дә моның артыннан. Бик ерак та түгел иде әле, булса бер илле метр киткәндер. Шул йөгергән уңайга абынып кына егылды кебек. Туктап, башын күтәреп карыйм дисәм — маңгае, йөзе тоташы белән юк моның. Шартлаган снарядның зур кыйпылчыгы тигән, күрәсең. Элекке кичне генә килгән иде. «Ун көнгә ял бирделәр, иртәгә кичен, Бресттан утырып, Мәскәү аша Казанга китәм»,— дип сөйләнде. Менә бит язмыш дигәнең...

Шуннан үзебезнең рота старшинасы йөгертеп алып китте. Казарма алдындагы мәйданны үтеп, паркка якынлаша башлаган идек, тотындылар пулеметлардан сиптерергә! «Ура» кычкырып, тегеләргә

каршы ике рәт күтәрелеп карадык. Юк. Алдырып булмый. Безнең часовойларны юк итеп, пулеметларын утыртып өлгергәннәр иде, күрәсең. Күтәрелә башлаган көйгә, үлән еккан кебек кыралар егетләрне. Ул да түгел, безнең уң флангтан унлап мотоциклда башларына мөгезле каска кигән немецлар килеп чыкты. Килеп тә чыктылар, мотоциклларыннан төшмәстән безгә ут ачтылар. Пулеметларын мотоциклга көйләгәннәр. Барган шәпкә генә сиптерәләр. Сарык көтүе кебек өереп кыралар инде, малай. Шул чакта, әле дә ярый, теге старшина булды. Бер-бер артлы ике гранатаны алып тегеләргә җилләде дә кире якка торып йөгерде. Мин моның артыннан. Туктаусыз берәр сәгать йөгергәнбездер. Шуннан бер сазлык җиргә барып тәртелдек. Барысы унике кеше җыелганбыз. Карасак, старшинаның уң колагы юк, пәке белән кисеп алган кебек. Ничек җитте шулай күлмәк ертып, бәйләдек моны. Шулай булды безгә сугыш башлануы...

Сабур, әрнүле күзләрен Хәбиргә төбәп, озак кына сүзсез утырды. Табын тын, самавыр борынынннан стаканга чупылдап тамган тамчы гына үтеп барган вакытны саныйдыр кебек иде. Сабур дәвам итте:

— Кая барырга? Нәрсә эшләргә? Сугышмы бу, түгелме?

«Атарга!»— дигән боерык та булмады бит әле безгә. Без каян гына белик инде андый зур эшләрне?!

Шуннан үзебезнең старшина, аз гына туктап хәл алгач, барыбызны да тезде. Алтыбыз пантонный батальоннан, калганнарыбыз — артиллеристлар. Корал барыбызда да бар икән. Кайберәүләребезнең гимнастеркалары юк, ә бер артиллеристның итекләре. Яланаяк бу. Зур, таза гәүдәле рус егете. Бөтен нәрсәсе урынында. Гимнастерка, чалбар, бил каешы. Каешына ап-ак чолгаулар кыстырган бу. Пилоткасын кигән, карабинын аскан, патронташын алган. Икенче кулында — зур тимер тартма. Шуннан старшина, азрак карап торды да тегенәргә, сорый:

— Фамилиягез ничек? Итегегез кайда? Сафтан чыгыгыз!

Бик исе китми генә чыгып басты бу кеше саф алдына. Старшина сораганга да кабаланмыйча, тыныч кына җавап бирде:

— Кызылармеец Прошкин Александр Иванович. 1921 елны туганмын. Артиллерист-наводчик. Старшина кичен, барлаганнан соң, итекләремне полк мастерскоена ремонтка илттерде.

— Алмашка бирмәделәрмени?

— Юк шул. Аяк зур минем. Ротада минем кебек зур аяклы кеше юк.

Сафта торганнар Прошкинның аягына карадылар. Аның агач тамырларына бәрелеп, сыдырылып беткән аяклары, чыннан да, яман зур иде.

Старшина кызылармеецның зур, әмма җыйнак гәүдәсенә карап, елмаюын мыегы астына яшерде:

— Ничәнче размер киясең?

— Кырык алты, иптәш старшина.

— Ярар! Минем итек запасым юк. Хәзер Россия язмышы хәл итела. Тапсаң табасың, тапмасаң, яланаяк сугышасың инде.

— Есть!

— Тартмаңда гранаталармы!

— Әйе, гранаталар.

Старшина, алдында торган сафка бик җентекләп карады да, азрак тотлыга биреп, сүз башлады:

— Иптәш кызылармеецлар! Сезнең арагызда дәрәҗә ягыннан да, яшь ягыннан да мин иң зуры. Сезнең өстән командалыкны һәм бөтен җаваплылыкны үз өстемә алам. Кайда гына нинди хәлдә күрсәгез дә, сезнең бурыч — фашистны үтерү, бетерү, юк итү. Мин немец белән үткән сугышта ук көрәшкән кеше. Бик тә әшәке, хә-

шәрәт алар фашистлар. Хәзер без, барлык коралны барлап, дошманга каршы каты сугыш ачарга тиешбез. Артиллеристлар да, пантончылар да, үзебезнең зур командирларга барып җитешкәнче, пехота булып сугышачакбыз. Карабиннарыгызны карап, тикшереп чыгыгыз. Патроннарны санагач, миңа доклад бирерсез. Прошкин!

— Мин! Иптәш старшина!

— Итексез булсаң да, мин сезне, паникага бирелмичә бер тартма граната күтәреп йөгергәнегез өчен, үземнең ярдәмчем итеп билгелим.

— Есть!

— Гранаталарны кызылармеецларга таратып бир. Запалларын куйсыннар! Карабиннарны корыгыз! Унбиш минуттан солдатларны сафка тезегез!

— Есть!

Мин дә башкалар эшләгәнне эшләдем. Иң элек карабинны подсумоктан алган майлы чүпрәк белән сөртеп чыктым. Подсумокта биш обойма — егерме биш патрон бар. Шуның өстенә Прошкин миңа ике кул гранатасы бирде. Коралларны карап, җайлап бетергәч, старшина безне тезеп барлады. Прошкин, фамилияләрне, исемнәрне язып, исемлек төзеде. Аннан старшина безгә мөрәҗәгать итеп әйтте:

— Улларым! Бу сугыш тиз генә бетә торган түгел. Хәзерге көннәрдә ил язмышы хәл ителәчәк. Шуңа күрә һәрберебез соңгы тамчы канына кадәр ил өчен, халкыбыз өчен, иптәш Сталин өчен сугышырга хәзер булсын. Канга — кан, үлемгә — үлем!

Без, үзебезнекеләрне эзләп китәр алдыннан, юлга чыгып карарга булдык — Прошкин бер кызылармеец белән разведкага барып килде. Тик аның сөйләгәне башка сыймый иде:

— Юл — фашистлар техникасы белән туп-тулы. Танклар, автомашиналар, бронетранспортерлар — барысы да көнчыгышка бара. Машина тулы солдатлар. Машиналарның өсләре ачык. Ашыйлар, эчәләр, го-го-го килеп көләләр...

Прошкин, нәрсәдер әйтеп бетерергә кыймыйча, сораулы күзләрен старшинага текәде дә туктап калды. Старшина, тирә-ягында тавыш-тынсыз тыңлаучы кызылармеецларга күз йөртеп алды да, әйтте:

— Барысын да сөйләгез!

— Чалбарларын салып, оят җирләрен урманга күрсәтәләр дә: «Русс капут, Сталин капут»,— дип, кычкырып көләләр. Үзләре, барган уңайга урман эченә пачкалап листовкалар очыралар.

— Кая, нинди листовка?

— Юк, мин алмадым.

— Нигә?

— Ничектер җирәнгеч! Ул листовкаларда алар безне сугышмыйча бирелергә өндиләр.

— Ярар, Прошкин, рәхмәт.

Старшина, тиз генә аның йөзенә карап алды да, азрак елмаеп:

— Итекләре ничек фашистларның, итекләре, Прошкин?— диде.

Прошкинның күзләрендә ачу утлары күренде:

— Итекләре шә-әп! Калын табанлы, киң, кыска кунычлы. Итек кунычына әллә нинди озын таяклар тыкканнар.

— Таяклар түгел ул, Прошкин, кул гранаталары. Ярар, хәзер без, тыныч берәр урын табып, үзебезгә привал кебек нәрсә ясыйк. Аннан соң үзем барып карыйм әле мин ул кеше икмәген ярат учыларны...

Сабур, байтак кына дәшми утырды да, авыр сулап куйды...

— Ике көн үткәч, шул унике кешедән икәүебез тере калдык. Кояш батып бара иде. Бер үрле җирдә, юл борылып машиналарның тизлеге әкренәйгән урында, засадага яттык. Башта байтак машиналарны тимичә үткәрдек. Чөнки солдатлары күп, ә безнең көч җи-

тәрлек түгел. Таң атып килгән вакыттарак, ике мотоцикл артыннан килгән җиңел автомобильгә һөҗүм иттек. Тик абайламый калганбыз: йөз-йөз илле метрлар чамасы артта, шул машинаны саклап, немец солдатлары белән тагын бер тимер машина килә икән. Барысында да автомат, җитмәсә, пулеметтан да аталар. Без дә тик ятмыйбыз. Бераздан теге җиңел машина яна башлады. Эчендәгеләр берсе дә чыкмады шикелле. Менә шушы җирдә безне, уратып алып, юк итәргә тотындылар. Урман эченә ыргылып карадык — немецлар. Юлда — немецлар. Юлның икенче ягына ташландык — немецлар. Курыкканга куш күренә дигәндәй, урман эче тулы немец солдаты инде менә! Чигенә-чигенә, икәү генә торып калганбыз. Атыш тынып, берәр сәгать тирәсе вакыт үткәч, киттем теге сугыш булган җиргә. Иптәшләрне теткәләп салганнар. Старшина да бер агач төбендә ята. Прошкинны исә зур юан наратка бәйләп атканнар. Агачка бәйләгәннәр дә, такта белән шуңа «Нах Москау» дип язганнар. Барысын да җирли алмадым. Шулай да старшина белән Прошкинны урман эченә өстерәп алып кердем. Кабер сыманрак чокыр казып, икесен бергә күмдем.

Өй эче тын. Шул тынлыкта самавыр борыныннан тамган тамчы тавышы һәм Шәрифә әбинең пышылдап: «Әй аллам, мәрхәмәтләреңнән ташлама!»— дигән ялваруы гына ишетелеп куйгалый.

— Шул китүдән киттем берүзем. Ашарга юк. Ни барысы өч патрон калган. Нишләргә? Юл тулы немец танклары-машиналары. Авыллар тулы шуларның солдатлары... Дүрт көн үткәч, атлар белән ике пушка өстерәгән артиллеристларга туры килдем! Командирлары, бер капитан, мине алмаска әйтә. Куа, кит, ди. Унлап кеше болар, ашарларына да бар, тик бер генә снарядлары да юк. Калмыйм болардан, иярүем иярү. Теге капитан пистолетын чыгара башлады. «Ат,— мин әйтәм,— ат менә монда!» — дип маңгайга күрсәтәм. Азрак уйлап торды да, пистолетын кире кабурына тыкты бу. Шуннан минем карабинны алып карады. Карабин ялт итеп тора, өч патроны да бар. Шуннан ияртteләр. Үзләре белән алырга теләмәүнең сәбәбе дә булган икән. Ике кызылармеец кушылган боларга, чигенгән вакытта. Төнлә нишләгәннәр? Ике атының корсагына штык кадап качканнар. Диверсант яисә, сатлык җан булганнар, күрәсең... Чигенә торгач, Днепр елгасына килеп җиттек. Кичкырын, уннан артык яхшы гына карагайларны аударып, пушкаларга ике сал ясадык. Төнлә белән елганы кичәргә тотындык. Атлар — йөзеп, үзебез теге салларда тавыш-тынсыз гына киттек, малай, су агышы белән. Кемдә нәрсә бар, шуның белән ишәбез суны. Капитан кая барырга икәнне яхшы белә — сугыш алды елларында шушы җирләрдә маневрларда катнашкан икән. Ул-бу булмады. Таң алдыннан кичеп чыктык елганы. Икенче пушканы ярга чыгарып, капитан янына җыйналдык. Шулчак, таң караңгылыгын ярып, яр буендагы куаклыктан электр фаралары кабынды. Немецчә боерык ишетелде:

— Ауфштецн! Һинде һох![1]

Егермеләп немец солдаты, автоматларын юеш киемле кызылармеецларга төзәгән килеш, аларны Днепр суына кысып, коралсызландырды. Офицерлары, пушкаларның төзеклеген карап чыкты да, җайлап кына йөреп, безне күзәтә башлады. Бер сафка тезеп куйдылар болар безне. Билдән каешларны чишеп, читкә ыргыттылар. Шуннан немец офицеры, безнең алга басып, русчаны ватып-җимереп сөйли башлады:

— Без, Германия армиясе, бөек фюрер Адольф Гитлер тарафыннан монда тәртип урнаштырырга һәм сезнең армиягезне юк итәргә җибәрелдек. Менә ике көн инде, сезнең чигенгән солдатларыгызны

[1] Урыныгызда торыгыз! Кулыгызны күтәрегез!

шушы елга кичүендә тотып, әсирлеккә җыябыз. Ә хәзер без сезне сортларга аерабыз. Коммунистлар һәм жидлар ике адым алга!

Сафтан чыгучы булмады.

Офицер, гәүдәсенең авырлыгын итек үкчәсеннән башына күчереп берничә тапкыр хәрәкәт ясап алды да, сафның уң ягында басып торган капитан-артиллеристка таба атлады.

— Син, капитан, ни өчен сафтан чыкмыйсың? Әллә коммунист түгелме?

Капитанның битендә бер генә мускулы да селкенмәде:

— Коммунист мин!

— Шулай булгач, нигә кыймылдамыйсың? Куркасыңмы?

— Мин беркайчан да, бер кемнән дә курыкмадым.

— Алайса, нигә сафтан чыкмыйсың?

— Чөнки мин үзебезнең командование боерыкларын гына үтәргә өйрәнгән кеше.

— Ә безнең боерык синең өчен закон түгелме?

— Түгел! Мин сезнең фашизм белән соңгы тамчы каныма кадәр...

Немец офицеры, кизәнми-нитми генә, кара перчатка кигән уң кулы белән артиллеристның эченә китереп сукты. Сугу кыска һәм каты иде. Капитан, сугудан урталай бөгелеп, чайкала төшеп, көчкә аяк өстендә кала алды.

— Рус чучкасы! Белеп тор немец офицеры кулын...

Чайкалып торган капитан, ачуы йөзенә чыккан фашисттан күзләрен алмыйча, турая башлады. Яртылаш калкынган гәүдәсен кискен рәвештә турайтып, йодрыклаган уң кулы белән немец офицерының ияк астына тондырды:

— Менә шулай сугалар аны!

Немецнең тешләре тешкә бәрелеп шыкырдады. Үзе, җиңел туп кебек очып, мәтәлеп, яр комына барып төште. Шулчак өч немец солдаты, безнең капитанны аяктан егып, яр комында тәгәрәтеп, типкәли башладылар. Капитанга ярдәмгә ташланган ике артиллерист автомат утыннан җиргә аудылар.

Авызыннан аккан канны кулъяулыгы белән сөртә-сөртә аягына баскан офицер, бераз вакыт капитанны типкәләгәнне карап торгач, әмер бирде:

— Хальт![1]

Өч солдат, теләр-теләмәс кенә, талап бетерә алмаган этләрне хәтерләтеп, комда бөгәрләнеп яткан гәүдә яныннан читкәрәк китеп, аңарга автоматларын төзәп бастылар. Капитан зур авырлык белән генә тора башлады. Яр комына манчылган, дулкынланып тора торган кара чәчләрен сул кулы белән артка сыпырды да бергә басып торган кызылармеецлар төркеменә карап атлады.

— Хальт!

Немец офицеры капитанның юлына аркылы төште:

— Синең тормышың шушында бетәчәк. Әнә теге якка атла! Офицер, сул кулын сузып, яр читенә табан күрсәтте.

Капитан, үзенә якын килә башлаган ике автоматлы солдатка карап та тормыйча, кызылармеецлары белән хушлашты.

— Җиңүебезне күрергә насыйп булсын сезгә! Хушыгыз, иптәшләр!

Яр буенда капитанны аттылар.

Шуннан безне тагын тезеп барладылар. Бәйләнде бит миңа шунда теге немец офицеры. Карап торды-торды да, мине яһүд диде. Юк, мин әйтәм, татар мин, яһүд түгелмен, дим. Ул әйтә, нигә чәчең кызыл, нигә аякларың кәкре түгел, нигә күзең кысык түгел, ди. Аттыра

---

[1] Тукта!

инде дип торам. Тотындым моңарга татарчалап, тозлап-борычлап сөйләргә. Тыңлап-тыңлап торды да, башкача миңа бәйләнмәде бу.

Шуннан безне парлап тезделәр дә якындагы авылга алып киттеләр. Өйләгә кадәр шул авылның урамында утырдык. Ярты көн эчендә илледән артык кеше җыйды болар. Китереп торалар гына безнең халыкны. Кемнәр генә юк араларында. Командирларны килгән көенә аерып алалар да исемлек төзиләр. Шуннан бер утыз чакрымнар булыр, куып бәрәңге басуына китереп җиткерделәр. Анда чәнечкеле тимерчыбык белән уратылып алынган бер урын. Дүрт почмагында биек итеп агачтан ясалган каланча кебек дүрт нәрсә, башында пулеметлар белән икешәр немец солдаты. Атна буена җыйдылар безнең халыкны. Көненә егерме кешегә бер чиләк су. Ашарга бирү юк. Теге бәрәңге басуын кул белән казып, бәрәңгесен, сабагын, бөтен үскән үләнен, алабутасын — барысын да ашап бетердек. Чәнечкеле чыбык аша кулларны сузып, буй җиткән кадәр, андагы үләнне дә ашап бетердек. Бер егермеләп булыр, үзебезнең армиядә медперсонал булып хезмәт иткән хатын-кызлар да пленга эләккән. Аларга безгә караганда да кыен. Фашист солдатлары, тартынып-нитеп тормый, тоталар да мәсхәрә итәләр. Штыклары белән тәннәренең төрле җирләренә төртәләр, чәнчәләр. Үзләре шырык-шырык көләләр — кызык, янәсе. И-их, малай! Кеше үтерүне чебен урынына да күрми икән фашист...

Сабурның йөзе җитди. Ул кабаланмый гына үткән елларның истәлекләрен сүтә...

Шул бәрәңге басуында атнадан артык вакыт үткәч, ачтан сусаудан үләр дәрәҗәгә җиткән Сабур, аллага тапшырып, тәвәккәллек итә. Ике иптәше белән бергә яткан чокырдан чыгып, башына пычрак чүпрәкләр бәйли дә әйтә:

— Аркадий! Мин табышка чыгып карыйм әле. Ни булса, шул булыр. Кире әйләнеп килмәсәм, хушыгыз.

Алда, каралы-аклы шлагбаум янында басып торган, автомат тоткан ике немец солдаты, үзләренә якынлашып килгән Сабурга — котсыз карачкыга, бернинди кызыксынусыз карыйлар. Алар бу шлагбаум янына килгән рус солдатларын берничә тапкыр күрделәр. Әнә, соңгы икесенең атылган гәүдәләре кичкелеккә авышкан кояш астында, әле дә булса ята. Тагын берәү килә икән, әйдә, килә бирсен...

Немец күкрәгендәге автоматын аның эченәрәк каратып бора башлагач, Сабур тукталды. Туктала да уң кулын азрак һавада күтәрә бирәп әйтә:

— Аен момент! Их зинген, ейне зинген. Их зинген...[1]

Сабур, тырышып-тырышып, немец теле укытучы Сыртланов абыйсы өйрәткән сүзләрне исенә төшерә:

— Их гут зинген! Я, я гут зинген! Айн момент! Их зинген!...[2]

Солдатларның шлагбаум бавын тотып торганы җирдә яткан кыр телефонының тоткасын бора:

— Герр лейтенант![3].

Эседән ялыккан икенче солдат, автоматын әзер тоткан килеш, Сабурны әйләнеп урап чыга, аның үкчәләре тапталып беткән итеген алып кызыл чәченә ураган чүпрәгенә кадәр ялкау гына күз йөртә дә иптәшенең мавыгып телефоннан сөйләшүен тыңлый башлый:

— Я, я, гер лейтенант! Яволь, герр лейтенант![4].

Немец солдаты, телефон трубкасын урынына куя да, Сабурга дәшә: — Ауфштейн!![5].

---

[1] Бер секунд! Мин бер җыр җырлыйм!
[2] Мин яхшы җырлыйм. Әйе, яхшы җырлыйм. Бер секунд! Җырлыйм!
[3] Лейтенант әфәнде!
[4] Әйе, лейтенант әфәнде! Тыңлыйм!
[5] Басып тор!

Шлагбаумнан ерак булмаган зур чатырдан, пистолет кобурасы тагылган каешын биленә буа-буа, немец лейтенанты һәм тагын дүрт солдат күренделәр. Лейтенант, килеп җитүгә, Сабурга текәлеп карый да бер генә сүз әйтә:

— Битте! [1].

Шуны гына көткән Сабур эсседә әлсерәгән әтәч канатларын хәтерләтеп, ике кулын азрак салындырып, читкә җәеп җибәрә дә бер аягында азрак аксый биреп, түгәрәк ясап атлап китә. Җиде немец, цирк карарга җыйналган кыяфәт белән, Сабурны уратып алалар. Алар бу совет солдатының нәрсә эшләргә теләвен әле белмиләр, тик лейтенантының аны моннан тере көенә җибәрмәячәген яхшы аңлыйлар. Чөнки командирларының принцибы шундый: совет кешесе немец солдатыннан (Россияне яулап алучыдан!) берәр нәрсә сораса, бу юньлегә түгел. Шуңа күрә ул юк ителергә тиеш! Аның шулай икәнлеге исбат ителгән шлагбаум янына үзләре белән кешечә мөрәҗәгать итүне сорап килгәннәрнең барысы да, үзләренә тиешле кургашынны алып, җирдә череп яталар әнә.

Сабур, кабаланмый гына, ут күзләрен җирән керфекләре астына яшерергә тырышып, аксый-туксый немецлар уратып алган түгәрәкне ике тапкыр урап чыга да урталыкта туктый. Туктый да, әлсерәп йөдәгән карт әтәчне хәтерләтеп, карлыккан тавыш белән кычкырып җибәрә:

— Ки-и-ке-ри-кү-үк!

Аннан соң, җирән башын уң кул башына салып, азрак басып тора. Тагын әтәч моңын бирә:

— Ки-и-ке-ри-и-ику-үк!

Тукталган җиреннән, гаҗәпләнеп, тирә-ягына тиз-тиз карап ала да, арлы-бирле килеп, түгәрәк эчендә йөгергәләп, югалган тавыкларын эзләгән әтәчне сурәтләп әйләнә башлый. Солдатлар арасыннан берсе кыска гына итеп көлеп куя. Шуны гына көткән Сабур, солдатлар арасыннан зур, симез немецны сайлап ала да, башын әле бер якка, әле икенче якка бора-бора, аяк очларына гына басып, тамагыннан: «ко-ко-ко»,— дигән сугышчан аваз чыгарып, аңа якынлаша. Кулына ярыйсы гына колбаса кисәге тоткан солдат Сабурны күрми дә диярлек, үзенең күшәвен белә. Гәүдәсенең зурлыгы, симезлеге белән башкаларыннан аерылып торгангамы, немец солдатларына көлү өчен җай чыга, ахрысы. Сабур аңа якынлаша башлау белән, барысы да гөрелдәтеп көлеп җибәрә. Теге симезе генә, бер нәрсәгә дә исе китмичә, чәйнәвендә икән. Ә Сабур үзенекен итә. Солдатка ике-өч адым кала туктап, бер урында таптанып, дошманын сугышырга чакырган, тик үзе аңардан бераз шүрләгән җирән әтәчне хәтерләтеп, кәдрәеп-кәдрәеп кабатлый:

— Ко-ко-ко! Кы-кы-гы-гы-ко!

Юан солдатка да азрак кызык була башлый, ахрысы, ул алдыннан кәдрәеп бөтерелгән Сабурга азрак аптыраган хәлдә карап тора да, кискен хәрәкәт ясап, уң аягын кинәт кенә күтәреп җиргә шап итеп тибә:

— Бег! [2]

Көтелмәгән бу хәрәкәттән Сабур, ике кулын һавада селки-селки артка сикерә дә, түгәрәк буйлап йөгереп китә. Аның бөтен гәүдәсендә тавыкларын югалтып, ятим калган әтәчнең өметсезлеге сизелеп тора:

— Ко-ко-ко-ко-о-о!

Немец солдатлары гөрләп көлешә. Берничәсе хәтта кул да чаба. Сабур шул мизгелдә, йөгереп килгән җиреннән азрак һавага сикерә

[1] Рәхим итегез!
[2] Кит моннан!

дә. Кытыйка исеме алган елларын хәтерләтеп, түгәрәк уртасында туктап, ике кулын да җилпеп канат кага:

— Кыттый-кыттый, кытыйка-а-а!

Немец солдатлары әтәч булып кыланган Сабурдан күзләрен алмый. Ә Сабур, эчендәге әллә нинди кадерле җепләрен өзгәләп, еракта калган, Урал тауларының итәгенә урнашкан туган авылының тузанлы урамнарын күз алдына китереп, җырлый-җырлый биергә тотына:

Кыттый-кыттый-кыттыйка,
Кыттый белән Сытыйка-а...

Заманында үзен юк-бар белән җәберләгән, хәзер аның өчен кадерле истәлеккә әверелгән авылы кешеләрен Сабур үзе чыгарган җыры белән, якты истәлек итеп, җырлап искә ала. Җырдагы Миңнегали хәзер инде аның өчен җонлы Гали түгел, ә кадерле Миңлегали абыйсы, Гыйльметдин дә, арада иң котсыз кеше булмыйча, дөньядагы иң сөйкемле кешегә әверелгәнен Кытыйка Сабур бик яхшы аңлый. Яхшы күңелле, гадел, уңган кешеләр яшәгән икән аның туган авылында! Ә адәм актыклары, кеше исеме күтәреп йөргән сасы көзәннәр, менә алар — Сабурны уратып алганнар.

Ә Сабурга ничек булса да бер генә кисәк икмәк, бер генә йотым су табарга кирәк. Сабурның йөрәге ярылырга җитеп ярсыган. Күк йөзен урталай ярып, әче итеп кычкырасы килә аның. Ә ул көлә, җырлый, бии, бу хәшәрәтләргә әтәч кәмите күрсәтә. Чөнки Сабурга илен сатмыйча тере калырга, җәрәхәтле иптәшләрен аякка бастырырга кирәк!

Биеп бетергәч, тузанга буялган битеннән, муеныннан аккан тирен дә сөртмичә, немец офицеры янына килеп туктый ул.

— Гут! Зеер гу-ут![1] — ди немец, сузып. Алдында хәлсезләнеп, тирләп-кызарып басып торган Сабурга төссез күзләре белән карап тора да иренеп кенә өстәп куя:

— Нох ейнмал![2]

Авылда, мәктәптә укып йөргәндә, Сабур — немец теле укытучысы Сыртлановның иң яраткан укучысы булды. Сабурга немец теле ошый иде, ул аны теләп укый иде...

Арыган аякларын кузгатып, Сабур тагын биеп-җырлый. Ул туктауга, немец офицеры иренеп кенә, тагын кабатлый:

— Нох ейнмал!

Сабур тавыш-тынсыз басып торуын дәвам итә. Лейтенантның күзләрендә салкын ялтырау күренеп китә. Ул пистолет кобурасын чишә башлый һәм кычкырмыйча гына сүзләрен теш арасыннан сыгып чыгара:

— Нох ейнмал!

Көлүдән кызарып бүртенгән немец солдатлары уртасында Сабур тагын биеп җырлый. Шулай итеп, немец уенны өч тапкыр кабатлатып, түгәрәк уртасында хәле-тыны бетеп, аягында көчкә басып торган Сабур янына килә. Җирән сакал-мыек баскан биюченең битмуеныннан, юл-юл эзләр калдырып, кара тир ага, күзләрендә җан газабыннан кабынган ут яна. Немец офицеры саф рус телендә сорау бирә:

— Нәрсә теләп килдең?

— Су, икмәк...

— Бездә тоткыннарга бирә торган азык юк. Тагын килсәң, тере килеш китмәссең! Ә хәзер — марш!

---

[1] Яхшы! Бик яхшы!

[2] Тагын бер мәртәбә!

Чатан Хәбир авыр сулап, уфылдап куя. Сугыш башланганнан бирле аракы эчмәгәнлектән, кызарып-алсуланган йөзе, ялтыраган күзләре Сабурга юнәлгән:

Син, Сабур энем, сугышның башыннан азагына хәтле күрдең бит инде шул плин җәфасын. Ничек түзмәк кирәк шундый хурлыкка?

Аның, Сабирга яхшы сүз әйтеп, авылдашының арыган-талчыккан җанын юатасы килә иде.

— Башыңа төшсә, түзәсең икән шул, Хәбир абзый, түзәсең!

— Германиядә булдыңмы, Сабур?

— Булдым, булдым, анда да булдым... Кырык өченең көзенә хәтле Проскуров дигән кала янында аэродром төзеттерделәр. Нык эшләттеләр. Ашау ягы юк иде. Теге чөгендер суы да, тагын әллә нинди ботка. Кыйнаулар да булды, тик бик җәфаладылар дип тә әйтеп булмый. Чөнки без утыз алты гына кеше идек. Эш күп. Шуңа да бик тимәделәр шикелле. Аннан, 1943 елның көзендә, безнекеләр Киев каласын алгач, бер төн эчендә эвакуация ясап, бөтен аэродромны Германиягә озаттылар. Ну анда күрдек инде күрмәгәнне! Араларында Матхаузен белән Кведленбург дигән концлагерьлар бик әшәке булды. Германиянең үзендә тәртип бар барын. Шәһәрләре чиста. Урманнарына керсәң, җирдә бер ботак та күрмәссең. Агачларына нумер суккannar. Шул ике концлагерьда елга якын тордым. Ашау юк диярлек. Алып киенәсең инде үлгән иптәшләреңнекен, кая барасың. Миңа үземнең җирәнлек тә ярдәм иткәләде шикелле. Ни өчен дисәң, алар арасында да күп икән җирән халык. Кухня тирәсенә эшкә җибәргәләделәр, бәрәңге тазартырга, утын ярырга, күмер ташырга куштылар. Лагерь охранасының кухнясы аерым. Солдатлар күрмәгәндә, бер карт немка ашаткалады. Әгәр солдатлар күреп калсалар, нык итеп кыйныйлар иде. Хелман дигән бер ефрейтор бар иде. Тикторганда, арттан килеп, уң аягы белән кешенең җилкәсенә тибә торган иде, спортсмен, янәсе. Шул типсә, яртышар сәгать ушыңны җыялмый ятасың инде менә...

Табындагылар тавыш-тынсыз гына Сабурны тыңлыйлар. Алар алдында авыл кешеләренә җыр чыгарып, биеп, бишәр тиен акча, кәнфит җыеп тәм тапкан Сабур түгел, ә күп нужалар күреп, егерме биш яшеннән маңгае җыерчыкланган, кызыл чәчләрен агартып кайткан ир утыра...

— Шулай, кырык дүртнең сентябрь башында бер алпавыт немец хатыны сатып алды безне концлагерьдан,— дип дәвам итә ул.— Өйлә җитәрәк, безне эштән алып кайтып киләләр иде, бер ат җиккән фаэтонда килеп төште бу. Ну, атлары шәп инде! Карап торышка әлләниләр бирерсең. Тик хайваннарны, ямьсезләп, ялларын һәм коерыкларын кискәннәр. Аппелплац дигән җиргә тезделәр безне. Концлагерь начальнигы эс-эс майоры иде. Шул тылмач аркылы әйтә, кем җир эшен белә, сафтан чыгыгыз, ди. Ишәүдән, якты кояштан туеп, чигенә барып җиткән идек инде. Кыш та җитәргә тора. Үзем арык, өстәвенә йөткерә башладым. Шуңардан да начар булмас, дидем дә чыктым саф алдына. Бу хатын үзе чалбар-галифе кигән. Кулында озын саплы чыбыркы кебек бер нәрсә. Шуның сабы белән минем иякне күтәреп карады, очы белән корсакка төртте дә «гу-ут» дип сузды. Минем белән бергә санаганда, унсигез кеше алды бу сатып. Барысы да крестьян балалары булып чыктылар. Тезделәр дә, концлагерьдан алып чыгып, йөк машинасына утырттылар. Ике автоматчы сагы астында алып та киттеләр. Үз машинасы икән бу монынң. Бик бай хуҗа булып чыкты. Ире Африкада сугышта үлеп калган, үз хуҗалыгы янындагы зиратка алып кайтып күмгәннәр. Атна саен бара бу иренең каберенә. Март аена кадәр шушы хуҗалыкта эшләдек.

Баштарак ике ат җиккән бричка белән йөрдем. Аннан ат белән

җир сөрдем, тырмаладым, чәчтем. Крестьян эше кайда да бер инде — тузан, пычрак, тирес. Ат, сыер абзарлары артында бетонлаган өч зур чокыр моның. Бер чокырын тирес белән тутырта да, аннан соң өч ел буе янып ята теге. Өч ел үткәч, яланга түктертә. Бездә генә ул кыш үтүгә, авыл очына чыгарабыз да очырабыз. Аларда алай итү юк икән. Әгәр станция янындагы складларга иген илтсәң, бер брезент капчык биреп җибәрәләр. Шуңа юл уңаенда атлары төшергән тизәкне тутырып алып кайтасың. Кайткач, тикшерәләр әле: алып кайттыңмы, юкмы, янәсе. Атлар үзләре шундый чакта туктый. Өйрәтелгәннәр.

Сәкедә утырган Тимеркәй шаркылдап көлеп җибәрде:

— Безнең зират каршындагы тиреслектән дә килеп төяп алсыннар, әнә күпме анда.

Башкалар да елмайды. Һәм, тагын да бирелеп, Сабурны тыңлый башладылар.

— Менә шунда эшләдем мин. Шунда азрак хәл алып тазардым. Ютәлләү дә бетте. Колынлы өч биясе иде хуҗаның. Шуларны савып, кымыз ясадым. Үзем теләп керәм асларын тазартырга. Шул атлар тирәсендә йөргән Иохим исемле, сыңар куллы бер карт немец бар иде. Шул ярдәмче кеше булды. Көн дә диярлек, дәшми-тынмый гына, минем куенга бер бутерброд тыгып китә бу.

— Анысы нәрсә тагын?

— Ипи белән колбаса, яисә сыр кыстырып куелган ипи. Бутерброд — үзе майлы ипи дигән сүз. Серне беркем дә белмәде: эчтем, тәүдә кымыз итеп эчтем. Ну, ике немец шул мин ясаган кымызны таптылар. Иснәп, кабып карадылар, лач итеп түкерделәр. Бия сөте икәнен белмәделәр, ахры, алай да, кыйнадылар. Шуннан соң сөтне сауган шапкә эчә башладым. Шул терелтте булса кирәк.

Ә качуын март аенда, бодай чәчкәндә качтым мин аннан. Бәләкәй генә иген чәчкечләрдә эшли идем. Атларны кичкәрәк калып тугардым да, берсен менеп, берсен җитәкләп, киттем туп тавышлары ишетелгән якка. Төне буе чаптым. Гел юлсыз. Сөргән җирдән атларны алмашлап менәм дә, әйдә куарга. Берәр сәгать баргач, ак күбеккә әйләнә тегеләрең. Таң ата башлагач, су буендагы сыек кына куаклыкка кереп яттым. Атларны бәйләп куйдым. Иртәнге якта, бер ярты чакрымнар ераклыкта булыр, унлап танк үтеп бара мин сиңәйтим. Немец танкларына охшамаган. Шулай, карый-карый, башняларындагы кызыл йолдызны күреп алдым бит. Үзем елыйм, үзем тегеләр артыннан чабам. Йөгереп кенә ничек танкны куып җитәсең инде? Кире борылып, артларыннан ат менеп җилдердем. Барып җиттем дә иң ахыргы танк белән кырдаш булып чаба башладым. Шуннан якынрак килдем дә аттан теге танк өстенә сикердем бит. Танкистларга приказ биргәннәр икән: өч юл бергә кушылган чатка чыгып, шуның аша чигенгән немец гаскәрләрен үткәрмәскә. Ундүрт сәгать сугыштык шул җирдә. Рәхәтләндем пулеметтан, автоматтан атып. Круговой оборона диләр андый сугышны. Шул юл чатын уртада калдырып, ун танкны, пушкаларны төрле якка каратып куйдылар. Бик яшь бер подполковник командалык итә болар белән. Танклар юлдан килгән немецлар колоннасына ата да башладылар. Кырык бишенче елгы немец солдаты сугыш башындагы солдат түгел инде ул. Техникаларын, машиналарын ташлыйлар да кайсысы кая йөгерәләр. Өйләдән соң тагы бер зур колонна килеп чыкты. Тик без окоплар казып, әзерләнеп өлгергән идек инде. Механик-водительләр белән бергә мин дә катнаштым. Сугыш азагында булса да, үчемне алдым, әз булса да ачуымны бастым. Нык тордык шул җирдә. Төнлә белән үзебезнекеләр килеп җитте. Башта коляскалы ике мотоцикл белән тегеләрнең разведчиклары килде, аннан безнекеләр. Бер зур дәрәҗәдәге генерал кочаклап үк үпте теге яшь подполковникны...

Икенче көнне мине, ике автоматчик уртасына утыртып, бер капитан алып китте. Бик нык сорашты. Сөйләгәннәрне язып алды.

Сугыш беткәч, дивизиядән өч йөз кеше булыр, җыйдылар безне. Гел теге плен булган, Кызыл Армиягә Германиядә кушылган халык. Ун көн тирәсе үтүгә, сак куйдылар да, вагоннарга төяп, Архангельск каласы янына, тайга кисәргә алып та киттеләр. Күпмегә алып киттеләр — әйтүче булмады. Шунда менә елдан артык урман кистек. Акча түләү юк. Ашау фәкыйрь булды. Әсир кеше — гаепле кеше, диделәр. Нишләмәк кирәк. Йөрәкне ярып күрсәтеп булмый...

Тайга эчендә эшләгән чакта берәмләп-берәмләп тә алып киткәләделәр. Теге сатлык Власов армиясендә сугышкан халык та булган икән безнең арада. Беләләр, табалар, әй, май аенда мине дә чакырдылар. Кулга документларны тоттырдылар да, бар, өеңә кайт, гаебең юк, диделәр. Менә, мин сезнең каршыда, туганнар, әни!

Шәрифә әби, улы кайтканнан бирле туктата алмаган яшьләрен юеш яулык очы белән сөрткәләп, телгә килә:

— Ишек шакый бит бераү, төнлә белән. Йөрәгем сизенде дисәм, бик үк дөрес булмас. Чыктым өй алдына да сорыйм: «Кем йөри бу вакытта»,— дим. «Мин»,— ди бит бераү. Йөрәккәем ярыла дип торам. Үзем ишек келәсен эзлим, үзем таба алмыйм. Тапкач, ача алмыйм. Шуннан соң, үзем елыйм, үзем сорыйм: «Әллә, Сабур улым, син инде»,— дим. Ишек ярыгыннан чыбык тыгып, үзе ачты ишекне. И-и түккән яшьләрем шушы балам өчен...

Тимеркәй әнисен юатып куйды:

— Ярар, елама инде, исән-сау кайткан — куанырга кирәк.

— Шулай, шулай. Шәрифә түти! Инде йортыңа хуҗа кайтты, иншалла, юнәлер дөньягыз. Сабур энем, сиңа да дөнья көтү турында, әнкәң турында кайгыртырга туры килер. Эш табарга кирәк.

— Безнең эш, колхоз, Хәбир абзый, колхоз. Пленда булганнарга юллар ябык хәзер. Сталин шулай дип әйткән, ди.

— Ябык дип инде, җилкәң булса, камыт табылыр ла ул. Бик йончыдык бит без дә монда ирләрсез. Гел бала-чага да карт-коры, хатын-кыз колхозда. Исән-сау кайткансың икән, аллага шөкер ит тә, эшкә тотын инде, Сабур энем.

— Шулай, Хәбир абзый! Шулай!

— Ярар, мин кайтыйм әле. Рәхмәт яусын сиеңа. Теге гарип аяк рәхәт итеп җылынып китте. Җиңгәңне аптыратам инде хәзер. Сөенче алам. Мин бит синең кайтканыңны кичтән үк белдем.

— Кит аннан! Ничек, каян белдең?

— Белдем инде, сер анысы. Йә, сау булыгыз!

## Яшь сунарчылар

Файзыр укуын бишенчедә йөргәндә, 1943 елда ук ташлаган иде. Шуннан соң укырга бар диючe дә, нигә йөрмисең дип, эзләп килүче дә булмады. Тик әнисе генә аның арык, ач гәүдәсенә карап авыр сулады:

— Ярар инде, балам, йөрмәсәң йөрмәссең. Анда барып, суыкта катып утырганчы, нәрсә күрсәк тә бергә күрербез, өйдә утыр, әйдә,— диде.

Шул көннәрдән башлап, Файзыр колхоз эшләренә йөри башлады. Сугыш беткән елны, өч тәрәнле трактор сабанына утырттылар. Ул чакта яңа үндүрте тулып үткән генә иде. Шуннан бирле — колхозда прицепщик.

Абыйсы, авылда атаклы куян атучы, аңа сугыштан кайтмаган укытучы Хәмитнең ау мылтыгын сатып алып бирде. Дусты, күрше

малае Зиннурны үзенә ияртеп, ауга чыккалый башлады. Зиннурның вазифасы капкыннар күтәреп бару, капкын салынгач, Файзырның куян сукмагы янындагы эзләрен күмү, эләккән булса, куянны күтәреп кайту. Файзырга ияреп еш кына ауга чыккаласа да, Зиннурның төп эше әнисенә ярдәм итү һәм уку булды. Әнисе аның Мәрьям исемле. Әтисе аңа матур итеп, Мәрҗәм дип эндәшә. Зиннур белә-белгәннән бирле, әнисе еш кына бер сүзне кабатлый:

— Йә инде, улым, нигә генә кыз булып тумадың икән? Минә кул арама керергә кеше юк бит. Апаң укуда.

Зиннурның Хөршидә исемле апасы калада, институтта укый. Ул — боларның төп өметләре. Менә бетерер дә, менә укыта башлар, менә нужа баскан дөньяларына азрак ярдәм итәр. Зиннур әнисенең зар-моңнарын тыңлый, аңа ярдәм итә, чишмә башыннан көянтәләп су ташый. Шуңа күрә, аның көянтә астына бөгелеп кереп су ташыганын күргән малайлар, исем тактылар: килен! Чишмә тавы буеннан кәкре тыкрыклар, урамнар, көртләр аша кайтканчы чакрым ярым булыр. Зиннур, үзен үртәгәннәргә ачуы килсә дә, әнисен чишмә суыннан өзми. Чөнки алар чәйне бары тик чишмә суыннан гына куялар. Аннары, вакытлар үтү белән, зур чиләкләр аскан бәләкәй гәүдәле малайга урамдагылар күнегеп тә беттеләр.

— Әй, илаһым кәрим. Бу бала — Мәрьямнең теге су ташый торган малаедыр әле, рәхмәт төшкере! Эшлә, улым, эшлә. Әниеңә ярдәм ит, акыллы булып үс!

Тик ул, барысыннан да бигрәк, укырга ярата. Беренче класстан башлап, мәктәпнең иң шәп укучыларыннан саналды. Тәртип ягыннан шаянрак булса да, укытучылары ярата үзен. Сугышта ятып калган абыйсы Гарифулланы укыткан өлкән буын укытучылар, Зиннурга карап искә алалар:

— Сәләте, укуы белән абыйсы кадәр үк булмаса да, Гарифкә тарткан бит бу Зиннур Булатов. Әмма шаян. Ә Гариф кызлар кебек басынкы, тыйнак иде. Күзгә карарга да ояла торган иде.

Шуннан гаҗәпләнүләрен белдерәләр:

— Бер ата-анадан туган балалар бит инде, югыйсә! Нилектән алай икән ул, ә? Күрәсең, монысының энергиясе күбрәктер.

Зиннур һәр эшкә өлгерергә тырыша. Әле менә дусты белән ау серенә өйрәнеп йөргән көннәре...

Ике кыш үткәреп өченчегә кергәндә, Файзыр да оста аучыга әйләнә башлаган иде инде. Абыйсы Габдерахман Яңгол бабайдан алып кайткан ике куян капкынын бик җентекләп карады. Кайбер җирләрен игәде, икесенең дә тәлен алыштырды. Ә икенче кышын капкыннарны ул үзе ясый башлады. Шуңа дип, җәй көне үк хәстәрен дә күрделәр. Югары төпкелгә барып, каен күмере яндырдылар. Ул авыр эшне аталары Ибраһим белән тагын ике малае башкарды. Бер атна азапланганнан соң, алты чыпта капчык күмерне алып кайтып, мунча алдындагы улакка тутырып куйдылар. Инде эш тимер-томырдан калды. Анысының да җае табылды. Зират тавының икенче ягындагы машина-трактор станциясенә җәяүләп барып, аның чүплегеннән яраклы дип саналган тимер-томырны сайлап, аннан соң шуларны атка төяп алып кайттылар. Шуннан соң тотындылар инде капкын ясарга. Күбрәк вакытлары мунча эчендә тимер чүкеп үтте. Тик, тимерләре калын булып, аны кыздыра алмаганда, шуны кул арбасына салып, колхоз тимерчеләренә бара торган булдылар. Анда бөтен гомерен тимер чүкеп үткәргән Мөхетдин Чәүкә (Чәүкә кушаматы аңа чыкылдатып тимер чүкегәне өчен бирелгән) ярдәм итте. Чөнки бүре капкыны ясау аңа да кирәк — үткән елны аның сыер кадәр танасын ике бүре егып ашады. Бүреләргә аның үче бар. Моңа кадәр капкын ясаганы булмаган икән аның. Ясаша да, өйрәнә дә. Ике кыш үтеп

бетеп барган чакта, Файзырда капкыннар күпме тели, шул кадәр иде инде.

Тәүге кышны ул куяннан уза алмады. Сугыш беткән елларда ялан тулы куян, төлке, бүре иде. Сугыш вакытларында, соңгы елларда сунарчылар бик аз булганлыктан, бүреләр күп үрчеде. Кайбер елларда, февраль-март бураннарында, нәсел калдыру эше белән мәшгуль чакларында хәтта эт алуга да күчәләр. Шул вакытларда, авыл читендәге йортларның күбесендә этләр бетеп, тик авыл уртасында гына торып калалар. Иртән хатын-кыз кое, чишмә яннарында, төнге хәбәрләр белән уртаклаша:

— Карале, әйгенәм! Бүген төнлә Агач Хуҗакайның этен ике бүре алган ди, ишеттеңме?

— Ю-ук, ишетмәгәниием әле.

— Агач Хуҗакай әйтә, ди, үзем күреп тордым тәрәзәдән, ай яктысында дип, әйтә ди. Читәннән бер-бер артлы сикереп төшәләр дә инде уйныйлар, инде уйныйлар Акбай белән чабышып, дип, әйтә ди. Тәүдә мин аларны этләр дип торам. Шуннан ишегалдыннан бәрәңге бакчасына чыгып киттеләр. Акбай да тегеләр белән инде. Шуннан иртән торсам, эт юк дип, әйтә ди. Бакчага чыгып карасам, ак кар — капкара кан дип, әйтә ди. Этнең, мескеннең, йоннары гына торып калган, сөякләренә кадәр чәйнәп, ашап киткәннәр дип әйтә, ди.

— Нигә, бер атна тирәсе бардыр, артык булмаса. Мәсәл Фәтхияләренең этен дә өч бүре тәрәзә төпләрендә акыртып ашамадымыни? Ашадылар бит, җонын да калдырмадылар.

— Әйтмә инде. Юлыңа каршы килә күрмәсеннәр...

Габдерахман белән Файзерахман, өченче кышка кергәндә, бүрегә капкын салырга ният иттеләр. Яңгол бабайдан кайтканнан соң Файзыр икенче көнне үк абыйсына капкын салып күрсәтте. Кабаланмыйча, җентекләп, бик тырышып эшләде. Аларга кергән Зиннурның да дустына ярдәм итәргә исәбе бар иде. Габдерахман абый рөхсәт итмәде:

— Син, Зиннур, мишәйт итмә, үзе генә эшләсен. Карап кына тор!

Бакчадагы читән кырына, буран өеп киткән көрткә, «куян эзләре» ясадылар. Шул эзләргә Файзыр капкын корып куйды.

— Ярыйсы кебек инде,— диде Габдерахман, капкынны кулына алып.— Бар, хәзер үк илтеп сал!

Икенче көнне капкын карарга киткән Файзыр буш кул белән кайтып керде.

— Юкмыни? — дип сорады аңардан капка төбен күрәп йөргән абыйсы.

— Бар шу-ул,— диде Файзыр, азрак аптыраган тавыш белән.

— Нәрсә бар?

— Сон, нәрсә булсын, куян,— диде Файзыр, абыйсына карамаска тырышып.

— Кая соң, булгач?!

Файзыр абыйсының елмаюдан авызы ерылган йөзенә карый алмыйча гына җавап бирде:

— Эләккән инде, эләккән. Тик елый бит...

— Кем елый?

— Кем булсын, капкынга эләккән куян елый. Мин бара башлагач бигрәк тә. Тач бәләкәй бала.

— Соң?

— Кызганыч бит. Мин аның янына бара алмадым. Капкыны белән тал төбендә калды...

— Шула-аймыни, елыймени?! Ә син ауга йөрүне, дәшми-тынмый гына куян ите ашап утыру, дип белдеңмени, ә! Йөрмә алай булгач чабата туздырып!

Моннан соң куян һәм төлкеләрне Файзыр үзе алып кайта башла-

ды. Аның бу эшенә тирә-як күршеләре башта көлеп кенә карадылар. Тик, куян һәм төлкеләр әллә чыннан да бик күп иде, әллә Файзыр Яңгол бабайның шәп укучысы булып чыкты — ул атнасына ике-өч куян тота башлады. Беренче кышта өч төлке дә эләктереп алды. Икенче кышны тотылган куяннарның исәбен белүче булмады. Төлкеләр дә ярыйсы эләкте. Капкын салыр өчен әллә кайларга барып йөрисе дә түгел, үзләренең өеннән ерак түгел, авыл очында гына таллык башлана, ә таллык эчендә — куян сукмаклары. Файзырның капкыннары да җиңелләр, бик ыспай ясалганнар. Салганда, абыйсы өйрәтүе буенча, беләк калынлыгындагы кыска агач кисәге бәйләп, капкын белән бергә күмә. Агачны куян капкыннарына гына бәйли. Үткән елны төлке, таллар арасында шул түмәр белән эләгеп туктагач, үзе аягын үзе чәйнәп өзеп качкан иде. Шуңа күрә төлке капкынnarын агач бәйләмичә генә сала ул хәзер. Йөргән саен, капкыннарны күбрәк салган саен, аның тәҗрибәсе арта бара. Яланнарга кышын чыгып йөри алмаган чатан абыйсына Файзыр бөтен күргәннәрен, юлда булган хәлләрнең һәммәсен дә берәмтекләп сөйли. Аның сөйләгәннәрен абыйсы бик тә бирелеп тыңлый, уйлана һәм аңарга киңәшләр бирә. Башлы кеше аның Габдерахман абыйсы. Әгәр ул таза-исән булса, мөгаен, шәһәргә барып укып, машиналар ясый торган берәр инженер булыр иде. Абыйсы турында һәрчак әнә шулай уйлый Файзерахман.

Файзырның хәзер уналты калибрлы бер мылтыгы, ун гильзасы, Яңгол бабайныкына охшатып ясалган хәнҗәре аучылыкка рөхсәт ителгән билеты бар. Ул тотып алып кайткан куян һәм төлкеләрне Габдерахман кабаланмыйча, бик әйбәт итеп туный, аннан соң үзе ясаган калыпларга кидереп киптерә. Кипкән, әзер тиреләрне союзкожга илтеп тапшыра. Анда шул тиреләр исәбеннән дары, ядрә, кургаш, чәй-шикәр һәм акча бирәләр. Куян тиресе — унбиш сум, төлкенеке — йөз егерме. Бүре тиресенә биш йөзне түлиләр. Аннан соң кайсы колхоз кырында тотсаң, шул колхоз бушка бер баш сарык бирә икән. Габдерахман белән Файзерахман җәй буена бүре тотарга әзерләнделәр. Габдерахман бик тырышып, тешле итеп бүре капкыннары ясады. Ул капкыннарның зурлыгы уртачарак җиз тас хәтле бардыр. Капкынны ясаганда, кеше күзенә күрсәтәселәре килмәгән иде. Тик авылда андый нәрсәне яшереп буламы соң? Капкыннар яртылаш кына ясалган чакта ук, урамдагы хатын-кыз телгә килде:

— Ишеттеңме? Мөчтәкнең чатан малае бүре капкыны ясый икән, әйгенәм!

## Капкынлы бүре

Татар мәктәбенең тугызынчы сыйныфында тарих дәресе бара. Укытучы Сания апа, урыныннан тормыйча гына һәм класс тактасында эленеп торган картага әйләнеп тә карамыйча таягы белән картаның кирәк җиренә төртеп күрсәтә:

— Менә сезгә картада Лондон дигән шәһәр. Сез аның Англия башкаласы икәнен беләсез. Англия үзе төрле яктан диңгез белән уратылып алынган һәм бөек диңгез дәүләте булып киткән. Шуңа күрә аның диңгез флоты да бик зу-ур булып, ул би-ик күп колонияләр яулап алга-а-ан... Син, Булатов туган, кулларың белән нәрсә эшлисең анда парта астында, ә? Бас әле, ба-ас!

Зиннур торып баса. Тик пәкесе белән юынган агач кисәге пимасының кунычы эчендә инде.

— Мин нәрсә сөйләдем әле? Мин сөйләгәннең иң соңгы җөмләсен кабатла әле!

— Шуңа күрә аның диңгез флоты бик зу-ур булып, ул би-ик күп колонияләр яулап алга-а-ан...

— Шулаймы?

— Шулай, апа.

— Ә нигә сузып сөйлисең?

— Сез бит кабатларга куштыгыз?

Азрак тынлык.

— Күрсәт кулларыңны!

Кулларда бер әйбер дә юк.

— Ә-ә, бернәрсә дә юкмы?

— Юк.

— Эзләсәм, табам мин, эзләсәм генә. Ярар, утыр, дәресне тыңла.

Сания апа бу укучысын бик ярата. Бишенче класстан бирле Зиннур аңардан тарих өйрәнә, менә дүртенче ел инде ул аның дәресләреннән һәрчак «биш»ле билгесе генә ала. Сания апа бу укучының тарихка булган сәләтенә сокланып һәм азрак шүрләберәк тә карый. Чөнки ул кайбер илләр турында укытучысыннан да күбрәк сөйли ала. Кайсы вакытларда Сания апа аның соравына тулы җавап бирә алмый һәм, үзенең дә бик белеп бетермәгәнлеген сиздермәс өчен, ашыгыбрак:

— Утыр, Булатов туган, утыр! Син программадан читкә чыгып сораша башладың. Мин сиңа алар турында аерым сөйләрмен,— дип җавап бирә.

Укытучы, бүленгән сүзләрен исенә төшереп, Мария Стюарт турында сөйләргә хәзерләнә башлаганда, класс ишеге ачылды. Ишек ярыгында Файзырның бәләкәй генә борынлы, очлы авызлы, өшегән бите күренде.

— Зиннур, тиз чык!

Сания апа утырган урыныннан тормыйча гына, ишек ягына карарга дип җай гына борыла башлаганда, Булатов ялт итеп күренеп калды да юкка чыкты. Класста утырганнар көлеп алдылар. Тик, Сания апа тагын кабаланмый гына класска таба борылганда, анда утырганнарның барысының да йөзләрендә, Англиянең башкаласы Лондон икәнне беләбез инде, ә аннан соң нәрсә, дигән сорау гына иде.

Зиннур белән Файзыр, чыгып эләктереп алмасыннар дигәндәй, рус мәктәбе почмагына кадәр йөгерделәр. Мәктәп почмагын үтеп, ишекләре күренмәс булгач, Файзыр тукталды.

— Беләсеңме нәрсә, беләсеңме?!

— Нәрсә?

— Белмәсәң, бе-ел, капкынга бүре эләккән!

Зиннур буш кулы белән бүреген башының артына этте.

— Кит аннан. Кайсы җирдә?

— Теге сугышка хәтле тавык фермасы бар ие бит.

— Ы-ы.

— Шуңа таллык аша чыга торган тар сукмак барые бит!

— Ә-ә!

— Менә шул сукмакта. Мин өченче көн анда бүре капкыны салган идем. Кичә чаңгы белән үтеп киткән идем, ул-бу күренмәде. Бүген иртән әни мине җибәрмәскә иткән иде, абый, барсын, диде. Көн суык, үзең күрәсең. Абый әйтә, бүре йөрсә, шушындый суыкларда йөри инде ул, ди. Ач көе ятып кара син суыкта, ди.

Файзыр бүре капкыннарын кар төшкәннән бирле сала иде инде. Яртышар потлы ике капкынны чаңгы табанлы чанасында әллә ничә мәртәбә алып барып, әллә ничә тапкырлар алып кайтты. Салырга барганда Зиннурны ияртми. Карда эзләрең, агачларда исең кала, ди. Мөчтәк дисәң дә Мөчтәк инде! Кышкы карда, туң талда нинди ис калсын икән. Менә соңгы тапкыр салыр алдыннан, мунча казанына тал каерысы тутырып, капкыннарны шунда бергә кайнаттылар.

— Таң вакытында эләккән, ахрысы,— ди Файзыр, сүзен дәвам итеп.— Ну сикергән, әй, капкын эләктергәч, әлләлә-ә! Икәү булганнар. Монысының эзе минем уч хәтле бар. Икенчесенең этнекеннән аз гына зуррак. Абый әйтә...

Зиннурның башкача тыңларга түземлеге җитми:

— Үзен күрдеңме соң?

— Ю-ук шул.

— Нигә?

— Азрак бардым да кире борылдым. Капкынны өстерәп киткән ул. Ялгыз каен төбенә таба.

— И-эх си-и-ин! Нигә инде?

Файзырның күзләре төрле якка йөгергәлиләр. Ул Зиннурга тиз генә карап ала да, нигәдер пышылдап кына әйтә:

— Ике бүре артыннан берүзең барып кара, алай батыр булсаң!

Әлеге сүзләрне ишеткәч, Зиннурның эчен шатлык биләп ала. Файзыр бит аны, болай булгач, иптәшлеккә алырга килгән!

— Абый әйтә, Зиннурны чакырырга кирәк иптәшкә, ди. Ул бит чаңгыда да шәп йөри, ди. Барасыңмы?

Ике бүре дигән сүзләр Зиннурның эченә салкын йөгертә. Тик ул сер бирмәскә тырыша.

— Сорап торасың, бармыйча тагын, әлбәттә, барам! Әйдә, мин чабата гына киеп, чаңгыларны алам да ычкындык. Бик ерак җибәрергә ярамый.

Алар йөгерә-атлый өйләре ягына киттеләр.

— Син әнигә сиздерә күрмә тагын. Ишәрсең ишәк чумарын. Тукта, син безгә кереп тә торма. Мин хәзер киенеп кенә чыгам!

Зиннур, Файзырдан аерылып, алдан йөгерде. Өйләренә кереп, пималарын тиз генә мич башына ыргытты да, тула оек өстеннән киндер чолгаулар урап, чабаталарын киенә башлады. Чиләк белән сөт күтәреп кереп килгән әнисе аңа бәрелә язды.

— Ишектән кергән җиргә утырмасаң, бүтән урын беткәндер. Нәрсәгә кайттың тагын?

— Чаңгы алырга. Соңгы дәрес, чаңгы ярышы икән.

— Кыш булса, көн дә шул ярыш булыр инде сезнең. Теге арихмитикаңны күбрәк укыр идең ичмаса. Хәршидә апаң, шул кирәгрәк, ди бит!

Әнисе сөйләнгән арада улы юк та булды. Тәрәзә аша улының чаңгыларын күтәреп, кабалана-кабалана үтеп киткәне генә күренеп калды.

— Әй илаһым! Исән чагымда шушы баламны укытып, кеше итсәм генә ярар иде инде. Бигрәкләр дә Гарифуллама охшаган, куллары, торышлары тач абыйсы.

Әни кеше, сугыштан кайтмаган зур улын, төпчегенә охшатып, һәрчак аны сагынып исенә ала иде.

Файзырның әнисе, Хәсбия әби, Зиннурга кечкенә бер капчык астырды.

— Син, Зиннур балам, шушыны аркаңа ас әле. Чүпрәккә төргән ике куян боты белән ярты ипи икегезгә.

— Кирәкми, Хәсбия әби, хәзер кайтабыз без.

— Кайтсагыз, кире алып кайтырсыз, ашаучы табылыр монда. Ачыксагыз, берәр җаен китереп, ашарсыз. Файзерахманның аркасында мылтыгы, кесәсендә патруннары, аңа авыр булмасын. Бер-берегезне карап йөрегез, ташлап китмәгез!

Чыгып китәр алдыннан, Габдерахман абыйлары аларга кыска гына вәгазь укыды:

— Тирегездән чыгарлык булып кумагыз. Капкын өстерәп Сәхәп буеннан ары китә алмас. Ярты потны өстерәргә күпме кирәк аңарга.

Атканда кабаланма. Маңгаена төзә. Бик якын бармагыз, өстегезгә ыргылуы ихтимал. Егерме-егерме биш адымнан әйбәт булыр. Эх, үземнең аягым сау булса-а... Ягез, юлыгыз уң булсын!

Тал сукмагыннан кереп, бүреләрнең эзләренә төштеләр. Капкынга эләккәч, бүре бик нык сикергән, бәргәләнгән, тартылган. Эләккән урынында, бик күп яшь таллар бөгелгән, егылган, сынган иде. Таллыктан бүре эзе белән бәләкәй генә калкулыкка күтәрелделәр. Монда инде капкын өстерәгән бүре эзенә икенче бүре эзе килеп кушылды. Болары бәләкәйрәкләр иде.

— Кырданрак бар. Чаңгыларың белән эзләрне таптама. Азактан кирәк булуы бар.

Нәрсәгә кирәк булуын Зиннур аңламады да, сорамады да. Эз эз инде. Аны таптадың ни дә, таптамадың ни. Хәзер куып җитәргә һәм атып алырга гына кирәк үзен. Тере бүреләр бит, тере бүреләр!

Бүре эзләрен уртада калдырып, алар алга шудылар. Файзырның чаңгылары да авырлар, үзе дә акрынрак кыймылдый иде. Чөнки аның чаңгылары кыска һәм Зиннурныкыннан ике тапкыр киңрәк. Кулында да чаңгы таяклары урынына тар гына агач көрәк. Бүрек колакчыннары ияк астына тартып бәйләнгән, абыйсы куян тиресеннән тегеп биргән битлек белән бите бөтенләй диярлек капланган. Әлеге битлектә өч кенә тишек — икесе күзләренә, берсе — борынына. Шуңа күрә дә суыкта аның эшләре көйле.

Киң кыр уртасында япа-ялгыз утырган юан каенны сулда калдырып, сөзәк кенә үргә күтәрелә башладылар. Зиннурның йөрәге ашкына. Ул, Файзырны калдырып, алга китәргә омтыла. Файзыр аңа бернičә тапкыр әйтеп карады, Зиннурның аны тыңларга түземлеге җитми. Ниһаять Файзыр туктады һәм Зиннурны алга киткән җиреннән үз янына чакырып алды.

— Менә нәрсә, Зиннур! Яңгол бабай әйтә, сунар барган чакта бер генә кеше башлык була, ди. Сунардагы барлык кешеләр дә аның әйткәненә буйсынырга фарыз, ди. Әйдә, сүз куешыйк! Бүре минем капкынга эләккән. Шулай бит?

— Шулай инде.

— Шулай! Аннан мылтык та минеке. Син мине тыңларга тиешсең. Әгәр теге бүреләрнең капкынсызы кире борылып килеп өстеңә ташланса?

— Таяк белән...

— Бик куркыр инде бүре синең юкагач таягыңнан!

— Алайса мылтыгыңны бир! Мин аларны тиз генә куып җитеп...

— Бирде ди, сиңа мылтык бирми ни. Аучыга мылтыгын беркайчан да башка кешегә бирергә ярамый. Миңа аучы билеты биргәндә, шулай дип кул куйдырып тоттырдылар.

— Тизрәк күрәсе килә бит бүреләрне...

— Килсә киләдер. Минем үземнең дә күрәсем килә аларны. Йә мине тыңлыйсың, яисә бар, кайтып кит. Ялан тутырып, Зинну-ур дип, кычкырып йөрисе генә калды ди хәзер. Миңа бүре алырга кирәк. Йә, әйт сүзеңне, тыңлыйсыңмы, юкмы?

— Әй, ярар инде, нәрсә син...

— Ярамый. Тыңлыйсыңмы, юкмы?

— И-и, Мөчтәк! Бәйләндең тек бәйләндең! Бүреләр китә бит!

— Китсеннәр!

— Тыңлыйм, тыңлыйм, әйдә, тизрәк!

— Шулай дип кенә котылсаң!

Кузгалдылар. Сөзәк, озын үрне менгәнче байтак вакыт үтте. Абыйсының тирләмәгез дигәнен исендә тотып, Файзыр кабаланмады. Чөнки ул үзе дә яхшы белә: салкын көнне шәп йөреп тирләгәннән соң, йөрешеңне акырынайтсаң, бик тиз өши башлыйсың.

Көн аяз. Суык. Күк йөзенең бер читендә эленеп торган «алка»лы

кояштан бер генә җылы әсәре дә килми. Ярый әле җиле юк. Шулай да кул белән бит өши. Ә Файзырның бите өшеми. Кулында да яхшы йоннан бәйләнгән өч бармаклы бияләй. Аның өстеннән тагын киндер белән тышланган зур куян бияләйләр кигән. Бүреге эченнән дә куян тиресеннән теккән түбәтәй. Сырмасы астында да куян тиресеннән тегелгән кәртилек. Тула оегы эчендә дә — әлеге шул куян тиресеннән тегелгән оекбашлар. Аларның бер пары көне-төне йөрегән Файзырга бер айга гына җитәдер. Ничә куян киткәндер аңа киенергә, тик ул өшүнең нәрсә икәнен дә белми. Файзыр ауга йөри башлаганнан бирле, Янгол бабайга охшатып, куян тиресеннән киенә. Тик чалбар тегеп кияргә генә базнат итми — кич аулакка баргач, кызларның көлүеннән курка. Бүген ул калын сырган чалбар кигән. Суык аны бер яктан да ала алмый.

Зиннурның куян тиресеннән теккән киемнәре юк. Тик ул да әйбәт киенгән. Өстендә яңа куфайка, сырган чалбар, башында тышлаган бүрек. Йонга кәҗә мамыгы катыштырып бәйләгән бияләй һәм оекбашлар. Зиннур төпчек бала. Әнисе аны бик ярата һәм кышларын җылы итеп киендерергә тырыша. Тула оегының башы ике кат, аның өстеннән киндер чолгаулар уралган. Шулай киенсәң генә тула оеклар һәрчак коры була.

Аучылар, сөзәк үрне менеп җиткәч, текә тауга җитеп барган ике җәнлекне шәйләп алдылар. Зуррагы алдан, ә бәләкәйрәге арттан бара иде.

— Әнә, Файзыр, карале!

— Кая? Күрмим бит.

— Әнә ич, әнә-ә! Сал битлегеңне! Тау башында үсә бит өч усак, шулардан аз гына уңгарак кара. Әнә-ә!

— Ә-ә, әйе, әйе, күрдем. Зуррагы алдан...

— Шул, шул...

Тауга түбән шактый тиз шуып төштеләр. Гөмбәт суын чыгып, бүреләрнең эзләре белән, тауга күтәрелә башладылар. Тау башына җитеп килгәндә, икесендә дә бер үк уй: тау башына менеп җитсәк, бүреләргә инде якынлашабыз... Тик тауны менүгә, бүреләр анда юк иде. Үзләренең артларыннан куа килүне сизенгәннәр булса кирәк, бүреләр атлап барудан сикереп чабуга күчкәннәр иде. Сикергән саен зур, авыр капкын кырда тирән-тирән эзләр калдырган. Башта әнкә бүре алданрак чапкан, күрәсең, кайбер урыннарда капкын аның эзләрен юк итә барган. Ярты чакрымнар тирәсе баргач, бүре эзләрендә кан күренде. Шуннан соң ул сикерүдән туктап, капкынны сөйрәп атлауга күчкән иде.

Аучылар бүреләрне Байгара үрендә куып җиттеләр. Аз гына алдан атлаган Файзырның кар каплаган куе шомырт куагын, аның тирәсендәге кар көртен урап чыгуы булды, үзе дә сизмәстән, кинәт артка чигенде. Файзырның киң чаңгылары салган эздән дәшми-тынмый гына килгән Зиннур аңа бәрелә язды.

— Нәрсә булды?

Файзыр дәшми генә алга табан ымлады. Анда, вак кына каен агачлары янында, капкынны җиргә бәрә-бәрә атлап, зур соры бүре китеп бара. Өстеннән, мунчадан чыккан кебек, пар күтәрелә. Ул артына да карамый, туктамый да. Ә бүре үтеп киткән урын белән малайлар арасында, кап уртада, буйга зуррак гәүдәле икенче бүре басып тора. Ул, елмайган кебек, иреннәрен җәеп, кызыл уртларын һәм очлы ап-ак тешләрен күрсәтеп, авызын яман зур итеп ачып ырылдый. Ике малай, үзләре дә сизмәстән бер-берсенә елыша биреп, баскан җирләрендә өнсез катып калдылар. Күпме шулай басып торганнардыр, билгесез, тик бераздан, капкынлы бүренең ерагаюын күреп, Зиннур Файзырга пышылдады.

— Тегесе китә бит, Файзыр!

Якындагы бүре исә китәргә уйламады да. Боларга караган көенә басып торуын дәвам итте. Ул ата бүренең җанын саклаша иде. Малайлар аз гына хәрәкәт итә башласа, иреннәрен киңрәк ачып, тешләрен тагын да ныграк ыржайта. Шундый бер мәлдә Зиннурның күзенә Файзыр җилкәсендәге мылтык чалынып китте.

— Ат, Файзыр, ат! Тидерәсең син аңа, якын бит, шушыннан, ат!

Файзыр тиз генә көрәген карга кадады да, кабаланып, башы аша мылтыгын сала башлады. Моны күреп алган әнкә бүре, «хорк» дигән тавыш чыгарды да тырыша-тырыша атлаган капкынлы бүренең артыннан чапты.

Бүреләрне тагын куа киттеләр. Капкынсыз бүре, тегесенең киткәнен саклап, тагын эздә утырып калды. Файзырның туктый башлавы булды, ул тагын торып чапты. Шул рәвешчә, Байгара тавының яртысы диярлек үтелде. Суык та, колаклы кояш та һәммәсе дә онытылды. Малайларның күз алдында шушы ике бүре генә торып калды. Алар күпме генә тырышсалар да, әнкә бүре аларны капкынлы бүрегә якын җибәрмәде.

Аптырый һәм азрак курка да башлаган Зиннур Файзырдан сорап куйды:

— Мондый чакта нәрсә эшләргә ди соң Яңгол бабай? Исеңә төшер әле!

— Ул миңа бүреләр тоту турында берни дә сөйләмәде.

— Нәрсә эшлибез соң инде хәзер, Файзыр?

— Белмим.

— Әйдә алайса, тисә-тимәсә, якындагысына төзәп ат та куй!

— Тимәсә?!

— Алайса, бир миңа мылтыгыңны. Мин урап каршыларына төшим. Ә син моннан барган булып кылан!

— Юк, аерылышырга ярамый безгә! Бүре мылтыкның кемдә икәнлеген яхшы белә ул. Әнә кара, миннән күзен дә алмый. Сиңа мылтыкны биреп, син китсәң, ә ул миңа ташланса?

— Алайса, үзең каршыларына бар!

— Сиңа ташланса?

Байтак кына сүз куертканнан соң, капкынсыз бүрегә төзәп атарга булдылар.

— Минем жакан патруннар дүртәү генә бит!

— Ни булса да булыр, берсен җибәрик! Аннан күз күрер!

Файзыр көрәген Зиннурга тоттырды да, бияләйләрен салып, бил каешына кыстырды. Мылтыгын ике куллап кысып, бүреләргә таба кузгалды. Зиннур да, чаңгы таякларын ташлап, нигәдер Файзыр кебек итеп, бияләйләрен бил каешына кыстырды. Аркасындагы капчыгын салып, карга ыргытты, көрәкне ике куллап кысып тотып, Файзыр артыннан калмыйча атлады. Капкынсыз бүре дә хәзер нәрсәдер буласын аңлады, ахрысы, тешләрен ыржайткан хәлдә сикерергә әзерләнгән кебек, чүккәннән-чүгә барды. Ике күзе, яшел ут чәчеп, ялтйолт килә башлады. Бүренең чүгә барганын эчке бер курку катыш дулкынлану белән күзеннән ычкындырмыйча мылтыгын күтәрде дә, аңарга табан каратып, бик тиз атып җибәрде Файзыр. Урман-тауларны яңгыратып, гөрселдәп атылган мылтык тавышына кушылып, бүре чыелдады, ә капкынлы бүре барган җиреннән читкә ыргылды. Ыргылып, берничә тапкыр сикерде дә, малайлар ягына карап, борылып утырды. Аткан тавыш, Байгара урманнарыннан кайтаваз булып кире әйләнеп кайтканда, капкынсыз әнкә бүре, кар тузанын туздырып, тау кыры буйлап чабып китеп, малайлар күзеннән юк булды. Яшь аучылар зур, ата бүре белән күзгә-күз үзләре генә торып калдылар. Бүреләрнең капкынсызы куркып качкач, аучыларның эченә азрак җылы керде. Мылтыкны яңадан корып, аның көпшәсен

бүрегә каратып тоткан килеш. Файзыр бүрегә якынлаша башлады. Агач кәрәкне кулларында кысып тоткан Зиннур аңардан калмаска тырышты. Азрак атлагач, икесе дә туктап чаңгыларын салдылар. Арты белән карда утырган зур, соры бүренең алгы уң аягы — капкында. Җилкә-муеннары озын, куе йон белән капланган киң маңгайлы, киң күкрәкле иде ул.

Йөз-йөз егерме адымнар кала Файзыр туктады да калган араны күзе белән чамалап-үлчәп карады.

— Ераграк бит, әй, тидереп булмаса, ике генә жакан кала.

— Әйдә, тагын якынрак барыйк.

— Өскә ыргылса?

— И-и, капкынны өстерәп ыргылганчы, качырбыз. Кар да бик батмый. Әйдә! Үзең атмасаң, миңа бир! Мин барам...

— Юк инде, сорама да. Син әллә тидерәсең, әллә юк. Атуың чамалы. Әйдә алайса, якынрак барыйк.

Куркып-шыртлап, бер-берсенә елыша-елыша, азрак араны атладылар да, бүрене җентекләбрәк карый башладылар.

— Карале, Файзыр, карале. Күзгә күренеп агара бит, бүре, карале!

— Бәс ул. Төлке дә шулай була, суыкта капкынны өстерәп туктагач.

Чыннан да, бүренең тирләп юешләнгән йоннары, туктагач, бәсләнеп агара башлаганнар иде. Бүре үзе бик нык арыган, гыж-гыж килеп тын ала һәм аның яшәүдән өмете өзелеп бетә язганы күренеп тора иде. Тик ул янып торган күзләре генә, эчендәге ачуын каршысында басып торган әлеге ике малайга сибеп, якты дөньяга азаккы тапкыр бүречә карыйлар иде.

Файзыр җитмеш адымнар калгач, Зиннурның кулбашына мылтык көпшәсен куеп, бик җентекләп һәм озак итеп төзәде. Бүре туп-туры мылтыкның көпшәсенә карап утырган җиреннән кымшанмады. Файзыр бүренең сул аягы белән күкрәге арасына турылады... Мылтык тавышына кушылып, улаган кебек аваз чыгарып, бүре капкыны белән бергә һавага сикерде дә, ак кар өстенә килеп төште. Башкача селкенмәде.

Үзләре эшләгән эштән курыккан малайлар, бүрегә якын барырга кыюлыклары җитешмичә, байтак кына тавыш-тынсыз басып тордылар. Алар бу вакытта Тукай әкиятендәге кәҗә белән сарыкны хәтерләтәләр иде.

Беренче булып тынгысыз Зиннур телгә килде:

— Файзыр, әйдә янына!

— Тукта, кабаланма! Юри генә үлгән булып ятса. Каны күренми бит. Бик хәйләкәр була ди ул бүре.

Азрак дәшмичә уйланып торгач, Зиннур тагын үзенең ашыгулы теләген белдерәсе итте:

— Әйдә, тагын бер ат!

— Патрон бетә бит!

— И-и, бетсә инде. Аның тегесе чаба-чаба Ибракай тауларын да үтеп киткәндер инде.

Кабаланмый гына атлап, бүренең маңгае күренеп торган якка чыктылар да якынрак килделәр. Якын да булгач, аннан бүренең тере түгеллегенә дә ышана башлагач, Файзыр тагын да җентекләбрәк төзәп, бүренең туп-туры маңгаена тидерде. Бүренең башы дертләп селкенде, гәүдәсе кузгалмады. Ул, чыннан да, үле иде.

Азакќы патрон белән мылтыкны тиз генә корып, кәрәкне әзер тотып, курка-курка гына бүрегә якынлаша башладылар. Янына килеп җиткәч тә әле Файзыр бүренең башына төзәвен дәвам иттерде. Зиннур кәрәк белән бүренең аркасына төртте. Бүре кымшанмады. Сакланып кына урап чыгып, бүренең күзләрен карадылар һәм икесе дә

җиңел итеп сулыш алды. Маңгаеның нәкъ уртасында баш бармак сыярлык пуля эзе булып, аның күзләре инде тонып бетеп бара иде. Маңгаендагы тишектән саркып, кан катыш ниндидер соры нәрсә ага.

— Әллә мие инде, Файзыр,— диде Зиннур, пышылдап.

Файзыр аңарга бер нәрсә дә әйтмәде. Сул кулы белән капкынны дугасыннан эләктерде дә бүрене аркасына әйләндерә башлады. Ярдәмгә Зиннур да килде. Бүрегә атылган беренче пуля сул аягы төбеннән кереп, йөрәгенә тигән. Шул ярадан аккан кан, бүре астындагы карны эретеп, тишеп кереп киткән, тышка күренмәгән икән.

Зиннур, кулындагы көрәген карга атып бәрде дә, бүреген һавага чөя-чөя, бүре тирәсендә сикергәли башлады. Аңарга уң кулындагы мылтыгын һавага күтәреп, чайкый-чайкый Файзыр да кушылды.

— Урра-а-а, урра-а-а!

«Ура» кычкырып бетергәч, бүрене авылга алып кайтырга кирәклеге исләренә төште. Зиннур, туңмас борын ерткычның тиресен тунап алырга тәкъдим иткән иде, тик үзе үк ул фикереннән кире кайтты. Башмак зурлыгы бүрене авылга шул көе алып кайтып күрсәтү үзе ни тора! Файзырның киң чаңгыларыннан бау үткәреп, икесен бергә бәйләделәр дә бүрене шунда салдылар. Ул авыр икән! Икесеннән дә юк-бар бауларны, чалбар каешларын җыйнап, мылтык бавын да алып, бүрене чаңгыларга ныклап беркеттеләр. Зиннур да үзенең чаңгыларын бүре өстенә салып нығытты. Аннан чаңгыларга, бау белән җигелеп, авыл ягына карап кузгалдылар.

Байгара тавын төшү әллә ни авыр булмады. Әмма тау астындагы Сәхәп суын бик читенлек белән чыктылар. Чөнки кар астындагы кечкенә елга туңмаган иде. Ничек житте алай, Зиннурның чаңгыларына баса-баса, икенче ярга сикерделәр. Үзләре артыннан чаңгылар өстенә салган бүрене өстерәделәр. Локман Атрубына килеп җиткәндә, икесе дә хәлдән тайганнар иде. Азрак ял итеп алу исәбе белән, көрт басып киткән борчак саламы эскерте янына туктадылар. Эскертнең бер почмагын көрәк белән кардан ачтылар да, саламын чокып, өн кебек бер нәрсә ясап, шуңа кереп утырдылар.

— Кая теге куян ботлары белән ипи? Чыгар тизрәк!

Зиннур, капчыкны чишеп, Файзырның әнисе куйган төенчекне алды. Файзыр аларны тигез ике кисәккә бүлеп, берсен Зиннурга тоттырды.

— Әйдә, куян боты белән җибәрик әле без бу ипекәйне. Көч күп кирәк әле безгә кайтып җиткәнче. Аша!

Пешкән суык куян боты белән туң арыш ипие бигрәк тәмле була икән! Тавыш-тынсыз ашап та бетерделәр. Тик җылы урыннан берсенең дә чыгасы килми иде. Салам эчендә җылы да, йомшак та. Азрак утыргач, Файзыр телгә килде:

— Беләсеңме, Зиннур, нәрсә?

— Нәрсә?

— Әйдә, утырып куян кумыйлар, ди Янгол бабай. Син чаңгыларыңны ки дә, сыз авылга. Бригадир Закир абзыйга кереп торма, туры конюх Ибрай бабайга бар. Шулай-шулай диген, бүре аттык, Файзыр яланда калды диген. Бер ат бирсен сиңа. Син шул атны тиз генә җигеп килеп җит. Безнең икебезнең генә көч җитми моны алып кайтырга, ат кирәк!

— Һе, ә юлда бүреләрнең тегесе очраса, мин нәрсә эшлим ди?

Файзыр эндәшмәде.

— Әйдә, икебез дә китик. Син бер үзең йә туңарсың монда. Аннан безгә һич тә аерылырга ярамый хәзер. Кем белсен, бәлки теге бүре безне сагалап йөри дә башлагандыр инде.

Бүрене чаңгылардан чишеп алдылар да үзләре әле генә утырган салам өстенә күмделәр. Чаңгыларын аякларына көйләгәч, тиз атларга тырышып, авыл ягына киттеләр.

Малайлар үгез җигелгән чана эченә күп итеп салам салдылар да юлга җыендылар. Тик Банжур бабайлары боларны ул көе генә җибәрмәде.

— Бар, улым Зиннур, өйгә кереп, минем толыпны ал! Кергән көйгә ишекнең сул ягында, чөйдә. Чаңгыда атлаганда, җылыдыр да ул, тик чанада җил йотып бара башласагыз, тиз өшерсез. Бар, йөгер. Миңнекамал әбиеңә әйт, Ибраһим бабай толып алырга кушты, диген!

Чаңгыларын ат дворында калдырып, үгез җиккән чанага икесе бер толыпка уранып утырып, малайлар Локман Атрубы ягына чыгып ычкындылар.

Сугыш башланганчы, колхоз күп атлы хуҗалык иде. Сугыш башланып киткәч тә иң яхшы атларны сугышка алдылар. Алай да калган атлар җитәрлек иде әле. Тик 1942 елны Казак далаларына барып кайткач өч атниндидер таныш булмаган авыру ияртеп кайтты. Ат барган җиреннән туктый да калтырый башлый. Калтыравы көчәйгәннән-көчәя барып, шапылдап егыла да җан бирә. Атна-ун көн эчендә колхозның шактый гына атлары кырылды. Колхоз картлары аны «калтырча авыру» дип атадылар. Авыру бер авылда гына калмыйча, район буенча, хәтта күрше районнарга да тарала башлады. Калган атларның бәхетенә, авылның түбән очында, Тал Борыны дип йөртелгән җирендә, кибиткасы шыгрым тулы хатын-кыз һәм бала-чага белән бер карт чегән туктый. Авыл картларының берсе менә шул карт чегәнгә киңәш сорап бара. Чегән, авыру атларны килеп карагач, өч көн һәм өч төн чыкмастан картларны ат дәваларга өйрәткән. Атларның корсаклары аша дилбегә үткәреп, аяклары җирдән аерылганчы тарттырып, абзар әрлегенә күтәртеп асып куярга икән. Бернәрсә дә ашатмаска. Көненә ике тапкыр азрак он бутап, җылы су эчерергә, көненә өч тапкыр кайнар су белән аркаларын, күкрәкләре, аяк-тоякларын юарга. Чегән карты янына авылның унлап карты җыйналып, аның кушканын эшләп, колхозның байтак атларын менә шулай үлемнән саклап калганнар. Тик атлар шактый азайган иде инде. Менә шул елларда күп кенә колхозларда үгез җигүгә күчтеләр. Чөнки сугыш, ир-егетләрне алып киткән кебек, атларны да санаусыз соравын дәвам итте.

Ул елларда кышкы карлы юллардан дүрт-биш атлы юырта, ә алар артыннан, аркылы агач камыт белән чаналарга җигелгән, төрле төстәге үгезләрнең чабуы табигый бер күренеш буларак кабул ителә иде. Колхоз үгезләрне, өч яше тулган чагында, авыл халкыннан сатып ала. Алар инде, колхозга алынганчы ук, авыл малайлары кулы аша үтеп, җигелергә өйрәнелгәннәр. Исемнәре дә кемнән сатылып алынуга ишарә: Сапкамал, Шүрәле, Песәй, Ташкергән, Күгәрчен...

Шушы үгезләр җигелгән чаналарда, колхозның барлык эшен җимереп эшли торган малайлар килә. Сугыштан кайткан ирләр аларга кычкырып-әрләп эндәшсәләр, малайлар тартынуны-нине белмичә, аты-юлы белән каршы җавап бирәләр. Җавап бирәләр дә, аптыравыннан телсез калып, әзмәвердәй ирнең кыза башлавын басардай сүзләр табып, кулына янчык тоттыралар.

— Мә тот, Миңнәхмәт абзый, берне төреп җибәрик, без янганчы тәмәке янсын. Төкер башына. Кычкырышу белән колхоз эше бетмәс ул. Ә ул эшне барыбер синең белән безгә эшләргә.

Шундыйрак сүзләр белән, аптыравыннан ни әйтергә дә белмичә торган, сугыштан орден-медальләр тагып кайткан фронтовикның кәрәк хәтле кулына, ертып алып, гәзит кәгазе кисәге тоттыра, шуңа тәмәкесен дә салып өлгерә. Үзе дә сизмәстән тәмәке урый башлаган Миңнәхмәт абзасы әйтеп куя:

— Ай-һай, Рәхмәтулла, атаң мәрхүм дә бу хәтле сырлап сүгенә белми иде, син кайдан өйрәндең?

Тегесе дә сүз эзләп янчыкка кереп тормый, тәмәкегә ут элдерәэлдерә үзенекен өсти:

— Эти синең кебек надан булган, Миннәхмәт абзый. Ә минем өч класс белем бар. Ә сугенү анысы сез сугышып йөргән елларда, сыер җигеп, сабан сөргән чакларда, җир астыннан килеп чыкты. Тамак ипигә туйгач, аяктан чабата төшкәч, бетәр әле, кайгырма син аңа...

Карлы юл буйлап, арт аякларын читкә селти-селти чапкан Сапкамалны кабаландырып, борчак саламы эскерте янына малайлар шактый тиз килеп җиттеләр. Әлеге эскерт печән-салам ташыган юлдан ярты чакрым чамасы эчтәрәк, калкып-күренеп тора. Зиннур, чанадан төшеп, кар бик тирән булмаган җирләрне чамалый-чамалый, эскерт ягына китте. Үгез аның артыннан иярде. Тик салам эскерте янына йөз метр тирәсе калгач, нәрсәгәдер тынычсызланып, пошкырып куйды. Аннан ун-унбиш адымнар тавыш-тынсыз гына атлады да, тагын пошкырды һәм баруыннан шып туктады. Аркасы буйлап чажылдаган каеш чыбыркыга да исе китмәде. Файзыр аңарга тагын сукты, дилбегәне тарткалап, үгезне Зиннур артыннан кузгатырга теләде. Һәрвакыт тыңлаучан, тырыш Сапкамал, башын аска иеп, мөгери һәм, алгы аягы белән кискен-кискен сугып, карны актара башлады. Файзыр артына карамыйча да атлаган иптәшенә кычкырды:

— Зиннур, кире борыл, бүрене сиздe бу. Әнә нәрсә кылана. Үгез белән сугышып аптыраган ике малай туктап киңәш кордылар. Нәрсә эшләргә? Малайларның кулы дилбегәдән бушаганны сизгән Сапкамал урыныннан капылт кузгалды да, кар ерып, авыл ягына ычкынырга тырышты. Аны тиз генә эләктереп алып, башын тәртәгә бәйләп куйдылар. Файзыр кызуланып команда бирде:

— Мин үгезне тотып торам, син өстерәп китереп, бүрене чанага сал!

Тотындылар болар чанага бүрене төяргә. Файзыр үгезнең башына асылынган, ә Зиннур туңа башлаган бүре гәүдәсен өстери. Булмагач, булмый икән! Зиннур кар ерып бүрене өстерәп чанага якынлашырга тырыша. Ә Сапкамал, башы шакарылып тәртәгә бәйләнгән булуга да карамастан, чучка кебек хорхылдап, әллә кая ыргыла. Файзыр, аның башына чыбыркыны урталай бөкләп сугып та карый, тик үгезне туктата алмый. Бүре өстерәгән Зиннур белән чана арасы һич кенә дә кыскармый. Малайлар урыннарын да алыштырып карадылар. Юк кына бит!

Сапкамалга карап нәрсә эшләргә дә белмәгән ике малай бүре түшкәсе өстендә байтак утырдылар. Берникадәр вакыт үткәч, Зиннур сикереп торып аягына басты:

— Таптым! Әйдә!

Бүрене икәүләшеп борчак саламы эскерте өстенә мендереп салдылар да, Файзыр шунда калды. Зиннур өстеннән куфайкасын салып, Сапкамалның күзләрен томалап, эскерттән югары якка алып китте. Җил булмаса да, һава агымы шул яктан тарта иде. Малайларның планы буенча, эскерт яныннан үткән чакта Файзыр бүре белән бергә, чана эченә килеп төшәргә тиеш. Әгәр инде Сапкамал дулый, яисә читкә чаба башласа, Зиннур аның куфайкага уралган башын салам эскертенә төртергә тиеш.

Һәм шулай эшләделәр дә. Бүре белән бергә Файзыр чана эченә лапылдап килеп төшкәч, башы белән эскерткә кадалган Сапкамал дер-дер калтырарга тотынды. Аны юата-юата, сыпыра-сыпыра куфайкасын алмый гына кайту юлына чыктылар. Зиннур иплән кенә үгезнең башын бәйләгән дилбегәне чиште. Шуннан соң, Файзырга дилбегәне нык итеп тотарга кушып, үгез башындагы куфайкасын тартып алып, чанага ыргылды.

Сапкамалның үзе гомерендә дә шушындый тизлек белән чапканы булмагандыр. Ул бер җирдә дә тизлеген киметмичә, авыл ягы-

на карап чапты да чапты. Шул ук тизлек белән авыл урамына барып керделәр. Тик Сапкамал тыңлаудан узган иде. Чана ягыннан бертуктаусыз килгән куркыныч бүре исе — аны авылның көртле урамнары буйлап туктатмастан куды. Сапкамалны туктата алмыйча, малайлар Файзырлар өе янынннан ике тапкыр узып киттеләр. Инде өченче тапкыр якынлашып килгәндә, кемнеңдер кычкырганы ишетелде:

— Бүрегезне төшереп калдырыгыз, агач башлар!

Карале, чыннан да шулай бит!

Бүрене, саламы-ние белән чанадан төртеп төшерделәр. Бүре белән бергә, юлдагы ат тизәкләре арасына Файзыр да очып төшеп калды. Урамга чыккан кешеләргә кызык та, көлке дә иде.

Үгезне ат дворына Зиннур үзе генә илтте. Ибраһим бабай, чанадан учлап салам алып, үгезнең аркасын, күкрәген, корсак асларын сөртте. Үзе бертуктаусыз сөйләнде:

— Ну, машинник та малайлар икәнсез. Сез авылга кар бураннары туздырып килеп кергәч, урамда бер эт калса икән. Кая ул өрү, кайсысы кая таеп беттеләр. Минем Мучка әнә әвеслек астында ята. Тавыш-тыны беткән. Мылтыктан аткан кебек кенә кайтып керде дә шунда посты.

Ибраһим бабай, зур кулы белән Сапкамалның аркасына суга-суга, абзар эченә алып кереп китте:

— Тынычлан, малкай, тынычлан. Мондый егетләр җиккәнгә куан гына син, һәр үгезгә эләкми ул бүре ташу дәрәҗәсе!

Шул көнне кич йокларга ятканчы һәм икенче көнне көне буена авыл халкы Файзырлар өенә бүре күрергә агылды.

Бүре, чыннан да, бик зур һәм мәһабәт гәүдәле иде. Идән уртасына бер-берсенә терәлеп диярлек ике утыргыч куелган. Шул утыргычларда, аяклары идәнгә тияр-тимәс кенә итеп, бүре урнаштырылган. Киң маңгайлы башы ишек ягына каратып куелган. Ишектән кергән кеше иң башта бүренең ике күзен күреп, өнсез кала. Аннан ул күзләрнең пыялаланганлыгын чамалап, курыкканын сиздермәскә тырышып, көлгән була. Аңа карап, инде байтактан бирле бүре күреп утырганнар да көлешәләр. Шуннан соң бүрене карый башлыйлар. Иң тәүдә тешләрен, аннан аякларын, сыртын. Ә ишек төбендә, алга үтәргә кыймыйча, ереле-ваклы малай-шалай таптана. Чабаталарыннан эреп аккан су белән юешләнгән идәндә әрле-бирле килеп, лышык-лышык борыннарын тартып, бүредән күзләрен ала алмыйлар... Малайлар өчен генә түгел, зур соры, ата бүре авыл халкының күңелендә, мәңгелек истәлек булып калды. Файзырның зур булмаган ябык гәүдәсе, бер көн эчендә, әкияттәге батырлар гәүдәсе хәтле булып үсте. Ул хәзер күпләр өчен башлы, көчле, бүреләр тота торган сунарчыга әверелде.

Ике көн үткәч, идарәдән алган рөхсәт язуы тотып, Файзыр белән Зиннур «8 Март» колхозы фермасына бүре тотканнары өчен сарык алырга бардылар. Ферма мөдире аларны сарыклар торган сарай эченә алып керде.

— Барыгыз, егетләр, кайсысын телисез, шунысын сайлап алыгыз, сезгә миннән хөррият бүген. Бик җәфа чигәм мин ул бүре халкыннан. Иң атаманын юк иткәнсез, болай булгач, сездән сарык кызгану юк. Барыгыз, алыгыз! Йә, нигә аптырашта калдыгыз?

— Сайлый белмибез.

— Сезгә нәрсәгә, суяргамы, нәселгәме?

— Нәселгә.

— Ә-ә, шулаймы! Ярар алайса, хәзер без аны карыйбыз!

Ул, карана-карана көтү эченә кереп китте дә тәбәнәк буйлы, юантык кына, каралы-аклы бер сарыкны сырт йонынннан эләктереп алды.

— Менә сезгә нәсел сарыгы, тотыгыз! Ел саен икене бәрәнли, үзенең җоны озын, нечкә. Яшькә дә бише белән генә китте. Үзе Мин-

һаҗ кулак сарыклары нәселеннән. Ул кулак сарыкның ниндиен асырарга икәнен бик яхшы белә торган иде. Мәгез, рәхәтен күрегез, балалар, сезнең яшәү алда бит әле...

Укытучы Сания апа, тарих дәресендә, Зиннурны такта янына чыгарып, үткән теманы сөйләтеп, «биш»ле куйды.

— Булатов туган, сине, бүрене капкынга эләктергән кебек, бер эләктереп, ничек кенә бер «ике»леле куярга инде. Тәртип ягы аксый синең, туган, сүзне тыңламыйсың.

Такта янында кулына таяк тотып басып торган Зиннурга соклану тулган күзләре белән карап алды да өстәп куйды:

— Егетсең! Һәрчак шулай бул. Барыгызга да үрнәк булсын бу укучы. Бөтен җиргә җитешә: эшли дә, шаяра да белә. Дәресләрен дә гел «биш»ле билгесенә генә укый. Ишетәсеңме, Җәләкаев, мин сөйләгәннең очы сиңа кагыла. Утыр, Булатов. Сәбәбе бүре тоту булса да, икенче юлы дәрестән рөхсәтсез чыгып чапма!

## Бәләкәч Габдерахман

Сугыш бетеп өч ел үткәч, авыл урамында таныш булмаган, унбиш-уналты яшьләрдәге бер малай күренде. Киңчә, карасу бите белән казакъка охшаган. Чем-кара күзле, өстендә солдат шинеле сукносыннан тегелгән пальто, аягында ул чакларда «рабочий ботинка» дип йөртелгән, калын табанлы ботинкалар, башына кечкенә козыреклы «жулик» кепка кигән иде ул. Ике тыкрык чатында туктап, пальто кесәсеннән «Норд» дигән папирос чыгарып кабызды да, тирә-якка җентекләп бер карап алгач, Хаҗи карга йортын сулда калдырып, кабаланмый гына Вәписләр урамы белән Пожар каланчасына кереп китте.

Тачкаларына чиләк асып суга китеп барган берничә малай, ят кешедән күзләрен ала алмыйча, зур игътибар белән күздән кичергәч, туктап тиз-тиз сөйләшеп алдылар. Нәрсә инде бу? Көпә-көндез, авыл урамы буйлап, папирос көйрәтеп йөр, имеш! Тәмәкене Папай Нигъмәтләре, Мөхми Сәлимнәре, Керпә Гарифлары да тарталар тартуын. Тик алар, бит бу малайдан зуррак, ә үзләре колхозда эшлиләр. Аннан соң алар тартсалар да, атта утырып үткәндә, арба өстендә чакта гына, яисә зурларга күрсәтмәскә тырышып, җиң эченә тыгып кына тарталар. Каршы очраган карчык-корчыклар, ата-бабасын телгә алып, әрли башласалар, тегеләр, атларына сугып, тизрәк күздән югалу ягын карыйлар. Ә бу? Ничек инде?

Пальтолы малай, әлеге вак-төяккә бөтенләй әһәмият итмичә, Пожар урамына күтәрелгәч, Гариф Танаулар яныннан сулга борылды. Почмактагы ташчы Фәттах йортын үткәч, Заһит Тазның читәне янында үзеннән ике-өч яшькә кечерәк берничә малайны күреп, шулар янына якынлашты. Караңгы төшкәч, кемнең бакчасына кыярга төшәргә, дип киңәшеп утырган авыл малайлары, үзләренә якынлашып килүчене күргәч, калача киенгән үсмергә карап тынып калдылар. Малай кулындагы папирос төпчеген җиргә ташлап, аны ботинкасы белән басып сүндерде дә, күзләрен бозлатып, үзенә карап торган малайларга эндәште:

— Исәнмесез!

Моны көтмәгән малайлар, аптырап калып, аңарга җавап кайтармадылар, тавышсыз гына кузгалып, урыннарыннан тора башладылар. Алар барысы да төрлесе-төрле ямаулы чалбар-күлмәк кигәннәр һәм барысы да яланаяк иделәр.

— Исәнмесез, дим бит, нигә эндәшмисез?

Малайлар арасындагы кыюрагы, Кабан Хәлиме, аңа җавап кайтарды:

— Нигә, исән булмасак, син әллә духтырмы ул хәтле?

Ят малайның зур авызы елмаеп җәелде:

— Түгел, духтыр түгел мин...
— Кем ату?
— Нигә, танымыйсызмыни?
Хәлимгә кызык була башлады:
— Ә син безне таныйсыңмы соң?
— Таныйм, нигә танымаска ди. Син Кабан Хәлиме, менә бу Кәчти Равиле, монысы Капар Рәшите, монысы Китек Рәшит!
— Ә мин кем?
— Син — Ташкерган Тадип.
Авыл малайлары ул сөйләгән саен җанлана, елмая башладылар. Шулчак алар арасыннан Кәчти Равиле телгә килде:
— Һе, мин дә сине таныдым шикелле.
— Танысаң, әйт!
— Син теге Төрек күле янында сугышка хәтле торган Җомай Мәҗит бабайның кече улы Габдерахман бит.
Равил әйткәч, Габдерахманны калганнары да таныды. Ят кеше дигәннәре, чыннан да, әтисе Мәҗит белән абыйсы Габдерәхимне, берсен трудармиягә, икенчесен сугышка алып киткәч, апасы Хәбибә белән каладагы балалар йортына озатылган Җомай Габдерахман иде. Малайлар аны уратып алып, зурларча кул биреп, күрешергә тотындылар. Йә инде, менә бит, бергә шар сугып, чебенле, лапталы уйнап, урам тутырып чабып йөргән Җомай Габдерахманы «гарадской» булып кайтып кергән! Таныгач, азрак шау-шу басылгач, Габдерахман, урамның түбән ягына карап, малайлардан сорады:
— Миңа Зиннур кирәк иде, белмисезме?
— Кайсы Зиннур, Писерме?
— Әйе.
— Белмибез шул, өйдәме икән? Папай Нигъмәте белән ургычта эшли ул.
Капар Рәшитенең ун яшьләр чамасындагы энесе кабалана-кабалана, сүзенең азаккы иҗекләрен йота-йота яңалык әйтте:
— Өйдә ул. Яңа гына Алатай белән кайтты. Ургычларының шатуны сынган, ашарга да алып китәргә кирәк бит. Папай Нигъмәте, Хирахау Хәлите белән өчәүләп, Сәхәп яланында бодай чаба.— Зурлар белмәгәнне белеп, күп сөйләгәне өчен, телдәр малайның аркасына берне тамызып алдылар. Ул тиз генә абыйсы артына посты. Абыйсыннан да өстәү алгач, бөтенләй тынды. Малайлар арасында башлык булыбрак йөргән Хәлимгә хәзер әлеге сүзне җөпләргә генә калды.
— Әйе, шул! Ургычта бодай чабалар. Әйдәгез, тизрәк барыйк!
Габдерахманны ураткан малайлар өере урам буйлап китеп барды. Зиннурның әтисе Лотфулла бабай — сары мыеклы, зәңгәр күзле, зур гәүдәле кеше. Ул унсигезенче ел башында ярман сугышыннан карабин, кылычлар белән кайтып, дусты Төкәй Хафизы белән авылда Совет власте урнаштырып йөргән кеше. Авыл советында күп еллар буе секретарь булып эшләгән. Халык аны шуңа күрә Писер Лотфулла дип йөртә. Совет хөкүмәтенең беренче елларында секретарь сүзе нигәдер халык теленә ятып бетмәгән. Шул лакаб исем уланына да күчкән. Писер Инсуры, Писер Зиннуры. Каладан кайткан Габдерахман менә шул кешеләргә юнәлгән иде.

Малайлар төркеме боларның йортына килеп җиткәндә, өстенә куфайка, аякларына оек-чабата кигән Зиннур, капкаларын ачып, чибәр гәүдәле, ала тостәге, өч яшьләр чамасындагы тайны җитәкләп урамга чыгып килә иде. Ул тынып калган малайларга сораулы күзләрен текәде. Габдерахман, малайлардан аерылып, берничә адым алга атлады, азрак карлыкканрак тавыш белән Зиннурга эндәште:
— Таныйсыңмы мине, Зиннур?
Зиннур култык астына кыстырып тоткан шатуннарын җиргә ыр-

гытты да, колачын җәеп, ничәмә еллар күрмәгән дустына таба атлады.

— Гаптери-и!

— Зину-у-ур!

Әгәр исемен әйтмәгән булса, Зиннур бәлки аны тиз генә танымаган да булыр иде. Бары тик Габдерахман гына бер «н» авазын төшереп калдырып әйтә белә аның исемен. Сагынышкан ике үсмер бербереен баштанаяк карап чыктылар. Азрак тынгач, Зиннур, Хәлим кулындагы шатуннарга үрелеп, Габдерахманнан сорады:

— Нинди җилләр ташлады? Әллә бөтенләйгәме?

— Һе, бөтенләйгәме? Кемгә кайтам инде мин бөтенләйгә? Туган елым турында таныклык кирәк. Сорап язганнар иде дә, тик җавап килмәгән. Миңа тиздән уналты тула бит, балалар йортыннан китәргә кирәк. Һөнәр училищесенә җибәрәләр. Куйбышев шәһәренә. Так что, рабочий класс булам. Паспортный өстәленә барырга кирәк.

— Ала-ай икән синең эшләр...— диде Зиннур. Аннан азрак дәшми торды да:

— Әйдә, без болай итик. Мин тимерчелеккә Мөхетдин Чәүкәгә бу шатуннарны менгереп бирим. Башларын ябыштырып, төзәтә торсын. Син туган елыңа таныклык барып ал да кире безгә кайт!

Зиннур үзләрен уратып алган малайларга карап чыкты да Хәлимгә эндәште:

— Син, Хәлим, бер-ике-өч сәгатьтән безгә кил әле. Шатуннарны яланда Нигъмәтулла абзый көтеп тора. Илтеп бирерсең. Әгәр дә ургычта йөрергә кирәк булса, утыр, яме. Тик ургычның платформасында башыңны унга сузып карама. Арттан канаты белән башка китереп суга. Кушса, кичкелеккә бәрәңге әрче, атларны тышаулап җибәр!

— Ярар, Зиннур, ярар!

— Китте, Гаптери. Әй, тукта, әйдә, өйгә керик әле. Мин сине әнигә күрсәтим. Миннән элегрәк кайтсаң, танымый торыр.

Габдерахманны өендә калдырып чыккан Зиннурны малайлар көтеп алды.

— Таныдымы әниең?

— Юк, танымады. Әйткәч кенә таныды да елый башлады. Әй, илаһым, ди. Әниең генә күрә алмады бу хәтлек булып үскәнеңне, ди. Кош балалары кебек, кайсыгыз кая таралышып беттегез бит инде, дип елый.

— Ә абыйсы турында беләме?

— Беләдер ул, сорамадым мин. Инде өч ел бит сугыш беткәнгә дә.

— Кайвакыт малай-шалай башына да кирәкле уйлар килеп кергәли. Зиннур Кәчти Равилгә йомыш кушты:

— Син, Равил, Латыйф абзыйга барып әйт әле. Шулай-шулай диген, Габдерәхим абыйның энесе Габдерахман кайткан диген. Вакыт табып, абыйсы турында сөйләп китсен иде.

Зиннур, иелеп, Хәлим кулындагы шатуннарны алды да тимерчелеккә таба юыртып китте. Малайлар аның артыннан олылап карап калдылар. Чөнки ул колхоз уртасында уңган-эшчән Папай Нигъмәтенең ярдәмчесе булып эшли. Ә колхозда бөтен кеше белә: туганда ук эшләп туган Папай Нигъмәтулласы — үзе янына килде-китте малайны алмый.

Икенче көнне, өйлә җитеп килгәндә, Зиннур Габдерахманны калага озатты. Габдерахман кулына зур булмаган төенчек тоткан. Төенчектә — абыйсыннан истәлек булып, әллә кайдагы Норвегиядән кайткан, дөя йонынннан бәйләгән калын, җылы свитер һәм Зиннурның әнисе биргән берничә таба күмәч. Кичә кич Латыйф абзый килеп китте. Абыйсын кайда һәм ничек итеп соңгы тапкыр күргәнен сөйләп бетергәч, свитерны Габдерахманга сузды:

— Тот, энем! Абыеңның төсе итеп сакларсың! Мин ике рәт кенә

кидем. Теге Керкенес каласы, абыең искә төшәләр дә, башым әйләнеп, тыным кысыла башлый.

Габдерахман, кечкенә йөк машинасына килеп утырыр алдыннан, Зиннур белән кочаклашып хушлашты. Машина кузгалып киткәч тә, яшь баскан күзләре белән, Зиннурның кичерәйгәннән-кичерәя барган гәүдәсен күздән югалганчы карарга тырышты. Аннан, авылны чыгып биек таш койма белән уратылган зират яныннан үткән чакта, моңсу күзләрен ак кылганнар каплаган иске каберлекләрдән ала алмады. Шул каберләрнең берсендә бу дөньядан утыз сигез яшендә китеп барган газиз әнисе ята. Тик Габдерахман аның каберенең кайда икәнен белми. Чөнки әнисен күмгән көнне мәрхүм Мәҗит абзый елаудан шешенгән кече малаен зиратка алып бармады...

Габдерахман, авыр сулап, пальтосының каты якасын күтәреп куйды.

Машина авылдан чыгып, кала юлына төшүенә шатлангандай, тизлеген арттырганнан-арттыра иде. Ә кузовта, абыйсының соңгы истәлеге булган свитерны күкрәгенә кысып, Габдерахман атлы ятим малай, иске капчыклар өеменә яткан хәлдә, тавыш-тынсыз гына елый иде. Шул китүдән соң ул суга төшкәндәй юк булды һәм башкача туган якларына кайтып күренмәде...

## Соңгы йөк бодай

Бер мең тугыз йөз илленче елның язы коры килде. Карлар эреп, елгалар боздан арынды. Май ае үтеп барса да, җир өстенә бер генә бөртек тә яңгыр төшмәде. Әллә ни зурлар булмаса да, ике бригададан торган колхозда бер ЧТЗ, өч тешле тәгәрмәчле тракторлар һәм байтак кына ат көчләре кулланып, язгы чәчүне тәмамлау өчен тырышалар иде. Яңгыр юклыктан сусап, кара тузан очырып яткан коры җиргә алтын бодай кебек бодай бөртекләре чәчеп, шуларны әрәм итүдән йөрәкләре өзгәләнгән берничә авыл карты кичләтеп кенә колхоз идарәсенә килделәр. Аларның биргән сәламен колхоз рәисе Басыйр сагаю белән каршы алды. Чөнки картларның нинди исәп белән йөрегәннәрен ул үзе дә сизенә иде. Картлар, кергәннән соң, бераз дәшми утырдылар. Тик рәиснең үзе башлап сүзгә керешмәячәген аңлагач, азрак кузгалышып, йөткергәләп алдылар да араларыннан берсе кыюлык күрсәтте:

— Инде, энем Басыйр, без сиңа аптыраганнан килдек. Бер-бер хәл кылырга кирәк, ахры. Ә син чәчәсең дә чәчәсең...

— Нәрсә чәчим мин, Сәхиулла абзый?

— Безнең бу бодайны чәчүебез заялар гына итү түгел микән? Яңгыр юк, җир янып ята, ә син чәчәсең дә чәчәсең...

— Шулай, шулай. Яңгыр юк — син чәчәсең.

— Соңгы бодайны да яндырабыз түгелме икән?

Басыйрның сакал-мыек баскан, йончыган йөзенә күңелсез елмаю чыкты.

— Соң абзыйлар, безнең эшебез шул бит инде. Яз көне иген чәчү. Ил халкына икмәк ашату.

— Анысы шулай ла ул. Ә яңгыр булмаса?

— Булмый калмас, булыр! Колхоз көзгә икмәк бирергә тиеш. Хөкүмәткә икмәк кирәк.

— Шулай анысы, энем, дөрес әйтәсең. Тик без уйлаштык, уйлаштык та, әллә, дибез, чәчкәне белән тукталып, калган игенне, ирләре сугыштан кайтмаган хатыннарга бүлеп бирикме? Аннан яланга яңгыр сорарга картларны, карчыкларны чыгарыйкмы әллә, дибез. Бу хәтлек корылыкка...

Басыйр аңа сөйләп бетерергә форсат бирмәде, сорау белән бүлде:

— Шулай дисезме?

— Әйе, энем, шулай әйбәт булыр, дибез. Унбиш-егерме карчыкны җыйнап чыгарсак, шәп булыр, дибез. Ә калган бодайны, җиргә күмеп яндырганчы, бала-чага ашасын, дибез.

— Ярар, сезнеңчә дә булсын, ди инде. Бүлешеп алып, ашап та бетердек, ди. Ә яңгырлар китсә, кырларны алабута, билчән, эт эчәге бассынмы?

Колхоз рәисе, алдында яткан кәгазьләрне кузгаткалап алды да, сүзне бетерергә ашыкты:

— Чәчәбез, картлар, җир орлыксыз калырга тиеш түгел. Ата-бабадан калган йоланы бозып яшәмик, әйдә. Чәчәбез, абзыйлар, чәчәбез. Шуның белән сүз бетте дип исәплим. Барыгыз, кайтыгыз, халыкны котыртып йөрмәгез.

Картлар, ризасызлыкларын күрсәтеп, рәис белән саубуллашмыйча да чыгып киттеләр. Идарә болдырыннан төшкәндә берсе сукранып куйды:

— Атасы мәрхүм дә, шулай тискәреләнсә, гел үзенекен сөйләп, үзенекен генә эшләп йөри торган иде. Бу да атасына тарткан икән...

Таякка таянган Бәшәр карт, моның зарланганын тыңлап бетермичә үк, шелтәләп алды:

— Напрасны кузгаттың син карчыклар турында, напрасны. Шундый эшкә хатын-кызны кыстыралармыни инде, йә, бигрәк тә карчыкларны. Их, син!

Алар, башкача сүз куертмыйча, тавышсыз гына төрле якка таралдылар.

Колхоз рәисе, картларны тыңламыйча, үз сүзен сүз итеп, чәчүне бетерергә ашыкты. Тагын бер атнадан чәчүнең соңгы көне килеп җитте.

Авылның кояш чыгышы ягында, өч чакрым чамасы җирдәге ялан кыр уртасында, ботакларын җәеп, ялгыз бер карт каен үсеп утыра. Аның халык телендәге исеме дә Ялгыз Каен. Бүген Ялгыз Каен ялнында колхоз соңгы бодаен чәчә. Колхоз исеме белән «Марс келәтләре» дип йөртелгән урыннан Папай Нигъмәте соңгы йөк чәчү бодаен төйи. Аның көчле куллары сиксәнешәр килограммлы бодай тутырылган капчыкларны уйнатып кына алып арбага ыргытканын бер кулы сугышта гарипләнеп кайткан колхоз кладовщигы Пачар Бики сокланып карап тора. Көч-гайрәте белән сугыштан кайтмаган абзасы Гыйният мәрхүмгә охшаса да охшар икән бу егет!

Нигъмәтулла, чыннан да, таза һәм көчле егет иде. Бераз камытрак аяклы, киң күкрәкле, ишелгән бау кебек уйнап торган мускуллы кеше иде. Эшкә тотынганда ук кулының ятыш, сәләтле икәнлеге күренеп тора. Кырык беренче елдан — унбер яшеннән колхозда эшли башлады, шуннан бирле туктаганы юк. Эшчәнлеге, кеше нужасын аңлый белүе, кеше күңелен күрә белүе, сүгенмәве, эчмәве өчен аны авылның барлык кешесе ярата.

Җиңсез зәңгәр майкадан гына калып капчыклар төяүче Нигъмәтнең бүгенге көннәре — колхозда соңгы эш көннәре. Чөнки Рәхми абзасыннан аңа күчкән солдат гимнастеркасының түш кесәсендә военкоматтан килгән повестка ята. Анда: «Сез, Гапсаттаров Нигъмәтулла Гобәйдулла улы, 1950 елның 12 июнендә Совет Армиясе сафына алынасыз. Үзегез белән түбәндәге әйберләрне алып килергә...» — дип язылган.

Нигъмәтнең тизрәк армиягә китәсе килә. Аның да Писер Инсуры яисә Көрпә Гарифы кебек солдатча киенеп, погоннар тагып, урындык аркасына таянып төшкән сурәтен авылга җибәрәсе килә! Тәвәккәллеге җитсә, берсен бәлки Рәмиләгә дә салыр әле. Менә шуңа күрә дә ул хәрби комиссариаттан килгән повестканы кадерләп, унынчыда

укып йөргән күрше Зиннурдан алган ак кәгазь битенә төреп, түш кесәсендә, йөрәк турысында йөртә. Кем белә, бәлки Инсур янына Сахалинга, яисә Гариф янына Курил утрауларына да барып эләгер. Аның Курил утрауларына, Гариф янына барып чыгасы килә. Чөнки Гарифы армиядә дә атлар карый икән. Ә Нигъмәт атсыз бер көн дә тора алмый. Аның колхозда иң яратып җиккән аты Таракан исемле. Утызынчы еллар башында колхозга кергән Таракан Барыеның аты. Чабуы бик шәптән түгел, ләкин көче чамасыз кебек. Ялы, койрыгы аксыл. Төсе белән җирән тараканга охшаганга, элекке хуҗасының кушаматы да Таракан булганга күрә, ат та — Таракан исемле. Нигъмәт артыннан ул эт шикелле калмастан ияреп йөри ала. Әгәр дә хуҗасы, шушында гына ор, беркая да китмә, дисә, көне буена шул бер урында басып тора. Нигъмәтнең Тараканны җигә башлаганына өч ел тулып үтте инде. Һәр елны яз көне, колхозда эшләгән малайлар, бригадир Сәвәләй Закирның ниндидер кенәгәсенә кул куеп, үзләренә бирелгән атны яхшы карарга, дип йөкләмә алалар. Нигъмәт Тараканны алганда апрель азаклары иде. Элек ул җигеп йөргән Захмай исемле атны, бригадир аңардан алып, кайнеше Таз Камәргә беркетте. Камәр атны көндез колхоз эшенә, төнен урлашырга җигеп, ике-өч көн эчендә күтәрәмгә китереп җиткерә. Шуннан анасы аша җизнәсенә әйттереп, юньлерәк атка алыштыра. Бу юлы да шулай эшли — Захмайны Нигъмәттән алып җигә башлый. Ә Нигъмәткә йөгәнеп, каеш чыбыркы белән бертуктаусыз кыйнаудан сырт йоннары коелып, тиресе кутырлап беткән Таракан кала. Сәвәләй Закиры, тынычсыз күзләрен Нигъмәттән яшереп, аңа Тараканны тага.

— Шәп ат иде. Карау, тәрбия җитмәгәннән генә азрак йончып китте. Ал инде син бу хайванны, Нигъмәтулла! Башта җиңелрәк эшкә йөрерсең, аннан күз күрер тагын.

— Һе, ал имеш! Сиңа ышанып, ничәмә-ничә атны аякка бастырдым инде мин. Исеңә төшер әле: Әмәт, Дорожный, Шихан, Миңгерәү бия. Хәзер Тараканмыни инде? Ул Таз Камәргә закун юкмы әллә? Бригаданың барлык атларын үз кулы аша үткәрә, бөтенесен эштән чыгарып, ябыктырып кире кайтара. Төне буена бурлыкта йөри кайнешең! Җитәр сезгә!

Нигъмәт, аякларын көчкә атлаган Тараканны җитәкләп өенә алып кайткач, сыерларын сарык абзарына күчерде. Колхозның кладовщигы Пачар Бикие — Нигъмәтнең сугыштан кайтмаган Гыйниятулла абзасының яшьлек дусты. Нигъмәт шул Пачар Бикиеннән сорап, кеше күрмәгәндә генә салам астына салып, ике капчык солы алып кайтты да, Тараканга шуны аз-азлап биреп, аны аякка бастыра башлады. Үзе колхоз эшенә айга якын үгез җигеп йөрде. Тараканга ял бирде. Ай үтүгә, абзардан чыккан ат — тәртә арасына кертеп җигәрлек хәлгә килеп, азрак тазарып, мал төсенә керә башлаган иде. Менә шул көннәрдә хәл алып, тазарып киткән Таракан икенче бригаданың иң эшчән, тырыш атына әйләнә. Икенче елны Таз Камәр Тараканны тагын кире алып җигәргә чамаласа да, Нигъмәт атны аңа бирми. Менә шул көннәрдән соң Нигъмәт белән Таракан һәрчак икесе бергә генә йөри торган булып китәләр...

Бодай йөге төялеп бетүгә, Пачар Бики Нигъмәттән сигез капчык бодай биргәненә кәгазьгә кул куйдырды да үтенгән тавыш белән эндәште:

— Энем, Нигъмәтулла, үтереп тартасы килә, бер урат инде син миңа.

— Мә, мә, Биктимер абзый, тот әйдә.

Ул чалбар кесәсеннән янчыгы белән тәмәкесен чыгарып сузды.

— Үзең дә ура инде син.

— Ярар, барып җиткәч урармын әле. Анда чәчәргә орлык бетә-

дер. Аз гына калды дигән иде Нурый абзый. Тракторларны бүген алып китәргә тиешләр икән. Чәчеп бетерәсе иде шулар киткәнче.

Ул, бодай төялгән йөк аша үрелеп, кладовщик кулыннан тәмәке янчыгын алды да күңелле итеп елмаеп куйды.

— Ну, урыйсың әй, бушка булгач. Бармак юанлыгы бардыр.

Нигъмәткә кушылып Биктимер дә көлде:

— Соң, урамый. Безнең рота старшинасы әйтмешли, гадәтем туган.

Капчык тотыручы бер хатын, кыйбла ягына кулы белән ишарәләп, Нигъмәткә эндәште:

— Китәсең китүен дә, туганым, ай-һай анау яктан яшәреп килә бер болыт. Азрак көт булмаса. Ул-бу була күрмәсен, ходайныкын белеп булмый.

Келәтләр янындагы халык кыйбла ягына карады. Чыннан да, тау артындагы Хәләкәй авылы ягыннан, күптән инде яңгыр көтеп яшәгән халыкның күңеленә шатлык белән бергә шом да уятып, күк йөзен тулаем каплардай булып, кабарып, кара-кучкыл болыт болар ягына таба килә иде. Хатыннарның берсе, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп, укынырга тотынды:

— Йә ходай, мәрхәмәтләреңнән ташлама. Ләхәүлә вәлә куәтә, бисмиллаһир-рахман ир-рахим...

Куркуыннан ике доганы бергә бутап укынган хатыннан Биктимер көләргә тотынды.

— Шулайдыр бик, ләхәүләдер сиңа. Гайнулла белән яшь чагыңда кунып йөргәннәреңнең гөнаһын кая куярсың икән, ә?

— Тфү-тфү, кит. Пачар, әллә нәрсә әйттерерсең. Тәүбә-әстәгыфирулла, кайсы Гайнулла ул тагын, нинди куну, ди. Юкны лыгырдарга булса, сиңа куш! Әнә Нигъмәтне җибәрмә, күрмисеңмени нинди болыт килә...

Күк йөзен каплап килә торган кара болыт, җир өстендә шомлы бер тынлыкка урады. Һава бөркүләнә, авырайганнан-авырая бара. Биктимер, Нигъмәткә карап, аны бик тә үз иткәнен белдереп, әйтә куйды:

— Кайчак хатын-кыздан юньле сүз чыгып куя ул. Син, энем, чыннан да, азрак көт. Китереп, яшенләп салып җибәрсә, кала яланда бер ялгызың нәрсә эшләрсең? Көт азрак, сабыр ит!

Нигъмәт, капчык төяп кызышкан тәненә гимнастеркасын киякия елмайды:

— Ат шәп минем! Ул болыт килеп җиткәнче, тракторчылар янына барып өлгерәм. Ни булса да бүген чәчеп бетерергә кирәк. Тоз түгелмен, эремәмен әле.

Нигъмәт, дилбегәсен кулына алып, атына эндәште:

— Әйдә, Таракан, җилдертик, дускай! Азрак солың да бар. Анысын барып җиткәч инде. Киттек, малкай!

Келәт янында эшләүче хатын-кызлар күңелендә Нигъмәтулла мәңгегә шулай атын иркәләп сөйләшкән һәм елмайган килеш калды. Бер сәгать үтәр-үтмәстә, аның яшен атып үтергән гәүдәсен атына салып өенә алып кайттылар.

Келәтләр яныннан киткәч, тузанлы юл белән чаптырып, Бакый Баткан елгасы күперен җирдән генә чыккан да, аты кырыннан җәяүләп, үргә атлый башлаган. Өч йөз метрлар чамасы ераклыктан моны Нигъмәткә каршы килүче өч тракторчы күреп торганнар. Трактор өстендә чатырдаган тавыш чыгарып, яшен яшьнәп алган. Тракторның моторы эшләүдән туктаган. Тракторчылар, кайсысы бисмилласын әйтеп, кайсысы күзен йомып, тизрәк башларын яшергәннәр. Шулай да мизгел эчендә күреп калганнар: аты яныннан барган Нигъмәтулла, аякларын кабаланмый гына бөкләп, тояклар янәшәсенә бөгәрләнеп яткан. Тракторчылар йөгерешеп

килеп җиткәндә Нигъмәтнең җаны чыккан була инде. Курка-курка гына кузгатып та караганнар, тик егетнең тын-сулышы сизелми. Шулвакыт яздан бирле кәтелгән эре, җылы яңгыр яварга тотынган...

Җансыз гәүдәне өенә кертеп сәкегә урнаштыргач, Сабур Кытыйка Нигъмәтнең гимнастеркасын салдырган. Аның маңгаенда борчак зурлыгы гына кара тимгел икән. Аннан яшен аның бөдрә, йомшак чәчләре арасыннан үтеп, җилкәсенә чыккан да, аркага күчкән. Аркасы агач тамырлары кебек, тармакланып-тармакланып, кара көеп янган. Яшен уты, арка буйлап аска төшеп, уң аягындагы дагалы итеге аша җиргә кереп киткән.

Нигъмәтнең гәүдәсе сәкедән озын булып чыкты. Шуңа күрә аяк очына бер утыргыч куеп, аның өстенә үзенең колхозда эшкә киеп йөргән ямаулы куфайкасын җәеп, аякларын шуның өстенә суздылар.

Ул көнне кичкә кадәр, икенче көнне өйлә җиткәнче, авыл халкы Нигъмәтулла белән хушлашырга агылды. Кешеләрнең берсе керде, берсе чыкты. Ишегалдында, урамда, төркем-төркем булып җыйналып, озак таралмый тордылар. Үлгәненең икенче көнендә аны җирләделәр. Кәфенләнгән гәүдәне зур чүпрәк паласка төрделәр дә, ишек алдына алып чыгып, Таракан җигелгән арбага салдылар. Еллар буе күрше дә, яхшы абзый да булып яшәгән Мәчтәк Габдерахманы Нигъмәтулланы соңгы тапкыр сурәткә төшерде. Аннан соң, дулкынланудан кызарып чыккан шадрарак битен боргалап, халык арасыннан кемнедер эзләде. Эзләгән кешесен тапкач, фотоаппаратын өчаягы белән энесе Файзырга тоттырды да халык арасына титаклап кереп китте.

— Әйдәле, туган, бас дустың янына. Мәрхүм Нигъмәт сине бик ярата иде. Дустың белән мәңгелек истәлек итеп төшерим әле сине.

Габдерахман абзый халык арасыннан җитәкләп алып чыккан малай, былтыр җәй буена диярлек колхоз эшендә Нигъмәтулла белән бергә эшләгән, бу вакытларда унынчы сыйныф өчен язгы сынаулар биреп йөргән, туктаусыз елаудан битләре шешенеп беткән Зиннур иде.

Картлар, җомгадан чыгуга, Нигъмәтулланы зиратка алып барып җирләделәр. Карт мулланың, йөрәк кылларын өзгәләп, моңлы мәкам белән догалар укыганын тыңлаган Зиннур, күзеннән өзлексез аккан яшьләрен туктата алмыйча, яңа гына казылган кызыл балчык өеме янында тезләнеп озак утырды. Аның башы кичәле-бүгенле булып үткән хәлләрне сыйдыра алмый һәм ул үзен ниндидер сөрем, төтен эчендә утырган кебек хис итә иде. Кырык икенче елны Харьков каласы янындагы язгы һөҗүм вакытында, каты җәрәхәт алган, Нигъмәтнең бертуган абыйсы Рәхмәтулла да елаудан шешенгән күзләрен җирдән күтәреп карый алмый. Гәүдәсенең сул ягы фашист авиабомбасы кыйпылчыкларыннан телгәләнгән аның. Бүген ул бердәнбер тәргә булган таза, көчле гәүдәле, арысландай энесен җир куенына бирә. Дөнья михнәтләренә һәм нужаларына тулы көннәр, атналар, еллар белән көрәшергә япа-ялгыз торып кала.

Нигъмәтулланы җирләп, коръән сүзләрен соңгы тапкыр укыгач, күмешергә килгән халык тавыш-тынсыз гына таралды. Яңа күмелгән кабер янында Рәхмәтулла белән Зиннур икәү генә утырып калдылар. Кабернең тирә-ягы үткән ел көздән калган ак кылган белән капланган. Аннан ерак та түгел, заманында күпләрне сокландырып, берберсенә матур итеп беркетеп ясалган зур таш коймалы, сирень куаклары каплаган, еллар-җилләр, яңгыр-карлар шомартып тоныкландырган иске кабер тора. Бу кабердә үткән гасырда авыл мәдрәсәсенең атаклы мөдәррисе булган Нигъмәтулла Тукаев мәңгелек йокыга талган. Хәзер аңа күршегә юаш, эшчән Нигъмәтулла Габсаттаров кабере барлыкка килде. Иске каберне каплап үскән сирень агачлары, зират эчен хуш искә манчып, чәчәк атканнар. Нәфис исләр, тирә-

якны биләп алып, яңа кабер янында тезләнеп утырган, кайгыдан башларын түбән иеп сызланган ике кешене дә уратып алганнар. Бу исләр алар күңелендәге юксынуны көчәйтә, бертуктаусыз аккан күз яшьләрен арттыралар иде. Ничәмә еллар шул куе сирень агачлары эчендә оя корган, парлашып бала чыгарган сары сандугачларның берсе кыюсыз гына сайрау авазы салды. Сайрый башлап, зиратның авыр тынлыгын бозганын сизгәч, туктап тыңлап торды. Озак та үтмәде, әлеге кабердән ерак та түгел үскән икенче куак эченнән аңарга бүтән сандугач җавап бирде. Бераздан исә зиратның төрле почмагында сайраган төрле сандугачларның моңы — мәңгелек йокыга талган асыл затларны тибрәтә кебек иде.

* * *

Нигъмәтне җирләп берничә көн үтүгә, Тараканны тагын Таз Камәре җигә башлады. Шул көннән соң атна үтәр-үтмәстә, ябыккан, чыбыркы белән кайналган атның сырт йоннары коелып бетә язды.

Дусты исән вакытта ул, колхоз дворыннан Банҗур Ибрай чыгарып җибәргәч, һәркөнне иртән туры Нигъмәт йортына кайта иде. Капка янына җиткәч, кече капка келәсен тартып ача торган нечкә каешны бәрхет иреннәре белән кымтап каба да тарта. Келәнең ачылган тавышы ишетелгәч, каешны иреннәреннән ычкындырмыйча, капканы башы белән тартып ача һәм ишегалдына уза иде. Кайтуына, болдыр янындагы җиз таска салып, Нигъмәт аның өчен азрак солы яисә бәрәңге кабыгы әзерләп куя иде.

Хәзер Таракан кече капканы ача алмый. Чөнки Нигъмәтнең абыйсы келә каешын алып ташлаган. Килүче кешеләр кече капканы куллары белән өстән үрелеп ачалар. Ә ат алай эшли белми, ул капка төбендә кешнәп таптана башлый. Рәхмәтулла Тараканны берничә тапкыр энесеннән калган җиз тәңкәле йөгән кидереп, колхоз дворына кире илтеп тә куйды. Әмма Таракан икенче көнне иртән тагын кайтты, тагын кешнәде. Рәхмәтулла, сыктап елаган йөрәген баса алмыйча, Тараканны чыбыркылап куып карады. Тик яхшы хуҗасын югалткан хайван, аңламыйча, һаман кайтты, һаман үзенең сөекле дустын эзләде. Капканы ача алмагач, алгы аягы белән тырнап, аның такталарын ватып бетерде.

Тик Таз Камәр Тараканны Нигъмәтнең капкасы янына кайтудан туктатты. Берничә көн иртән капка төбендә көтеп алып, каеш чыбыркы белән яра-яра үзенең өенә алып китте. Шуннан соң иртәләрен Таракан Нигъмәт капкасы янына кайтмас булды. Ә Таз Камәрдән кача башлады. Соңгы качуында берничә көн авыл очындагы куе таллыкта яшеренеп яшәде. Таз Камәр, табып алып кайтып, колхоз сарае эчендәге юан баганага башын күтәртеп бәйләп, каеш чыбыркы белән сәгатькә якын кыйнады.

Тирләп-пешеп мәктәпкә килеп кергән Банҗур Ибрайның улы Халит геометрия буенча барган консультациядән Зиннурны эзләп тапты.

— Тизрәк, Зиннур! Анда Таз Тараканны кыйнап үтерә. Әйдә!

Тараканның башын каерып бәйләгән җиреннән, зур кыенлык белән чишеп, урамга алып чыктылар. Җылы һавага чыгу белән ат, хәлсезләнеп, аякларын бөгеп, үләнгә ята башлады, тик Зиннур белән Халит, аңа ятарга ирек бирмичә, тугай буена алып киттеләр. Кояш кичкелеккә авыша башлаганда, атны тышауламыйча гына колхоз атлары янында калдырып, ике малай күңелсез генә өйләренә атладылар.

Икенче көнне авыл гөж килде! Иртән, сыер көтүен авылдан алып чыгып барган көтүче Мукшы Вәчили белән аның уН яшьләр чамасындагы улы, таш койма белән уратып алынган авыл зиратының

капкасы төбендә, Тараканның үле гәүдәсенә юлыкканнар. Ат, дагалы аякларын бөкләп, астына тыгыбрак яткан да муенын сузып, башын такта капкага терәп үлгән. Гүя, ул шул такта капканың эченә кереп юк булган, йөрәге белән сөйгән дусты Нигъмәтне күрергә өмет итеп, күзләрен капка ярыгы аша зират эченә текәп җан биргән...



• • •

Бодай урган көннәрнең берсендә, кичләтеп бригадир Сәвәләй Закир йортына Зиннур килеп керде. Закирның хатыны Гайшә апа аны кече капкадан кергән чагында ук күреп алып, иренә эндәште:

— Әй, сиңа әйтәм! Лотфулла абзыйның төпчек малае Зиннур кереп килә, бар каршы чык. Берәр йомыш белән киләдер. Әтисе бахыр, үзләренең лапас абзарын сүткәндә, егылып төшеп, билен имгәткән, йөри алмый ята икән хәзер.

Бригадир белән Зиннур ишегалдында, келәт янындагы бүрәнәгә утырып сөйләштеләр:

— Шуннан, энем, эшләр ничек? Ун сыйныфны бетердең инде син, шулай бит!

— Бетердем, Закир абзый. Аттестат алдым.

— Нәрсә эшләргә уйлыйсың инде хәзер? Ничек яшәргә?

Зиннур азрак дәшмичә утырды, аннан гозерен әйтте:

— Мин, Закир абзый, сиңа эш сорап килдем. Син миңа Захмайны бир инде.

Закир аптыравын яшерә алмады.

— Туктале, энем, синең бит ун класс белемең бар. Син бит зур укымышлы кеше безнең өчен. Ә син ат җигеп кара эшкә чыгарга исәп тотасың. Сәбәбе нәрсәдә?

— Соң, сәбәбен үзең беләсең инде — нужа белән фәкыйрьлек. Институтка китәргә хәл юк безнең. Әтинең карап торган бер кәҗәсе белән ике сарыгы гына бар. Абый армиядә. Апа кияүгә китте быел. Аннан соң өскә киярлек юньле кием дигәндәй... Әле килеп,әти дә имгәнде...

Зиннур,тамагына килеп тәялгән төерне көчләп йотты да,дәвам итте:

— Түшәмгә бәйләнгән бауга тотынып кына урыныннан тора, аннан аркага күтәреп, үзем тышка алып чыгам. Мин карамасам, кем карый аны?!

— Шулай икән... Тик сине бик шәп укый диләр иде бит. Укырга кирәк иде сиңа. Бу кара эштә без изелгән дә җиткән.

— Ярар инде, Закир абзый, сүзне бетерик. Кайтырга кирәк. Син миңа Захмайны бир инде шулай да.

— Нигә Захмайны? Бурлы бияне ал. Ул шәбрәк бит!

— Юк, син миңа Захмайны бир. Мин аны Нигъмәтулла абыйның төсе итеп җигәрмен. Таракан исән булса, мин синнән аны сорар идем дә, ул юк бит инде...

Бригадирның йөзе караңгыланды.

— Ярар алайса, Зиннур. Синеңчә булсын. Ибрай бабаңа әйт, сиңа Захмайны бирсен, яңа тәгәрмәчле арбаны ал. Пачар Бикиеннән бүген үк капчыклар сора. Иртәгә Ялгыз Каен яланында урган комбайннан бодай ташый башла. Капчыкларны тотыручы кызлардан капчыкларны җиргә ташлатмыйча, комбайн мәйданчыгыннан күтәреп ал, җирдән күтәрергә калса, көч килә...

Закир абзый, азрак эндәшмичә бер ноктага карап утырды да, эчке бер яну белән өстәп куйды:

— Игеннәр уңды быел. Бигрәк тә шул Ялгыз Каен яланындагы бодайлар шәп булды. Нигъмәтулла чәчкән бодайлар...

# Нури Арсланов

## Төшмим

Таулар менү ансат димсең әллә?
Дөрес түгел бер дә!
Төшү тагы да кыен, баш әйләнә,
Түбән карый күрмә.

Инде менмәм — меналмамын артык,
Авырын үттем юлның:
Тик төшмим дә элеккемнән кайтып,—
Кыяларда урыным!

*1989—1990*

## Яфраклар коелганда

Җиргә төшкән һәрбер сары яфрак
Өзелеп төшә төсле йөрәктән:
Мине болай, узганнарны ядлап,
Сызланырга кемнәр өйрәткән?!

Заман безне кире юлга куды,
Ышанычлар һаман алданды:
Бөтен вәхшәт күз алдында булды,
Бергә булды чыны, ялганы...

Чыным һәр дәм үземнеке иде,
Ә ялганны көчләп тактылар...
Әйтерсең лә мескен колны — мине —
Буйсынучан җанны таптылар.

Ватан сагышы Иделләрдән ашты,—
Йозакланган иде уй, теләк,
Азатлык һәм шатлык ерак качты,
Яшьле күзләр торды мөлдерәп...

Сулды дөнья... Өзелмәде өмет,
Кыйналсам да рухи богауда!
Тик суларың, Идел, җитмәс кебек
Корбаннарның канын юарга...

Һәр өзелеп төшкән сары яфрак
Өзелгән бер гомер шикелле...
Хәят чиксез, ул гел бара атлап!
Ә мин тоям инде чигемне.

Шулай да ир таба ибен-җаен:
Яшәү тәмен татыдым бит бераз,—
Шуңа сары көзләр җиткән саен
Искә төшә күкрәп яшел яз.

*1989—1990*

---

Нури АРСЛАНОВ *(1912) — күренекле шагыйрь, татар, казакъ, рус телләрендә дөнья күргән күпсанлы шигырь, тәрҗемә китаплары авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты. 1991 елның 14 апрелендә вафат булды.*

## Андыйлар баш ими

Кешеләргә шигырь бәхет өләшсә дә,
Кайсы шагыйрь үзенә рәхәт тапканы бар?!
Овидийне, бәхет өчен көрәшсә дә,
Язмыш илдән еракларга атканы бар...

Язык булмас монда бераз арттырсак та:
Бөек җырчы тарих яралганга хәтле
Җырлаган ди, ялыкмыйча гел бер хакта,—
Кешеләрдә изге хисне — мәхәббәтне.

Варислары аның бездә һәйкәл булып
Себерләрдә бозга дүнде, катып калды,
Күз яшьләре һәм кан җиргә төшми туңып,
Карлы юлда асылташтай ятып калды...

Кәфенлеләр өне йолдызларга бәрелеп
Чыңлап торды, моңы өзде үзәкләрне!..
Хәят мескен дер калтырап, каушап, әрнеп,
Тоеп торды газраилләр күзәткәнне.

Овидийнең рухы Дунай буйларында
Әле дә йөри икән диләр Римны барлап.
Ә бездәге миллионнарның рухы монда
Дошман тапмый йөри икән кемне каргап?!.

Мин-җырчы да йөрдем күпләр арасында,
Кайчан миңа атар диеп тартылган ук,
Бөтен дөнья үзгәрде күз карашымда:
Өем дә юк иде минем, Римым да юк...

Читтә калдым мин Овидий язмышыннан:
Сугышлардан сугышларга ташландым мин.
Каушасам да «тыныч ватанымда» шомнан,
Мәйданнарда дошманнардан качмадым мин!

Овидий юк — күп гасырлар инде гүрдә,
Ләкин рухы чагыла дөнья язмышында:
Азат җаны азат илләр белән бергә,—
Андыйлар баш ими язмыш ялгышына!

*1990*

## Батыр калыр

Уянгандай мәрткә китеп йоклаучылар да,
Уяныр бер халкым минем, килер аңына.
Кемнәр анда? Ашыкмагыз ясин чыгарга,
Иртә әле аны гүргә илтеп салырга!

Торыр ул, аякка басар пәһлеван булып,
Җиң сызганып киң һәм якты мәйданга атлар,
Килгән кебек дөньяларга яңадан туып,—
Мәһабәтен күреп, каушап калырлар ятлар.

Ул куптармас бабайларның шомлы мирасын,—
Ник кан кою?! Әгәр вакыт ирек өләшсә?
Тик көрәшсез булмый ирек, беләбез ансын! —
Батыр калыр ул татарча гадел көрәштә.

*1990*

## Мәңгелек турында

Дөньяга килгәндә кеше ваемсыз бала икән.
Үсә-үсә үзен-үзе борчуга сала икән:

Йосыф үлмәсә дә канлы кулмәге калган диләр,
Мәҗнүн йөрәгеи мәхәббәт телгәләп ярган, диләр.
Таһирлар кабердә... Зәнки — арада ята, диләр,
Фәрһад гыйшкы, силләр булып, кыялар вата, диләр...

Илләр-халыклар югалса, хәрабә кала икән,
Хәрабәдән, тамыр җәеп, яңа ярала икән.
Һәрбер әйбер дә искереп көлгә тарала икән:
Матдә матдәгә әверелеп үзгәрә бара икән.

Дөнья куулар кешегә кирәкле чара, имеш:
Шул юлда ул йә ир-егет! Йә бер бичара, имеш...
Ничек тә һәммәсен байгош кичерә ала, имеш.
Уйласаң, яшәү һәм үлем бер адым ара, имеш...

Ләкин МӘҢГЕЛЕК КОЯШЫ һәр таңда яна икән! —
Тереклек моңа шатланып бәхеткә тала икән,
Шул бәхет нурында дөнья бездән дә кала икән...

*1987*

## Сәйдәш моңы

Яңгыратып ерак узганнарны
Данлы «Кызыл гаскәр» маршында
Йөрәкләрнең үлмәс генералы
Сәйдәш басып тора каршыда.

Мин гомеремдә күпме тылсымчылар,
Күпме илләр көен тыңладым.
Алыштырмыйм ләкин тән чымырдар
Гаҗәп серле Сәйдәш моңнарын.

Ул рояльдә, гармун телләрендә,
Оркестрда сыкрый-сызлана,
Алып китә гарәп чүлләренә,—
Уйларында кәрван кузгала.

Бөек Тукай сүздә әйткәннәрне
Әйтеп бирә көйләп халкына:
Моңнарында Илнең бәхете, гаме
Халкы белән бергә талпына.

Бер татлы, бер күз яшедәй ачы —
Үзәкләргә үтә тавышы:
Күңелләрнең сайрар сандугачы
Сайрый безнең кыен язмышны.

*1989*

## Карулашмыйм

Әйләндермә башкаемны, Ләйсән,
Ул болай да бик еш әйләнә:
Шулай дим дә, китәр идем әйтсәң,
Карулашмый бер дә «әйдә!»ңә.

Тарткан белән Акыл авызлыкны,
Гел котыртып тора бит Өмет,
Нәфес үртәп тора һаман шукны:
«Бәхеттән баш тартма!» ди көләп.

Уыз төмен дә бит таткан идем...
Кайда инде хәзер уызлар!

Күпләр кебек мин дөньяга килдем,
Уйнамады безгә кубызлар...

Туйсыз үтте гомер, тик калдыгын
Үткәрергә иде күңелле.
Юк, дауламыйм бер дә мин артыгын,
Телим фәкать: зәңгәр күгемне

Болыт капламасын. Кояш төшеп,
Балкып торсын иде тирәмдә.
Син әйт кенә,— китәм җитәкләшеп,
Карулашмый «әйдә!» дигәнгә.

*1989*

## Ялгыз аккош

Мин — канаты каерылган аккош,
Гаҗәпмени әгәр очмасам?
Кайдан алган сабырлыкны байгош,—
Талпынмый да күңел ичмасам.

Болытларда аккош кәрваннары,
Әллә сөзелә, әллә кагына?
Җитәр алар, кичеп ал таңнарны,
Дөньяларның җылы ярына.

Мин тын күлдә ялгыз аккош сыман,—
Ник яралы җанны кыстарга! —
Дөнья матур көзнең алтыныннан,
Озакламас көмеш кышлар да...

*1990*

❀

Кеше үзенә канун сипли,
Канун аның юлын чикли.

❀

Кем гомерендә иң соңгы кат яхшылык кыла,—
Элек кылган яманлыгы шундук онтыла.

❀

Талау, сую, таптау, сугыш-кырылыш —
Таҗ-тәхетләр хөкем сөргәндә,
Акыл, мәдәният, тыныч тормыш
Һәм шигърият була сөргендә...

---

Уыз — угыз, бозаулаган сыерның беренче сөте. Аны эчкән кеше бәхетле була, диләр.

Зәвык, ләззәт кагыла күңел кылларына,
Сокланам мин бөек сәнгать эшен күреп,—
Шатланам мин синең гаҗәп җырларыңда
Нәфасәтнең изге тылсым көчен күреп.

## Түгелә йолдыз

Көянтәләп алтын ташый шук киленнәр,
Ай нурында чиләкләрдән түгелә йолдыз,—
Болар нишләп суга болай соң килделәр,
Дисәм,— сылтау тапкан икән яшь хатын-кыз:

Көзгедәй күл, күл буенда алтыбакан,
Анда даган атына җырлар, уен-көлке...
Бу кешеләр ник шатлана, нәрсә тапкан,
Дип йөридер төсле посып бүре, төлке.

Җырлар җырлап Сарарканың даласында
Минем дә түбәм күккә тигәне бар! —
Бия сауган яшь киленнәр арасында:
«Акын икән гой бу бала», дигәне бар.

Күп йөргәнем бар козгойрык[2], җауказыннар
Яшел япкан Каркаралы тауларында.
Йөри идек егет дигән без «азгыннар»
Шаңырактан төшеп кызлар аулагына.

Кыю, тапкыр кызлар гел исемдә:
Сүзләреннән күпме рәхәт тапканым бар!
Акан-сире колагирен[4] менмәсәм дә,
Җилдән узып конаннарда чапканым бар.

Шуннан бирле һич иярдән төшкәнем юк,
Чапмасам да инде, шөкер, җилеп барам:
Мәңгелеккә абелхәят әчкәнем юк,
Ә шулай да сиксәнемә җитеп барам.

Гүя тагын көянтәләп шук киленнәр
Йолдыз ташый, юлларыма түгелә алтын:
Син бәхетле, диләр миңа, син бай, диләр...
Мин байлыкны далам туфрагыннан алдым!

Улжам[5] уртак булды, тәңрем кабул итсен.
Элеккедәй тузмаса да юллар чаңы[6],
Мин һаман да тоям әле дала исен...
И гомернең болыт кунмас аяз чагы!

*1990*

---

Сарарка — Сары арка — Арал белән Иртеш арасындагы дала.
Козгойрык — Козы койрык — кыргый, вак тау кәбестәсе; жауказын — тау юасы.
Шанырак — киез өйнең түбә укларын беркетә торган түгәрәк корылма, төнлек.
Акан-сире — бөек казак акыны. Колагир — аның данлы чабышкысы.
Улжа — табыш, уңыш.
Чаң — тузан.

# Нурия Измайлова

## Улларыма исем куштым

Исемнәре чакырып торсын,
Алга омтылсыннар дип,
Зурына Искәндәр куштым,
Кечесенә Солтан дип.
Исемнәрен ишетүгә
Карасыннар тукталып.
Без — каратырлык халык:
Улларыбыз туа әле
Чәчрәп торган карашлы.
Искәндәр[1] дә, Солтаннар да —
Шул ук адәм баласы.
«Кем булса да, ярар!» димә!
Ярамый, кем дисәң дә!
Улым әнә стенадан
Үрмәли ич түшәмгә!
Күкне күрсәтеп: «Кю-кю!» ди
Ачылмаган телләре!
Ә безнең уллар үрләве —
Ул халыкның үлмәве!
Ә «Хәрәкәттә — бәрәкәт»
Дигән милләт — кем әле?..
Ничек тә бер сынык икмәк
Табып була ул ансы.—
Тамак тую гынамыни
Яшәүнең бар гыйлләсе?
Нинди шатлыклардан дисез
Йолдызлар балкып тора?
...Ә аста калган халыклар —
Казылма байлык була...

## Улыма дога

Улым сары бәбкә генә,—
Усал тилгән тимәсен.
Улым алсу чәчкә генә,—
Усал җилләр тимәсен.
Улым нәни чеби сыман,—
Усал чирләр тимәсен.
Улым чибәрләрдән-чибәр,
Усал күзләр тимәсен.
Улым бирәү генә җирдә,
Җеннәр алыштырмасын!
Улым! Бирмәм сине җенгә.
Үзең алышынма син!
Дөньяны, әлбәттә, иңлә,
Асылыңны җуйма син!
Таяныр талыңны җуйма —
Иман алыштырма син!
Үз догасы — һәрбер чорга,
Син — бу чорда тугансың.—
Дога алыштырма син!

## Хәл шулайрак

Әй, быел октябрь буе
Куандым да юандым,
Ни теләсәм шуңа юрап
Бу әбиләр чуагын:
Октябрьгә калган булгач,
Ул гадәти түгелдер.—
Димәк, үзгәрәчәк быел
Бар агышы гомернең.
Ә үзгәреш — күптән көткән,
Күктән төшкән алла ул.
Ул — бары бәхет китерә!
Онытабыз — алдавын...
Үзгәреш — начарга булмый.
Без — иң үҗәт оптимист.—
Начарны кире кагабыз,
Җитмеш мисал бар килеш...
Хәер, аска бер су кергәч,
Яңгырдан курыкмыйсың!
«Ике рәхәт бергә булмас»
Дигәнне дә хуплыйсың...
Хәл шулайрак — һәр яңалык
Яхшыга юралырга.
...Ура! Октябрьгә калган
Әбиләр чуагы да!

---

Нурия ИЗМАЙЛОВА — *шагыйрә, «Яратам», «Алтын тарак» һ. б. шигырь китаплары авторы. Проза әсәрләре дә яза. Мәскәүдә яши.*

[1] Искәндәр — биредә: Александр Македонский исгә тотыла.

## Шомлы заманда

Төштә — ат...
Үлемгә диләр,
Төшемгә диләр,
Китемгә диләр,
Бетүгә диләр.
Ни икән?
Ат бетү микән?
Кот китү микән?
Йот[1] төшү микән?
Әллә... мин микән?
Ходай дим!
Балаларым бар,—
Алмый тор мине!
Балаларым бар,—
Сакла бу илне!
Балаларым бар,—
Ачлык китермә!
Балаларым бар,—
Атны бетермә!
Атлы милләтнең
Милли улларын
Ашсыз һәм атсыз
Итмә, ходаем!
Хак түләмичә
Китсәм, кичермә...
Ләкин тәмугны
Җиргә китермә!
Алма йортымны!
Алма котымны!
Син харап итмә
Шушы токымны!

## Вәсвәсәле минутларда

Күчмә кошлар бигрәк моңлы сайрый! —
Сагына белгән кошлар бит алар.
«Сагыну» сүзе — түрдә — безнең телдә.
Ә тел һәм рух ахры бер каннан.

Корабка су кергәч, акыллылар
Кача икән, инде ни көтә?..
Бездә акыл тирән түгелдерме,
Артык тирәндерме лирика...—

«Монда тудык, монда үстек инде,
Монда сайрап токым арттырыйк.
Бу ил белән кара булдык инде,
Бу ил белән инде ак булыйк!»

## Кырымда

Гүзәл Кырым — энҗеле калфактыр.
Энҗеләре артсын елтыр-елтыр.
Татарлары кайтсын үз иленә.—
Үз илендә һәркем энҗе бит ул!

❁

...Бөтен нәрсә монда илаһидыр.
Бу мәһабәт горур камиллек
Бер сызыгын үзгәртсәң дә, рәнҗеп,
Токымыңны каһәрләр кебек.

[1] Йот — бу урында, афәт, үләт (мур) мәгънәсендә.

Шушы камиллекне зар елатып,
Кемдер халык кадәр халыкны
Йолкып алган. Ничек ходай сукмый!
(Әллә ходай чынлап та юкмы?!)
Суккан мәллә? Гаепләләр юк ич!
— Табарсыз, тик ачкач тәмугны!

## Төпчек улым тугач

Яшьлек белән хушлашу бу —
Күзләремнән яшь тама...
Мәңгелеккә тоташу бу —
Эчкә сыймый тантана!

Бөтен нәрсәм булды инде!
Күңелдә бар кыл-көем...
Иң шатлыклы гимндыр бу!
Иң сагышлы реквием...

## Үзгә йолдыз нуры

Алсу болан — дөньяда да булмаганча,
Тезләнгән дә — боланнарда булмаганча.
Муеннарын сузып, кардан китеп бара,
Тезләреннән тезелеп-тезелеп эзләр кала.
Күзләренә яшьләр тулган — акмый гына,
«Кызганыгыз!» дияр сыман — әйтми генә.
« Ни эзлисең?» димим, күрәм сулавыннан —
Сөю эзли... Әй, кыз болан! Әй, кыз болан!
Нинди сөю бу караңгы, җансыз мартта,
Сирәк урман үтә күренеп торган чакта!
Бу заманда! Сулар кипкән, кошлар беткән,
Дөньяларның ходай биргән күрке киткән...
Нинди сөю, җирне чир һәм корт басканда,
Җирдән шәфкать, изгелек һәм кот качканда?!
Алсулыгың нигә синең? Ах итмәсләр.
Арзан хәзер садә хисләр һәм саф яшьләр.
Һәм мәхәббәт юк тезләнеп ялварырлык!
Җан сакласаң, шуңа шөкер, шул — бар өмет.
Ә токымың калдыралсаң, бәхетең булып,
Тупырдап үт, күкрәгеңне киерә биреп!
Сиңа көнләп карап калсын барча болан...
... Ах, нигә син алсу булган? Алсу булган...
Сиңа тиеш Сөю үлгән... Сырхау — урман.
Әллә син бу планетага ялгыш туган?
Сине үзгә йолдыз нуры коендырган,
«Җир» йолдызы гөнаһ алган — сыендырган...

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Заһир Садыйков**

# ЯСАЛМА ЧӘЧӘКЛӘР

ПОВЕСТЬ



Баш врач булмәсенә, «Мөмкинме?»— дип, бер кыз килеп керде. Артык кыю иде, ишекне дә шакып тормады, тартынып-нитеп тә маташмады — килеп тә керде, түргә дә үтте.

— Мин шәхси эш белән кердем,— диде тәкәллефсез генә.

«Тагын берәр шикаятьтер инде, баш врач янына рәхмәт белән керәләрмени?»— дип уйлады Чыңгыз.

Кыз үзен әллә ничек сәер тота иде. Каядыр ашыккан, эшен тиз генә бетереп чыгарга кергән кеше шикелле, бер җирдә генә тора алмый, утлы табага баскан шикелле таптана, як-ягына боргалана.

— Рәхим итегез, утырыгыз,— диде Чыңгыз, сүзнең озакка сузылачагын сизеп, үзе кәгазьләрен читкә үк этәреп куйды да, гәүдәсен артка ташлап, дикъкать белән кызга төбәлде. Кыз да керфек астыннан аңа бер кыска, сак караш ташлап алды. Шул мизгелдә Чыңгызның йөзенә ягымлы нур сирпелгәндәй булды, күз аллары балкып китте. Бары тик хатын-кыз алдында гына кабына торган, инде онытылган, әмма таныш, якын, кадерле һәм изге бу ялкын аның хәтерендә ләззәтле, якты дулкыннар кузгатты. Кыз искитәрлек дәрәҗәдә Аңа — Диларәгә охшаган иде...

Әй күзләр, күзләр! Кеше матурлыгының күркәм бер юлдашыдыр сез. Сез — җан көзгесе. Сез чәчәкләр кебек төрле һәм, чәчәкләр кебек үк, гүзәллекнең иң югары билгесе.

Чыңгыз, кызга артык төбәлеп карамас өчен, башын иеп, чәчләрен бармаклары белән җентекләп аралый-аралый, уйга калды. Әллә кызга артык тирән карады микән ул? Юк, иркәләп, үз итеп кенә карады ич. Шундый охшашлык аны сискәндереп кенә алды лабаса... Кыз, беравык икеләнеп торганнан соң, Чыңгыз күрсәткән урынга, озын өстәлнең сул ягындагы кәнәфигә килеп утырды.

— Йә, тыңлыйм?— диде Чыңгыз, ниһаять.

— Мин моннан китәм,— дип башлады сүзен кыз.

— Кая китәсез?

— Белмим... Кая булса да!..

Кызның утыруында, гәүдә тотышында, җиңелчә генә калтыран-

---

Заһир САДЫЙКОВ *(1951) — «Ялгышсыз язмыш» повесте һәм көндәлек матбугатта чыккан сатирик хикәяләр авторы. Казанда яши.*

ган бармакларында, юка, ләкин горур җилкәләрендә, чем-кара чәч дулкыннарында күзне генә түгел, йөрәкне дә җәлеп итәрлек аерым бер нәзакәтлелек, күркәмлек бар иде. Каушау аркасында тагын да бераз агарып киткән йөзе, тигез кашлары, шәрыкча бераз кара күзләре, кечкенә генә туры борыны, иреннәре нәкъ Диларәнеке кебек.

Туктале!.. Кинәт исенә төште Чыңгызның: бу кызны — Диларәгә охшаган кызны әлек кайдадыр күргәне бар түгелме соң аның?! Тик кайда? Кайчан?

Әйе, узган җәйдә, комбинат ашханәсенә кереп барганда баскычта очраткан иде ул аны. Кыз, ашханәдән чыгып, баскычтан төшеп килә иде; Чыңгыз, гадәтенчә, уйланып барган җиреннән кинәт башын күтәреп, шушы сылу кызны күреп, сыны катып калган иде. Күктән иңгән, һич көтелмәгән бу очрашу, бу сәер охшашлык аны шундый тәэсирләндерде ки, ул хәтта исен-акылын җуеп торды, кызның кая китүен карап калды. Ләкин кыз халык арасына кереп югалган иде инде.

Кызның моңарчы бу комбинатта күренгәне юк иде. Киләчәктә ничек тә эзләп табарга, кем икәнен белергә, һич югында читтән генә булса да тагын бер мәртәбә карап калырга, дип үз-үзенә искәртеп куйган иде Чыңгыз ул чакта. Искәртте дә, онытты да. Эшкә муеннан гына түгел, башы-аягы белән чумган, яңа шифаханә төзү эше белән ду килеп йөргән Чыңгызның вакыты шактый тыгыз иде шул. Гомумән, ул кешеләр белән башкалар кебек тиз генә, җиңел генә таныша алмый, ә хатын-кыз белән танышу өчен аңа шактый гомер, аның күңел нечкәлеген, уй-тойгылары тирәнлеген ачып салырлык гадәттән тыш шартлар кирәк кебек иде. Шушы холкы аркасында Чыңгызның дус-ишләре, таныш-белешләре дә күп түгел һәм, шуңадыр ахрысы, ул аларның кадерен бик белә иде. Юкка-барга сарыф ителмәгән йөрәк җылысын ул алар өчен саклый, дуслыкка, урнашкан мөнәсәбәтләргә бик сак һәм җаваплы карый иде. Аның шундый бераз йомыклыгын кайберәүләр тәкәбберлек дип кабул итәләр иде булса кирәк.

Икенче тапкыр бу кызны моннан бер ай чамасы элек, поликлиникада күргән иде Чыңгыз. Кыз беренче каттагы олы көзге каршында ыспайланып тора иде. Ә Чыңгыз исә, эшен бетереп, кире үз бүлмәсенә менгәндә игътибар итте: ул әле һаман көзге каршында! Чибәрләр көзге ярата шул. Көзге яратмаган кеше чибәр дә, пөхтә дә була алмый — анысы да бар. Врач бүлмәсе янында утырмагач, кызның ни сәбәпле поликлиникага килүен, кайсы врачка керергә теләвен сорау кыен да, уңайсыз да иде.

Әллә артык игътибар белән карады микән ул чакта Чыңгыз бу кызга? Бәлки, кыз шуны сизгәндер?.. Аңа — буйдак, җитәкче кешегә — хатын-кыз белән салкын гына сөйләшү гадәте алыштыргысыз бер нәрсә кебек иде. Ә күзлеге исә аның күзләрендә чагылган кичерешләрне яшерә, гүя күңеленнән очып чыккан очкыннарны каплап-яшереп тора. Шунлыктан, күзлек кигәндә ул үзен калкан тоткан кеше сыманрак хис итә. Һәм күзлек аңа башкаларны күзәтеп, үзен сер итеп сакларга ярдәм итә кебек иде. Менә шул, врачларга гына хас аерым бер сизгер күзәтүчәнлек, һәр төсмерне нинди дә булса фал итеп кабул итү, очраклы хәлләр арасында да ниндидер бәйләнеш эзләү, аларны юрау һәм аннары аларның дөреслеген тикшерү гадәте Чыңгызның күңелен нечкәртә, уйларын тирәнәйтә, тойгыларын баета, фантазиясен күпертә, тормыш тәҗрибәсен яшенә караганда күпкә арттыра иде. Шуңадыр ахрысы, ул гаҗәеп бер сизгерлек белән башкаларның күзенә дә чалынмаган әллә нинди нечкәлекләрне күрә, сизә, белә кебек иде.

Чыңгыз Исламович кызның үз-үзен тотышыннан, сүзләреннән эзсезлегеннән аның нигә кергәнлеген тойды. Тик, нишләптер, әллә

кызны Диларәгә охшатканга, каршысында озаграк утыртасы килеп, әллә аңа шушы гаҗәеп охшашлык өчен бер илаһи изгелек эшләргә теләп, сүзне кинәттән өзмәскә булды.

— Мин монда калалмыйм...— дип өзгәләнеп дәвам итте кыз, баш врачның бүтән сораулар бирмәячәген тәгаен аңлагач. Билгеле, ул Чыңгыз Исламовичның сүзсез калуын аңа теләктәшлек йөзеннән тынычлану мөмкинлеге бирү дип кабул итте.

— Авырга уздыгызмы?

— Әйе.

— Ә нишләп соң миңа кердегез, алай булгач, безнең гинеколог бар ич? Хатын-кыз үзе...

— Кералмыйм мин аның янына...

— Миңа керергә берәр кеше киңәш иттеме?

— Юк, үзем кердем.

— Ни өчен турыдан-туры миңа кердегез?

— Хатын-кызга аңлату кыенрак...

— Соң, мин бит гинеколог түгел.

— Мин сезнең баш врач икәнегезне белмәдем, мондый врач кына дип уйлаган идем. Ир врач итеп сезнең янга кердем.

— Ярый. Мин ничек ярдәм итә алам соң сезгә?

— Белмим...

— Төшертмәкче буласызмы?

— Әйе.

Чыңгыз тагын уйга калды. Бүлмәдә киеренке тынлык урнашты. Кыз түземсезлек белән аның карарын көтә иде. Чыңгыз исә уйларының очына һич кенә дә чыгып җитә алмады. Ул икеләнә иде. Һәм сораулар биргәндә, кызга киңәшләр биргәндә, аларны үзе өчен дә әйтә, сөйләгән сүзләренә үзенең дә ышанасы килә иде.

— Төшерттегез, ди. Аннары киләчәктә балагыз булмаса? Гомер буена кысыр калсагыз, баласыз интексәгез?.. Уйладыгызмы шул хакта?

— Уйладым,— диде кыз кырт кисеп.— Мин сезне дә, үземне дә беркайчан гаепләмәячәкмен.

— Бүген, әлбәттә, сез шулай дисез. Ә иртәгә?.. Кайгы тиз онытыла бит ул. Аннары кеше үз ялгышларында беркайчан да үзен гаепләргә яратмый. Намус хөкеменнән дә авыррак нәрсә юк дөньяда. Үлмичә котылып булмый аңардан. Ә сез, әнә, читкә китеп котылмакчы буласыз...

— Мин инде аны таба алмыйм. Гарип бала табасым килми...

— Дарулар кулландыгызмы әллә?

— Әйе.

— Нинди дарулар?

— Исемнәрен белмим, ул эчерде...

— Һмм... Ничек инде нинди дару эчкәнегезне дә хәтерләмисез?

— Ул бит миңа аларның исемнәрен әйтмәде. Аракы да эчерде.

— Ни дип эчерде инде ул аларны?

— Менә шушы даруларны эчсәң, аракы эчсәң, үзеннән-үзе төшә, диде.

— Сез шуңа ышандыгызмы?

— Ышандым...

— Ул кем, врачмы?

— Юк, ветеринар.

— Кайда эшли?

— Укый гына әле...

Чыңгыз ветеринария институтында танышлары барлыгын, шулар аркылы теге азгын егетне җавапка тарту мөмкинлеген уйлап куйды.

— Яратасызмы соң сез аны?

— Юк. Мин аны хәзер кеше дип тә әйтә алмыйм. Кеше түгел ул, хайван.

— Ләкин сез бит шул «хайван»ны әле күптән түгел генә яраткансыз. Хәзер ул сезгә, әлбәттә, начар кеше булып тоела. Кайгы болыты үтеп киткәч, кояш тагын чыгачак. Хикмәт менә нәрсәдә бит.

— Юк, хәзер инде мин аны аңладым.

— Ә ул сезне ярата мы соң?

— Элек, ярата, ди иде... Башта мин аны үзем яратмадым, санламадым. Шундый үҗәт нәрсә, һаман минем арттан тагылып йөрде, ялгызымны гына беркая аяк бастырмады, гел эзәрлекләде...

— Аның әти-әнисе сезне беләме?

— Беләләр.

— Соң, шулай булгач, барырга да әтисе белән әнисенә сөйләп бирергә: «Мин сезнең улыгыздан бала табам»,— дияргә.

— Аның әнисе мине яратмый.

— Каян беләсез?

— Шулай инде, яратмый. Нишләтсәң дә, алар барыбер малайларын яклаячаклар.

— Ул бит сезне ярата. Ирләр алар, яратсалар да, мондый хәлдә үзләрен кырыс тоталар, юри начар кеше булып кыланалар... Ул да кылана гына. Әгәр сез аңа бала күтәреп кайтып керсәгез, кая китсен ди ул? Бер кая да китә алмый. Димәк, сезгә тәвәккәлләргә, баланы табарга кирәк.

— Кешедән оят бит. Кеше ни уйлар?

— Бу уйлар сезгә элегрәк килергә тиеш иде. Ә хәзер инде сезне бөтән кайгы борчырга тиеш.

— Кем миңа квартира бирә? Мин аны тулай торакта үстерергә тиешмени?

— Бүлмәгездә ничә кыз торасыз?

— Өчәү.

— Менә шул иптәшләрегез ярдәм итәр.

— Иптәшмени алар миңа...

— Бу хакта алар беләләрме?

— Юк, минем аларга белгертәсем килми.

— Мин сезгә шуны гына киңәш итә алам: егет белән тагын бер тапкыр ныклап сөйләшергә кирәк. Бер ирнең дә үз тормышын алименттан башлыйсы килми. Әти-әнисе дә килешерләр. Күрше-күлән, туган-тумача алдында хурга каласылары килмәс ич инде... Кулларына онык китереп тоттырсаң, эри дә китә ул әби белән бабай йөрәге... Телисез икән, егетегез белән үзем сөйләшеп карыйм.

— Кирәкми, ул монда килмәячәк... Баштарак ул үзе, тап, диде, ул чакта мин риза түгел идем. Хәзер аның ишетәсе дә килми. Шуның өчен дарулар да эчерде.

Кыз сөйләгәннәрнең очы-очка ялганмый кебек иде. Бәлки, кыз әле дарулар да эчмәгәндер, бәлки юри өметсезрәк итеп күрсәтмәкчедер. Бу шикләнүләр нигезсез түгел иде. Моннан ярты сәгать чамасы гына элек, поликлиникадан чыгып барганда, Чыңгыз ишек төбендә кыз белән күзгә-күз очрашкан иде. Кыз артыннан озын буйлы, аксылкөрән төстәге куртка белән тезләре уңган джинсы чалбар кигән, ялан башлы, маңгай түбәсе шәрәләнә башлаган юка, сары чәчле бер егет килеп керде. Чыңгыз аларга юл биргән иде. Егетнең кыз артыннан ук килеп керүе очраклы хәлме, әллә... Нигәдер Чыңгызга кызны поликлиникага шул егет алып килгән, алар сөйләшә-сөйләшә кереп, баш врачны күргәч кенә шып туктап калганнар шикелле тоелган иде.

— Шулай да, сез егет белән тагын бер мәртәбә ныклап сөйләшеп карагыз әле. Ул үзен утта янмый, суда батмый торган, боз кебек шома кеше итеп күрсәтергә маташа. Ә сез аның әйткән бер сүзенә ышанасыз. Егет кармакта, аның котылу чарасы юк, язмышы хәзер

сезнең кулда. Бердәнбер юлы — теләсә ничек сезне төшертергә мәҗбүр итү. Менә шул меңнән бер котылу мөмкинлеген, аңлыйсызмы, бердәнбер мөмкинлекне сез аңа үз кулларыгыз белән китереп тоттырмакчы буласыз... Әгәр телисез икән, хәлне рәсмиләштерергә була: уку йорты директорына, комсомол комитетына врачлар исеменнән хат яза алабыз. Билгеле, азгынлыгы өчен түгел, күрәләтә агулаганы өчен, махсус рәвештә дарулар эчерткәне өчен. Моңа статья да куллап була. Егетне хөкемгә тартырга мөмкин ич. Барысын да аңлатып, мин әйткәннәрне искәртеп сөйләп күрсәтегез үзенә... Бөтен эш сезнең катылыктан гына тора. Әлегә сезнең икегезнең арасында «кем-кемне» дигән көрәш бара. Кайсыгыз йомшаклык күрсәтә, кайсыгыз чигенә — шул җиңелә... Әлбәттә, баладан котылып була, ләкин мәхәббәттән, үз-үзеңнән котылып булмый.

— Сөйләшүен сөйләшеп карармын, билгеле, ләкин ул өйләнешү турында ишетергә дә теләмәячәк.

— Их, бөтен нәрсә дә дөньяда теләк белән генә эшләнсә икән, бөтен ир дә теләп кенә өйләнсә икән ул!.. Шулай булгач, өйләнешегез — егет беренчесе дә, соңгысы да түгел. Студент егетләр арасында мәҗбүри өйләнүчеләр очрый ул. Белмәсәм, мин сезгә мондый киңәш биреп маташмас та идем... Сез аның белән кайчан очрашырга тиеш?

— Шимбә көнне.

— Ярый, миңа дүшәмбедә керерсез. Тагын бер тапкыр әйтәм: ятып калганчы, атып калырга кирәк!

— Сау булыгыз...

Кыз чыгып киткәч, Чыңгыз иркен сулап куйды. Күптән инде аңа мондый четерекле үтенеч белән мөрәҗәгать иткәннәре юк иде. Эшли генә башлаган елларда, ярдәм сорап, егетләр килгәләделәр килүен. Ул, ничектер, әллә инде яшьлек катгыйлыгы белән, кырт кисеп, аларны кире борып җибәрде. Бүген исә алай итә алмады. Нигә кызны шундук кире борып чыгармады соң ул? Кешенең серен тыңлау да үз өстеңә бик зур җаваплылык алу дигән сүз бит. Ярдәм итәрлек булмагач, кызны җәһәннәм утына салган кебек, сөйләтеп тә тормаска иде. Шул охшашлык бәласе инде: һаман Диларә эзәрлекли Чыңгызны. Диларә... Элек хыял булып җанга тынгы бирмәде, хәзер инде шәүләгә әйләнеп артыннан йөри. Бу кыз Диларәнең шәүләсе ич. Шәүләсе... Һәрхәлдә, кыз үзенең нинди адым ясаганын бик ачык белергә тиеш. Үз-үзеңнән качу юк, вөҗдан газабыннан качу да юк дөньяда. Кызга менә шуны төшендерергә тырышты Чыңгыз. Шуңа озаклап сөйләште, акыл сатты һәм уйланырга, барысын бизмәнләп карарга вакыт бирде.

Хатын-кыз табигатен ярыйсы гына аңлый иде бугай Чыңгыз. Кубада госпитальдә хезмәт иткән ике елын исәпләмәгәндә, институт бетергәннән алып бирегә күчкәнче, ул хатын-кызлар бүлегендә эшләде. Шул елларда ук инде ул, үз күзәтүләреннән һәм тәҗрибәсеннән чыгып, бала тапмаган хатын-кызның нервлары какшавы, холкы тиз үзгәрүе, гомумән, аларның авыруга бирешүчәнлеге һәм, иртәме-соңмы, кыен дәвалана торган нинди дә булса бер авыру белән авыруы турында ныклы нәтиҗә ясап өлгергән иде. Ә үзең ясаган нәтиҗәне тиз генә онытып та, үзгәртеп тә булмый шул аны. Әгәр кызга булышса, кыз шул сәбәпле гомерлеккә баладан мәхрүм булып калса, Чыңгыз аны, белә торып, киләчәктә бәхетсезлеккә дә, авыруга да дучар итә түгелме соң?.. Юк-юк, ул болай гына әйтте дүшәмбедә керегез, дип. Ул кызга ярдәм итмәячәк. Тапсын баласын кызый! Кеше сөйли-сөйли дә туктый ул. Яшьлек үтә, авырлыклар да җиңелә, ә бала картлыкта бердәнбер юаныч булып кала. Һәм хатын-кыз гомере буе кимсенеп яшәми, баласы барлыгына сөенеп, ана бәхете белән канатланып яши. Ирсез тору, ялгызың бала үстерү — бу бит хәзерге заман өчен гадәти бер нәрсә. Кем генә тигезлек белән кар-

таер микән соң алар буыныннан? Сирәк, бик сирәк булачак андый парлар. Хәзер үк инде, кая карама,— шунда ялгыз. Егетләр кызларга ышанмый, кызлар — егетләргә. Яраталар да ялгышалар, ялгышалар да, янә ярата башлыйлар. Мең яшьлек мәхәббәтнең, адәм баласының кинәт кадере китте. Сайлыйлар, сайлыйлар да, сайланып калалар. Утызда, кырыкта гына табалар кайбер хатыннар беренче балаларын. Ничек таза булсын инде ул балалар. Чәчәк кебек вакытта табарга кирәк баланы! Кияүгә иртә чыкканнары күз дә йоммыйча аерыла. Алимент белән тәмам котын алдылар мескен ир-атның. Алар хәзер инде җиде тапкыр түгел, җитмеш тапкыр үлчәп тә бер кисәргә куркып торалар. Шуңа күрә ирләр, аерылсалар, икенче тапкыр өйләнергә ашыкмыйлар; алар үзләре алдаган кызга ышанмыйлар, өйләнмәс өчен аларны төрле юллар белән бала төшертергә мәҗбүр итәләр. Юк, юк, болай баралмый дөнья, монда нәрсәнедер үзгәртергә кирәк. Хатын-кыз көчәйдеме, ирләр — көчсезләнә. Алар батырайса, ирнең бәясе бетә... Ай-яй, тәвәккәлләнде хәзер хатын-кыз! Аларга бала гына тусын, ир булса ярый, булмаса да начар түгел. Чыңгызның танышлары арасыннан да ике хатын-кыз, утыздан узгач, тавышсыз-тынсыз гына бала тапты. Кем дә: «Атасы кем балаңның?»— дип төпченеп йөрмәде. Дөрес, аларга эш урыннарын алыштырырга туры килде. Әмма тәвәккәлләделәр бит. Бу — кыз чибәр. Ә чибәрләр кулыннан андый батырлык килми, алар үзләрен корбан итәргә яралмаганнар. Алар, сорыкортлар кебек, бүтәннәр хисабына яшиләр. Шуңа күрә алданалар. Алдакчылар алар — чибәрләр. Гомумән матурлык ул — алдау, күз буяу гына. Алдансаң да үкенәсең, чибәрләрне яратсаң да үкенәсең. Азагы бер. Кыз да төшертәчәк баласын. Ялганлый ул, бернинди дә дару эчмәгәндер әле, Чыңгызны гына куркытмакчы. Дүшәмбе көн керер дә: «Бардым, очраштык, сөйләштек, ул риза түгел»,— дияр. Ялгыш әйтеп ташлады, ахры. Чыңгыз ярдәм итү мөмкинлеген. Кырт кискән булса, тәвәккәлләми кая китсен кызый? Йомшаклык, җебегәнлек күрсәтте ул, икеләнүен белгертте. Хатын-кыз белән икеләнеп сөйләшергә ярый ди мени? Хәзер инде кыз аның ярдәменә ышана, баладан котылуына ышана. Менә сиңа мә — авыртмас башка тимер тарак! Нишләп кыз турыдан-туры аның янына керде соң? Кем кертте кызны аның янына? Теге джинсы чалбар кигән егетме? Бәлки, Чыңгызны белгән берәр кеше керткәндер? Кем дә булса шундый яшерен эшләр белән шөгыльләнәме әллә? Кем аны кырын эшкә барыр дип уйлый икән?.. Чыңгыз Исламович бу сорауларның очына һич чыга алмады.

Ни генә әйтсәң дә, кызның турыдан-туры аңа килеп керүе гадәти хәл түгел. Нәрсәдер ята моның төбендә. Ләкин нәрсә? Чарасызлыкмы? Соңгы өметме?.. Димәк, кыз аңа ышана. Ышанмаса, кермәс иде. Әгәр кыз, чыннан да, арлы-бирле сугылып, тәмам хәлдән таеп, куллары салынып, чарасызлыктан өметләнеп, үз теләге белән кергән булса? Бу кыз бүтән врачларга ышанмый, аңа гына ышана дигән сүз. Аның бәладән коткаруына, сер саклавына, олы җанлы, мәрхәмәтле кеше булуына ышана. Әгәр кыз, чибәрлегенә инанып, үзенең баш врачка ошавына ышанып: «Мин — матур, сез мин ни сорасам, шуны эшләячәксез, шулаймы?»— дип кергән булса? Юк, юк, кыз алай дип керергә тиеш түгел. Беренчедән, ул әле бозылып ук бетмәгәндер, икенчедән, бәла алдында мин-минлек онытыла...

Чыңгыз сәгатенә карады. Эш сәгате бетеп килә иде инде. Тик ул, уйлары алып киткән дөньядан кайта алмыйча, дөресрәге, кайтырга теләмичә, һаман утыра бирде. Әйтерсең, ул хәзер томанлыкта йөзә, менә шул томан таралып, утырып бетмичә, дөньяның кыясы — кыя кыйбласы булып күренмичә, җаны тынычланмас, ә җаны тынычланмыйча ул кайта алмый иде...

Узган җәйдә әле кызның егете булмаган икән бит. Димәк, узган

җәйдә ул кыз белән танышкан булса, бүгенге күңелсез хәлләр килеп чыкмас иде. Ник туктатып сөйләшмәде икән ул теге вакытта кыз белән?.. Тукта! Нигә үкенә соң әле Чыңгыз? Киресенчә, монда шатланырга кирәк түгел микән? Үз намусын саклый алмаган, шундый җилбәзәк, ышанычсыз кызга юлыккан булыр иде. Ни генә димә — бүгенгесе көндә аның җаны тыныч. Тынычмы соң? Юк шул. Нидер көйдерә җанын. Астан гына, бер генә почмагын көйдерә. Ничек кенә көйдерә әле!..

Менә шулай, аны сагынып көткән көннәрдән бер көнне чәлпәрәмә килгән бәхетең ватыкларын тотып, үз аяклары белән килеп керсен әле яныңа сөйгән кызың! «Бөтен гомерем синдә, бәхетемне ябыштырып бир»,— дисен әле! Нигә аңа гына шундый тозаклы сынаулар корган икән язмыш? Бүтән бер дә шаярыр кешесе юк микәнни соң бу язмышның?.. Ис китмәслек мени: бөтенесе яңадан кабатлана. Бу кызда да — Диләрә үтенече. Шул күзләр, шул ук үтенеч!

Ник шул хәтле башсыз микән бу кызлар? Ике кешенең бәхете салынган касәне кулларыннан төшерәләр дә ваталар. Алдап яисә алданып бәхетле булырга мөмкин микәнни?.. Соңарды, тагын бәхетенә соңарды, бусында да бәхетенә соңарды Чыңгыз. Гомере буе шулай — ошаткан бер кызын югалта барды ул. Алар белән якыннан танышуны, очрашып сөйләшүне һаман иртәгегә калдыра, киләчәккә кичектерә килде. Ул кызлар аның карашыннан ук үзләренең аңа ошаганлыкларын беләләр, оялчанлыгын да күрәләр, шуңа көтәләр, көннәрдән бер көнне, ниндидер гаҗәеп мизгелдә килүен көтәләр сыман тоела иде. Бу — алдану иде. Чыңгыз шуны сизмәде, күрмәде, белмәде. Күп тә үтми, ул кызлар янында башка егетләр пәйда була, ә тагын бераздан алар кияүгә дә чыгып китәләр иде.

Эшли башлагач, ул эшләгән мохитта күңел төшәрлек кызлар бөтенләй очрамады. Иртә өйләнүдән уттан курыккан сыман курыккан Чыңгыз өчен бу бик тә кулай иде. Кырык төрле шөгыле бар, галәмәт мавыгучан иде ул. Бу шөгыльләр аңа җан азыгы иде. Алар Чыңгызның игътибарын үзләренә җәлеп итеп, аны гел алдый килделәр. Яшьлектә мөмкин кадәр күбрәк эшләп, күбрәк укып, күбрәк һөнәршөгыль үзләштереп калырга кирәк, картлыкта бернәрсә дә сиңа сер булмасын, дип яшәде ул. Өйләнсә, аның бөтен хыяллары зилзилә килер кебек иде. Бәйсезлеген, иреген югалтудан курыкты Чыңгыз. Ул белә иде: бер өйләнсә, ул аерылышып йөри торган кешеләрдән түгел, түзеп булса да торачак. Ләкин бу очракта ул ике ут арасында яшәр иде. Шуңа күрә, һаман: «Өйләнергә әле иртәрәк»,— дип йөрде, кызлар артыннан дөнья бетереп кумады. Ә очраганнарына игътибар итмәгәндер, күрәсең.

Менә бу кыз йөрәгенә керер, Диләрә урынын алыр шикелле иде. Шул охшашлыгы өчен генә дә яратыр кебек иде аны Чыңгыз. Кыяфәтен, килеш-килбәтен, күзләрен, әлбәттә. Кем ул, нәрсә ул — бу турыда Чыңгыз берни дә белми иде. Хәер, аның өчен хәзер моның әллә ни әһәмияте дә юк иде төсле. Күзәтә-өйрәнә, уйлана-уйлана ул шундый фикергә килгән иде инде: хатын-кызның барысының да уй-фигыле, аңы-җаны, холкы бер чама, ә Чыңгызны аңлый алырлык, аның бар таләпләренә дә җавап бирерлек, аны тәэсирләндерерлек, ягъни идеалы булырлык хатын-кыз дөньяда юк. Ул идеал аның хыялында гына туып, хыялында гына яшәгәнлеген Чыңгыз бик тә сыкранып, авырлык белән аңлаган иде. Матурлыкны күрә белгән, таный белгән кешегә дөньяда яшәү бик тә читен. Ул үз идеалын чибәрләр арасында да, урта матурлар арасында да, чибәрлектән мәхрүм кызлар арасында да очратмады. Көткән кешесе табылмады. Ахырда, барысына да кул селтәп, мәхәббәттән бөтенләй ваз кичте Чыңгыз Исламович. Аннары төрле димләүләр китте. Иренмәгән һәр кеше аны кемгә дә булса димли иде. Төп туганнарыннан алып, чыбык очына, энә очла-

рына хәтле барып җитәләр иде димчеләр. Һәм һәрберсенең, гөнаһ шомлыгына каршы, йә ирдән кайткан, йә кияүгә чыгалмый калган кемедер табыла. Күңелләренә авыр алмасыннар өчен, ул алардан һәрвакыт, елмаеп: «Вакыт юк бит әле»,— дип котыла иде. Күңеле төшеп, өметсезләнеп йөргән вакытлары да булды. Егерме тугыз-утыз яшендә ул шактый тирән өзлегү кичерде. Язлар инде бүтән килмәс, ул үз оясына соңарган, аның өчен дөньяда төсләре ташып, ялтырап торган, «мин мәңгелек гүзәллек өчен тудым» дип торган бер генә язгы чәчәк тә калмаган, язмыш юлында хәзер әрсез, бары тик орлык өчен генә яралган, төсләре уңган, кыска сабаклы көзге чәчәкләр генә очрар кебек тоела башлаган иде.

Аннан соң тагын йөрәгендә өмет шытты. Һәм шул өмет таҗлары бик озак шиңми торды. Яшәү — бер нәрсә, хыял — икенче нәрсә, дигән карарга килде Чыңгыз. Өмет инде аңарда беркайчан да сүнмәс шикелле иде. Тик... сүнде шул... Ә бит, уйлап карасаң, һәммәсе дә — кичәге кебек кенә...



• • •

Моннан ун ел чамасы элек, Кара диңгездән кайтышлый, бер группада укыган, күптән инде ирле-хатынлы булган Алмаз белән Әкълимә сугылды аңа. Институтны бетергәч, Алмазны — хирург, Әкълимәне терапевт итеп Төмәнгә эшкә җибәргәннәр, алар шунда төпләнеп тә калганнар иде.

Кызык бит ул ирләр дуслыгы. Хат та язышмыйлар, хәбәрләшмиләр дә, ә очраштылар исә — яңа гына аерылышкан кебек, шундук араны җылытып та өлгерәләр. Алмазлар да, хат-фәлән язмыйча, җай уңаена гына сәлам юллап, ара-тирә, исләренә төшкәндә, бәйрәм уңаеннан гына котлап тордылар.

Иртә өйләнгән иде Алмаз — беренче курста ук. Икенче курста кызы туды. Кызга Диларә дип исем куштылар.

Әтиләренә Диларә дә ияргән иде. Аны күреп шаккатты Чыңгыз. Елак бер кызчык урынына сокланып туймаслык сылу кыз басып тора иде. Үтсә дә үтә икән гомер: сигезенче классны тәмамлаган иде инде Диларә.

Чыңгыз дусын Казанга кайтырга өндәде. Алмаз да аны шундый теләк белән эзләп тапкан булып чыкты. Озакламый ул, чыннан да, Чыңгыз Исламович ярдәме белән, ординатурага керде, диссертациягә тотынды. Ординатураны тәмамлап, читтән торып аспирантурага кергәч кенә гаиләсен алып килде Алмаз. Квартира алыштыруда да Чыңгыз булышты аңа. Аңынчы тулай торакта яшәде Алмаз. Баштарак һәр көн йә шалтыратты, йә килеп йөрде ул Чыңгыз янына. Авыр иде аңа яңа шартларга ияләшү. Билгеле, фән буенча да, яшәү өчен дә таныш-белешләр кирәк иде. Көченнән килгәннең барын да эшләде булса кирәк Чыңгыз үз дусты өчен.

Гаиләсе дә күчеп килгәч, бөтенләй үзгәрде дөнья.

Шул көннән башлап, Чыңгызның тормышында да бертөрле эзлеклелек, нур кебек туры, якты, ерак бер максат барлыкка килде. Күптән көткән алсу офыктан Диларә калкып чыкты да, зәңгәр яулыгын болгап, томанлы болытларны таратты, аны тылсымлы гүзәллек дөньясына чакырды.

Бу мәхәббәт иде һәм ул мәхәббәттән курка да иде Чыңгыз. Һәм шул курку үстерде, көчәйтте генә бугай аның мәхәббәтен. Ярата мы ул аны? Юк, юк, ошый гына аңа Диларә. Ә ошау белән ярату арасында әле тамчы белән диңгез кебек аерма бар. Әйе, әйе, ошый гына. Кемгә кем ошамас бу дөньяда. Шулай дигәч, Диларә аның

уеннан югала. Ләкин күпкә түгел. Суга батырылган төнбоек шикелле, бераздан яңадан калкып чыга.

Диләрәне оныту хакына әлек үзен туйдырып бетергән танышТыруларны кире какмый башлады ул. Чакырган җирләргә йөрде. Үзен бик иркен тотты, чөнки бик тиз, аны ошатсалар да, ошатмасалар да, яңа танышларның үзе өчен барыбер булуын аңлады.

Яшерен утта янды Чыңгыз!

Бөтен бәла шунда: эш монда мәхәббәттә генә түгел иде. Аның өчен Диләрә — ул зарыгып көткән, сусап беткән сафлык, нәфислек, гүзәллек идеалы һәм, аның фикеренчә, хатын-кыз өчен мәҗбүри һәм мөһим бөтен күркәм сыйфатларга ия булган бердәнбер якты, даһи образ, чын алиһә иде. Ничектер Диләрә шундук аның идеалына да, хыялына да әверелде. Ул идеалын тапты, ниһаять, идеалын тапты!.. Чыңгызның бу хәбәрне күкләр күкрәтеп кычкырасы килә, ләкин ул аны беркайда да, беркемгә дә әйтә алмады. Менә шундый тыелган күкрәү йөртә иде ул күкрәгендә. Богауланган, яшерен мәхәббәт иде бу. Мәңге ирекеә чыгалмаслык, үзең белән генә сүнә торган көзге мәхәббәт, соңгы мәхәббәт иде бу. Сөйләү түгел, мәхәббәтенең аз гына кыймылдавыннан, ыңгырашуыннан да куркып яшәде Чыңгыз. Бу мәхәббәттә хатын-кызга карата мөмкин булган, яшәү дәверендә югалтмыйча, җилгәреп бетермичә сакланган һәм еллар гына, тормыш тәҗрибәсе генә тудыра торган, әле бөтенләй сарыф ителмәгән, иң саф, иң җылы, иң изге хисләр тупланган иде.

Чыңгыз яшендә инде ирләр үзләреннән олы яшьтәге хатынкызларга гашыйк булмыйлар. Кырыкка җиткәндә, яшьләргә тартыла ир күңеле. Дәрт тә, дәрман да ташып торган бу яшьтә ирләр үзләрен күк йөзендәге бөтен йолдызны йолкып алып, сөйгәннәренең түшенә кадый алыр сыман хис итәләр. Чыңгызның да Диләрә өчен, Гыймаевлар гаиләсе өчен, вак-төяк изгелекләргә генә риза булмыйча, әллә нинди могҗизалар ясыйсы килә иде. Әкълимә ханымга могҗиза кирәкми, аңа — җирдә нык басып, җәяүләп йөргән кешегә — конкрет эш: бүгенге көндә кызын институтка кертү, киләчәктә аны отышлы итеп кияүгә бирү кирәк.

Гыймаевлар Казанга Диләрә унынчыда укыганда күчтеләр. Чыңгыз исә бу кадерле вакыйганы яшерен, эчке тантана белән каршылады.

Тормышлары җайга салынгач, Алмазларга Чыңгыз сирәгрәк бара башлады. Гыймаевлар да аны артык кыстамыйлар иде инде хәзер. Участок терапевты булып урнашкан Әкълимә тиз арада кирәкле кешеләр белән танышып өлгерде. Алмазның да яңа дуслары арткан-нан-арта барды. Хирург кешегә очрый торган тегенди-мондый танышларны исәпкә дә аласы юк. Дөрес, Чыңгызның аларга барасы килә, бик тә килә, ләкин ул серен белгертүдән, хисләрен сиздерүдән шүрли һәм, шуңа күрә, Гыймаевларның берәрсе шалтыратмыйча яисә үзенең берәр житди йомышы төшмичә, сәбәпсез генә бармый, барырга кыенсына иде. Аның каравы, Диләрә аны һәрвакыт көтеп ала кебек иде. Килгәндә гел Чыңгыз абыйсы янында бөтерелә, бөтенләй үзгәреп, канатланып китә.

Еш кына Чыңгызга ишекне Диләрә ача һәм шатлыгы эченә сыймаган кебек: «Әни, әти, Чыңгыз абый килде!»,— дип, өйгә гаҗәп бер җанлану кертеп җибәрә иде. Чыңгызга шул минутта рәхәт тә, моңсу да булып китә. «Абый» сүзе колагын сыйпап үтә дә, йөрәгенә ук сыман барып кадала.

Әмма ул моны сиздермәде. Менә шулай, эчтән яна-яна, кичерешләрен тыштан белгертмәскә өйрәнде ул.

Теләсә кайсы яфракка, кыякка кунарга мөмкин булган саксыз, саф чык тамчысы кебек иде Диләрә.

Чыңгыз озаграк килми торса, Диләрә аны гел: «Без сезне бөтен-

ләй югалттык»,— дип, үпкәле һәм шелтәле-иркә тавыш белән каршы ала.

Бу мәхәббәт ялкыны булмады, ахрысы. Ялкын булса, аз гына җылытыр иде җанны. Ә ул, йөрәгенә кан саудыра-саудыра, саргайтып киптерде Чыңгызны. Шушы көннәрдә аның күңеле тагын да ныграк бикләнде. Ул күзгә күренеп уйчанланды. Чәчендә әлек беленер-беленмәс кенә, энҗе инәләр кадаган кебек кенә ялтыраган сирәк чаларган төкләр, чамасыз куерып, бөтен башын каплап алды.

— Чыңгыз абый, чын мәхәббәтне ялган мәхәббәттән аерып буламы?— дип сорады аннан беркөнне Диларә.

— Әлбәттә, була,— диде Чыңгыз.— Ләкин моның өчен вакыт кирәк. Чын мәхәббәт озын гомерле була. Ялган мәхәббәт кыска гомерле, йөрәк озакка түзә алмый ул. Дөресрәге, озак алдаша алмый.

— Йөрәк алдаша да беләмени?— дип гаҗәпләнде Диларә.

Ә икенче тапкыр алар арасында мондый сөйләшү булды:

— Сезгә нинди хатын-кызлар ошый?— дип сорады аңардан Диларә.

— Акыллы хатын-кызлар.

— Ә ирләрнең нindиләре ошый алайса?— диде Диларә, серле елмаеп.

— Ирләрнең дә акыллылары.

— Ничек белергә соң аларның акыллымы, түгелме икәнен?

— Матур кешене ямьсез кешедән аерып буламы? Була. Шуның шикелле инде, акыллыны да акылсыздан аерырга мөмкин.

— Бик тә җиңелдер сезгә яшәве, Чыңгыз абый. Сез шундый акыллы, сез шундый күп беләсез. Сез беркайчан да ялгышмагансыздыр һәм ялгышмассыз да, мөгаен. Кайвакыт миңа шундый бер күңелсез уй килә: сез берзаман өйләнерсез, сезгә усал хатын эләгер дә, сезне безгә җибәрми башлар. Безгә бик, бик күңелсез булачак. Мин сезне югалтудан куркам, Чыңгыз абый...

Шушы сүзләр җитә калды Чыңгызга. Диларәләрдән кайтканда аның шатлыгы ташып чыккан, ул бәхетле иде. Әйтерсең, аның йөрәге кыңгырау һәм шул кыңгырау бөтен шәһәргә тантана авазлары тарата иде.

Бервакыт Диларә аңардан Югославиядән килгән артистлар концертына билет табып бирүен сорады. Уйлаштылар да, концертка дүртәүләп, кызның әти-әнисе белән бергәләп бардылар. Диларә Чыңгыз янында утырды. Аларны концертта Диларәнең классташ кызлары күреп калган икән. Күпмедер вакыт үткәннән соң, Диларә аңа бу турыда үзе әйтте:

— Чыңгыз абый, безнең кызлар сезне шундый ошатканнар. Каян таптың син аны: шу-ундый ир-рр диләр. Озын, зифа, могтәбәр, диләр. Ә сез, чыннан да, мәһабәт ир, Чыңгыз абый. Сезне хатын-кыз яратадыр, күпләре гашыйктыр әле, мөгаен...

Артык зур әһәмият бирде Диларәнең бу сүзләренә Чыңгыз. Үзе күп уйлап, аз сөйләшүчән кеше булгангамы, ул бу сүзләргә, үзеннән өстәп, әллә нинди тирән мәгънәләр салып бетерде.

Диларәнең әлеге сүзләре аның уяулыгын йоклаткан булып чыкты. Татлы сүзләрдән айныганда Диларәдәге үзгәрешләр шактый иде инде.

Ул көнне дә Диларә аны: «Без сезне бөтенләй югалттык»,— дип каршылады. Бусы гадәттәгечә иде. Чыңгыз аңардан:

— Син моңсулангансың әле, Диларә. Моңсулануыңның сәбәбе йөрәктә, савабы еракта кебек, шулаймы?— дип сорады.

— Шулай,— диде Диларә.— Каян белдегез?.. Әйтәм ич, сез акыллы, дип...

Диларә аңа Түбәндә чакта бер рәссам егеткә гашыйк булуын, хәзер шул егетне сагынуын сөйләп бирде. Моны ишеткәч, тәне буй-

лап кайнар дулкын йөгерде Чыңгызның. Диларә, әлбәттә, аның авыр, тирән кичерешләрен сизмәде. Замана баласы иде шул Диларә...

Ул көнне кайтканда күкрәгендә кыңгырау какмады инде Чыңгызның. Кыңгырауның телен кемдер, нәрсәдер кысып тоткан да, ычкындырырга һич тә уйламый кебек иде.

* *

Диларәнең теге егеткә барыннан да бигрәк рәссам булганга гына күз салуы Чыңгыз өчен көн кебек ачык иде. Һәрхәлдә, ул үзен шулай ышандырды. Бәлки, нәкъ менә шуңа күрәдер, кызга бирәр матур рәсем бүләк итәргә уйлады.

Тик менә кайчан бүләк итәргә соң? Аның бирәр ныклы сәбәбе булырга тиеш ләбаса. Тора салып рәсем күтәреп килеп кермәссең ич инде. Башта ул Кубадан алып кайткан диңгез пейзажларыннан берсен бүләк итмәкче иде. Ләкин тора-бара ул уеннан да кире кайтты. Диларәгә атап махсус язылмаган рәсем бүләк итәргә аңа намусы кушмый иде. Уйлады, уйлады да, елның унике аен да тасвирлаган, кечкенә генә унике рәсемнән торган, «Романтик төсмерләр» дигән цикл ясарга карар кылды. Өйдә буяулары җитми иде. Күптәнге танышы рәссам Әбрар Уразгильдиевнең остаханәсенә китте.

— Гашыйк булдыңмы әллә?— дип каршылады аны рәссам. Күрәсең, Чыңгызның хәл-халәте кыяфәтенә үк чыккан иде.

— Бер тоташка үзем ясап пейзажлар тезмәсе бүләк итәргә иде исәп,— диде Чыңгыз, серенең шулай тиз чишелүенә бераз күңеле кителеп.

— О-оо! Бик мәслихәт, бик мәслихәт...

Әбрар хатын-кыз мәсьәләсендә төс-тәм белә торган ир иде. Ул, бик иртә өйләнеп, авызы пешеп аерылган һәм шуннан бирле өйләнүдән— «иректә көндә муенга элмәк салудан» тәмам ваз кичкән, хәзер инде ахыргача буйдакка әверелгән бер кеше иде. Шуңадыр ахрысы, аның хатын-кызга мәхәббәтен, гомумән мөгамәләсен аңлап кына бетерерлек тә түгел иде.

Чыңгыз аның остаханәсенә еш йөрде, армый-талмый эшләде.

— Ял итеп ал,— ди аңа Әбрар.— Ашыкма, болай да өлгерәсең.

Чыңгыз белә: Әбрарның теле кычыта, сөйләшәсе килә. Ул ялгызлыктан туйган, шуңа күрә тыңлаудан бигрәк, сөйләүгә мохтаҗ:

— Гүзәллекне аңларга безне хатын-кыз өйрәтә. Янында сөйгәнең булмаса, табигатьнең нинди генә хозур почмагы да сиңа матур булып күренми. Ә яраткан хатын-кыз каршында торганда, син чүлдә дә мең төрле гүзәллек табасың. Сәнгатьнең дөньяга туына да хатын-кыз сәбәпче. Мәхәббәт абстракт нәрсә түгел, үтә конкрет нәрсә. Шуңа күрә һәрбер бөек сәнгать әсәренең конкрет илһамчысы бар. Шуңа күрә иҗат кешесенә хатын-кызга иптәш итеп кенә карарга ярамый, ул аңа йә фәрештә, йә алиһә итеп карарга тиеш. Хатын-кызга мәңгелек мәхәббәт — менә нәрсә иҗатта җанны хәрәкәткә китерә...

Чыңгыз инде бу сүзләрне яттан диярлек белә, ләкин һәрвакыт яратып тыңлый.

— Бөтен бөек әсәрләр дә әнә шул хатын-кызга мәхәббәт аркасында туган. Ләкин иҗат өчен гади мәхәббәт кенә җитми. Тирән мәхәббәт, көчле мәхәббәт кенә иҗатка егәрлек, нур өсти ала. Ә иң тирән, иң көчле мәхәббәт ул — кысыр мәхәббәт. Бары кысыр мәхәббәт кенә мәңгелек була ала. Йөрәктәге хисләр алар — капкачын ябып кайнатканда гына ургып, пар атып кайный. Без менә шул парны саклый белмибез. Шуңа безнең йөрәкнең дә, ир-атның да егәре юк. Хәлбуки, бөтен классик әсәрләр — кысыр мәхәббәт җимеше. Бир син

миңа шундый кысыр мәхәббәт — һәм мин менә диган шедеврлар иҗат итәчәкмен! Чынлап әйтәм, бүләк ит син миңа ялкыныңны!

Әбрар, урыныннан сикереп торып, Чыңгызның рәсемнәре янына килде, күрәсең, яңа бер күзлектән карап чыкты:

— Ярыйсы бит. Үлгән талантны тергезгәнсең бит. Әгәр минем осталыкка синең мәхәббәтне кушсаңмы?!.

Ул, бармагын чиртеп, урынында бөтерелеп алды. Аннары Чыңгызның каршына килеп басты:

— Беләсең килсә, Чыңгыз, монда мин гаепле түгел, хатын-кыз үзе гаепле. Гашыйк буласың, бәлки инде бусы мине саргайтыр, дисең — юк!.. Танышасың, очрашасың, кем икәнлегеңне әйтәсең һәм менә шуннан китә инде. Рәсемнәреңне күрсәт әле, дия башлыйлар. Остаханәгә чакырасың, йөрәкне сикертә торган бик отышлы берике рәсем күрсәтәсең, аннары шәраб белән шоколад, аннары талгын гына музыка, йә үзең гитарада чиртеп, карлыккан тавыш белән бәхетсез язмышың турында җырлап җибәрәсең. Өч җырдан соң: «Туташ, син шундый чибәр, минем синең портретыңны ясыйсым килә»,— дисең һәм туташ йөрәге, кызган табага салган май кебек, эри дә төшә. Мәхәббәт гөле тумас борын сула. Йә, монда мин гаеплеме? Хатын-кыз дан-шөһрәткә шулкадәр мохтаҗ ки, минемчә, ул даншөһрәт өчен, рәсемнәрен күргәзмәләрдә элдертер өчен әллә нинди корбаннарга риза. Гомумән, ярата белү, минемчә, үзе бер талант, зур талант. Күрәсең, ул миндә юктыр.

— Нишләп булмасын. Аның яралгысы һәркемдә дә бар. Ул синдә әлегә уянмаган гына. Дөресрәге, ул синдә уяныргa өлгерми дә кала, чөнки син бик еш һәм нык гашыйк буласың, ләкин тиз суынасың. Яз саен мәхәббәт яңартасың, ә көзгә суынасың. Шуңа илһамың да гыйшкың гомере сыман кыска синең.

— Язмыштан узмыш юк. Монда да, күрәсең, мин үзем генә гаепле түгелдер. Мин шулай уйлыйм: һәрбер ирнең йөрәгендә беренче мәхәббәт эзе ята. Тәүге хисләр күңелдә нинди дә булса бер төсмер — ярату төсмере калдыра. Һәм син, кемне генә яратма, күпме генә яратма, һаман шул бер төсмерне эзлисең...

Чыңгызның әле беркайчан да шулкадәр илһамланып, тырышып, дулкынланып рәсем ясаганы булмагандыр. Аның саф, мәңгелек мәхәббәте бар! Әнә ничек өзгәләнә Әбрар сөя белмәве аркасында! Димәк, Чыңгыз — бәхетле! Бәхетсез мәхәббәте белән бәхетле...

Яңа ел кичендә ул, рәсемнәрен күтәреп, Диларәләргә килде. Тик бу мәҗлестә Диларә юк иде. «Иптәшләре белән каршылый»,— диде әнисе.

Рәсемнәрне бик тә ошаттылар Алмаз белән Әкълимә. «Диларә, мин аларны сиңа багышлап ясадым»,— дип әйтмәкче иде бит юкса Чыңгыз.

Алмаз, дусты алдында үзенең ир дәрәҗәсен күрсәтергә тырышып булса кирәк, кызын аның рөхсәтеннән башка җибәргән өчен, Әкълимәне шелтәләп алган иде, әмма хатыны:

— Ул бала түгел инде хәзер, бераз ирекккә чыксын, кеше күзенә күренеп йөрсен. Почмакта утырып калуын телисеңмени?— дип, хуҗаның авызын бик тиз япты. Алмаз шып булды. Чыкылдап торган «матриархат» иде бу гаиләдә. Әкълимә участок терапевты булып урнашкач, ашарга-эчәргә дә үзе таба башлагач, ул ни әйтсә, шул дөрескә әйләнде. Телисеңме, теләмисеңме — кыз баланы барыбер ана тәрбияли.

Соңгы чиктә Яңа ел кичендә ярыйсы гына йомшарып, наян кешенең шаян сүзе итеп, Алмазның телен тарткалап карарга да әзерләнеп килгән иде ул. Иртәгә Яңа ел, яңа тормыш башлана ич. Сөйләнгән сүзләр иске елда кала. Һич югында, котылу чарасы бар — исерүгә сылтарга була.

Шушы мәҗлестән соң аларның аралары йә мәңгегә суыначак, йә... Менә шул «йә» дип килгән иде дә инде Чыңгыз. Һаман билгесезлектә йөзгәнче, әнә шулай бер талпынуда ике ярның берсенә чыгу бу хәлдән котылу өчен бердәнбер юл кебек иде. Ләкин ул исермәде. Башына да, теленә дә гел аек фикерләр генә килде. Шулай итеп, сөйләшү, аңлашу тагын кичектерелде. Сөйләшү булмый калуда Диләрәнең юклыгы да хәлиткеч бер сәбәп иде. Айлар, еллар үткәннән соң кайта-кайта уйлап та, бары тик шул Яңа ел кичәсендә генә аңлашырга мөмкин иде дигән нәтиҗәгә килде ул. Чыннан да, бүтән андый җай чыкмады...

* * *

Диләрә, мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, медицина институтына керде. Болай да кызының өс-башы, «бишле»ләре белән генә кызыксынган Әкълимә морадына ирешкәч, Диләрәне бөтенләй иреккә чыгарды. Чыңгыз килгәндә Диләрә өйдә сирәк туры килә торган булып китте. Бәйрәм, каникул вакытларында ул еш кына иптәшләре белән каядыр китеп бара иде. Ә Чыңгыз исә кызның үзе белән очрашканда бераз оялуын, бит очлары алсулануын, дулкынлануын тели иде. Бик, бик көтте ул кыз мәхәббәтенең бу тәүге төсмерләрен. Ләкин Диләрә аңа абыйсына караган кебек кенә карый иде, ахрысы.

— Бигрәк изге кеше инде сез, Чыңгыз абый, сез ярдәм итмәсәгез, без Казанга да күчеп кайта алмас идек, әти дә диссертация яза алмас иде,— диде Диләрә бервакыт. Ул мондый җан җылыта торган сүзләрне, гүя, Чыңгызны бәйдә тоту өчен, аның йөрәген бөтенләй үк бозландырып җибәрмичә, вакыт-вакыт җылытып тору өчен генә әйтә иде. Ә ул, юләр, шуңа ышана иде, теләмәсә дә ышана иде. Диләрәнең татлы сүзләреннән нинди генә өметле нәтиҗәләр ясап бетерми иде Чыңгыз!..

Диләрәнең тизрәк студентка булуын түземсезлек белән көткән иде Чыңгыз. Чөнки көннәр аның файдасына, аның бәхете хакына агалар кебек иде. Чыннан да, бу сыйфат үзгәреше аларның яшь аермасын киметә, һәрхәлдә, күзгә артык ташландырмый торган итә иде. Ләкин вакыт, киңәя барган елга шикелле, аларны — ике ярдагы ике йөрәкне — ерагайтты да ерагайтты.

Болай озак дәвам итә алмаячагын аңлагач, Чыңгызның башына бер-бер артлы артык кыю, юләр уйлар килергә тотынды. Ул, Диләрәне каядыр институт юлында очратып, аңа серен ачып бирергә карар кылды. Әгәр Диләрә аны кире какса, Чыңгыз Диләрәдән бу турыда әтисе белән әнисенә беркайчан да сөйләмәвен үтенергә, ә үзе алар өенә аяк та басмаска тиеш иде.

Әмма, гадәтенчә, бу эшне дә тагын кичектерде Чыңгыз. Ә үзе көтте, һаман көтте, һаман ялгыз килеш, буйдак килеш йөри бирде. Уйларның төрлесе килә бит аның: агы да, карасы да. Вакыт-вакыт ул да: «Нигә кирәк кысыр хыял, ник онытмыйм мин аны? Ул гына мени сөйкемле сөяк? Синең өчен җанын фида кылырлык кызлар тирәндә чуалганда, кара кайгыга батып, бер җилбәзәккә мөкиббән китеп йөр инде»,— дип уйлана иде. Дөньясына төн иңә иде аның шул минутларда. Тик озакка бармый иде күңеленең андый вакыты. Бераздан тагын таң ата һәм алсу офыкта зәңгәр яулык болгаган Диләрә күренә иде. Югалганда әнә күзе хәтле генә яктылык-нур — өмет нуры калдырып югала иде ул.

Беренче курстан соң, Диләрәнең практикасы вакытында, Алмаз белән Әкълимә бер атнага авылга кайтып киттеләр. Диләрә өйдә берүзе калды. Язмыш үзе елмайды бит, югыйсә, шунда Чыңгызга.

Хәзер булса, һичшиксез барып, Диларә белән аңлашыр иде ул. Һәрхәлдә, хәзер аңа шулай тоела. Кемгә файда соңарган акылдан? Теге вакытта ул бара алмады. Бу юлны аңлашу өчен тыелган ысул дип санады Чыңгыз. Әтиләренең киткәнен генә көтеп йөргән кебек, яшерен эш кебек килеп чыга сыман иде.

Рәсемнән туйды шулчакта Чыңгыз. Бу сәнгатьнең төгәллеге аның рухи халәтенә һич тәңгәл килә алмый, аның йөрәгендә билгесезлек, йөз төрле билгесезлек иде. Ә күңел төшенке вакытта җанга музыка кирәк. Музыка йөрәк сызлавын баса, китек җирләреннән сыйпый-сыйпый, күңелне тынычландыра. Чыңгызның да йөрәге моңга сусады. Әгәр шушы шөгыльләре булмаса, мең төрле сораулардан, төссезлектән, чарасызлыктан ул авыруга сабышыр, хәтта акылдан шашар кебек иде. Ул Уфадан, әтиләреннән, малай чакта уйнаган пианиносын алып килде. Һәм шуның белән үзенә беразга менә дигән иптәш, сердәш тапты. Эштән борчылып кайтканда борчуларын тарата, күңелен күтәрә, уйларын бер төрле талгынлыкка юнәлтә иде. Музыканың чиксезлеге, ирекле һәм мәңге яшь булуы җанын дәвалый иде аның...

* * *

Диларә икенче курска күчте. Шул вакыттагы тагын бер авыр сөйләшү хәтерендә калган Чыңгызның.

— Минем бүгенге көндә биш поклоннигым бар,— диде аңа Диларә.— Ничек уйлыйсыз, бу күпме, азмы?

— Анысын белмим, ләкин шуны әйтә алам: бәхетең өчен бары берсе кирәк.

— Әгәр мин аларны сезнең белән таныштырсам, Чыңгыз абый, сез аларның кайсысы мине ныграк яратуын әйтә алыр идегезме?

— Кайсысы белән синең тиң булуыңны, кайсысын яратырга мөмкин икәнен, бәлки, әйтә алыр идем. Әлбәттә, аның белән берәр кич сөйләшеп утырганнан соң. Яратып та, сөйгәнеңне бәхетсез итәргә, һәлакәткә илтергә була ич. Мәсәлән, сине үлеп яраткан егет көймә ала да, аның тишекме-юкмы икәнен дә тикшереп тормыйча, давыл кузгаласын да белмичә, «Әйдә, диңгезгә!»— дип чакыра һәм сине һәлакәткә дучар итә...

— Минемчә, сез әле беркемне дә чынлап яратмагансыз. Сез әле үз мәхәббәтегезне, бәхетегезне очратмагансыз, Чыңгыз абый.

— Бәлки, шулайдыр да. Тик шуны исеңдә тот: акыллы ирләр генә акыл мәхәббәте белән ярата алар. Ә син йөрәк белән ратканын эзлисең. Бу — синең яшьлек галәмәте. Бу синең хатаң түгел, борчылма.

— Сез үзегез кемне дә булса әнә шул акыл мәхәббәте белән яраттыгызмы?

— Бу турыда өч сүз белән генә әйтеп булмый, Диларә. Моңа шактый вакыт кирәк, ә син ашыгасың...

— Әйе шул, свиданиега барасым бар. Бер артист белән очрашам бүген.

— Нинди артист соң ул?

— Әй, җәйге практика вакытында танышкан идек. Чибәр болай. Ул укый гына әле, театр училищесында...

Диларә чыгып киткәч, алар өчәүләп чәй эчәргә утырдылар.

— Син кара аны, кызның тәмам башы әйләнгән,— диде Алмаз хатынына.— Әллә ниләр булып куймасын тагын, ходай сакласын...

— Йөрсен, сайласын, гомерлеккә сайлый бит,— дип кырт кисте Әкълимә.

— Алай сайлануга калгач, бетте инде ул. Арадан иң начарын

сайлар әле менә, күреп тор. Бер кеше белән генә йөрергә кирәк.

— Синең дә кызларың бар иде инде миңа чаклы, минем арттан да егетләр йөрми түгел иде. Шулар арасыннан син мине сайладың, мин — сине.

— Без яшь вакытта заманы башка иде шул аның. Без «өйләнәм» дигәч кенә үбә идек кызларны, ә хәзер...

— Йөрсен, мөстәкыйльлеккә өйрәнсен...

Еллар нык үзгәрткән иде Әкълиманы. Беренче курстагы оялчан, кечкенә, шыпырт-тыйнак Әкълимә җир тетрәтерлек юан һәм кырыс бер хатынга әверелгән иде инде. Ул бер дә икеләнеп сөйләшми, әйткән бер сүзен өзә дә тезә, өзә дә тезә иде.

Чыңгыз алар сүзенә катнашмады. Шушы көннән, ахры, ул мәхәббәтен тере килеш җиргә күмә башлады. Аны сүзгә тартырга теләпме, Әкълимә, соңгы вакыттагы гадәтенчә, яңа димләү тәкъдимнәре ясарга тотынды. Аның туганнан-туган бер апасының «бик уңган, бик булган» олы кызы, «булмаган бер адәмгә ялгыш» кияүгә чыгып, күптән түгел ирдән кайткан икән. Элек Әкълимә аңа танышбелешләрен генә димли иде, бүген чират үз нәселенә дә җитте. Әллә тормыш әрсезләтә, тупасландыра бу хатын-кызны, әллә табигатьләре шундый — көннән-көн ир күңеленә җим булган тыйнаклык, нәфислек, горурлык дигән гүзәл сыйфатларын югалта баралар.

Чыңгыз шимбә көннәрне теннис уйнарга йөри иде. Әллә нишләп аның бу көнне иртәннән үк кәефе булмады. Гадәтенчә, йөгереп тә кайтты, гадәтенчә, салкын душ та керде. Әмма йөрәгеннән шом китмәде. Дөрес, ул Диларә белән соңгы очрашудан соң болай да күңелсез йөри иде. Ләкин күңелсезлек бер нәрсә, шом икенче нәрсә шул. Чыңгыз беркая бармаска, көне буе китап укып утырырга булды. Әмма ул Әбрар белән теннис уйнарга килешеп куйган иде, аңа шалтыратты. Әбрарның өендә дә, остаханәсендә дә телефон җавап бирмәде. Сүз куешкач, Чыңгыз уенга бармый кала алмый иде. Җанын тынычландыру өчен, иртәрәк чыгып, җәяү барырга, юл уңаеннан медицина китаплары кибетенә дә сугылырга булды.

Кояшлы, җылы көн, шәһәрдәге язгы җанланыш аның күңелен бераз күтәрә төште. Шом да басылды шикелле. Менә, студент чактан ук һәр чокыры, ярык-йорыгы дигәндәй таныш Бутлеров урамы, гаҗәп зәвык белән салынган, үткән саен күзгә ямь өсти торган, Казан өчен, ул исәпләгәнчә, җиде могҗизаның берсе булган, күз шифаханәсенең сокландыргыч бинасы... Чыңгыз Казанга килү белән игътибар итте бу бинага. Үзенең борынгы, Казан өчен ят бер стильдә эшләнүе белән беренче күрүдә үк тәэсирләндергән иде ул Чыңгызны. Кемдер аңа бер бай сәүдәгәр үзенең сөяркәсенә бүләк итеп төзеткән ул йортны, дип сөйләгән иде. Сүз дөрес булса, менә нинди гүзәл эз калдырган бит җирдә сәүдәгәр мәхәббәте! Һиндстандагы Мәһәл мавзолееен да Җаһан шаһ сөйгән хатыны Мәһәлгә багышлап төзеткән ич. Кызык та, кызганыч та: мәхәббәтең җирдә гүзәл эзен, тарихта гүзәл исемен калдырсын өчен, йә шаһ, йә сәүдәгәр булырга кирәк. Гади кеше даһи итеп сөя алмый микәнни? Чыңгыз да, кодрәтеннән килсә, Диларәгә багышлап мәхәббәтен мәңгеләштерерлек берәр гүзәл һәйкәл салдырмас идемени?!

Үткәнне уйлаганда киләчәк онытыла, киләчәкне уйлаганда үткән онытыла. Юк, юк, кеше беркайчан да бер үк вакытта өч заман турында уйлый алмый. Шуңа ялгыша, абына адәм баласы. Кинәт ул уйларыннан арынды. Туктап бер мәл һәйкәлгә карап торды да, юлын яңадан дәвам итте. Шулвакыт ни күзе белән күрсен — нәкъ аңа каршы, үзара шаяра-шаяра, Диларә белән бер егет килә иде. Чыңгыз өнсез калды. Ул тиз генә юлның икенче ягына чыкмакчы иде дә, өлгерә алмый калды. Нәкъ шул вакытта Диларә алга карады. Ул, һичшиксез, Чыңгызны күргән булырга тиеш иде. Хәзер инде тегендә-

монда борылу качу сыманрак килеп чыгачак...

Үч иткәндәй, урамның бу ягында бер генә кеше дә юк. Алар өчәү генә. Гүя, бөтен кеше, аларны махсус очраштырыр өчен, урамның теге ягыннан гына йөри башлаган.

Чыңгыз йөрәгенең дөп-дөп типкәненә хәтле ишетте. Әгәр кинәт җир убылса, гарьләнүдән шунда җир астына да кереп китәргә әзер иде ул. Йөрәге юкка гына шомланмаган икән иртәдән бирле.

Диләрә белән егет, берсен-берсе йомшак кына, иркә генә иңнәре белән этешеп, шаяра-шаяра, киң урамны иңләп киләләр. Аларга бүген урам гына түгел, дөнья да тар шикелле.

Диләрә шундый шат, шундый бәхетле, бөтен урамны яңгыратып көлә. Чыңгыз белән тигезләшкәч, Диләрә аңа битараф кына караш ташлап исәнләште дә кабат егеткә таба борылды. Алар тагын бер мәртәбә нидәндер кычкырып көлделәр. Чыңгызның моңарчы әле беркайчан да шундый ахмак хәлдә калганы булмагандыр, мөгаен. Ул шулкадәр уңайсызланды, шулкадәр үртәлде ки, бөтен тәне, ут капкандай, кызып-кызып янарга тотынды. Шабыр тиргә батты Чыңгыз. «Юләр, юләр!— дип битәрләде ул үзен.— Син, акыл сатып, үгет-нәсихәт биреп, әллә нинди югары материяләр турында әкият сөйләп йөрисең. Ә Диләрә... Диләрә гап-гади бер гашыйк. Әнә ич ничек очкынланып балкый аның күзләре!..»

Ул китап кибетенә кереп тормады, турыдан-туры паркка юнәлде. Капка төбендә Әбрар күренмәде. Хәер, ул килергә иртәрәк иде әле. Тынычланыр өчен, Чыңгыз берничә тапкыр паркны әйләнеп чыкты. Йөрәге үз урынына һаман урнашып бетмәгәнгә күрә, ул әкрен генә йөри алмый, шуңа күрә паркны бик тиз әйләнеп килә иде.

— Нигә сөмсерең коелды?..

Чыңгыз Әбрарның көр тавышыннан сискәнеп китте.

— Болай, уйланып кына утырам...

Алар уйнарга тотындылар. Чыңгыз ачу катыш бер кыргый дәрт белән уйнады. Тупны да тукмады гына! Кизәнеп-кизәнеп суккан саен, аның хәле дә, тәне дә җиңеләя барды. Диләрә исенә төшкән, күз алдына килгән саен, үҗәтләнебрәк селтәнде. Бертуктамый тәүлек буе уйнарга да риза иде ул бу сәгатьләрдә.

Уеннан соң алар, күнегелгән гадәт буенча, ресторанга кереп, ашыкмый гына ашадылар. Әбрар һаман Чыңгызны сүзгә тартырга маташты:

— Табигатьтә иң гүзәл чак: таң аткан вакыт һәм кояш баеган вакыт. Көндез яктылыктан күз камаша, тавышка колак тона, йөрәк кан белән тула. Бары тик таң атканда, яисә кояш баеганда гына безнең уй белән хисләр бер-берсенә тыңлашалар, бер-берсенә гашыйклар кебек сокланалар. Без уй белән хис кушылганда гына дөньяга, табигатькә тиешле дәрәҗәдә тирән итеп карый алабыз.

Чыңгызның исә хәле фәлсәфә тыңларлык түгел иде. Әбрар да моны аңлады, ашыгып саубуллашты. Чыңгыз яңадан паркка кереп китте. Ул, аягы кая тартса, шунда барды. Шулай исәнгерәп йөри торгач, паркның моңарчы үзенә таныш булмаган бер аулак почмагына — каенлыкка килеп чыкты. Каенлыкның бер читендәге буш җирдә агач утыртып йөргән кешеләрне күреп, шулар янына килде. Кинәт аның башына көтелмәгән, матур, тәвәккәл бер уй килде.

— Миңа да утыртырга мөмкинме?

— Утырт кына, энекәш. Әнә, тегендә тагын бер машина үсенте бар. Хет бөтен аланны утыртып бетер. Рәхмәт кенә әйтербез.

Чыңгыз, арадан иң төз, иң озын, үсәргә иң өметле бер каен үсентесен сайлап алып, истә калырдайрак урын эзләп китте. Ахырда чәчәк түтәле кебек калкыбрак торган бер урында чокыр казыды. Үсентене шул чокырга төшерде дә, ниндидер йола үтәгәндәй, тантаналы рәвештә уйланып торды. Аннары, бу тантаналы минутларның

кадерен белеп кенә, учы белән чокырга берәм-берәм балчык ташлады. Гүя ул агач утыртмый, ә бәлки мәхәббәтен, мең дә бер кайгылы мәхәббәтен җиргә күмә... Аның мәхәббәте дә шул каен тамыры кебек күмелеп, сер булып, күренми, беленми калды түгелме соң?

Чыңгыз тагын парк буйлап китте. Йөри-йөри, үзе дә сизмәстән, зиратка килеп керде. Зиратта аны һәрвакыт эзәрлекли, шундук җанына үтеп керә торган таныш салкынлык билэп алды. Элек бала йоннарын кабартып, җанын өшеткән ул салкынлыктан хәзер аңа ничектер рәхәт булып китте. Чыңгыз зиратта үз хәленә чын иптәшлек, аһәңлек тапты. Һәр каберлек ул — мәхәббәт каберлеге дә...

Шушы очрашудан соң, әкренләп, Диларәләргә барып кайткан саен берәм-берәм сүнә барган шәмнәр дөньясы дәррәү сүнде. Ул инде хәзер беркайчан да — ишетсен дөнья!— беркайчан да хатын-кызның изгелегенә, күңеле сафлыгына ышанмаячак!..

Чыңгызның да алиһәсе үлде. Беренче тапкыр күреп калганнан соң, ике ел буе бөтен җаны-тәне белән хыялында Диларәнең идеал образын төзегән иде ул. Әгәр һәр көнне бер бизәккә тиңләсәң, ике ел буе үзенчә мәхәббәте тәхетен, бәхете тәхетен бизәгән иде Чыңгыз. Менә шул алтын тәхет, комнан төзелгән сарай кебек, ишелде дә төште.

Врачлар күпвакыт бүтәннәр белмәгәнне беләләр, бүтәннәр күрмәгән нәрсәне күрәләр. Чыңгызга да, эше буенча, җавапсыз мәхәббәт аркасында кайбер кызларның, егетләрнең үз-үзләренә кул салуы яки төрле дару яисә агулар эчүе, яшь ирләрнең исә тәүге төннән күңелләре кинәт бозланып, хыянәттән өметләре тәмам өзелеп, эчүчелеккә сабышулары белән очрашырга туры килә иде. Бу — чарасызлык, җанга бүтән оя таба алмау бәласе. Әлбәттә, моның турында күп сөйләргә яратмыйлар. Ләкин тормышта ул мәсьәлә, ул кайгы бар һәм ул, тау чишмәсе кебек, төптән генә, челтер-челтер генә ага һәм йөрәкне кага бирә. Ирләр мондый кайгыны сөйләмиләр, эчтән сыза ир күңеле.

* * *

Ни өчен нәкъ менә Диларәгә гашыйк булды соң әле ул? Чыңгыз бу турыда күп уйлады. Әмма һәрбер уй аның тормышында иң якты истәлек булып калган бер вакыйгага кагылып үтә иде. Эш шунда: диссертация яклагач, кафедрада аңа урын табылмады. Яше алтмыштан узган мөдир ханым, Чыңгыз Исламовичтан шүрләде булса кирәк, ассистент итеп аны түгел, урта яшьләрдәге бер хатын-кызны алды. Чыңгыз артык хафаланып йөрмәде, фәнгә кул селтәде дә, өч елга Кубага китеп барды. Менә шул Кубада үткәргән өч ел аның хәтерендә мәңгелек истәлек, язмышында тимер чылбырга таккан алтын буын сыман балкып калды да инде.

Чыңгыз Кубада хәрби госпитальдә эшләде. Вак-төяк тормыш-көнкүреш вәсвәсәләреннән, бигрәк тә фән өлкәсендәге җан өшеткеч ыгы-зыгылардан кинәт котылу аңа моңарчы күрмәгән, татымаган буш вакыт бирә, башын кырык төрле күңелсез уйлардан арындыра һәм тормышының бөтен гүзәллеген, бөтен көчен, тәмен белеп яшәргә дәртләндерә иде. Кояш, искиткеч матур табигать, ирек күңелләрне йомшарта, уйларны нечкәртә, хисләрне нәфисләндерә. Ярда кызынып ятканда тәнне, хәтта җанны да җылы җил — дулкын җиле иркәли. Табигать хозурлыгын, яшәү рәхәтен тоюдан сулыш тирәнәйгән, йөрәк тынычланган шул минутларда, ирексездән, янәшеңдә иң бөек, иң кадерле кеше итеп санарлык сөйгәнең булуын тели башлыйсың. Аның алтын ком өстенә сибелгән чәчләрен иркә генә, сак кына сыйпыйсы, нур булып аның йөрәгенә үтеп керәсе, җил булып аның

керфекләреннән үбеп аласы килә. Аның һәрбер күзәнәгеннән ялаган әрсез кояштан, күкрәкләренә кагылган, тәненең иң серле җирләренә хәтле үтеп кергән оятсыз, ялагай җилдән чын-чынлап көнләп, алардан күкрәгең белән каплап саклыйсы, яшерәсе килә. Ничек сөясе һәм сөеләсе килә шул минутта! Ак канатлар тагып төпсез зәңгәр күккә, бик биеккә менеп, сөйгәнең алдында әллә нинди батырлыклар кыласы, ак җилкәнгә утырып дулкыннар белән көрәшәсе килә. Беләктә бетмәс-төкәнмәс көч, йөрәктә бетмәс-төкәнмәс дәрт уяна һәм син үзеңне мәңге шулай шат, яшь килеш калыр кебек хис итәсең. Мәхәббәтең өчен, сөйгәнең өчен бар җаның бер тамчыга тулып өзелеп төшәр шикелле. Нинди татлы, тылсымлы сүз — мәхәббәт!

Чыңгыз нәкъ менә шунда, шул вакытта әле канатлы мәхәббәт кичермәгәнлеген аңлап алды. Аның ничек кенә булса да үз мәхәббәтен табасы, канатлы мәхәббәт кичерешләрен татып карыйсы, гомер юлындагы шушы тау бакчасына, соңарса да, менеп карыйсы килде. Хисләрнең иң тирән, дәртнең иң көчле чагы булган канатлы мәхәббәт хәлен кичермәсә, ул гомере буе үкенеп, бик үкенеп, кимсетелгән, өметен югалткан сукбай кебек кенә яшәр кебек иде. Әгәр инде, язмыш кушып, ул шундый мәхәббәтне очрата икән...

Үзенең менә шундый сөйгән кешесе булмау сәбәпле, үткән гомерендә, язмышында бушлык сизде Чыңгыз. Шул бушлыктан аның йөрәге авыртып сыкрады. Кубадагы өч ел, таныш-белешләре белән элемтәләрне өзеп, оныттырып, бу бушлыкны тагын да зурайта, тирәнәйтә генә түгелме соң? Менә шуннан курка иде Чыңгыз. Менә шул шом, күзгә кергән тузан кебек, вакыт-вакыт җанын әчеттерә һәм һәрвакыт, ап-аяз күктә кинәт хасил булган кара болыт сыман, көтмәгәндә уйларына килеп кереп, күңелен бозгалап тора иде.

Кубада төннәр бик караңгы була. Ай да Казандагы кебек елмаеп, теләктәшлек сирпеп, кызыксынып тормый, ә арган шикелле, битараф кыяфәттә, «Синдә кайгым юк, мин үзем дә ялгыз» дигәндәй, күккә карап, җиргә сыртын куеп ята. Йөзен күккә каратып ятканга, елмаймаганга җиргә яктылыгы җитми айның. Күрәсең, шуңа төннәр дөм-караңгы. Караңгыда күңелсез. Уй юк караңгы төндә. Ай калыктымы — уй туа һәм уй-тойгылар белән серкәләнеп, күз ачып йомганчы хыял булып күпереп җитә. Айлы төн — хыялый төн. Айлы төндә тормыш салмаклана, ниһаять, үзенең табигый эзенә кергәндәй булып китә. Җирдә, җиһанда бөтен шыксызлык югала, чокыры-чакыры нур белән тулып тигезләнә, йөрәкне моң баса. Күңелгә шундый рәхәт, шундый рәхәт, хәтта таңны — таңның үзен бит!— аттырасы килми.

Шулчак кайдандыр йомшак кына гитара тавышы ишетелә. Аһәң, ритм килеп кушыла. Ритм күңелгә шулкадәр тәңгәл килә, әйтерсең, гитарада кеше түгел, нурлары белән йөрәк кылларына чиртә-чиртә, Ай үзе уйный. Моңга ритм кушыла, йөрәк дәртләнеп тибәргә тотына, шатлык күңелдән ташып чыга, ирексездән биисе килә башлый. Ләкин ялгыз түгел, парлап биисе, баш әйләнгәнче, җир — мамыкка, куллар канатка әйләнгәнче бөтереләсе килә.

Караңгы төннәрдә күз күктән бер генә булса да якты нокта эзли. Йолдыз күп кирәкми, берәү дә җитә. Күзгә дә, җанга да нур сирпи торган бер генә йолдыз кирәк. Бердәнбер йолдыз. Ә йолдызлы төннәрдә күз алдана, сайлана башлый, әле анысы, әле монысы яктырак яна кебек күренә. Күз сайлый белми бит ул. Күз генә түгел, йөрәк тә еш кына ялгыша әле.

Нигә хыялның чиге юк икән? Алдый да алдый хыял күңелне. Канатлар да китереп тага үзе, ә менә шул канатларга сине җирдән аерырлык егәр бирми.

Мәхәббәт юклыктан, өзелеп сөярлек ярың юклыктан килә тор-

гандыр, ахры, артык хыяллану. Ярата башладыңмы — бөтен изгелекләр, бөтен гүзәллек, иң югары, иң тирән мәгънәләр — барысы бергә — бер кыска гына исемгә сыялар да бетәләр.

Чыңгызның йөрәген кайчакта курку да биләп ала иде. Әгәр ул инде хәзер мәхәббәтен таба алмаса, беркемне дә ярата алмаса? Мәхәббәтен таба алмыйча гомергә шулай ялгыз калыр микәнни?.. Шундый итеп, тирән итеп, җаның фида кылырлык, яшьлегең кире кайтырлык итеп яратасы иде бит, әй! Бардыр ич инде аның өчен дә җанкай-җанаш. Юкка гына сулкылдап сусамыйдыр инде күңел, сизгәнгә сусыйдыр...

Таңнарда — Таңсылу, тауларда — Таусылу, айлы төннәрдә — Айсылу, диңгездә Сусылу күтә сыман иде аны.

Чыңгыз госпитальдә бер хирург — кубалы Рауль Гомец Михель белән дуслашты. Гомец Михель аны су астында йөзәргә һәм рәсем төшерергә өйрәтте. Гомец Михельнең бабасы энҗе эзләүче булган икән. Әлек нәселдән нәселгә күчә килгән бу һөнәргә ул бабасыннан өйрәнгән. Хәзерге заманда, билгеле, суга акваланг киеп чумалар һәм энҗе эзләү — элеккеге кебек осталык та, батырлык та таләп итми.

Диңгез төбе сокланып туймаслык, гаҗәеп дөнья булып чыкты. Табигатьтә бер генә дә очраклы нәрсә юклыгына, һәр төснең, һәр тамганың, һәр билгенең сәбәбе, мәгънәсе, мохит белән тыгыз бәйләнеше барлыгына барыннан да бигрәк диңгездә ышанасың икән.

Диңгез Чыңгызның хыял бишегенә әйләнде. Монда ул үзен әкияттәге Сусылу патшалыгына иңгәндәй итеп тоя һәм, укымышлы ир-егет булуына да карамастан, шул әкияткә, Сусылу белән очрашуына, бала шикелле, ихлас күңелдән ышана, инана башлый иде. Шуңа күрә, җай чыгу белән, ул диңгезгә ашыга; шуңа күрә, Гомец Михель бара алмаганда да, бар куркуын онытып, ялгызы гына йөзә иде. Хәер, куркыныч булса да, ялгыз йөзү аңа — ялгызлыкка күнеккән кешегә — кызыграк та иде. Болай ул үз көенә, уйланып, хыялланып йөзә. Чыңгызга һәрвакыт аны диңгездә Сусылу күтә, уйнар, шаярыр өчен ялгыз йөзгәнен сагалап тора сыман тоела иде.

Диңгезнең байлыгын, гүзәллеген әйтеп бетерерлек тә, күреп бетерерлек тә түгел. Урман-урман булып утырган мәрҗәннәр, болын-болын булып җәелеп киткән суүсемнәр, гаскәриләр сыман катып калган мәгърур кыяташлар, төрле төстәге бакырчыклар, балыклар, мең төрле башка җан ияләре — болар бар да су астын бизәр өчен генә дөньяга яралгандыр.

Җиһанның иң гүзәл почмагы булган су асты күренешен табигать теләсә кем күзеннән махсус яшереп, батыр йөрәкләр өчен генә саклыйдыр шикелле. Ләкин, һәрбер матурлык кебек, бу зәңгәр тынлык та — ялган матурлык. Әлеге зәңгәр гармония яшен тизлегендә бозылырга мөмкин. Чөнки бу зәңгәр пәрдә астында һәр минут, һәр секунд яшәү өчен аяусыз көрәш бара. Берәүләрнең үлеме икенчеләрне яшәтә. Анда да табигатьнең котылгысыз кагыйдәсе хөкем сөрә: йә — көчле, йә хәйләкәр җиңә. Нишләп гүзәллек шулкадәр гаҗиз икән? Ник һәрбер җан иясе үзен яклый да, саклый да алмый икән?

Кызык: кеше үзенең табигатьтән яралуын, экологик законнар каршында хокукы акуланыкы, әкәм-төкәмнеке, суүсемнеке кебек кенә икәнен бары тик шунда — диңгез төбендә генә чын-чынлап аңлыйдыр, мөгаен.

Гомец Михель белән Чыңгыз Кариб диңгезендә дә, Мексика култыгында да йөзде. Су астындагы кыяташларның, мәрҗәннәрнең Җир шарында иң матур җире Кариб диңгезе икән. Ә кубалылар, күрәсең, моңа күнеккән. Аларның бу гүзәллеккә һич тә исләре китми, әйтерсең, ул башкача булырга да тиеш түгел.

Шулай итеп, берсеннән-берсе күркәм мавыгулар белән өч ел үтеп тә китте. Казанга кайтканда Чыңгызның хыялый мәхәббәте, хатын-

кыз турындагы идеалы, гомумән, хатын-кызга карата ялгызлыкта гына туа торган күтәренке, тәэсирле мөнәсәбәте һич җуелмаслык булып өлгереп, бер калыпка сыешып беткән иде инде. Бүтән төрле итеп әйткәндә, бизәкле кыса әзер, шул кысага киертергә портрет кына кирәк иде. Ләкин иң кыены менә шул кысага ярарлык портрет табу да иде инде.

Чыңгыз мәхәббәтне иҗади нәрсә дип, теләгән кешегә күңелдә мәхәббәт уятып, аны үстереп, иҗат итеп була, дип уйлый иде. Гүзәллекне һәркем таныган кебек, саф, көчле мәхәббәт алдында теләсә кайсы сөйгән ярның йөрәге эреп төшәр төсле тоела иде аңа. Бары тик сокландырырлык итеп, рухланып ярата белергә генә кирәк.

Әгәр Кубада эшләмәгән булса, аның күңеле бу кадәр үк бай, мәхәббәте шулкадәр үк көчле булмас иде, мөгаен. Ачлыктан интегеп карамаган кеше икмәкнең кадерен, чын тәмен белмәгән кебек, ялгызлыкта яшәп карамаган кеше дә җанга бәлзәм булган мәхәббәтнең асылын, кадерен, тәмен белә алмый. Берәү дә сусамыйча су эчми. Мәхәббәттә дә шулай бит: сусамасаң сөя белмисең. Бәгырьсез сөю — кадерсез. Менә шуңа күрә, Чыңгызның Кубада йөрәгенә уеп кайткан хыял кысасында яшь Диларә бер күрүдә керде дә утырды.

* * *

Күпме бармыйча йөргәндер Чыңгыз Гыймаевларга, анысын санамады. Һәрхәлдә, аңа бик озак сыман тоелды. Алмаз шалтыраткач, әллә нәрсә булды тагын: әллә антын онытты, әллә аны хаксыз дип тапты, түзмәде — барды. Акылы теләмәсә дә, аяклары тартты. Әкълимә ял йортына киткән иде. Диларә өйдә күренмәде. Хәер, аның өйдә булмавы яхшырак та иде Чыңгыз өчен. Алмаз үз эше буенча киңәшләшергә чакырган икән. Алар бик озак сөйләшеп утырдылар.

Диларә төнге унберләр тирәсендә кайтты. Кулында кыр чәчәкләре иде. Диларә ишек ачканда сикерә башлаган йөрәге чеметтереп алды Чыңгызның. Әллә сизми иде кызындагы үзгәрешләрне Алмаз, әллә шулай тиеш сыман кабул итә иде — монысын Чыңгыз аңламады. Шул көннән алып Чыңгыз чәчәкләргә шактый гына үпкә саклап йөрде. Үзе генә чәчәк бүләк итә, дип йөри иде бит ул Диларәгә...

Диларәләргә барып кайткан саен үз идеалыннан бер басмага төшә-төшә яратты аны Чыңгыз. Ә кыз исә, басмаларны санап торган шикелле, Чыңгызны түбәнгә таба атларга мәҗбүр итүче сәбәпләрне табып кына тора иде.

Нигә кирәк аңа берьюлы «биш поклонник»? Мактану өченме? Әллә берәр төрле комсызлыкмы? Дүртесен алдап йөри дигән сүз бит бу. Шул бишесе арасыннан иң яхшысын, үзеңә ошаганын сайлап, калганнарын, өметләндермичә, кире борып булмый микәнни соң аларның?

Чыңгыз үзе озын буйлы, камыш кебек төз гәүдәле. Ошаган кызны үзеңә карата алуына Чыңгыз беркайчан да шикләнмәде. Әмма кемнеңдер бәхетсезлегенә корылган бәхет аның өчен тәмсез, кирәксез бәхет иде. Ул беркайчан да кемне дә булса ымсындырып йөрмәде. Диларә Чыңгызның бу таләбенә дә җавап бирә ала, чөнки ул әле бик яшь һәм аның бу яшьтә, Чыңгыз уйлаганча, яраткан кешесе дә булмаска тиеш иде. Әгәр Диларә белән якынаеп китсәләр, ул кемнең дә юлын кисмәс иде ич.

Диларә өченче курска күчте. Чыңгыз аларга хәзер мәхәббәтен искә алу мәҗлесенә йөргән шикелле генә, йола үтәргә килгән шикелле генә йөри иде инде.

Ул җәйне Диларә әнисе тапкан путевка белән Балтыйк диңгезе буенда, яшьләр лагеренда ял итте. Шуннан кайткач, ахрысы, Диларә

ничектер дипломатын ачканда, дипломаттан бер кап сигарет төшеп киткәнен абайлап калды Чыңгыз. Һәм, ирексездән, кызның иреннәренә игътибар итте. Шундук аңлап алды: Диләрә, һичшиксез, тәмәке тарта башлаган иде. Ә этисе диссертация язды да диссертация язды...

* * *

Көннәр үтә торды. Бервакыт, приказ язып утырганда, ишек шакыдылар.

— Керегез.

Ишектән, кыюсызланып кына, Диләрә килеп керде.

— Син мени бу, Диләрә?— диде Чыңгыз, урыныннан үзе дә сизмәстән сикереп торып. Аннары, дулкынлануын яшерергә тырышып:— Нинди җилләр ташлады сине бу якка?— диде.

— Менә юл уңаеннан, үтеп барышлый кердем әле, без илленче балалар больницасында практика үтәбез.

— Утыр, бераз ял итеп китәрсең. Мин әкрен генә менә шушында эшләп ятам инде.

— Матур урында урнашкан икән. Кабан күле дә уч төбендәгедәй күренеп тора.

— Берәр йомыш белән килгән идеңме?

— Әйе, каян белдегез?

— ...

Чыңгыз Диләрәгә сокланып карап куйды. Диләрәнең аңа йомышы төшүгә, бигрәк тә, ниһаять, үзенең монда килүенә ул чиксез шат иде.

— Тыңлыйм, Диләрә.

— Миңа сезнең ярдәмегез кирәк, Чыңгыз абый... Дөресрәге, миңа бары тик сез генә ярдәм итә аласыз. Ләкин әниләр бу турыда белергә тиеш түгел...

— Килештек.

— Мин ялгыштым...

Диләрә, башын читкә борып, кулъяулыгы белән күзләрен сөртергә тотынды.

— Мәхәббәттәме?

— Әйе...

— Аңлашылды.

— Миңа бит тиз эшләргә кирәк. Мин анда кереп яталмыйм. Кая карама, бөтен җирдә безнең студентлар. Миңа кич белән кереп, иртән чыгып китә торган итеп сөйләшергә кирәк. Безнең группадан бер кыз шулай эшләде. Беркем дә белмәде. Әтиләргә мин, иптәш кызларымда кунам, дияр идем.

Чыңгыз Диләрә алдында үзен чын ир, акыллы, батыр һәм мәрхәмәтле кеше итеп күрсәтергә тырышты. Кызның йөрәк ярасына тоз сибеп, сораулар биреп, төпченеп маташмады. Тик, шулай да, башына кемдер китереп суккан, миңгерәүләнгән кеше кебек, беравык ни эшләргә белмичә, уйланып утырды, аннары калтыранган куллары белән телефонга үрелде. Дер-дер килгән бармаклар тиз генә номер җыя алмый интекте.

— Әйдә, барып кайтыйк, барыбер аларны телефоннан тотып булмый. Шунда сөйләшербез. Син, чыгып, машинага утыра тор, мин хәзер төшәм,— диде ул, мөмкин кадәр тынычрак күренергә тырышып.

Чыңгыз бу көтелмәгән хәбәрдән өнсез калды. Диләрәне алданрак төшереп җибәрүенең сәбәбе дә бүлмәсендә бераз хәл җыеп, тынычланып алу иде. Ләкин, Диләрә ишекне ябу белән, ул биредә йөрәк ярсуын баса алмаячагын аңлады.

Машинада Чыңгыз Диләрәгә карамаска тырышты. Чыңгыз махсус

шифаханәнең баш врачы Георгий Романович Борисовка мөрәҗәгать итте. Сөйләшә торгач, аңлаша торгач — ә врач врачны һәрвакыт аңларга тиеш — килештеләр, көнен билгеләделәр. Чыңгыз машинада илтеп куярга тәкъдим итсә дә, Дилара аның бу сүзен кире какты, рәхмәт әйтеп, җәяү генә кайтып китте.

Машинада тирбәлеп кайта-кайта, Чыңгызның күз алдына, бербер артлы, Диларәнең сабый чагы белән бәйләнешле вакыйгалар килә башлады. Барыннан да бигрәк, хәтеренә Диларәне бала табу йортыннан алып кайткан көн уелып калган. Җылы, җилсез кышкы матур көннәрнең берсе иде ул. Җиргә талгын гына тәңкә-тәңкә кар ява иде. Табигать җирдәге иске эзләрне күмеп, яңа эзләргә — Дилара эзләренә ак хәтфә әзерли. Алмаз Диларәне ак юрганга төреп алып чыккан иде. Юрган алсу тасма белән бәйләнгән... Алар бергәләп фоторәсемгә төштеләр. Ул рәсем әле дә Чыңгызның альбомында саклана.

Диларәнең тәүге елмаюы, нәни куллары белән аны кочаклавы, иркә, күркәм, матур кыланышлары, назлы шаярулары — болар барысы да, яз көтеп күмелеп яткан орлыклар шикелле, Чыңгызның хәтерендә кинәт берьюлы шытып чыкты.

Аннары бушлык. Диларәнең мәктәп елларын Чыңгыз инде бөтенләй белми. Һәм шушы бушлык аркасында ул Диларәне аңлап та бетерми төсле.

Чыңгызның Диларәне инде байтактан күргәне юк. Өйләренә дә барганы юк. Кирәксә, Алмазның эш урынына гына бара иде, андый күрешү-очрашуларны да нык сирәгәйтте.

Күпмедер үткәч, секретарь ханым: «Бер кыз калдырды»,— дип, аңа икесе кызыл, берсе ал төстәге өч канәфер чәчәге кертеп бирде. Алар ясалма чәчәкләр иде. Кыз үзенең кем икәнлеген әйтмәгән. Киеме, кыяфәте турында сорашкач, Чыңгыз чәчәкләрне Дилара калдырып китүен белде. Менә шуннан бирле утыра тәрәзә төбендә өч канәфер чәчәге.

Ни өчен Дилара аңа ясалма чәчәкләр бүләк иткән — Чыңгыз моңа һич кенә дә төшенә алмады. Озак торсын өченме? Кыш көне бүтән чәчәк таба алмау аркасындамы? Әллә кызык, оригиналь булсын дипме?

Үзенең Диларәгә кылган ярдәмен Чыңгыз соңыннан гына бөтен тирәнлеге, нечкәлеге, бөтен фаҗигасе белән, әкренләп, бер атнадан соң гына аңлый башлады.

Ачы, бик тә ачы булды ул хакыйкать. Ир-егетнең күзе еламый, күңеле генә елый шул. Шуңа күрә ир кайгысы күзгә күренми. Шуңа ир-егетнең ничек елаганын ходай үзе генә белә.

Бәхетсез мәхәббәт — кеше өчен зур кайгы, ләкин үтә торган кайгы. Бер мәхәббәт ярасын икенче мәхәббәт дәвалый. Ә менә идеалыңны югалту — мәңгелек югалту. Аны алыштырып та, дәвалап та була торган түгел. Бу югалту күңелдә мәңгелек бушлык калдыра. Чыңгызның да дөньясында кояш тотылды. Алиһәсе үлде.

Дилара аның күңел кылларына балта белән китереп чапты. Кылларның өзелгәндә ялваруы әле дә колагында зыңлап тора Чыңгызның. Бәлки дөрес эшләгәндер Дилара? Кем белә, әле күпме алданып, хыялланып, сагынып-саргаеп яшәгән булыр иде Чыңгыз. Хәзер барысы да көн кебек ачык, һәммә нәрсә үз урынына кайтып төште...

Вакыт үтә-үтә, Чыңгызның да Диларәгә үпкәсе кими барды. Хәзер инде ул, нишләптер, Диларәгә тел-теш тидереп, аны гаепли алмый иде. Дилара — замана баласы. Барысын да шуның белән аңлатып була. Һәм шулай гына аңлатырга кирәк тә. Чыңгызны музыкага, рәсемгә, иҗатка илһамландырган өчен, аңарда йоклап беткән сәләтләрне уяткан өчен мең-мең рәхмәт Диларәгә!..

Чыңгыз мәхәббәттә хәер сорашып йөрмәс. Аңа әле кырык кына яшь. Нәрсә ул таза ир өчен кырык яшь? Замана күзлегеннән караганда яшьлекнең яшьлеге генә әле ул. Ул әле табар үз ярын, үз яртысын. Аннары, Диләрә белән кавышырмын дип уйламаган да иде бит ул. Мәхәббәткә лаеклы булырга гына кирәк. Чиләгенә күрә капкачы табылмыйча калмас, табылыр. Чыңгыз язмышка ышана. Изгелекнең җирдә ятмавына, бәхетнең кабатлануына ышана. Хәтта яшьлеге дә кире кайтыр сыман әле аңа...

Күп тә үтми, Диләрә кияүгә чыкты. Бу хәбәр яңалык түгел иде инде Чыңгыз өчен. Алмаз аны алдан ук искәртеп куйган иде. Чыңгыз, шалтыратып, аларны телефоннан гына котлады, чакырулары өчен бик зур рәхмәтен, инде егерме ел Диләрәнең туена әләгү турында хыялланyуын, ләкин ялын алдан ук планлаштыруын, инде билетлар да алып куюын, бер төркем альпинистларга врач булып баруын, бик нык үкенүен, әмма хәзер инде соң булуын, берни дә эшли алмавын әйтеп, тиз генә ял алып, чыннан да, альпинистларга ияреп, Тянь-Шань тавына китеп барды.

Диләрәнең кияүгә чыкканына быел өч ел тула. Ул кияүгә чыкканнан бирле, Чыңгызның аларда булганы юк. Һәм оныткан да кебек иде бит ул Диләрәне. Бүген генә, әле генә теге кыз кереп, яңартты аның ярасын. Юк, ярасын түгелдер, хәтерен генә. Әйе, әйе, хәтерен генә...

Кыз, чыннан да, Диләрәгә бик тә охшаган иде. Шундый ук кашлар, шундый ук күзләр... Кыз Диләрәнең коеп куйган күчермәсе иде. Шуңа кызыксынды да Чыңгыз аның тормышы белән. Язмышларында да берәр охшашлык юк микән, дип уйлады.

Кайчандыр, кайдадыр укып та, уйлап-күзәтеп тә ул шундый фикергә килгән иде: һәр адәмнең җирдә табигый күчермәсе бар, ягъни аңа охшаган тагын бер кеше яши. Наполеонның, мәсәлән, шундый күчермәсе булган. Гомумән, кайбер корольләр андый кешеләрне махсус эзләтеп таптырганнар. Шаяра язмыш Чыңгыз белән, һаман шаяра. Юкса бүген Диләрәнең күчермәсен аңа үз аяклары белән китереп кертер идемени? Үшән, Диләрәдән колак каккан идең, инде бусы белән нишләрсең, ди микән?..

Сәгать кичке тугыз тулып килә иде инде. Дежурда түгел микән, дип, Чыңгыз Борисовка шалтыратты. Ул тагын Георгий Романович аркылы эш итеп карамакчы иде. Телефонны алучы булмады. Бүлеккә шалтыраткач, анда бүтән кешенең дежур икәнлеген әйттеләр.

Кызга ярдәм итүне хәзер үзенең җан бурычы дип исәпли башлады Чыңгыз.

Георгий Романович белән ул икенче көнне, чәршәмбе көнне, шәһәрнең сәламәтлек саклау бүлегендә киңәшмәдә очрашты. Киңәшмә беткәннән соң, аның кадрлар бүлегендә эшен бетерүен махсус көтеп торды. Сөйләшә-сөйләшә кайтырга чыктылар. Җаен туры китереп, Чыңгыз сүз кузгатты:

— Георгий Романович, кичә минем белән бер кызык хәл булды бит әле. Кешеләр кабул итеп утырганда, бүлмәгә бер кыз килеп керде. Яндым ди, гинекологка керергә теләмим, шуңа күрә сезгә кердем, ярдәм итегез, ди...

Георгий Романович Чыңгызның сүзләренә игътибар итмәде. Аның үз кайгысы кайгы иде. Ул киңәшмәдә күтәрелгән хәлләр турында борчылып бара иде. Чыңгыз Исламович аны, сак кына, тагын бер тапкыр, соңгы тапкыр сүзгә тартырга тырышып карады:

— Әйттем, мин сезгә ярдәм итә алмыйм, бу эштә белгечләр белән киңәшеп карарга кирәк, алар нәрсә әйтерләр, дидем...

Георгий Романовичның бу юлы да исе китмәде. Әйтерсең, ул Чыңгызны бөтенләй ишетми дә иде. Алар бераз сүзсез бардылар.

Чыңгыз кыз турында сүз кузгатырга бүтән батырчылык итмәде. Чатка җиткәч кенә теле ачылды Георгий Романовичның:

— Бирә кирәгэн егетләр, ә? Киңәшмә арты киңәшмә җыйдылар, ике битлек план яздырттылар, комиссия төзеттеләр: быел ташу көчле була, имеш. Галәмәт! Ә кар, тавышсыз-тынсыз, бер атна эчендә эреде дә бетте. Галим дә белми, мөгаллим дә белми табигать кодрәтен. Апрельдә мондый җылыны мин хәтерләмим дә шикелле... Озакламый барыбер салкынайтачак. Иделдә боз кузгалганда һәрвакыт салкынайта, бер атна чамасы салкын булып торачак. Тагын майда, шомырт чәчәк атканда салкынайтып ала...

Чыңгызның исә җаны тыныч түгел иде. Ул һаман кыз мәсьәләсен берәр ничек хәл итү турында баш ватты.

Георгий Романович белән алар Игезәкләр урамында аерылыштылар.

Пәнҗешәмбе көнне ул беркая да шалтыратмады, кыз үтенече артыннан йөрмәде. Җомга көн дә, шимбә көн дә шулай ук үтеп китте. Дүшәмбе көн кыз керергә тиеш. Әлбәттә, кыз керәчәк, аның бүтән чарасы юк. Аның бүтән барыр җире юк. Аның бүтән ярдәмчесе юк. Ә Чыңгыз исә кыл да кыймылдатмады. Кызның үтенечен кире кагыр иде, үзенең булдыксызлыгын күрсәтәсе дә килми...

Шулай чарасызланып, инде катгый бер карарга килеп, кызга ярдәм итмәскә уйланып йөргәндә, якшәмбе көнне иртән бассейннан чыгышлый, аңа Тукай урамындагы тәпәннән сыра эчеп кайтып килүче курсташы Владимир Кузьмин очрады. Кузьмин врачларның белемен күтәрү институтына ике айга укырга килгән икән. Чыңгыз аны үзенә кунакка алып кайтты. Ирләр җыелып утырган җирдә һәрвакыт бәхәс куба. Владимир да кабакта бәхәсләшкән кайнарлыгыннан суынып җитмәгән иде әле. Шуңа ул, кунак буларак, хуҗаның өе белән танышып та, хәл-әхвәл сорашып та маташмады. Аңа бу минутта үз туксаны туксан иде. Чыңгыз исә кеше килеп кермәс борын ук аңа сораулар бирә башлауны әдәпсезлек санады. Өлгерермен әле, дип уйлады. Кунакның күңеле тынычланганын көтте.

— Кая бара бу дөнья, Чыңгыз?— дип башлады сүзен Кузьмин. Нишләтә безнең гүзәл хатын-кызларыбыз? Нишләтәләр безне? Нинди көя төште аларның мамык җаннарына?.. Беләсеңме, Чыңгыз, мин хәзер гел шул турыда уйланам. Әллә картлык баса, әллә хаклык — алла белсен. Кайчагында төннәр буе йоклый алмыйм ятам. Төнге дежурларга күп йөргәч, йокы ритмы бозыла, йокысызлык белән җәфа чигәм. Минем дә кыз үсә бит. Тиздән кәләш булачак. Көннәрдән бер көнне кайтып керер дә: «Әти, коткар, син белгеч бит»,— дияр. Нишләрсең шунда, ә?

— Ә син аны тәүфыйкълы итеп тәрбиялә...

— Тәүфыйкъ, имеш. Сез — буйдаклар — бөтенегез акыл сатарга осталар. Әнә безнең кызның класс җитәкчесе, ата-аналарны җыя да, ничек бала тәрбияләргә өйрәтеп, сәгатьләр буе лекция укый, үгет-нәсихәт бирә. Ә үзенең баласы юк, кияүдә дә түгел. Нәрсә белә соң ул гаилә мәсьәләсендә, бала тәрбияләү турында? Һаман шул китап сүзе. Ә китап еш кына алдаша. Башта бер академик теориясен ятлаталар, аннары, ул үлгәч, аның китапларын ертып аталар да, алай түгел, болай ул, дип, адәм башын йөз сиксән градуска борып, мигә шуның киресен тукырга тотыналар.

— Монда бит укытучылар гаепле түгел.

— Укытучылар гаепле булмаса, мәктәп гаепле. Син анда балаларны нәрсәгә өйрәткәннәрен беләсеңме соң?

— Юк.

— Бәхетле кеше син, Чыңгыз.

— Шулай да...

— Элек аларның бөтенесен югары уку йортларына әзерлиләр

иде, сан кирәк иде: кемнеке күпме кергән. Хәзер бөтенесеннән шәһәрдә — эшче, авылда крестьян ясамакчылар. Тагын сан кирәк: кемнең күпмесе заводка киткән яки авылда калган. Ә зур тормышка аларны беркем дә әзерләми.

— Ата-аналар, гаилә әзерләсен.

— Каян ул ата-ананың вакыты калсын инде? Мин, мәсәлән, ике ставкага эшлим, чөнки эшләргә кеше юк. Бүлектәге өч хатын-кызның берсе елдан артык декретта утыра, икенчесе туктаусыз бюллетеньдә, өченчесенең яшь баласы бар — аны төнге дежурлыктан азат иттеләр. Миңа ставка ярымнан артыгын түләмиләр, ярамый, имеш. Телең этнеке кебек салынып төшкәнче эшләргә ярый, ә акчасын алырга ярамый икән. Инструкция, приказ... Хатын да ставка ярымга эшли. Яшәргә кирәк бит. Иртәдән кичкә тикле участокта чаба. Менә шуннан үзең исәпләп чыгар, арган ата-ананың балага күпме вакыты кала да, күпме көче кала? Телисеңме, теләмисеңме — баланы хәзер барыбер мәктәп белән урам тәрбияли. Түлә син миңа хатын акчасын да: ә ул өйдә утырсын, бала тапсын кимендә өчне, аларны чирләтмичә үстерсен, тәрбияләсен, илгә таза, сау-сәламәт, хезмәт сөючән граждannар үстерсен. Илгә дә файда, иргә дә файда. Ә болай... Гаилә саен бер бала, бердәнбер эгоист. Ике балалы гаилә инде ишле бала исәпләнә. Ә бала үстерү хәзер көннән-көн авырая гына бара. Шуңа күрә бер бала аз, ике бала инде күп. Менә кайда хикмәт. Ике бала да әле ул демография өчен артым түгел, син тартмыйсыңмы?

— Юк. Әйдә, кухняда тарт, мин чәй куя торырмын.

Алар кухняга чыктылар. Чыңгыз форточканы ачып җибәрде. Аның тыныч кына тыңлап утыруы Кузьминның күңеленә хуш килде, ахрысы. Эчен бушатудан канәгатьләнү хисе аның төсенә үк чыккан иде. Ул, тәмәкесен тирән итеп суыра-суыра, тагын сөйләргә тотынды:

— Тормышта эгоизмнан да көчлерәк нәрсә юк. Безнең белән эгоизм идарә итә. Хатыннар ирләр эгоизмыннан зарланалар, ирләр — хатыннарныкыннан. Аннан соң, ирләр белән хатыннар җыелалар да, балалар эгоизмын каргарга тотыналар. Балалар да буш калмый, алар ата-аналар, олылар эгоизмын тупка тоталар. Менә табып кара хакыйкатьне шушы лабиринтта!.. Син, Чыңгыз, үзең турында да уйла. Вакыт, бик вакыт. Соңга калуың бар. Исеңдә тот: кеше кешегә үзенең соңгы ипи сыныгын бирергә мөмкин, хәтта гомерен дә жәлләмәскә мөмкин, әмма бәхетен беркем дә, беркайчан да бүтәнгә бирми. Шуңа күрә әлектер тизрәк үз кисәгеңне.

— Шулаен шулайдыр да ул, тик мин бәхетне мәхәббәтсез күз алдына да китерә алмыйм. Бәлки, мин сиңа беркатлы бала-чага сыман күренәмдер. Ләкин мин моңа ышанам, ихлас. Мәхәббәт аркасында адәм баласы дөньяга килә...

Кузьмин шаркылдап көлеп җибәрде:

— Минем өлешкә кермә әле син, туганкай. Мин — акушер-гинеколог. Адәм баласының нидән һәм ничек дөньяга килүен абзаң синнән яхшырак белә. Һәрхәлдә, хатын-кыз минем кулга килеп эләксен өчен мәхәббәт бөтенләй шарт түгел. Мәхәббәт ул очкын кебек, мизгел генә, тормыш исә дилбегә кебек озын һәм тормыш үзе генә дә, мәхәббәтсез генә дә, шәп нәрсә. Ә, бәлки, мәхәббәтсез, йөрәк сикертүләрсез, газаплы төннәрсез җиңелрәк һәм яхшырак, гүзәлрәктер тормыш, ә?!

— Кемгә ничек бит, миңа калса, минем өчен бәхетнең нигезе — мәхәббәт.

— Бик мөмкин. Мин бит сине мәхәббәттән тәүбә иттерергә җыенмыйм. Күңелеңне бераз кети-кети итеп кытыклап, җенеңне генә чыгарырга маташкан идем. Үз дигәнеңчә яшә. Әмма ләкин,

кырыкка хәтле план корам, кырыктан соң плансыз гына торам, дигән әйтемне онытма.

— Халык бит аны алай димәгән,— «Кырыкка тикле корам, кырыктан соң бары белән торам», дигән.

— Бездә аны мин әйткәнчә әйтәләр. Һәр төбәкнең үз түмгәге инде.

— Хәтерлисеңме, Алмаз Гыймаев беренче курстан соң ук өйләнде?

— Нишләп хәтерләмәскә?

— Аның кызын ничек кулларында тотканына карап, мин көлә идем, оешып җитмәгәнлеген күреп кызгана идем. Алмазлар, иртә өйләнешсәләр дә, бер бала белән генә калдылар. Миңа сиңа тагын бер кызык нәрсә: иртә өйләнешүче студентларның күбесе шул бер бала белән кала, йә балаларының яшь аермасы бик зур була. Шуның аркасында балалар арасында психологик гармония бозыла. Һәм бу тәрбия эшендә тагын бер зур минус. Бәлки, син белмисеңдер, Алмазлар монда күчеп кайттылар бит.

— Чын диген?

— Күптән инде. Кызлары хәзер мединститут бетерә. Алмаз үзе тиздән кандидат булачак.

— Бигайбә туган. Кырык яшьлек кандидаттан фәнгә ни файда? Болай исем өчен, шөһрәт өчен, шәхси максатлар өчен ярый, әлбәттә. Ул бит алтын куллы егет. Бармакларын ходай биргән хирург бит ул. Ни пычагыма аңа диссертация?

— Кеше үлгәч тә өч көн хыялланып ята, диләр бит. Нигә кешенең канатын сындырырга? Булдыра ала икән, молодец кына инде...

— Мин дә Казанга кайтыр идем, хатын каршы. Андый мәсьәләдә хатын белән бәхәсләшү... үзең беләсең. Хәер, белмисең һәм белмәскә ходай насыйп итсен. Сине аңлый торган, санлый торган хатын бирсен ходай үзеңә. Кырыкка тикле саклангансың икән, туганкаем, инде теләсә кемгә капланма. Берүк ялгыша күрмә. Минем бер иптәш әйтә: «Кырыкта инде ир өйләнми, аны өйләндерәләр».— ди. Гафу ит, мин болай гына, сүз уңаеннан чыгып кына әйтәм. Акыл сатып әйтмим. Ә гаилә тормышы ул, туганым, диңгез өсте кебек: бүген болай, иртәгә тегеләй. Аңлашкан җирендә аңлашып, аңлашмаган җирендә алдашып яшисең шунда. Һәм күбрәк үзең өчен түгел, балалар хакына яшисең... Әйтик, ирләрнең эчкечелеккә тәгәрәвенә күбрәк хатын-кыз үзе гаепле. Мескен ирләрне якларлык бер генә закон да калмады бит хәзер. Бөтен закон хатыннар яклы. Ә хатын-кыз — төрле бит ул, хатын-кыз серле бит ул... Без аларны, президиумнарга утыртып, меңнәрчә трибуналардан «гүзәл хатын-кызларыбыз» дип дан җырлаган арада алар бозыла да башлаганнар икән ләбаса. Баксаң — араларында газиз балаларын ташлап качучылар да, фәхишәләр дә бар икән бит. Заман үзгәргән, иман күгәргән.

— Ну, Володя, син бигрәк инде тирәнгә кереп киттең бугай... Андыйлары аерым очрак кына ич аның...

— Белмисең икән, тыңлап тик утыр. Мин башламадым бит бу сүзне, үзең башладың. Шулай булгач, тыңла хакыйкатьне, Чыңгыз Исламович! Сал әле, җандагы юшкынны тагын бер тапкыр юып төшерим, ичмасам.

— Син капкалап та ал, болай башка тиз бәрә ич ул. Бер дә ашамыйсың...

— Бәрсен. Булганда бәреп калсын. Син инде, дустым, хакыйкатьне белергә телисең икән, аек башлар сүзен генә тыңлап йөрмә, исерек телләр сүзенә дә колак сал. Миңа ышанмасаң, мә, менә шушы куллардан сора. Кара, кара, чирканма! Менә алар — бәләкәй генә ике тырыш кул. Җир йөзендәге иң изге кулларның берсе —

минеке. Чөнки бу куллар дөньяга кеше тудыралар, ишетәсеңме, кеше! Ә нарасыйлар алар — сап-саф, шундый садә, шундый гаҗиз, аларның тәнендә хәтта бер генә микроб та юк. Тәүге сулыш алу белән генә алар үпкәсенә микроблар кереп тула. Әйе, әйе, мин үз эшемне яратам. Минем эш — бөек эш. Билгеле, һәр кеше үз эшен бөек эш дип санарга тиеш. Ләкин тормышта, җәмгыятьтә үз урынын тапкан кеше генә шулай ихлас әйтә ала. Минем эш — аерым бер төрле эш. Мин дөньяга яңа кеше, яңа тормыш, саф кеше, саф тормыш иҗат итәм. Ул аннары кем була — бусы сездән, ишетәсеңме, сездән тора. Мин анысына җавап бирмим. Минем кулда чакта алар берсе дә җинаятьче дә, фәхишә дә түгел. Мин аларны меӊ төрле үлемнән исән-имин алып калам. Үз эшемне мин намус белән башкарам... Кайчагында сырттан тир чишмә кебек ага, сәгатьләр буе бертоташтан операция өстәле янында торасың. Ләкин болар — исән калган ана белән, исән калган бала белән чагыштырганда, берни түгел. Ана хәлсез елмаеп, бала хәлле генә елап җибәргән шул мизгел өчен әллә нинди корбаннарга да ризасың. Юк, аны сөйләп булмый, аңлатып булмый, аны тоярга гына мөмкин.

— Көнләштерәсең бит.

— Ашыкма, дускай... Син сорамыйсың бит: нигә шул изге кулларың белән күпме яңа гомерне юк иттең, дип сорамыйсың?

— Ярый алайса, сорадым дип исәплә.

— Бәхетемә каршы, мин аларны санамыйм, санап барсам, йөрәгем әллә кайчан инде шартлап ярылган булыр иде. Күп, бихисап күп. Кешелекне бетерү өчен сугыш-мазар да кирәк түгел. Аның өчен хатын-кызны бәйдән генә ычкындыр, аңа чикләнмәгән ирек кенә бир. Әйдә, балконыңа чыгып тартып кerәбез. Юкса, монда тәмәке төтене сеңеп калачак. Атна буе төчкереп йөрерсең аннан соң.

Алар балконга чыктылар. Караңгы төшеп килә торган эңгер-меңгер вакыт иде. Кузьминның туктар исәбе күренми иде, Чыңгыз аны сабыр гына тыңлый бирде.

— Бозыклык, әшәкелек һәр җәмгыятьтә дә бар. Димәк, кешене изгеләндерү — уртак проблема. Һәм моңа без кешенең табигатен фән ярдәмендә үзгәртеп кенә ирешәчәкбез. Һәр бозыклыкның, начар гадәтнең баш миендә үзәге бар. Менә шул үзәкләрне өйрәнеп, аларны җиңел таба белеп, үзәк күзәнәкләренә ниндидер нур белән тәэсир итеп йә бөтенләй юк итәргә, йә бәйләнешләрен өзәргә кирәк. Кешене һәм җәмгыятьне камилләштерүнең бердәнбер юлы шушы, минемчә.

— Кешенең табигатен үзгәрткәч, ул үзенең индивидуальлеген югалтса, бөтен кеше бертөрлегә әйләнсә, тормыш төссезләнсә, кешегә яшәүдән кызык калмаса? Уйладыңмы шул турыда?

— Ләкин нидер эшләргә кирәк бит. Кешенең кылган бөтен әшәкелекләрен һаман да шулай: әлеге дә баягы тәрбия җитенкерәмәү белән генә аңлатып йөрербезмени? Ни өчен соң, алайса, Сократ заманында ук каһәрләнгән бозыклыклар әле дә шул килеш яшәп килә? Фән, сәнгать, аң, белем алга китте бит. Җәмгыять системалары гына да ничә тапкыр алышынды!.. Юк, туганкай, кешенең асылы камил түгел. Тышкы яктан гына гүзәл ул.

— Ник син шулкадәр скептик, Володя?— диде Чыңгыз, балконнан шәһәр өстенә күз ташлап.

— Чөнки мин кешене азмы-күпме беләм. Миңа бит күбрәк кешенең эчке дөньясы белән эш итәргә туры килә. Барысында да технократлар гаепле. Кая гына барма, түр саен техник белемле түрә. Нәрсә беләләр соң алар кеше турында, аның табигате турында? Алар кешегә трамвай кебек алга-артка гына йөрергә тиеш бер нәрсә, әйбер җитештерә торган станок итеп кенә карыйлар. Шуңа бездә табигать турында да, кеше турында да чын кайгырту юк. Кайда да шул: сүз уйнату, күз буяу гына. Син менә кешегә хезмәт

күрсәтә торган конторларга гына барып кара. Кемгә дә кирәк түгел син анда. Кечек ни дә, син ни — барыбер жикерәләр. Ярый, аларын калдырып торыйк. Кеше гомеренең ике мөһим фазасына хезмәт күрсәтә торган бала табу йортын һәм зиратын гына алыйк. Беренчесенә — син туганда ук кирәк түгел, икенчесенә — үлгәч кирәк түгел. Әгәр мин сиңа бала табу йортларындагы хәлләрне сөйләсәм, чәчләрең үрә торыр иде! Бала таба торган җир гыйбадәтханә кебек булырга, аның хезмәткәрләре үзен руханилар кебек тотарга тиеш, югыйсә. Дөньяга кеше — безнең киләчәк туа торган җир ич ул. Хыял тормышка аша торган җир. Ә безнекеләр — храм түгел, срам.

— Син һәр нәрсәгә профессиональ күзлектән карыйсың.

— Ә мин нинди күзлектән карарга тиеш соң? Минем вазифа, минем бурыч — дөньяга таза, сау-сәламәт кеше тудыру. Һәм мин аны ничек яхшырту турында уйларга тиеш. Менә син хатын-кызның иң элек йөзенә карыйсың, ә мин аның оча сөякләренә карыйм. Сөякләре киң булса, баласын җиңел табачак. Тора-бара син үзең дә шулай минем кебек гади итеп, сәламәтлек күзлегеннән карап фикер йөртә башлаячаксың. Үзең, балаларың, якыннарың сау сәламәт, озын гомерле булу — менә нәрсә ул бәхет минем өчен. Синең дә хыял түшәмең түбәнәер. Гыйффәтлек, тугрылык, матурлык — болар бар да үтә торган нәрсә. Иң мөһиме — хатының бала тапсын! Таза, сау-сәламәт бала! Калганы бөтенесе, бөтенесе онытыла... Җирдә иң зур, иң биек әхлаклылык бар. Ул — җан иясен ярату, җанны ярату...

— Синең кайда да булса берәр җирдә шушы фикерләр белән чыгыш ясаганың бармы?

— Юк. Кем акушерны трибунага менгерсен ди? Нотык сөйләү минем эш түгел. Аның өчен түләүле сөйләүчеләр бар. Бәлки, үзем дә шүрле торганмындыр. Батырлыкның дүрт төрле дәрәҗәсе бар. Хакыйкатьне кеше үз алдында таныса, бу — беренче дәрәҗәдәге батырлык. Дөреслекне кеше алдында әйтсә, бусы инде — икенче дәрәҗәдәге батырлык була. Җанына зыян китермәслек активлык күрсәтә — өченче дәрәҗәдәге батырлык, ә инде хакыйкать өчен җанын да кызганмаса — бусы дүртенче дәрәҗәдәге батырлык. Күрәсең, минем батырлык беренче дәрәҗәне үткән, әмма икенчегә барып җитмәгән. Минемчә, безнең заманда һәр буын бер дәрәҗәгә батырая бара. Әйтик, безнең әтиләр заманында шик белдерү дә чиксез батырлык исәпләнгән. Балалар һәм оныклар бездән дә уздырачак. Ләкин тәүбәсез батыр була алмыйсың. Безгә тәүбә итәргә өйрәнергә кирәк. Эшләнгән гөнаһлар өчен генә түгел, ә кылмаган изгелекләр өчен дә тәүбә итәргә...

Чыңгыз кунагын озата чыкты. Такси тукталышына кадәр җәяү киттеләр. Менә шунда Чыңгыз, һич тартынмыйча, сүз башлады:

— Володя, миңа синең бер бик четрекле мәсьәләдә, белгеч буларак, киңәшең кирәк,— диде.

— Файдасы тисә, рәхим ит.

— Шушы атнада, сишәмбе көн миңа бер кыз килеп керде. Кыскасы, янган. Ярдәм итегез, ди. Чынлап торып ялвара. Минем сездән бүтән ярдәм итәр кешем юк, зинһар өчен кире какмагыз, дару да эчтем, аракы да эчтем, гарип бала табасым килми, ди.

— Беләсеңме нәрсә, Чыңгыз, җиб-бәр син аларны берәр ягы. Беренчедән, ул бернинди дә дару эчмәгән, алдый гына. Шулай сине кызгандырырмын дип уйлый, синең шәфкать кылларыңа чиртә. Икенчедән, аракыдан шул кадәр ук куркырга ул әле ашып узган алкоголичка түгелдер ләбаса. Өченчедән, башымны кистерергә дә риза — аның вакыты узган. Һәй, юләр, вакыты үтмәгән булса, сиңа кереп тә йөрми ул. Хәзер ирекле бит, теләсә кайда ясата ул аны.

— Алдый микәнни...

— Әйтәм ич, ыш-шанма хатын-кызга, дим. Безгә кайчак унынчы класс кызлары кереп ятып чыга. Кая ашыгасың, кызыкай, дисәң, «Атом гасыры бит, тизләнеш чоры»,— дип кенә җибәрәләр.

— Шулай укмы?

— Әйе шул. Шуңа күрә син аның белән бәйләнеп маташма, туганкай. Башыңны сакла. Бәладән башаяк. Белмәгән, күрмәгән — мең бәладән котылган.

— Аңладым. Киңәшең өчен рәхмәт.

— Аптырыйм мин сиңа, Чыңгыз. Ничек син, шушы яшькә җитеп, хатын-кызга, гомумән, тормышка шулай беркатлы, алсу төсләр аша гына карый аласың? Бер дә алданганың юкмени соң синең?

— Кызык сез — өйләнгән кешеләр. Әйтерсең, сез генә беләсез хатын-кызны. Шундук авызны томалап куймакчы буласыз.

— Бигайбә, туган, әйттем исә кайттым. Үзең хәл ит хатын-кыз, өйләнү мәсьәләсен. Мин сиңа шундый нәрсәләр, шундый хәлләр сөйләр идем, бераз күзеңне ачар идем, ышанмагач, сөйләмим. Ләкин ышанмасаң да, минем сүзгә колак сал. Гафу ит, әмма мин хатын-кызны беләм. Мин алар турында шундый серләр, шундый тирән серләр беләм, юк, сөйләмим... Бәхетле буласың килсә, белми яшә, чөнки хатын-кыздан күңел кайту ул — яшәүдән күңел кайту дигән сүз. Дөрес, тормышның бөтен яме, гүзәллеге — хатын-кыздан. Билгеле, алар арасында да изге җанлылары очрап куя. Шундыйлары очрый — телләреңне шартлатасың, сокланасың, көнләшәсең. Ләкин андыйлары сирәк һәм аның андыйлары чибәр дә түгел. Алар, кагыйдә буларак, бәхетсезләр һәм шуңа күрә изге җанлылар. Ләкин, канатлар салынмасын өчен, өмет сүнмәсен, ышаныч бетмәсен өчен ир-егеткә шул да җитә. Алар, сусаганда кипшенгән иренгә тамган тамчы кебек, җанга тамып, җанны терелтеп җибәрәләр...

Машина килеп туктаган икән. Кузьмин, Чыңгызны кочаклап, яңагыннан үбеп алды. Чыңгыз, шоферга акча бирде дә, кунакны илтеп куярга кушты.

— Кил, хәзер адресны беләсең,— дип кычкырып калды ул машина артыннан.

* * *

Киңәшне бирүе генә җиңел.

Шулай да бераз тынычланды Чыңгыз. Намусы чиста иде аның кыз алдында. Игътибарсыз калдырмады ич аның үтенечен. Ихластан булышмакчы иде дә бит — килеп кенә чыкмады.

Дүшәмбе көнне эш урыныннан тегендә-монда китеп йөрмәде Чыңгыз, кызны көтте. Ә кыз ничектер кичкә таба гына килде. Бу юлы инде ул оялып кына керде. Оялчанлык тагын да чибәрләтә иде аны. Белсәләр икән чибәрләр үзләренә оялчанлыкның ничек килешкәнен! Тылсым, серлелек өсти ул аларга.

Кыз күк төстәге өр-яңа җиңел пальто кигән, иңбашларына таратып салып, бик пөхтә итеп, читләренә ялтыравыклы аксыл җепселләр тартылган юка зәңгәр шәл бәйләгән иде. Чәчләре дә, теге көндәге кебек, пөхтә, килешле итеп ясалган.

— Мин килдем,— диде ул һәм аның битләре кинәт алсуланып китте. Кая карарга белмичә, күзләрен бераз дымландырып, йөгертеп алганнан соң, аска карап, Чыңгыз тәкъдим иткән йомшак кәнәфигә килеп утырды.

— Ничек бардыгызмы?— диде Чыңгыз, кыз үзе сөйли башламас микән, дип беравык дәшми торганнан соң. Ул, уңайсызламас өчен, кызга карамый, сүз башлаганда гына яшерен, йөгерек караш ташлап ала иде.

— Бардым...
— Ничек соң?
— Элеккечә. Файдасыз.
— Һмм... Нәрсә ди инде ул?
— Син мине куркытма, ди.
— Соң, сез үзегез нишләмәкче буласыз?
— Нишлим инде мин... Шуңа күрә сезнең янга кердем дә инде.
— Нигә этисе-әнисе янына бармадыгыз?
— Аларга барып ни файда, барыбер уларын яклаячаклар.
— Төшертәм дә котылам, дип уйлыйсыз инде... Әгәр онытa алмасагыз, яңадан аның янына барсагыз, ул сезне кичермәячәк, уйладыгызмы шул турыда? Һәм егет кылынган эштә бары сезне гаепле итәчәк...
— Миңа аның кирәге юк. Хайван ул, кеше түгел. Дөньяда ул гына дигән мени...
— Кызганыч, ләкин мин сезне куандыра алмыйм. Сөйләштем мин белгечләр белән, тик берсе дә риза түгел... Вакыты, чыннан да, узган, шулаймы?
— Әйе.
— Ә нигә соң сез миңа аны башта ук әйтмәдегез?
— Кире кагарсыз, дип курыктым.
— Иртәме-соңмы, барыбер беленә ич ул. Дөресен әйтергә кирәк иде... Мин сөйләшкән кешеләр дә нәкъ минем фикердә: баланы табарга кирәк. Соң инде хәзер, аңлыйсызмы соң!
— Кайда, тулай торакта үстериммени мин аны?
— Тулай торакта да үстерүчеләр бар ич, бер сез генә түгел.
— Юк, мин хурланам.
— Сезгә хәзер инде төшертергә ярамый, аңлагыз. Төрле өзлегүләр килеп чыгу куркынычы бар. Авыруга сабышырга мөмкин. Гомерлеккә кысыр булып калудан курыкмыйсызмени?
— Аңлыйм, барысын да аңлыйм, ләкин сез дә мине аңлагыз — мин риза.
— Юк, сез артык батыр кыланасыз. Сез әле кысыр хатын бәхетсезлеген белмисез. Миңа ышанмасагыз, тәҗрибәмә ышаныгыз. Күпме хатын-кыз бала таба алмыйча интегә! Онытылыр, барысы да онытылыр: хурлыгы да, авырлыгы да!
— Мин бит сезне гаепләмәячәкмен. Бөтенесендә дә үзем генә гаепле. Сезгә барыбер түгелмени?
— Түгел шул. Беренчедән, мин — врач, сезне күрәләтә авыруга сабыштырасым һәм бәхетсезлеккә дучар итәсем килми. Беләм: сез: «Әнә, тирә-юньдә ничәмә-ничә кыз төшертте дә, рәхәтләнеп, менә дигән егеткә кияүгә чыкты»,— дип уйлыйсыз. Ләкин кырын эш кырык елдан соң да беленә ич, шулаймы? Шулай. Андый эшләр эзсез үтми алар. Югалтканын табигать мәңгегә югалта. Һәм сез моны тирән акыл белән аңларга тиешсез. Кияүгә чыгарга була булуын, ләкин бу бит тормышның соңгы ноктасы түгел, башы гына. Тормыш иптәшеңне гомер буе алдап яшәргә дә кирәк бит әле. Ирләр алар алдауны беркайчан да кичермиләр. Сез ничек уйлыйсыздыр, белмим, мин үзем шундый фикердә торам: әгәр хәзерге заман кызлары тотнаклырак булсалар, таркалган гаиләләр саны бу кадәргә үк менеп җитмәс иде.
— Мин бит сезнең белән бәхәсләшергә кермәдем.
— Ярый, алайса,— диде Чыңгыз, авыр сулап.— Мин җибәрде дип әйтмәгез, үзем килдем диегез. Миңа әйткән кебек үк, сездән бүтән ярдәм итәр кешем юк, диегез. Берни яшерми сөйләп бирегез. Вакытын алдамагыз, дөресен әйтегез.
Ул кәгазьгә тиешле шифаханәнең адресын язды да кызга сузды:
— Мәгез, баш врач янына керегез. Георгий Романович аның

исеме, фамилиясе — Борисов. Ул — белгеч. Ул ни әйтсә, шул булыр. Бүтәнчә мин сезгә берничек тә ярдәм итә алмыйм, гафу итегез.

— Рәхмәт. Хушыгыз,— диде кыз һәм, тиз генә торып, җитез адымнар белән бүлмәдән чыгып китте.

Чыңгыз аның озын, зифа буена, ишектән чыкканда сирпелгән дулкынлы чәчләренә карап калды. Кыз чыгып китү белән, башына явыз зат кидерткән кысан кыршауны салдырып аткан сыман рәхәт булып китте аңа. Кызны озын коридорда озатып калган кебек, ул әле шактый гына ишеккә карап утырды. Вакыт-вакыт аңа, нишләптер, кыз кабат килеп керер төсле тоелды. Кыз белән сөйләшкәндә, ул, күрәсең, яшерен генә, йөзенә, күзенә үк чыкмаслык дәрәҗәдә генә дулкынланган булгандыр. Нәрсәдер артык әйтелгәндер, нәрсәдер әйтелми калгандыр. Әллә нишләп төне буе уйлап чыккан, күңелдән йөз тапкыр кабатланган сөйләшүне дә эзлекле итеп, кызны күндерерлек итеп алып баралмады, сүз дилбегәсен кыска тота алмады Чыңгыз. Ул моны дулкынлануга сылтады һәм, дулкынлануын басарга теләгәндәй, урыныннан торып тәрәзә янына килеп басты, ерактагы Әҗем мәчете манарасына карап тора башлады. Бөек Кантның да, уйларын туплау өчен, тәрәзәсеннән һәрвакыт бер үк манарага карап торырга гадәтләнеп китүе һәм нииндидер сәүдәгәр, ике арага биек каралты салып, манараны тәрәзәдән күренмәслек итеп каплап куйгач, манара күренеп торсын өчен күп акча түләп, сәүдәгәрдән теге каралтыны сүттерү исенә төшеп, Чыңгыз үз алдына көрсенеп куйды. Кант өйләнмәгән, гомер буе ялгыз яшәгән. Шуңа күрә ул аерым кеше проблемалары турында түгел, ә кешелек проблемалары, җиһан проблемалары турында гына уйлаган. Җиңел булгандыр аңа — ул хатын-кызның кем икәнлеген белмәгән...

Чыңгызның күзе ирексездән башта кара сөрем белән төтенләүче биек торбага, аннары комбинат бинасыннан күккә болыт-болыт булып күтәрелгән парларга төште. Йөрәге әрнеп китте, башын авыр, караңгы уйлар томалый башлады һәм ул, андый уйлардан качкан шикелле, янә урынына барып утырды...

* * *

Шул китүеннән кыз бүтән күренмәде. Төрле көннәре булды Чыңгызның. Кайбер вакытларда ул кыз белән ачыктан-ачык сөйләшмәвенә, аның хәтта исемен, кем булып, кайсы фабрикада эшләвен дә сорамавына үкенә, үзен нык кына битәрләп ташлый иде. Бәлки, әгәр кыз белән узган җәйдә танышкан булса, кызны да бәхетле итәр иде, үзе дә бәхетле булган булыр иде. Өйләнмәслек кыз түгел ич ул. Диларәгә мәхәббәте хакына, Диларәгә охшаганы өчен генә дә өйләнә алыр, ә өйләнә алганны — тора гына алыр кебек тоелды Чыңгызга.

Кайбер вакытларда аңа: «Бәлки, ул кызга... әйе, әйе, авырлы килеш өйләнергә, аны гомерлек бәладән йолып калып, бәхетле итәргә кирәк булгандыр?»,— диган сәер уй да килә иде. Тик, әлеге дә баягы — кызның сөйләгәне хак булса — каһәр суккан аракы һәм дарулар исенә төшә иде.

Май урталары иде. Шулай беркөн, киңәшмә үткәреп менгәндә, Чыңгызның күзенә әлеге кыз чалынып киткән төсле тоелды. Кирәк бит, нәкъ шул минутта Чыңгыз күзлексез иде. Икенче көнне ул гел күзлектән генә йөрде. Һәм, чыннан да, төш вакытында теш врачы бүлмәсе янында утырган кызны күреп-танып алды. Бик килешле куртка-чалбар кигән иде кыз. Ул, Чыңгыз Исламовичны күрү белән, башын тәрәзәгә таба борды.

Чыңгыз аның күрмәмешкә салышуын аңлады һәм кыз яныннан

тизрәк үтеп китүне кирәк тапты. Кызга авыр булуын, аның әлек баш врачка сөйләгән серен хәзер үзенеке генә итәргә теләвен, сөйләгәненә дә үкенүен, шуңа күрә баш врачны бөтенләй белмәмешкә салышуын аңлады Чыңгыз. Ул мондый хәлләргә, әйтергә кирәк, күнеккән иде инде.

Тагын бер көн, бер төн үтте. Өченче көнне кыз янә шул урында утыра иде. Әллә ничек җайсыз, бер якка янтаеп утыра иде ул. Кыз янына килеп җиткәч, Чыңгыз үзе дә сизмәстән аңардан:

— Сез минем янга түгелме?— дип сорады.

— Сезнең янга,— диде кыз, урыныннан кинәт кузгалып, аннары Чыңгыз бүлмәсенә таба атлады. Керде дә, берничди рөхсәтсез-нисез түргә узды:

— Бу — сезгә! Яхшы кеше булганыгыз өчен. Миннән...— диде ул һәм өстәлгә бер бәйләм канәфер чәчәкләре китереп салды. Әйе, әйе, ул аларны куймады, аерым бер нәфислек белән, бераз таратып, өстәлдәге кәгазьләр өстенә, үтә нәзакатле итеп куйды. Кәгазьләр өстендә — тере чәчәкләр!.. Чыңгыз каушап, дулкынланып калды.

— Ничек соң... Тәртипме?

— Әйбәт. Бар да бик әйбәт,— диде кыз.

— Мин әйткән җиргә бардыгызмы?

— Әйе. Мин моннан китәм инде.

— Китеп мәнә дөрес эшләмисез. Хәзер инде сезгә, киресенчә, монда калырга кирәк. Бәлки әле ул килер...

— Соң инде. Ризалык бирдем инде. Берни эшләп булмый хәзер. Кешеләрне ышандыргач, сүздән кире кайтуы кыен.

Кыз аңа, күзләрен тирән итеп төбәп, ачык итеп елмайды да, һич тартынып тормыйча — әйтерсең, ул баш врачның туган сеңлесе яки күптәнге бер бик якын танышы — түрдәге тәрәзә янына ук үтте. Вазадагы ясалма канәфер чәчәкләренә иелеп, чәчәкләрне иснәде, аннары аларга бармагы белән сак кына кагылып алды һәм кинәт, Чыңгызга борылып, ихлас гаҗәпләнү һәм шатлану белән: «Ясалма икән ич болар, ә мин аларны тере чәчәк дип торам»,— диде. Аннары, җил бөтереп алган мамык сыман, күз ачып йомганчы бүлмәдән юк булды. Чыңгыз тагын кыз артыннан карап калды һәм тагын озак кына ишеккә карап утырды. Бераз һушын җыйганнан соң, буш вазага су салып, чәчәкләрне бик кадерләп, саклык белән генә вазага утыртып, үзенең каршысына, шкаф киштәсенә куйды. Кыз аңа җиде чәчәк бүләк иткән иде: дүртесе чия төсендә, икесе кызыл, берсе ак... Нишләп нәкъ менә җиде чәчәк бүләк итте икән кыз аңа? Чәчәк саны, аларның сайланган төсләре берәр фал түгел микән?..

Ул аларны Диларә бүләк иткән ясалма чәчәкләр белән чагыштырып карады. Тере чәчәкләр шундый нәфис, шундый серле иделәр. Башларын шулай иеп торулары, төрлесенең төрле якка каравы — бар да, бар да Чыңгыз күңеленә якын һәм кадерле иде. Мөгаен, табигатьнең иң зур гаделсезлегедер ул чәчәкләрнең үз-үзләрен озак саклый алмаулары. Ә ясалма чәчәкләр беркайчан да шиңми. Алар әрсезләр, ясалма матурлыкларын гел чәчеп торалар.

Икенче көнне эшкә килгәндә Чыңгыз үзенә каратып куйган берданбер ак чәчәк бүтән чәчәкләрдән түбәнрәк иелгән һәм ныграк шиңгән иде. Аның күңеле бу һич көтелмәгән хәлдән сыкранып куйды. Шундый актан-ак чәчәкнең — аның өчен сафлык символының — башка чәчәкләрдән иртәрәк шиңүе күңелне мең төрле күңелсез уйлар, тойгылар белән тутыра иде.

Чәчәкләр шиңеп беткәч тә ул әле аларны атна буе, сабаклары, яфраклары саргая башлаганчы тотты. Аннан соң да үзе алып ташларга батырчылык итмәде, җыештыручы хатынга кушып калдырды. Чәчәкләрне ташлагач, аның бүлмәсендәге ямь юкка чыккан иде.

Шул китүеннән кыз суга төшкәндәй югалды. Әгәр очратса, аңлашып сөйләшер иде Чыңгыз аның белән. Ярату белән өйләнү икесе ике нәрсә икәнлеген Чыңгыз, ниһаять, төшенде шикелле.

Соңгы вакытта Чыңгызның уйлары гел Кузьмин сөйләгән нәрсәләр тирәсендә бөтерелде. Ул Владимир белән һаман да эчтән бәхәсләшә, ләкин аның хаклыгын да сизә иде. Гүя, нәкъ аның каршында гына тормыш үзәне ята, ә Чыңгыз биек таудан шул үзәнгә төшү юлын гына белми. Эчке бәхәс юл эзләү кебек иде. Әмма Чыңгызның колагында Әбрар сүзләре дә яңгырап тора: «Идеал безгә түбән тәгәрәмәс өчен, язмыш юлында аяк таймасын өчен кирәк». Ничек һәм күпме генә уйлама, барыбер хатын-кыз идеалы кирәк, дигән ныклы карарында калды Чыңгыз.

Әгәр кодрәтеннән килсә, бөтен кешене дә бәхетле итәр иде Чыңгыз. Берсен генә дә бәхетсез калдырмас иде. Ә усал, явыз кешеләрне бәхеткә тилмертер иде, яхшырмый, төзәлми торып, бәхет йөзе күрсәтмәс иде ул аларга.

Теге кыз Чыңгызга чәчәкләрне «яхшы кеше булганы өчен» бүләк итте. Ләкин яхшылык эшләдеме соң ул кызга, әллә явызлыкмы?

Диларәнең дә һаман баласы юк. Бар, билгеләп кара син изгелек белән явызлык, бәхет белән бәхетсезлек арасындагы чикне!..

Тагын ике ел вакыт үтте. Чыңгызның буйдак булып яшәве әтисен дә, әнисен дә тәмам чиргә сабыштырды. Алар өчен синең фәлсәфәң дә, һөнәрләрең дә, хәтта мәхәббәтең дә кирәкми иде. Һәм, Чыңгызга тәмам кул селтәп, бу юнәлештә үзләре җан-фарманга эш кузгаттылар. «Балаларыңны сөеп үләсебез килә»,— диделәр.

Озакламый алар Чыңгызга «менә дигән» бер яр эзләп таптылар. Чыңгызны Уфага кайтып танышып китәргә чакырдылар. Ул, чыннан да, кайтып, танышып килде. Кәләш врач булып эшли, беренче карашка болай ошамаслык та түгел иде.

Казанга кайтканда Чыңгыз белән Уруссу станциясенә хәтле бер яшь гаилә кайтты. Үз кайгысы да өйләнү булганга, ул юл буе шушы гаиләне күзәтеп, уйланып кайтты. Ире Азамат, хатыны Илһамия, кызлары Гүзәл исемле иде. Поездга утырганда Гүзәл йоклый иде. Берзаман ул уянып китте. «Әти-ии!»,— дип, кечкенә куллары белән әтисен кочаклап алды. Бала әтисенә шундый саф, шундый турылыклы итеп карады ки, ул караш Чыңгыз хәтерендә мәңгегә уелып калды. Шул караштан, шул пакь ихлас тавыштан аңа яңа дөнья ачылгандай булып китте. «Бәлки, чыннан да, тормышта без иҗат итә алган иң зур гүзәллек — балалардыр?»— дип уйлана башлады Чыңгыз. Бәлки, Кузьмин хаклыдыр, табигатькә үзең кебекне тудыру иң тирән әхлаклылык, иң бөек бурычтыр?.. Чыңгызга әле соң түгел. Ул өлгерә әле. Киресенчә, хәзер нәкъ вакыты. Кырык яшьлек ирләрдән, яшь хатыннардан акыллы, сәләтле балалар туа. Җыйган аң-белем, тәҗрибә, хәтта һөнәрләр дә геннар аша бирелә. Озак яшәүчеләр арасында да соң өйләнүчеләр, кырык яшьләрдә өйләнүчеләр күбрәк. Юк, юк, өйләнергә әле соң түгел. Юкка хафаланалар Чыңгызның әтисе белән әнисе. Уң эш соң булмый.

Өйләнү турында уйланса да, сөйләнсә дә, күз алдына Диларә килеп баса. Ә Диларәнең, нишләптер, һаман баласы юк. Җанына гөнаһ алды, ахры, Чыңгыз... Ә теге кызның хәле ничек икән?..

Танышып китүне әтиләре ризалык дип аңлады, ахрысы. Хатлар кар кебек ява башлады. Ә Чыңгыз, төрле сәбәпләр табып, сүзне һаман суза килде, суза килде. Яңа хат алган саен, башында икелемикеле уй барлыкка килә, әмма, эшкә килеп канәферләргә күзе төшү белән, андый уйлар юкка чыга, акылы эзгә баса иде. Ясалма чәчәкләр, гүя, аның һәрбер уена, һәрбер эшенә шаһит булып, аны һәрвакыт күзәтеп утыралар һәм хәтта уй-тойгыларның аз гына тай-

пылышына да хөкем чыгарырга әзер торалар кебек иде.

Көннәрдән бер көнне Чыңгыз шундый төш күрде: имеш, тикшерү белән аны бер завод шифаханәсенә җибәргәннәр. Ул барып кергәндә бригаданың бүтән кешеләре — хатын-кызлар килеп җитмәгәннәр иде әле. Чыңгыз аларны баскыч төбендә көтеп, күренмәсләрме инде, дип, завод капкасына карап тора иде. Шулвакыт ул йөзе кып-кызыл булып кызарган, күзләрен яшереп, башын аска иеп кереп килүче бер яшь хатынны күреп алды. Йөрәге кинәт урыныннан купты Чыңгызның — бу теге кыз иде. Чыңгыз хатынны куып җитте дә, хезмәттәшләре аны-моны уйламасыннар өчен, янәшә бара башлады.

— Димәк, бу сез?— диде ул, үз күзләренә үзе ышанып җитмәгән кеше шикелле.— Сез читкә китмәдегезмени?

— Юк,— диде хатын,— сез мине, берүк, гафу итә күрегез инде. Мин сезне алдадым. Миңа... миңа сезнең алда бик оят иде. Очрап йөрмәс өчен, шушы заводка күчтем.

— Тормышыгыз ничек соң?

— Сорамагыз инде. Теге чакны сез бик хаклы булгансыз.

— Димәк, кияүдә хәзер?

— Әйе!

— Ә ирегез кем?

— Монда эшли, инженер. Ләкин мин инде хәзер ирдә түгел.

— Сәбәбе шулмы?

— Шул да, ул гына түгел дә. Мин аны бик яратып чыктым. Шуңа күрә, түкми-чәчми, аңа барысын да сөйләп бирдем. Кичерер дип уйлаган идем. Хәзерге заманда аның әһәмияте юктыр, кемнең кайчан кеме булмаган, дип уйлаган идем. Ул мине кичерә алмады. Миңа «Синең балаң булмый»,— диделәр. Тикшерендем, дәвалandым — файдасыз. Бу чүп өстенә чүмәлә булды. Ул — яхшы кеше. Мин — бәхетсез. Җир йөзендә иң бәхетсез хатын мин...

Чыңгыз үзенең бу төшен бөтенләй онытты иде. Икенче көнне аны кичкә таба сәламәтлек саклау министрлыгына чакырдылар. Бөгелмәгә барып, бер шикаять тикшереп кайтырга куштылар. Кулына калын гына хат тоттырдылар. Көн үткән иде инде. Билет хәстәрен күреп йөрергә вакыт аз калган иде. Самолет белән очса, иртәгә кимендә ярты көне юлга үтәчәк. Чыңгыз Исламович «Казан—Бөгелмә» поезды белән шул ук көнне юлга чыкты.

Ул килеп кергәндә купеда бер чибәр ханым утыра иде.

— Хәерле кич,— диде Чыңгыз.

— Хәерле кич,— диде ханым кыяр-кыймас кына. Аның йөзе кинәт кып-кызыл булып балкып китте һәм ул, нишләргә белмичә, сүз югыннан сүз дигән шикелле: «Сезгә өстәге урыннар гына калды, монда минем ирем утыра»,— дип әйтеп ташлады. Чыңгыз аны башта оялудан, аннары уңайсыз әйтеп ташлаган сүзләреннән шулай нык кызарды дип уйлады, һәм хатынга карамаска тырышты.

— Ярый, кайда да...

Чыңгыз плащын элеп куйды, портфелен утыргыч астына салды, яңадан торып маташмас өчен ишек янынарак утырып, гәҗит актара башлады.

— Сез бер дә үзгәрмәгәнсез,— диде ханым. Аның йөзендәге кызыллык бераз кими башлаган иде.

«Кем минем белән болай сөйләшә? Нинди танышым икән соң ул?»— дип баш ватты Чыңгыз.

— Сез дә һаман яшь һәм чибәр...— диде Чыңгыз, болай гына, кыек атып, туры тидереп. Ул ханымга беренче тапкыр төбәп карады һәм кинәт дулкынланып китте. Ышаныргамы-ышанмаскамы дигәндәй, ханымга тагын бер, тагын бер карап алды. Аның халәтен сизгән шикелле, хатын тизрәк сүзгә күчте:

— Мин ике бала анасы инде хәзер. Ике малай үстерәбез.—

дип сөйләп китте. Каршыда, чыннан да, ул — Чыңгызга теге вакытта чәчәк бүләк иткән кыз утыра иде. Хатын тизрәк ире турында, балалары турында әйтеп, сүзне үткәннәргә җибәрмәскә, хатирәләр уртаклашып утыруның файдасызлыгын искәртергә ашыга иде, ахрысы.

— Сез бәхетле, димәк?— дип сорады Чыңгыз Исламович үз нәүбәтендә. Бу темага артык сүз куертасы килмәгәнен сиздерергә тырышып.

— Әлбәттә.

— Мин бик шат.

Шулвакыт ишекне киң ачып, купены тәмәке исе белән тутырып, уртача буйлы, таза бер ир килеп керде. Ул бераз салмыш та иде.

— Таныш булыгыз, бу минем ирем була,— диде ханым, ике араны ялгарга тырышкан төсле.

— Бик шатмын. Мин Чыңгыз Исламович булам.

— Михаил Семенович.

Михаил Семенович күп сөйләшергә яратмый иде, ахры; ул, артык исе китмичә генә, тәрәзә янына барып утырды да перронга төбәлде. Чыңгыз да кабат гәҗит укый башлады.

Поезд кузгалды.

Чыңгыз коридорга чыгып китте. Аз сөйләшү аның өчен мәслихәт иде. Ул, күп сөйләшеп, сүз ара сүз кереп китеп, хатынны кыен хәлдә калдыруым бар, дип курыкты. Үзенең дә хәле җиңел түгел иде. Чыңгыз әле дә бу очрашуның өн булуына ышанып бетә алмый иде. Менә сиңа төш! Менә сиңа телепатия!.. Тәрәзәгә карый-карый, уйга чумды. Бу очрашуны ул язмыш бүләге итеп кабул итте. Аны иң шатландырганы — хатынның бала таба алуы иде. Шул хәбәрдән аның хәзер йөрәге җиңеләеп, күңеле җылынып китте. Җанын суырып торган әрсез сорауларның берсе кинәт юкка чыкты. Чыңгызның вөҗданы тынычлана башлады. Бары тик бөтенләй тынычланып беткәч кенә, акылы тәмам салкынаеп җиткәч кенә ул теге вакытта кызны бәхетле итәргә хыялланууын искә төшерде. Менә бу, ичмасам, очрашу!.. Чыңгыз, үзе дә сизмәстән, башын чайкап куйды.

Ул көнне Чыңгыз йоклый алмады. Башта аны ирнең гырлавы борчыды. Аннары башыннан йокы бөтенләй качты. Кысан урында уй көчәя генә икән. Чыңгыз төн буена үзенең бар үткәнен аркылыга-буйга йөреп чыкты. Вакыт-вакыт аның уйлары бүленә, ул хатынның әйләнеп ятканын, тирән итеп сулап куюын ишетә, ләкин аска карарга кыймый иде. Хатын да йокламады. Ничектер, ул үзенең йокламавын Чыңгызга белгертергә тели сыман тоелды. Кызык, нәрсә турында уйлый икән ул хәзер? Нәрсә йокы бирми микән аңа? Нишләп кешеләр бер-берсенең уен белә алмый икән?..

Командировкада Чыңгыз ике көн булды. Кеше язмышларын тикшереп йөрү аның иң яратмаган эшләреннән берсе иде. Үзен тикшергәнне дә аның җене сөйми. Кадерле вакытны әрәм итеп, дәүләт акчасын туздырып, өч тиенгә ярамаган шикаять тикшереп йөрү аның болай да бозылган кәефенә чүп өстенә чүмәлә генә булды. Шуңа күрә ул Казанга күңелсез кәеф белән кайтты. Икенче көнне эшкә килү белән, үзе дә аңламастан, ясалма чәчәкләрне әрнүле ачу белән чүп савытына томырды.

Менә шундый уйлар, хисләр күтәрелеше вакытында Чыңгыз күзләрен чытырдатып йомды да: «Ярый инде, ни булса — шул булыр»,— дип, бер ай эчендә Уфа кызына өйләнеп тә куйды.

Ә тагын ике айдан аңа Диләрәнең ирдән аерылып кайтуын хәбәр иттеләр...

*Казан. 1986*

## Гурий Тавлин

# БУРАН

ХИКӘЯ

Иртәнге якта көн җилсез, тыныч, ярыйсы ук әйбәт иде. Ләкин төш алдыннан күксел тонык пыяла төсендәге күкне, кайдан өерелеп килгәннәрдер, исәпсез-хисапсыз алама болытлар томалады. Аннары алар, куерып, җиргә үк диярлек төштеләр һәм, күп тә үтмәде, галәмәт зур иләктән коелган кебек вак-вак кар ишәк онны хәтерләтеп, ап-ак кар яварга кереште. Озакламый бөтен әйләнә-тирә мамык кар белән түшәлде. Бөтен нәрсә ничектер басынкыланган шикелле булды. Тавышлар тонykланды.

Әмма күп тә үтмәде, капыл гына көчле җил чыгып, җиргә әле рәтләп кунарга да өлгермәгән йомшак кар бөртекләрен һавага яңадан чөеп биетергә, тулганландырырга кереште. Тирә-юньдәге бөтен нәрсә кар пәрдәсе аша төсмерләнми башлады. Көннең сые китте.

Кино төшерүчеләр төркеме юлга көн бозылганчы кузгалган иде. Алар арасында кинәт буран чыгуга игътибар итүче булмады. Тәгәрмәчләренең алгы һәм арттагылары да тарта торган, махсус җиһазланган УАЗ машинасына табигать көйсезлеге чүп кенә ич ул! Юл такыр, машина әчено җил үтми, тышта буран котыру гына түгел, ник шунда җиренең асты өскә килеп капланмый!

Олы юлны калдырып, читкә — басу юлына кергәнче, машина хәвеф-хәтәрсез барды. Кайчандыр бульдозер чистартып үткән, инде тирән көрт астында калган бормалы-сырмалы ташландык юлдан ул әллә ни озак җилдерә алмады, кереп утырды да кар чокырына, ни алга, ни артка кузгалмас булды.

— Килеп җиттек шикелле,— диде шофер егет.

Аннары ул, машинадан төшеп, тезләренәчә көрткә бата-бата, алдагы юлны тикшереп килде. Аның өс-башын мул булып кар сырган, какча йөзе юешләнгән, караңгыланган иде.

— Нәрсә, «айгыр»ың чыгалмаслык батканмы әллә?— дип кызыксынды сирәк чал мыеклы, калын күзлекле, цирк көрәшчесе шикелле таза кинооператор.

— Машина, булышсаң, чыгарлык. Тик бу аның беренче һәм соңгы утыруы булмаячак. Алда юл юк. Бәлки кире борылырбыз, ә?— диде шофер.

— Юк, юк, барып җитәргә инде, күп булса, биш-алты чакрым ара калгач, кире борылу — җинаять ул, энем. Максатка юл такыр түгел, батмаклы, дигән бер акыллы бәндә. Борылмыйбыз, барабыз. Буран комачаулады, дип, әшебезне башкармыйча кайтсак, нинди йөз белән кеше күзенә күренербез? Бу «айгыр»ны аннары утильгә генә тапшырасы булыр бит, уйладыңмы шуны?— диде кинооператор. Аның тавышы күтәренке иде, сүзе белән башкаларны да дәртләндерергә теләде бугай.— Иә, егетләр, булышабызмы бу дүрт көпчәкле нәрсәкәйгә?

Кинооператор һәм аның колга кебек озын, әле бер генә тапкыр да пәке тимәгән битендә бала йоннары тырпаеп торган ярдәмчесе, муены иңнәренә баткан, арык куллары тезләренәчә асылынып торган бөкрерәк гәүдәле тавыш операторы да, буран куенына чыгып, машинага кар капкасыннан арынырга булыштылар. Ләкин, беренче капкыннан ычкынып күп бармадылар, уазик тагын батты. Ул, чыгымчы ат шикелле, алга да, артка да сикеренде, әмма кузгала алмады. Ямьсез авазлар чыгарып ула-

---

Гурий ТАВЛИН *(1925)* — *«Сары яфраклар коела», «Тәвәккәл таш яра» һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

ган буран кочагына тагын чыгарга, барасы юлны арчырга, урыныннан кузгала алмаган машинаны җан-фәрман килеп кат-кат этәргә туры килде. Мең бәлаләр белән кузгалып китеп, янә дә күп бармадылар — тагын утырдылар. Тагын.... тагын... тагын... Әйтерсең, кар катламы машинаны үз әсирлегеннән һич тә ычкындырырга теләми, аңардан мәсхәрәләп көлә, үчлекләшә иде. Киночылар тәмам йончыдылар. Машиналары яңадан да унбиш-егерме минут буена җәфаларлык булып утыргач, кинооператор, группада өлкән һәм җитәкче кеше буларак, кышкы юлга әзерлексез чыккан шоферны орышырга тотынды:

— Кыш бит бу, наныем, аның ышанычсыз, алдакчы икәнен син белергә тиеш. Сабый түгел, дөньяга бүген генә килмәгәнсең. Ә синең машина көпчәкләренә киертергә чылбырларың да юк хәтта. Шәһәр асфальтында машинаны җилдертергә кем дә маһир, менә бу шүрәле карганган шайтан сукмагыннан да шәһәр урамнарында чапкан күк чап син, егет булсаң. Бел синә машина этәргә ялландыкмы? Ялланмадык. Эшеңне җиренә җиткереп эшли белмәгәч, тотынмаска кирәк...

Бу сүзләр бәгыренә шырпы төсле кадалсалар да, шофер, сүз озайтуның файдасызлыгын аңлаптыр, җавап кайтармады.

— Хәзерге яшьләрдән ни көтәсең, арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит аларга,— дип кинооператорның сүзләрен куәтләде яктырту техникы.— Башларында нечкә сыйраклы кызлар да, танцы-манцы гына ич хәзерге сантыйларның. Ул баранкасы артыннан купмый да, ә без җан көчебезне салып этәргә тиеш аның чыгымчы калтырчасын!

Шоферның, теләсә, акланырга мөмкинлеге бар иде. Бу уазик аныкы түгел, ул йөк машинасында эшли. Бу машинаның шоферы, кинәт авырып, больницага керде: уазикка ул, студия директорының хуҗалык эшләре буенча урынбасары бик үтенгәч, «Совет Армиясе көненә киножурналга Дан орденнарының тулы кавалеры турында үзәк сюжет кирәк, шунсыз журнал пычаксыз суела, киногруппаны кирәкле материалны төшерергә Тулпар дигән авылга алып барып кайт, зинһар, ерак ара түгел»,— дигәч кенә утырырга риза булды. Башкача, кеше машинасына утырып юлга чыгар идеме? Чыкмас иде. Аңа уазикның төзеклеген, юлга чыгарга яраклымы, түгелме икәнен тикшереп торырга вакыт та булмады, кинооператор артына ут капкандай ашыктырды. Хәзер менә сүгә, синең көпчәкләргә кигертергә махсус чылбырларың да юк, ди. Чылбырлар белән нәрсә кырасың, ни майтарасың мондый көрттә? Уазик аэрочана түгел ич...

Юл кешеләрендә бик яман бер гадәт бар — аларга юл уңайсызлыкларын, юлдагы эчпошыргыч бертөрлелекне онытсырырлык адәм кирәк була. Моның өчен — поезддамы, теплоход яки башка төр транспорттамы — барыбер, арада йомшаграк табигатьле, үзен тиешенчә яклый белми торган берәүне сайлыйлар һәм аны аз-азлап «чеметкәләргә» тотыналар. Уены-чыны белән юлдагы бөтен уңайсызлыкларны аңардан, араларында ул булудан «күрәләр». Башта юк-бар төрттерүләрдән башланган шаярту ахырда хәтта чын-чынлап мәсхәрәләүләргә барып җитә. Сайланган «объект» салкынрак канлы, пошмасрак бәндә булса — урынсыз үртәүләргә җене чыкканын сиздерми, түзә, башкаларга кушылып көлә; ә инде тиз кабынып китүчән бәндә туры килсә, сусыз самавардай кайнап аклана, тупас сүзләр әйтә, гауга куптара. Ә шаяртучыларга шул гына кирәк тә, алар аны тагын да дәртләнебрәк үртиләр, ирештерәләр, авырттырыбрак «тешлиләр». Шул рәвешчә, юл күңелсезлеге, җанны кыйный торган бертөрлелек юкка чыга.

Кинооператор ярдәмчесе белән тавыш операторы өлкән иптәшләрен тел тибрәтеп якламыйлар, әмма күңелләреннән алар да «булдыксыз» шоферны тиргиләр. Шофер исә бар көченә тырыша, машинасын ничек тә алга таба алып бара.

Юл газабы киночыларны тәмам талчыктырды. Аларның бердәнбер көрәк белән чиратлашып көрт казудан куллары кабарып бетте, тырышатырыша машина этүдән җеп өзәрлек җегәрләре калмады — тәннәре сулыгып сызлый. Ә буран котырынуын белә. Машина, юлчыларны үртәп, аларның түземнәрен төкәндерә баруына тантана иткәндәй, кузгалып алтыҗиде адым китә дә тагын көрткә кереп утыра. Аңа башта ихлас күңелдән булышкан, ул ни алга, ни артка китми башлау белән җәһәт кенә төшеп, юл арчырга, аны этәргә ташланган кешеләр, инде көчкә-көчкә кыймылдап, тышка, җәза алырга чыккандай, авырлык белән генә чыгалар.

Чыкмаслар иде, япан кыр уртасында буран үкерүен тыңлап, бер-берләренә бүрегә караган кебек карап утырасылары да килми. Бер карыш кына алга үтсәң дә, кем әйтмешли, хәрәкәттә — бәрәкәт бит. Әмма уйсулык аша салынган бу каһәр төшкән юлның да, чамасыз котырынган буранның да ахыры-азагы булмас шикелле.

— Без төшереп кайткан сюжет экранда, күп дигәндә, өч минут барыр. Шул өч минутлык тамаша өчен шушылай җәфа чик инде,— дип ачулы мыгырданды кинооператор, парланган күзлеген чиста кулъяулыгы белән сөртә-сөртә.— Беләме икән тамашачы безнең дә ипине тир түгеп ашаганны?

— Белде ди, көт!— дип әләктереп ала аның сүзләрен яктырту техникы.— Сезгә менә ярый да әле, эшегез күзгә күренә, экранга чыга, гонорар аласыз. Ә минем эшем? Сез төшергәндә, кайда гына булса да, мең бәлаләр белән ут көйлим, яктыртам. Шуның белән вәссәлам! Съемка беткәч, дөньяда барлыгымны да белүче юк. Сезнең фамилиягез аршынлы хәрефләр белән титрга языла, минем фамилиям бухгалтериянең акча ведомостеннан ары китми. Анда да әле күпвакыт адәм танымаслык итеп боргалыйлар. Минем Гайнуллинмы, Гыйльмуллинмы, Гыйздуллинмы икәнемне хәтта кассир да аера алмый азаплана. Шулай инде ул, тамашачыга тамаша булса, калганында аның гаме юк.

Яңадан шоферны «тетү» башланды. Ачу — аю, дип юкка әйтмиләр шул, юкка гына түгел.

Машина тагын «утырды». Шофер аны, алга-артка селкеткәләп, урыныннан кузгатырга озак азапланды. Мотор йотлыга-йотлыга үкерде. Бу юлы инде буран куенына чыгарга беркем дә ашыкмады. Юлчылар, берберләренә карамаска тырышып, урыннарында мыштым гына утыра бирделәр. Ахырда, шофер егет үзе машинадан төште. Ул башта уазик тирәсендәге карның тирәнлеген тикшерде, аннары, бата-чума, бер йөз метрлап алга үтте. Тукталды. Куллары белән йөзен җилдән саклап, буран пәрдәсе аша әйләнә-тирәне караштыргач, ашыкмый гына машинасы янына кайтты да, ишекне ачып, юлдашларына әйтте:

— Алда юл без үтәрлек түгел. Мин хәзер, якындагы авылга барып, бульдозер алып киләм,— диде.— Бәлки, берәрегез миңа иярер, иптәш булыр?..

Аңа ияргә берәү дә теләк белдермәде. Шофер, моторны сүндереп, ишекне япкач, буран эчендә күздән югалды.

Ионсыган киночылар өчен ялыктыргыч минутлар башланды. Көчле җил машина өстенә тартылган брезентны кубарып чөяргә теләгәндәй ярсып какты. Тәрәзәләрне, калын булып, кар сырды. Буранның улавы эчне пошыра, ярсыта иде. Киночылар үзләрен капкында кебек тойдылар. Күңелләрен әллә нинди ятышсыз уйлар били башлады. Кыр уртасында, билгесезлектә алар күпме шушылай утырырлар? Ә бит кайчан гына әле, машина бик еш «утырса» да, метрлап кына булса да, алга баралар — өмет бар иде. Хәзер машина җансыз, шофер юк. Ул берәр авылга адашмый барып җитә алса — бер хәер, ә адашса нәрсә? Күпме утырырлар бу хәрәкәтсез албастыда — бер сәгатьме, икеме, әллә тәүлек буена яки буран басылганга кадәрме? Кайчан басыласын үзе белә микән әле ул буран?..

— Теге ахмакның безне кәкре каенга терәтүе булмасын бу,— дип сүз башлады яктырту техникы, үзалдына сөйләнгәндәй.— Хәзерге яшьләр хак сүзгә дә кылтаялар бит. Сез миңа мораль укыдыгыз, менә мин дә сезне өйрәтим әле, дигәндер ул сөрхәнтәй. Күпме битәрләдек, ләм-мим сүз катмады, астыртын. Өргәне тешләми, өрмәгәне тешли этнең. Менә көт хәзер син аның бульдозер алып килгәнен! Килде ди, бульдозер аны гына көтеп тора ди авылда. Бу буранда безгә ярдәм итәм дип кем юлга чыга?

— Ашыгыч нәтиҗә ясамыйк, күрербез, көтик,— диде кинооператор.

— Көтәбез инде анысы, көтәргә калган баш. Тик менә ашыйсы килә башлады. Мин иртән рәтләп ашамаган идем.

— Түз, ашау качмас.

Әңгәмә куермады. Сөйләш, сөйләшмә — файда юк. Тышта эч пошырып буран улый, күрәзәлек итү, акыл сату берни бирми. Вакыт уза торды. Киночылар, хәрәкәтсез утырып, туңа башладылар.

— Бу калтырчада төн чыксак, шакраябыз без,— дип сүз башлады тагын яктырту техникы.— Кеше, чатнама суыкта түгел, күбрәк шушындый буранда катып үлә. Минем үз гомеремдә шундый әллә никадәр очракларны ишеткәнем бар. Буранда катып үлү бик җиңел, диләр. Җил, кешене көй-

ләп йоклата да, соңыннан акрынлап туңдыра, имеш. Моннан бишме, алтымы ел элек Йошкар-Ола телестудиясеннән ике кешенең шушындый буранда аяк сузуларын онытмагансыздыр әле?

— Алар исерек булганнар бит, без исерек түгел,— диде аңа кинооператор, иренеп кенә.

— Без исерек түгел, без — ач. Ачлык сәрхүшлектән дә яманрак.

— Син үлсәң — үләрсең, безнең яшәргә исәп әле,— диде кинооператор.— Тик үлгәнче, белгән догаларыңны укы, юкса теге дөньяда тәмугка эләгүең бар...

— Мин уйлап фикер йөртәм, ә сез авыз ерасыз.

— Мин дә уйнап әйтмим, уйлап, сиңа яхшылык теләп әйтәм.

Кинорежиссер үзалдына сөйләнгәндәй генә әйтте:

— Кичә мин газетада Рим империясе башлыгы Карл дүртенченең дүртле санын яраткан турында укыдым. Аның илендә дүрт башкаласы, дүрт сарае, һәр сараенда дүртәр бүлмәсе, һәр бүлмәдә дүртәр тәрәзәсе булган. Тантаналар вакытында башына да дүрт кырлы таҗын кигән. Шуның өстенә, дүрт ат җигеп йөргән, көнгә дүрт тапкыр ашаган, гомерендә дүрт хатын алган. Хәтта үлгән көнендә дә көндезге сәгать дүрттә үлгән,— диде.

Вакыт бик акрын үтте. Әйләнә-тирәдә дулаган җил-буран тавышыннан кала, башка тавышлар юк иде. Юлчылар тын гына йокымсырадылар. Тыштагы буран улавы аша кинәт кенә мотор гөрелтесе ишетелеп киткәндәй булды. Кинооператор белән кинорежиссер бер-берсенә текәлделәр.

— Бульдозер килә бугай, мотор тавышы ишетелә шикелле.

Чыннан да, җил улавына аралашып, бер көчәеп, бер югалып, нидер гөрелди иде. Кинооператор ярдәмчесе түзмәде, ишекне ачып буран эченә чыкты. Мотор тавышы көчәйгәннән-көчәя бара иде.

Әле генә өметсезлеккә төшеп, күңелсез уйларга бирелеп утырган киночыларга җан керде. Алар, берәм-берәм, буран куенына чыктылар. Бераздан тирән көрттә юл ярып үзләренә таба килгән бульдозерны күрделәр. Бульдозер пычагы тыгыз карны әле бер, әле икенче якка эшереп чыгара, кечкенә уазикка: «Юлсыз җирдә менә ничек юл салалар аны, ә син югалып калгансың энем»,— дия кебек иде.

Шофер егет, бульдозер кабинасыннан төшеп, машинасы янына килде.

— Юлда очрады,— диде ул.— Авылга барып җитәргә тагын чакрымлап ара калган. Хәзер инде маҗараларсыз барып җитәрбез, шәт.

Бульдозер, уазикка чистартылган юлга чыгарга булышкач, алгарак китте. Юл буе ләм-мим сүз катмый килгән шоферны, әйтерсең, алмаштырганнар иде. Ул туктаусыз сөйләнде.

— Ярый бардым әле, бульдозерның бу якка килергә исәбе юк иде. Ул салам эскертләренә барырга юл арчырга чыккан икән. Бәхетебезгә очраттым аны. Кайдан килүебез, кем икәнебез белән кызыксынмады, килде. Шәп егет бульдозерчы. Хатыны бүген иртән генә малай тапкан, юл буе шул турыда сөйләде. Ул булмаса, бу юлны без үтә алмый идек, кар билдән, рәхмәт бульдозерчыга.

Бер чакрым чамасы хәвеф-хәтәрсез үткәч, алда ниндидер карачкы күренде. Кеше икән. Ул, кулын күтәреп, машинаны туктатты һәм, шофер ягындагы ишеккә килеп:

— Энем, зинһар, тарттырыгыз әле,— диде.

Машинадагылар, барысы да тизрәк авылга, җылыга барып җитәргә теләп, түземсезләнеп утыралар иде, машиналары туктагач, яңадан утырдык ахры, дип сагайдылар.

Тартырга сораучы чирләшкә кыяфәтле, алтмыш биш яшьләр тирәсендәге бер карт иде. Шофер егет аңа папирос кабызып бирде.

— Авылга еракмы әле, абзый?

— Бер өч чакрымнан ары калмагандыр инде. Кая юл тотасыз?

— Тулпарга.

— Безнең авылга икән. Машинагыз тыгыз икән, бәлки, миңа да урын табылыр, ә? Бик йончыдым, көчкә сөйрәләм...

Шофер егет җавап кайтарырга өлгермәде, кинооператор:

— Урын юк, иптәш, утырта алмыйбыз, бигайбә. Әйдә кузгалдык, шофер,— диде.

— Буран бит, алыйк. Карт кешене көртләр арасында, җил эчендә калдыру әйбәт түгел,— дип каршы төште шофер.

Кинооператор сүзеннән кайтмады:

— Без юлга исерекләр җыярга чыкмадык, юлыңда бул!— диде.

Машина кузгалып китте, карт юл читендә басып калды.

— Буран димиләр, көн сыйсыз димиләр, җил куалар. Машинада борылыр урын да югын күрә үзе, утыртыгыз, ди. Оят юк кешедә. Салмыш бит үзе. Сәкесендә намазлык өстендә генә утырыр чагы карт тиленен, ә ул исереп юл йөри, сәрхүш...

Киночыларны фатирга Дан орденнары кавалерының үзенә урнаштырдылар. Хуҗа өйдә юк иде, карчыгы кунакларны якты йөз белән каршылады, тиз генә чәй кайнатты, барысының да өс киемнәрен киптерергә элде, ә үзенең күзләре гел тәрәзәдә булды. Ул, борчылып, ирен көтте.

— Яхшы кешенең эте дә йөрмәс бу буранда, кайтырга чыкмаса гына ярар иде,— дип сөйләнде үзе.— Ике аягының икесе дә протиз бит аның. Юлга җәяү чыкса, бу сыйсызда үлә ул. Барма, барма, дидем, тыңламады,— оныкларны күреп кайтыйм, бик сагындырдылар, диде. Кызыбыз күрше авылда киядә безнең. Кунып ятмам анда, бүген әйләнеп кайтырмын, диган иде. Әйткән сүзендә тора торган кеше ул, буран булса да, йөрәге түзмәгәндер, чыккандыр кайтырга. Хараплар гына булмаса ярар иде...

Киночылар карчыкны тынычландырырга тырыштылар:

— Юкка кайгырма, апа, мондый көнне юлга чыгарга башы ике түгел кешенең. Менә бераз хәл алыйк та, күрше авылдан җилдереп алып кайтырбыз үзен, кайгырма,— диделәр.

— Белсәгез икән сез аны,— дип үрсәләнде карчык.— Үзенә хилаф китерүен уйламый ул, ике аягым да юк дип кул кушырып утырмый, комбайнда эшли әле. Бүген кичен авыл механизаторлары белән зәнәтие үткәрәсе бар дип сөйләнгән ие. Буран дип тормаячак, юлга чыгачак ул.

— Кайгырмагыз, алайса, кайтыр...

Шыгырдап капка ачылган тавыш ишетелде. Хуҗа карчык ян тәрәзәгә капланды һәм шундук:

— Кайтты картым, кайтты, рәхмәт төшкере!..— дип сөенде.

Киночылар дә тәрәзәгә капландылар. Капкадан ишегалдына кергән кеше, болдырга таба бик кыенлык белән берничә адым ясагач, киселгән агач кебек, йөзе белән карга ауды. Хуҗа карчык:

— Иа раббым, мәрхәмәтеңнән ташлама!— дип сөйләнеп, атылып өйдән чыгып китте.

Киночылар да, өсләренә дә киенеп тормастан, аның артыннан ишегалдына чыктылар. Алар юлда үз машиналарын туктатып тартырга сораган кешенең кар эчендә һушсыз ятканын күрделәр. Шофер егет аны күтәреп алып өйгә кертте. Карчык:

— Үзеңнең дуамаллыгың аркасында башыңа җитәсең бит инде. Картаеп та акыл кермәсә кермәс икән кешегә,— дип такмаклап картын чишендерергә керeште.

Шофер ашыгып киенә башлады.

— Син кая җыенасың?— диде аңа кинооператор.

— Колхоз идарәсенә барам, врач чакыртырга кирәк.

— Бар, машинаңны кабыз, без дә хәзер җыенып чыгарбыз...

Киночылар, тиз-тиз киенеп, өйдән чыгып киткәч, хуҗа аңына килде. Карчык пышык-пышык елый иде.

— Җылама, карчык, мин исән, шайтан таягына кырау тими. Хәзер, бераз хәл алам да, торам. Өйгә син күтәреп керттеңмени мине?

— Сине кинога төшерергә дип, Казаннан килделәр. Биш кеше. Фатирга аларны безгә керттеләр. Сине өйгә шуларның берсе күтәреп кертте.

— Кайда соң алар, күрмим?

— Машиналарына утырып, врач алып киләбез дип чыгып киттеләр.

— Брезент өсле кечкенәме машиналары?

— Ие, безнең персидәтелнеке күк бәләкәй машина.

Хуҗаның йөзе кинәт караңгыланды.

— Хәлең әллә яңадан авыраямы, картым?

— Борчылма, карчык, хәлем әйбәтләнде, шөкер. Тиз генә самавырыңны чыжлат, тамагым янды.

Озакламый аларга фельдшер килде. Хуҗа, үзенә берни булмагандай, урыныннан торды.

Киночылар аларга бүтән әйләнеп кайтмады. Алар, төн җитте, буран котыра, дип ике уйлап тормадылар, тизрәк кире Казанга таба юл тоттылар...

**Ранис Газизов**

# КҮККӘ ЯБЫШКАН БОЛЫТ

ХИКӘЯ



Сәрия карчыкның күккә күтәрелеп каравы булды, әсселе-суыклы булып китте, чайкалып ук куйды, ярый әле ишек тоткасына ябышкан иде. Күр инде син бу болыт кисәген! Карчык гомерендә инде ничәмә-ничә тапкыр яңгырлар яуды, җил-давыллар, кар-бураннар булды, ә теге болыт һаман оят дигән нәрсәне белми — килә дә карчыкның баш очында эленеп тора, килә дә эленеп тора. Сәрия карчык өчен тәмам табышмакка әйләнде ул. Шул болыт кисәген күрүгә карчык: «Ахырзаман шушы була торгандыр инде»,— дип, авызын кыймылдата башлый. Аннары үзенең нәрсә сөйләгәнен абайлап та ала булса кирәк: «Тфү, тфү, әстәгъфирулла, авызымнан җил алсын»,— дия-дия, тирә-ягына төкеренә башлый. Шуннан соң, бисмилласын әйтә-әйтә, тизрәк ишекне яба да өенә кереп китә. Уйлар өере анда да тынгылык бирми. Карчык соңгы вакытта үзен еш борчыган сорауларга җавап табарга тырыша...

Табигатьнең нык үзгәрүе, адәм баласының аңа карата миһербансыз булуы борчый иде аны соңгы вакытларда.

... Әллә нәрсә булды бу дөньяга! Кышы — кыш түгел, җәе җәйгә охшамаган. Элек, ичмасам, кышын кар өйләрне күмеп китәрлек булып ява торган иде, ә хәзер болай да учка сыярлык кына булган кар кыш уртасында эреп юкка чыга да куя. Алар үскәндә бала-чага урамнан кайтып керми, рәхәтләнеп яланаяк йөри иде. Йөрмичә соң: җир шундый җылы, йомшак була иде бит ул чакта. Ә инде чык төшкән чирәмдә йөрүе тәнгә үзе бер рәхәтлек бирә торган иде. Хәзер кая инде ул, җәен яланаяк йөреп кара әле син. Әллә инде кояшы да бездән ераклашты шунда? Көзен күр инде син! Атналап, айлар буе тоташтан яңгыр ява да ява, күк тишелгән, диярсең. Табигать кенәме соң, кешеләрен дә аңлап булмый хәзер. Нәрсә инде бу, әллә чынлап та, ахырзаман җитүе шушымы?..

Аның зиһенен тәмам айкаган әлеге уйларга янәдән әйләнеп кайтуы очраклы түгел иде — баш очында эленеп торган болытны күргәнгәме, аңа ничектер ямансу иде бүген.

Гомумән, соңгы бер ел эчендә Сәрия карчык күзгә күренеп картайды, какчаланды, чаларды, бөкерәйде, карачкы сыман ямьсезләнде, зиһене тәмам чуала башлады. Соңгы вакытта аны сагыш басты, хәтта көннән-көн сагыш әсирлегенә эләгә барганын үзе дә тоймый иде инде. Әнә, бүген дә ул арт бакчасындагы бәрәңге өчен борчылып утыра. Борчылмас иде дә, авылда бер Сәрия карчыкның гына бәрәңгесе алынмаган килеш тора. Бәрәңге сабаклары да, аның сагышын аңлагандай, саргаешып утыралар кебек. «Яңгырларга киткәнче үзебез алып бирик булмаса. Улым, киленем, тагын оныкларым синең унбиш сутый бакчаңны ярты көн дигәндә актарып чыгарлар, күрми дә калырсың»,— дигән иде бит аңа күршесе Өммегөлсем. Юк шул, тыңламады аны Сәрия карчык, киреләнде, үсүзләнде.

«Кырдагысы түгел, амбардагысы ашлык»,— дип кабатларга яраткан Сәрия карчыкның күңеле бәрәңгене идән астына кертеп салмыйча тынычланмас, билгеле. Юкса, җитмешкә җитеп килгән карчыкка өч-дүрт капчык бәрәңге җитеп ашкан да бит. Терлек-туарына кыш буе ашатып чыгарга кирәкме ул бәрәңге? Иә булмаса кош-кортынамы? Биш тавык та бер әтәч —

---

Ранис ГАЗИЗОВ *(1959) — вакытлы матбугат битләрендә чыккан шаян хикәяләр авторы. Журналда проза әсәре белән беренче тапкыр катнаша. Казанда яши.*

аның бөтен мал-туары да, кош-корты да шулар гына бит. Карчыкның ел саен арт бакчасын тутырып бәрәңге утыртуы авыл халкын гаҗәпсендерә иде. «Нигә нужалана инде бу карчык?»— дип уйлаучылар да, «һаман да җитмәс икән, ач күзләнү җүнлегә илтми ул!»— дип әйтүчеләр дә табыла араларында.

Карчыкның кызы өчен тырышканын беләләрме соң алар? Белсәләр, җыен юк-барны сөйләмәсләр иде шул. Хәер, кызы «утыртмыйк, әни» дисә, Сәрия карчык арт бакчасына бөтенләй әйләнеп тә карамас иде. Туйган инде ул аннан. Артык җирен, тотар иде дә, әнә, бакча башындагы Фәхретдингә бирер иде. Югыйсә, ул, арткы бакчасында урын җитмәгәнгә, бәрәңгене ел саен авыл башындагы кырга утырта. Утыртмый хәле юк, тугыз баласын ашатасы бар аның. Фәхретдин инде ничә тапкыр Сәрия карчык белән шул җир хакында сүз кузгатып карады, хәтта аңа ашарга җитәрлек бәрәңгесен дә үзе үстереп бирергә вәгъдә итте. Карчык ризасын риза, тик шәһәрдәге кызының да тамагы бар бит әле. Аның да, Фәхретдин балалары кебек, бәрәңге ашыйсы килә ич. Шуңа күрә унбиш сутый җиргә ябышып ята ул, әнә хәзер дә шул бәрәңгесе өчен ут йотып утыра. Ут йотарсың да, чөнки бәрәңгенең алтынга тиң чаклары күп булды Сәрия карчык гомерендә. Шул чакларның берсе исә хәтеренә аеруча нык сеңеп калган.

... Сәриянең әтисе беренче Бөтендөнья сугышыннан әйләнеп кайтмады. Тормышның бөтен йөге әнисе җилкәсенә күчте. Ашарга каян әләкте шуннан, ничек туры килсә шулай табыштыргалап, ата назыннан өзелгән өч баланың тамагы турында кайгыртты ана. Беркөнне, төн урталары җитеп килгәндер, Сәрия әнисенең үксеп-үксеп елаган тавышына уянып китте һәм куркынган тавыш белән:

— Әнием, әни дим, ник елыйсың? Ни булды?— дип, әнисенең кочагына ташланды. Балалар арасында иң зурысы булганмы, әнисе Сәриядән берни яшерми — һәрчак үз күңелендәгесе белән уртаклаша торган иде.

— Ашарга бәрәңгебез бетеп килә бит, кызым, нишләрбез?— диде ул.

Шул бәрәңгене кыш чыгасы калган көннәргә ничек тартып-сузып җиткергәннәрдер — Сәрия моны әле дә булса башына сыйдыра алмый. Аннан соң инде күпме сулар акты, ничәмә-ничә тапкыр бәрәңгеләр чәчәк атты, аны туйганчы рәхәтләнеп ашарлык вакытлар да җитте, тик Сәрия карчыкның күңелендә әлеге вакыйга шул килеш әче тамырлары белән утырып калды.

Ниһаять, җиде көн, җиде төн бертоташ яуган яңгырлардан соң, көннәр аязып китте. Хәтта, берән-сәрән генә булса да, кояш күренгәләп алды. Табигать белән бергә Сәрия карчыкның күңеле дә үзгәреш кичерә иде. Болай булса, бәрәңгесе юештә череп ятмас, алыныр, тик менә кызы гына кайтып җитсен. Бәрәңге алырга кайтмый калган елы юк иде Сафиясенең. Гомумән, кызы еш кайта торган иде аның. Ә быел нишләптер җәйдән бирле кайтканы юк. Менә шул хәл Сәрия карчыкның күңелен телгәли дә инде. Ниләр генә уйлап бетермәде ул. Үзе дә, бернигә карап-нитеп тормый калага чыгып китәр иде дә, тик Сәрия карчыкның бер биш былтыр инде беркая да барганы юк. Ерак юлга чыгарга курку картлык галәмәтедер инде. Хәер, Сәрия карчыкның башына нинди генә уйлар килмәсен, кызының бүген, бүген булмаса, иртәгә кайтасына өметен өзми иде ул. Көн дә көтте ул аны. Инде ничәнче тапкыр төшендә күреп сөйләште. Тик төшендә генә шул...

Сәрия карчык өчен көтеп алынган шимбә көн дә килеп җитте. Нишләптер, кызы бу ялга кайтырга тиеш кебек тоелды аңа. Бүген кызы кайтырга тиеш, дип, үзен артык инандыргангамы, күңеле күтәренке иде. Көне дә матур булырга охшаган. Карчык, торуга ук, урын-җирләрен пөхтә итеп җыеп куйды, караватына бәйрәмнәрдә генә җәя торган чәчәкле япмасын җәйде, идәндәге паласларны рәтләде. Шулар белән мәш килеп, вакыт үткәнен дә сизмәде. Чәй дә эчеп тормыйча, авыл башына таба юл алды. Ерак барырга туры килмәде аңа, урам чатында Хөснижиһан карчык белән очрашты.

— Нихәл, Сәрия! Кая болай иртәләдең әле?— дип сорады ул, бертуктаусыз кеткелдәп, каршысында таягына таянып басып торган Сәрия карчыкны баштанаяк күзәтеп.

— Аллага шөкер, Хөснижиһан, исәнлекме-саулыкмы?!— диде дә, капылт кына тукталып калды Сәрия карчык. Моңсулана барган карашын олы юл ягына төбәп, авыр гына бер көрсенде дә, сүзен дәвам итте: — Кызым кайтмасмы бүген дигән идем әле. Ай саен, кая ул, кайвакыт атна

саен диярлек кайта торган иде. Иөрмә инде болай атна саен арып-талып дигәч тә, барыбер кайта иде. Өч ай бит инде, өч көн генә түгел...

Әйтәсе сүзен яшергәндәй, Сәрия карчык чәчәкле яулыгының чите белән авызын каплады.

— Шулай шул, Сәрия, нишләтергә инде ул балаларны, төннәр йокламый, бер алманы бишкә бүлеп дигәндәй, барысын уртак, юкны бар итеп үстерәсең-үстерәсең дә,— диде дә, Хөснижиһан карчык көрсенеп куйды.— Аннары, үсеп җиткәч, аналарының чәче нилектән агарганын оныталар, күрәсең... Югыйсә, бер-ике кәлимә сүз белән генә булса да кош теледәй хат язып салырга була бит. Мин үземнең Азатымны әйтәм. Хатларны бигрәк сагындырып кына яза инде. Ә менә икенчесе — Айрат улым — бөтенләй башка, күз тимәсен, хаты килми калган атнасы бик сирәктер...

Хат турында сүз кузгатылгач, Сәрия карчык канатланып киткәндәй булды:

— И-и, Сафияне әйтмәгән булсын, хатны яудырып кына тора анысы. Атна саен диярлек хаты килеп тора. Язган хатларын укыган саен укыйсы гына килеп тора, бигрәкләр дә җылы итеп яза инде, балам. Соңгы вакытта хаты саен, кайтырмын, әни, көт, дип яза. Кайтасым бик килә дә, эшемнең бик тыгыз чагы дигән шул, балам. Эшкә баштанаяк чума инде ул. Аның өчен беренче чиратта эш, аннары гына үзен карый. Бигрәкләр дә эш җанлы бала булды инде... Әле авыл башына таба барышым, ничектер бүген Сафиям кайтыр төсле, шуңа каршы бара торыйм дидем.

Озакламый, каршысында Хәдичә карчык пәйда булды. Юлны кара мәче бүлдемени, Сәрия карчык шып итеп туктады, мондый кискенлек аны куркытты булса кирәк, хәтта ул җиңелчә калтыранып та куйды. Карт кешегә күп кирәкмени?! Анысына гына түзәргә булыр иде әле, тик, хәләхвәлләр сорашканнан соң, сүз ничектер үзеннән-үзе Сафиягә күчте. Менә шунда булган икән инде Сәрия карчыкның күрәселәре, ишетәселәре! Миләш ашаган диярсең, Хәдичә карчыкның бөрешкән авызыннан сүзләр түгел, уклар атылгандай тоелды. Кычкырмады аңа Хәдичә, әшәке сүзләр дә әйтмәде, тик аның авызыннан бер җепкә тезелеп чыккан сүзләр Сәрия карчыкка шулкадәрле тәэсир итте ки, шул минутта җир ярылса, ул шунда төшеп китәргә дә риза иде. Әйтте шул Хәдичә, кырык елдан соң Сәрия карчыкның сер сандыгын ачты да салды:

— Сафия синең үз кызың түгел икән бит...— диде.

Сәрия карчык гомере буе шушы серне берәрсе белүдән өркеп яшәде, хәер аны шуңа өйрәттеләр, заманы башка иде бит. Кылган игелекле эшләре, изгелекләре өчен куркып яшәргә мәҗбүр булды адәм баласы. Хәдичә сүзләреннән соң Сәрия карчык башта, шул курку галәмәтеннәндер инде, калтыранып куйды, аннары куллары белән битен каплады да җиргә тезләнде, гыйбадәт кылган кешедәй, маңгае пычрак җиргә тигәнче чүгәләп алды, авыз эченнән нидер мыгырдый-мыгырдый башын күтәрде. Бертуктаусыз: «Ал-лам, Сафия кызым, балам»,— дип кабатлады. Карчыкның бу кыланышларына карап нишләргә белми аптырап басып торган Хәдичә, аңына килеп, ашыга-ашыга китеп барды.

Шул вакыйгадан соң Сәрия карчык өч көн рәттән урын өстендә ятты. Бик каты авырды ул. Аның нидән һәм нинди чир белән авырганын бер генә врач та, бер генә күрәзәче дә белә алмас иде, мөгаен. Өч көн, өч төн саташып чыкты Сәрия карчык, алдында бер яшьлеге, бер аждаһадай ыжгырып торган Хәдичә килеп басты: «Сафия синең үз кызың түгел икән бит... Сафия синең үз кызың түгел икән бит...»

«Галимулланы оныттыңмы әллә?— диде аңа Хәдичә теге чакта.— Яшь чак — җүләр чак, диләрме әле. Яшьлектә синең башыңны әйләндергән кеше шул Галимулла түгелме соң инде? Яле, хәтереңне яңартып кара, бәлки исеңә төшәр. Гомере буе укытучы булып эшләгән кешенең хәтере яхшы булырга тиеш аның. Менә шул Галимулла белән кодалар булдык та куйдык бит әле. Шулай ничектер сүз ара сүз чыгып, синең хакта сөйләп киттем. Шуннан синең белән ничек кызыксынганын күрсәң әгәр. Бөтенесен сорашты. Үткәннәрне һич кенә дә оныта алмый икән, сине инде теленнән дә төшермәде. Тормыш көтелмәгән хәлләргә бик бай бит ул. Сафия турында газетадан укыган, «Туктале, бу шул Сафия түгелме икән, фамилиясе Сәриянеке кебек»,— дигән дә Сафияне эзләп тапкан, аның белән күрешкән. Кызыңның күптән кайтканы юк бит инде, Галимулланың да аның белән очрашып сөйләшүенә алты айлап вакыт үткәндер. Миңа сөйлә-

гәннәрне Сафиягә дә сөйләми калмагандыр, билгеле. Дөреслекне белгәч, кызың да синнән йөз чөергәндер...»

Кода булганнар, имеш, Галимулла белән. Хәер, Галимулласын да әйтер идем, кеше түгел икән. Кеше булса, теге вакытта Сәрияне җиде юл чатында калдырып киткән булыр идеме? Яшьлегендә үк инде ул Галимулланы тормышыннан гомерлеккә сызып ташлаган иде дә, бүген Хәдичә кабат исенә төшерергә мәҗбүр итте.

... Утыз җиденче елның көзге салкын төне. Сәрия, иңбашына иске күксел пәлтәсен салып, тәрәзә янында утыра. Ире — Галимулласы кайтып җитмәгән, шуңа урамнан күзен алмый аны көтә ул. Иренең болай соңарып кайтуы беренче тапкыр гына түгел инде. Сәрия моңа ияләнеп тә бара бугай, тик барыбер күзенә йокы керми интегә.

Тәрәзә янында шулай уйга бирелеп утырган Сәрия кинәт кисәк-кисәк ишек дөбердәткән тавышка сискәнеп китте. Галимулласының ишекне бервакытта да болай шакылдатканы юк иде. Кем булыр икән? Галимулладан башка беркемне дә көтми бит Сәрия. Ул ишекне ачарга җыенгалаганчы, теге яктан аяк белән дә типкәли башладылар. Ул да булмады, сабый баланың колакларны ярып кергән, үксеп-үксеп елаган әче тавышы ишетелде. Сәрия кабалана-кабалана ишекне ачты. Һәм аннан-моннан гына төрелгән баланы кулына кысып тоткан яшь кенә кызның куркынган күзләрен күрде. Кайдадыр күргәне бар бит аның бу кызны, таныш күзләр. Тик кайда? Бәй, күршесе Халисәләрдә яшәүче фатирчы — студент кыз бит бу. Сәрия, аны-моны уйлап-нитеп тормыйча, кызның кулыннан баланы үз кочагына алды. Шунда гына ул кызның әллә куркудан, әллә туңудан дердер калтырануын тойды. Аны, кулларыннан җитәкләп, өйгә алып керде. Сәрия берни дәшмәде, дөресрәге, дәшә алмады. Чөнки күңеле аның нидер сизенә иде, бик яман хәбәрләр ишетәсен дә белә иде...

Иң элек кулында тыпырчына-тыпырчына бертуктаусыз елаган баланы тынычландырырга кирәк иде. Ул аны, караватка салып, аннан-моннан гына төрелгән чүпрәкне сүтә башлады. Бәй, Халисә кызы ич бу!

— Ни булды тагын? Халисә апаң үзе кайда?— дип сорады Сәрия, куркынган кыяфәтен студент кызга төбәп.

— Алып киттеләр...— Кыз, башындагы яулыгын салып, бит алмасына кунакларга өлгергән күз яшьләрен сөртеп алды.— Халисә апа үзенең соңгы сүзләрен сезгә җиткерергә кушты. Менә алар: «Кызым Сафиямне, йөрәк пārәмне, күршедәге укытучы Сәрия апаңа кертерсең. Саклый күрсен баланы, изгелеген гомерем буе онытмам. Бөтен ышанычым да, таянычым да аңарда гына»... Халисә апаны ябулы машина алып китте. Машина капка төбенә килеп туктауга, белгәндәй, ул миңа тизрәк баланы төреп бирде дә, без чыгып та өлгердек. Машина күздән югалганчы качып карап тордык та, менә сезгә кердек...

Шул шомлы төннән соң Сәрия өчен тынгысыз да, шул ук вакытта яңа шатлыклы мәшәкатьләр өстәгән көннәр һәм төннәр башланды. Бигрәк тә төннәрен янында нәни бала барлыгына сөенеп йөрде. Хәзер ул, Галимулласын беркадәр көтә дә, Сафия янына барып ята һәм аның белән бергә йоклап киткәнен тоймый да кала.

Тик беркөнне Галимулласы янә шомлы хәбәр салды:

— Ишеттеңме син, Сәрия, шәһәрдә шундый сүзләр йөри,— дип, ашыкмый гына сөйли башлады.— Халык дошманнарының балаларын махсус йортларга озаталар икән...

Сәрия тәмам коелып төште, идән уртасына тезләнгән килеш:

— Нинди вәхшилек бу, нинди явызлык?..— дип үкседе.— Иә, әйт, Галимулла, балаларның биредә ни гаепләре бар соң? Алар бит әле сабый гына, берни белмиләр...

Бары тик таң алдыннан гына килде шундый уй аңа. Иртән Галимулласына да җиткерергә ашыкты:

— Авылга китәргә кирәк безгә, Галимулла, аннан алар Сафияне таба алмаслар, ә авылда аның фамилиясен дә, атасының исемен дә үзгәртербез,— дип әйтүе булды, йокылы күзләрен уып торган Галимулла кистереп салды:

— Авылга?! Юк! Юк! Мин биредән беркая да китмәячәкмен...

Нәкъ менә шундый җавап ишетүдән курыккан иде дә инде Сәрия. Шулай булыр дип чамалаган иде. Тик һаман өметен өзмәде.

— Галимулла, Сафия безнең балабыз булыр. Без аны үзебезнең кызыбыз күк үз итеп үстерербез. Баласыз да яшәп булмый бит инде,— диде.

— Нәрсә?! Кеше баласынмы? Мин, кеше баласын караганчы, үз баламны үстерәм.
— Ни сөйлисең син, Галимулла, нинди бала тагын? Һични аңламыйм...
— Нинди бала булсын — үз балам.
— Ничек? Безнең балабыз булмауда гаеп синдә түгелме соң?
— Гаеп синең үзеңдә! Минем балам, беләсең килсә, бар инде Үз балам!
Икенче көнне иртән Сәрия авылга юл тотты. Шәһәрдән аңа берьюлы ике хәбәр килеп ирешә: беренчесе — Галимулла хакында иде, аңа Сәриянең әллә ни исе китмәде. Ул Галимулланың шәһәр поликлиникасында эшләүче врач хатын белән бергә яшәвен, аның белән ир бала үстерүләрен белде. Ә менә Халисәләрне, имеш, Себер ягына озатканнар...
Сәрия карчык таң алдыннан гына йокыга талды. Иртән ул, бит алмаларына кунаклаган кояш нурларына сөенә-сөенә, ишегалдына чыкты. Урамда җылы иде, рәхәт иде аңа. Әбиләр чуагы буласы дигәннәр иде, шул башланадыр, күрәсең. Болай булгач, бәрәңгесе дә алыныр, бәлки, кызы да кайтып төшәр. Ә инде Хәдичә әйткәннәр дөрескә туры килеп, кайтмаса? Сер йомгагы, ничек кенә төенләп чорналса да, сүтелә икән. Төенләнгән килеш гомере буе сандык төбендә сакланыр, дип, үз-үзен инандырып яшәде бит ул. Күр әнә, гомереннең азагында сүтелде ул йомгак. Ә бит Сафиягә, үсеп җиткәч, барысын да сөйләгән булса, болай килеп чыкмас та иде. Сафиягә дөреслекне сөйләргә дип ничә тапкыр талпынып карады, картаймыш көнендә ялгызы гына калудан куркып, дәшмәде. Менә хәзер, барын да сер итеп саклаганы өчен, ходайдан бирелгән җәзаның иң зурысы шушыдыр инде, дип, үз-үзен битәрләде карчык.
Якшәмбе көн Сәрия карчык иртүк, агач көрәген тотып, бакчасына чыкты. Казый башлауга ук, буразнада мул булып уңган бәрәңгеләр дә күренгәли башлады. Сәрия карчыкның сагышларын үзләренә сеңдергәндәй, сап-сары бәрәңгеләр җир өстендә тәгәрәшеп ята. Карчык бер буразна бәрәңгене казып бетереп килгәндә бакчага берәм-берәм, көрәк-чиләген тотып, авыл хатыннары җыела башлады. Берәүләр казыды, икенчеләре чүпләде. Эшләр шулай гөрләп барганда, Хөсниҗиһан карчыкның тавышы барысын да шомландырып җибәрде.
— Сәрия, Сәрия дим!
— Нәрсә булды! Шулкадәрле котны алырдай кычкырмасаң...
— Сәрия, Сәрия, карале дим...— Хөсниҗиһан әйтәсе килгән сүзен, ничек кенә тырышмасын, кычкырып әйтә алмады, бары тик пышылдап, кулы белән генә төртеп күрсәтә алды. Шул якка Сәрия карчыкның борылып каравы булды, аның кулыннан бәрәңге белән тулган чиләге җиргә килеп төште, сап-сары бәрәңгеләр буразнага сибелде.
— Кызым, йөрәк парәм...— дип кенә әйтә алды ул һәм буразналар буйлап бакча башына таба йөгерде. Күз яшьләренә төелгән карчык, көченнән килгәнчә, абына-сөртенә йөгерде. Хәтта искән җил белән башыннан яулыгының төшеп калуын да тоймады ул...
Төне буе Сәрия карчык өендә ут янды. Карчыкның кызы белән чәй артында бер-берсенә сөйләр сүзләре күп иде...
Өч көннән соң, бәрәңгеләр алынып беткәч, Сафия калага китеп барды. Авыл капкасына җиткәндә генә, Сафияне озатып калган Сәрия карчык күксел-кара болытның кызы артыннан ияреп киткәнен күреп алды. Кызын нәрсәдәндер кисәтергә җыенгандай, ул кычкырырга теләде, ләкин булдыра алмады. Ә болыт Сафия артыннан иярүен белде. Бу тикмәгә түгелдер, дип хафаланды карчык...
Соңлап булса да кызына дөреслекне сөйләүдән карчык шатлык һәм җиңеллек кичерсә дә, аның болытка карап хафалануы юкка түгел иде. Сафия күп нәрсәләрне әйтеп бетермәде әнисенә: үзенең өч ай буе шифаханәдә ятканын яшерде. Ул бит врачлардан әнисен күреп килү һәм бәрәңге казуда булышу өчен генә сорап чыккан иде. Хәер, Сафия әле үзенең яман шеш чиреннән интегүен дә белми иде. Авылдан кайткач, ул тагын шифаханәгә кереп ятарга тиеш...
Болар хакында Сәрия карчык әлегә берни дә белми иде. Ләкин табигать нидер сиздерә икән: күккә ябышкан болыт карчыкның картлык гомеренә килеп ябышачак кара кайгыдан ишарә иде.

*Быел ЮНЕСКО карары белән бөтен дөнья күләмендә төрек халкының бөек шагыйре Юныс Әмрәнең иҗат бәйрәме билгеләп үтелә. Шул уңай белән без шагыйрьнең Төркиядә басылган юбилей китабыннан кереш мәкаләне һәм шигырьләрен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез.*

# МИЛЛИОННАР КҮҢЕЛЕНДӘ

Юныс Әмрә һәм аның шигырьләре инде менә җиде йөз елдан артык заман күңелләрдә һәм телләрдә яши. Анадолудагы авылларда йөргәндә мин еш кына колактан-колакка, нәселдән-нәселгә тапшырылган Юныс әсәрләрен искә алучы кешеләргә юлыктым. Австралиядә дә төрекчә белмәгән бер пакыстанлыдан Юныcның илаһи шигырьләрен тыңладым. Балкан илләрендә һәм Албаниядә Юныс әсәрләре яшәвенә шаһит булдым.

Төркиядә Юныс Әмрәне яратмаган кеше бар микән! Юныс Әмрәнең исеме ничәнче гасыр нур чәчә һәм мәхәббәт җилләре истерә. Юныс Әмрә мәхәббәте безне бер-беребезгә баглаган иң кыйммәтле җепләрнең берсе. Менә шуңа күрә милләтебез аңа күп яктан бурычлы.

Әзербайҗанлы мәшһүр шагыйрь Ваһабзадә «Бер җирдә булган хәлдә, нигә мең җирдә кабере» булуын сорый һәм җавабын болай бирә:

Һәр көн казылыр, чөнки күңелләрдә кабере,
Үләннәрдә, чәчәкләрдә һәм гөлләрдә кабере.
Ялгандырмы, чындырмы, бу инсан ничә инсан?
Барлык өнедер чыккан төрекнең кубызыннан!

Тереклек авазы ул Юныс Әмрә, «Барлыкның берлеге» билгесе. Шунлыктан үләннәрдә, чәчәкләрдә, гөлләрдә һәм күңелләрдә ул. Барлыгының чынлыгы, кешенең тереклек чылбырындагы югары урыны һәм кешенең бу югарылыкка күтәрелүе — чынбарлык яшәешенең нигезе. Ягъни, бер ислам суфые ул Дәрвиш Юныс.

Тереклекнең сәбәбе мәхәббәттер. Бар итүчегә мәхәббәт аша якынаелыр. Дөньяга килүнең сәбәбе һәм максаты — мәхәббәт. Кавышу юлы да аның иң бөек яратылыш булган кешенең күңеленнән кичәр...

Мин килмәдем өндәгәнгә,
Мин йөримен сөю өчен.
Дусның өе — күңелләрдер,
Күңелләр табарга килдем.

Барлыгы яратканнарының барлыгына охшамаган, затын төшенү мөмкин булмаган, бары әсәрен аңлау юллары гына ачык булган Алла бәндәсен бөтәннәр чылбырында халифә буларак яраткандыр. Алла кешегә яратканнарының иң изгесе булу бөеклеген биргән, чөнки аны галәмнең үзе сыйфатында бар иткән. Кеше нәни галәмдер. Кешене аңлаган галәмне дә төшенер. Гыйлем юлларында алга китү дә Алланы танып-белү юлыдыр. Белем кешенең Алла каршында бурычыдыр. Белем кешегә «үзен ачадыр». Үзеңне танып-белү бөтен белемнәрнең нигезедер.

Гыйлем, гыйлем — белмәктер,
Үз-үзеңне белмәктер.
Син үзеңне белмәсәң,
Нинди гыйлем булмактыр.

Бу дөньяда бер насыйбыбыз бардыр. Аны алырбыз һәм китәрбез. Берәү дә мәңгегә калмас. Асыл алачагыбыз һәм бирәчәгебез — мәхәббәт. Бар булуның нигезе — мәхәббәт.

Яратыйм, яратылыйм,
Бу дөньядан кем дә кичәр.

Кешелек әйләнеп кайтмый торган бер заман дәвамында яши. Фән-техника революциясе бөтен дөньяны һәм әһәмиятле системаларны кискен үзгәртә. Бу үзгәреш барышында Юныс Әмрәгә һәм аны барлыкка китергән мәдәниятќә әкренләп бөтен кешелекнең ихтыяжы үсә. Фән һәм компьютерлар дөньясында кешенең онытылмавы аның үзен таныл-белүенә бәйләнгән, адәм баласының яратылышын иң бөек могҗиза һәм галәмнең яшәеше рәвешендә бәйләгән Юныс Әмрәнең безнең белән бергә булуы әһәмиятле. Киләчәк көннәр кешесе роботлар әсирлегендә калмасын өчен шагыйрьләр яшәве хаҗәт. Моңа ирешү дә безнең, ягъни, бөек шигъри мәдәниятнең иясе булган милләтебезнең бурычыдыр. Юныс Әмрәне һәм аның рухи дөньясын менә ни өчен яңадан таныл-белүебез, аңлавыбыз һәм бөтен кешелеккә ачып бирүебез кирәк. Гыйлем заманының ГЫЙЛЕМ һәм МӘХӘББӘТ заманына әйләнүенә без дә лаеклы өлеш кертик.

**Намык КӘМАЛ ЗӘЙБӘК,**
Төркия республикасы мәдәният министры.

*Т. ӘЙДИ тәрҗемә итте.*

## Юныс Әмрә

*

Йә, Илаһым, әгәр сорау бирсәң миңа,
Шушы сүзем җавап булып торыр сиңа.

Кылсам да мин үз-үземә золым, гөнаһ,
Синең алда ни гаебем, әй, падишаһ?

Туганда ук әйттең: ул адәм кем?— дидең,—
Ул — гөнаһлы бәндә, бер тәкәббер мескен, дидең.

Үзең баштук гыйсьянчы ясагансың да,
Соңрак тарттың бар дөньяның җәзасына.

Эшләдең минем белән — ни эшләсәң дә,
Үзең куйган урыннан һич күчмәсәм дә.

Мин үземне төземәдем, син төзедең.
Ким-хурлык белән тутырып бар вөҗүдем.

Күзем ачып күргәнем шул: дөньяң — зиндан.
Бозыклыклар анда, шайтанлыклар тулган.

Төрмәң эчендә үлмәскә дип ачлыктан,
Мин сукбаең күпме шакшылыклар йоткан.

Мөлкәтеңнән артык нәрсә алдыммы мин?
Әллә бирәр хикмәтеңнән тандыммы мин?

Ризыгыңны тартып алыпмы ач иттем?
Әллә барлыгыңны талап мохтаҗ иттем?

Үчең бетмәдеме һаман, мине үтереп?
Черетеп мине, күземә туфрак тутырып?

Кыл кеби күпер төзеп, әйттең: «Кем кичә?
Булдыра алсаң, тәмугыма әләкмичә...

Адәмме соң кыл күпердән чыга алыр?
Таяна алмый, шул упкында ул югалыр?..»

Әгәр кулың күпер салса изге эштән,
Андый затлар бу хәятне җиңел кичкән.

Игелек кыл! Иң нык күпер шул булыр ул!
Җәннәтеңә иткән тугры юл булыр ул!

Гыйшкың алды миннән «мин»не...
Күңел тели бары сине!
Янамын мин көне-төне,
Миңа бары тик син кирәк!

Ни барына сөенерем,
Ни югына көнегерем,
Гыйшкың белән юаныры —
Миңа бары тик син кирәк!

Гыйшкың гашыйкны үтерер,
Диңгезләренә батырыр,
Барча дөньяны тутырыр —
Миңа бары тик син кирәк!

Гыйшкың шәрабеннән эчим,
Мәҗнүн булып таулар кичим,
Син дип, көн-төн янып көйим,
Миңа бары тик син кирәк!

Суфыйларга сөбхәт[1] кирәк,
Аһиләргә[2] ахир кирәк,
Мәҗнүннәргә Ләйлә кирәк,—
Миңа бары тик син кирәк!

Әгәр мине үтерсәләр,
Көлем күккә очырсалар,
Шунда да вөҗүдем елар —
Миңа бары тик син кирәк!

Юныс булыр минем атым,
Көн-төн арта хәсрәт утым,
Ике җиһанда максудым —
Миңа бары тик син кирәк!

---

[1] Сөбхәт — иркенләп сөйләшеп, гәпләшеп утыру.
[2] Аһи — суфыйлар берләшмәсенең әгъзасы.

*Aşkın aldı benden beni*
*Bana seni gerek seni*
*Ben yanarım dün ü günü*
*Bana seni gerek seni*

*Ne varlığa sevinirim*
*Ne yokluğa yerinirim*
*Aşkın ile avunurum*
*Bana seni gerek seni*

*Aşkın âşıklar öldürür*
*Aşk denizine daldırır*
*Tecellî ile doldurur*
*Bana seni gerek seni*

*Aşkın şarâbından içem*
*Mecnûn olup dağa düşem*
*Sensin dün ü gün endişem*
*Bana seni gerek seni*

*Sûfilere sohbet gerek*
*Ahîlere ahret gerek*
*Mecnunlara Leylâ gerek*
*Bana seni gerek seni*

*Eğer beni öldüreler*
*Külüm göğe savuralar*
*Toprağım orda çağıra*
*Bana seni gerek seni*

*Yûnus'durur benim adım*
*Gün geçtikçe artar odum*
*İki cihanda maksûdum*
*Bana seni gerek seni*

Фани дөньяда кунып киткәннәр
Инде янәдән килә алмаслар.
Туфрак-юрган бер ябынылгач,
Сөйли алмаслар, хәбәр салмаслар.

Кем баш очында үсә агачлар,
Кем баш очында сула үләннәр.
Яшьли үлгән дә, картлый үлгән дә
Сөйли алмаслар, хәбәр салмаслар.

Туфракка баткан җансыз тәннәре,
Сүзләре бетми кипкән телләре...
Дога кылыгыз! Алар үзләре
Сөйли алмаслар, хәбәр салмаслар.

Кайсы сәүдәгәр, кайсы мулладыр...
Әҗәл ширбәте кемгә дә авыр.
Фәкыйре дә, бай пире[1] дә — аннан
Сөйли алмаслар, хәбәр салмаслар.

...Әй, бахыр Юныс, күр тәкъдир эшен:
Коелыр тешләр, керфек-кашлар да...
Баш очындагы билге-ташлар да
Сөйли алмаслар, хәбәр салмаслар.

*Төрекчәдән Равил ФӘЙЗУЛЛИН тәрҗемәсе.*

1. Пир — ниндидер тәрикатькә нигез салучы, тәрикать башлыгы (тәрикать — суфыйлар оешмасы).

ПУБЛИЦИСТИКА

## Әмирхан Еники

# КЕМ ҖАВАПЛЫ?

Без көтелмәгән бер чорга килеп кердек. Сиксән бишенче елның язына чаклы дәвам итеп килгән «мактаулы заман» беркайчан да үзгәрмәс төсле иде. Хәлбуки, үзгәрүен, үзгәрергә тиешлеген әчебездән генә көтсәк тә, өмет-ышаныч бик аз иде. Чөнки мактаулы заманыбызның тәртип-низамнары тимербетоннан коелгандай һич тә какшамас кебек иде. Аларның шулай нык, мәңгелек булуына безне 70 ел буена өзлексез ышандырып килделәр... Инде менә какшамастай итеп төзелгән социализм атлы якты бинабыз көтмәгәндә селкенеп куйды, төрле җирендә тирән ярыклар күренде, хәтта ишелә дә башлады, һәм, ниһаять, аның эчтән тәмам черегән, тик тыштан гына сылап-буяп куелган бер корылма булуы ачыкланды.

Баштарак моңа бик үк ышанасы да килмәгән иде, алай ук куркыныч-хәтәр түгелдер әле дигән шик тә бар иде. Әмма аяусыз чынбарлык һәртөрле шикләрне сибереп ташлады: әйе, без моңарчы яшәп килгән дөньябызның таудай гөрселдәп ишелүен, аның җимерек хәрабәләре астыннан яңа дөньяның көч-хәл белән чыгып килүен күреп торабыз. Искесе нигезенә чаклы ишелеп бетәрме, яңасы ахыр чиктә чынлап күтәрелә алырмы — менә нәрсә хәзер безнең акылыбызны биләп, җаныбызны өзлексез борчып тора. Нинди булачак безнең киләчәк заманыбыз, азатлык белән иркенлекне күрербезме, ниһаять?! Уйлану күп, сүз-бәхәс күп, мәгәр көткән ачыклык юк та, тулы ышаныч аз хәзергә!

Шушы вакыйгалар уңае белән мин яшьләрнең без — картларга төбәлгән шикле һәм үпкәле карашларын күреп торам. Гүя алар бездән: «Ничек итеп сез илнең шушы хәлгә бер килеп төшәчәген алдан күрмәдегез, әйләнәгездәге гаделсезлекне, изү-талауны, алдау-көчләүне вакытында фаш итмәдегез, нәрсә карадыгыз сез, язучылар?» — дип туп-туры бәреп сорыйлар кебек... Әмма моңа дөрес җавап бирүе бер дә җиңел түгел.

Иң элек бер ачыклык кертәсе килә: бөтен гомеребез совет чорына туры килсә дә, күп хәлләрне үзебез күреп кичерсәк тә, без бик күп нәрсәләрдән шулай да хәбәрсез яшәдек. Партия һәм совет органнары үз эшләренең бик күбесен халыктан яшереп килгән. Бары хәбәрдарлык дигән яңа бер сәхифә ачылгач кына, әллә никадәр һич көтелмәгән чын хәлләрне без дә беренче мәртәбә шаккатып белдек.

Аннары инде, картларның үзләренә килгәндә, алар бит барысы да бер калыптан төшкән кешеләр түгел иде. Бик төрле иде бит алар — үзләре дә, язмышлары да, иманнары да... һәм заманга да аларның мөнәсәбәтләре бик төрле булды. Җаны-тәне белән ышанучылар бар иде (болар күпчелек), ышанып бетмәүчеләр дә аз түгел иде, хәтта заманны кабул итә алмаучылар да юк түгел иде. Мин үзем, мәсәлән, яңа заманның ясалма-ялган булуын ничектер тирем белән бик иртә тоя башладым, әмма аңа ышанырга, аңа ияреграгә тырышып яшәдем... Дөресен генә әйткәндә, бу өч төрле «картлар» арасында замана мәсьәләсендә берниндн бәхәс, фикер көрәше юк иде һәм булуы мөмкин дә түгел иде, чөнки безнең өстән хакимлек итүче идеология, аны бик уяу саклаучы тоталитар власть һичбер төрле бәхәскә, фикер хөрлегенә юл куймый иде. Шул сәбәпле, эчеңнән ни генә уйласаң да, син хаким идеологиягә буйсынырга һәм иҗатың белән тормышыңны да шуңа көйләргә мәҗбүр идең. Кыскасы, Сталин, Хрущев, Брежнев чорларын кичергән бүгенге картларның ул чактагы гамәлен ике төрле нәрсә билгеләде: **алдану** һәм **курку**. Алдану — ышану өчен, курку — башыңны саклау өчен ки-

рәк иде. Моңардан түбәндәге нәтиҗәне дә ясарга мөмкин: әгәр дә бүгенге яшьләргә без кичергән заманнарда яшәргә туры килсә, шик юк ки, аларның язмышлары нәкъ безнеке төсле булыр иде.

• • •

Әнә шул алдану белән куркуның бик ачык мисаллары итеп, мин безнең әдәбият дөньясыннан үзем кичергән берничә вакыйганы язып калдыруны, ниһаять, кирәк таптым. Боларны «Соңгы китап»ка кертергә дә исәбем бар иде, ләкин вакыты җитмәгән әле, дип кичектергән булдым. Хәзер исә җиту генә түгел, шактый соңга да калдым шикелле. Хәер, гыйбрәтле фактлар беркайчан да әһәмиятен югалтмаска тиештер дип беләм.

Сүз биредә сугыштан соңгы елларда безнең язучылар союзының өч рәисе белән минем арада булып узган һәм күңелемдә гомерлеккә уелып калган бик үкенечле дә аянычлы өч вакыйга турында барачак. Шуның беренчесе Афзал абзый Шамов вакытында булды.

• • •

1956 елның әллә җәй ахыры, әллә көз башы иде, минем шәһәр читендәге кечкенә генә агач өем алдына Язучылар Союзы машинасы килеп туктады. Ул чакта Союзның бердәнбер иске җиңел машинасын Майшәкәр исемле ифрат уңган җитез хатын йөртә иде. Өйгә килеп керү белән ул кабалана биреп: «Әмирхан абый, Сезне алырга килдем»,— диде. Мин аптырабрак: «Ни өчен?»— дип сорагач, Майшәкәр: «Белмим. Афзал абзый тизрәк алып килергә кушты»,— диде.

Шактый ук сәер булып тоелды бу миңа... Союз машинасының беренче мәртәбә мине алырга килүе — нигә ул хәтле кирәк булдым икән мин персидәтель абзыйга?

Кузгалып киткәч тә Майшәкәр әйтте: «Инде хәзер Нәкый абзыйны кереп алабыз». «Ул да кирәкмени?» «Әйе, аны да китереп җиткерергә кушты Афзал абзый!» ...Ала-ай, кызык бит әле бу... Союз Нәкый абзыйны сирәк кузгата торган иде, нинди гадәттән тыш вакыйга килеп чыкты икән анда? «Тагын кемнәрне алып килергә кушты, Афзал абзыең?»— дип сорадым мин сак кына... «Барыгызны да чакыртты... Сезнең телефон юк бит, менә миңа барырга туры килде»,— диде Майшәкәр.

Нәкый абзыйлар ул чакта Кольцодан чак кына арырак, Тукай һәйкәле артындагы яңа йортта торалар иде. Майшәкәр, җитез генә төшеп, аларга кереп китте. Мин машинада калдым. Шактый гына көтәргә туры килде — Нәкый абзый, кем генә чакырса да, кабалана торганнардан түгел... Ниһаять, чыктылар, исәнләштек, һәм кузгалып киттек. Бер-ике минуттан Матбугат йортына барып та җиттек. Баскычтан менешли Нәкый абзый миннән әкрен генә сорап куйды: «Бу ни тамаша, нигә кирәк булдык икән без Әбзәлетдин иптәшкә?» «Менә, хозурына кергәч, белербез инде»,— дидем мин аңа.

Әле көннең беренче яртысы гына булганга күрә, Союз тирәсендә «каләм әһелләре» күренмиләр иде. Афзал абзый бүлмәсендә ялгызы гына иде, ул безне аягүрә каршы алды, утырырга кушты, үзе һаман баскан килеш калды. Кыска гына хәл-әхвәлне сорашканнан соң, бернинди кереш сүзсез туп-туры бездән сорады:

— Пастернак турында ишеткәнсездер инде?

Безнең өчен бу шактый көтелмәгән сорау булды. (Без бит үзебездә берәр хәл булмады микән, дип уйлабрак килгән идек. Баксаң, эш әнә нәрсәдә икән). Дөрес, соңгы вакытларда Борис Пастернак исеме тирәсендә зур шау-шу купканын без күпмедер дәрәҗәдә ишетеп тә, укып та белә идек. Тора-бара бу шау-шу бер кампания төсен дә алып өлгерде. Аңа «Доктор Живаго» дигән әсәре өчен Нобель премиясе бирелгәч, шагыйрьне каты гаепләү һәм яман тиргәү аеруча көчәйде... Әйе, болары безгә мәгълүм диярлек. Мәгәр безне менә бүген машинада җилтерәтеп бирегә китерү нигә кирәк булды соң? Нинди гадәттән тыш вакыйга бар тагын?

Афзал абзый моны да безгә бик ачык әйтеп бирде:

— Пастернакны язучылар союзыннан чыгарганнар?

Шунда ук «ни өчен» дигән сорау туса да, без аны биреп тормадык — туктаусыз кыйналып килгән шагыйрьнең ахыр чиктә союздан чыгарылуы бер дә искитәрлек вакыйга түгел иде. Безнең заманда андый хәлләр һаман булгалап тора... Күптәнме әле Анна Ахматова белән Зощенконы да, дөнья шаулатып, әдәбияттан кудылар... Шулай да Афзал абзый, без бирмәгән сорауны үзе сизгәндәй, эшнең ничек булганын бераз аңлатып та бирде:

— Мәскәүдә язучыларның зур җыелышы булып узган. Шунда Пастернакның совет язучысына һич тә килешмәгән гамәлен бик каты тәнкыйтъ иткәннәр... Алай гына да

түгел, аны союздан чыгарырга дип бертавыштан карар да кабул иткәннәр... Берәү дә яклап чыкмаган, беләсегез килсә!

Нәкый абзый, гадәтенчә, сүзне уенга борырга теләде:

— Һа, әшне тиз тотканнар икән, безнең ризалыкны көтеп тормаганнар. Бик әйбәт... Алайса, Әбзәлетдин, безгә бүрекләрне кияргә дә ярый торгандыр инде.— Һәм ул китәргә җыенгандай кузгалып куйды.

— Карале, Нәкый, бу бит — бер дә уен эш түгел,— диде Афзал абзый гаҗәпләнү һәм әзрәк ачу белән дә.— Сүз, беләсегез килсә, гаять житди политик мәсьәлә турында бара... Совет язучысы исемен йөрткән Пастернак асылда безнең революциянең изге максатларын бозып, яманлап әсәр яза, шуны чит илдә бастыра, шуның өчен, җитмәсә, Нобель премиясен дә ала.

— Алмаган шикелле әле,— дидем мин, икеләнебрәк.

— Алыр, баш тартмас,— диде Афзал абзый, сүзен кызу гына дәвам иттереп.— Буржуазия бәлә бүләкне кемгә бирергә... Кыскасы, Пастернакның бу антипатриотик эшенә без, татар совет язучылары да, үзебезнең мөнәсәбәтебезне билгеләргә тиешбез.

— Ничек итеп? — диде Нәкый абзый.

— Ягъни без, татар язучылары, Пастернакның ул гамәлен хөкем итәргә һәм аңа карата күрелгән чараны дөрес дип санарга тиешбез.

Алай икән. Без сүзсез генә утыра бирдек. Бу бик киеренке бер мизгел иде. Афзал абзый шуны тоеп булса кирәк, бераз акланырга теләгәндәй:

— Бездә генә түгел, барлык союз оешмаларында да бу шулай эшләнә,— диде.— Тиешле урыннар белән сөйләшеп, киңәшеп... Бер минем инициатива гына дип уйламагыз!

— Соң сез дә, кирәксә, союз исеменнән шулай эшләгез... Минем моңа ни катнашым бар?! — диде Нәкый абзый, иңбашын җыера биреп.

— Юк, Нәкый, синең дә катнашың бар,— диде Афзал абзый, кистереп.— Һәрбер намуслы язучының...

Ләкин Нәкый абзый, ни әйтәсен алдан ук белгән шикелле, аның сүзен бүлде:

— Гаҗәп, гаҗәп!.. Мәскәүдә әнә туздан сорап тормыйча Пастернакның эшен бетереп куйганнар бит инде... Тагын ни кирәк?

— Синең сүзең кирәк, Нәкый... Әнә шул Мәскәү язучылар җәмәгатьчелегенең Пастернакка карата чыгарган карары белән килешәсеңме-юкмы?.. Мин, мәсәлән, Татарстан язучылары килешергә тиеш дип беләм. Чөнки сүз бер язучының союз уставын тупас бозуы, ягъни уставта әйтелгән совет позициясеннән читкә тайпылуы турында бара.— Без менә,— диде ул, сүзен дәвам итеп,— язучылар исеменнән Мәскәүгә җибәрергә хат яздык, ул әнә алдыгызда ята... Күп кенә иптәшләр аңа кул куйдылар инде. Сез дә укып карагыз... Килешсәгез — кулыгызны куясыз, килешмәсәгез — юк, мәгәр позициягез ачык булырга тиеш.

Нәкый абзый кинәт кычкырып көлеп җибәрде.

— Кара син аны! Позицияне ачыклар өчен генә син безнең арттан машина җибәргәнсең икән ләбаса!

Афзал абзый кара янып китте, ләкин тынычлыгын саклап калды.

— Сезнең эше мөхтәрәм язучыларны җәяү йөртеп булмый бит инде,— диган булды ул.

Ә Нәкый абзый шунда ук бик җитдиләнеп, аны бөтенләй тыңламагандай, үз уйларына бирелгән иде.

Инде минем үз хәлемә күчәсем килә. Афзал абзыйны тыңлап утырганда ук миндә ирексездән ике төрле уй үзара тартыша башлады. Күптән инде үзем дә кагылып-сугылып килгәнгә күрә, кешегә политик гаеп ташларга бер дә яратмый идем. Менә хәзерге шикелле бөтен вөҗүдем андый эшкә каршы, һәм моңарчы минем һич кемне дә политик яктан гаепләп чыкканым булмады.

Аннары, Борис Пастернакның зур шагыйрь икәнлеген ишетеп белсәм дә, хәзергә кадәр миңа, оятыма каршы, аның бер әсәрен дә табып укырга туры килмәде. Ә каядыр читтә басылганын әйтеп торасы да юк... Димәк, мин аңа ташланган гаепнең чынмы-ялганмы икәнен белмим, шулай булгач, кешелек ноктасыннан караганда, минем аны гаепләргә хакым бармы?.. Юк, һәм булмаска да тиеш!

Әйе, минем үз акылым миңа шулай ди, бу гаепләү кампаниясенә кушылмаска, намусымны кечләмәскә куша. Әмма шул ук вакытта фани исәплардән туган икенче бер уй да миңа үзенекен тукый, җанга тынычлык бирми иде. Дөресен генә әйткәндә, минем бу уем да әнә шул күптән кагылып-сугылып килүләрдән туган иде. Без кичергән чорларда идеология һәм политика аркасында кыйналулар да, бөтенләй харап ителүләр дә бик күп булды. Әнә хәзер дә Афзал абзый: «Позициягез ачык булсын!» — ди. «Позиция» диган бу сүз хәзер бик модада — аны гел искә төшереп кенә торалар. Позициясе туры килмәгән кеше әллә ничә төрле күзәтү астында яшәргә мәҗбүр. Аны төрлечә

кыса башлыйлар (мәсәлән, язган әйберене басмыйча йөдәтәләр яки нәшрияттагы китабыңны планнан сызалар). Ә кая барасың, ни эшли аласың, ничек яшисең бу ирегең һәм жаның богаулы бер заманда?! Әнә шундый бер-берсе белән килешергә теләмәгән «ике фикер» көрәше арасында идем мин...

Ә Афзал абзый бөтен мәһабәт гәүдәсе белән үрә басып, безнең кузгалганны көтеп тора. Барлык язучыларныкына караганда да Нәкый Исәнбәт белән минем нишләргә уйлавыбыз аның өчен әһәмиятлерәк иде кебек... Үзенә күрә безне тагын бер сынап карау!

Мин, билгеле, Нәкый абзыйдан узып ни дә булса эшләргә тиеш түгел идем. Ул яше белән дә, дәрәҗәсе белән дә миннән күп өстен, һәм миңа караганда күбрәк кыйналган да кеше. Әле кайчан гына җәдитчелектә гаепләп каты гына кыйнадылар — Хрущевның үзенә барып җитәргә мәҗбүр булды агаебыз!.. Аннары гади әдәп дигән нәрсә дә бар бит әле — сүзне башлап олы кеше әйтергә тиеш.

...Тынып тору озаккарак китте булса кирәк, Афзал абзый коры гына:

— Йәгез, иптәшләр, мин көтәм! — дип куйды.

Шуннан соң Нәкый абзый, бер сүз әйтмәстән, кинәт кенә сикереп торды да, хатка күз дә салмыйча, астына тиз-тиз генә кулын куеп, каләмен ташлады. Аның бу хәрәкәтләре миңа ничектер «чәнчелеп китегез!» дигән шикеллерәк тоелды. Һәрхәлдә, аның кул куюы теләп, килешеп эшләнгән эш түгел иде. Соңыннан ул моны үзе дә миңа әйтте.

Инде минем чират... Торып, өстәлдә яткан хатны өстән-өстән генә карап чыккан булдым. Билгеле, хатның эчтәлеге белән танышу өчен дә, аңа карата нидер әйтер өчен дә түгел. Бары вакытны сузар өчен генә. Ахырына җиткәч, сүзсез генә кулымны куйдым — монда имзалар җитәрлек иде инде...

Шул рәвешчә, Нобель премиясенә лаек булган шагыйрьне хөкем итүгә без дә катнаштык. Бу — кичерүе читен түбәнлеккә бару иде, әмма намусыбыз кушканга түгел, ә ирексездән ниндидер өстен бер рәхимсез көчкә буйсынып... Нинди көч соң ул безне шулай еш кына сындыра? Бу сорауга җавапны мин иң ахырдан гына бирәчәкмен. Хәзер исә минә мондый сорауга үзеннән-үзе җавап сорала шикелле: ирексездән кылган гамәлебезне вөҗдан хөкеме алдында аклап буламы? Юк, булмый, мөмкин түгел!.. Иллә мәгәр түбәнлеккә баруыбызны беркадәр җиңеләйткән сәбәп шулай да бар иде. Эш шунда ки, шагыйрь Пастернакны соңгы вакытларда бөтен матбугат тирги, каһәрли, русның безнең өчен авторитет булган зур-зур язучылары аны гаепләп чыга, беркем тарафыннан яклау сүзе ишеткәнебез юк. Шуннан соң безгә, гел шик астында яшәүче ике татар язучысына, нәрсә эшләргә кала?.. Әгәр Пастернакны гаепләү нахак булып чыкса (ә нахаклыгын алдан ук күрергә мөмкин иде), бу бөтен совет әдәбиятына җуелмас оят китерәчәк һәм бөтен җавабы да безнең һәммәбез өстенә төшәчәк. Кампания колына әйләнү коточкыч нәрсә ул!

Миңа калса, Афзал абзый үзе дә — кампания колы. Татар язучылары исеменнән Пастернакка каршы хат язарга аңа, мөгаен, обком кушкандыр әле. Моның кебек җитди эшне ул үз белдеге белән генә эшләргә, ихтимал, җөрьәт итмәс иде. Безнең председательләр көн саен диярлек обкомга йөреп торалар. Бер генә эш тә шул бинада утыручы эреле-ваклы «җитәкчеләр»нең кушуыннан яки рөхсәтеннән башка үтәлми бездә...

Билгеле, Афзал абзый үзе кол булуын инкарь иткән булыр иде. Партия кушкан һәр эш аның өчен, күңеленә хуш килсә дә, килмәсә дә, һичшиксез, дөрес һәм хаклы! Ул бит, үзе әйтмешли — партиянең «тугрылыклы солдаты» иде, мәрхүм!

• • •

Үкенечле вакыйганың икенчесе союзда Ибраһим Газый рәислек иткән чагында булды. Бусы да «кул кую» белән бәйләнгән, әмма мине иң аптыратканы һәм авыр газапка дучар иткәне!..

1968 ел, августның соңгы яртысы, ә мин җәй буе диярлек яңа квартирга ордер алалмыйча җәфаланып йөрим. Шәһәр читендәге кечкенә агач өебезне сүтәргә тиешләр. Күрше өйләрне сүтеп бетерделәр инде, безнең дә капка-коймаларны ваттылар, бакчабыздагы алмагачларны да кистеләр, япа-ялгыз утырып калган өйдән безнең чыгып киткәнне генә көтәләр. Монда зур яңа йорт сала башлаячаклар, материалларын да инде ташырга тотындылар.

Менә шундый бик кыен хәлдә калып аптырагач-йөдәгәч, мин союзга, Ибраһим Газый янына бардым. Бердәнбер ярдәм сорарлык җиребез шул союз гына — бигрәк тә

минем өчен... Ибраһим эшенә, килсә, иртә килә торган иде. Мин килгәндә, ул инде бүлмәсендә ялгызы гына нидер язып утыра иде. Кыяфәте бик җитди, мине дә: «Ник вакытсыз йөрисең?»— дигән төслерәк каршы алды. Яза торган кәгазен дә каплабрак куйды. Җитди эшеннән аерылуын күргәч, мин дә сүземне кыска тоттым.

— Гафу ит, Ибраһим! — дидем.— Аптырагач, сиңа килдем... Әллә кайчан билгеләгән квартирага һаман да ордер алалмыйча йөрим. Әүземне көн дә өйдән куалар.

— Кем бирергә тиеш?

— Горсовет инде...

Шунда ук телефон трубкасын алды, номерын җыйды, кем беләндер коры гына исәнләште һәм туп-туры аңа болай диде:

— Күктә бит фәрештәләр генә торалар, ә без — җирдә йөрүчеләр — барыбыз да гонаһлы бәндәләр, хөрмәтле Фалән Фәләнович!.. Ни өчен язучы Еникеевны аңа билгеләнгән квартирага ордер бирмичә интектерәләр? Кайчан бетәр бу волокита?!.

«Ай-һай!» — дип эчемнән пошынып куйдым, аның бу кадәр туры бәрүен ишеткәч... Фәрештәләр белән гөнаһлы бәндәләрне искә төшерүе дә, мөгаен, минем хакта нидер аңлатырга теләве булгандыр... Гомумән, Ибраһим Газыйның, ачуы килгәндә, берәүдән дә курыкмыйча ярып әйтә торган гадәте бар иде. Хәтта әнә үзеннән югары утыручыларга да!..

Шулай сөйләшкәннән соң, Ибраһим шап иттереп телефон трубкасын куйды.

— Миңа яңадан шалтыратырга тиешләр,— диде ул, күзлеген киеп.— Син, Янкәй, пока чыгып тор, минем менә бик ашыгыч эшем бар, хәбәр алгач, үзем чыгып әйтермен.

— Булырмы соң ул хәбәр?

— Булырга тиеш. Ишеткәнсеңдер, мин горкомның беренче секретаре белән сөйләштем. Ә ул хәзер үк горсовет белән сөйләшергә булды. Пока шул... Көт, яме!

Мин ничектер кыенсынып кына чыктым да коридорда арлы-бирле йөрергә тотындым. Язучының язучыга чыгып торырга кушуын ишетүе бик үк күңелледән түгел... Хәер, Ибраһим Миңгазыев иптәш безнең председатель дә бит әле: үпкәләп тору бу очракта урынсыз да булыр. Ашыгыч эшем бар ди бит... Ашыгыч эшләр, гадәттә, обкомнан килә шикелле, яки Мәскәүнең үзеннән... Эшнең бик җитдие булса кирәк. Ахунга да тапшырмаган, иртүк үзе килеп утырган. Хәтта яза торган нәрсәсен миннән дә яшерергә тырышты. Гаҗәп әле бу!..

Шулай уйланып, коридорны буйлап йөргәндә, Ибраһим да бүлмәсеннән чыкты, үзе янıма килде.

— Сөйләштем, ордерны бирерләр, алырсың,— диде ул миңа һәм, кулларын артка куеп, зур тоташ тәрәзәдән урамга карап тора башлады. Аңарда бераз йончыганлык сизелә иде. Мин, рәхмәтемне әйтеп, китмәкче булдым.

— Тукта, китмә,— диде ул, һаман тәрәзәдән урамга карап торган килеш. Аннары шактый көттереп, әкрен генә сорады: —Чехословакиядәге хәлләрне ишеткәнсеңдер?

Мин икеләнебрәк калдым: нинди хәлне сорый икән?.. Чехословакиядә яздан бирле инде төрле җитәкчеләр арасында ниндидер көраш-тартыш барганлыгын газеталардан укып белә идек. Дубчек дигән берәүнең җитәкчелекне кулына алуын да ишеткән идек, ләкин безнең газеталар аны мактап түгел, яманлап язганнар иде. Ибраһим шуны сорыймы, мәгәр бу бит инде иске хәбәр. Тагын нәрсә бар икән?

— Юк, ишеткәнем, юк,— дидем мин ахырда.

— Радиодан тыңламадыңмыни?

— Бүген иртәгесен тыңламыйча калдым.

— Җәл, бик мөһим белдерүне ычкындыргансың. Безнең танклар Прагага кергәннәр...

— Ягъни?

— Ягъни, безнең хөкүмәт Чехословакиягә гаскәр кертүне кирәк тапкан...

Ибраһим соңгы сүзләрен бер дә күпертмичә гади генә итеп әйтте. Минем дә артык исем китмәде — гүя көтелгән бер нәрсә турында сүз бара иде.

— Әнә шулайрак эшләр,— диде Ибраһим, көрсенгәндәй.— Без хөкүмәтнең бу чарасын хупларга тиешбездер инде, шулай түгелме?

Мин дәшмәдем — нинди «хуплау» турында сүз булырга мөмкин?!.

Ибраһим, ниһаять, миңа таба борылды.

— Кыскасы, болай, Еники,— диде ул,— язучылар исеменнән мин отклик яза идем, бетергәч, син дә кул куярсың шуңа?

— Һай, Ибраһим! — дидем мин, бик борчылып,— хәзер миндә ул кайгымыни?.. Үземнеке-үземә җиткән, беләсең бит инде!

— Сүз бит Чехословакияне саклап калу турында бара!..

— Аңлыйм, Ибраһим... Ләкин минем бит бу хакта радиодан да ишеткәнем, газиттән дә әле укыганым юк... Белер-белмәс көе тот та нәрсәгәдер кул куй, имеш! Ярыймыни алай?

— Нигә, миңа ышанмыйсыңмыни? — диде Ибраһим, иягеп учлап.

Билгеле, сүз ышану-ышанмау турында бармый иде. Совет армиясенең чехларга бәреп керүенә берсүзсез ышанырга була — безнең сәясәт өчен бик нормаль күренеш ул. Юк, минем әнә шул сәясәтне хуплаган кәгазьгә чынлыкта кул куясым килми иде. Тик менә шуны Ибраһимга туп-туры әйтергә кыюлыгым җитми. Гомумән, Ибраһим белән сөйләшкәндә артык чишелеп китүдән дә тыелырга мәҗбүр идем мин...

Ибраһим Газый ортодоксаль коммунист иде. Совет властена тел-теш тидерәнне бер дә яратмый иде, чөнки үзенең яшәвен, кеше булуын бары тик шул власть аркасында гына дип белә иде. Әмма ул аягүрә катып калган догматик та түгел, тормышның кимчелекләрен дә күрә белә, җитәкче органнарның начар эшләрен тәнкыйть итүдән дә куркып тормый, бюрократлашып беткән кайбер аңгыра-мокыт түрәләрне ул еш кына «чуен башлар» дип атый торган иде.

Инде безнең мөнәсәбәтләргә килгәндә, нәрсә диярgə мөмкин? Безнең танышлык бары сугыштан соң гына башланды. Бер эш кешеләре буларак, без союзда үткәрелгән җыелышларда, төрле утырышларда очрашабыз, бергә кайткан, бергә сөйләшеп утырган чакларыбыз да була иде. Бервакытны, җәйнең матур бер көнендә, Ибраһим белән Афзал абзый һич көтмәгәндә минем шәһәр читендәге өемә дә килеп чыкканнар иде. Бу «визит» мине гаҗәпләндерде дә һәм куандырды да... Бакчада күпмедер сөйләшеп утырганнан соң өчәүләшеп йөрергә чыгып киттек. Казан суы буйларында озак кына йөреп, шактый арып-талып Ял паркына да күтәрелдек. Ә анда цистернадан сыра сатып яталар. Ничек инде салкын сыраны эчмичә үтеп китәргә мөмкин ди?! Мин юлдашларымны кыстап карадым, ләкин алар цистернага якын да килмәделәр. Минем сыра күбеген өрә-өрә тәмләп эчкәнне бер читтә сабыр гына көтеп тордылар. Эчү мәсьәләсендә бик тәүфыйклы иде алар, мәрхүмнәр!

Кыскасы, Ибраһимның миңа мөнәсәбәте начар түгел иде, дип әйтә алам. Дөрес, ул минем карашларның рәсми идеологиягә туры килеп бетмәгәнен белә иде, мәгәр аңа карап мине чит-ят итмәде. Язучы дип таныды, әсәрләремә карата каты сүз әйткәне булмады. Ул әле мине бер хикәямнең исеме белән «Ялгыз каз!» дип тә атый иде. (Очрашканда еш кына: «Нихәл, син, ялгыз каз!»— дип уза торган иде.)

Безнең ара-тирә кайбер актуаль мәсьәләләр буенча ачык кына сөйләшкән чакларыбыз да булды. Аңа каршы сөйләсәм дә, ул чыраен сытмый, усалланмый иде. Гадәтенчә, шаблон сүзләр кулланмыйча гына, беркадәр юмор да кыстырып, үзенекен аңлатырга тырыша һәм ахырдан гына: «Сиңа, парин, Марксны күбрәк укырга кирәк»,— дип өстәп куя иде. Үзе ул язучылар арасында марксизм-ленинизмны бөтенесеннән дә яхшырак белүче булып санала иде.

Гәрчә без бер-беребездән шактый ерак торсак та, мин аңардан шикләнми идем, гадел кеше булуына ышана идем. Ләкин аның ортодоксаль карашларын белгәнгә күрә, мин, әйткәнемчә, сакланыбрак сөйләшергә дә мәҗбүр идем. Ачуын китерсәң, Ибраһим Газый иптәшнең хәтер саклап тормыйча бик туры бәреп әйтә торган гадәтен дә белә идем.

Инде менә Чехословакиягә безнең армияне кертү уңае белән аның ниндидер «хуплау» язып маташуы миңа бер дә ошамады — ошамау гына түгел, күңелдә «нигә кирәк булды әле ул?» дигән авыр сорау да тудырды. Шәт, Ибраһимның үзенә дә ачыктыр инде — күрше дус илгә гаскәр кертү — бу бит аның эчке эшләренә дорфа рәвештә тыгылу, көч белән аны үз ихтыярыңа буйсындыру дигән сүз... Саклап калу, имеш! Кемнән, нәрсәдән?.. Агрессиянең икейөзле бер формасы ич бу!.. Күп күрдек без моның ише хәлләрне!.. Сугыш вакытында безнең гаскәр азат иткән илләрнең һәркайсында властьны коммунистлар кулына алып бирдек. Җитәкчеләрен дә без куйдык, ярамаганнарын алып ташладык, хәтта суд ясатып, кайберләрен аттырдык та — кыскасы, барысы да безнең боерык буенча эшләнде. Инде без таккан системага халык түзә алмыйча баш күтәрә башласа, гаскәр керттек, танклар белән бастык.

Инде менә Чехословакия. Шул ук ялган сылтау, шул ук танклар өере, шулай ук, карта алыштырган шикелле, җитәкчеләрне алыштыру... Һәм мин шушы вөҗданым кабул итмәгән эшне «хупларга» тиешмен имеш! Дөресен генә әйткәндә, мин Ибраһимның да үз теләге белән «хуплавына» ышанып бетми идем. Мөгаен, аңа бу эшне «югарыдан» кушканнардыр... Шуңа күрә ул, иреннәрен кысып булса да, ашыгыч мөһим боерыкны үтәргә мәҗбүрдер... Мәгәр мин болай фараз кылуымны аның үзенә, билгеле, әйтеп тормадым. Бу очракта бит ул Союз председателе буларак хәрәкәт итә, һәм аның карашы рәсми позиция белән, һичшиксез, туры килергә тиештер инде... Ләкин минем үземә нишләргә соң? Ул әнә минем җавапны көтә: хуплау кәгазенә кул куярга мин ризамы, түгелме? Әлбәттә, риза түгел, әлбәттә, теләмим!.. Тик ничек итеп моны аңа әйтергә? Әмма сизәм, менә хәзер үк туп-туры әйтеп бирергә кыюлыгым җитмәячәк. Бердән, әлеге каһәр суккан сагаю тота, икенчедән, Ибраһимның кәефен дә бозасым килми. Шуңар күрә, үземә калса, дусларча гына әйтеп котыласым килде.

— Ибраһим, кичер, мин хәзер көтеп тора алмыйм. Син, давай, ул нәрсәңне язып бетер, чакырырсың, килербез, сөйләшербез... Анда тагын күз күрер...

— Синең тизрәк ычкынасың килә инде,— диде Ибраһим, мәгънәле генә көлемсерәп.— Бар алайса, бар!

— Мин синнән качмыйм, Ибраһим! — дидем мин аңа, ихлас күңелдән.

Шуның белән сүз бетте, Ибраһим үзенә кереп китте, мин дә үз юлым белән китеп бардым. Бу урында бик мөһим бер моментны әйтеп үтәсем килә: безнең иң соңгы сүз алышуыбызның һәркайсыбыз өчен яшерен мәгънәсе булган икән. Мин, мәсәлән, Ибраһимның, «ычкынасың килә инде» дигән сүзен «кул куюдан качарга телисең» дип аңладым. Ә минем җавапны аның ничек кабул иткәнен миңа соңрак аңларга туры килде. Тагын өстәп шуны да әйтим: мин, билгеле, яңадан союз тирәсенә барып йөрмәдем, һәм, чакырсалар да, бармаска, дип күңелемне беркетеп куйдым.

Бер-ике көн үтте микән, «Татарстан» газетасында Ибраһим Газый тарафыннан язылган һәм бер төркем язучылар кул куйган әлеге «хуплау» басылып та чыкты. Тексты зур түгел иде, анысын өстән-өстән генә укып, мин тизрәк кул куючыларга күз төшердем: башта Ибраһим Газый үзе, аннары Афзал Шамов, Гомәр Бәшир, тагын берничә мөхтәрәм язучының исеме һәм шулар арасында... минем исем дә! (Кызганычка каршы, ул газета миндә сакланмады, шуңа күрә исемнәрнең хәтердә калганнарын искә төшерү белән генә чикләнәм.)

Үз исемемне күргәч, минем кечкенә күзләрем атылып чыга язды. Бу ни хәл?!. Кайдан, нигә, ни өчен монда минем исем? Күрмәгән, укымаган, кул куймаган белдерүдә?!. Аңлый алмыйм, күзләремә ышанасым килми, әллә нәрсә бу!!..

...Ярый, «хуплау»ның үзен ул югарыдан кушу буенча язсын ди, әмма аның астына кемнәрнең исемнәрен куеп чыгаруны да кушып тормаганнардыр инде... һичшиксез, бу — Ибраһимның үз эше! Димәк ул, коммунист иптәш, Чехословакияне танклар белән таптатуны үзе генә хуплау түгел, минем исемнән дә хуплата! Мин аның өчен үз акылым, үз вөҗданым белән яшәүче шәхес түгел, минем белән теләсәң ни эшләсәң дә һәм миннән теләсәң ни эшләтсәң дә, ярый икән ләбаса! Җанны иң нык сыкраткан ны һәм тетрәткәне әнә шул хакыйкатьне ачу булды. Гаҗәеп бер ачыклык белән мин үземнең, партия диктатурасы шартларында, гади бер чүпрәк уенчыкка әйләнүемне аңлагандай булдым.

Әйе, әнә шул рәвешчә, мин үз ихтыярымнан тыш мөртәтлеккә дучар ителдем, үз теләгемнән башка тарих битендә канлы бер җинаятьне хуплаучы булып калдым. Әйтәсе дә түгел, моның газабы минем өчен бик авыр иде һәм озакка сузылды.

Бераз айнып төшкәч, минем кемгә дә булса зарымны сөйлисем килә башлады. Тәвәккәлләп Гомәр абзыйга шалтыраттым. Ленин бакчасында очрашырга булдык.

Укучыда сорау туарга мөмкин: ни өчен Гомәр Бәширгә, ни өчен Ибраһим Газыйның үзенә түгел? Әйе, беренче минутларда ук миндә андый тыелгысыз теләк туган иде. Ләкин эш узгач, ярсып барып, талашып кайтудан ни мәгънә?! Ә минем бу акылга сыймас күңелсез вакыйганың чын сәбәпләрен ныграк аңлыйсым килә. Гомәр абзый — Ибраһимга кадәр, үзе дә безнең оешманы җитәкләгән кеше, әдәбиятыбызның танылган авторитеты, югарыдагы җитәкчеләр белән дә даими бәйләнештә... Аннары иң мөһиме, мин аңа ышанам, курыкмыйча барын да сөйли алам. Ә хәзер миңа бары тик шундый кеше кирәк.

Икенче көнне очрашкач һәм бакчаның аулаграк бер җиренә барып утыргач, мин аңа булып узган вакыйганы бик ачынып сөйләп бирдем. Әмма Гомәр абзыйның моңа һич тә исе китмәде.

— Мин дә укымадым, мин дә кул куймадым,— диде ул, мине шаккатырып.

— Ә башкалар?

— Белмим... Юктыр, булмагандыр... Ибраһим үзе генә кирәк кешеләрнең исемен куеп чыккандыр... Ашыгыч эш, гадәттә, шулай эшләнә инде ул... Әнә, некролог язганда да имза җыеп йөрмиләр ич!

Соңгы мисалы бик кызыклы, әмма урынлымы ул, ничек итеп мин мондый аңлату белән килешә алыйм ди?!

— Гомәр абзый, бу бит үтә җитди вакыйга! — дидем мин, кызып китмәскә тырышып.— Бер дәүләт икенче дәүләтнең җиренә гаскәр кертә, аны көч белән үзенә буйсындыра, һәм шушы... ямьсез эшне, ризалык сорамыйча гына, безнең исемнән хуплыйлар!.. Йә, әйтегез, килешеп буламы мондый башбаштаклык белән?..

— Анысы шулай инде,— диде Гомәр абзый, киң, шәрә маңгаен ышкыштырып.— Вакыйгасы да бик күңелсез, «хуплау» да бик үк дөрес эшләнмәгән... Ибраһим телефон белән генә сорап чыкса да яхшы буласы икән дә бит, күрәсең, югарыдан бик ашыктырганнардыр инде... Ләкин син, Әмирхан, артык борчылма. Кем андый «хуплауларны» укып тора?.. Бездә шулай бит инде ул, зуррак вакыйга булса, югарыдан тоталар да тизрәк йә «хуплау», йә «яманлау» оештырырга кушалар... Вакыйгасына карап... Мәгәр үтә дә китә ул, кеше аңа игътибар да итеп тормый... Оныт син аны!..

Әнә шулай юатты Гомәр абзый мине... Ул инде тәҗрибәле кеше, ихтимал, аның

үзенә дә оештырырга туры килгәндер андый белдерүләрне. Гадәти эш, диде ич!.. Мәгәр бу хакыйкатьне белүдән җанга тынычлык киләмени, юк, киресенчә, ачуны һәм газапны көчәйтә генә ул!.. Ни өчен соң мин Ибраһимның үзенә шул чакта ук бернинди кәгазьгә кул куймаячакмын, дип туп-туры әйтмәдем?..

Бу хәлләрне мин шул чакта ук бер блокнотыма язып та куйган идем. Ихтимал, кирәкләчәктә бер кирәк булыр дип... Шуның белән бергә Ибраһим Газыйның үзенә дә нияләр кичергәнемне әйтәсем килә иде. Белсен, белмичә калмасын, дия идем мин һаман да үземә. Ләкин бик озак җай таба алмыйча йөрдем. Председатель союзга сирәк килә, килсә дә һәрвакыт янында кешеләр була. Ахырда көннәрдән бер көнне Ибраһимның үзен генә бүлмәсендә туры китердем. Исәнләшеп, әзрәк хәл-әхвәл сорашкач, мин аңа ипләп кенә әйттем:

— Быелгы җәй минем өчен шактый авыр, мәшәкатьле булып чыкты. Ләкин алары үтәр, онытылыр... Тик күңелдәге авыр бер төер генә онытылмас, ахрысы... Шуны сиңа әйтмичә кала алмыйм: хәтерлисеңме, Чехословакиягә армия кертү уңае белән син үзең язган хуплау кәгазенә, минем ризалыгымнан башка, исемемне куеп чыгардың?..

Әйтеп бетерергә өлгермәдем, Ибраһимның йөзе кинәт үзгәрде, бик җитдиләнде, күзләре дә күзлеге аша зурая төшкәндәй булды. Менә хәзер миңа ташлана инде дип көткән идем, ләкин ни гаҗәп, ул кабынып китмәде, ничектер үзен тыеп калды. Иягеи учлап, шактый гына дәшми торганнан соң, миңа туры карап әйтте:

— Нигә алайса бирәр газитәгә, минем ул кәгазьгә кул куйганым юк дип, язып чыкмадың? Кирәк иде, төер саклап йөрткәнче...

Инде мин аптырап калдым аның бу җавабына: чынлап әйтәме, әллә үртәпме?.. Әлбәттә, үртәп, чөнки андый белдерүне бер газитәнең дә басмаячагын белеп тора ич ул! Шулай да ул, акыллы баш, бик нечкә җирдән тотты. Җавапсыз калмас өчен генә мин:

— Чынлап та, син әйткәнчә эшләргә кирәк булган икән,— дигән булдым.— Кызганыч, вакытында уйлый белмәгәнмен.

Ибраһим әче генә елмайды:

— Белсәң дә, язарга йөрәгең җитмәс иде.

— Ни өчен?

— Шулай. Синең дә башың ике түгел бит.

«Синең дә»— ничек аңларга моны?.. «Минеке дә ике түгел»,— дип әйтмәкче буламы әллә?.. Әгәр тел төбендә шул икән, димәк, ул да каяндыр, кемдер кушканны теләсә-теләмәсә дә үтәргә мәҗбүр булган.

Ходаем, кемнәр соң без? Һәртөрле явызлыкны аклап тору безнең бурычыбызмыни?! Кайдан бу мөртәтлек, икейөзлелек, ниһаять, куркаклык?

Моның җавабын мин шушы язманың ахырында әйтергә тырышырмын.

* * *

Инде рухи коллык заманы өчен «типик» булган аянычлы вакыйганың өченчесенә күчик. 1967 елны минем «Салават күпере» дигән хикәяләр җыентыгым язучылар союзы тарафыннан Тукай премиясенә тәкъдим ителде. Башта, кагыйдә буларак, мәсьәлә идарә утырышында каралган. Билгеле, мине тәкъдим итү шома гына узмаган. Идарә әгъзаларыннан Хәсән абзый Туфан, Фатих Хөсни, Рафаэль Мостафин яклап чыксалар да, союзыбызның җитәкчесе Мирсәй Әмир шактый нык каршы торган. (Аңа кушылучылар да, әлбәттә, булгандыр дип уйлыйм). Ләкин тавышка куелгач, күпчелек белән шулай да мин үткәнмен. Әйтергә кирәк, җитәкче фикеренә каршы бару, һәр җирдәге шикелле, безнең союзда да бик сирәк була торган хәл иде.

Мин үзем бу вакытта каядыр читтә идем, бары кайткач кына идарә утырышында ниләр булганын ишетеп белдем.

...Күпмедер вакыттан соң газеталарда Тукай премиясенә тәкъдим ителүчеләрнең исемнәре басылып чыкты. Алар өч кандидат иде: рәссам Бакый ага Урманче, язучылардан мин һәм Татар академия театрында куелган «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә катнашучылардан бер төркем. Аларның тәкъдим ителгәнен күргәч тә премиянең миңа тимәячәген аңладым. Хәтта мине үткәрмәс өчен аларны, югарыдан кушу буенча, тәкъдим иткәннәрдер әле, дигән гөнаһлы уй да күңелемә килгән иде.

Инде спектакльнең үзе һәм анда катнашучылар турында берничә сүз: «Гүзәлем Әсәл»— Чыңгыз Айтматовның «Тополек мой в красной косынке» исемле повесте буенча эшләнгән инсценировка. Тәрҗемәсен миннән эшләткәннәр иде... Әсәрне сәхнәгә Ташкенттан махсус чакырылган үзбәк режиссеры Хаджиев куйды. Декорацияләрен Качалов исемендәге театрның баш рәссамы Гельмстан ясаттылар, баш рольләрне Наилә Гәрәева бе-

лән Ринат Таҗетдинов башкара... Күрәсез, тәкъдим ителүчеләр барысы да бик лаек кешеләр.

Шуңа күрә дә мин, конкурентның бик көчле булуы белән бергә, Мирсәй Әмирнең дә каршы икәнлеген белеп, башта ук премиянең миңа булмаячагына күңелемне беркетеп куйган идем. Аннары обкомда утыручыларның да миңа карашлары шәп түгеллеген күптән инде ничектер тирем белән сизәм. Ә Тукай премиясен кемгә бирүне асылда шунда хәл итәләр — бу кадәресе дә бераүгә дә сер түгел... Шул сәбәпле нидер өмет итеп, борчылып йөрүнең һич тә кирәге юк иде.

Гомумән, мин беркайчан да дан-шөһрәт артыннан кумадым. Һәртөрле исем-бүләкләргә нәфсемне дә сузмадым. «Үз эшеңне бел дә тыныч кына йөр!»— шулай юата торган идем мин үземне.

Әмма бу юлы минем тынычлыгым уйламаганда бозылып куйды. Апрель аеның епшек бер кичендә, без, күп кенә язучылар, Газый Кашшафка 60 яшь тулу уңае белән «Татар ашлары йортында» үткәрелгән мәҗлестә булдык. Гадәттәгечә, мул ашау-эчү, ялкынлы котлау-мактаулар, дәртле җыр-биюләр үз чираты белән бара торды. Беләсез инде, Газый тыйнак кеше, мәҗлесе дә аның, үзенә охшап, ыгы-зыгысыз, күңелле-җылы гына узды. Бик соңга калмыйча гына барыбыз да бер үк вакытта диярлек кузгалдык та... Профсоюз урамы буйлап, төркем-төркем кайтып барган чакта, без Мирсәй Әмир белән ничектер бергә туры килдек. Берәүләр алга китте, берәүләр арткарак калды, ә мин Мирсәйдән аерылып китәргә яхшысынмадым. Бераздан ул үзе сүз башлады.

— Әмирхан,— диде ашыкмыйча салмак кына,— тиздән Тукай комитетының утырышы булачак. (Пауза)... Мин, уйлана торгач, синең кандидатураны якларга булдым... Ник дисәң, Тукай премиясе ул иң элек үзебезнең оригиналь әсәрләргә бирелергә тиеш. Ә академия театрының спектакле нәрсә ул? — тәрҗемә әсәр, куючысы читтән чакырылган, художнигы да читтән — аларга Тукай премиясен биреп, без нәрсә отабыз?.. (Пауза. Мин аның сүзен ничек тә бүлмәскә тырышам.) Дөрес, башта мин сине тәкъдим итүгә каршы идем, ләкин ахырда, нык кына уйлагач, башкалар фикере белән килештем; хикәяләрең минемчә дә зур бүләкне күтәрерлек... Үтәр дип ышанам...

Мин аны бик игътибар белән тыңладым, сүзен бүлмәдем, сорау да бирмәдем. Мирсәй сүзен җилгә ташлый торган кеше түгел,— шуңадыр бик җиңел ышандым мин аңа... Бары чын күңелдән:

— Рәхмәт, Мирсәй, рәхмәт! — дидем.— Бүләкне бирерләрме-юкмы, анысы мине ул кадәр борчымый, әмма синең карашың үзгәрүе минем өчен кыйммәтрәк!..

Бүтән нәрсә дим? Минем бит бу хакта аның белән сүз башларга һич уйлаганым да юк иде — ул үзе башлады, үзе әйтте. Билгеле, миңа карата уен үзгәртүе аңа бер дә җиңел булмагандыр — үз позициясендә нык торучы икәнен барыбыз да яхшы беләбез. Ә шулай да ənə үзгәрткән. Димәк, аны уйланырга мәҗбүр иткән җитди сәбәпләр булгандыр. Берсен ул үзе үк әйтте: Тукай премиясен оригиналь әсәргә бирергә кирәк, диде. Идарә утырышында күпчелекнең минем файдага тавыш бирүе дә аны нык кына уйландыргандыр, мөгаен. Аннары Тукай премиясенә тәкъдим ителүчеләр турында матбугатта чыгып барган фикерләрнең дә аңа, һичшиксез, йогынтысы булмыйча калмагандыр. Мәсәлән, «Татарстан»да басылган Газый Кашшаф мәкаләсен күрсәтергә була. Газый үзенең шул зур мәкаләсендә премиягә тәкъдим ителгән ике әсәр — минем хикәяләр җыентыгы белән «Гүзәлем Әсәл»— турында фикер йөртеп, ахырында: «Мин Тукай бүләген Әмирхан Еникигә бирү ягында»,— дип ачыктан-ачык язган иде... Башкалар тарафыннан да минем хикәяләргә карата уңай фикерләр әйтелгән иде.

Һәрхалдә, Мирсәй Әмир ənə шуларның барсын да исәпкә алгандыр дип ышанырга була. Төпле кешенең, тискәрелеккә бирелмичә, фикерен үзгәртә алуы үзе генә дә — чын егетлек ул!

Апрельнең епшек кичендә, мәҗлестән кайтышлый көтелмәгән бу кыска сөйләшүнең, әйтәсе дә түгел, минем үземә тәэсире көчле булды; күптән инде сүнгән өмитне ул яңадан терелтеп җибәрде... Ходаем, булмас нәрсәмени ул?! Танылган олы язучы, союз җитәкчесе, премия мәсьәләсе каралганда, мине яклап сүз әйтә икән, моның бит, һичшиксез, хәлиткеч әһәмияте булырга тиештер инде?!. Анда әле башка яклаучылар да булачак — мин моны белә идем. Дөрес, тавыш бирүнең нәтиҗәсе бүтәнчәрәк тә килеп чыгарга мөмкин, әмма, ничек кенә булмасын, минем өмит-ышанычым бик нык үскән иде. Комитет утырышына кадәр калган вакытны мин аз гына борчылу-дулкынлану кичергән халдә, әйбәт күтәренке кәеф белән үткәрдем.

Белмим инде, язмышның бер шуклыгы булдымы — Тукай комитетының карарын мин көне-сәгате белән үк белдем. Ленин урамы буйлап союзга таба китеп барам, ә Кремль ягыннан Рафаэль Мостафин кайтып килә. Матбугат йортына төшә торган урам чатында очраштык. Күрештек. «Каян киләсең?»— дип сорыйм. Рафаэль читкә карабрак: «Совминнан»,— ди.

— Әллә комитет утырышыннан?

— Әйе, шуннан... Яңарак кына бетте...

Сүз ничектер өзелеп калды. Мин утырыш нәтиҗәсен сорарга кыймыйча торам. Ул да әйтергә ашыкмый... Бу инде шунда ук күңелдә авыр шик уятты, ләкин шулай да мин үзем башлап сорадым: йә, нәтиҗә ничегрәк соң?

Рафаэль нигәдер шактый ашыгып җавап бирде:

— Комитет Тукай премиясен Бакый Урманче белән «Гүзәлем Әсәл»гә бирергә булды.

Ала-ай!.. Кай җиремәдер, нәрсәдәр чәнчеп куйды. Мәгәр тыштан мин тыныч идем. Рафаэль минем нәрсә көткәнемне белеп, шулай ук ашыгыбрак, сүзен дәвам итте:

— Сезнең хакта да шактый бәхәс булып алды. Якладык. Хәсән абый да, мин дә, Җәүдәт Фәйзи дә... Яклап язылган хатлар да бар иде — аларның да кайберләрен укыдылар.

Шул мизгелдә үк тел очыма килде, һәм түзмәдем, сорадым:

— Ә Мирсәй?.. Мирсәй ни диде?

— Әгәр Мирсәй абый да якласа, нәтиҗә, конечно, башка булачак иде,— диде Рафаэль.

Якласа?! Аңлап җитә алмыйм, валлаһи!

— Нәрсә әйтте соң ул?

Рафаэль икеләнгән шикелле көттеребрәк җавап бирде:

— Кеше сүзен җиткерүе аллә ничек килешми дә, ну сезгә әйтмичә дә булмый, чөнки аның сүзе барыбызны да бик гаҗәпләндерде... Мирсәй абый болай диде: Әмирхан Еники совет әдәбиятының олы юлыннан читтә торган язучы, хикәяләре әдәби эшләнгән булса да, идея-эчтәлекләре белән безнең заман рухына туры килеп бетми, диде. Җәүдәт Фәйзи шунда ук: ничек инде ул алай, Еникине язучылар союзы тәкъдим итә, союз җитәкчесе каршы чыга, һич аңлый алмыйм мин моны дип, гаҗәпләнүен белдерде. Ә Мирсәй аңа кыска гына, мин башта ук каршы идем, диде. Менә шул!..

Рафаэль әйткәннәр, чәнчеп кенә калмыйча, башыма чукмар белән китереп органдай булды. Минем инде шуннан артыгын сорыйсым да, тыңлыйсым да килмәде. Союзга төшеп тормадым, Рафаэльгә ияреп бераз бардым да Ленин бакчасына борылдым. Барышлый аңардан тагын шуны да ишеттем: комитет утырышында миңа да 5-6 кеше тавыш биргән икән.

Әлбәттә, миңа аулак урын кирәк иде. Ленин бакчасының кардан арынып, яңа кипкән, яшәрә башлаган чагы, эскәмияләре дә былтыргы сары яфраклардан чистарынып бетмәгән — мин шуларның берсенә барып утырдым. Әлбәттә, минем башымда премия кайгысы түгел иде — ул шунда ук онытылды, юкка чыкты. Миңа Мирсәяф Әмир иптәшне аңлау кирәк иде. Аның вәгъдәсен бозуы мине бөтенләй хәйран итте, ток суккандай тетрәтте, хәтта зиһенемне дә бер мәлгә чуалтты. Ничек кенә аңларга соң чал чәчле мөхтәрәм язучының бу гамәлен?! Миндә әле аңа карата ачу да, рәнҗү дә юк иде. Мин тик аны аңлаудан гаҗиз идем. Әмма күпмедер вакыт ни уйларга белмичә, шулай сыкранып утырганнан соң, мин кинәт үзем өчен бер хакыйкатьне ачкандай булдым: әлбәттә, бу — Мирсәйнең үз эше түгел. Вәгъдәсен бозарга аны мәҗбүр иткәннәр. Бу, һичшиксез, шулай!.. Күптән билгеле бит инде: Тукай премиясен кемгә бирү мәсьәләсен башта обкомда хәл итәләр. Мөгаен, бу юлы да шулай эшләгәннәрдер; утырыш алдыннан Мирсәйне, союз җитәкчесен, чакырып алганнардыр да әйткәннәрдер: «Ә. Еники премиягә лаек түгел, син шуны исбат итәргә тиешсең!»— дигәннәрдер. Ә аның сүзе комитетта хәлиткеч роль уйнаячагын боерык бирүчеләр, әлбәттә, белеп торганнар. (Комитет әгъзаларының, председателеннән башка, күпчелеге исә әдәбият һәм сәнгатьтән бик ерак торган кешеләр.)

Башкача мин Мирсәй Әмирнең гамәлен аңлый алмыйм. Яклыйм дигән вәгъдәсен мин аңардан тартып алмадым, үз теләге белән башлап әйтте, шулай булгач, миңа хәзер нәрсә генә уйларга кала?!

...Ыграк уйлаган саен, Мирсәйнең үзенә карата рәнҗүем дә арта баргандай булды. Ничек инде, ничек инде ул, арабызда иң төпле, иң акыллы кешебез, үз карашында һәрвакытта нык торучы Мирсәй Әмир, чал башы белән вәгъдә бозу кебек түбәнлеккә барды икән?! Аңа бит: «Вәгъдә — иман!» дип кистереп бер әйтү дә җиткән булыр иде. Моның өчен беркем дә олы яшьтәге мөхтәрәм язучыга кагылырга җөрьәт итә алмас иде.

Әйе, әйтәсе дә юк, каләмдәшем Мирсәй Әмирнең ул гамәле мине тәмам вәйран итте, миңгерәүләтте, тирән яра салды бәгырьгә!.. Һәм мин шактый вакыт рухи авыруга сабышып йөрдем. Союз тирәсенә барып йөрүдән туктадым — бигрәк тә Мирсәй белән күзгә-күз очрашудан кача идем. Һәм сизә идем кебек: Мирсәйнең дә очрашырга бер дә теләмәвен... Ул шулайрак булды да — шактый озакка сузылды бу ике яклап очрашудан качу... Вәләкин барыбер очрашырга туры килде — бер үк юллардан йөрибез ич!.. Көннәрнең берендә мин матбугат йортының баскычыннан кызу гына төшеп барам, ә түбәннән Мирсәй авыр гына менеп килә. Секундның бер мизгелендә «Туктаргамы?» дип уйлап алдым, ләкин Мирсәй үзе, мине күргәч, туктады һәм якынаюыма үзе үк сүз дә башлады.

— Әмирхан,— диде әкрен генә.— Синең миңа үпкәң зурдыр инде?

Җавап көткәндәй, аз гына тукталды, ә мин җилкәмне генә җыергандай иттем.

— Аңлыйм,— диде ул, башын кагып.— Ләкин син дә белергә тиешсең эшнең миннән генә тормаганын...

— Беләм! — дидем мин дә әкрен генә һәм шунда ук түбән төшеп тә киттем. Бәлки, болай ук ашыгырга кирәкмәс тә иде, әмма ләкин бу очрашуның, бу кыска гына сүз алышуның Мирсәй өчен дә, минем өчен дә никадәр авыр икәнлеген тоймыйча мөмкин түгел иде. Мәгәр шушы ике авыз сүз дә безнең арага күпмедер ачыклык керткәндәй булды...

Вакыт — иң көчле дәва, дип юкка гына әйтмәгәннәр... Менә җәйләр үтеп, көзләр дә җитте. Союзда эшләр дә җанлана төште, төрле җыелышлар да ешрак була башлады. Билгеле, ул җыелышларда без икебез дә булабыз. Мирсәй күбрәк президиумда, мин — залда. Инде кара-каршы туры килсәк, тыйнак кына исәнләшеп узабыз.

Баскычта очрашып сүз алышудан башка безнең арада бүтән аңлашу да булганы юк. Нигә кирәк ул — мәсьәлә болай да үтә ачык. Иң яхшысы — барысын да тизрәк оныту...

Әмма ләкин Мирсәй мәрхүмнең җаны шулай да тыныч булмаган икән, нидер аның күңелен һаман да борчып торган. Моның ике дәлиле бар.

Берсе. Союзда җитәкчелек алмашынып, идарәгә Гариф Ахунны председатель итеп куйгач, Мирсәй Әмир мине яңадан Тукай премиясенә тәкъдим итүне кузгатып карамакчы булган. Мәсәлән, «Гөләндәм туташ хатирәсе» чыккач, ул Гарифка әйткән: «Әмирханның бу әсәрен Тукай премиясенә тәкъдим итәргә кирәк иде!»— дигән. Гариф аңа болай дип җавап биргән: «Мирсәй абый, ни өчен әле син үзең эшләгән хатаны миннән төзәттермәкче буласың?»— дигән. Мәгънәсе аңлашылса кирәк... Күрәсез, Мирсәй чынлап та «хатасын» төзәтмәкче булып караган. (Гариф моны миңа үзе сөйләде. Исән-сау кеше, әйткәннәреннән, шат, баш тартмас дип ышанам).

Икенче дәлил — Мирсәй Әмирнең миңа җитмеш яшем тулган көннәрдә язган хаты... Хатның эчтәлеген шәрехләп торудан тыеласым килә. Укучы үзе укып, үзе нәтиҗә ясарга тиеш.


*«Хөрмәтле Әмирхан туган!*

*Без синең белән Казанга бер чорда килгән, татар мәдәнияте йорты бусагасын бергә бер елларда таптый башлаган; син дә, мин дә хөрмәт иткән Такташларны, Кутуй, Туфаннарны, Галимҗаннарны тыңлап үскән кешеләр.*

*Бөтен серләребезне уртаклашырлык якын дуслар була алмадык. Язган әсәрләребезгә карата бер-беребезне хупдаган кебек, «тукмаган» чакларыбыз да булды.*

*Бүген, сиңа җитмеш тулган көндә, кулымны күкрәгемә куеп, чын күңелдән әйтәсем килә: «Дус кеше»ңнән башлап, шушы көнгә кадәр мин синең талантлы художник икәнлегеңне һаман күреп, танып, икърар итеп, тылсымлы каләм көченә сокланып килам.*

*Аерым әсәрләреңә карата канәгатьсезлек күрсәтүләрем булса да, үземчә хәсни нияттән чыгып (хәзер инде ялгышкан чагым булмагандыр дип тә әйтә алмыйм), сиңа һәм әдәбиятыбызга карата яхшылык теләүдән генә булды.*



*Һәр әсәреңне мин дә, Фәүзия дә, кызыксынып яратып укыйбыз. Зур юбилееҗ белән, җиңү бәйрәмеңә сокланырлык матур уңышлар алып килүең белән чын күңелдән котлыйбыз!*

*Исәнлек-саулык, сүнмәс иҗат дәрте, гаилә бәхете теләп, Әмирханча язылган яңа әсәрләреңне көтеп калабыз.*

*Мирсәяф, Фәүзия Әмирләр*
*1.03.79 ел. Казан».*

Тик бер фикеремне әйтүдән тыеласым килми: «Саф күңел» әсәрен язган әдипнең үз күңеле, үз намусы турында борчылып яшәве, аның күп кенә еллардан соң миңа юллаган шул хатында ачык чагыла дияр идем.

• • •

Яңадан әлеге «Без кемнәр идек соң?» дигән сорауга кайтырга вакыт. Хәер, баштан кичкәннәрне сөйләгәннән соң, сорауны икенче төрлерәк тә куярга була: безнең гамәлебезне һәр очракта кем, нәрсә билгеләде?

Кыскасы, безнең гомеребез, бала-чагыбыздан алып, вакыйгалар еш алышынып торган мавыктыргыч кызыклы, әмма киеренке-куркыныч заман шартларында узды... Мин әле шул гаять катлаулы заманның рухи дөньябызга ничек тәэсир итүе турында язу белән генә чикләнмәкче булам.

Мәгълүм ки, заманны кулында авызлыклап тотучы, аны үзенә кирәкле якка теләсә ничек боручы бердәнбер көч — большевиклар партиясе иде. Бу партиянең алдау белән көчләүгә нигезләнгән һәр адымын аклаучы бердәнбер тәгълиматы — марксизм-ленинизм иде (Сталин аңлатуында). Менә шул идеология безне һава шикелле чорнап алган иде. Сыйнфый нәфрәт белән сугарылган бу идеология күпләрнең аңына гына түгел, канына үтеп керде. Шәхес иреге һәм фикер хөрлеге дигән төшенчәләрне юкка чыгарды. Алай гына да түгел, какшамас догмага әйләнгән ул идеология һәр нормаль кешедә булырга тиешле вөҗдан, намус, инсаф-шәфкать кебек әхлак кагыйдәләрен басып китте, тәмам бетерә язды. Әгәр дә кеше, аеруча коммунист кеше, берәр җитди мәсьәлә алдына килеп басса, ул үзендәге кешелек сыйфатларын буып булса да, партия идеологиясе таләбенә буйсынырга мәҗбүр иде. Әнә шулай кешене үз ихтыярыннан тыш мескен кол итү яки алдап-көчләп ерткычка әйләндерү коточкыч репрессия елларында бөтен караңгы тирәнлеге белән ачылды. Шундый вакытлар булды ки, халык әллә сарык көтүе, әллә бүреләр өере — аерып та булмый башлады.

Без әнә шуларның барысын да күреп уздырдык. Ә бик күпләргә партия тудырган тоталитар системаның бөтен кансыз ерткычлыгын үз җилкәсендә дә татырга туры килде. Шулай булгач, Мирсәй Әмирне обкомга чакырып, аның кулына су салырга да ярамаган кемдер берәү вәгъдәсен бозарга мәҗбүр иткән икән, моңа гаҗәпләнеп буламы соң?! Дөрес, мин моның белән Мирсәй тиз бирелүчән йомшак кеше иде дип әйтергә һич тә җыенмыйм. Киресенчә, нык кеше, моны ул 1937 елны төрмәдә утырган чагында да күрсәтә алган. Әмма бөтен хикмәт шунда ки, Мирсәй Әмир әлеге марксизм-ленинизм идеясенең хаклыгына тулысынча ышанган, шул идеяне байрак итеп күтәргән партиягә беткәнче бирелгән кеше иде. Шуңар күрә дә бит ул, мәрхүм, 37 елны Сталин палачлары аның башына тимер кыршау кидерсәләр дә, гомеренең ахырына кадәр шул партиягә барыбер тугрылыклы булып калды.

Бездәге бөтен аерма да әнә шунда иде. Мин — фиркасыз, партия диктаты миңа турыдан-туры кагылмый. Мин күпмедер дәрәҗәдә хөр кеше, үземчә фикер йөртә алам. Бер генә мисал әйтик, Мирсәй өчен (шулай ук Афзал абзый белән Ибраһим өчен дә) бездәге «социализм»— теләп, көрәшеп алынган чын, табигый тормыш иде. Мин исә адәм сөякләре өстендә төзелгән социализмның чын, табигый булуына үземне ышандыра алмый идем, ничектер аның ялган-ясалма бер җәмгыять булуын гүя күңелем белән тоеп яши идем. Бу зур, җитми аерма... Әмма шундый аермага карамастан, без барыбыз да шул ясалма җәмгыять шартларында, шул җәмгыятьне тудырган бердәнбер партиянең чикләнмәгән хакимлеге астында яшәдек. Безнең бөтен уй-фикеребезне, бөтен эш-гамәлебезне шул партия билгеләде, юнәлдерде, гел үзенә буйсындырып килде. Шуңар күрә дә мин инсаният таләпләренә хилаф бөтен гөнаһларыбызны Ленин-Сталин партиясенә кайтарам, аның өстенә салам. Тарих алдында җавабын да ул тотсын!..

...Сүзем бетте кебек... Югарыда сөйләнгән үкенечле эшләребез өчен замандашларымның берсенә дә минем дәгъвам яки үпкәм юк. Мәрхүмнәрнең авыр туфраклары җиңел булсын! Без барыбыз да — ярлыкауга мохтаҗ бәндәләр...

*1990 ел, октябрь.*

**Рәшит Ягъфәров**

# ХӘЛЛӘРЕҢ НИЧЕК, МӘКТӘП?

Халыкны юк итәргә, үзаңын бетерергә һәм милләт буларак таркатырга теләсәң, аның тәрбия системасына — мәктәбенә ябыш, мәктәбен бу. Шуны эшләдеңме, милләт үлә, бетә, таркала. Безнең халык — империя итеге астында интегүне күп татыган халык. Фаҗигане күп күргән. Әмма шунысы таң калдыра: нинди генә фаҗига кичермәсен, халык яраларын төзәтеп, яңадан аягына баса алган. Бу берничә тапкыр кабатланган. Моның сәбәбе нәрсә? Минем уемча, төп сәбәп шул: халык, нинди генә афәткә дучар булса да, тәрбия, мәгариф эшен үз кулыннан ычкындырмаган. Халкыбыз шулай Октябрь революциясенә, милли мәгариф системасын үз кулында тоткан хәлдә килеп керде һәм ул, татарларга дәүләтчелеге кайтарылган елларда да, милли интеллигенция кулында булды. Әмма егерменче еллар ахырында Сталинның йодрык политикасы милләт кулыннан халык мәгарифен акрынлап ала башлады һәм аны милләтләрне бетерү, милли культураларны юк итү юнәлешенә борып җибәрде. Бу сәясәт торган саен көчәя барып, соңгы вакытта шундый дәрәҗәгә җитте ки, безнең милләт балаларының, илебез буенча караганда, җиде проценты гына мәктәптә үз ана телендә укый ала. Ә урта махсус, югары уку йортларында бу процент бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Җыеп әйткәндә, яңарыш чорына без әнә шулай: милли мәктәпне, мәгариф системасын кулдан ычкындырган хәлдә килеп кердек. Безнең кулда дилбегә түгел, менә өзеләм, менә өзеләм дип торган җепләр генә калган.

Иң әүвәл шуны әйтеп куйыйк: мәгариф системасы бер-беренә тыгыз бәйләнгән буыннардан тора. Гаилә — балалар бакчасы — мәктәп — югары мәктәп — белем күтәрү системасы. Болар бер-берсеннән аерылгысыз. Әгәр дә бу системада нинди дә булса үзгәреш ясарга телибез икән, моны бер буында гына эшләү мөмкин түгел. Әйтик, безнең хәзерге төп бурычыбыз — укыту һәм тәрбияне туган телдә, милли гадәтләргә таянып алып барыла торган мәктәп системасын тудыру. Әмма бу теләкне урта мәктәп звеносында гамәлгә ашырып булмый. Бу идея гаилә тәрбиясеннән алып югары уку йортына кадәрге бөтен буыннарда хәл ителергә тиешле. Хәзер без милли мәктәптә белем алу системасының бөтен буыннарында да ана телендә укытуны, тәрбияләүне җайга салырга бурычлыбыз. Бу нәрсәне үзебезнең республика территориясендә генә түгел, ә Россиянең утызлап республика һәм өлкәләрендә, союздаш республикалар, авыл һәм шәһәрләрендә тормышка ашырырга кирәк. Авыр йөк, авыр миссия! Кыенлыгы әүвәл шунда ки: мәгариф системасының бөтен буыннарыннан да табигый милли җирлек, тулысынча диярлек, кысрыклап чыгарылган. Аны кабат яңартырга кирәк.

Мәгариф системасының икенче мөһим буыны — балалар бакчалары. Милли тәрбия системасында без бу буынга, гомумән, игътибар аз биреп килдек. Егерменче елларда аның махсус программалары булдырылып, хрестоматияләр чыгарылып килсә, соңга таба бу эшләр бөтенләй игътибардан читтә калды. 1985 нче елдан башлап, шөкер, бу буынга да беркадәр игътибар күренә башлады.

Белгәнебезчә, Татарстан авылларындагы 750 бакча татар телендә эшли. Ә рус бакчаларының саны 1692. Димәк, милли татар бакчалары рус бакчаларына караганда ике мәртәбә азрак. Республика шәһәрләрендә милли балалар бакчалары, Әгерҗе шәһәрен искә алмаганда, бөтенләй юк. Чаллы, Азнакай, Әлмәт, Лениногорск, Арча кебек җирләрдә милли балалар бакчалары булмавы — безнең өчен оят. Хәзер халкыбызның күпчелек өлеше шәһәрләрдә яши. Димәк ки, аның язмышы да нигездә шәһәрләрдә хәл ителә.

Күп еллар буена шуны күзәтеп килдек: шәһәр гаиләсе шартларында азмы-күпме ана телендә сөйләшә башлаган балалар, бакчаларда тулысынча рус теле мохитенә эләгеп, үз телен онытуга дучар ителде. Яшермичә әйтергә кирәк, мәгариф системасының бу буыны шәһәр шартларында туган телебезнең яшәешен үсенте чагында ук тамырыннан корытып торучы буын-звено булып килде.

Хәзер русча эшләүче балалар бакчаларында ике сәгать ана теле укытуны кертүниндидер дәрәҗәдә алга китеш булды. Әмма бу перспектив юл түгел. Беренчедән, атнасына ике сәгать уздырыла торган дәресләрдә генә балага ана телен өйрәтеп булмый. Бу — үз-үзеңне алдау гына. Икенчедән, рус һәм татар балаларын аермыйча, бергә дәресләр уздыру рус балалары өчен файдалы булса да, татар балаларының бу

вакытта тел өйрәнүе тоткарлана. Төп юл — саф татар бакчалары, татар группалары ачу булырга тиеш. Чөнки безнең төп максат — ана телендә аз-маз сукалаучылар үстерү генә түгел, ә шул телне баетучы, шул телдә иҗат итүче, тормыш алып баручы буын тәрбияләү.

Шунысын да әйтик, балаларны милли рухта тәрбияләү Татарстанда гына чикләнми. Республикабыздан читтәге төбәкләрдә дә татар баласы тәрбияләнә торган бакчалар бар. Аларның санын төгәл әйтү кыен. Безнең исәпләүчә, РСФСРда гына да, кимендә, мондый бакчалар саны 2500 чамасы булырга тиеш. Алардагы укыту-тәрбия процессын милли нигезгә кую да — безнең изге бурычыбыз.

Милли мәктәпләр турында берничә сүз. Башта статистика. Безнең республикабызда 2253 мәктәп булып, шуның 1192 милли мәктәп санала. Моңа укыту процессын татар телендә алып барылганнары да, рус телендә алып барылып татар теле аерым фән булганы да керә. Бик кызык ситуация: мин үзем шул системада эшләсәм дә, чын үз телебездә укытыла торган милли мәктәпләрнең санын белә алганым юк.

Гомумән алганда, мәгариф системасында эшләүче иптәшләр сан белән качышлы уйнарга ярата. Ә бит барыбызның да күз алдында җәмәгатьчелекнең, ата-аналарның, мәгариф органнарының теләктәшлек итүенә, зур тырышлык куюына карамастан, милли мәктәпләр саны артмый. Моңа халыкта таралган милли нигилизм, манкортлык төп сәбәп. Икенчедән, еш кына республикада яшәүче башка милләт вәкилләренең җирле милләтнең табигый омтылышын дөрес аңламавы, аңа шикләнеп каравы да сәбәпче була. Нәтиҗәдә кирәкмәгән каршылык туа. Казанның Горки поселогында 10 нчы мәктәп базасында татар гимназиясе оештыру вакыйгасын гына алыйк. Карап торышка гади генә хәл ителергә тиешле нәрсә, рус телле ата-аналар белән татар ана-аталары һәм эшне оештырып йөрүче Ш. Мәрҗани һәм Иҗтимагый үзәк вәкилләре арасында кирәксез бәхәсләр китереп чыгарды. Бу эшкә Югары Совет халык депутатлары, Мәгариф министрлыгы вәкилләре катнашып китте. Ике якның да ташламалары нәтиҗәсендә генә килешү ясалды.

Шәһәр җирләрендә татар мәктәпләре, татар бакчалары, милли группалар ачу алга таба да җиңел булмаячак. Монда дәүләтнең рәсми рәвештә җаваплы органнарыннан һәм Татар иҗтимагый үзәгеннән, Ш. Мәрҗани исемендәге мәдәният җәмгыятеннән һәм, әлбәттә, ата-аналар тарафыннан зур оешканлык, политик ныклык, рухи инанганлык таләп ителә. Мәгариф органнары милли мәктәпләр ачуны күрсәтмә бирү, рәсми гамәлләр белән генә башкарып чыга алмый һәм алмаячак.

Хәзерге көндә милли мәктәп проблемаларының иң авыры — мәктәпләрне дәреслекләр һәм укытучы кадрлар белән тәэмин итү. Татарстан китап нәшрияты, СССРдагы барлык мәктәпләр өчен дәреслекләр бастыруны башкара алмый. Куәте җитми. Кайбер регионнардан заказлар вакытында килмәү сәбәпле, тираж кирәгенчә формалашмый. Нәтиҗәдә, аерым регионнар бөтенләй дәреслексез кала. Былтыр Иҗтимагый үзәк халыктан иске дәреслекләрне җыеп алып, төрле регионнарга җибәрүне оештырган иде. Ул хәзер дә дәвам итә. Ләкин бу — батканда саламга ябышу кебек кенә бер гамәл. Республикада махсус «Мәгариф» нәшриятын тизрәк булдыру кирәк.

Милли мәктәпләр өчен укытучы кадрлар хәзерләү хәзер бик зур проблемага әйләнде. Республикабыз әзерләгән кадрлар гына хәзер җитәрлек түгел. Мәйданнары чикләнгәнгә, Казан дәүләт педагогия институты укытучылар әзерләүне арттыра алмый. Татар теле һәм әдәбияты буенча кадрлар әзерләүне чит регионнарда да алып бару өчен чаралар күрелә. РСФСР халык мәгарифе министрлыгының милли мәктәпләр бүлеге кушуы буенча хәзер без милли мәктәпләр институтының Казан филиалы белән берлектә Россия буенча татар укытучыларын әзерләүнең планын хәзерлибез. Безнең уебызча, бу үзәкләр түбәндәгечә булырга тиеш. Урал регионы өчен татар теле һәм әдәбияты белгечләрен Пермь педагогия институтында, Көнчыгыш Себер өчен (Алтай, Красноярск, Новосибирск, Томск, Кемерово өлкәләре) Новосибирск педагогия институтында, Көнбатыш Себер өчен (Омск, Төмән, Курган өлкәләре) Тобол педагогия институтында, Урта Азия, Казахстан һәм Оренбург өлкәләре өчен Оренбург педагогия институтында, Иделнең түбән агымы өчен (Саратов, Пенза, Әстерхан өлкәләре) Әстерхан педагогия институтында, Урта Идел өчен (Куйбышев, Түбән Новгород, Ульян өлкәләре) Куйбышев педагогия институтында әзерләнергә тиеш.

Башлангыч мәктәп укытучылары әзерләү башланды да инде. Куйбышев, Ульян, Свердлов, Төмән, Чиләбе, Пермь өлкәләре педучилищеларында татар бүлекләре булдырылды. Алдагы көндә Идел буе, Себер өлкәләрендә дә педагогия училищеларында да татар бүлекләре ачу мәсьәләсен кую кирәк булачак. Бу катлаулы мәсьәләләрне хәл итүдә Татар иҗтимагый үзәгенең теләктәшлек группалары, филиаллары актив эш алып баралар.

Әйтергә кирәк, бөтен ил буенча караганда, татар мәктәпләрен, татар балалар бакчаларын берләштерүче бернинди дә оешма юк. Республикадан читтәге мәктәп-

ләрдә безнең министрлык баш түгел. Аларда белем күтәрү системасы да билгеле бер тәртиптә алып барылмый. Безнең уебызча, хәзер Казанда татар теле укытучылары һәм балалар тәрбиячеләренең Бөтенсоюз ассоциациясен төзергә вакыт җитте. Өстәп әйтик, бу юнәлештә эш алып барыла. Татар иҗтимагый үзәгенең бер пленумында бу мәсьәлә буенча махсус резолюция дә кабул ителде һәм инициатив группа төзелде. Анда республикабызның мәгариф эшлекләләре — мәгариф министрлыгы, милли мәктәпләр институтының Казан филиалы, Татарстан укытучыларның белемен күтәрү институты хезмәткәрләре кертелде. Ассоциациянең беренче съездын быел җәй уздырырга карар кабул ителде.

Милли мәктәпнең язмышын югары мәктәп билгели. Институтларыбызда татар бүлекләре ача алабыз икән, милли мәктәп үсәчәк; юк икән — милли мәктәп үсми һәм аңа өмет баглау кыен. Бу яктан караганда, республикада әле конкрет эш юк диярлек. Югары уку йортларының кайбер факультетларында (КДУ, КДПИ) һәм башкалар татар телен фән яки факультатив рәвештә укыту, яки укытырга җыенудан гайре гамәл күренми. Мин монда КДУдагы татар филологиясе, АДПИ, КДПИдагы татар бүлекләре турында сөйләп тормыйм. Сүз институтларда һәм илебезнең татар төбәкләрендә эшләүче белгечләрне ана телендә укытып хәзерләү турында бара. Хәзер безгә Татар иҗтимагый үзәге һәм Ш. Мәрҗани җәмгыяте энтузиастлары белән бергә, һәр институт каршында инициатив группалар төзеп, бу эшне контрольгә алырга, югары уку йортларында татар телендә дәресләр алып барырлык галимнәрне туплауда институт җитәкчеләренә конкрет бурычлар йөкләргә һәм ярдәм дә күрсәтергә кирәк.

Безне Казан югары уку йортларына керүчеләр арасында татар яшьләренең саны кимү күренеше бик борчый. Статистик мәгълүматларга караганда, КДУга 1980 нче елда 661 татар яшүсмере кабул ителгән. Бу — барлык беренче курска кергәннәрнең 42,6 процентын тәшкил итә. Ә 1985 нче елда бу күрсәткеч 555 кә (34,7 процент), ә 1988 нче елда 552 гә кала. Шундый ук процесс Казан авиация институтында, Казан ветеринария институтында да күзәтелә. Гомумән, бу бөтен республика күләмендә дә сизелә.

Соңгы ун елны алып карасак, югары уку йортларындагы татар студентларының саны елдан-ел кими. Әйтик, 1980-81 нче елда алар Татарстандагы студентлар санының 45,4 процентын тәшкил итсә, 1989-90 нчы уку елында 42,9 процентка калган. Бу — бик куркыныч нәрсә. Моны республикада татар халкының интеллектуаль потенциалы кимүгә таба киткән дип тә аңлап була. Сәбәп нәрсәдә? Социологлар моны тикшерергә тиешләр. Һәрхәлдә, татар халкының үз илендә, үз җирендә кадере артканлыктан килеп чыккан күренеш түгел бу. Безгә, бу турыда бөтен парламентларга ишетелерлек итеп чаң кагарга вакыт җиткән, димәк.

Безне шул да борчый: республиканың халык мәгарифе министрлыгы территориядәге бөтен уку йортларына җитәкчелек итә алмый. Аңа мондый вәкаләт бирелмәгән. Югары уку йортлары белән бары тик үзәк министрлыклар гына җитәкчелек итә. Безгә хәзер халык мәгарифенең бөтен буыннары белән идарә итә торган мөстәкыйль халык мәгарифе министрлыгы кирәк. Һәм ул илебез күләмендәге милли татар мәктәпләре белән дә эш итәргә, республика югары уку йортларында башка өлкәләрдән килгән татар абитуриентлары өчен мөмкинлекләр тәэмин итә алырга да тиеш. Шулай ук югары уку йортларының җитәкчеләрен билгеләү үзебезнең республика карамагына тапшырылырга тиеш дип уйлыйбыз.

Безне милли мәктәпне торгызу юнәлешендә зур эшләр көтә. Аларны без ныклап башлый да алганыбыз юк әле. Хәзер без «Татар телен мәктәпләрдә ике сәгать кертикме, өч сәгать кертикме?» дигән мәсьәләләр белән баш ватабыз. Шуның ише башка төрле вак-төяк экспериментлар ясап торабыз. Уңга ташланабыз, сулга ташланабыз. Ә алга китеш юк дәрәҗәсендә. Моның сәбәбе — төп юлыбызны билгели торган фәнни нигезләребез — милли мәктәп концепциясе булмау. Безнең мәгариф өлкәсендә эшләүче галимнәребез бу өлкәдә байтак кичектеләр. Якут, Калмык, Коми, Мари кебек республикаларда да мондый концепция эшләнде. Бездә һаман юк. Барыр юлыбызның юнәлеше билгеләнмәгән. Кыйбласын белмәгән кешенең хәле мәгълүм инде.

Мәгариф өлкәсендәге төп бурычларыбыз, милли мәктәпне аякка бастыру республикабызның суверенлыкка ирешүе белән турыдан-туры бәйләнгән. Бу — ачык мәсьәлә. Мәктәп үз дәүләте, үз халкы кулында булганда гына миллилеген саклый ала. Мәктәбе юк икән — милләтнең үзе дә юк. Дилбегәне үз кулыбызга алырга вакыт җитте. Юкса, кеше арбасына утырып ерак китә алмабыз. Кеше арбасына утырсаң, аның җырын җырларсың диләр. Үз атыбызны, үз арбабызны булдырып, үз җырыбызны җырлар вакыт җитте.

## ӘДӘБИ МИРАС

# ТУКАЙНЫҢ «АДАШКАН» ШИГЫРЬЛӘРЕ

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның иҗат мирасы бүген дә тиешле дәрәҗәдә барланмаган хәлдә яши. Минем Тукайның җыентыкларына кермәгән әсәрләрен барлау, эзләү белән махсус шөгыльләнгәнем юк. Шулай да кулга очраклы рәвештә эләккән гарәп хәрефендәге иске китапларны, язмаларны караштырганда күз төшкән шигырьләр арасыннан мәшһүр шагыйребезнең күпләр игътибарыннан читтә калган берничә шигырен күчереп алганмын.

Тукайның Балкан сугышларына мөнәсәбәтен белдереп 1912 елда язган «Тәмсил» дигән шигыре Октябрьдән соңгы чорда бер генә мәртәбә, 1943 нче елда чыгарылган «Сайланма әсәрләре»нең беренче томында гына басылган. Чынлыкта, аны бүгенге укучылар белми. Ибраһим ага Нуруллин аның яңа дүрт һәм биштомлыкларга кертелмәвенә ярсып, күп мәртәбәләр мөнбәрләргә чыгып тавышланса да, шигырь һаман шагыйрь томнарында үз урынын ала алмый әле.

## Тәмсил

I

Әһле Балкан — кечкенә бер эт иде.
Төркия — күктә очар бөркет иде.
Һәр заман, торды бу көнче эт өреп,
Күктә очкан солтанат кошны күреп.
Өрде-өрде, кошны иткән күк харап.
Торды пычрак аузы күкләргә карап.
Хөр вә шат, якты һавада кош оча.
Койрыгын болгап, елый эт: эч поша.
Эт улый мәшъүм[1] вә тырный үз битен,
Бәдбәхет, чәйнәргә хәзер үз итен.
Ошбу күренеш башкаланмый күп заман,
Төркия хәле — гүзәл, этнең — яман.
Очты бөркет киң һавада, хөр вә шат
Кәгъбә — шат милләт вә шат солтан — рәшат[2]
Әлләкем аткан тирән бер ярадан,
Билгеле бер сайъат[3] мәлгунәдән
Кош — төшә җиргә (бу мәгълүм, язмый ук)
Кәрлә этнең — көнче этнең авызынук.

II

Шунда да курка һөҗүмгә эт — сәфил[4]
Читтән әйткәнне көтә: «Өс-с-с!»
Чөнки, шанлы кош чукып алса күзен,
Һичберәү әйтмәс ди ул яклау сүзен.

---

[1] Мәшъүм — усал итеп.
[2] Рәшат — юл күрсәтүче.
[3] Сайъат мәлгунәдән — ләгънәтле әшәке эштән.
[4] Сәфил — хур ителгән.
[5] Инҗил — христиан динендәгеләрнең изге китабы.

«Пиль» — диде, кемдер җибәрде өстереп,
Сугыша маэмай койрыгын селкеп, өреп
«Ошбу этлекне изге бер кан,— диләр,—
Сугыша Инҗил[5] белән Коръән,— диләр.
Алдый алмаслар халыкны юк белән:
Монда, хәзрәтләр сугышмый поп белән.

1925 нче елда Заһирә Салихиянең «Мәктәпкә кадәр тәрбия» дигән китабы басылып чыга. Бу китапта да Тукай исеме куелган, әмма үз җыентыкларына кермәгән ике шигырь китерелә:

## Атларым

Кара атым кешнидер, бар эшне дә эшлидер:
Кырдан йөкне ташыйдыр, солы, печән ашыйдыр.
Ала атым бик матур. Ул чабарга бик батыр:
Атлангачтан, ул, ярсып, чабадыр тыпыр-тапыр.
Бездә күк ат бар тагын. Сөйгән атым-аппагым:
Беләм аның тай чагын; сөям матур чапканын.
Бездә тагын тайлар бар,— сылу, матур тайлар бар,
Аның берсе — алмачуар,— бик күнелле хәйваннар.
Безнең юртак ат күрән: чаба — чыгара буран!
Ул атка түгел әрәм, ясатсаң яхшы аран.

## Көтүче

Алды кулына сорнаен көтүче: тру-ру-ру!
Ә аңарга бер сыер каршы чыкты: му-му-му!
Син, сыер, кит урманга, хәтфә төсле кырларга:
Тик, кайтырсың кич белән, кич белән, күп сөт белән.

Тел, әдәбият, тарих институты кульязмалар бүлегендә Закирә ханым Шәрәфнең үз абыйсы Фатих Кәрими турында язып калдырган бер хатирә дәфтәре бар. Шуның азагына Закирә ханым Г. Тукайның җыентыкларында юк тагын бер шигырен теркәп калдырган.

## Кадер кич

Коръән ингән җиргә күктән, Ләүхелмәхфүздән[6] бу кич,—
Барча бәйрәм кичтән изгедер — Кадер кич! Ошбу кич,
Тәсбих әйтеп, нур түгә күк йөзе йолдызлары,
Тәһлил әйтеп[7], Җиргә иңәләр оҗмах хур кызлары.
Нәкъ җиде төн уртасында күк капусы ачылыр,
Яктырыр Җир кодси[8] шәгъләә[9] берлән, бердән ялт итәр.
Шунда сузылыр Җиргә күктән бер Фәзаи[10] киң күпер.
Бар фәрештә җиргә иңәр ошбу кич, һәр елда бер.
Әхрәви[11] тынлык бирер Тәңре, бу төн — бик тын кичәр,
Тик менә әкрен генә, бер, таң җиледәй, җил исәр.
Һәм бу кич,— мөэмин күңелләрне гаҗәп моңлык басар,
Һәр теләк, һәрбер гыйбадәт, туктамый күккә ашар.

---

[6] Ләүхелмәхфүз — күктә, тәкъдирләр язылган яшерен язма.
[7] Тәһлил әйтү — доганың, гыйбадәтнең бер төре.
[8] Кодси — изге.
[9] Шәгъләә — нур.
[10] Фәзаи — күккә карашлы.
[11] Әхрави — ахирәткә, теге дөньяга карашлы.

Ниһаять, Гаяз Исхакый исемен телгә алган өчен заманында әдәбиятка кертелмәгән бер эпиграмма. Бу шигырьнең зур һәм кызыклы тарихы бар. Столыпин реакциясе елларында, эшсез-акчасыз калган Сәгыйть Рәмиев демократик яшьләрнең төп һөҗүм объектына әйләнгән консерватив «Бәянелхак» редакциясенә секретарь булып эшкә керергә мәҗбүр була. Элеккеге фикердәшләре моны — идеалларга хыянәт, иманын сату дип кабул итәләр. Тукай да бу мәсьәләгә әче-әче сүзләр белән кагылып ала. С. Рәмиев тә «Бәянелхак» хуҗасы Ә. Сәйдәшев кулына күчкән «Казан мөхбире» газетасында «Без» дигән сатирик бүлек ачып, андый чәнчүләргә ачулы җаваплар кайтара. Бәрелешләрнең нинди киеренкелеккә барып җиткәнен, С. Рәмиевнең шулай ук җыентыкларына кертелми торган, Тукайны хурлап, әрләшеп язылган, «Без»дә басылган шундый шигырьләренә карап күреп була.

«Фәхрмен тик үзем берлән,
Үземнең үк сүзем берлән!..» —
«Көчәнмә, юк, булмассың
Кеше, туңган күзең берлән!»

Бу инде шәхескә кагылу, кешенең физик кимчелегеннән (Тукайның бер күзенә ак төшкән булудан) көлү.

«Кеше булып кыланучы,
Маймыл»,— син ул, мин түгел!
«Кара карга!» Я — Былбылмы —
Ачиншигым син түгел!

## Шул ук кешегә

«Рәшитнең сурәтендә бер
Дөгет тулган чиләк китсә»...
Сасытмасмы Галәмне, бер
Кеше «Яшенче»гә типсә?!

«Яшенче» инде ул — Тукай... Тукайның Г. Исхакый исемен телгә алган җавап эпиграммасы да ул үзе чыгарган «Яшен» сатирик журналында басылган. Менә ул:

Кара карга вә бөлгән бай
Юып аслан бияз булмый!
Вә һәрбер көлтә баш — чын «Таң» —
чы һәм аслан Гаяз булмый.

Әйе, болар әдәби мохитнең күңелсез яклары... Әмма аңа күз йому — күрмәмешкә салыну белән, без аларны юкка чыгара алмыйбыз. Әле бит шулар өстәвенә аларда информация һәм тәҗрибә дә тупланган! Алар революция җиңелгәч, реакция елларында демократик көчләр арасында каушау, таркалу, перспективаны югалту ни дәрәҗәгә җиткәнен күрсәтә. Тарихта иҗтимагый күтәренкелек, активлык еллары төшенкелек еллары белән чиратлашып тора. Бер төшенкелек елларындагы хаталарны, ачы тәҗрибәләрне онытмау, истән чыгармау, икенче бер вакытларда, андый хәлләрдән күзне һәм аңны томалаттырмауга ярдәм итә ала. Аларны онытырга, күрмәскә тырышулар исә бер үк урында туктаусыз абыну-бәрелүгә генә китерә...

Мәсгут **ГАЙНЕТДИНОВ.**

# ТУКАЙЛАР РУХЫ



**Уфадагы татар мәдәнияте мәркәзе идарәсенең рәисе, шагыйрь һәм публицист Айдар Хәлим белән әңгәмә.**

*— Айдар әфәнде! «Дружба народов» һәм «Казан утлары» журналында, «Литературная Россия», «Ленинградский литератор», «Кызыл Таң», «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Аваз» һәм башка газеталарда басылган мәкаләләрегез аша, шулай ук «Дружба народов» журналында чыккан «Телем минем — дустым минем...» исемле мәкаләгез (6 сан, 1988 ел) уңаеннан төшерелгән «Ничек экстремист булырга» дигән фильмны карап, без Башкортстандагы хәлләрдән шактый хәбәрдар булдык. Сезнең иманыгыз ныклыгына һәм гаделлек өчен кыю көрәшегезгә чын-чынлап сокландык. Укучыларыбыздан килгән күп санлы хатларда да шундый тойгылар чагыла. Ләкин вакыт бара, сулар ага тора... Шуңа күрә әңгәмәбезне соңгы чорда булган үзгәрешләрдән башлап китик әле. Бүгенге көнгә, ягъни 1 февральгә, Башкортстан татарлары тормышында яхшы якка таба үзгәрешләр бармы?*

— Бу бик тә урынлы сорау. Аны хәтта яшәвебезнең мәгънәсе дип тә билгеләп булыр иде. Чөнки без, адәм балалары, яшәешебездә изгелек барлыгына ана сөте белән иман китергәнбез. Без шуның өчен — үзебез куаныр һәм башкаларны да куандырыр өчен дөньяга яралганбыз.

Уңай үзгәрешләргә килгәндә, алар хакында бар дип тә, юк дип тә бер сүз белән генә кистереп әйтү кыендыр. Әмма бар алар, бар! Аларны эчке һәм тышкы, рухи һәм матди, шәхси һәм иҗтимагый үзгәрешләргә бүлеп булыр иде. Мәгълүм ки, тышкы һәм матди үзгәрешләр беренче чиратта эчке үзгәрешләргә, ягъни шәхеснең фикерләвендәге яңарыш рухына бәйле. Безнең иң зур казанышыбыз әнә шул хәлиткеч адымның ясалуындадыр! Моңа кадәр Башкортстанда «тугандаш» татар халкының проблемасы «юк» иде. Мин тугандаш дигән атаманы куштырнаклар эченә алам. Чөнки бу — аны тиргә төшереп эшләткәндә генә дуслык уены уйнап, халык кадәр халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү мәсьәләләренә килгәндә исә тугандашлыкны йомып калдыру, аны ширбәтле сүзләр өермәсенә батырып калдыру кәсафәте иде. Үз мәктәпләре ябылган, иҗади интеллигенциясе үстерелмәгән, булганы да бары тик шәхси мәнфәгатьләрен кайгыртып, урындагы властьлар белән рухи һәм матди коррупциягә кергән, үз газета-журналлары, радио-телевидениесе һәм башка хәбәрдарлык чараларының челтәре, театры, җыелып бер сөйләшерлек «Шәрык клубы» шикелле почмагы да булмаган шартларда безгә нишләргә кала иде? Киң халык даирәсенә генә чыгарга кала иде! 1987 елның көзендә Уфада республикада формаль булмаган беренче иҗтимагый оешма — татар клубы оешкач, аны «буржуаз милләтчел, халыклар дуслыгын таркатучы, экстремистик оешма» дип тамгалап, көне-төне сүктеләр. КПССның Башкортстан өлкә комитеты бу турыда хәтта махсус карарлар кабул итте. Күбәйтеп, аны түбәндәге оешмаларына җитәкче документ итеп җибәрде, атна саен активлар, «түгәрәк өстәл»ләр оештырып, анда безне чакырып та тормыйча, «татар клубы»ның никадәр «зарарлы оешма» икәнлеген республика халыкларының миенә сеңдерде.

«Татар клубы»н оештыручыларның берсе — мөхтәрәм шагыйрь һәм галим Иосыф Гәрәй, бу кысымнарга түзә алмыйча, йөрәге ярылып, урамда җан бирде. 18 ел буе Сталин лагерьларында һәм сөргеннәрдә лаеш шулпасын татыган бу искиткеч туры сүзле әдипне җирләүдә катнашу һәм тиешле хөрмәт күрсәтүдән Башкортстан Язучылар берлеге баш тартты. Ул гынамы? «Башкортстанда татарлар юк,

---

**Редакциядән.** *Төрле-төрле карашларга игътибарлы булу заманын истә тотып, А. Хәлим фикерләрен үзгәртүсез бирәбез. Нәтиҗәне укучы үзе ясар.*

алар кайчандыр татарлаштырылган башкортлар»,— дигән ялган идеяне алга сөреп, көне-төне урындагы радио-телевидение, газета-журналлар утыз җиденче ел репрессияләрендә бердәнбер «гаепле» кеше — Иосыф Гәрәйне уйлап табып, теманы «башкорт милли интеллигенциясен кыруда татар сатлык җаннарының роле» җирлегенә күчерделәр. Хәтта Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудашка да бихисап агулы ташлар атылды. Милләте ягыннан татар булган мәрхүм язучы Гайнан Әмиринең үзенең мәшһүр «Морадым» повестен Һадия Дәүләтшинадан урлаган, дип, тикшерү процессы кузгаттылар. Ярымяшерен шартларда барган бу тамашага, киң җәмәгатьчелек, татар клубы вәкилләре кертелмәде. Процесс матбугатта яктыртылмады. Шулай да ул процесс сабын куыгы кебек шартлады, хакыйкать өстә калды.

Без бу шартларда бары тик халыкның үзендә генә таяныч таба ала идек. Тукаебыз әйтмешли:

*Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,*
*Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,*
*Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,*
*Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен...*

1989 елның 14 октябрендә Нефтьчеләр мәдәният сараенда мең ярым кеше катнашында үткәрелгән гомумтатар митингысы бу җәһәттән хәлиткеч кочкә ия булды. Татар клубы аны бик җентекле әзерләде. Түрәләр ачык һавада соралган митингыны ябык бинага куып кертеп, бик җиңел генә котылырга теләгәннәр иде, әмма барып чыкмады. Татар халкында тупланган рухи җәбер потенциясе барлык киртәләрдән өстен булып чыкты. Бу форумда язмышыбыз өчен тарихи дип әйтерлек резолюцияләр кабул ителде.

Митинг көне итеп юкка гына 14 октябрь — Явыз Иванның Казанны басып алу «сәхифә»се сайланмаган иде. Мөхтәрәм кәрәштәшебез Сәид әфәнде Еники, мөнбәрдән торып, бу хакта бер-ике кәлимә әйтү белән, җыелышны өзү өчен залга кертелгән адәмнәр сызгырына, кычкырыша ук башлады. Мин залны халкыбыз бәйсезлеге өчен көрәштә һәлак булган татар уллары һәм кызлары хөрмәтенә нәкъ менә бүген — Казан алынуның 437 еллыгы көнендә — аякка басып, бер минут тынлык уразасында торырга чакырдым. Монда инде милли аерымлыклар да, дәрәҗәләр дә арткы планга күчте. Зал белән бергә, безнең хәлебезне аңламаган, йә булмаса аңларга теләмәгән җитәкчеләр дә, «ләббәйкә» һәм «долой»дан яралганнар да, хәтта гражданкиемендәге КГБ офицерлары да торып басты. Сынулары шунда булды. Икенче көнне газеталар — бигрәк тә урыс телендәге газеталар — «непредсказуемый» шагыйрьне бу «демократик» булмаган, имештер ки «халыкларны дошманлаштыруга илткән акция»дә гаепләргә ашыкты. Әмма алар да татар халкы алдында ясалма рәвештә тудырылган проблемалардан кача алмадылар. Тема «яшерен» булудан туктады. Башкортстандагы татар проблемасы барлык республикага, хәтта ки ил күләменә җәелде.

Татар клубы әгъзалары халкыбызның үзаңын күтәрүдә кыю һәм конституцион яктан гадел булган адымнар ясады. Татарча чакырулар язып, дистәләрчә җыелыш-диспутлар, лекция-концертлар үткәрде. «Татар халкына ачык хат», «Милләтебезгә олуг үтенечләр» кебек һәм башка шундый мәкаләләр белән «Кызыл Таң» газетасы аша киң халык даирәсенә чыкты.

Шулай итеп, дистә һәм йөз еллар буе тупланып килгән яман шеш тишелде, әйткәнемчә, яшерен тема булудан туктады. Бу уңайдан мин «Социалистик Татарстан», бигрәк тә «Татарстан яшьләре», «Аваз»га зур рәхмәтләр әйтер идем. Хәбәрдарлыкның үз чаралары булмаганда, СССР законнарына нигезләнеп, чит республикалардагы милләттәшләрең турында кайгырту — бу бит бик тә гуманлы, бик тә табигый күренеш.

Әчке, рухи, ягъни объектив үзгәрешләргә илтүче субъектив үзгәрешләрнең иң кадерлесе, минемчә, шуннан гыйбарәттер. Хәзер инде тышкы мохиттәге үзгәрешләргә килик. Әлегә кечкенә булса да, юк түгел алар. КПСС Үзәк Комитетының февраль (1988) Пленумында тәнкыйтькә эләккәннән һәм «Дружба народов» журналында чыккан мәкаләбездән соң, Башкортстанда көчләп башкортча укытуга күчерелгән берничә йөз мәктәп яңадан туган теленә — татар телендә укытуга кайтты. Мәктәпләрнең никадәр «татар» булуы, әсбаплар, укытучылар мәсьәләсе — бу инде икенче тема. Шулай да, татар хезмәт ияләре үз мәктәпләренең сәяси һәм граждан-лык статусын яклауда киләчәктә уяулык күрсәтерләр, дигән өмет бар. 1989 елда үткәрелгән халык санын алуда йөз меңнән артык милләттәшебез шулай ук көчләп яздырылган «башкорт»тан «татар»га кайтты. Әмма байтак паспортларны алыштырасы бар әле. Атнага ике генә тапкыр булса да, Башкортстан радиосы татарча концертлар бирә башлады. Урамнарда һәм сәхнәдә аяк терәп татарча сөйли, җырлый, хәтта ки театр уйный башладык. Үзәк Комитет күрсәтмәсе буенча Уфада ачылырга тиеш булган татар дәүләт театрын Башкортстан җитәкчелеге һичбер шартлары булмаган Туймазыга илтеп тыкты. Менә өч ел инде — театр һаман юк! Булачагы да билгесез. Татар клубы Уфада «Нур» театрын оештыруда башлап китүче, ярдәм кылучы булды. Әмма бүгенгә «Нур» театрын бар дип әйтү кыен. Аның бинасы да, акчасы да, актерлары да, тиешле режиссеры да юк. Башкорт дәүләт

педагогия институтында исә мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбияче-педагогларын әзерләү буенча татар бүлеге ачылды. Кушнаренкода татар педагогия училищесы аякка бастырылды. Уфада «Вакыт» исемле татарча газета чыга башлады. Озакламый бөтенреспублика татар яшьләре газетасы үз укучысына юл алыр дигән өмет бар. Сез сораган беренче уңай үзгәрешләр менә шулар. Кыска соравыгызга озынрак җавап биргәнем өчен гафу үтенәм. Чөнки ул безнең әңгәмәнең иң төп сорауларыннан берседер дип уйлыйм...

*— Рәхмәт, Айдар әфәнде. Әйтегез әле, сез «татар рухы, Тукайлар рухы» төшенчәсенә нинди мәгънә саласыз?*

— Иң туры, иң тиешле мәгънәне салам. Җир йөзендә милләтсез кеше булмаса да, безнең система милләтсез милләтләр хасыйл итүдә «халыкара» тәҗрибә туплый алды. Чын зыялы кеше, әгәр акылы камил икән, беркайчан да шовинист рухлы милләтче булмый. Тиешле белемне алмаган, әмма үз милләтенең никадәр кыерсытылган хәлдә икәнлеген аңлаган «телсез» Герасим-Мумуларның исә безнең заманда тәэлмәслек милләтчегә әйләнүе бик мөмкин. Чөнки аларны шушы система үзе үк әзерли. Милләтләрне кыерсыту аша!

Безнең оппонентлар еш кына: «Нигә сез татар халкының хәле турында артык борчыласыз?» — дип сорарга яраталар. Татарлар арасыннан завод директорларының фәлән, колхоз рәисләренең фәлән, фән докторларының фәлән, Хезмәт Геройларының фәлән проценты чыккан, имеш. Ләкин бит паспортыңда татар язылу гына, син — милләтең белән татар, дигән сүз түгел. Татар булу — ул милли үзаңлы булу, халкың кайгысы белән борчылу, халкың шатлыгы белән шатлану. Татар халкы рус империясенә беренчеләрдән булып куып кертелеп, үз милләте турында кайгыртудан ваз кичүгә кадәр җиткерелгән нининдидер мәҗүси массага әйләндерелде. Аның рәсми сеңдерелгән «интернациональлеген» мактау артында зур шик-шөбһәләр ята. Балаңа урыс исеме кушсаң, урыска кияүгә бирсәң, оныкларыңны урысча тәрбияләсәң һ. б. — син «интернациональ», имеш. Әгәр балаларыңның милли үзаңлы булуы турында кайгыртсаң, син — милләтче, имеш. Татар халкын интернациональлеккә өйрәтү хокукына ия булганчы, тәүдә үзеңә интернационалист булырга кирәк! Татар халкы барлык үткәне, үзенең мең еллык мәгърифәте, башка халыклар белән килешеп яшәве, уллары һәм кызларының бик күп милли мәдәниятләргә хезмәт итүе белән үзенең тирән интернациональлеген Ибн Фазлан заманнарыннан ук раслаган инде ул!

Аяныч хәл бит: кечерәйтеп, бик тә кечерәйтеп, бары тик җиде миллионга калдырылып, ЦСУ исемлекләренә кертелгән халкының өчтән бере дип әйтерлек туган теле итеп урыс телен күрсәтсен, балаларының бары җиде проценты гына туган телендә уку-язу таный белсен, һәр өченче-дүртенче улы һәм кызы катнаш гаиләләр корсын әле!.. һәм шушы хәлгә җиткерелеп тә, үз халкыңның иң газиз иҗаты — туган теленә хокукын яклаганда, синең җиреңдә яшәгән, синең суларыңны эчкән, синең икмәгеңне ашап кеше булган икенче бер милләт вәкиле сине «интернационалист булмауда» һәм «милләтчелектә», «милли фәтир» талап итүдә гаепләсен әле! Нининдидер милләткә карата үч саклау — татар халкының фигыль-табигатендә булмаган нәрсә. Ул шуның белән бөек. Әмма үзе турында кайгыртудан ваз кичүе, минем исәпләуләрем буенча, һәр йөз татарның җитмеш-сиксәненең чын миллилек, ягъни чын интернациональлекнең нигезен тәшкил иткән миллилектән «батырларча» арына барып, үзе турында да уйларга маңкортларча онытуы — бу система алып килгән иң зур бәлаләрнең берсе.

Тукайлар рухын мин шулай аңлыйм. Ул рух бары тик нининдидер әдипләр яисә әдәби мохит белән генә чикләнми. Тукайлар рухына тугры булу — ул үз милләтеңнең матурлыгын, рухи мәдәниятен саклау, үстерү, бер генә милләт интересларына да каршы килмичә, шушы казанышларны башкаларга да җиткерү. Үз милләтең учагы тирәсенә башкаларны туплау, сокландыру, һәркемне сөю, үзеңне һәм башкаларны кимсетмәү, рәнҗетмәү. Бүгенге шартларда һәр татар кешесе милли азатлык өчен көрәшнең уртасында булырга тиеш. Тукаебыз калдырган васыять тә шундый бит:

*Җырлап торам, торган җирем тар булса да,*
*Курыкмыйм, сөйгән халкым татар булса да;*
*Күкрәк кереп каршы торам, миңа милләт*
*Хәзерге көн мылтык-ук атар булса да...*

*— Сезнеңчә киләчәктә татар-башкорт халыклары арасында үзара якынаю һәм шул нигездә мәсьәләне гадел хәл итәргә тырышу булыр, дигән ышаныч бармы?*

— Ышаныч бар, дип фараз итәргә кирәк. Бары тик шайтан гына өметсез була ала. Татар һәм башкорт халыклары арасында берниндидә милли, социаль каршылык юк. Бүлешәсе җир-су да юк. Киресенчә, алар дөнья милләтләре инфраструктурасында сирәк очрый торган якынлыкка һәм рухи бердәмлеккә ия. Бүген килеп туган хәлләрдә халыкларыбызның бер гаебе дә юк. Ләкин һәр халыкның үз милли проблемасы, чишелүне талап иткән мәсьәләләре бар. Шуларны гадел юл

белән хәл итү урынына административ аппарат, үз гаебен яшереп калдырырга тырышып, гаепне «милләтара мөнәсәбәтләр»гә китереп ялгарга һәм шуны «тормышның үзеннән раслату» өчен илебезнең байтак регионында бәрелешләр китереп чыгара. Алма-Ата, Тбилиси, Баку, инде килеп, Литва хәлләре — барысы да шуны раслый.

Татар-башкорт мөнәсәбәтләрендә нинди кыенлыклар бар соң? Безгә, Уфа, ягъни Урал буе татарларына шунысы ачык: соңгы берничә ел эчендә дәүләт органнары белән якын мөнәсәбәткә кергән һәм бик тә сугышчан, бернинди килешү-консессуска барырга теләмәүче башкорт шовинизмы барлыкка килде. Кирәк җирдә яшерен, кирәк җирдә ачыктан-ачык рәвештә ул башкорт халкының төп дошманы итеп... үзенең бертуганы булган татар халкын игълан итте. Акрынлап, дистәләрчә ел буе бу фикер гади халыкның миенә сеңдерелде. «Бүлгәлә һәм хакимлек ит» кануны буенча халыклар белән курчак уены уйнаган Үзәктән башкорт милләтчел олигархиясе бу «батырлыклары» өчен күпмедер ясалма өстенлекләр дә алды. Халыкның тормышы начарайганнан-начарая барды, ә менә бөекдержавачыл шовинизм «үз теләге белән Россиягә кушылган башкорт халкы»ның кече шовинизмын яклап чыгыш ясый, аны рухи үстерә һәм бик нечкә фигыльләр белән «Россиягә үз теләге белән кушылырга ашыкмаган» татар халкына каршы куя. Бу ике шовинизм арасында уртаклыклар байтак. Белгечләр бу сфераны зур игътибар белән өйрәнсәләр, «кече туган» шовинизмының «өлкән туган» шовинизмыннан никадәр үрнәк алып дөнья көткәнлеген бик җиңел аңлар иде.

Гаеп үзебездә дә бар. Татар интеллигенциясе (мин биредә Татарстан интеллигенциясен күз уңында тотам) бу нечкәлекләрне ачып салып, башкорт һәм татар халыкларының элекке тарихи бердәмлеген ныгыту өчен хәлиткеч адымнар ясамый, үз оясыннан чыкмый, күбрәк имеш-мимешләр белән генә туенып тора, үзенә нинди тарихи сынаулар, нинди куркынычлар янаганын уйлап та бирмичә, иллюзияләр кочагында йоклый бирә... Кызганыч. «Дус яшәгез инде» дип өйрәтергә яраткан, Уфага командировкага килергә дә тартынган, килгән хәлдә дә башкорт милли интеллигенциясе белән ачыктан-ачык сөйләшүләр алып барырга ашыкмаган кайбер Казан әһелләре бу шартлылыкның безнең алга нинди киртәләр куюын аңлап җиткермиләр.

Билгеле булуынча, һәр милли хәрәкәт — әгәр ул демократик хәрәкәт икән — иң тәүдә үзенең гомуммилли мәсьәләләрен хәл итәргә тырыша. Ул башка халыкларның вөҗданына кагылмый, рәнҗетми, бергәлек һәм союз эзли. Ләкин башкорт милли хәрәкәте җитәкчелеге бу союздан уттан курыккан кебек курка — хикмәт менә нәрсәдә! Мисал итеп «Урал» башкорт милли үзәге кабул иткән һәм Б. Н. Ельцинга юлланган «Тәкъдимнәр»дән өзекләр китерик. Документ русча язылган, без дә аны тәрҗемә итеп тормыйк. «4. Установить право вето башкирского народа в решении всех общереспубликанских проблем... 9. Признать в конституционном порядке право собственности башкирского народа на землю и природные богатства в республике... 10. Избрать в Совет Национальностей СССР и РСФСР только представителей республикообразующей нации... 13. Считать, что ныне существующее в Уфе Духовное управление мусульман действует вразрез интересам башкирского народа и по существу стало центром великодержавного татарского шовинизма. Создать в Уфе самостоятельное Духовное Управление мусульман Урала и Сибири. Ныне действующее управление мусульман перевести в Казань... 16. На территории Башкирии, в целях сохранения спокойствия, размещать беженцев-башкир, а беженцев других национальностей принимать только в экстренных случаях... 22. Учитывая нациообразующую силу печати, впредь не допускать издания газет, книг на татарском языке в республиканском масштабе...»

Монда «ачышлар» тулып ята. Ә без килешү өчен көрәшкән булып ятабыз. Мөмкинме? «Башкорт халкының алты театры бар, татарга берне булса да ачыйк»,— дими бит совет мәктәбендә белем алган бу кешеләр!

*— Ситуацияне җайга салыр өчен иң беренче чиратта нәрсәләр эшләнергә тиеш?*

— 1922 елда халык ихтыярыннан башка «Кече Башкортстан»га кертелгән татарларның мәдәни-территориаль дәүләтчелеген һәм рухи ихтыяҗын тәэмин итүдә эшләр бихисап. Бу юлда әле беренче фикри адымнар гына ясалды. Шунысы ачык: башкорт халкыннан саны белән күпкә артык булган татар халкы проблемаларын хәл итми торып, Башкортстанда бер генә халык та бәхетле була алмаячак. Моңа ничек ирешергә соң? Әлегә республика парламентына ышаныч юк. Анда депутатлар булып сиксән-туксан процент партия-совет аппараты вәкилләре сайланды. Яшеренбатырын түгел, алар арасында Ярмәкәй райкомының беренче секретаре Галимов кебекләр дә җитәрлек. «Безгә татар ни, башкорт ни — барыбер»,— дигән сәер фәлсәфәдә тәрбияләнгән халык массаларын Галимовлар оста файдалана һәм алар урындагы шовинизмнан ныклы яклау таба. Ничек тапмасын ди, Галимов парламент трибунасыннан: «Мин үзем беренче класслы татар — мишәрмен, Башкортстанда татар теленең дәүләт теле булуына мин каршы, бездә андый мохтаҗлык юк»,— дип белдергәч!

Нәрсәләр эшләнергә тиеш, дисез. Әгәр без демократик һәм хосусый дәүләтчелек төзергә телибез икән, беренче эш итеп, үзгәртеп кору тәгәрмәченә аркылы таяк

тыгучы көчләрне туктатырга, гаделлек сызыгына куярга кирәк, хакимлек итүче коммунистлар партиясен сафландыру сорала, минемчә. Икенчедән, Башкортстанның бүгенге дәүләт структурасы шартларында андагы татар халкын бәхетле итү мөмкин түгел. Ул аңа бер генә нәрсә дә бирмәячәк. Димәк, татар һәм рус халыклары күп яшәгән элекке Уфа губернасы төбәгендә референдум үткәреп, Уфа татар-рус милли автономияле өлкәсен төзү юлы кала.

Бу — алдагы перспектива. Бүгенге чынбарлыкта исә, СССР законнары нигезендә, төньяк-көнбатыш Башкортстанның татар районнарында милли үзидарә итүгә корылган районнар төзү. Кызганычка каршы, без, татар халкы, сәяси яктан таркаубыз, СССР законнары биргән киң демократик мөмкинлекләрдән тиешенчә файдалана белмибез. Билгеле булганча, СССР Югары Советы 1990 елның 26 апрелендә, үз дәүләт-автономия корылышларыннан читтә яшәгән милләтләр ихтыяҗларын күздә тотып, тарихи закон кабул итте. 7 майда ул барлык газеталарда басылып чыкты. Әмма без аны гүяки күрмәдек тә. «Үз милли-дәүләт корылышларыннан читтә яшәгән яки андый корылышлары СССР территориясендә булмаган СССР гражданнарының ирекле үсеше турында» дип атала ул. Элегрәк бер республика җитәкчелеге яисә җәмәгатьчелеге икенче республикада яшәгән милләттәшләре турында аз гына кайгыртучанлык күрсәтсә, бу чит республика эшләренә тыкшыну, дип бәһалана иде. Хәзер кабул ителгән закон мондый кайгыртучанлыкны мәҗбүри дип саный. Шуңа күрә Татарстан Югары Советы Башкортстан Югары Советы һәм аның парламенты белән бәйләнешкә керергә, татар халкының тын алышын даими контрольдә тотарга, ике яклы килешүләр төзергә вәкаләтле. Мин әлегә белмим: Татарстан парламентында чит өлкә һәм республикаларда яшәгән халкыбыз белән кызыксынырга тиешле комиссия бармы? Булса, ул эшлиме? Без Уфада Татарстан Югары Советының Даими Вәкиллеге беренче чиратта төзелергә тиеш, дип уйлыйбыз.

*— Экстремистлык. Торгынлык елларында җыела килгән зур социаль, икътисади-сәяси проблемалар хәл ителүне сорап өскә калка башлагач, менә шушы сүз пәйда булды. Азатлык теләүче республикаларга карата «сепаратизм» сүзе, теге яки бу мәсьәләне гадел хәл кылуны таләп итүчеләргә карата «экстремист» тамгасы тагарга телиләр... Менә бу ярлыкларның икесе дә гаделлеккә каршы торучылар авызыннан әйтелә түгелме?*

— Сез үзегез куйган сорауга берникадәр җавап та бирдегез шикелле. Ярлык тагу белән шөгыльләнгән демократия бу илдә парламент демократиясе тәҗрибәсе булмавын раслый. Әлеге ямьсез атамалар Үзәкнең империячел холыгыннан, кискен сүзләр артына яшеренеп, үзенең череп чыккан коллык дәүләтчелеген сакларга тырышуыннан килә. Балтыйк буендагы кечкенә Литва халыкара һәм илебез Конституциясе нигезендә үзбилгеләнешен игълан итә. Әмма үзбилгеләнеш турында авыз суы корытып, халыкара масштабта демократ күренергә тырышкан Үзәк, әллә нинди проблемалар уйлап табып, шушы кечкенә Литвага икътисади, сәяси бойкот игълан итә, республика халкының нибары җиде процентын тәшкил иткән рус халкының «кысылуы» турында уйдырмалар китереп чыгарып, «шәхес иреге»н саклау өчен гаскәр кертә һәм канкою оештыра! Шул ук вакытта Башкортстанга куып кертелгән бер миллион өч йөз меңләп татар халкы монда яшәгән халыкның өчтән берен тәшкил итә, ә аның бернинди хокукы, хәтта Уфада җыелып сөйләшер, көрәшер өчен бер генә почмагы да юк! Без бу хакта Үзәккә дистәләгән хатлар, петицияләр язабыз, Уфада пикетлар, митинглар үткәрәбез. Әмма Үзәк күрми дә, ишетми дә. Безләрне яклап нигә гаскәр кертми икән соң Горбачев?

Татарстанны алыйк. 1990 елның 30 августында ул үзенең дәүләт мөстәкыйльлеген игълан итте. Тукай әйтмешли, «Шул халыкныңмы хокукка хакы юк? Халкыбыз уртак ватанда шактый ук!» Юк икән шул. Декларациядә РСФСРдан, СССРдан аерылып чыгу турында бер сүз булмаса да, Үзәк чаң кагарга керешә: «Аерылып чыгалар»! Алар татар халкының бәхете турында, илебезнең таркалмас бердәмлеге, халыкларның тигезлеге турында аз гына кайгыртсалар, булмаган сепаратизмда гаепләргә ашыкмаслар, югары мәдәниятле ия булган халык вә дәүләт вәкилләре буларак, бөтен дөньяны шаулатып, кечкенә бер Татарстанны үз дәүләтчелеген игълан итү белән котлап чыгарлар иде. Сер түгел: дәүләт җитәкчелеге, хәрби-промышленность комплексы, 1905 елгы «Рус халкы берлеге»нең рухи туганы булырдай шовинистик «Союз» хәрәкәте Татарстан мисалында Россия «федерациясе»нең Литва вариантын әзерли. Безгә Татарстан мөстәкыйльлеген яклар өчен бик нык көрәшергә, хәтта кыйналырга туры килер, бәлки. Ирек җиңел генә бирелми.

Мин бу уйлап чыгарылган «экстремизм»ның ил күләмендәге беренче корбаннарыннан булдым. Көтмәгәндә. Мәкаләмнең туксан проценты күләмендә башкорт халкын, аның хокукларын, мәдәниятен яклап чыксам да, «юлбашчыбыз» Шакиров җитәкчелегендә аска тәгәрәтелгән татар халкы турында авыз ачып сүз әйткән өчен «халыкларны каршы кую»да гаепләндем. «Дружба народов»тагы мәкаләмне Башкортстанда күчереп басмасалар да аның турында дүрт миллионлы халкыбыз хәбәрдар булмаса да, мине, минем аша мәкаләне, аларның икесе аша татар халкын хурлауга корылган һәм үзәктә басылып чыккан мәкаләләрнең гомуми тиражы йөз миллион данәгә җитте. Ә мине яклаучы юк. «Экстремист» — вәссәләм! Татар халкын теленнән, аның конституцион хокукларыннан, рухи ихтыяҗыннан мәхрүм иткән,

ике тугандаш халык арасына гомердә булмаган кара мәче җибәргән Шакиров түгел, ә шушы репрессияләрне дөньяга ачып салган Айдар Хәлим барысына да гаепле икән! Зур-зур җитәкчеләр тарафыннан алып барылган мондый сәяси уеннарның никадәр балачагалык икәнлеге хәзер инде бала-чаганың үзенә дә аңлашыла, ләбаса!..

*— Безнең республикада Салих Баттал, Нурихан Фәттах, Роберт Батулла, Фәүзия Бәйрәмова кебек кыю язучылар, фикер ияләре бар. Ләкин кайчак алар турында да «экстремист» дигән сыман сүзләр ишетелеп китә. «Дан алу өчен йөриләр...» — дигән пычрак гайбәт тә әйткәлиләр... Мондый сүзләрне, гадәттә, милләт өчен кыл да кыймылдатмаган һәм эшләргә теләмәгән адәмнәр, үз мәнфәгатен генә кайгыртучылар әйтә. Сезгә, билгеле, андый пычрак гайбәтләр ишетү авырдыр...*

— Башта авыррак иде. Мин аларга хәзер өйрәндем инде. Әлбәттә, йөрәктә яра кала. Аларның иң авыры һәм гафу ителмәслеге — кичә генә синең ышанычка кереп, популярлык яуларга тырышкан, синең аша халыкка хезмәт әшенә тәкъдим ителгән, бүген инде ниндидер вазыйфага ия булып, сине дарга мендерергә әзер торган кешеләр белән рухи коррупциягә кереп, югары органнарга чапкан һәм синдә, синең вөҗданыңа каршы турыдан-туры һөҗүмгә күчкән сатлык җаннар авызыннан ишетелүе. Мин бу хакта, татар тарихында аз яктыртылган темага, бер китап яза алган булыр идем, мөгаен. Ходай гомер бирсә, бәлки, язармын да...

Сез атаган шәхесләргә килгәндә, мин аларны олуг бер сөю белән сөям. Салих агай Баттал... Ул бит иң караңгы елларда, әле без бишектә арыш чумары имеп ятканда, татар дөньясының беренче диссиденты булды. Аның әлегә кадәр басылмаган әсәрләре безгә инде студент чакта ук билгеле иде. Нурихан абый Фәттах... Мин аны «абый» дип атыйм. Бу сүздә аның үзенә генә хас булган нечкәлек, ниндидер сихри күз кысу бар. Хәтердә, 1967 елда КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табеев Казанда пресс-конференция үткәрде. Ул очрашуда яшь шагыйрь-студент — мин дә катнаштым. Табеев бөтен залга: «Нурихан Фәттах — антисовет язучы! Без бергә укысак та, мин аның белән бүген кул биреп тә күрешмим!» — дип кычкырды. Русчалатып кычкырды ул аны. Мин шул минутта шәхес булып өлгердем, күрәсең. Табеевка сорау җибәрдем: «Сез антисовет төшенчәсенә нинди мәгънә саласыз?» Табеев укыды, йөзе җыерылды, әмма язуны кесәсенә тыкты. Сорау әллә ни батыр да булмагандыр. Ләкин мин рәнҗеп калдым. Роберт Батулла... Хәтердә, алтмышынчы еллар уртасы иде. Безнең яшь интеллигенция арасында, соңлап булса да, «Хрущев язы» булып алды. Язучыларның бер җыелышында без Роберт Батулла белән бик кискен рәвештә татар яшьләре журналын таләп итеп чыктык. Анда партия даирәләреннән Вәлиев, Мусиннар бар иде. Моннан тыш, тәнәфес вакытында, без Мәскәүдән килгән драматургка (фамилиясен хәтерләмим) Ярослав Смеляков исеменә язылган протест хаты тапшырдык. Чөнки ул үзенең бер шигырендә «На мельнице русской смоloли заезжий татарский язык»,— дип, татар халкына бик нык пычрак аткан иде... Тәнәфестә кемдер, кармап алып, кулымны кыса. Карасам — Әмирхан абзый Еники. «Син, якташ, сабыррак бул, саграк бул...» Рәхмәт, Әмирхан абзыйга. Татар халкының олуг язучысы — авыр елларда да милләт байрагына тап төшермәгән әдип, мине якын итеп, якташ итеп, киләчәк балалардән сакларга теләгән. Фәүзия Бәйрәмова... Халкыбызның ак шәл ябынган бер өмете бит ул. Аңардагы акыл һәм түзем, мөлаемлек һәм батырлык, эшчәнлек һәм тынгысыз җаваплылык — татар халкы, аның мең еллык мәдәнияте тудырган үлемсез запаслар күрсәткече бит ул. Без Фәүзия ханым белән өченче ел көз Бакуда Әзәрбайҗан Халык Фронты оештырган миллион кешелек митингта катнаштык. Фәүзиянең чыгышын тыңлап, мин халкым өчен тагын бер кат горурлык хисләре кичердем. Апшерон ярымутравын кырмыска иләве кебек каплаган миллион кеше артында чал Каспий үкерә иде. Әмма миллион кешенең: «Фәүзия, татарча сөйлә!» — дип аны күтәреп алуы мине дә югары күтәрде шикелле. Мин татар милли хәрәкәтендә бу затларга өстәп Әбрар ага Кәримуллин, Марат Мөлеков, Гәбделбәр Фәйзрахманов, Рәшит Әхмәтҗанов, Әхмәт Рәшитов әфәнделәргә дә зур ихтирам саклыйм.

Фәүзия ханым Бәйрәмовага карата исә ниндидер яман сүз куллану өчен бөтенләй мәгърифәтсез, имансыз яисә көнчел кеше булу кирәктер. Гавәм халкы түгел, татар язучысы авызыннан ишеткәнем бар минем: «Фәүзия Бәйрәмова ул, әлбәттә, һәйбәт көрәшче, әмма...» Нәрсәсе «әмма» икән аның, аңлашылмый! Нигә еракка китәргә? Әйдәгез, Туфан Миңнуллинны алыйк. Мин монда аның иҗади ягын күздә тотмыйм. Ул, бәлки, татарның Шекспирыдыр. Шулай була күрсен. Мин аның СССР Югары Советы депутаты буларак гражданлык йөзен чамалыйсым килә. Билгеле булуынча, торгынлык елларында Татарстан белән Башкортстан арасындагы мәдәни бәйләнешләр, «интернациональ дуслык» партия өлкә комитетлары төзегән исемлек буенча алып барылды. Әйтик, Уфадан башкорт әдибе саналган бер функциональ шома татарның Казанда китабы чыга яисә сәхнә әсәре куела. Казаннан шундый ук бер татар әдибенең әсәре дә Уфада тәсдыйкъ ителә. Шулай итеп, мәгърифәтсез калдырылган халыклар «дуслыгы» органнар тарафыннан оештырылган шәхесләр «дуслыгы»на кайтып кала...

Ләкин мәсьәлә анда түгел. Мәсьәлә шунда ки, үзенең премьераларына ел саен килеп киткән СССР халык депутаты Туфан Миңнуллин Уфадагы бердәнбер җылы, демократик татар учагы — Уфа татар мәдәнияте мәркәзенә килеп чыгарга, аның

ихтыяжлары белән кызыксынырга вакыт тапмый. Чөнки анда — «экстремистлар» гына. Әмма «Кызыл Таң»га да керми ул. Ә минә татар халкын рәнҗетү белән даими шөгыльләнгән «Башкортстан» редакциясенә интервьюлар бирергә форсат таба. Туфан Миңнуллин бер әңгәмәсендә: «Мин Айдар Хәлимнән куркам. Фәүзия Бәйрәмовадан да куркам мин...» ди. Аңламыйм, нәрсәгә куркырга икән?

*— Ә ни өчен нәкъ минә сез, Айдар әфәнде, килеп эләктерез бу көрәшнең уртасына? Сездә татар милләтеннән олы-олы шәхесләр, зур эдипләр — акыллы кешеләр шактый бит. Олы дәрәҗәле эдипләр дә... Бу гаделсезлеккә алар нинди мөнәсәбәттә соң?*

— Кухняда чәй-мәй эчеп утырганда, алар бу гаделсезлекләр белән килешмиләр. Иҗтимагый тормышта исә авызларына су кабалар. Монда язучы белән шәхес арасында упкын барлыкка килә. Упкынга җитәрәк кенә затлы кәрзиндә нәшрият темпланы, дәрәҗәләр, орденнар, премияләр, яхшы фатыйрга ордерлар, зур пенсия таныклыклары, бер юлы ике халык классигы булу хыяллары ята. Минә шунда сайлыйсың инде: халык, мескен, упкында җир сөрә. Син шунда төшеп, алар белән йә җир сөрәсең, йә кәрзиннән кирәген алып котыласың һәм «халык яклаучысы» булып күренү өчен уңайлы форсат көтәсең... Соңгы дистә елларда татар халкын икенче халыкларга хезмәт иттерүнең иң иезуит ысулларын тормышка ашырган шартларда хәтта ки аның иң талантлы, иң акыллы уллары-кызларында да эдиплек, әдәп белән шәхес арасында упкын яралды. Икейөзлелек фикерләү фигыленең ашы-тозына әйләнде. Андыйлар торгынлыкның кире кайтуын, диктатураның аякка басуын түземсезлек белән көтәләр.

Дөресен әйткәндә, мин студент чагымнан ук милли азатлык көрәшенә җигелгән идем. Әлбәттә, ялгызакларның берсе идем. Төкереп кенә дә бирмим ул темпланнарга һәм премия-дәрәҗәләргә! Хәбәрдарлык булмау аркасында бу үткән көрәш әле һаман томаннар артында ята. Бу көрәшкә мине туган җирем, газиз анам сөте, тугайларда үзем киерелеп чапкан печәннәр, әлбәттә, иң мөһиме — бөек Тукай һәм демократик татар әдәбияты әзерләде. Яшем иллегә җитеп, Тукай әйтмешли, «бөкрем чыгып, картайсам да», минем Тукай турында шигырь язарга батырлыгым җитми. Ә минә Тукай турында ширбәтле шигырьләр язган тере классикларыбыз Башкортстан Язучылар берлеге оештырган мәсхәрәле җыелышта җиде сәгать буе мине тукмарга батырлык тапты. Чөнки җыелышны өлкә комитеты вәкиле алып барды. Бердәнбер гаебем — «Дружба народов» журналында татар халкын яклап сүз әйтүем иде...

Бу адымга һәрчак әзер идем. Казанны ташлап, көтмәгәндә генә Уфага кайтып төшүем дә шуңа бәйле бит. Башкалар барысы җылы урын эзләп Казанга китә, ә мин, тиле, Уфага кайтам. Кызык бит. Халкыма булган олы сагыну алып кайтты мине туган ягыма, дисәм, шәт, шапырыну булып яңгырамастыр. Заводка эшче булып урнашырга да әзер идем. Аңарчы артымнан шактый гына эзләр һәм күзләр бар иде инде. 1968 елның августында Казан дәүләт университеты дипломы белән Түбән Камага барып төштем. Милләт байлыгын талап, милли рухны аяк астына салып таптаган бу шәһәрдә икенче көнне үк диярлек татар иҗади яшьләренең «Кама таңнары» исемендәге берләшмәсен, хәзерге тел белән әйтсәк, формаль булмаган оешмасын оештыруга керештем. Без меңәр кеше катнашында әдәби-сәяси кичәләр үткәрә башладык. Бу тарихларны Рахмай Хисмәтуллин яхшы белә. Шул ук елның ноябрендә шәһәр комитеты миңа актив алдында, концертта шигырь укырга тәкъдим итте. Мәскәүдән дә зур җитәкчеләр катнашкан бу «энҗе-мәрҗән»нәребез корылтаенда мин башта урысчалатып татар мәдәниятенең никадәр авыр хәлдә булуы турында нотык тотып, соңыннан татарча шигырь укыдым. Сәхнә артына үткәндә шәһәр комитеты инструкторы Закирова һушыннан язган иде... 1969 ел кышында, «Прометей» яшьләр клубы семинарында катнашып, яшь татар иҗади интеллигенциясен милләтчелектә гаепләп лекция укыган Татарстан дәүләт иминлеге комитеты политбүлек начальнигы полковник Морозов белән 400 кеше алдында кискен бәрелешкә кердем. Семинарны ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетының ул чактагы беренче секретаре Рәис Беляев алып бара иде. Шул ук вакытта мин, төзелеп яткан Түбән Кама комбинатында эшләгән җитәкче кадрлар нисбәтен тикшереп, андагы йөз эре «начальник»нең нибары икесе генә — баш бухгалтер һәм хуҗалык цехы җитәкчесенең генә татар икәнлеген, фатир, балалар бакчалары бүлүдә татар хезмәт ияләренә карата үткәрелгән кысу сәясәтен ачыклап, шәһәр комитетына шикаять яздым. Шикаять дөресләнде, җинаятьчеләргә җәза бирелмәде, нәкъ алты айдан соң штаттан кыскартылдым. Өч ай эшсез утырганнан соң, балта остасы булып киттем. Сәяси күзәтү астына алындым. Казан әсәрләремне басудан туктады. Яшьлек дәрте белән язылган, Түбән Кама тарихында беренче әдәби әсәр булган «Беренчеләр» поэмасы, иҗади секция уңай бәя бирсә дә, басылудан тыелды.

Уфага кайтканда минә шундый «мактаулы» тәрҗемәи хәлем бар иде. Өлкән каләмдәшләремнән берәүнең минем хакта: «Аңа дан гына кирәк... Ул бит Казаннан куылып кайткан, аны моннан да куарга кирәк»,— кебек нахак сүз таратуы кызганыч, әлбәттә.

Мине туган җирдән беркем дә куа алмаячак. Безне туган җирдән беркем дә куа алмаячак! «Яңа «Китмибез» дигән шигыремдә андыйларга ачыктан-ачык әйттем:

*— Без — төп халык!— Чаң сугалар.—Сез, татарлар, бетегез!*
*Иә тиз башкортка үтегез, йә «Казань»га китегез!*
*Көтмәгез сез — бетмибез без! Бер милләтне сукмибез.*
*«Үтмибез» дә, «нитмибез» дә, «Казань»га да китмибез!*

*— Ә шулай да, сезгә, шагыйрь кешегә, бу көрәш нәрсә бирә? Моны шуның өчен сорыймын: бездә дә милли мәктәп, милли матбугат оештыру мәшәкатеннән уттан курыккан сыман куркучы каләм ияләре бар. Барысын да кемдер оештырып бирергә тиеш аларга. Әзергә генә киләчәкләр, имеш. Татар милләтенең хәзерге хәленнән чыгып караганда, мондый позиция дөрес микән?*

— Соравыгыз ике өлештән булып чыкты. Милли көрәш, әлбәттә, иҗатка дигән вакытны, миемнең сафлыгын урлый. Әмма үкенмим: халыкта аз-маз булса да рухи уяну күрү миңа шатлык китерә. Минә алтынчы ел инде үземне тәмугта хис итәм. Җиңел нәрсә түгел бу. Үз халкың язмышына төкереп карау — бу рухи җинаять. Мондый кешеләр халык азатлыгы өчен башлары мордар киткән ата-ана рухы, соңгы сугышта һәлак булган җиде йөз меңләгән милләттәшләребез алдында гафу үтенергә тиеш. Кем ничектер, мин үзем таңнан уянам һәм күз алдыма саф чишмәләр, хуш исле болын чәчәкләре килә... Мин алардан оялу тойгысы кичерәм. «Нигә безне якламыйсыз, абый?» — дип әйтә кебек алар миңа. Миллионлаган корбаннар, тигәнәк үскән чокыр төпләреннән күтәрелеп: «Без ни хакына башыбызны салдык, аңлатыгыз?!» — дип оран саладыр сыман. Безгә нинди гафу булуы мөмкин? Һәр милләт бүген үзенең Нюрнберг процессына мохтаҗ. Мондый хәлләр беркайчан да кабатланмасын өчен...

*— Без төрки милләтләр, бергә һәм бердәм булсак кына нинди дер уңышка ирешә алачакбыз... Шуны истә тотып, башкорт һәм татар халкын уртак эшкә, уртак көрәшкә туплый алырдай бер зур һәм актуаль идея күрмисезме?*

— Бар ул идея. Ул — башкорт һәм татар халыкларының мөстәкыйль дәүләтен төзү. Шуны булдырмый торып, без ике халык мөстәкыйльлеген саклый алмаячакбыз. Бигрәк тә башкорт халкы ихтыяҗларына тап килә бу. Татар халкы белән ул бер вакытта да югалмаячак. Аңа каршы барып исә үзенең көчен генә киметәчәк. Бөекдержавачыл сәясәт безгә баз казыды һәм казыячак. Әмма бу идея башкортның консерватив көчләрен ифрат дәрәҗәдә куркыта. Имеш, татар башкортны йотачак... Тарих шаһит: башкорт халкына мәгърифәт илткән, аның мәктәбенә әлифба алып килгән, аның театрын, мәктәбен, әлифбасын булдыруда бәһасез өлеш керткән татар халкының шундый «агрессив» булуы мөмкинме һәм шуңа берәр дәлил бармы?

Төрки милләтләргә килгәндә, безгә, царизм һәм сталинчыл дәүләт көчләп таккан «пантюркизм» идеясын атып бәреп, чын-чынлап, иң демократик, интернациональ-милли җирлектә торып берләшергә кирәк. Тарих алдындагы мәдәни бурычыбызны без шунда гына үти алачакбыз. Моның өчен Төрки халыклар конгрессын булдырырга, якындагы елларда латин имлясына күчәргә кирәк иде...

*— Язган әсәрләрегез барысы да дөнья күргәнме? Шигырь язарга вакыт каламы? Кайчан яңа китабыгыз дөнья күрәчәк?*

— Бу сорауларга ярым шаян рәвештә дә җавап бирергә мөмкиндер: ходайга шөкер, киләсе елларда дөньяның бер генә нәшриятендә дә минем китабым чыгу көтелми. Күңел тыныч. Әсәрләремә килгәндә, аларның яртысыннан күбесе дөньяга чыкмаган әле. Дистәләгән мең юл шигырь, поэмалар, берничә том проза һәм публицистика, иҗади портретлар, бер том чамасы пьесалар, балалар өчен әсәрләр... Гомер буе кыерсытылгач һәм сугылгач, әсәрләрнең чыгу-чыкмавы да арткы планга күчә икән. Битарафка әйләнәсең. Шулай да, үзем исән чакта күрмәм микәнни, дип борчылып куйган чаклар була... Күптән түгел Татарстан китап нәшрияты минем «Йөрәк ташы» дигән кечкенә китабымны басып чыгарды. Эш аның кечкенәлегендә түгел. Аның туган телемдә чыгуында. Егермеләп китабым башкортча һәм русча дөнья күреп, мин аларны язылган телендә — туган телендә бүген генә күрдем. Еладым. Рәхмәт нәшриятка. Хәзер мең дә дүрт йөз укучы минем шигырьләрем белән татар телендә таныша ала...

*— Мәкаләләрегездә сез баланы үз ана телендә укытмауның психологик зыяны булуга кагылып үтәсез. Рәсми пропаганда раславынча, баласын туган телендә укытырга, имеш, ата-ана үзе «теләми». Шул турыда махсус язарга уйламыйсызмы?*

— Ана телендә укытмау кеше табигатенең барлык функцияләренә дә кире йогынты ясый. Психологик, физиологик һәм иҗтимагый фикерләү куәсеннән чыгып караганда, үзәк мәгариф органнары моны бик тирән төшенеп эшли. Аларга иң мөһиме — шәхесне җимерү, милли узаңнан мәхрүм итү. Бу бөекдержавачыл амбицияләргә тулысынча җавап бирә. Үзгәртеп кору заманында туган телдән аерым тәрбияләнгән зәгыйфь шәхесләр юккамыни атасын һәм анасын, туган халкын һәм иманын саткан «интерфронт»лар булып оешып, империя сакчыларына әверелделәр?

Менә шушы мөһим өйгәнне кулдан ычкындырмас өчен мәгърифәтсез мәгариф министрлыклары туган телдә укытырга ата-ана «теләме» дигән уйдырма уйлап чыгара. Әйе, теләмәүчеләр дә байтак. Ләкин бу теләмәүче үзе шундый зәгыйфьлектә тәрбияләнгән бит! Аңа бер кило колбаса туган телдән кадерлерәк. Аннары мәгариф органнары ата-ананы куркыталар, аңарда «Ә-ә, татар телендә генә укыгач, балам русча белмәячәк икән»,— дигән синдром тудыралар. Туган республикаңда көн итеп, туган телеңне инкарь итү ярый торган шөгыльме? Юк, ярамый торган шөгыль. Ә нигә шәхесне әхлаклы итеп тәрбияләүне алга куйган мәгариф органнары моны халыкка аңлатмыйлар? Нигә баланың туган телен, әдәбиятын, мәдәниятен өйрәнүне дәүләт законы нигезендә тормышка ашырмыйлар? Нигә күптән расланган бу урталыкка кире кайтмыйлар? Чөнки элеккедән килгән урыслаштыру сәясәте хәзер икенче киемгә — ата-ананың «теләмәү» хөлләсенә төрелгән. Бу эштә мәктәпләребездә чиксез үрчегән милләтсез «интердиректор, интерзавуч, интерукытучылар» зур комачаулык ясый. Татар халкы үзе тудырган, үстергән, туендырган һәм киендергән газиз балаларны аның милли үзенчәлекләрен, милли мәдәниятен һәм инсаниятын инкарь иткән икенче бер милләт вәкилләре кулына тапшырудан туктарга тиеш.

*Аерып телдән, мәктәптә алма кебек балаңны*
*Бирәсең кемнәр кулына йөрәккәең таланмый?*
*Тудырып-үстереп аны татарың исәбенә,*
*Саласың язмышын читнең караңгы кесәсенә...*

Әйе, мине сабыйларыбыз трагедиясе бик борчый. Мин бу турыда махсус китап язарга ниятлим. Бу — дөнья педагогикасында, татарда бигрәк тә, юньле-рәтле ачылмаган тема. Минем сабыйның эмбриональ яралгыдан алып, туып, теле ачылып, дүртенче сыйнфка кадәр үткән юлын тасвирлыйсым килә. Ул китапның исеме, бәлки, «Сабый-сабыя» дип аталыр.

*— Айдар әфәнде, сез былтыр октябрьнең карлы-яңгырлы көннәрендә, Башкортстан Югары Советы республика суверенитеты Декларациясен кабул итәр алдыннан Уфа үзәгендәге Совет мәйданында сәяси ачлык тоттыгыз. Ачлыкның таләпләре нидән гыйбарәт иде? Өметләрегез акландымы?*

— Башкортстан халыкларының тигезлеге, татар теленә дә дәүләт статусы, татар мәктәпләре һәм балалар бакчалары ачуны таләп иткән бу сәяси ачлыкны без эшче Кадерле Имаметдинов белән башладык. Берничә көннән безгә Яңавылдан Мәүләви Сәләхов, Нефтекамск шәһәреннән Владимир Щербаков килеп кушылды. Реанимациядә үткән өч тәүлекне дә исәпләгәндә, без игълан иткән ачлык ун тәүлек дәвам итте. Безнең акция халыкның аңын уятуда бик зур этәргеч булды. Аның иң төп казанышы шундадыр. Мәйдан җиде тәүлек буена ирекле фикерләү республикасына әверелде. Суверенитет декларациясе кабул итәргә ике сәгать калгач, мин сессиядә чыгыш ясау өчен ике-өч кенә минут вакыт сорап, Югары Совет рәисе М. Рәхимовка хат яздым һәм кулыма Коръән күтәреп, сессия үткән бинага юнәлдем. Әмма кертмәделәр!

Өметләр дигәннән. Өметләр акланмаса да, сессия тәмамланганнан соң бераз вакыт үткәч, Югары Совет Башкортстанда татарча яшьләр газетасы һәм 1992 елдан татар яшьләре журналы булдыру турында карар кабул итте.

*— Сезнең сәяси ачлык турында илебез матбугаты, Үзәк телевидениенең «120 минут» программасы, бар дөньяга тарала торган «Экспресс-хроника» газетасы, «Азатлык», «Америка авазы» һ. б. радиостанцияләр хәбәр итте. Ә Башкортстан матбугаты аны яктырттымы?*

— Юк! Һаман да шул — сәяси культура җитми, халыкны басып тору теләге көчле! «Кызыл Таң» газетасы безнең чатырның почмагын фотога төшереп, укучыларына күрсәтте шикелле...

*— Илебезнең татарлар яши торган барлык төбәкләрендә дә Сезнең кебек фидакарь көрәшчеләр үсеп чыгачак. Үзегезнең зур тәҗрибәгездән чыгып, аларга нинди киңәшләр бирер идегез?*

— Мин үземне берниндн дә фидакарьлек эшләдем дип исәпләмим. Киресенчә, мин гади кешелек бурычымны үтәргә тырыштым. Алдамадым һәм алданмадым. Шигъри эчкерсезлекне беркатлылык дип аңлаган сәяси сәүдәгәрләр бик нык ялгышалар. Әйе, андый көрәшчеләр үсеп чыгарга тиеш һәм чыгачак та! Иншалла! Татар халкының үз тарихына тиң булган бөек халык булып яңадан аякка басачагына һәм дөнья мәгърифәтен бөек җәүһәрләр белән тулыландырачагына ышанычым зур. Эчтә консервацияләнгән көчләр озакламый үзенең шытымнарын бирәчәк. Яшь көрәшчеләргә безнең бу беренче адымнар кечкенә генә илһам өстәсә, язган әсәрләр йөрәкләргә барып җитсә, җирдәге кешелек бурычым үтәлгән дип исәпләр идем. Киңәшләргә килгәндә: тирән белемле, түземле, батыр, саф йөрәкле көрәшче булу...

Әңгәмәне Мансур **ВӘЛИЕВ** әзерләде.

**Артур Сәгадеев,**
философия фәннәре докторы

# СОЛТАНГАЛИЕВ ҺӘМ СОВЕТЛАР РОССИЯСЕНЕҢ МИЛЛИ СӘЯСӘТЕ



Соңгы вакытларда үзәк һәм республика матбугатында татар халкының күренекле революционеры Мирсәет Солтангалиев турында мәкаләләр ешрак дөнья күрә башлады. Бу сөенечле хәл. Әмма исеме өч кыйтгада зур хөрмәт белән яңгыраган әлеге шәхесне тулысынча күзаллау өчен болар гына җитеп бетми, әлбәттә. Чит илләрдә инде күптән аның турында саллы мәкаләләр, китаплар языла, эшчәнлеген гыйльми дәрәҗәдә тирәнтен өйрәнү бара. Мәсәлән, моннан биш ел элек кенә бер Алжир язучысы аңа багышлаган романын Парижның «Синдбад» нәшриятында китап итеп бастырып чыгарды (Tengour H. Sultan Galiev.— P.: Sindbad, 1985).

М. Солтангалиевне «өченче дөнья» революциясенең атасы, мөселман Көнчыгышындагы азатлык хәрәкәте идеясен яңа дәвер шартларына яраклаштыруны күтәреп чыгучы дип атыйлар. Дөньяның барлык телләрендә диярлек ихтирам белән «солтангалиевизм» турында сөйлиләр.

Мирсәет Солтангалиев 1892 елда элекке Уфа губернасының өяз үзәге булган Кырмыскалы дигән татар авылында, мөгаллим гаиләсендә туган. Башлангыч белемне туган авылында ала, Казан педагогия училищесын тәмамлый. Аннары укытучы, китапханәче булып эшли. Шул вакытларда вакытлы матбугатка мәкаләләр яза башлый. Мәгълүматларга караганда, беренче буржуаз-демократик революция дулкыны аны азатлык өчен көрәшчеләр сафына китереп бастыра. Ул укучы яшьләрнең «Ислах» революцион хәрәкәтендә актив катнаша. Биредә мөселман реформаторлыгының сул канаты белән беренче тапкыр таныша һәм, әйтергә кирәк, сәяси карашлары калыплашуда аның йогынтысы зур була.

1905 елгы революция җиңелгәннән соң М. Солтангалиев Бакуга китә. Анда да ул шулай ук укытучы, китапханәче булып эшли, татар вакытлы матбугатында мәкаләләрен бастыра. Азәрбайҗан азатлык көрәшчеләре белән тыгыз элемтәдә торып, үзенең революцион эшчәнлеген дәвам итә. Аның биредәге революцион эшчәнлегенә Нариман Нариманов та югары бәя бирә.

1917 елның май аенда М. Солтангалиев Мәскәүдә үткәрелгән Бөтенроссия мөселман съездында һәм анда сайлаган Бөтенроссия мөселман Советы эшендә катнаша. Шушы елның июль аенда ул Казанга кайта, биредә М. Вахитов бе-

ләп якыннан танышып, бергәләп Мөселман социалистик комитеты (МСК) төзүдә актив эш башкара. Бу комитетның программасы большевиклар программасы белән тәңгәл килә һәм түбәндәге таләпләрне куя: 1) бөтен хакимиятне эшче, крестьян һәм солдат депутатлары Советына бирергә; 2) кичекмәстән җирне крестьяннарга бирергә; 3) дума һәм губерна советын таратырга; 4) элекке хөкүмәт белән аның союзниклары арасында килешүләрне гамәлдән чыгарырга; 5) сугышны туктатырга.

1917 елның ноябрь аенда М. Солтангалиев большевиклар партиясе сафына баса.

А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеже фикеренчә, Керенский хөкүмәте бәреп төшерелү белән гражданнар сугышы башланган вакыт аралыгында Солтангалиев автономлы мөселман коммунистлар оешмасы төзүне уйлаган. «Без бу турыда аермачык кына белмәсәк тә, милли коммунизм доктринасы ахыр чиктә аның гомум фикерләвендә булуы ихтималлылыгына шик юк»,— дип язалар алар (1; 100 б.).

Бу мәсьәләгә М. Абдуллин белән С. Батыевның карашлары бик кискен. «Мәгълүм булганча,— дип яза алар,— буржуаз пропаганда нигезсез рәвештә «мөселман милли коммунисты» итеп санаган бу кеше коммунизмнан бик ерак иде» (2; 73). «...Солтангалиев үзенең милләтчел фикерләвен марксистик фразеология белән яшерергә маташты... Коммунистлар партиясенә кереп, Солтангалиев бары тик тышкы яктан гына «бизәлде». Ул марксист булмады. Аңа дөрес характеристика биреп, безнең партиянең күренекле эшлеклесе С. Орджоникидзе 1923 елда болай диде: «...Теге яки бу мөселман интеллигентының реакциягә каршы көрәштә катнашуы... әле бер нәрсә дә аңлатмый. Бу әле коммунист булу дигән сүз түгел. Димәк ки, бу безнең юлдаш кына булу» (2; 125).

Әлеге ике автор раславынча, Мирсәет Солтангалиев «татарлар арасында сыйнфый аерымлану факты»н кире каккан. Моны дәлилләргә тырышып, алар болай диләр: «Аның фикеренчә, татарлар арасында сыйнфый яктан көчле аерымлану бары тик... 1918 елда гына башлана. Шуның белән бергә, Солтангалиев татарларда пролетариат һәм буржуазияне, алар арасындагы көрәшне кире кага» (2; 125). Аерым җөмләләргә генә алынган тулы текст Солтангалиев язмасында исә башкачарак яңгырый: «Бу органнарны бетергәннән соң (ягъни кискен сыйнфый көрәш барышында татар пролетариаты тарафыннан татар буржуазиясенең сәяси органнары бетерелүе — А. С.) татарларның сәяси тормышында яңа эра — көчле сыйнфый бүленеш чоры башлана. Бу эш ике юнәлештә алып барыла: татар авылында сыйнфый бүленеш һәм хезмәт ияләрен Кызыл Армиягә тарту. Беренче бурычның үтәүне мөселман (татар һәм башкорт) комиссариатлары үз өсләренә алдылар, ә икенчесен — хәрби эшләр буенча Халык Комиссариаты каршындагы Үзәк (татар) хәрби коллегиясе» (3; 36). Күренүенчә, сүз социаль процесслар, пролетариат һәм буржуазия барлыкка килү турында түгел, ә бары тик мөселман комиссариатларының татар авылында үткәрелгән сәяси эшләре һәм Үзәк хәрби коллегиясенең авыл ярлылары арасында сыйнфый үзаңны күтәрү, аларны Кызыл Армиягә җәлеп итү максатларын тормышка ашыру турында бара. Татарларның сәяси тормышында сыйнфый бүленешнең көчәю вакыты — гражданнар сугышы чорында «аклар» яки «кызыллар» ягында булыргамы, дигән төгәл сорауның крестьян алдына куелган вакыты була.

И. Таһиров, Солтангалиевнең матбугатта басылган чыгышларына нигезләнеп, аның үз милләттәшләре арасындагы сыйнфый аермалыкларны гына түгел, ә сыйнфый капма-каршылыкларны да исбатлавы турында яза: «Татарлар арасындагы сыйнфый көрәшкә багышлап шул чорда язган барлык мәкаләләре дә татарлар сыйнфыйлыкны белмәгән бердәм халык дигән уйдырмаларны фаш итүгә юнәлтелгән»,— (4; 164). Шуңа күрә дә милләтчеләрнең аны марксизмга якыная барганы өчен аларны милләт дошманы, сатлык итеп күрүләр бер дә гайре табигый түгел. Мондый яла ягуларга Солтангалиев «Кояш» газетасында болай дип җавап бирә: «Мин аларга милләтемне сатар өчен, аның канын эчәр өчен бармыйм — юк, юк!» (4; 164).

Казанда Октябрь революциясе көннәрендә Солтангалиев һәрвакыт Мулланур Вахитов белән бергә була, татар хезмәт ияләре һәм революцион солдатлар арасында оештыру эшләре алып бара. «Бу фактны аеруча билгеләп үтәргә кирәк,— дип яза И. Таһиров,— чөнки татарлар революциягә бернинди дә өлеш кертмәделәр дигән сүзне соңга табанлыкны итеп күрсәтәләр» (2; 164).

1917 елның октябрендә И. Сталин җитәкчелегендәге Милләтләр эше буенча Халык комиссариаты төзелә. Бу комиссариатның мөселман секциясен җитәкләү өчен ул Солтангалиевне чакыра. Соңгысының сәяси карьерасында бу кискен борылыш була. Чөнки «Сталин 1918 елда инде большевиклар һәм хәтта

марксизмны таныган мөселманнар белән берлегенең бары тик вакытлыча гына булуын, соңгыларын юк итүнең кирәклеге турында яхшы белгән» (1; 105).

Озакламый Сталин Солтангалиевкә илдә мөселманнар яшәгән барлык төбәкләрдәге хәлләр белән якыннан танышу эшен йөкли. Солтангалиев Көнбатыш Себер, Кырым, Төньяк Кавказ, Төркстан якларында була. «Кызганыч,— дип билгелиләр А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеже,— аның бу турыдагы язмалары Милләтләр эше буенча Халык комиссариаты архивларында ята, ләкин аларга Көнбатыш галимнәренә дә, совет тарихчыларына да үтеп керергә мөмкин түгел. Шунысы бәхәссез, бу сәфәр Солтангалиевкә урындагы урыс большевикларының мөселманнарга карата «дингә ышанучылар» һәм «пролетар булмаган элемент» буларак үткәрелгән тәкәббер колониячел тәртипләрен яхшы аңларга ярдәм итә» (1; 106).

Милләтләр эше буенча Халык комиссариатында М. Солтангалиевнең абруе нык үсә. Халык комиссарлары Советының 1918 ел, 15 февраль декреты белән бу комиссариатта Сталин җитәкчелегендә идеология эше буенча коллегия төзелгәч, ул аның составына кертелә. 1918 елның 19 гыйнварында биредә шулай ук әчке Россия һәм Себер мөселманнары эше буенча Үзәк комиссариат төзелә, рәисе итеп М. Вахитов, аның урынбасарлары — язучы Г. Ибраһимов һәм Ш. Манатов тәгаенләнә. 1918 елның июнь аеннан бирле комиссариатта РКП(б) вәкиле сыйфатында Солтангалиев эшли. «Бу орган Россиядәге мөселманнарны «большевиклаштыру» һәм сәясәтләштерүгә зур өлеш кертә...» (1; 107). Мөселман комиссариаты, Россия мөселманнары тормышының төрле тармаклары белән кызыксынучан буларак, үзендә хезмәт, авыл хуҗалыгы, промышленность, мәгариф, матбугат, финанс, хокук, армия, халыкара пропаганда бүлекләре булдырып, эшчәнлеген шактый киң төбәкләрдә җәелдерә. 1918 елның җәендә Россиянең егерме алты зур шәһәрләрендә аның филиаллары була.

1918 елда Халык комиссариатлары Советының декреты белән теоретик яктан — хәрби эшләр буенча Халык комиссариатына, ә фактик яктан Мөселман комиссариатына буйсынган Үзәк мөселман Коллегиясе төзелә. Аның беренче рәисе итеп Солтангалиев билгеләнә, Вахитов әгъзалардан берсе була.

Мөселман комиссариаты Советлар Россиясендә яшәүче мөселманнар арасында матбугат аша сәяси пропаганда алып бара. Бу комиссариат тарафыннан 1918 елның гыйнвар-ноябрь айларында,ягъни ун ай эчендә, дүрт миллион данә белән татар телендә газета бастырылып таратыла. Мәскәүдә «Чулпан», «Эш», мөселман гаскәриләр өчен «Кызыл Армия» газеталары чыга. Болардан гайре башка төбәкләрдәге мөселман комиссариатлары үз газеталарын чыгаралар. Мәсәлән, Казанда «Эш», Уфада «Көрәш», Әстерханда «Тартыш» — шундыйлардан, Солтангалиев шушы зур идеологик эш белән идарә итүдә үзенең талантын, журналистлык тәҗрибәсен киң куллана, марксизм әдәбиятын татар теленә тәрҗемә итә.

1918 елның 8 марты. Мәскәүдә М. Солтангалиев һәм М. Вахитов оештырган Россия мөселман хезмәт ияләренең Конференциясе ачыла. Егерме көнгә сузылган бу Конференциядә Казан, Мәскәү, Петроград, Архангельск, Мурманск, Сәмәрканд, Коканд кебек шәһәрләрдә н вәкилләр катнаша. Алар, Казандагы Үзәк мөселман социалист-коммунистлар комитеты үрнәгендә, мөселман социалист-коммунистлар комитетлары төзү мәсьәләләрен карыйлар.

А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеже фикеренчә, «Мөселман социалистик коммунистлар партиясе... Россия компартиясенә бәйле булмый һәм коммунистлар өчен генә төзелми». (1; 111). Казандагы Социалистик комитетка охшаш буларак, ул «коммунистлар партиясе программасы әзме-күпме дәрәҗәдә таныган бөтен мөселман революционерларының органы иде» (1; 111).

Солтангалиевнең иң якын тарафдарларыннан берсе булган Борһан Мансуров тәкъдиме буенча, яңа оешкан партиянең Үзәк Комитеты сайлана. Аның рәисе — М. Вахитов. Бу уникe кешелек коллегия «Россиядәге бөтен мөселман оешмаларының контроль органы булырга тиеш була» (1; 111).

1918 елның гыйнвар аенда Казанда икенче Бөтенроссия мөселман хәрби корылтае үткәрелә. Аның эшендә мөселман (татар) полкларыннан, руханилардан, татар һәм башкорт сәяси оешмаларыннан, шулай ук Урта Идел төбәгендә яшәүче мөселман булмаган башка халыклардан — мари, удмурт, чуваш, мордвалардан барысы 150 делегат катнаша. Корылтайда катнашучыларның күпчелеген социалистлар, уң эсерлар, меньшевиклар, кадетлар тәшкил итә, ә утыз делегаттан гыйбарәт булган большевиклар азчылыкта кала. Биредә төп бәхәс Идел-Урал штатлары төзү мәсьәләсе тирәсендә кызып китә.

Әле 1917 елның ноябрендә Мәскәүдә үткәрелгән, Милләт мәҗлесендә үк Идел-Урал штатлары исемле федератив дәүләт төзү турында фикер әйтелә.

1917 елның декабрь аенда, Уфада, башкаласы Казан булган Идел-Урал штатлары игълан ителә. Аның җирләре Урта Идел, Урал алды һәм хәзерге Казакъстанның бер өлешен тәшкил итәргә тиеш була. Штатлар төзү буенча коллегия 1918 елның гыйнварында Казанга килә һәм шәһәрнең Болак елгасы артында урнаша. Күп тә үтми, анда «Болак арты республикасы» оеша.

Шул елның 21 февралендә Казан Советы Солтангалиев рәислегендә Мөселман комиссариаты төзи, ә биш көннән соң аның революцион штабы барлыкка килә. Казан хәрби хәлдә дип игълан ителә, «Болак артындагылар»ның шура әгъзалары кулга алына, меньшевиклар һәм уң эсерлар чыгарып килгән газеталар ябыла. 22 мартта матбугат битләрендә «Татар-Башкорт Совет Республикасы турында положение» басыла, 28 мартта исә Казан Советы үтенече белән Мәскәүдән өч йөзләп Кронштадт моряклары килеп төшә. Икенче көнне «Болак арты республикасы» яшәүдән туктый.

1918 елның маенда Мәскәүдә РКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан Татар-Башкорт Совет Республикасының Раслау (Учредительный) съездына әзерлек киңәшмәсе чакырыла. Киңәшмәнең рәисе Сталин, аның ярдәмчеләре Солтангалиев һәм Вахитов була. Биредә Раслау съездын Уфада үткәрү турында карар кабул ителә һәм, аңа әзерлек эшләре алып бару өчен, башында Вахитов торган җиде кешелек комиссия төзелә. Ләкин гражданнар сугышы комиссиянең эшен өзеп тора. Ә аннан соң түбәндәге вакыйгалар булып үтә: Совет хөкүмәте белән Әхмәтзәки Вәлиди арасындагы килешү нигезендә, башкаласы Эстәрлетамак булган Башкорт Совет Республикасы төзелә; РКП(б) ҮК Политбюросы милләтләр буенча Халык комиссариатының 1918 ел, 22 март декретын («Татар-Башкорт Совет Республикасы турындагы положение») кире кага һәм партия әгъзаларына алга таба ТБСР өчен агитация үткәрүдән тыелып торырга тәкъдим итә; 1920 елның 27 маенда Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты (ВЦИК) һәм Халык комиссарлары Советы Татарстан республикасы оештырылуы турында декрет бастырып чыгара.

«Солтангалиев һәм аның фикердәшләре,— дип яза «Татарстан АССР: чынбарлык һәм буржуаз мифлар» китабы авторлары,— үзләренең гегемонлык планнарыннан чыгып, аерым башкорт автономиясе оештырылу турында ишетергә дә теләмәделәр. Совет хөкүмәте белән башкорт милләтчел хөкүмәте арасындагы килешү нигезендә совет автономиясе төзү солтангалиевчеләрдә тискәре реакция тудырды. 1919 елның 27 февралендә, аклар сафында булган башкорт гаскәрләре Кызыл Армия ягына чыкканнан соң, Солтангалиев туры элемгә аша Зәки Вәлидов белән сөйләшкәндә болай ди: «Син бик нык ашыктың, син юкка большевиклар ягына чыктың һәм моның белән эшне боздың...» «Эш» дигәндә, Солтангалиев берләштерелгән татар-башкорт дәүләте төзү идеясен күз алдында тота» (5; 129—130).

Солтангалиевнең бу идеяга бәйле омтылышлары ул вакытта әле көчендә булган «Татар-Башкорт Совет Республикасы турында положение» белән тулысынча тәңгәл килә. Әгәр дә бу омтылышлар милләтчелек һәм гегемонлык дип исәпләнсә, шундый ук, хәтта аннан да зуррак нигез белән мондый карашларны Мулланур Вахитовка да хас итеп күрсәтергә мөмкин булыр иде. Чөнки М. Абдуллин белән С. Батыев аны «бозык милләтчел идеологиягә» (5; 73) каршы көрәшче сыйфатында сурәтлиләр. Ә бит ТБСРның Раслау съездына әзерлек комиссиясе белән җитәкчелек итү эше нәкъ аңа йөкләтелә.

ТБСР төзү турында декретны халыкка җиткереп һәм аны гамәлдән чыгарып, Башкорт республикасын игълан итүгә нибары уник ай вакыт үтә. М. Роденсон моны «Колчак һәм чехлар җиңелгәннән соң Идел һәм Урал буе мөселманнарының ярдәме бик үк кирәкми башлый» (4; 856) дигән фикер белән аңлата. Болай әйтүнең нигезе дә бар, чөнки РСФСРның Халык комиссарлары Советы һәм Мөселман комитеты гражданнар сугышы башланганда «Барлык мөселман хезмәт ияләренә!» дигән өндәмә белән чыгалар. Анда ТБСР төзү идеясенең тормышка ашуы татар һәм башкортларның ак чехларга каршы коралллы күтәрелешенә турыдан-туры бәйле итеп куелган: «Кадерле иптәшләр, әгәр сез газаплар эчендә туган Татар-Башкорт Совет Республикасының ирекле гражданнары буласыгыз килсә, сезнең күңелләрегездәге өметләр миллионлаган җәберләнгән һәм кимсетелгәннәрнең өметләре белән бергә булса, мөселман социалистик армиянең кызыл байрагы янына ашыгыгыз» (5; 105). Әмма француз галименең саклык белән әйтелгән бу фикере М. Абдуллин һәм С. Батыев тарафыннан кискен тәнкыйть ителә. «М. Роденсон,— диләр алар,— Совет хөкүмәтен үзенең вәгъдәсен бозуда гаепли», ләкин «адресы белән нык ялгыша: хезмәт ияләрен риялы вәгъдәләр белән алдау ысуллары Совет хөкүмәтенә түгел, ә буржуаз хөкүмәткә хас» (5; 106).

Әлеге мәсьәлә белән шөгыльләнүче башка галимнәр, аерым алганда А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеженең фикерләре дә, бу авторлар тарафыннан инкяр ителә. Чөнки, Көнбатыш галимнәре язганча, «1920 елда Советлар җиңүе тәэмин ителгәч», Татар-Башкорт Совет Республикасы төзү проектына Сталин тарафыннан «буржуаз-милләтчел» (1; 121) дигән тамга салына.

М. Абдуллин белән С. Батыев аерым башкорт, аерым татар совет автономиясе төзелүне «күпчелек хезмәт ияләренә ярдәм, теләктәшлек өчен пролетариатның сыйнфый көрәше» белән аңлаталар, гәрчә хакимиятне яулап алганнан соң «бу көрәш башка формаларда дәвам итә» (5; 106) һәм «1919 елда аерым башкорт автономиясе төзүне күтәреп чыгып, партиянең ҮК һәм Совет хөкүмәте башкортларның татарларга булган ышанмаучанлыкларын юкка чыгару өчен нигез салдылар. Бу аңлатманы В. И. Ленинның С. Шаумянга язган хатыннан өзек белән ныгыталар: «...кайвакыт ирекле аерылудан соң күп бәйләнешләр барлыкка килә» (5; 112).

Биредә шунысы ачык түгел: нинди башкортларның нинди татарларга карата ышанмаучанлыгы турында сүз бара соң? Аны М. Абдуллин белән С. Батыев «изүче сыйныфларга гына каршы көрәш алып бармыйча, гомумән, башка милләтләргә дә дошманлык тудыручы башкорт буржуаз милләтчеләре» (5; 111) карашлары белән бер итеп күрсәтәләр. «Башкортстанның милли буржуазиясен татар буржуазиясенең башка төрки халыклар өстеннән гегемонлык урнаштыру курсы канәгатьләндермәде, чөнки ул «үзенең» массасы белән җитәкчелеккә дәгъва белдерде», (5, 110) — дип раслаучы М. Абдуллин белән С. Батыевка фәкать шундый ышанмаучылыкны гына танырга туры килә.

Әйткәнебезчә, Татар-Башкорт республикасы проекты РКП(б) ҮК Политбюросының 1919 ел, 13 декабрь карары белән гамәлдән чыгарыла. Бу исә шушы ук елның 22 ноябрь—3 декабрьдә Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының икенче Бөтенроссия съездында бердәм ТБСР төзү буенча эшне дәвам итәргә кирәклеге турындагы карарның күпчелек тавыш белән кабул ителгән көннәрдән соң була. Шунысын да искә төшереп үтәргә кирәк: 1919 елның 23 мартында Башкорт автономиясе төзү, шулай ук бер ел элек кенә кабул ителгән «Россия Совет Федерациясенең Татар-Башкорт республикасы турындагы положение»гә каршы килә (ул 1918 елның 22 мартында расланып, 23 мартта «Правда» газетасында басыла).

1919 елның ноябрендәге РКП(б)ның беренче Башкортстан конференциясе «көчләп» ТБСР төзү «башкорт ярлыларының теләгенә каршы килә һәм татар пролетариаты, крестьяннары мәнфәгатенә туры килми»,— (5; 114) дигән белдерү белән чыга. Бу белдерү М. Абдуллин белән С. Батыев китабында да РКП(б) ҮК Политбюросының 1919 ел, 13 декабрь карарын аклау өчен китерелә, гәрчә алдагы унлап биттә ТБСР оештыру турында декрет «Идел һәм Урал буе хезмәт ияләренең революцион оешмаларында чагылыш тапкан мәнфәгатьләренә» (5; 104) җавап бирә, диелә.

И. Таһиров дөрес билгеләгәнчә, Татар-Башкорт республикасын төзү бөтен яктан да тәфсилле өйрәнелмәгән әле. ТБСР төзүне яклап Солтангалиев үзенең «гегемонлык планнарыннан чыга» (5; 129) дип тәкърарлыйлар М. Абдуллин белән С. Батыев. Имеш, Солтангалиев Көнчыгыштагы башка төрки халыкларга карата «татарларның культура миссиясе» Россиянең көнчыгышында яшәүче халыкларны «татар буржуаз милләтенә» буйсындырып тоту өчен «төрки халыкларны рухи һәм мәдәни үзәк буларак Казанга юнәлтеп торуның һәрвакыт кирәклеге» (5; 124—125) турында әйткән.

Татарларның «культура миссиясе»нә һәм мөселманнарның «рухи һәм мәдәни үзәге Казан»га килгәндә исә Солтангалиев, төрки халыклар һәм мөселманнарга мәҗбүри юнәлеш тагудан, гомумән, ерак торган. «Казан элек-электән Россия мөселманнарының сәяси һәм рухи-мәдәни үзәге исәпләнә, биредә зур мәдәни көчләр тупланган» (5; 12) дигән сүзләрен бозып күрсәтү, шулай ук мәгънәсезлек. «Татарларның культура миссиясе» мәгънәсез Солтангалиевнең түбәндәге фикереннән ул болай аңлашыла: «Татарстан барлыкка китергән барлык мәдәни көчләр алга таба да безнең башка Көнчыгыш окраиналарда мәдәният үстерүдә пионер булып торалар. Без әле үк Урал, Себер, Урта Азия, Төркстан, Хива һәм Бохара төбәкләреннән, хәтта ерак Әфганстаннан Татарстанга мәдәният хезмәткәрләре: укытучылар, журналистлар һ. б. җибәрүне сорап килүгә шаһит булып торабыз. Бу сәбәпле татар работникларына да кискен кризис сизелә: Татарстан хәлсезләнә» (3; 40).

Болар барысы да М. Абдуллин белән С. Батыев өчен бер әйберне белдерә: «культура миссиясе» формулировкасы артында Солтангалиевнең Россия көнчыгышындагы халыкларны татар буржуаз милләтенә бәйле хәлгә кую макса-

ты яшерелгән (5; 124—125). Алга таба аларның язмаларында түбәндәгеләрне укыйбыз: «Татар-Башкорт республикасы төзү Солтангалиевнең соңгы максаты булмаган — ул аны Идел буе, Урал, Казакъстан һәм Урта Азияне үз составына алган Туран республикасы төзергә бер аралык итеп караган» (5; 130). «Шулай итеп, Солтангалиевнең концепсиясе үтәдән-үтә панисламизм һәм пантюркизм белән сугарылган. Аларны яшерү өчен Солтангалиев үзенең милләтчел фикерләрен марксистик фразеология белән капларга тырыша» (5; 125),— дип, «солтангалиевчелек» турындагы фикерләренә нәтиҗә ясый әлеге ике автор.

М. Абдуллин белән С. Батыевның бердәнбер дөреслек фикере шунда — ТБСР төзү Солтангалиевнең соңгы максаты булмый. Аның бу турыдагы карашлары М. Вахитов карашлары белән тәңгәл килә. Эш шунда, 1918 елның апрель ае азагында Вахитов Казанда губерна мөселман коммунистларының һәм теләктәшлек белдерүчеләрнең ТБСР төзү буенча киңәшмәсен үткәрә. Делегатлар зур күтәренкелек белән теләктәшлек өчен Ленин һәм Сталинга рәхмәт белдерелгән резолюциягә тавыш бирәләр, Татар-Башкорт республикасын Көнчыгыштагы социалистик революциягә очкыннар чәчүче учак итеп күрергә телиләр. Тик Вахитов һәм Солтангалиевнең бу фикере шул вакытларда ук каршылыкка очрый.

Көнбатышта пролетар революциянең триумфаль рәвештә җиңәчәге турындагы уй партия җитәкчеләренең башыннан китмәгән бер вакытта, Солтангалиев бу мәсьәләгә карата үзенең карашларын язып чыга. Аның бу карашы «Социалистик революция һәм «Шәрык» дигән мәкаләсендә ачык чагылыш таба. Әлеге мәкаләнең өч өлеше Милләтләр эше буенча Халык комиссариаты органы булган «Жизнь национальностей» журналының 1919 елгы октябрь һәм ноябрь саннарында дөнья күрә. Соңгы өлешенең азагында дәвамы алдагы саннарда басылачагы турында хәбәр ителсә дә, Солтангалиевнең бу мәкаләсе тулысынча басылмыйча кала. Чөнки мәкаләдә большевиклар сәясәтенә анализ ясала.

Мәкалә Россиядәге социаль революция бөтендөнья революциясенең, халыкара пролетариат белән империализм арасындагы хәлиткеч алышның башлангычы, ә Россиядәге якынлашып килүче гражданнар сугышының чикләре киңәергә, бөтен илләрне каплап алырга тиешлеген бәян итүдән башлана. Аннан соң ул икенчел итеп кенә каралган «Шәрык мәсьәләсе»нә булган мөнәсәбәт белән килешмәүчәнлеген белдерә.

Солтангалиев, үз заманының барлык коммунистлары кебек үк, «Совет корылышы» белән «буржуаз-капиталистик дәүләтчелек»нең үзара тыныч яшәү мөмкинлеген кире кага. «Алар вакытлыча гына бер-берсенә карата теге яки бу якта көчләрнең өстенлек алуына кадәр генә түзеп тора ала, ә аннан соң шул моментта көчсезрәк якка көчлесенең һөҗүм итүе котылгысыз» (3; 15) — ди.

Социаль-икътисади күзлектән караганда, Шәрык «бөтенләй диярлек» Көнбатыш Европа буржуазиясенең изү объекты һәм авыр промышленностеның «төп чимал чыганагы» булып тора. «Ак тәнлеләрнең» матди байлыклары гына түгел, рухи хәзинәләренең дә бихисап өлеше барлык раса һәм милләтләрне, җирле халыкларны талау хисабына тупланган. «Европалыларның үзләре «ачкан» Америкада кылган барлык гамәлләре каршында Аксак Тимер, Чыңгызхан һәм башка монгол ханнарының Европага ясаган һөҗүме үзенең рәхимсезлеге, һәлакәтлеге белән бик нык калыша»,— дип яза М. Солтангалиев (3; 19—20).

Солтангалиев Шәрыкнең үзендә милли буржуазия изүне дә онытмаска кирәклеген ассызыклап үтә. «Халыкара революциянең Шәрыкка кагылышлы ягын, ягъни анда Көнбатыш Европа империализмын юк итү белән генә тәмамланырга тиеш түгеллеген без бер генә минутка да күз уңыннан ычкындырырга тиеш түгелбез. Ул алга таба да дәвам итәргә тиеш, чөнки Шәрык алдында торган бу этаптан соң үз-үзен саклап калу өчен тиз арада тиешле вакытка кадәр либераль булып кылануы позициясен үзгәртә торган, ә асылда залим һәм клерикаль-феодал үз буржуазиясен юк итү мәсьәләсе тора» (3; 22) —, ди ул бу турыда.

Бу мәсьәләгә тукталып, «Татарстан АССР: чынбарлык һәм буржуаз мифлар» китабы авторлары анда бирелгән концепция «бөтендөнья империализмына ясалган соңгы удар, янәсе, Шәрык халыкларының милли-азатлык хәрәкәтенә дә бәрелә, Солтангалиевчә, милли-демократик революция һәм колониаль системаны юк итү халыкара империализмның автоматик рәвештә җимерелүен китерә» дигән фикердән чыккан дип раслыйлар. «Шәрыкне югалткан, Һиндстан, Әфганстан, Персия һәм Азия, Африкадагы колонияләреннән аерылган,

Көнбатыш Европа империализмы,— дип белдерә ул,— тончыгырга һәм үзенең табигый үлеме белән үләргә тиеш». Бу концепциягә нигезләнеп, Солтангалиев барлык илләрнең революционерлары игътибарын Көнбатышка түгел, ә янәсе халыкара империализм язмышы хәл ителгән Шәрыкка юнәлтә... Солтангалиевнең бу карашлары турында укыгач, әйтерсең лә «революцион давылларның үзәге Шәрыккә күчте, хәзердән башлап «Шәрыктән искән җил Көнбатыштан искән җилне бастыра» дигән әлеге заман маоистик вәгазьләр белән эш иткәндәй хис итәсең һ. б.» (5; 127).

М. Абдуллин белән С. Батыев бу нәтиҗәләрне үзләре тынкыйть иткән революционерның мәкаләсеннән, гәрчә аны алар үз күзләре белән күрмәсәләр дә, алынган бердәнбер фразага нигезләнеп ясыйлар (алар бу цитатаны Л. Рубинштейн хезмәте буенча китерәләр). Дөресен әйткәндә, бу фраза чынлыкта исә мондый контекстта яңгырый: «Без һәрвакыт һәм нык итеп шуны истә тотарга тиешбез: Шәрык бөтенләе белән халыкара империализмының нигездә туплану чыганагы булып тора һәм бу мөнәсәбәттә бөтендөнья социалистик гражданнар сугышы шартларында безнең алар белән бәрелешү факторы ахыр чиктә безгә дә, халыкара империалистларга отышлы түгел. Шәрыкне югалткан һәм Һиндстан, Әфганстан, Персия, Азия һәм Африкадагы башка колонияләреннән аерылган Көнбатыш Европа империализмы тончыгырга һәм үзенең табигый үлеме белән үләргә тиеш» (3; 22) (ассызык минеке — А. С.).

Китерелгән өземтәдән күренгәнчә, үзенең колонияләрен югалткан империализмның автоматик рәвештә юкка чыгуы турында биредә берниндн дә сүз бармый. Солтангалиев фикеренчә, колонияләр Көнбатыш Европа буржуазиясен ясалма рәвештә тукландырып килделәр һәм аның гомерен озынайттылар, ә аларны югалту белән капиталистлар хәзер табигый рәвештә (тик «автоматик» түгел), ягъни бөтендөнья социаль революциясе барышында үлемгә дучар ителәчәк. Бу мәгънәдә Солтангалиевнең «Азәрбайҗан совет республикасы игълан ителүгә карата» дигән мәкаләсендә әйтелгәнне дә билгеләп үтәргә мөмкин: «Без ышанабыз, тиздән Шәрыкнең җәфа чигүче ач һәм ялангач халык массалары Көнбатыш Европа буржуазиясе ясалма рәвештә кидергән авыр богауларны салып ташлаячак һәм моның белән алар Көнбатыш Европа пролетариатының азат булуына ярдәм итәчәкләр» (3; 71).

«Колониаль җәмгыятьтә барлык сыйныфлар да капитализм тарафыннан изелгәч, янәсе алар барысы да «пролетариат дип аталырга хаклары бар» дигән тезисы белән Солтангалиев барлык изелүче халыкларның да халыкара пролетариат белән берләшергә тиешлеге турындагы Ленинның даһи идеясен фактик яктан сызып ташлады» дигән белдерү дә чиктән тыш доктриналы төсмер ала. Шулай итеп, марксистик аңлатмадагы «пролетариат» терминын вак буржуаз термины белән алыштырып, Солтангалиев милли-азатлык хәрәкәтендә пролетар җитәкчелекнең кирәксезлеге турындагы нәтиҗәгә юл ачты. Марксизм-ленинизм белән азмы-күпме дәрәҗәдә таныш булган укучының күзенә бу шулкадәр бәрелә ки, хәтта ревизионист Р. Гароди Солтангалиевнең тезисын «милләтчелек», «марксистик анализның фундаменталь принципларына ят» (5; 128) дип әйтергә мәҗбүр була,— диләр М. Абдуллин белән С. Батыев.

Солтангалиев изелгән халык белән халыкара пролетариатның берлеге кирәклеге турындагы фикерне кире какмый. Киресенчә, ул бу идеяне үз заманында популяр публицистикада ассызыклап үтә. Шулай ук пролетариатның җитәкче роле турындагы Ленин идеясен Солтангалиев «милли-азатлык хәрәкәтенә җитәкчелекне Совет Россиясендәге Шәрыкнең алдынгы халыкларына тапшыру (мәсәлән, татарларга)» (5; 128) дигән фикер белән алыштырган дигән тезисның да абсурд булуын билгеләп үтәргә кирәк.

Ниһаять, «аның халыкара эшчеләр сыйныфының революцион сәләтсезлегенә тирән ышанмаучанлыгы» (5; 128) турында. Бу сүзләрдә, гомумән, ниндидер рациональ орлык бар икән, моны Россиядәге социаль революциягә Көнбатышның алга киткән илләрендәге социаль революцияләр белән ярдәм итү мөмкин булмаячагын Солтангалиев яхшы аңлаган дип кабул итәргә кирәк.

Шуны да искә төшереп үтү урынлы булыр, Солтангалиевчә, метрополиядәге буржуазия пролетариатның икътисади таләпләрен канәгатьләндереп, аларның капиталистларга каршы актив чыгышларын йомшарта. Ләкин Солтангалиев бу очракта «метрополияләрдәге эшчеләр массасы» белән империа-

лизмның» аерым бәрелешүләре» турында сүз алып бара. Капиталистлар белән эшчеләр сыйныфы арасында сәяси нигездә гомум капма-каршылыкны ул күрмәде, чөнки андый нәрсә булмады да.

Мәсьәләне бары тик Солтангалиевнең Шәрык һәм аның бөтендөнья социаль революциядәге роле турындагы гипотезасы чынбарлыкка никадәр туры килүе турында кую дөресрәк булыр иде. Бөтендөнья революцион процессның Октябрь революциясеннән соңгы мөһим уңышлары һәм бөтендөнья социалистик системаның барлыкка килүе, беренче чиратта аеруча Азия, Африка һәм Латин Америкасы илләрендә милли-азатлык көрәшенең үсешенә бәйле булуы турындагы аның гөман итүләре пәйгамбәрләрчә алдан күрү кебек иде. Ләкин аның хатасы шулкадәр генә, бу илләрдә колонияләрнең бетерелүе элекке метрополияләрдә эшчеләр сыйныфының күтәрелешен барлыкка китермәде һәм китерми.

Солтангалиев теориясенең көчле һәм көчсез яклары революцион практика белән турыдан-туры һәм көнүзәк мәсьәләләргә үз вакытында җавап бирү ихтыяҗы белән барлыкка килүенә бәйле. Аның анализларының бер өлкәсе шулкадәр тирән һәм төгәл ки, аның кирәклеге һәм масштабы белән ул бары тик безнең көннәрдә генә ачыла. Бу өлкә — Исламны җәмгыятьнең революцион яңарту контекстында карау. Ул әлеге мәсьәләгә 1922 елда Мәскәүдә милләтара Халык комиссариаты тарафыннан брошюра итеп чыгарылган, 1921 елда «Жизнь национальностей» журналының ике санында дөнья күргән «Мөселманнар арасында дингә каршы көрәш методлары» дигән мәкаләдә тирән анализ ясый.

Мәкалә Исламның килеп чыгышын, аның яшәүчәнлеген һәм көчле тәэсир ясаучанлыгын бәян итү белән башлана. Исламның чагыштырмача яшь дин икәнлеге һәм яшәүчәнлеге аңарда гражданлык-сәяси элементларның булуы белән бәйләп күрсәтелә. Ислам бөтен нечкәлекләре белән эшкәртелгән шәригать кануннары нигезендә мөселманнар тормышының барлык якларын җайга сала. Шунысын да әйтеп үтү кирәк, мөселман хокугында дингә ышанучыларның тормыш корылышы күп кенә позитив яклар белән чагылыш тапкан: мәҗбүри белем алу, файдалы хезмәт белән шөгыльләнү, тәрбия мәсьәләләре, байлык артыннан кууны кире кагу, мөлкәтне әрәмшәрәм итмәү, исерткеч эчемлекләрне куллануны тыю, ришвәт алмау һ. б.

Исламның ныклыгы мөселман дин әһелләренең җәмгыятьтә төрле файдалы вазифалар башкаруына да бәйле: алар еш кына мөгаллим, табип, казый (судья) һ. б. булып та торганнар. «Шулай ук мөселман руханилары арасында сайлау-сайлану системасы булу да мөһим роль уйнаган. Бу исә аларны христиан руханиларына караганда яхшырак һәм ныграк биеклеккә куйган. Югарыдан куелган урыс дин әһеле, билгеле инде, үзенең диндарлары арасында азрак абруй казанган. Ә инде татар мулласы яисә үзбәк улемы үзләрен «халык хезмәтчеләре» итеп санаганнар, һәрвакыт халык сүзенә колак салып яшәгәннәр, попның урыс мужигы каршындагы халәтенә караганда, мәхәлләдә зур ихтирам казаналар һәм тәэсир көченә ияләр» (3; 44—45).

Россия чынбарлыгында мөселманнар арасында дингә каршы көрәшнең мәгънәсезлеге тирәнәя бара, чөнки пропагандист «Исламга каршы көрәшне» урыс миссионеры белән бердәй итеп гәүдәләндерә башлый.

«Ислам үз асылы белән башка диннәрдән аерылып тору сәбәпле, көрәшнең төрле методларын таләп итә, чөнки бу аңа ышанучы төрле халык үзенең табигый-тарихи һәм мәдәни-көнкүреш аерымлыклары, социаль-икътисади халәтенә бәйле, шуңа күрә дингә каршы көрәшнең татарларга яраганы кыргызларга ярамый, Россия мөселманнарына карата кулланылган Әфганстанда яки Бохарада яраксыз һәм киресенчә» (3; 65),— дип яза Солтангалиев.

Солтангалиевне бер үк вакытта милләтчелектә, пантюркизмда һәм панисламизмда гаепләргә маташу бөтенләй сафсата. Чөнки үз дәүләтендәге мөселманнар арасында гына түгел, ә аның чикләреннән тыш та яшәүче мөселманнар арасында дингә каршы пропаганда алып барырга чакыручы кеше берничек тә панисламист була алмый.

Янәсе, ул Туран дәүләте төзү идеясен сеңдерергә тырышкан, дигән уйдырмага таянып кына аны пантюркист дип бәяләү — шулай ук нигезсез. Пантюркизм — ул төрки телле халыкларны Төркия хакимияте астында берләштерү доктринасы. Солтангалиев беркайчан да Төркия хакимияте астында берләшергә чакырмый.

Биредә караган мәсьәләгә кагылып, И. Таһиров болай дип яза: «Солтангалиевнең фикеренчә, патша Россиясендә изелгән һәм кимсетелгән мөселман халыклары арасында хаклыкка беренче чиратта татарлар мохтаҗ иде. Шул ук вакытта ул татарларны Россиядән аерып карау турында уйламаган, минем тирән инануымча, бернинди дә Туран дәүләте төзү турында ниятләмәгән. Ул төрки һәм мөселман халыкларының бердәм демократик һәм социалистик Россиядә тату гаилә рәвешендә яшәүләрен теләгән. Табигый, бу беркем өчен дә сер түгел. Төрки халыкларның бертуганнар кебек итеп яшәргә омтылышларын пантюркизм дип әйтеп буламы соң? Юк, әлбәттә» (2; 172).

Солтангалиев тарафыннан эшләнгән программаны тормышка ашыру юлында торган каршылыкларның берсе, А. Беннигсен һәм С. Уимбаш фикеренең Европа социалистлары алдында милли мәсьәләнең икенчел дәрәҗәдә булуы һәм аның социализм җиңгән дөньяда үз үлеме белән үләчәгенә инанулары. Урыс социалистлары да, бигрәк тә большевиклар, милли социал партияләр төзүгә каршы чыгалар. Шунысын әйтергә кирәк, урыс социал-демократлары ике мөселман оешмасына карата түзеп тора алмаслык мөнәсәбәттә булалар: болар — башында Хөсәен Ямашев һәм Гафур Колахмәтов торган, 25-30 татар интеллигентлары һәм эшчеләре булган, большевистик юнәлеш тоткан «уралчылар» (1907 елның гыйнвар-апрель айларында Оренбургта чыккан «Урал» газетасына нисбәтән) һәм Бакуда урындагы мөселман социал-демократлар нигез салган большевистик юнәлештә булган «Гуммет» («Энергия») оешмасы (1920 елда бу оешма РКП(б) составына кушыла).

Солтангалиев һәм аның көрәштәшләре, марксистик кадрлар җитәрлек булмаса, мөселман коммунистларына алга таба эш алып бару мөмкин булмаячагын яхшы аңлыйлар. Шуның өчен 1918 елның 23 маенда Солтангалиев, Вахитов һәм Мөселман Үзәк Комиссариатының башка җитәкчеләре Казанда Бөтенроссия мөселман укытучыларының съездын чакыралар. Монда Үзәк гыйльми Мөселман Коллегиясе раслана һәм ул Казанда Мөселман университеты төзү, Шәрык музееи, Үзәк мөселман китапханәсен нигезләргә дигән проект кабул ителә (1; 122).

1918 елның 17—23 июнендә Казанда — Үзәк Мөселман Комиссариаты тарафыннан Казан, Мәскәү, Петроград, Әстерхан, Пермь, Самара, Урал, Сембер, Сарытау мөселман комитетлары вәкилләре катнашлыгында — мөселман коммунистларының Беренче конференциясе үткәрелә. РКП(б) әгъзасы булган делегатларның күпчелеге, оештыруның элеккеге формаларын калдырып, мөселман коммунистларының (большевикларның) Россия партиясен нигезләргә карар итәләр. Бу партия РКП(б)ның Уставын кабул итә, ягъни үзенең 11 әгъзадан торган ҮК урындагы мөселман коммунистлары бюросы белән автономлы булып кала. Бу карар РКП(б) җитәкчеләре тарафыннан кискен тәнкыйтьләнә, ә Сталин бу конференциягә буржуаз-милләтчелек чагылышы дигән мөһер суга (1; 123).

1918 елның сентябрендә Солтангалиев, коммунистик оешмаларның Үзәк бюросындагы иптәшләре белән бергә, Мәскәүдә Шәрык яшь коммунистларының беренче Бөтенроссия конференциясен үткәрә. Конференция Шәрык яшьләре арасында коммунистик идеяләрне пропагандалау өчен комсомолның Үзәк Шәрык бюросын төзү турында карар кабул итә. Солтангалиев җитәкчелек иткән бу бюро Шәрыктәге җирле комсомол бюролары белән җитәкчелек итәргә тиеш була. Шәрык мөселман халыкларын берләшүгә өндәп үткәрелгән әлеге конференциядә, А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеже билгеләп үткәнчә, «солтангалиевчелек»не «фаш» итүгә юнәлдерелгән соңгырак хезмәтләрнең авторлары тарафыннан, имеш, Солтангалиев беренче булып Коммунистик Колониаль Интернационал идеясен күтәреп чыкты, дигән ялган күрсәтмәләр бирелә.

Конференция тәмамланып күп тә үтмәстән, «Жизнь национальностей» журналында, комсомолда һәр милләт өчен ярым бәйсез оештыру аппараты төзергә маташып тупас хата җибәрделәр, дигән сүзләр язылган гаепләү мәкаләсе дөнья күрә. Комсомол ҮК катнашлыгы белән, Шәрык бюросы проекты гамәлдән чыгара.

1918 елның ноябрендә үткәрелгән мөселман коммунистларының Беренче съездында (Мәскәү) Солтангалиев рәислек итә. Съезда катнашучылар РКП(б)га үз мөнәсәбәтләрен белдерергә тиеш булалар. Солтангалиев һәм кырым-татар коммунистлары җитәкчеләреннән берсе И. Фирдәвес, Казан татарлары, кавказлылар, өлешчә башкортлар һәм Кырым татарлары делегатлары ярдәмендә, автономлы мөселман коммунистлар партиясен тануны

таләп итәргә тырышалар. Алар фикеренчә, үзләренең Үзәк Комитетларын саклап, РКП(б)га федератив нигездә кушылырга кирәк була. РКБ(б) белән мондый мөнәсәбәтләр, Солтангалиев сүзләренә караганда, колониаль сәясәткә каршы революция таләпләренә җавап бирә, чөнки Шәрыктә социализм идеяләрен пропагандалау белән урысларга караганда мөселманнар яхшырак шөгыльләнә.

Сталин автономия таләпләрен кире кага, ул аны үзәкләштерү принципларына һәм административ эффектлылыкка каршы килә, дип белдерә. Мөселман коммунистлар оешмаларын, аларның секцияләре бюросы белән бергә, РКП(б)ның бер секциясенә кертүдән көчне максималь туплауны күздә тотып, мөселман һәм мөселман булмаган коммунистларны берләштерүнең кирәклеген билгели. Ул йомгаклап болай ди: «...Партиянең хәбәр итү өчен ҮК миңа йөкләгән фикере менә шул» (5; 132).

А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеже билгеләвенчә, Сталин һәм Солтангалиев беренче тапкыр стратегик мәсьәләдә әнә шулай бәрелешәләр. Ләкин «өченче дөньядагы коммунистик хәрәкәтнең киләчәге һәм җитәкчелекне кем кулга алырга тиеш — урысларммы, әллә татарлармы, икенче термин белән әйткәндә — европалылармы, әллә азиатлармы, дигән сорауга җавап белән тәмамланырга тиешле төп бәхәс» (1; 133—134) тә офыкта инде өлгереп килә!..

Съезд, Сталин киңәше буенча, милли секцияләрне урындагы партия оешмаларына буйсындырылган хәлдә саклау өчен, мөселман коммунистларының (большевикларның) Россия партиясен РКП(б)ның Мөселман оешмасы дип исемләргә карар итә. РКП(б)ның мөселман оешмасы Үзәк бюросы яңа рәисе итеп Сталин сайлана, ә Солтангалиев бюроның биш әгъзасыннан берсе булып кала. Съезд шулай ук Үзәк мөселман комиссариатының эшен канәгатьләнерлек дип таба.

1919 елның март аенда үткәрелгән РКП(б)ның VIII съезды бөтен милли коммунистик оешмаларны бетерергә карар итә һәм мөселман оешмаларының Үзәк бюросы Шәрык халыкларының коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы дип алыштырыла.

Солтангалиев, мөселманнар арасыннан РКП(б) иерархиясендә югары постларны биләсә дә, «ярымдиссидент» булып кала. «Солтангалиев — өченче дөнья революциясенең атасы» дигән китапның авторлары раславынча, 1919 елның яз һәм җәй айларында аны еш кына Көнчыгыш фронтта, Кызыл Армиянең татар частьлары Колчак белән канкойгыч сугышлар алып барганда күрергә була. Ул мөселман революцион хәрәкәтендә мөстәкыйльлекне кайтару идеясен таратудан туктатмый. 1920 елның апрелендә Кызыл Армия Бакуны азат иткәч, Солтангалиев, Россия читләрендәге мөселман төбәкләрен кордон артындагы Шәрыкне коммунистик хәрәкәткә тарту өчен база итеп файдаланырга мөмкин икән, дигән фикергә килә.

Колониаль сәясәткә каршы революция һәм анда мөселман коммунистларының роле проблемасы Коминтернның 1920 елның июль аенда үткәрелгән IV Конгрессында кызу бәхәсләр тудыра. Биредә Солтангалиев Россия делегациясе сыйфатында катнаша. Бу проблема шушы елның сентябрендә Бакуда үткәрелгән Шәрык халыкларының Беренче съездында янә тикшерелә. Солтангалиев анда үзе катнаша алмаса да, мәгълүм булганча, аның идеяләрен казакъ делегаты Турар Рыскулов һәм Төркстан вәкиле Нарбутабеков (соңыннан алар икесе дә Сталин тарафыннан буржуаз-милләтче солтангалиевчеләр дип гаепләнә һәм 1938 елда атып үтерелә) яклап чыгалар.

Рыскулов, нигездә, тулаем рәвештә Шәрыктә коммунистик революциягә исәп тотарга ярамаганлыгын — чөнки ул анда милли һәм вак буржуаз төс алачагын, ләкин кирәк чакта социаль хәрәкәткә әйләнәчәген белдерә. Шәрыкнең эшче революцион оешмалары әле йомшак булу сәбәпле, җитәкчелекне вак буржуаз демократлар алырга тиеш, дип исәпли. Ул Нарбутабеков исә Солтангалиевнең, Көнбатыш пролетариаты бөтендөнья революциясенең яхшы элементы булса да, Россия революциясенә йогынты ясый алмый, шуның өчен вакытны бушка әрәм итмәстән, Шәрыкне акыл белән аның аерым социаль мәдәни һәм икътисади шартларына яраклы рәвештә оештырырга кирәк, дигән тезисын алга таба үстерә. «Шәрык» — ди ул,— Көнбатыштан бик аерыла һәм аның мәнфәгатьләре дә бүтән төрле, турыдан-туры коммунизм сеңдерергә тырышу анда каршылыкка юлыгырга мөмкин» (1; 152—154).

Мөселман делегатларының бу тәкъдимнәре Коминтерн җитәкчеләре Зиновьев, Радек һәм Бела Кун тарафыннан кире кагыла. Зиновьев һәм Бела Кун күрсәтмәсе белән, съезд болай дип белдерә: империализмга каршы милли-азатлык һәм урындагы феодалларга, буржуазиягә каршы социаль революцияләр бер үк вакытта булырга тиеш.

Шулай ук Европа делегатларының да күпчелеге колонияләрдәге революцион хәрәкәт белән җитәкчелек итүне радикаль вак буржуазиягә түгел, ә ярлы крестьяннарга тапшыру кирәклегенә басым ясыйлар. Шәрыктә промышленность пролетариаты булмау сәбәпле, Бела Кун күзаллавында, ярлы крестьян диктатурасы шул ук пролетариат диктатурасы булып аңлашылырга һәм Советларда җитәкчелек крестьяннар кулында булырга тиеш иде. Конгресс делегатлары Шәрыкне азат итү Көнбатыш пролетариатының җиңүеннән башка мөмкин түгеллеген раслыйлар. «Шул рәвешле татар коммунистларының Азиядә «үсештә булган революция» хыялы сүнә»,— дип яза А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеже (1; 156).

«Ни өчен соң Мәскәү җитәкчеләре, аерым алганда Сталин, ашыгыч рәвештә Солтангалиев теориясен кире кагалар, дигән сорау туарга мөмкин»,— дип яза әлеге авторлар. Куелган сорауга, алар фикеренчә, җавап өч төрле планда булырга мөмкин:

1) Интеллектуаль планда: җитәкче большевиклар Шәрыкне белмиләр һәм промышленность пролетариаты тарафыннан яклау тапмаган революцион хәрәкәткә битарафлык күрсәтәләр.

2) Сәяси планда: Солтангалиев Россиянең мөселманнар яшәгән җирен, бигрәк тә Казанны, Азиягә революция илтүдә сикерү басмасы итеп файдаланырга уйлаган. Бу үз чиратында татарларны Коминтернда чын-чынлап арадашчы ясар иде, ләкин урыслар аларга сәяси ышаныч белдермиләр.

3) Психологик планда: Сталин һәм РКП(б)ның башка урыс җитәкчеләренең килешә алмаучанлыгы үзәктән читтә булган мөселман төбәкләрендә мөстәкыйль яки үзәк аппарат белән яхшы ук җайлашмаган милли җитәкче аппаратларның булуын танырга теләүдән баш тартучы бюрократик рух белән сугарылган иде (1; 158—159).

Солтангалиевнең Шәрыктә социаль революцияне яклауга багышланган эшчәнлегенең икенче аспекты мөселман хәрби частьларын оештыру белән тыгыз бәйле. Әле Үзәк Мөселман Комиссариаты төзелгәнче үк барлыкка килгән беренче татар часте булып, нигездә, Алафузов һәм Дары заводы эшчеләреннән торган Казан кызылгвардиячеләр отряды санала. Ул 1917 елның декабрь аенда Беренче мөселман социалистик полкы итеп үзгәртелә. 1918 елның февраль аенда, «Болак арты республикасы»н тар-мар итү моментларында, полкта 600 дән артык кеше исәпләнә, ә шул ук елның июнь аенда инде берничә меңгә җитә. 1918 елның февраль-март айларында «Хәрби шура» частьларын тараткач, күпчелеге татар һәм башкорт булган, патша армиясе сафларында яхшы хәрби әзерлек үткән солдат һәм офицерлар коммунистлар карамагында кала. Әстерхандагы мөселман комиссариаты татар, казакъ, төрекмән, нугайлардан мөселман ротасы төзи. Пермь мөселман комиссариаты Уралдагы татар эшчеләреннән дүрт рота оештыра. Мәскәүдә М. Вахитов 1918 елның апрелендә Беренче татар-башкорт батальоны төзи. Бу батальон Казанда һәм Сызраньда чехословак легионерларына каршы сугышларда катнаша. 1918 елда татар, башкорт, төрекмән, үзбәкләрдән торган Икенче мөселман социалистик батальоны барлыкка килә. Шул ук елның июлендә ике татар укчы бригадасы, ике татар-башкорт укчы полкы һәм берничә батальоннан гыйбарәт 50 мең кешедән артык мөселман частьлары Колчак армиясенә каршы сугышларның алгы сызыкларында булалар (1; 125—126).

«Нәтиҗәдә, татар кызылармеецлары,— дип яза Солтангалиев,— күләм ягыннан бик зурайды: гражданнар сугышының иң кызган мәлләрендә Көнчыгыш һәм Төркстан фронтларында татар кызылармеецлары барлык гаскәрнең яртысыннан күбрәген тәшкил итте, хәтта 70—75 процентка (Бишенче Армиядә) җитте» (3; 37—38).

1918 елда, Мулланур Вахитов инициативасы белән, Үзәк мөселман комиссариаты каршында Төркия компартиясе Үзәк Комитетының булачак беренче рәисе Мостафа Сөбхи җитәкчелегендә Халыкара пропаганда бүлеге төзелә. Бу бүлек төрек, гарәп, фарсы телләрендә брошюралар, мөрәҗәгатьләр, листовкалар бастырырга, төрек телендә «Яңа дөнья» исемле журнал

чыгарырга һәм Төркиядә, гарәп илләрендә, Иранда, Һиндстанда революцион төркемнәр оештыру өчен мөселман агитаторлары әзерләргә тиеш була.

Төп игътибар Төркиягә юнәлтелә. 1918 елның июнь аенда Солтангалиев Мәскәүдә төрек социалистларының киңәшмәсен үткәрә, ә соңыннан Мостафа Сөбхи белән берлектә төрек хәрби әсирләреннән ике батальон оештыра. Бу батальоннар Көнчыгыш һәм Көньяк фронтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнаша. Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының Беренче съездында (1918 ел, ноябрь) төрек коммунистлары фракциясе үзенең резолюциясендә бөтендөнья революциясе факелын кабызу өчен Кавказдагы империалистларны куарга, ә моның өчен Төркиядә революция ясарга кирәк, дип билгеләләр (2; 168).

Биредә шуны әйтеп үтәргә кирәк, Солтангалиевнең бу эшчәнлеген кайвакыт аңа тагылган Мөселман Эшче-Крестьян Кызыл Армия төзү идеясе белән бәйлиләр, бу идеяне үз чиратында революцияне экспортлау итеп кузаллыйлар.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк. Интернационал Кызыл Армия частьлары кебек үк Шәрык Пролетар Кызыл Армиясе төзү турында Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының II съезды карарларында да әйтелә (1; 150). Дөрестән дә, Солтангалиевнеке итеп каралган проектта сүз урыслар, «Европа» гаскәрләре турында түгел, ә автономлы мөселман коммунистик оешмалары җитәкчелек иткән автономлы мөселман армиясе турында бара. Бу армия социалистик революцияне алдынгы илләрдән артта калган илләргә күчерү өчен түгел, ә халыкара империализмга каршы көрәштә уртак язмыш, уртак тарихи максатлар белән бәйләнгән халыклар арасында үзара хәрби ярдәмләшү өчен кирәк була. Әйтик, төрек ирекләләренең Кызыл Армия сафларында Көньяк фронттагы хәрби хәрәкәтләрен, алар ярдәмендә Якын Көнчыгышта революция таратуны яки алар ярдәмендә Кавказдан империалистларны кууны һәм үз илләрендә, Сөбхи фикеренчә, революция ясауны революция экспортлау дип әйтеп буламы соң?

1919 ел урталарыннан алып мөселман хәрби частьлары Солтангалиев җитәкчелек иткән Мөселман хәрби коллегиясе һәм Үзәк Мөселман комитеты күзәтүе астында була. «Ләкин, күреп үткәнебезчә, милли коммунистларның оештыру һәм җитәкчелек эшләре,— дип яза А. Беннигсен һәм С. Уимбаш,— 1918 елның азагына тулысы белән дип әйтерлек РКП(б) иерархиесенә буйсындырыла. Мәгълүм ки, милли хәрби оешмаларга каршы урыс большевиклары башлаган кампаниягә Сталин тарафыннан күрсәтмә бирелеп тора. 1918 елның азагында, мәсәлән, бөтен җирле коммунистик сәяси оешмалар РКП(б)га буйсындырылгач, бер үк вакытта бөтен мөселман полклары да тулысынча Кызыл Армия җитәкчелегенә буйсындырыла. Халык комиссарлары Советының 1919 ел, июнь аенда кабул ителгән декреты нигезендә, Мөселман хәрби коллегиясе юрисдикциясе фәкать Кызыл Армиянең хәрби әзерлек һәм тәэмин итү өлкәсенә генә кагылган Революцион хәрби Советы Сәяси идарәсенең Шәрык бүлеге итеп үзгәртелә» (7; 66).

Гражданнар сугышы азагына таба шул беленә: Солтангалиев һәм Вахитов тарафыннан Урта Иделдә аякка бастырылган барлык җитәкче һәм сәяси аппаратлар төрле хәрби хәрәкәтләр нәтиҗәсендә җимерелә. 1918—19 елларда төзелгән комиссариат, комитет һәм бюроларның күбесе юкка чыга, чехословак фетнәчеләре һәм колчакчылар белән хәлиткеч бәрелешләрдән соң мөселман кызыл частьлары бик нык сирәгәеп кала.

Моңа да карамастан, Солтангалиев үзенең оптимистлылыгын югалтмый. Ул Шәрык хезмәт ияләренең Коммунистик университетында (КУТВ) лекцияләр укый. «Бу абруйлы уку йорты III Интернационал җитәкчеләренең очрашу урыны була. Биредә Бухарин, Зиновьев, Павлович кебек ортодоксаль теоретиклар, Солтангалиев йогынтысын алган Турар Рыскулов, Нариман Нариманов, Әхмәд Байтурсын, Һиндстанлы Мобендра-Нат Рой кебек Шәрыкнең зур сәяси эшлеклеләре очрашалар. Университет тыңлаучылары арасында бөтен Азиядән килгән яшь революционерлар, соңыннан үз илләрендә күренекле җитәкчеләр булып киткән индонезияле Тан Малака, японлы Сен Катаяма, кытайлы Лю Шауцы, вьетнамлы Хо Ши Мин кебекләр дә була» (1; 165—166).

«Сәләтле теоретик буларак,— дип яза А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеже,— Солтангалиевнең дә теорияләре реалистик һәм практик юнәлештә булулары белән башка большевикларныкыннан аерылып тора... Өченче дөньяда революция бер үк вакытта социаль һәм шул ук вакытта иске

карашлар мөселман дин әһелләренә, милли һәм чит ил изүчеләренә каршы юнәлтелгән булырга тиеш, дип күзаллый Солтангалиев. Ләкин ул, мөселман җәмгыяте корылышында бер үк вакытта ике революция ясау мөмкинлеге бирелмәгәч, бөтен өстенлек милли азатлык хәрәкәтенә генә бирелү сәбәпле, социаль революцияне башлау сәгатен кичектереп торырга кирәклеге турында төзәтмә кертә... Үзенең фикер дөреслеген исбатлау өчен ул, окраиналардагы җирле җәмгыятенең үзенчәлекле, аларның аз санда һәм идеологик яктан йомшак булуына ишарә ясап, мөселман ярлы крестьяннары һәм пролетариаты хакимиятне үз кулларына алырга әлегә сәләтле түгеллекләрен күрсәтә. Аның фикеренчә, тормышы начар дип исәпләнгән урыс яки немец крестьяны да хәлле татар кулагыннан баерак. Шуңа күрә «татар крестьяннарының җирле кулаклар тарафыннан сыйнфый изелүе турында түгел, ә татар крестьяннарының тулаем артта калганлыгы турында сөйләү» (1; 192—193) дөресрәк булыр иде.

Шәрык шартларын яхшы белмәгән урындагы җитәкчеләрнең компетентсызлыгы Солтангалиевне борчый иде. «Социаль революция һәм Шәрык» дигән мәкаләсендә ул, игътибарны Персиядәге вакыйгаларга юнәлтеп, аннан урыс гаскәрләрен чыгаруга китергән Совет җитәкчеләренең сәясәте «безнең көчсезлегебезнең чагылышын тануыбыз» (3; 14) булып тора, ди. Төркстан Халык комиссарлары рәисе К. Атабаев, Гилян республикасы игълан итү турында сүз алып барганда, бу мәсьәләне тагын да яхшырак итеп ачып бирә: «Сез беләсезме, егерменче елларда без бик зур уңышларга ирештек: гаскәрләребез Каспий артында акгвардиячеләрне җиңеп, аларны тулысынча тар-мар итү өчен Энзилене алдылар... Бу көрәштә без Хорасан провинциясеннән алып инглизләрне Мәшһәдтән эвакуацияләнергә мәҗбүр иткән фарсы революционеры Кучук-Хан белән бергә идек. Һәм менә зур гына уңышларга ирешкән сыман булгач, без — коммунистлар — хан нәселеннән булган Кучук-Хан белән эш итүебезне кинәт искә төшердек. Шуның өчен без аны властьтан төшерелгән дип игълан иттек. Кучук-Хан, әлбәттә, безгә каршы фронт ачарга кирәклеген бик тиз аңлады, нәтиҗәдә без Персиядән китәргә мәҗбүр булдык» (Папоров Ю. «Белое солнце пустыни?..», «Юность», 1990, 1 сан, 82 б.).

А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеже Солтангалиев эшчәнлеген бөекдержава шовинизмы һөҗүмен булдырмау өчен көрәшүче украинлы Микола Скрыпник, грузиннар Ф. Махарадзе һәм П. Мдивани, карт большевиклар, инанган интернационалистлар, чын марксистларның омтылышлары белән чагыштыралар. Алар партиядәге драматик үзгәрешләрнең шаһитлары булдылар: европача яхшы белемле булган карт большевик-интеллигентлар, чыгышы буенча пролетар, күпчелеген урыслар тәшкил иткән большевикларның яңа буыны белән бәрелештеләр. «Надан һәм диалектика нечкәлекләренә битараф, ләкин амбициоз һәм реалист, теләсә нинди кыргый рәвештә индивидуаль һәм коллектив хәрәкәтләр ясарга сәләтле бу кешеләр Сталин тирәсенә берләштеләр. Бу вакыттан башлап алар инородецларга карата булган масаюлы һәм нәфрәтле мөнәсәбәтләрен яшерми башладылар. Урыс булмаган большевистик җитәкчеләрнең аеруча алдан күрә белүчеләре «яшь большевиклар»ның бу калкуын бик саклык белән күзәттеләр. Бу очракта алар иске урыс шовинизмының пролетар динамизмы белән тулыландырылган иң начар билгеләрен күрделәр» (1; 199—200).

Махарадзе һәм Мдивани грузин компартиясенең Үзәк Комитеты автономлы булуын һәм Мәскәүнең бу партия эшенә тыкшынмавын гына теләделәр. «Ләкин грузиннарның барлык таләпләре дә Сталин тарафыннан тупас рәвештә кире кагылды» (1; 201). Моңа кадәр Скрыпникның мөстәкыйль украин компартиясе булдыру турындагы тырышуы нәкъ шушындый хәлгә дучар булган иде. Сталинның «үзәкләштерелгән монополизмы» шулай ук экономика һәм мәдәниятне дә биләп алды.

И. Сталин, үзен милләтләр мәсьәләсе буенча зур белгеч исәпләп, Милләтләр эше буенча Халык комиссариаты аша бүтән төрле, асылда капмакаршы линия үткәрергә омтылды. Ул берсүзсез үзәккә буйсыну, аңарга бәйле булу өчен бернинди чигенеш тә ясамауны таләп итә. Милли төбәкләрнең суверенитетлы булуларына, аларның мөстәкыйль экономикасы һәм мәдәнияте үсүенә төрлечә каршылык күрсәтергә тырышты. Сталин фикеренчә, суверенлык милли хисләрнең уянуына китерә, ә ул бу хисләрне марксизмга чит булган милләтчелек итеп карады» (Окунев И. Дом в Трубниковским 11 «Московский комсомолец».— 1989.— 8 сентябрь, 2 б.).

Милли сәясәттә Ленин һәм Сталин линияләренең каршылыгы бигрәк тә 1922 елда — СССР төзелү нисбәтеннән тагын да тирәнәйде һәм шушы елның декабрендә Ленин «Милләтләр яки «автономизация мәсьәләсенә карата» дигән хезмәте белән чыгыш ясый. Ул анда «чынлап та инородецларны урыс держимордасыннан саклауга юнәлтелгән эштә Сталинның чаралар күрмәве өчен аның җаваплылыгына махсус туктала. «Бирeдә Сталинның административ мавыгулары һәм ашыгып нәтиҗә чыгаруы, шулай ук аның «социал-милләтчелеккә» карата үчегүе язмышны хәл итүдә зур роль уйнады»,— дип язды Ленин (9; 17).

Икенче линиянең капма-каршы торуы РКП(б)ның XII съездында (17—25 апрель, 1923) Ленин курсының раслануы белән тәмамлана: «...бөек урыс шовинизмы калдыклары белән көрәш безнең партиянең беренче бурычлары» (9; 83), «...милләтләр арасындагы фактик тигезсезлекне бетерү, артта калган халыкларның хуҗалык һәм мәдәни дәрәҗәсен күтәрү икенче бурычы» (9; 84), «...милләтчелек һәм шовинистик калдыклары белән көрәш безнең партиянең өченче бурычы булып тора» (9; 85).

1923 елның март аенда, Сталинның шәхси күрсәтмәсе нигезендә, Дәүләт сәяси идарәсе (ГПУ) Солтангалиевне күзәтү астына ала. Аның Уфадагы бер иптәшенә язган хаты да шымчы кулына элэгә. Ул хатта мондый юллар язылган була: «Үзәк хөкүмәтне яхшы белгән кеше буларак, хөкүмәт тарафыннан урыс булмаган халыкларга карата алып барыла торган сәясәтнең иске бөекдержава сәясәтеннән берни белән дә аерылмаганлыгын бөтен җаваплылыгым белән раслый алам. 1917 елда бирелгән вәгъдәләр үтәлмиләр. Шуның өчен без алда булачак съездда казакълар, төркстанлылар белән берләшергә һәм үзебезнең милли мәнфәгатьләребезне саклау өчен бердәм фронт төзергә тиешбез» (1; 208).

РКП(б) съездыннан соң ук, И. Таһиров мәгълүматлары буенча, 4 майда Троцкий, Каменев һәм Зиновьев имзалары белән ныгытылган Сталин боерыгы нигезендә Солтангалиев Мәскәүдә кулга алына. Дөресен әйтергә кирәк, мондый акциядә, Ленинның авырганыннан файдаланып, бер генсек кына түгел, ә ул вакытларда РКП(б)ның бөтен югары постларында торучылар да катнашкан. «Каменев,— дип яза Троцкий үзенең «Сталин» дигән хезмәтендә,— бервакыт миңа болай диде: «Сез 1923 елда Халык Комиссарларының Татар Советының элекке рәисе Солтангалиевне кулга алуны хәтерлисезме?[2] Сталин инициативасы белән кулга алынган беренче күренекле партия әгъзасы иде ул. Кызганыч, Зиновьев һәм мин үзебезнең ризалыгыбызны бирдек» (6; 170).

Солтангалиев сак астында тотылганда, 1923 елның 9—12 июнендә Сталин күрсәтмәсе буенча, милли республика һәм өлкәләрнең җаваплы хезмәткәрләре белән РКП(б) Үзәк Комитетының Дүртенче киңәшмәсе үткәрелә. Киңәшмә игътибарына Сталинның «Милли мәсьәләләр буенча партиянең XII съезды резолюцияләрен тормышка ашыруда практик чаралар» һәм «Солтангалиевнең партиягә, советларга каршы эшчәнлеге турында Үзәк Контроль комиссиянең докладлары» тәкъдим ителә.

* * *

Солтангалиевне нәрсәдә гаеплиләр соң?

Аның «эше» буенча киңәшмә резолюциясенең кайбер пунктларында диелә:

1) «Партия тарафыннан җаваплы постка (Милләтләр буенча Халык Комиссариаты Коллегиясе әгъзасы) куелган Солтангалиев, үз вазифасыннан файдаланып, урындагы работниклар белән элемтәдә булу аркасында, конспиратив юл белән партиянең милләтләр сәясәте өлкәсендә үткәргән чараларын бозып күрсәткән ялган информацияләр җибәреп, республикалар һәм өлкәләрдәге (партияле һәм партияле булмаган) кайбер ныгып җитмәгән работниклар арасында үзәк партия органнарына каршы эш алып бару өчен легаль булмаган оешма төзергә маташкан».

[2] Каменев хаталана. Солтангалиев бу постны биләмәде.— А. С.

2) «Бу оешманың эшен «электә изелгән милләтләрнең революцион пролетариатка ышанычын һәм бу көчләр арасындагы берлекне юкка чыгаруга юнәлдерергә тырышкан».

3) «Шәрыктәге кайбер (Персия, Төркия) дәүләтләрдәге үзенең фикердәшләре белән элемтәгә керергә омтылган һәм аларны милли мәсьәләдә Советлар хакимиятенә каршы куелган платформада берләштерү йөзеннән үзенең оешмасын Советлар Республикасы Берлеге чикләреннән тыш та җәелдерергә маташкан».

4) «Аның тарафыннан максат итеп куелган контрреволюцион бурычлар һәм партиягә каршы эшнең логикасы Солтангалиевне Совет төзелешен җимерүгә юнәлдерелгән контрреволюцион көчләр белән берләшү эзләргә китерде, империализм тарафыннан хупланган Бохара-Төркстан басмачыларының бер җитәкчесе Зәки Вәлидов белән элемтәгә керергә маташканда бу ачык чагылыш тапты».

5) «Солтангалиевнең җинаятьчел хәрәкәтләре» аны Коммунистлар партиясе сафларыннан аерым куя».

6) «...Республика һәм өлкәләрдәге работниклар арасында милләтчелеккә авышу урындагы урыс иптәшләрнең хатасы нәтиҗәсендә барлыкка килгән бөекдержава шовинизмына каршы реакция булып тора: «милләтчелеккә авышудагы иң бозык чагылышның башлангычы итеп Солтангалиевнең эшчәнлеген әйтергә мөмкин» (9; 130—132) һ. б.

Солтангалиевкә бер-ике чит ил кешесе белән сөйләшеп тору да аны «үзенең оешмасын Советлар Республикасы Берлеге чикләреннән киңәйтергә» маташуда гаепләргә, ниһаять, Зәки Вәлиди белән телефон аша сөйләшүе аны сатлык җан итеп күрсәтергә җитә.

Киңәшмәдә «Солтангалиевнең партиягә һәм хөкүмәткә каршы «эшчәнлеге» буенча башта Үзәк Контроль комиссия исеменнән В. В. Куйбышев чыгыш ясый.

Солтангалиевкә тагылган ялган гаепләүне ҮК әгъзалары кире кагачакларын алдан күреп,Сталин административ хәйлә кора. Шуңа күрә Куйбышев та, киңәшмә рәисе Каменев та, татар большевиклары вәкиле Ибраһимов та (язучы Галимҗан Ибраһимов — А. С.) гаепләнүченең революцион хезмәтләрен әйтеп үтәргә онытмыйлар... Нигә соң әле аны шундук диварга? Башта Солтангалиевне мәсхәрә итәргә, «солтангалиевчелек» дигән сәяси ярлыкны таратырга кирәк.

Сталин шулай ук сәяси сәхнәгә Солтангалиевнең якташы, чиктән тыш ортодоксаль карашлы, берсүзсез Үзәк директиваларын үтәүче С. Сәидгалиевне дә чыгара. Генсекка яшертен шымчының хәбәр итүенә караганда, Сәидгалиев гаепләнүче белән үзенең шәхси исәп-хисапларын өзәргә каршы түгел икән. «Татарстанда продразверстканы тормышка ашыру вакытында Сәидгалиев татарлар һәм урысларга налогны тигез салмый. Ә инде моның белән риза булмаучылар баш күтәргәч, ул моны контрреволюцион күтәрелеш дип атый. Солтангалиевнең катгый таләбе буенча гына бу булдыксыз администратор Татарстан республикасыннан кире чакыртып алына. Әлеге киңәшмәдә шул чакта «кимсетелгән» өчен ул (Сәидгалиев — А. С.) үчне Солтангалиевтән алуга ирешә» (10; 102). Үзәккә үзенең әнә шулай бирелгәнлегенә карамастан, Сәхибгәрәй Сәидгалиев тә 1938 елда кулга алына һәм бер елдан соң атып үтерелә).

Киңәшмәнең стенографик отчетына караганда, А. Беннигсен әйткәнчә, аның резолюциясе детектив жанрга охшап тора (11; 653). Ләкин дедуктив метод безгә катгый бер карарга килергә мөмкинлек бирә: гаепләүчеләр кулында Солтангалиевне контрреволюционер сыйфатында гаепләргә һәм кулга алырга берни дә исбатлау дәлиле булмый.

«Солтангалиев эше» — Дәүләт сәяси идарәсе (ГПУ) катнашлыгында, Каменев һәм Зиновьевларның фатихасы белән, Троцкийның демонстратив битарафлык күрсәтүе нәтиҗәсендә, Сталин тарафыннан югары профессиональ дәрәҗәдә үткәрелгән сәяси провокация ул. Шулай ук моны утызынчы еллар процессы өчен генераль репетиция, ә Солтангалиевнең үзен сталинчылыкның беренче корбаны итеп карарга мөмкин.

Тарихи фактлар һәм мантыйк әнә шуны раслый.

## Әдәбият исемлеге


1. Bennigsen A., Lemecier-Quelquejay Ch. Sultan Galiev, le pere de la revolution tiers — mondiste.— P.: Fayard, 1986, 307 б.

2. Таhиров И. Кем ул Солтангалиев? «Казан утлары», 1989, 4 сан.

3. Sultan-Galiev M. S. Articles.— Oxford: Soc. for Central Asian studies, 1984, 80 б.— (Repr. ser. Soc. for Central Asian studies; № 1).

4. Rodinson M. Communisme et Tiers Monde: Sur un précurseur seur oublié // Les temps moderner.— P., 1960-1961.— t. 16, 177 сан, 853—864 бб.

5. Абдуллин М., Батыев С. Татарская АССР: Реальность и буржуазные мифы. Казань, 1977, 199 б.

6. Bennigsen A., Quelquejay Ch. Les mouvementes natioaux chez les musulmans de Russie: Le «sultangalievisme» au Tatarstan. P., La Haye: Mouton, 1960, 285.

7. Bennigsen A., Wimbush S. E. Muslim national communism in the Soviet Union: A revolutionary strategy for the colonial world.— Chicago etc.: Univ. of Chicago press, 1979.— XXII, 267 б.— (Publ. for Middle Eastern studies; 11 сан).

8. Революционный процесс на Востоке: История и современность. (Отв. ред. Ульяновский Р. А.) Москва, 1982, 390 б.

9. «Коммунистическая партия Советского Союза в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК». М., 1984, т. 3, 494 б.

10. Антонов-Овсеенко. И. В. Сталин и его время. «Вопросы истории», 1989, 1 сан, 82—104 бб.

11. Bennigsen A. Sultan Galiev, l'URSS et la revolution coloniale // Esprit.— P., 1957, 249 (4) сан, 641—659 бб.

# ҖЫЕННАР ТАРИХЫННАН

Татар халкының милли бәйрәмнәре чагыштырмача күп булмаган. Шуларның иң көтеп алынган, иң борынгыларыннан берсе язгы чәчү алдыннан үтә торган Сабантуй булса, икенчесе — Җыен бәйрәме.

XIX гасырда Җыен турында язучылар (К. Фукс, П. Шино, А. Риттих һ. б.) аны җыр-биюгә бай булган, туганнар очраша торган бәйрәм дип билгеләгәннәр. Совет чоры галимнәре исә Җыенның структурасын, үткәрү үзенчәлекләрен, килеп чыгу тарихын тикшерделәр.

Бәйрәмнең тамырлары бик еракта — ыруглык мөнәсәбәтләренә барып тоташа. Җыеннар бердәм территориясе, хуҗалыгы, туганлык мөнәсәбәтләре булган төрки кабиләләрдә үк булган. Тора-бара кабиләләр таркала. Ләкин туганлык җепләре өзелми. Сыйнфый җәмгыятьтә Җыен, үзенең беренчел мәгънәсен югалтып, авыл төбәкләренә күчкән. Гадәттә, 10—15 авыл җыен округын тәшкил иткән. Җыеннарның тулы бер циклына шундый 4-8 округ кергән. Алар ел саен билгеле бер вакытта, чиратлашып, берберсен кунак иткәннәр. Бәйрәм һәр округта җомга көн башланып, 3—5 көн дәвам иткән. Җыенның үткәрелү вакыты май ахыры — июнь башыннан алып июль ахырына кадәр булган.

Галимнәр фикеренчә, Казан ханлыгын Рус дәүләте яулап алганнан соң, җыенның классик формасы Казан арты авылларында сакланып калган. Казан тирәсеннән генә 40 чакрымга якын радиуста татар халкы үз җирләреннән куылган. XIX гасыр башында монда 80 гә якын җыен округы булганлыгы билгеле[1].

Тау ягында яшәгән татарлар, урыс колонизациясе нәтиҗәсендә, Идел буеннан көнбатышка таба куылганнар. Бу тирәдә яшәгән җирле халык белән аралашып урнашканнар. Элекке Җыен структурасы таркалган. Тау ягының көньяк өлешендә күбрәк татар мишәрләр яшәгән. Аларда Җыен бәйрәм ителмәгән. Тау ягында Җыеннарның төгәл әйләнеше бозылып, алар күбрәк ярминкәләргә әйләнеп калганнар. Кама аръягында да җыеннар исеме астында ярминкәләр үткән. Аларда башка милләт вәкилләре дә катнашкан[2].

Җыеннар ул вакыттагы Сабантуйлардан кай ягы белән аерылган соң?

Беренчедән, җыеннарда җыр-бию, төрле уеннар, күңел ачуларга күп вакыт бирелгән. Төп музыка кораллары гармун белән скрипка булган[3]. Икенчедән, җыеннар кунаклар һәм читтән кайткан туган-тумачалар күп булу белән аерылып торган. Өченчедән Сабантуйда үткәрелә торган спорт ярышлары, көч сынашу җыеннарда булмаган. Ат чабышы урынына яшьләр, атлар җигеп, бер авылдан икенчесенә күңел ачып йөргәннәр. Дүртенчедән, Сабантуен татар хатын-кызлары ерактан гына күзәтергә хокуклы булса, Җыенда исә кызлар бәйрәмнең үзәгендә — егетләр белән бергәләп күңел ачканнар, кичке уеннарда катнашканнар. Кыз күзләү, яр сайлаулар нәкъ менә бәйрәм вакытында хәл ителгән. Җыенны бөтен халык, бигрәк тә яшьләр көтеп ала торган булган. Халык хәтерендә сакланып калган мондый сүзләр дә шуны раслый:

*Елга килә ике гает,*
*Һич тә искә алмыйлар.*
*Җитсә җыен көннәре,*
*Хәзерләнми калмыйлар.*

Җыеннар вакытында ислам диненең кырыс кануннары бозылган. Шуңа күрә дә 1861 елда Оренбург Диния Нәзарәте бәйрәмне тыю турында махсус указ чыгара һәм властьларга мөрәҗәгать итә. Бу мөрәҗәгать нигезендә, 1861 елның 5 сентябрендә Казан губерна идарәсе Җыенны тыю турында карар кабул итә. Шәһәр һәм өяз полицияләренә, Диния Нәзарәтенә бәйрәмне юкка чыгару өчен тиешле чаралар күрергә кушыла.

Архивта Җыенны бетерергә вәгъдә рәвешендә язылган Казан өязе Яңгул волостеның 11 мулласы кул куйган документ сакланып калган. Олы Карахуҗа, Байлар Сабасы, Олы Әтнә, Күпербаш авылларында җыеннар вакытлыча тукталып тора. Күпербаш авыл халкы Җыеннан кешеләрне куып йөргән полиция вәкилен кыйный[4]. Андый җәбергә кайбер муллалар да дучар булган.

---

[1] Бурганова Н. Б. О системе народного праздника Джиен у казанских татар.— «Исследование по истории диалектологии татарского языка». — Казань, 1982, 26—49 бб.

[2] Кашафутдинов Р. Г. Народные (общественные и семейные) праздники Казанских татар. Диссертация канд. ист. наук.— Казань, 1969., 116 стр.

[3] Шино П. А. Волжские татары.— «Современник», 1860, 81 т., 261 стр.

[4] Татары Среднего Поволжья и Приуралья.— Казань, 1967, 226 б.

Бәйрәмне тыю өчен төрле чаралар кулланылган. 1881 елны хәтта халыкны Җыен бәйрәмен үткәрмәскә өндәгән, дидактик характердагы «Җыен кыйссасы» да басылып чыга. Ләкин дин әһелләре милли бәйрәмне халык тормышыннан җиңел генә сызып ташлап булмаслыгын таныйлар:

*Кай вакыттан бирле чыккан бу җыенның булуы,*
*Һич тә файда бирмидер муллаларың тыюы*[5].

XIX гасырның 70 елларында Казан губернасында да аграр кризис башлана. Татар крестьяннарының экономик хәле башка халыклар белән чагыштырганда авыррак була. Аларның патша хөкүмәтенә бурычлары арткannan-арта бара. Шундый бер вакытта Казан губернаторы Черкасов кулына Казан өязе, Кавал волосте, Мөндеш авылы крестьяны Хәсән Галиев хаты килеп керә. Галиев халыкның ярлылыгын Җыеннан күрә. Аның фикеренчә, имеш, күпләр бәйрәмне үткәрү өчен бурычка баталар. Бурыч түләү крестьяннарның җирләрен арендага бирү, мал-туарларын сату белән тәмамлана. Бәйрәмнең дини бәйрәм түгеллеген дә искә төшереп, Х. Галиев Җыенны тыюны сорый.

Хат белән танышкач, Черкасов тыюны законлаштыру өчен мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилевкә Диния нәзарәте исеменнән Җыенны бетерүне сорап үтенеч язуы таләп итә.

Черкасов башлаган эшне аның урынына калган Андреевский дәвам итә. 1885 елның 14 мартында, мөфтидән алынган «үтенеч» нигезендә, барлык өяз исправникларына «мөселман дине тарафыннан кертелмәгән, әхлакый яктан зыянлы, крестьяннарны бөлдерә торган Җыен бәйрәмен үткәрмәү турында» боерык бирелә. Буйсынмаучылар җавапка тартылырга тиеш була[6]. Бер үк вакытта Диния Нәзарәте муллалар аша эш җәелдереп җибәрә.

Ләкин шуңа да карамастан, 1885 елда Җыен Казан өязенең Кавал һәм Олы Мәңгәр волостьларында һәм Кукмара волостеның бер авылында бәйрәм ителә. 1886 елда бу исемлеккә Олы Этнә, Салкын Чишмә, Алат волостьлары авыллары кушыла. Мәмсә волостенда дин әһелләре, ураза дип, бәйрәмне вакытлыча тыюга ирешәләр. Күрәнебезчә, полиция һәм җирле башлыкларның Җыенны юкка чыгару өчен тырышуы әлле ни уңышка китерми.

Җыен бәйрәмен бетерү турында мәсьәлә өченче тапкыр губерна күләмендә 1887 елда, Казан сәүдәгәрләре А. Сәйдәшев һәм М. Галиев хаты аркасында күтәрелә. Аларның дин эшенә һәрьяклап ярдәм итүләре мәгълүм. Сәүдәгәрләр бәйрәмнең Олы Этнә, Мәмсә, Олы Мәңгәр, Алат, Салкын Чишмә һәм Кукмара волостьларында үткәрелүен әйтәләр. Алар үзләренең гозерләрен: бәйрәмнең халык акчасыз вакытка туры килүе; Җыенның авыл хуҗалыгы эшләренә зыян китерүе; бәйрәм вакытында шәригать тарафыннан тыелган эчү, җырлау, сугышу һ. б. булу белән дәлилләр.

Алар татар крестьяннарының тормыш хәле түбән булуын Җыен бәйрәменә генә бәйләп аңлаталар. Бу хатта, Х. Галиев хатындагы кебек үк, бер дөреслек ярылып ята: татар крестьяннарының тормыш дәрәҗәсе шулкадәр түбән ки, акча чыгымы белән бәйле һәрбер нәрсә (бу очракта Җыен) ярлы крестьяннарны хәерчелеккә төшергән.

Казан өязе исправнигы сәүдәгәрләрнең Җыенга шундый берьяклы карашларын кире кага. Аның фикеренчә, Җыеннар крестьяннарның экономик хәленә артык зур йогынты ясамыйлар, бәйрәм вакытында һәртөрле сугыш, тавыш, эчү, бәхетсезлек очраклары булмый[7].

Җыеннарны тыю сәясәте дәвам итә. Тик җирле властьлар кулга алынган халыкны нинди җавапка тартырга белмиләр. Россия законнарында үз милли бәйрәмен үткәргән халыкка карата җәза каралмаган була.

Губернатор Андреевский мәсьәләне тиз чишә. Җыенны бәйрәм иткән өчен җавапка тарту, җыенәтьләрне кисәтү һәм туктату Уставының 157 һәм 170 статьялары нигезендә мөмкин, дип игълан ителә.

Шулай итеп, властьлар законның фәкать христиан дине тотучыларга караган «дини һәм мәдәни музыканы бергә кушарга ярамый» (157 ст. һәм «артист, музыкант яки җырчы булмаган кешеләр халык алдында концертлар белән чыгыш ясый алмыйлар» (170 ст.) дигән өлешләрен татарларга карата кулланалар[8]. Буйсынмаганнар шул ук карар нигезендә 50 сумга кадәр штраф түләргә, ә кеше күп җыелган очракта 7 көнгә кадәр төрмәгә ябылалар.

---

[5] Җыен кыйссасы.— Казан, 1881, 4 б.
[6] ТССР ҮДА, 1 ф., 3 тасв., 6030 эш.
[7] ТССР ҮДА, I ф., 3 тасв., 7233 эш.
[8] Устав о предупреждении и присечении преступлений.— СПб. 1876, 32, 34 б.
[9] Дудкин А. Джин у татар Казанского уезда.— «Северный весник», 1890, № 8, 30 б.

Властьлар татар крестьяннарының экономик хәлен яхшыртуны мәгълүм мәзәктәге «сазлыкка баткан кеше үзен-үзе тартып чыгарсын» принцибына куялар. Ул заманның алдынгы вакытлы матбугаты мондый «кайгыртучылар» турында: «Крестьян алар өчен бернинди ял һәм күңел ачарга хокукы булмаган эш көче»[9], — дип яза.

Мондый юл белән тормыш дәрәҗәсен «яхшырту», татар халкының милли хисләре һәм горурлыгы белән хисаплашмыйча, гасырлар буе яшәп килгән бәйрәмгә шул рәвешле балта чабу — патша самодержавиесенең татар халкын милли изү сәясәтенең бер чагылышы иде. Андый «изге эшләрдә» властьларның үзләре чыгарган законнарны бозуы табигый күренеш була.

Җыен бәйрәмен тыю, Р. Кашафетдинов фикеренчә, 1905—07 елларга кадәр дәвам иткән. Беренче рус революциясе белән бәйле иҗтимагый тормышның демократияләшүе бәйрәмне эзәрлекләүләрдән коткара. Илле елга якын дәвам иткән көрәштә татар халкы үз милли бәйрәмен саклап кала. Ул Казан ханлыгы бетерелгән вакытта башланган милли изү һәм урыслаштыруга каршы татар халкының милли-азатлык көрәшенең бер өлеше булып тора. Җыенны саклап калу өчен дин әһелләре белән барган көрәш халыкның көнкүреше, күңеле дин кануннарына гына сыймавын, аның ирек сөючәнлеген тагын бер кат раслый.

Җыен бәйрәме безнең гасырның 30 елларында юкка чыкты. Колхозлар оештыру, милли политикадагы юнәлешләр Җыенны «йотты». Аның вакытын күчердек тә, бүгенге Сабантуй бәйрәмендә Җыен элементлары бар, дибез. Шулай үзебезне аклыйбыз, тынычландырабыз.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН**

---

## *Безнең календарь*

# Сәрвәр Әдһәмованың тууына — 90 ел

Язучы һәм тәрҗемәче буларак танылган Сәрвәр Сабир кызы Әдһәмова элеккеге Оренбург губернасының (хәзерге Чиләбе өлкәсе) Троицк шәһәрендә туа. Шушы шәһәрнең Александровское училище дигән өч класслы мәктәбендә укый, аны мактау кәгазе белән тәмамлаганнан соң, мөгаллимәләр әзерли торган дәрелмөгаллиматта, аннары Троицк кызлар гимназиясендә белем ала.

Сәрвәр Әдһәмова шулай ук медицина факультетында белем ала. 1923 елда Казанга күчеп килгәч, бер еллык юридик курсларны тәмамлый.

Аның ныклы иҗади эшчәнлеге дә нәкъ менә шул елларда башланып китә. Балалар өчен язылган шигырьләре, хикәя һәм пьесалары бер-бер артлы дөнья күрә.

1932 елда Сәрвәр Әдһәмова профессиональ иҗат эшенә керешә. Аның тәрҗемәче буларак танылуы Л. Толстой, М. Горький, А. Чехов әсәрләрен татар укучыларына җиткерүе һәм чит ил классик әдәбиятыннан Д. Дефо, Д. Свифт, Бертуган Гриммнар һәм башка атаклы язучыларның әсәрләрен тәрҗемәләве белән бәйле.

Сәрвәр Әдһәмова — үзенең хикәяләре белән дә, Г. Ибраһимова, Ш. Бабич, Ш. Камал, К. Нәҗми кебек күренекле замандашлары турында язган истәлекләре белән дә әдәбиятка зур хезмәт куйган язучы.

Сәрвәр ханым Әдһәмова 1978 елның 10 ноябрендә Казанда вафат булды. Ул 1945 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

# Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанга 50 яшь



Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗан 1941 елның 14 апрелендә Татарстан ССРның Баулы районы Татар Кандызы авылында туган. Авыл мәктәбендә җиде класс белем алганнан соң, 1957 — 1958 елларда Бөгелмәдә төзүчеләр әзерләү училищесында укый, аннары нефть районнарында һәм Әлмәттә ташчы булып эшли. 1961 — 1964 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Армиядән соң Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, 1969 елда аны тәмамлый. 1974 елга кадәр Татарстан Культура министрлыгында сәнгать эшләре буенча инспектор, аннары «Яшь Ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталарында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1980 елдан ул — «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәре.

Рәшит Әхмәтҗан әдәбиятка илленче еллар ахырында килә. Шигырьләре «Азат хатын», «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналларында дөнья күргәч, аңа Х. Туфан, З. Нури, Г. Хуҗиевлар игътибар итеп, талантын, шигъри фикерләүдә үзенчәлеген — халыкчанлыгын билгеләп үтәләр. Шагыйрьнең 1965 елда басылып чыккан «Хыялларым үзем белән» исемле беренче китабы укучылар һәм тәнкыйть тарафыннан җылы каршыланды. Бүгенге көндә Р. Әхмәтҗан — дистәгә якын шигырь китабы, халыкта танылу тапкан җырлар, әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уяткан поэмалар («Бишташ», «Аучылар кибетендә», «Карачкы» һ. б.) авторы. Аерым шигырьләре күмәк китапларда рус һәм башка тугандаш халыклар телләрендә дә басылды. Быел исә шагыйрь иҗатының зур өлешен туплаган «Моңлану» исемле китабы «Шигырь китапханәсе» сериясендә дөнья күрде.

Р. Әхмәтҗан — 1970 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы.

Татарстан Язучылар берлеге һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлыйлар, сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр.

Китап күзәтү

# ХИКӘЯНЕ КҮҢЕЛ САГЫНГАН

Бер сөйләшүдә Әмирхан ага Еникиның: «Хикәя язу — бик авыр эш ул»,— дигәне бар. Хикәяләр остасы ни әйткәнен яхшы беләдер, чөнки язучының сәләте һәм осталыгы күпме булса, тотынган эшенең катлаулылыгын күрә белүе дә шуның кадәрле тирәнрәк. Тагын кемнеңдер хикәя язуны, зур таш кисәгенең артык җирләрен кисеп ташлап, гүзәл сын ясау белән чагыштырганы бар. Югары сәнгать, чын Нәфис Сүз таләпләреннән чыгып карасаң, бу чагыштыру да бик дөрес. Хикәядә һәр җөмлә, һәр сүз, һәр ишарә, һәр сурәт төгәл үз урынында булырга тиеш. Юкса, кечкенә генә төгәлсезлек тә әсәрне гариплaverдерәчәк.

Тагын шундый күренеш тә бар: публицистика өлкәсендә менә дигән итеп эшләп килгән язучылар хикәя яисә повесть эшләргә тотынсалар, күп очракта бөтенләй югалып калалар, эчпошыргыч әдәби әсәрләр иҗат итәләр. Аларда вакыйгалар да, сурәтләр дә — барысы да бар кебек, ә әдәби вакыйга, әдәби сурәт юк.

Озынга сузылган бу сүз башының нәтиҗәсе шул — Нәфис Сүз сынавы аша үтү гаять кыен шөгыль. Моны барыбызга да, беркайчан да истән чыгармаска иде. Әдәбиятта хөрлеккә ирештек кебек, инде осталыкка ничек ирешергә?.. Ахыр чиктә бит нәфис әдәбият өчен актуаль проблемалар мөһимлеге беренче урында түгел. Иң мөһиме — сәнгатьчә югарылык.

Солтан Шәмсинең газета-журналларда күренгәләгән әсәрләре игътибарымны күптән җәлеп иткәннәр иде инде. Иҗат өлкәсендә заман белән бер адымда баручы, әле чагыштырмача яшь әдипнең профессиональ осталыгы да, сөйләгән сүзенең табигыйлеге дә, нечкә зәвыгы да сизелеп тора. Кулымда аның 1989 елда басылып чыккан «Җәяүле буран» исемле хикәяләр җыентыгы. Монда иң элек «Соңгы юаныч» дип исемләнгән әсәр турында сөйләшеп үтәсе килә.

Шәһәргә килеп төпләнгән элекке авыл малайлары һәм кызлары берни белән дә чагыштырып булмый торган печән исен хәтерләмиләрдер инде. Миңа калса, ул хис хәтергә килгән саен, күңел балачакның серле дөньясына кайтып килгәндәй була. Гомумән, күп кенә атаклы язучылар әдәби иҗат өлкәсендә төрле исләр аша сурәтләүнең алыштыргысыз зур әһәмиятен билгеләп үтәләр. Шунысы да кызык: ис, иской килү, искә төшерү кебек сүзләрнең тамыры нигә бер икән?..

Хикәя, беренче карашка, соңгы елларда телдән төшмәгән экология һәм ата-аналар белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләр турында кебек. Әйе, әлеге әсәрдә болар барысы да бар, барысы да тормышчан кырыс хакыйкать рәвешендә сурәтләнә. Ләкин бакчасына гади үлән чәчеп, соңгы тапкыр хуш исле печән чабып карыйсы килгән гади авыл абзые бу хикәягә серле шигъри бизәкләр өсти. Бәлки, кемгәдер башта барысы да артык гади кебек тоелыр, кемдер кайбер вакыйгаларга ышанмас. Шулай да, хәтерендә печән исен саклаган һәм туган җирен сагына белү сыйфатын җуймаган моңлы һәм тырыш бәндәләргә барысы да аңлашылыр. С. Шәмсинең печән өстен тасвирлаган сурәт-бизәкләре аермачык булып күз алдына килеп басалар: «каерып чабарлык булып» җитешкән печән «җилдә дулкынланып уйный», «чыклы үлән тагын да куерып, калынаеп күренә, парланган пыяладай аксылланып утыра», иртәнге кояшта «өстенә асылташлар сибелгәндәй, җемелдәп-җемелдәп куя...» Көнкүреш ыгы-зыгысыннан башланган хикәя, үлән үстерү һәм печән чабу кебек гади эшләрнең тыйнак бөеклегенә таянып, югары фәлсәфәгә — йолдызларга кадәр үрелә: «...гүя ул инде дөньяда башкарасы бөтен эшен тәмамлаган да, ниндидер икенче сыйфатка күчкән һәм бу сыйфатында аяк астындагы ташларга, үсеп утырган үләннәргә, агачларга, хәтта күктәге йолдызларга да якынрак тора».

Хикәяне башлап җибәрергә әллә ни күп кирәкми, ә инде очлап чыга белү — шактый гына шигъри фикер осталыгы сорый торган четерекле һәм газаплы эш. С. Шәмси, гомумән, хәтта йомшаграк язылган хикәяләрендә дә, көтелмәгән берничә җөмлә белән кызыклы гына итеп йомгаклый белә. Моңа мисал итеп «Табигатьнең газиз баласы», «Җәйнең кыл уртасында», «Галәветдин абзый» дип исемләнгән хикәяләрне күрсәтергә мөмкин.

«Табигатьнең газиз баласы» — хәвефле

хикәя. Авылда беркемгә дә кирәге калмаган ялгыз карчык... Тук, битараф күзәтүчеләр... Телевизор карап утырганда бераүнең әйткәне бар: «Нигә яшәтәләр бу зәгыйфь балаларны?» Имеш, укол бирәсе дә йоклатасы... Ә кемдер үзен атып үтерергә тиешле солдатларга багышлап дога укый: «Ходаем, ярлыка син аларны, алар ни кылганнарын аңламыйлар». Аңламыйлар... Гасырлар буена тәртипкә салынып урнашкан әхлакый чик бар. Бу чикне узарга бер генә адым да җитә, ә аннан соң — афәт. Кем белә, зәгыйфь акыллылык үлчәме нинди югарылыкта тукталыр? Кузгалган дулкын инде үзеңә булмаса туганнарыңа яисә якыннарыңа кагылмый үтмәячәк һәм, ахыр чиктә, чикләрне җимерергә өндәүченең дә бугазына үреләчәк.

Сүзебез «Табигатьнең газиз баласы» — Гаффә карчык турында иде. Темадан ерак китмәдек шикелле. Кырыс, хәтәр заманда яшибез, усалланабыз, битарафлыкка өйрәнәбез. Җитмәсә, тарихыбыз да утлы, давыллы, адашулар күп... Шулай да, нинди генә шартларда яшәсәк тә, кешелек өчен әхлакый чик барлыгын онытырга ярамый. Юкса акыл ияләренең тамыры корый, яшәүнең мәгънәсе югала. Безнең ялкау вөҗданны юри котыртырга теләгәндәй, куркыныч хикәяне тыныч кына сөйләп чыккан С. Шәмси безгә әнә шуны әйтергә тели.

«Каты чикләвек» дип исемләнгән хикәя исә мәхәббәт турында. Хәзер саф сөю хисләрен тасвирлау җиңел эш түгел. Матбугатта да, әдәбиятта да, киноэкраннарда да әхлакый йөгәнсезлек, бозыклык, азгынлык күренешләре тулып ята... Мондый чолганышта калган яшьләргә ниндидер бер таяныч, юнәлеш, хыял нуры кирәк. С. Шәмсинең «Каты чикләвек» хикәясе аптырашта калган яшь күңелләрне якты чишмә булып сафландырып үтә. Хәтта, әйтер идем, кызларга үз-үзеңне тоту буенча үрнәк кулланма булырлык язма. Монда яшь кыз Рәмзия «...этеп тә җибәрмичә, тартып та китермичә, серле көлемсерәп йөрүен белә». «Кайдан килгән аңарга мондый түземлелек, үзеңне тота, сер саклый белү?» Аны әнисе яшьтән үк: «Соңгы сереңне беркемгә дә сөйләмә!» — дип тәрбияләгән икән. Җенси мәсьәләләр белән шөгыльләнүче галимнәр ничек уйлыйлардыр, миңа калса, ышанычым шул: ахырга кадәр барлык серләрен ачкан хатын-кыз мәхәббәтен дә, бәхетен дә, абруен да — барысын да югалта. Чикләвек эчендә ни барын ир-ат белмәскә тиеш. Алай да хикәя героинясы Рәмзия программа буенча гына корылган робот түгел, вакыйгалар агышын аңлаган игелекле кыз «үзен аның урынына куярга...», «иптәшләре алдында егетнең дәрәҗәсен төшермәскә...» тырыша. Димәк, сүз монда тиле кирелек турында бармый. Хикәянең ахыры кызганыч: Рәмзиянең чын хисләрен белергә дә өлгермичә, егет фаҗигале рәвештә һәлак була. Тулысынча дип әйтерлек тормыштан алып язылган бу хикәядә үлем — очраклы хәл. Ә гомумән, автор сүзләре белән әйткәндә, «Әй, бар ул безнең татарда андый холык... Елый-елый мендәрен чылатып бетерер, тешләп иреннәрен канатыр, ә ир-атка күңелен ачып салмас! Кайдан килә бу? Нигә шулай. Яхшыгамы бу, ямангамы — әйтүе кыен. Ләкин сизәм — соңгы вакытта андыйлар сирәгәя бара».

Китаптагы «Кала-тау өстендә» дип исемләнгән повесть гуманитарийлар белән прогматик технократлар арасындагы күптәнге бәхәсне дәвам иттерә. Әлеге дә баягы, шул ук физиклар һәм лириклар. Бу очракта, бер якта — җәйләрен борынгы шәһәр урыннарында казынып үткәрүче археолог Азат, икенче якта — производство коллективы җитәкчесе, балаларын ана телендә сөйләшергә дә өйрәтмәгән технарь Нәгыйм. Чын күңелдән ышанып, Нәгыйм: «...тормыш бит хәзер безнең ише халык кулында...», «...урта гасырларның бүгенге көнгә ни катнашы бар?» — ди. Ә Азат исә: «Шушы рәвештә фикер йөртүчеләр беркайчан да туган җире өчен утка кермәячәкләр»,— дип, кырыс хөкем чыгара. Көчләр бүленеше ачык, фикерләр таныш, ләкин монда кискен каршылык юк, бәхәс дуслар арасында тыныч рухтарак бара. Ахыр чиктә, хәзерге көннәрдә табигатьне исәпкә алмый эш итүче производство башлыгы Нәгыйм дә: «һай, матур да соң бу тургай сайраулары!» — дип, рухи экология мәсьәләләренә бераз якынлаша кебек.

Күрәбез, үз телләрен оныткан күп кенә милләттәшләр, гомер уртасын узып барганда, нидер эзләнә башлыйлар: вата-җимерә туган телләрендә сөйләшмәкче булып маташалар, туган җырларына колак салалар, тарих белән кызыксыналар. Зиһене, моңы, тәүфыйгы бөтенләй юылып чыкмаган адәмнәрне тамырлар барыбер тарта.

Үзләрен дөньяның тоткасы дип исәпләгән чеп-чи «эшлеклеләр» дә күп очрый тормышта. Алар арасында шундый закончалыкны да күзәткәнем бар: бәхетсезлеккә очраганда андый «эшем кешеләре» үзләренең кыйблаларын тиз җуялар һәм мескен, елак, көйсез имгәк булып, якыннарының тормышын җәһәннәмгә әйләндерәләр. Кирәк, һәркемгә дә кирәк ныклы тамырлар һәм рухи таяныч! Утлы, давыллы сынаулар аша үткәндә мәхәббәт, моң һәм үткән буыннар белән бәйләнеш кенә кешегә тиңсез куәт, балаларга тәүфыйк бирә.

Солтан Шәмсинең «Җәяүле буран» дип исемләнгән хикәяләр җыентыгын шундый уйлар белән ябам. Кычкырмыйча гына, шаккаттырырга теләмичә генә үзенең авырткан җирләре турында сөйләгән кешегә ныграк ышанасың. Нигә икән?

**Рәниф ШӘРИПОВ.**

**Әзәл Яһудин,**

Татарстанның атказанган артисты

# ШИГЪРИ СҮЗ КУӘТЕ

ИСТӘЛЕКЛӘРДӘН ӨЗЕК

Мин сәхнәгә драма артисты булып түгел, ә нәфис сүз белән килеп кердем. Беренче адымымда ук: «Кайсы шагыйрьдән башларга»— дигән сорау туды. Бәлки, бөек шагыйребез Габдулла Тукайдандыр?.. Дөрес бит, ә! Мин Габдулла Тукай шигырьләрен телем ачылуга сөйли башлаганмын. Граммофон тәлинкәсендә «Ысулы кадимче» шигырен Габдулла Кариевнең сөйләвен тыңлап: «... Ходай орган караклар, уңмаганнар, кесәмнән пыртманитны урлаганнар»,— дигән юлын отып, шуны теләсә кайда такмаклап йөргәнмен. Аннан соң инде үзем укый башлагач, Тукайның бик күп шигырьләрен яттан өйрәндем. 1923-24 уку елында безнең Әлки районы Яңа Чаллы авылының югароч мәктәбендә укытучы Габдрахман абый, бер кичә оештырып, укучылардан шигырьләр сөйләтте. Мин Тукайның «Теләнче» шигырен укыдым. Күрәсез, сәхнәдә беренче чыгышым да Тукайдан башланган бит. Инде, укып чыгып, артист булып, тел тибрәтә башлагач та, Г. Тукай шигырьләренә мөрәҗәгать итәргә булдым.

1940-1945 елларны, Татар драма академия театрында эшләгәндә, Тукайның «Гыйшык уты» исемле әсәрен сөйләп йөрдем. Бу әсәрдә мәхәббәт хаты язучы егет «гүзәлен» нәрсәләргә генә тиңләми?! Тамашачы, бу шигырьне тыңлаганда, өзлексез көлә. Бер иптәш миңа: «Әзәл! Син бу әсәрне шундый образлы итеп укыйсың, сине тыңлагач, бер кызга да карыйсы килми»,— дигән иде.

Минем 1930 елларда сәхнәдә башкарган шигырьләр-җырлар дәфтәрем саклана. Шуның саргайган битләрен ачам. Дәфтәр «Асиясе-Васыйләсе» көенә колхоз җырлары белән башлана. Әбүзәр Түрәйнең «Сыйныфташ», Сайкинның «Киелмәгән шлем турында», Сириннең «Сикерт атың», «Язгы тамчылар», «Тегүче кыз», «Безнең кайгылар» кебек шигырьләре... Минә трибун шагыйребез Һади Такташ, ул 1930 елдан 1987 елга кадәр миңа сәхнәдә эшләргә илһам бирде, дәрт бирде. «Киләчәккә хатлар», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Мокамай»...

Дәфтәремне актарам. Менә Муса Җәлилнең «Партизан ударник» шигыре. Бу 1930 еллардагы колхоз төзелешенә җибәрелгән егерме бишмеңчеләр хакында, ягъни, М. Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» романында тасвирланган Давыдовлар турында. Мин ул әсәрне яңадан искә төшерәм, мондагы романтик пафоска кабат сокланам. Бу шигырьне 1940 елларга кадәр сөйләп йөрдем. Инде 1953 елны, Муса Җәлилебез герой шагыйрь булып, «Моабит дәфтәре» белән яңадан илебезгә кайткач, аның шигырьләрен халыкка җиткерү эшенә кабат керештем. Газетада аның беренче шигырьләре басылу белән, аларны сәхнәгә чыгардым. «Гашыйк һәм сыер», «Хәдичә» шигырьләрен 1953 елның 4 октябрендә башкардым. Шул елны Татар дәүләт филармониясенең художество җитәкчесе, композитор Җәүдәт Фәйзи миңа М. Җәлилнең «Хат ташучы» поэмасын эстрадага чыгару бурычын йөкләде. Әле ул вакытта аның әсәрләре китап итеп басылмаган иде. Җ. Фәйзи М. Җәлилнең 1940 елда басылып чыккан һәм үзенә автограф белән бүләк иткән китабын бирде. Мин, җыр-музыка элементлары кертеп, чыгышымны әзерләдем һәм сәхнәгә чыгардым. Шул елны ук мин «Безнең яшьләр» исемле әдәби-музыкаль программа төзеп, үз кичәләремне оештыра башладым. Ул программага «Хат ташучы» (М. Җәлил), «Шаһиевның өйләнүе» (Г. Әпсәләмов), «Бәхет турында җыр» (М. Садри),«Кыңгыраулы яшел гармун» (Ф. Кәрим), «Гармун» (Ә. Фәйзи), «Мин картаймам» (С. Урайский), «Сабир» (Ә. Ис-

хак) һ. б. кергән иде. 1965 елда «Муса Җәлил һәм аның каләмдәшләренә багышланган әдәби-музыкаль программа төзеп, Татарстан районнарында чыгышлар ясадым. Кичә ике сәгатьтән артык дәвам итә иде. Кичәдә М. Җәлил хакында 5-6 минутлык кереш сүз сөйләп, аның әсәрләрен башкару эшенә керешә идем. Ике сәгатьлек программаның яртысы М. Җәлил шигырьләреннән тора иде.

Кичәне:

— Хөрмәтле иптәшләр! Бу кичәгә килгәндә кайбер тамашачылар, бер артист нәрсә генә күрсәтә алыр икән? дигән шикләнү белән киләләр. Бу сорауга кистереп кенә җавап бирү читен, аны кичәнең ахырына калдырыйк,— дип башлап җибәрә идем. Соңыннан халык: «Карасана! Бер артисттан да концерт була икән бит!»— дип, көлешеп, рәхмәтләр әйтеп тарала иде.

Мин бу программа белән берничә ел буе Татарстанның бик күп районына хезмәт күрсәттем, җәмгысы 400 ләп кичә уздырдым. Бу кичәләр хакында район һәм өлкә газеталарында бик күп җылы сүзләр басылды.

Теге яки бу шагыйрьнең әсәрен сәхнәгә чыгарганда аның башка нәфис сүз осталары тапмаган яңа бизәкләрен эзләү зарур. Әйтик, Әхмәт Фәйзинең «Гармун» шигырен кемнәр генә сөйләмәде икән?! Аны башлап Хәким ага Сәлимҗанов сөйләде бугай. Мин дә бу гармун каешына тотындым. Башта Җ. Фәйзинең «Гармун» көен башкарып, шигырьне укый башлыйм һәм шул ук көйне уйный-уйный сәхнәдән чыгып китә идем. Шушы уңай белән бер мәзәк хәл дә булып алды: 1943 елда, ягъни Бөек Ватан сугышы вакытында партия өлкә комитеты йөзләгән коммунистны районнарга пропагандист итеп җибәрде. Партия членлыгына кандидат буларак, Татар дәүләт академия театры партия оешмасыннан мин киттем. Без халыкара хәлләр, колхозлар алдында торган бурычлар турында сөйли идек. Минем артист икәнне белгәч, докладтан соң берәр шигырь укуымны сорыйлар иде. Тора-бара бу бер чарага әверелеп китте. Кичәдән кешеләр күңеле күтәрелеп җанланып, бик канәгать булып тарала иде. Элеккеге Тәкәнеш районының бер колхозында, гадәттәгечә, докладтан соң шигырьләр сөйли башлагач, бер укытучы ханым: «Иптәш Яһудин! Сез операдан берәр ария җырлагыз әле!»— дип сорады. Мин:

— Беренчедән, мин җырчы түгел, икенчедән, музыкант та түгел, ә бу бәләкәй гармунда андый катлаулы музыка әсәрләрен башкарып булмый»,— дим.

Чыгышымны дәвам итеп, Ә. Фәйзинең «Гармун» шигырен гармунда уйнап сөйләгәч, теге ханым: «Менә опера шикелле булды»,— дип куйды.

Райком минем эшемә зур бәя бирде: «Әзәл Яһудин уздырган кичәдән соң, иртәгесен барлык колхозчылар эшкә чыктылар»,— дигән белешмә белән Казанга кайтып киттем.

1950 елда мин, Татар дәүләт филармониясенә күчкәч, Ә. Фәйзинең тынычлыкка багышлап язган «Бер йөрәктән бөтен илләрдә» дигән шигыре белән концертны башлап җибәрә торган идем. Шигырь тамашачыны бик дулкынландыра иде.

1942 елның җәендә Фатих Кәрим фронттан яраланып кайтты. Ул Казан госпиталендә үзенең «Кыңгыраулы яшел гармун» исемле мәшһүр әсәрен иҗат итте. Аны башта Хәким ага Сәлимҗанов өйрәнде һәм Бөтенсоюз театр җәмгыятенең тулай торагында бер төркем шагыйрьләргә сөйләп күрсәтте. Шунда минем башыма, бу әсәрне җыр-музыка белән бизәп эшләргә дә мөмкин бит, дигән уй килде. Ниятем барып чыкса, шәп булачак, чөнки ул елларда Казан госпитальләр шәһәренә әйләнеп, безгә аларда бик еш шефлык концертлары куярга туры килә иде. Бу әсәр исә нәкъ шундагы яралылар өчен язылган кебек. Мин көйләрнең халыкчан булганнарын сайлап, финалга 1942 елгы җәйге гастрольдә өйрәнеп кайткан «Дөм-дөм» көен керттем. Шуннан соң «Кыңгыраулы яшел гармун» госпитальләрдә, концерт залларында, төрле очрашу мәҗлесләрендә зур уңыш белән үтә башлады.

1942 елның декабрь азагында, Фатих Кәрим сәламәтләнеп, яңадан фронтка китәр алдыннан, язучы Фатих Хөсни мәҗлес оештырып, безне кунакка чакырды. Менә шунда мин әсәрне Фатих Кәримгә сөйләп күрсәттем. Фатих, дикъкать белән тыңлагач, торып басты да, дулкынланып кулымны кысты.

— Рәхмәт, Габделәзәл, минем йөрәктәгеп әйтеп бирдең! Халыкка да нәкъ шулай җиткер...— диде.

Шуннан соң аның белән бүтән күрешә алмадык. Менә шул вакыттан бирле Фатих дустыбызның искиткеч бу әсәрен башкарып киләм, һәр башкаруда залда Фатихның моңсу йөзен күргәндәй булам. Бу әсәр 1942 елдан шушы көннәргә чаклы минем тарафымнан 4000 тапкырдан артык башкарылды инде. Хәзер чәчләр дә бәсләнде, битләр дә җыерчыкланды, ә «Кыңгыраулы яшел гармун» мине әле һаман да яшәртә, дәртләндерә, яшәргә, эшләргә, иҗат итәргә өнди. Һәм мин киләчәктә дә бу әсәрне сөекле шагыйребезнең кадерле истәлеге итеп башкарачагыма ышанам әле.

Язма-көндәлекләремнең сәхифәләрен актаруны дәвам итәм. Менә тагын бер

исталек. 1974 елда безнең концерт бригадабыз, Сара ханым Садыйкова иҗатына багышлап, ил буйлап гастрольгә чыкты. Унынчы апрельдә Павлодарда Драма театры бинасындагы концертта «Кыңгыраулы яшел гармун» 7 минут урынына 10 минуттан артыкка сузылды. Чөнки һәр җыр, һәр җөмлә саен диярлек залда алкышлар куба, сүз бүленә иде...

Фатих Кәримнең «Гармунчы аю белән җырчы маймыл турында әкият»е дә байтак еллар сәхнәдә яңгырады. Бигрәк тә укучы балалар өчен оештырылган концертларда шәп үтә иде ул. Мин аны болай башлап китә идем: «Бу әсәр балалар өчен язылган, ләкин зурларга каратылган, ягъни кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла! шикелле». Бу әсәрдә Хәйдәр образы бар. Ә һәрбер авылда Хәйдәр исемле кешесе дә табыла бит аның, шунлыктан тамашачы һич тә битараф калмый торган иде.

1930 еллар ахырында «Чаян» журналында Нәкый аганың кызыклы бер әсәре басылып чыкты. Анда Тукайның колхозлашу чорында Казанга баруы һәм Кырлай кешесе, тракторчы Миңлебайга утырып, Казанга килеп җитүе гаҗәеп юмор белән тасвир ителгән. Бу әсәр хәзер дә минем репертуарымда саклана. 1935 елда мин Татар дәүләт академия театрының колхоз филиалына кердем. Филиалның художество җиткәчесе Гали ага Ильясов драма бүлеге белән яңа эстрада-концерт бригадасы төзеде һәм октябрь-ноябрь айларында Норлат, Кайбыч, Апас районнарында гастрольдә булып кайткач, Нәкый ага безгә искиткеч юмор белән язылган «Әптери абзый әкияте» исемле шактый күләмле әсәрен китерде. Бу әсәрне Гали ага Ильясов режиссерлыгында әзерләдек. Аның нинди уңыш белән баруын язарга мин сүз таба алмыйм. Безнең театр 1942 елның җәендә Татарстан районнарына гастрольгә чыкты. Репертуарда драма спектакльләре генә түгел, ә концерт программасы да бар иде. Мин «Әптери абзый әкияте»н концерт программасына керттем, ләкин автордан рөхсәт алып, ахырын бераз үзгәрттем. Әптери абзыйны трактордан төшереп, танкка утырттым да фронтка җибәрдем.

1949 елда Татар дәүләт филармониясе Салих Сәйдәшевнең Урта Азия республикаларында иҗат концертларын оештыра. Бу гастрольдә Әсма Шайморатова, Фәйзи Биккинин, Рәшит Ваһапов, Илдар Мәҗитовлар катнаша. Шушы гастроль уңае белән Нәкый ага «Татарстан сәламе» исемле махсус шигырь язды. 1950 елда мин филармониягә күчкәч, бу әсәрне җыр-музыка белән баетып, күрше республика һәм өлкәләргә гастрольгә чыкканда концертны шуның белән башлый һәм зур уңыш казана идем. Мин ул әсәрне берничә мәртәбә Нәкый агадан төзәттереп, республикабызда туган яңа үзгәрешләр белән баетып та алгаладым. Нәкый ага һич авырсынмый, үтенечемне берсүзсез канәгатьләндерә иде.

1949 елда ул вакытта Радиокомитетта эшләүче Зәйнәп Хәйруллина, мине очратып: «Әзәл, Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романында бер өзек нәкъ синең өчен язылган, дип уйлыйм, укып кара әле»,— дип киңәш бирде. Мин ул өзек белән танышкач, чыннан да, миңа бик кулай, сөйләргә бик тә мавыктыргыч икәнен күрдем һәм аны хәзерләдем. Ул өзекне «Шаһиевның өйләнүе» дип атап, аз гына җыр-музыка кушып, сәхнәгә чыгардым. Өзекнең герое, сугышчы мишәр егете Шаһиев блиндажда мишәрчә, бик матур итеп үзенең ничек өйләнүе турында сөйли, залдагы халык соклanып, көлә-көлә тыңлый. Бигрәк тә Рәшит Ваһапов белән йөргәндә, аның туган ягы, Горький өлкәсе авылларында аеруча яраталар иде бу әсәрне. Кайбер сүзләр мишәрчә әйтелмәсә, тамашачылар мине төзәтә иде. Мәскәүдә узган гастрольләрдә дә бу әсәр концертның иң отышлы чыгышыннан саналды. Мин аны озак еллар сәхнәдә башкардым. Мәрхүм Габдрахман Әпсәләмов бу башкаруга соклануын әйтеп, үзенең иҗат кичәләрендә катнашырга чакыра иде.

Көндәлек-хатирәләр дәфтәрендә классик шагыйребез Хәсән ага Туфан иҗатыннан ничек файдалануым турында шактый язганмын. Хәсән ага Туфан иҗатына мин 20 нче еллардан ук гашыйк. Аның «Соңгы мамонт» поэмасыннан «Башлана башланды» өзеге инде ул елларда ук күңелгә кереп урнашкан иде. Менә Туфаныбыз 37 еллар әҗәленнән котылып, исән-имин яңадан Казанга кайтып, иҗатка чумды. Һәм мин «Башлана башланды»ны Бөек Октябрь Социалистик революциясенең 50 еллыгына багышлап эшләнгән әдәби-музыкаль концерт программасына кертеп, «Хәерле юлга», «Татарстан булып калырсың» шигырьләре белән эстрада концертларын башлап җибәрә идем.

1980 елны Татар дәүләт филармониясенең лекцияле бүлеге Буада Хәсән ага иҗатына багышланган кичәләр уздырды. Анда мин зур программа белән чыктым.

Ләкин кайбер шагыйрь-язучының әсәрләрен, алар никадәр гүзәл язылсалар да, сәхнәдә яңгыратып булмый. Дөресрәге, мин яңгырата алмыйм. Чөнки әсәр башкару осталыгыма, иҗади үзенчәлегемә туры килми. Минем сәләтем, башлыча, юмор-сатирага күбрәк дисәм, ялгыш булмас. Менә шуның өчен кайбер бик хөрмәтле шагыйрьләребезнең әсәрләренә «тешем» үтми.



Рәсемдә: *Рәшит Ваһапов (артта, сулдан-уңга), Әзәл Яһудин, Гали Җәмлиханов; (алда) концертмейстер Ләлә Шиһабетдинова, биюче Зәйтүнә Фиткулова һәм җырчы Сәйра Сәләхетдинова.*

Мәсәлән, хөрмәтле шагыйребез Сибгат Хәкимнең шигырьләрен мин сәхнәдә гөрләтә алмадым. Берничә мәртәбә алынып та карадым, ләкин күңелем канәгать булмады һәм башкармадым. Менә аның 1972 елда «Казан утлары» журналында бөек шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган «40 нчы бүлмә»се басылды. Мине бу әсәр әсир итте, канатландырды, илһамландырды. Көчем җитсә дә, җитмәсә дә, өйрәнергә булдым. Һәм бар көчемне, тырышлыгымны, сәләтемне җигеп эшләп чыктым. Бу әсәрне мин төрле очрушуларда да, телевидение аша да башкардым.

Бари Рәхмәт хакында аеруча зур хөрмәт сүзләрен язар идем. Ул яңа иҗат иткән шигырьләрен миңа даими җибәреп торды. Һәм мин аның әсәрләрен аеруча бер ләззәт белән башкардым. «Көн дә иртәгә», «Тәмәке турында», «Бабай белән дедушка», «Әби белән бабушка», «Маһирә» һ. б. шигырьләре махсус сүз осталары өчен язылгандыр дип уйлыйм. Ул үзе дә үз шигырьләрен сәхнәдә үзенә хас осталык белән сөйли, халык тарафыннан бик яратып тыңлана иде. Хәтеремдә: 1957 елда Мәскәүдә узачак Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы алдыннан инфаркт белән авырды ул. Иптәшләр аңа: «Бари ага, сезгә борчылырга, дулкынланырга ярамый, сезнең шигырьләрне әнә Әзәл дә яхшы сөйли, ул сөйләсен»,— дигәч, Бари ага: «Юк, юк, үзем сөйлим, үзем. Мин терелдем инде, үзем сөйлим!»— диде. Союзлар йортында уздырылган әдәби кичәдә әсәрләрен укып искиткеч зур уңыш яулады, алкышларга күмелде һәм... чыгышын тәмамлап, урындыкка утыруга ук, авып төште. Сәхнә артына алып кереп идәнгә салуга, ике тапкыр гына сулу алды да күзләрен мәңгелеккә йомды. Менә сиңа шигъри сүзнең куәте!

Минем программада якташ шагыйрь Нәби Дәүлинең әсәрләре дә шактый урын алып тора. «Бәхетлеме кеше дөньяда?» һәм «Икмәк турында уйлар»ы аеруча еш укылды. Авылларда йөргәндә, бер концертта «Икмәк турында уйлар»ны башкаргач, бер агай: «Иптәш Яһудин! Сез бу шигырьне безгә генә түгел, Казан кешеләренә дә укыгыз!— дип зал яңгыратып кычкырды. Гомумән, мин сәхнәдән башкарылган әсәрләргә карата залдан йә тәкъдим, йә киңәш, йә киная белән әйтелгән көлке сүзләр ишетелә. Мәсәлән, шагыйрь Әнвәр Давыдовның «Казанга!»— дип сөйли башлауга, залдан берәү: «Квартира бирерсезме соң?»— дигән сорау ташлады, билгеле, бу сүзгә зал шаулап көлеп алды. Мин дә: «Яхшы ният белән килүчеләргә урын табылыр»,— дигән рәвештә җавап биреп, чыгышымны дәвам иттердем.

Кайбер шагыйрь иптәшләргә мин үзем мөрәҗәгать итәм. Чөнки еллар үткән, гомерләр узган саен репертуар да үзгәрергә тиеш. 70 яшьтә яшьлек мәхәббәте хакында җырлап йөреп булмый. Шәйхи ага Маннурның картлык турындагы кыска

шигырьләре «Тынгысыз картлыгым һәм бәхет» исемле әдәби монтажга бик ярап куйды.

Шәйхи Маннур, кайбер шигырьләрен бераз үзгәртүен сорасаң, якын да килми иде. Аның бер шигырендә: «Әйе, вакытында үлә белү кирәк. 70 яшь ул артык күп гомер».— дигән юллар бар. Мин: «Шәйхи ага, мин сәхнәгә чыгып, вакытында үлегез, дип әйтә алмыйм. Аны менә болайрак үзгәртсәң, яхшы булыр иде»,— дигәч, ул: «Юк, юк, үзгәртмим, ул инде басылган, шулай калсын»,— диде. Шул сәбәпле әлеге әсәр сәхнәдә бүтәнчә яңгырамады.

Шигъриятебезгә илленче елларда килеп кергән шагыйрьләр дә минем иҗатка җимне мул бирде. Көлке капчыгының иң зурысы — Гамил Афзал кулында. Кайсы гына әсәрен алма, барысы да бездәй артистлар өчен язылган кебек. Аның «Күрде безнең башлар» шигырен мин сөйләп туя алмыйм, тыңлаучылар тыңлап туя алмый. Шул кадәр оста ялганлый аның Гаптерәшкә агае, ялганына үзең дә ышанасың.

Шагыйрь Равил Фәйзуллин энекәшнең (ачуланмаса, шулай дияр идем) минем репетуарда булган шигырьләреннән бөтен бер программа төзеп булыр иде: «Яшәсен», «Минем телем», «Җирдә әллә ниләр бар», «Хыялга», «Минем эти», «Җанга якын җаннар китә тора»... «Картлык», «Кер чайкыйлар кызлар», «Улымның бар дүрт сүзе...» Берсендә Равил әле яңа гына машинкада басылган «Саубуллашу» исемле поэмасын бүләк итте. Бу әсәр нәкъ мине күздә тотып язылган, дип уйладым. Чөнки поэма авторы яшьлеге белән саубуллашып, башын югалтып, миңгерәүләнеп, каңгырап йөри дә, картлыгы килеп җитсә дә, барыбер яшьлеге дәвам иткәнен сизә. 70 не узып барганда, сәхнәдә гөрләп яшәү — яшьлекнең дәвамы түгелмени?

Алтмышынчы елларда күтәрелеп чыккан шагыйрьләрдән Фәнис Яруллин, Шамил Маннап, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гатауллин һ. б. минем программаны яңартыр өчен бик күп шигырьләр бүләк итте. Арада Ш. Маннапның миңа бик ошаган шигыре — «Мишәрләрем». Чөнки мин үзем дә мишәрләр токымыннан.

Озынга китте бит әле бу. Ләкин ни хәл итмәк кирәк, ярты гасырдан артыкка сузылган иҗат дәверемдә, әйтергә яраса, «тау кадәр» шигырьләр, йөзләгән шагыйрь-язучылар белән иҗади дуслык урнашкан бит.

Шулай да Башкортстан язучысы Ибраһим Абдуллинның «Иремне ничек акылга утырттым» исемле әсәре хакындагы бер кызыклы истәлекне языйм әле. Әсәрдә бер эчүче адәмнең кунаклар алдында ничек мактануы, шапырынуы, лаф оруы һәм аны хатынының магнитофонга язып алып, икенче көнне иренә тыңлатуы, ирен акылга утыртуы турында языла. Бер концертта мин бу әсәрне сөйли башладым. Залның уртадагы юлында үз урындыгында җәелеп бер кеше утыра. Халык әсәрдәге исерек кыланышларыннан көлә-көлә тыңлый, ә аның тирәсендә утырган тамашачылар бу кешегә төрле яктан: «Әнә үзеңә кара» дигән төсле төртеләләр. Ахырда бу кеше түзә алмый сикереп торды да:

— Бу дөрес түгел, артист дөрес сөйләми, мин алай кыланмыйм!— дип ачулана-ачулана клубтан чыгып китте. Әй, көлде дә соң халык!

Әйе, 57 ел буена сәхнәдә сөйләнгән әсәрләрнең барысын да телгә алу мөмкин түгел, бик күп якын шагыйрь, язучы дусларым искә алынмый калды. Моның өчен мин алардан гафу үтенәм.

1930-1949 еллар эчендә бирелгән концертларның санын-исәбен алмаганмын. Ә 1950 елда, филармониягә күчкәч, һәр концерт турында язып бардым. 1950-1987 еллар эчендә 6713 концертта катнашканмын. Һәрхәлдә, 1930-1950 еллардагы концертларны кушсак, барлыгы 10000 концерттан ким булмас. Бу язмаларым — шул юлда кичергәннәремнең күңелгә уелып калган иң истәлекле сәхифәләре.

**Рөстәм Зарипов**

# МИН КЕМНӘН КИМ?




бу ике катлы ишек аша үтүләре... Гозер белән киләсеңме, сүгәргә дәшеп алалармы — ике катлы ишек көтә... Килү белән үк кереп китү бәхете, билгеле, тәтеми. Әүвәле кабул итү бүлмәсендә бер-ике сәгать тозланасың, пешәсең, җитлегәсең, өлгерәсең. Аннары секретарь туташ әйтә: керергәме, әллә икенче дүшәмбедә килеп карарагамы. Рас йоласы шундый икән — сабыр итми чараң юк: син кемнән артык әле? — аркаң — дуга, бүксәң — капчык. Башкалар көтә ич, дермантин тышлы агач диванга тезелешеп. Әнә, бер читендә сиңа да урын калган.

Сыену почмагы һәм ризыгы шушында булган мәчеләр сыман, син күз теккән ишектән тоткарлыксыз керә-чыга йөрүчеләр байтак. Ул тук йөзле кешеләрнең эш урыннары, күрәсең, биредә.

«Бәлки чиратсыз кереп булыр?»— дигән өмет белән зарыктыручы ишек тирәли шыпан-шыпан урап та киләсең. Син якынайган чакта аннан берәрсе чыкса, җәһәт кенә кереп китеп булыр төсле. Ләкин бу — бары тик сукыр хыял гына. Чөнки секретарь дигәнебез гаять сизгер нәмәрсәкәй: уеңны адымыңнан ук чамалап ала да, бер генә акая, күн диван читенә ничек барып чүмәшкәнеңне сизми дә каласың. Инде хәләл чиратың җитеп, кердем дигәндә дә әлеге тутаң, сине туктатып, берәр Мыраубикә яисә Мыраужанны үткәрә. Ә болар, кабинетка керү белән, шунда бата, чыгарга кирәклеген бөтенләй оныта... Ә көткәндә — минутлар гасырга тиң. Күзләрең күгәреп, кан басымың уйнап, саруың кайнап, тешең сызлап, тез буыннарың дер-дер калтырый башлагач, ниһаять, гаделлек тантана итә, вәгъдә сәгате суга — морадыңа җитәргә берничә генә адым кала. Берәр әрсез алабае тагын юлыңа аркылы төшү шөбһәсеннән тизрәк ишеккә ташланасы килә. Тик ярамый, дисең. Менмәгән абруеңны төшерүдән куркып, ут йотып, тәкатьсез күңелеңне көч-хәл белән авызлыклап, салмак атларга тырышасың. Беренче кат ишекне узгач, аны һәйбәтләп ябасың. Уф... Инде шәт, иншалла, бәреп узып китмәсләр, дисең... Шулчак, үзенчә шаян, ә асылда ахмак бер уй миеңне бораулап куя: «Әгәр кергән ишегеңне кинәттән бикләп алсалар, ә каршы яктагысы ачылмаса?» Көлемсерәгән буласың. Шунда икенче уй миеңне кымырҗыта: «Әгәр ике ишек арасында син басып торган мәйданчык өскә менеп, яки аска төшеп китсә? Лифт шикелле?» Тамак кырган буласың. Караңгыда капшана-капшана, ашыга-кабалана ишек тоткасын эзләргә керешәсең. Йә алла, табыплар булмый лабаса... Шушы түгелме?.. Шушы гына булса ярар иде, ди-ди, тотканы үзеңә тартасың... Ачылмый! Көлмәкче буласың. Кая ди ул көлү, авыз гына кыегая. Аяк терәп тагын бер тартасың. Юк, алга китеш сизелми. Аркага тир бәреп чыга, борыннан тамчы тама башлый. Инде ике куллап, бөтен көчеңә йолкыйсың һәм бу шөгылеңнән тотка суырылып чыга башлагач кына туктыйсың. Димәк, алга юл юк... Бәлки артка чигенергә юл калгандыр? Артык өмет багларга да куркып, ике учың һәм күкрәгең белән кергән ишегеңә капланасың. Уф... Бусы ачыла икән, ичмаса... Шул-

вакыт, чыгып та житте бу дип уйлап булса кирәк, зарыгучылардан берничә кеше дәррәү күтәрелеп ишеккә томырыла. Житмәсә, секретарь туташ та каядыр чыккан, боларны туктатырга бер ырлавы да житәр иде кана. Нишләргә? Авыз ачып торсаң, сине йә читкә болгап, йә таптап ук үтеп китәчәкләр! Үзеңдә моңарчы тоймый йөргән өлгерлек белән, тотканы ике куллап, чүгәли төшеп үзеңә тартасың, ябырылучыларның борыны төбендә ишекне шапылдатасың! Бер генә мизгелгә караңгыда каласың.

Тарткан мәлдә теге ачылмый интектергән ишеккә артың белән кагы гына бәрелүдән дөнья ни өчендер капылт яктырып китә. «Кайдан, нидән бу?»— дип, башта аңышмый торасың; аннары, тынсыз калып, галстук белән шактый тыгыз кыршауланган муеныңны борасың, ишек шыр ачык, түрдә — күтәртелгән юл кебек тезелеп сузылган өстәлләрнең очында кемдер бар шикелле. Әле, шөкер, кабинет — ындыр табагыдай, ара — хәтсез, синең ни белән матавыкланганыңны бинокльсез абайларлык түгел. Кабинет буйлап йомшак келәмнән бата-бата бераз баргач, шәйлисең: чыннан да, түрдә берәү бар һәм ул берьюлы дүрт телефоннан сөйләшә икән. Моны күреп, бөек кешеләрнең берочтан берничә эш башкарырга сәләтле булулары искә төшә. Син якынайган саен, теге һаман үсә бара. Менә ул, тау кадәрле булып, өстәле артыннан чыга. Ә син — кечерәясең дә кечерәясең. Шулай да, аның башмагы биеклегенә калгач, кечерәюдән туктарга кыюлык табасың. Тиз генә аның ботинкасы өслеген ялап куясың, бауларын төзәткәлисең. Моны күреп, әзмәвернең күңеле йомшый, авызы ерыла. Әмма ерык авыздан да ата-баба ишетмәгән сүзләр тәкерек катыш мул чәчри. Син инде, ул тотып ашамагач, мондый гына күнекмәләргә бик разый...

Китешли, башыңны еш ия-ия саубуллашасың, абына-сөртенә бик озак артка таба чигенәсең. Ниһаять, ике катлы ишек арасына кереп, ялт кына юк буласың. Караңгыда, ялгыз калгач, шыпырт кына үсәсең. Аннары, чыраеңа бәхетле елмаю чыгарып, танавыңны күтәрә төшеп, кукраеп, зарыгучылар бүлмәсенә тәпи басасың.

Баш бераз әйләнә. Тәндә — ниндидер жиңеллек. Мөгаен, парашюттан сикерүче дә, аягы жиргә тигәч, шушындыйрак хис кичерәдер. Юк. Уен түгел ул — ике катлы ишек аша үтүләре. Миңа бигрәк тә. Чөнки портфельле булуыма әле ай да юк. Дөрес, минем үземнең дә кабинет булды хәзер. Нәни генә. Ләкин аның кимчелеге билгән мәйданында түгел, ә ишегенең бер генә катлы булуында. Килү белән кызыксындым бу хакта бухгалтердан. Нишләп әле, мин әйтәм, илдә юк нәрсә бездә генә, минәйтәм. Ни өчен ишекнең икенче каты куелмаган? Бухгалтерга нәрсә, бу эш сметада каралмаган, дип аклана. Юк инде! Үз хезмәт хакымны тотсам тотам, ике катлы ишекне барыбер ясатам! Мин кемнән ким — арка чокыр, күкрәк киң!

## «СУ АНАСЫ» ГАЕПЛЕ, ИПТӘШЛӘР!

*Шаян рецензия*

Җәмәгатьләштерелгән милекнең урлануы турында социалистик реализм ысулы белән иҗат ителгән бер генә күренекле әсәр дә юк. Бу — мәңге искермәс темага совет шагыйрьләренең салкын карашын берничек тә аклап булмый. Шигырь сөюче бүгенге яшь буын моны гафу итә алмый. Милеккә кумәкләшеп кул сузу чәчәк аткан заманда поэзия дуслары бу теманың ешрак һәм нәтиҗәлерәк яңгыравына һаман да өметләнәләр.

Татар поэзиясендә бу проблеманы кыю күтәреп чыгучыларның берсе Тукай булды. Якты мисал үрнәгендә аның «Су анасы»н күрсәтеп үтәргә булыр иде, ләкин шигырьнең җитди җитешсезлекләре моңа мөмкинлек бирми.

Әлбәттә, Тукай, көнкүреш чынбарлыгын царизм шартларында мифик персонажлар аркылы булса да тасвирлап, киләчәктә ниләр күрәсебезне алдан сиземләп, кисәтеп куярга — оешкан җинаятьчелек юлына киртә

салырга тырышкан. Әмма шигырь максатына тулаем ирешкәнме соң?

Билгеләп үтәргә кирәк: шигырьнең формасы да, эчтәлеге дә авторның җитлегүе турында сөйли. Ләкин тәнкыйтьче буларак, без Тукайның балачак хыялларыннан тулысынча арына алмавын һәм, шул сәбәпле, тормышны җитәрлек яхшы белмәвен күрсәтеп үтмичә булдыра алмыйбыз. Шигырьләрен типик булмаган геройлар белән «бизәве», чынлыкта очратып булмый торган образлар тудыруы моны ачык чагылдыра.

Зоология үзләштерүче сабый балалар да, бөтенләй үзләштермәгән яки үзләштерүдән ерак торучы урта белемле яшүсмерләр дә тереклек дөньясында су анасы һәм шүрәле кебек килбәтсез хайваннарның юклыгын бүген яхшы беләләр. Нужәли, Тукай кадәр Тукай әлеге геройлары урынына исеме-фамилиясе мәгълүм булган реаль персонажлар таба алмады икән?! Үз вакытында тәнкыйть тә бу мәсьәләне читләтеп узган.

Инде шигырьнең эчтәлегенә якын килик. Әсәрнең кереш өлешендә үк аңлашылмый торган фигыль очратабыз. «Башым белән суны сөзәм», — дип яза автор. Моны ничек аңларга?!

Сөзү-сөзешү өчен, аз дигәндә, мөгез кирәк. Гади авыл малаена каян килеп мөгез чыкты икән? Табигый органнары да формалашып бетмәгән малайга мөгез куюу шагыйрь өчен нигә кирәк булды икән? Кызганыч ки, бу сорауларга җавап табылмый. Бәлки, кайбер укучылар бу җөмләне су сөзү, ягъни суны чүп-чардан арындыру, фильтрлау мәгънәсендә аңламакчы булалардыр? Алай уйлаганда да, малайның башы бу вазифаны үти алмас иде. Ә инде ул заманнарда ир балаларның чәчләре пәке белән кырылып торуны күздә тоткан һәм, теләсә нинди елганың суы сөзмичә дә эчәрлек, саф булуын искә төшерсәк — шагыйрь әйтергә теләгән фикернең урынсыз булуы көн кебек ачык. Тел кытыршылыгын калдырып торыйк, бу хакта аерым сөйләү кирәк — рецензиянең максаты ул түгел. Шуңа күрә «Су анасы»на икенче яктан караш салыйк.


Шигырьнең исеме уңышсыз. Әгәр Габдулла Тукай бу шигырен «Ачык авыз» дип исемләгән булса, әсәрнең төп идеясе укучыга тизрәк барып җитәр иде, аның тормышында, гыйбрәтле кисәтү буларак, файдалы киңәшчегә әверелер иде. Һәм, кем белә, бәлки шигырь үзенең актуальлеген бүгенгә кадәр саклаган булыр иде.

Чыннан да, илдә урлашучылар, суммасы меңәрләп кенә саналучы киң масштаблы караклар өлгерү кәсафәтенә кем гаепле соң? Аннары каракларның ни гаебе бар соң бу эштә? Алар үз эшләрен булдыра алган кадәр әйбәт башкаралар, җиренә җиткереп эшлиләр! Әлбәттә, һәр эштә дә начар эшләүчеләрне табып була. Андыйларны караклар арасында да очратырга мөмкиндер — чөнки кайберләре бик тиз тотыла. Мисал эзләп ерак барасы юк — шигырьдәге нәни каракны да тотылучылар исемлегенә теркәмичә булмый — су анасы аңа: «Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак?» — дип тикмәгә генә кычкырмаган.

Ләкин, ни генә әйтсәң дә, шигырь сөюче дус, урлашу эшендә урлатучы ачык авызлар ныграк гаепле. Әйтик, үзен берникадәр тәртипкә китергән су анасы, яңадан суга чуму алдыннан, тарагын кулына кысып тоткан булса, нәни карак артыннан эссе дә, хәл бетереп, чабып йөрмәгән булыр иде. Ахыр чиктә максатка ирешеп, тарагын кулга төшерсә дә, су анасының нәни каракны башта ук куып тота алмавы йөрәк түрендә җанга ятмый торган юшкын калдыра. Әлбәттә, әсәр ахырында карак малай тотылырга тиеш иде! Автор ни өчендер бу малай актыгын коткарып кала — шәфкатьлелек күрсәтә! Габдулла Тукай су анасының физик әзерлеге түбән булуын аңлы рәвештә, басым ясагандай итеп күрсәтә, шул рәвешчә, барлык ачык авызлардан берьюлы көлә. Дөньясын да, тарагын да онытып су астына ташланырга гадәтләнгән су анасын акылга чакыра шагыйрь. Тик шулай да автор белән тулысынча килешәсе килми — урта яшьләрдәге су анасының басмада, иң кадерле һәм бердәнбер шәхси мөлкәте — алтын тараны калдыруы укучыны ышандырмый һәм бүгенге хуҗалык җитәкчеләренә бозык, тискәре йогынты ясый. Шуңа күрә ачык һавада, кар астында, саксыз, игътибарсыз калдырылган кыйммәтле байлыкларның югалуы, бозылуы һәм әрәм булуы бүген безне гаҗәпләндерми. Безнең хуҗасызлыкка, ваемсызлыкка исебез китми. Димәк, бу сыйфатларны тудыру вә үстерүгә Тукай да өлеш керткән. Гомере озын булып, тагын 25-30 ел яшәгән булса, Тукай, әлбәттә, бу шигыре өчен тиешле җәзасын алган булыр иде. Жданов белән Сталин, татарча аңламасалар да, Тукайны тәзәтергә җаен табарлар иде...

Яшь буынны, бигрәк тә мәктәпкә йөрүче бала-чагаларны иясез калган әйберләр һәрвакыт кызыктырган, җәлеп иткән. Алай гына да түгел — бүген аларны ияле, яхшы саклана торган хәзинәләр дә кызыксындыра. Заманыбыз шундый: көн саен үзгәреп тора — йә алга, йә артка таба бара, яшьләр җитез, уяу булып үсәләр. Әмма ләкин Тукайның «Су анасы»нда нәни карак акылга килә — әйберләргә тими башлый. Моңа кем ышансын?! Бүгенге колонияләр шундый малайлар белән шыгрым тулы, ә ирекгәгеләреннән мәктәп, мәгариф органнары, милиция һәм барлык башкарма комитетлар җәфа чигә. Ә кем җаваплы? Җавапны зыянлы китаплардан һәм «Су анасы» кебек уйламыйча язылган шигырьләрдән эзләргә кирәк, иптәшләр!

**Амур ШАКИРҖАНОВ,**
Казан.



## Акъегет

Акъегет (Рөстәм Габдрахман улы Фәйзуллин) хәзерге Балык Бистәсе районының Балтач авылында туа. Аның балачак һәм үсмер еллары шул ук районның Котлы Бөкәш, борынгы татар исемен йөрткән бәләкәй генә урыс авылы Түләк, Балык Бистәсе һәм Казанда үтә. Казан шәһәренең 82 нче мәктәбен, аннары Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. 1974 елдан алып Татарстан радио-телевидение комитетында хезмәткәр — бүгенге көндә ул радионың әдәби-драматик тапшырулар редакциясендә өлкән редактор вазифасын башкара.

Акъегет ике шигырь җыентыгы авторы: «Ак болыт шәүләсе» (1987 ел), «Төнге сулар» (1990 ел).



## Зиннур Хөснияр (Хөснетдинов)

1961 елда Биектау районының Бикнарат авылында туа. Зур Битаман урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Казан дәүләт педагогия институтында укый. Студент елларында һәм аннан соң «Ялкын» журналында эшли. 1984-86 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Татарстан радиосында хәбәрче булып эшли. Татарстан китап нәшриятында редактор хезмәтен башкара. Хәзер ул — нәниләр өчен чыга торган «Салават күпере» журналының баш мөхәррире.

З. Хөснияр — «Таң ата да кич була» һәм «Тәгәри китте язмышлар» китаплары авторы.



## Ләбиб Лерон

1961 елның 11 ноябрендә Мөслим районының Түреш авылында туган. Үсмерлек чоры Актаныш районы Олыймән авылында уза.

Казан дәүләт университетының филология факультетын 1984 елда тәмамлый. «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә, Язучылар берлегендә, телевидениедә эшли.

Бүгенге көндә — «Салават күпере» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире.

Ләбиб Лерон — балалар өчен «Яңгырның ял көне», «Транзистор үч ала», өлкәннәр өчен «Күрше тавыгы» исемле китаплар авторы.

## ЯЗУЧЫЛАР СЪЕЗДЫ

15 мартта язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Татарстан язучыларының чираттан тыш съезды булды. Аны кереш сүз белән Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев ачты.

Р. Мөхәммәдиев Татарстан Язучылар берлеге һәм «Туган як» җәмгыятенең Г. Исхакый исемендәге ел саен бирелә торган ике мең сумлык премия булдыруларын хәбәр итте. Әдәбият өлкәсендә зур хезмәтләр һәм иҗтимагый-сәяси тормышта актив эшчәнлек өчен бирелә торган бу премиянең беренчесе әдип һәм драматург Р. Батуллага тапшырылды.

Съездда СССР Язучылар берлеге идарәсе секретаре К. Скворцов чыгыш ясады һәм СССР Язучылар берлегенә яңа кабул ителгән каләмдәшләребезгә әгъзалык билетлары тапшырды.

Съезд ТССР Язучылар берлегенең һәм Әдәби фондының уставларын кабул итте, Язучылар берлегенә кабул итү коллегиясе һәм контроль-ревизия комиссиясе турындагы положениеләрне раслады. Шулай итеп, съезд суверен Татарстан республикасының мөстәкыйль Язучылар берлеген төзеде. Хәзер эшчәнлеген ул РСФСР Язучылар Берлеге аша түгел, ә турыдантуры СССР Язучылар берлеге белән алып барачак. Съездда шулай ук СССР Язучыларының IX съездына 17 делегат сайланды.

Аннары әдәби ел йомгаклары турында сөйләшү башланды. Жанрлар буенча Ә. Гаффар (чәчмә әсәрләр), Г. Морат (шигърият), Р. Игъламов (драматургия), В. Корчагин (рус язучылары иҗаты), Р. Корбан (балалар әдәбияты) докладлары тыңланды. Башка кайбер мөһим мәсьәләләр тикшерелде.

Съезд эшендә ТССР Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары Р. Шәмгунов, ТССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары М. Хәсәнов, КПССның Татарстан рескомы секретаре М. Галиев катнашты.

## РЕСПУБЛИКА ДЕЛЕГАЦИЯСЕ ТӨРКИЯДӘ

Соңгы вакытта Татарстан белән Төркия җөмһүрияте арасында ныклы элемтә урнашып килә; төрле дәрәҗәдәге делегацияләр алмашу да гадәткә керде.

Мартта, мәсәлән, Татарстанның нефть химиясе, нефть чыгару предприятиеләре, КамАЗ, тышкы сәүдә берләшмәләре вәкилләре Төркия бизнесменнары белән эшлекле очрашулар үткәрде, Анкарадагы, Адандагы һәм Мәрсиндәге кайбер предприятиеләрне карап йөрде. Татарстан белән Төркия арасындагы гамәлдәге экономик элемтәләрне ныгыту, уртак предприятиеләр төзү турындагы мәсьәләләр уйланылды.

«Совет Татарстаны делегациясенең Төркиягә визитының максаты җирле базарны өйрәнү, төрекләр белән тыгызрак багланышлар урнаштыру, халыкларыбызның мәдәни элемтәләрен ныгыту. Мин бу хезмәттәшлек республикабызга һәм бөтен Союзга файдалы булыр дип уйлыйм», — дип белдерде делегация башлыгы, республика Министрлар Советы Рәисе урынбасары Р. Ф. Моратов.

Татарстанның Төркия белән сәүдә мөнәсәбәтләренең нигезен нефть — республиканың төп экспорт продукциясе тәшкил итә. Быел Татарстан нефтьчеләре Төркия базарына 1 миллион тонна нефть җибәрәчәк. Шуңа алмашка республикага азык-төлек, киң куллану товарлары, дару кайтачак.

Татарстан делегациясен Төркия президенты Т. Озал, премьер-министр И. Акболыт, сәламәтлек саклау министры Х. Шывгын, мәдәният министры Н. Зәйбәк кабул итте.

## ТАТАРСТАН ВӘКИЛЛЕГЕ

Мәскәүдә Татарстан Республикасының даими вәкиллеге эшли башлады. Илчелекнең төп бурычы — үзәктәге хөкүмәт һәм хуҗалык органнары белән үзара бәйләнешне тормышка ашыру, Татарстан ССРга кагылышлы мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу.

Даими вәкиллекнең җитәкчесе итеп элек Мәскәү дәүләт университетының производствоны идарә итү кафедрасында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшләгән 34 яшьлек Шәүкәт Арсланов билгеләнде.

## НӘШРИЯТ-ПОЛИГРАФИЯ КОМПЛЕКСЫ

Татарстан ССР Министрлар Советы нәшрият-полиграфия комплексы төзү турында карар кабул итте. Яңа комплекста республика Югары Советы һәм Министрлар Советы, Казан шәһәренең халык депутатлары Советы һәм шәһәр башкарма комитетының газета-журналлары редакцияләре, яңа оештырылачак нәшриятлар урнашачак, газет һәм китап басу куәтләре булачак.

ТССРның экономика буенча Дәүләт комитетына һәм Финанс министрлыгына проект әзерләү һәм төзү эшләрен башлап җибәрү өчен акча бүлеп бирергә кушылды.

Шулай ук нәшрият хезмәткәрләре өчен торак йорт салу да күздә тотыла.

## НӘҮРУЗ БӘЙРӘМЕ

Быел Татарстанда өченче тапкыр Нәүруз бәйрәме үткәрелде.

Мәгълүм булганча, XVIII гасырга кадәр татар халкы яңа елны 21 мартта — көн белән төн тигезләшкән вакытта каршылаган. Кешеләр бер-берсен яңа көн туу белән котлаганнар, матур теләкләр әйтешкәннәр. Кызганычка каршы, бу матур йола озак еллар онытылып торган иде. Ниһаять, ул халыкка кире кайтарыла башлады. Нәүруз бәйрәме 21 мартта Казан яшьләр үзәге каршындагы концерт белән башланып мәдәният сарайларына һәм театрларга күчте, «Нәүруз чибәре — 91» конкурсында илебезнең төрле төбәкләреннән, чит илләрдән килгән чибәр кызлар катнашты.

24 мартта М. Җәлил исемендәге татар дәүләт академия опера һәм балет театрында «Нәүруз чибәре»нең йомгаклау кичәсе булды. Нәүруз чибәре булу өчен кызлар җыр-биюдә, рәсем ясауда, тел, гореф-гадәтләр, тарихыбызны белүдә дә көч сынашырга тиешләр иде.

«Ватан» җәмгыяте президенты академик Мирза Мәхмүтов, Австралиянең «Деталее» фирмасы президенты Рөстәм Садри, Мюнхендагы «Азатлык» радиостанциясе журналисты Фәридә Хәмит, «Сөембикә» журналы баш мөхәррире Роза Туфитулова һәм башка мәдәният һәм җәмәгать эшлеклеләре составындагы жюри Нәүруз чибәренең исемен атады. Ул — Гөлназ Сәлахова (Казан). Икенче гүзәл исеменә Гөлшат Галимова (Тукай районы, ТССР) лаек дип табылды. Кызларның икесе дә үзләре теләгән вакытта Австралиядәге милләттәшләребез янына бару хокукына ия булдылар. Өченче-дүртенче урыннарны алган Римма Нәбиуллина (Казан) белән Лилия Мортазинага (Уфа) телевизорлар бирелде. «Деталее» фирмасы, «Ватан» җәмгыяте, «Азатлык» татар яшьләре берлеге махсус бүләкләр дә билгеләгән иде. Польшадан килгән Лиля Кривицкая белән Әлфия Сәйфетдинова, мәсәлән, Бөтендөнья татар яшьләре көннәренә путевка белән бүләкләнделәр. Ул 22 июльдән 2 августка кадәр узачак.

Норвегиядән кунак булып килгән Шаһназ туташ Таһир да ярышта катнашты. Аңа 24 яшь. Быел Осло университетына укырга кергән. Сәхнәдән тамашачыларны тәбрикләгәндә дә, М. Гафуриның «Уян, татар» шигырен укыганда да күпләр Шаһназның матур сөйләм теленә сокланып утырдылар. Кызганычка каршы, конкурска килгән байтак кызлар туган телне камил белү җәһәтеннән артык мактана алмадылар.

## КОМПОЗИТОРЛАР КИҢӘШӘ

Казанда Татарстан ССР Композиторлар берлегенең чираттагы пленумы булды. Быел ул «Татарстан композиторларының яңа музыкасы фестивале» дигән исем астында узды. Пленумда катнашучылар А. Монасыйпов, Ф. Әхмәтов, Б. Мөлеков, М. Яруллинның яңа симфоник әсәрләрен, М. Шәмсетдинова, Ш. Шәрифуллин, А. Миргородский һәм башка композиторларның камера концертларын һәм башка әсәрләрен тыңлап фикер алыштылар.

## ТӨРЕК ИМАМНАРЫ КАЗАНДА

Мартта Казанга Төркиянең Истанбул һәм Самсун шәһәрләреннән имамнар килде. Кунаклар Әҗем мәчетен яңартутөзәтү эше белән таныштылар, Казанның тарихи һәм истәлекле урыннарында булдылар, мәчетләрдә дин тотучылар белән очраштылар.

— Төрекләр һәм татарлар тел туганнары,— диде Истанбул имамы Хәмид Сәл.— Бу аерата якынлык билгесе. Коръән Кәрим безгә дус һәм тату яшәргә, аралашып гомер итәргә куша. Дөрес, төрекләр һәм татарлар күп еллар буе бер-берсен онытып торырга мәҗбүр булдылар. Моннан без бернәрсә дә отмадык, киресенчә, халыкларыбыз кардәшлек тойгыларын югалта башлады. Иншалла, хәзер карашлар үзгәреп бара. Без моңа бик шат һәм делегацияләр алмашу шуны раслый.

## КОЛ ШӘРИФ ИСЕМЕНДӘ

Борынгы бабаларыбызның ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулуга багышлап республикабыз башкаласында салыначак мәчет Казан ханлыгы чорында яшәгән галим, эдип һәм дин эшлеклесе Кол Шәриф исемен йөртәчәк. Шәһәр Советы бу корылма өчен ун гектардан артык җир бүлеп бирде.

Ф. Әмирхан проспектындагы бу мәчетнең зур залы берьюлы мең кеше гыйбадәт кылуга исәпләнгән. Анда шулай ук 700 урынлы җыелышлар залы, 110 шәкерткә исәпләнгән мәдрәсә һәм тулай торак, кунак йорты, китапханә, типография, шәфкатьханә, спорт корылмалары булачак.

Мәчетнең 75 әр метрлы дүрт манарасы ерак-ераклардан күренеп торачак. Проектны Мөнир Агишев җитәкчелегендәге ижат остаханәсе әзерләде.

Мәчет салуга ярдәм итәргә теләүчеләр түбәндәге счетка акча күчерә алалар:

*ТРУ Госбанка. Татарский филиал молодежного коммерческого банка г. Казани. МФО 265005. р/счет 161601.*

## ПОЛЬША МӘЧЕТЛӘРЕ

Польша җирендә татарларның күпләп яшәве мәгълүм. Алар телләрен югалтсалар да, диннәрен һәм үзләренең татар икәнлекләрен онытмаганнар. Хәзер биредә милли яңарышка юл ачыла бара. Бүгенге көндә илдә 18 мәчетнең яңартылуы, төзәтелүе мәгълүм. Аларның кайберләренең 200-300 еллык тарихы бар. Былтыр Гданьск шәһәрендә биек манаралы тагын бер таш мәчет үсеп чыкты. Бу хакта Польшада чыга торган «Мөселман тор-

мышы» (баш мөхәррире Сәлим Хазбиевич) журналы хәбәр итә.

### ТАТАРСТАН ЛОТЕРЕЯСЫ

Мөстәкыйль Татарстан җөмһүриятендә беренче тапкыр акча-әйбер лотереясы үткәрелде. Аны «Болгар» фонды оештырды. Отышлар арасында Казан һәм Чаллы шәһәрендә квартиралар, җиңел автомобильләр, телевизор, суыткыч, кер юу һәм тегү машиналары, башка төрле кыйммәтле әйберләр бар иде.

Отышларны түләүдән калган акча борынгы дәүләтебезнең башкаласы — Шәһре Болгарның тарих истәлекләрен торгызуга тотылачак.

### И. ГАСПРИНСКИЙГА БАГЫШЛАНА

Кырымда бөек кырым татар гуманисты һәм мәгърифәтчесе Исмәгыйль бәк Гаспринскийның 140 еллыгы киң билгеләп үтелә. 19 мартта Симферопольдә аның тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган халыкара гыйльми конференция уздырылды. Кырым татар милли хәрәкәте вәкилләре белән бергә анда Польшадан, АКШтан, Төркиядән килгән галимнәр катнашты.

Конференциядә Татарстан галимнәре И. Абдуллин төрки телләрнең кайбер мәсьәләләре хакында, Р. Фәхретдинов «Алтын Урда һәм татар халкының этник тарихы» дигән темага доклад белән чыгыш ясадылар.

### НӘҖИП ҖИҺАНОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Татарстанның мәдәни җәмәгатьчелеге Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты, СССР һәм ТССР дәүләт премияләре лауреаты, композитор Нәҗип Гаяз улы Җиһановның тууына 80 ел тулуны киң билгеләп үтте.

Шул уңайдан фәнни-практик конференцияләр, композитор әсәрләреннән төзелгән төрле жанрдагы концертлар булды. Ул яшәгән йортка мемориаль такта куелды, консерваториядә аның музей бүлмәсе ачылды.

21 мартта М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында Н. Җиһановның тууына 80 ел тулуга багышланган кичә булды. Аны кереш сүз белән ТССР Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары Р. Шәмгунов ачты. Композиторның иҗаты турында ТССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары, филология фәннәре докторы М. Хәсәнов сөйләде. Кичәдә шулай ук Россия Композиторлар берлеге идарәсе рәисе В. Казенин чыгыш ясады.

### «ТУРГАЙ» ФИРМАСЫ

Татарстан Композиторлар берлеге янында «Тургай» исемле иҗади-производство берләшмәсе эшли башлады. Ул татар музыкасын тарату һәм пропагандалауны максат итеп куя. Фирма хезмәткәрләре композиторларыбыз әсәрләре һәм халык көйләре язылган магнитофон тасмаларын якташларыбыз күпләп яши торган төбәкләргә — Себер, Урта Азия якларына, Идел буе һәм Урал өлкәләренә җибәрә. Фирманың тавыш яздыру студиясе дә ачылды.

### ЯКТАШЛАР ОНЫТМЫЙ

Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылында үз заманының мәшһүр артисты, Сталин лагерьларында һәлак булган Мохтар Мутин музее ачылды.

Музейда артистның балачагын, аның тормыш юлын һәм иҗат эшчәнлеген чагылдырган фоторәсемнәр, М. Мутинның шәхси әйберләре, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә ул тудырган образларны гәүдәләндерүче башка экспонатлар белән танышырга мөмкин.

### КИТАПХАНӘГӘ — ШАГЫЙРӘ ИСЕМЕ

Татарстан ССР Министрлар Советы карары белән Әлмәтнең үзәк китапханәсенә күренекле татар шагыйрәсе Саҗидә Сөләйманова исеме бирелде.

### ТАТАР СӘНГАТЕ БӘЙРӘМЕ

Ленинградның «Лактио» акционерлык берләшмәсе 1991 елның июнендә «Татарт» дип исемләнгән күргәзмә-фестиваль үткәрә. Ул татар рәссамнары сәнгатенә багышлана һәм төрле төбәкләргә чәчелгән осталарыбызны бергә туплауда бер адым булачак. 1 июньдә Ленинградтагы СССР халыклары этнографиясе дәүләт музееның Мәрмәр залында ачылачак күргәзмә-фестивальне оештыруда Ленинградтагы татар мәдәният үзәге, татар телен һәм мәдәниятен саклап калу һәм үстерү фонды, җырчы Альберт Әсәдуллинның «Әл-Әсәд» театр-студиясе, аерым оешмалар һәм шәхесләр катнаша.

Белешмәләр алу өчен телефон: 238-17-07 (Ленинград).

### КЫТАЙЧА ДА ЯҢГЫРЫЙ

Казан дәүләт университеты профессоры, филология фәннәре докторы И. Нигъмәтуллина шактый еллар инде әдәби иҗатны заманча комплекслы тикшерү белән шөгыльләнә. 1983 елда Казан университеты нәшриятында аның рус телендә «Әдәби иҗатны өйрәнүнең комплекслы методологиясе» исемле китабы дөнья күргән иде. Яңарак мәгълүм булды: бу китап 1987 елда Пекинда Фәннәр Академиясе кытайча чыгарган «Эстетик һәм әдәби методология» исемле җыелма китапта һич кыскартусыз урын алган. Бу хезмәттә татар шагыйрьләре Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин иҗатына анализга һәм шигырьләренә дә зур гына урын бирелгән. Шагыйрьләребез кытайча да яңгырый алганнар.

## ТАТАРЧА ТРАКТОР

«КамАЗ» акционерлык җәмгыяте кечкенә тракторларны күпләп чыгарырга җыена. Шәхси хуҗалыклар өчен бигрәк тә уңайлы бу машина үзенең исеме белән дә игътибарны җәлеп итә.

Аның эмблемасы шестерня эчендәге «К» хәрефеннән һәм «КамАЗ»ның данын еракларга тараткан җитез тулпар сурәтеннән гыйбарәт, ә ишегенә матур хәрефләр белән «Батыр» дип язылган. Ленинградның «Киров заводы» белән берлектә камазлылар мондый «Батыр»ларны инде быел ук 100 данә чыгарачаклар.

## ЯҢА БАСМАЛАР

### «Халык чишмәсе»

Пермьдә шундый исемдә татарча өлкә газетасы чыга башлады. Аның беренче саны 5500 данә тираж белән дөнья күрде. Киләчәктә исә газетаның тиражын 15 меңгә җиткерү күздә тотыла.

Газета тәүге санында СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнарының диния назарәте рәисе шәйхелислам мөфти-хәзрәт Тәлгать Таҗетдин белән әңгәмә, укучы хатлары һәм Пермь өлкәсендәге татар мәдәни хәрәкәте җитәкчеләренең язмаларын, өлкәдә Һ. Такташ һәм Х. Туфан белән бәйле урыннар турында материаллар бирә.

Газета «Татарстан яшьләре» форматы белән дүрт битле итеп, ике төс белән бизәп чыгарыла.

### «Мәгърифәт»

Татарстан студентларының февраль аенда дөнья күргән яңа газетасы «Мәгърифәт» дип атала. Моңа кадәр татар студентлары шактый ук булса да, югары уку йортларында ана телендә бер генә басма да юк иде. Газетаны оештыручылар: Казан дәүләт университеты, консерватория, Казан, Чаллы, Алабуга педагогия институтлары, медицина, мәдәният, төзүче-инженерлар, финанс-экономика, химия-технология институтлары, «Азатлык» Татар яшьләре берлеге, редакциянең хезмәт коллективы.

Яңа газета чыгу уңаеннан Татарстан ССР Югары Советы Рәисе М. Ш. Шәймиев газета редакциясенә котлау җибәрде. Анда болай диелә: «Бу яңа басманың дөньяга килүе студент яшьләр, югары мәктәп җәмәгатьчелеге өчен генә түгел, республикабызның, халкыбызның иҗтимагый-сәяси тормышында да зур тарихи вакыйга. Газета суверен Татарстан Республикасы каршында торган зур бурычларны тормышка ашыруда яшьләребезне туплап, берләштереп торучы сәламәт көч булсын!»

Газета студентлар тормышын һәрьяклап яктыртуны үз өстенә ала.

Беренче санында, мәсәлән, игътибар вузларда милли мәсьәләгә юнәлтелгән. Әйтик, без соңгы елларда республика җитәкчеләре авызыннан еш кына вузларга татар студентларын кабул итү арта бара дигән хәбәрләр ишетеп киләбез. Чынлыкта бу эшнең киресе эшләнеп ята икән ләбаса. «Мәгърифәт» газетасында игълан ителгән таблицага карагандa, соңгы елларда вузларга татар студентларын кабул итү сизелерлек кимегән. Әйтик, 1980/81 уку елында Казан дәүләт университетына кабул ителгән студентларның 42,6 проценты татар булса, 1988/89 уку елында алар 34,8 процент кына. Казан химия-технология институтында бу чагыштырма 35,9 — 26,2, Казан дәүләт медицина институтында 51,7 — 45,7, Мәскәү энергетика институтының Казан филиалында 36,0 — 29,8.

Татарстан үз суверенлыгын игълан иткән заманда уйланырлык фактлар бу.

Газетаның баш мөхәррире — Рифат Фәттахов. Редакция адресы: *420008, Казан шәһәре, Ленин урамы, 18, университет, журналистика факультеты, «Мәгърифәт».*

### *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** төрек әдәбияты классигы Юныс Әмрәнең Төркиядә басылып чыккан юбилей җыентыгы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** әдип һәм галим, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Ибраһим Нуруллин.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

Бәясе 1 сум 50 тиен. Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСТАНА
(на татарском языке)